А. Г. ЯХИН

Әдәбият

10



А. Г. ЯХИН Әдәбият 10

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

диалог


юмор

юану

Мәктәп
символ

А. Г. ЯХИН

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек

ӨЧЕНЧЕ БАСМА

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән басыла

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2007

УДК 373.167.1:821.512.145*10
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Я89

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Укытучылар игътибарына!

Шушы дәреслек белән эшләү өчен, А. Г. Яхинның «10 нчы сыйныфта әдәбият дәресләре: Укытучылар өчен методик кулланма» дигән китабы ирекле сатуга чыгарыла.

Яхин А. Г.

Я89 Әдәбият : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 10 нчы с-фы өчен д-лек / А. Г. Яхин.— Өченче басма.— Казан : Мәгариф, 2007.— 375 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-7761-1729-9

ISBN 978-5-7761-1729-9
© «Мәгариф» нәшрияты, 2001
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2007

КЕРЕШ

Октябрь революциясеннән соң иҗат ителгән әдәбиятны «совет әдәбияты» диләр. Элегрәк «совет» сүзе өр-яңа, иң яхшы, иң алдынгы мәгънәсен аңлаткан. Без, «совет әдәбияты» дигәндә, илдә советлар хөкем иткән еллардагы әдәбиятны күз алдында тотачакбыз, ягъни аңа еллар чиген билгеләүче итеп кенә караячакбыз.

Әдәбият тарихын өйрәнгәндә, аның чорлары арасындагы бәйләнешкә аеруча игътибар итәләр: күчеш елларында чорларның уртак яклары һәм аерымлыклары аеруча ачык күренә.

Әдәбият чорлары бәйләнешенә, ягъни алар арасындагы охшаш сыйфатларга **традиция** диләр. Әдәбият, күпме генә үзгәрмәсен, барыбер үзенең төп эчтәлеген һәм шул эчтәлекне ачу алымнарын саклап кала. Һәр чор әдәбияты үзенең асыл байлыгын башка чорга мирас итеп калдыра. Башка чор аны алдагысына түкмичәчми тапшырырга тырыша. Традиция дип әнә шундый асыл байлыкка әйтәләр. Татар әдәбияты революциядән соң да электән тупланган бай мирасны саклап кала алганмы? Быелгы уку елында сез, әсәрләргә анализ ясап, шул сорауга җавап бирергә тиеш.

Әдәбият чорлары бер-берсеннән нык аерылалар. Аерма зур булуга карап, ул чорларга бүленә дә. Әдәбият чорлары арасындагы аермага **яңалык** диләр. Яңа эчтәлеге, эчтәлекне ачудагы яңа алымнары әдәбиятның үсешен, үзгәрүен күрсәтә. Быелгы уку елында сез, әдипләр иҗатына анализ ясап, шул яңалыкны табарга тиеш буласыз.

Совет чоры әдәбиятын да сез алдагы сыйныфларда үзләштергән белемнәргә таянып өйрәнәчәксез. Әлбәттә, яңа алымнар, атамалар белән танышачаксыз. Әдәбият теориясен яхшы белү сезгә мөстәкыйль уйларга, әдәби әсәргә карата үз фикерегезне булдырырга һәм аны матур, эзлекле итеп язарга ярдәм итәчәк.

Әдипләр, тормышны өйрәнеп, әсәрләр иҗат итәләр. Укучылар бу әсәрләр аша тормышны өйрәнә. Әмма әдәбиятның үзен дә өйрәнәләр. Аны өйрәнә торган махсус фәнгә **әдәбият теориясе** диләр. Әдәбиятның үзе кебек, әдәбият теориясе дә үсеп, үзгәреп

тора. Дәреслек теориянең соңгы казанышларын искә алып язылды.

Совет әдәбиятын берничә чорга бүлеп өйрәнәләр. Гражданнар сугышы еллары, егерменче еллар һәм утызынчы еллар әдәбияты дип, без дә өч чорга бүләчәкбез. Совет әдәбиятының башка чорлары белән сез алдагы уку елында танышачаксыз.

Без өйрәнәсе чор татар әдәбияты үтәр юлындагы киртәләр алдында тукталып та калды, аларны әйләнеп тә үтте. Бәрелде, сугылды, яраланды, ләкин өзлексез алга барды, чыныкты, яңа үрләр яулады. Татар язучылары әдәбиятыбызны шул еллардагы иң алдынгы әдәбиятлар рәтенә бастырдылар да үзләре югалдылар: гаепсезгә хөкем ителделәр. Ә тоткынлыктан бик аз кеше генә кире әйләнеп кайтты. Тоталитар система иң талантлы, иң кыю затларны харап итте.

Исеменнән үк күренгәнчә, матур әдәбият кешеләр мөнәсәбәтендәге матурлык өчен көрәшә. Әдәби әсәрләрне аңлап укыганда, әдипнең хисе, уе тудырган матурлыкны күреп шатланабыз. Язучының гүзәллекне тасвирлау осталыгына сокланабыз. Шатланганда, сокланганда, безгә шундый гүзәллек бүләк итеп калдырган әдипләрнең фаҗигале язмышын да истә тотыйк.

Дәреслектә күләмле әсәрләр бу юлы да кыскартылып бирелде, ләкин без аның сюжет сызыкларын, бәйләнешкә керүче сүзләрен, образларын, вакыйгаларын саклап калырга тырыштык.

ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Еллар исәбе белән санаганда, бу чор — әдәбият тарихының иң кыска чоры. Ләкин 1917—1922 еллар эченә сыйган тарихи вакыйгаларның күплеге һәм әһәмияте үткән заманның теләсә кайсы гасырына торырлык булды. Бу вакыйгалар илнең астынөскә китерделәр. Татар милләте язмышына да зур үзгәрешләр керттеләр.

ТАРИХИ ВАКЫЙГАЛАР

1917 елның февралендә патша Николай II тәхетеннән баш тарта. Гасырлар буена күп халыкларның хөкемдары булган Романовлар династиясе идарә эшеннән читләшә. Февраль революциясе дип шул вакыйгага әйтәләр.

Россиядә Вакытлы хөкүмәт төзелә. Дөрес, ул башлыча элеккеге министрлардан тора. Ләкин илдә кискен үзгәрешләр кирәклеген һәм бу үзгәрешләрнең тыныч юл белән реформалар ясап башкарылачагын яхшы белгән кешеләрдән оеша. Алар яңарышларны демократик юл белән хәл кылырга ниятлиләр. Дәүләт төзелешенең төп мәсьәләләрен хәл итәргә тиешле Ил корылтае (Учредительное собрание) җыярга карар кылалар. Корылтайга делегатларны мөмкин кадәр демократик юл белән сайларга тырышалар. Россия халкы белән беррәттән, татарлар да Ил корылтаена зур өметләр баглыйлар. Әдипләр татар милләтеннән делегатлар сайлауны зур дәрәҗә итеп кабул итәләр. Корылтайда катнаша алуларына шатланалар.

Урыннарда һәм үзәктә эшче, крестьян һәм солдат депутатларының Советлары төзелә. Илдә ике хакимиятлелек барлыкка килә. Алар арасында кискен көрәш башлана. Реформа туктала. Сугыш дәвам итә. Ил көннән-көн бөлә. Канәгатьсезлек артканнан-арта бара. Шундый авыр хәлдән большевиклар бик оста файдаланалар. Алар, акрынлап, Советларны үз кулларына алалар. Хакимияткә килү белән, сугышны туктату, халыкка җир, ирек бирүне вәгъдә итеп, эшчеләрнең, крестьяннарның һәм гаскәриләрнең шактыен үз якларына аударалар. Казармаларга кинәт

һөҗүм итеп, андагы коралны халыкка өләшәләр. 7 ноябрь көнне большевиклар, эсерлар, меньшевиклар җитәкчелек иткән гаскәриләр һәм кораллы эшчеләр Вакытлы хөкүмәт урнашкан Кышкы сарайга һөҗүм итәләр. Вакытлы хөкүмәтне кулга алалар. Хакимияткә большевиклар, эсерлар һәм меньшевиклар партиясе килә. Ләкин большевиклар хакимиятне беркем белән дә бүлешергә теләмиләр. Революциядә актив катнашкан бу партия вәкилләрен хакимияттән читләштерәләр. Аннары эзәрлекли башлыйлар. Беренче утырышларына җыелган Ил корылтаен көч кулланып тараталар. Аларның хакимиятне бөтен халык сайлаган парламент белән дә бүлешәселәре килми. Дин вәкилләре дә, интеллигенция дә, казакълар да идарә эшенә дәгъва кылмыйлар. Ләкин алар халыкны үз артларыннан ияртә алалар. Шуңа күрә алар да дошманга әйләнәләр. Партия һәм Совет хакимияте аларны да эзәрлекли башлый: чиркәү, мәчетләрне вата, дин әһелләрен төрмәгә яба, интеллигенцияне илдән куа, казакъларга каршы сугыш ача. Хәлле хуҗалыкларның милкен талау да ил эчендәге киеренкелекне арттырганнан-арттыра бара.

Шул рәвешле, Советлар үз дошманнарын үзләре тудыралар. Илдә озакка сузылган рәхимсез гражданнар сугышы башлана. Сугышларның яхшысы булмый. Әмма гражданнар сугышында дус дуска каршы корал күтәрә, ата — улы, туган туганы белән дошманлаша. Ил, дошман якларга бүленеп, үзен үзе һәлакәткә илтә. Шуңа күрә гражданнар сугышы аеруча аянычлы, әхлаксыз сугыш булуы белән аерылып тора.

Гражданнар сугышы татар милләтенә дә чиксез бәхетсезлек китерә. Хәзер ул, туган якны бөлдереп, канга батырып, авылларга, ишегалларына килеп керә. Мондый хәлнең XVI гасырдан бирле күренгәне булмый.

Татар егетләреннән Аерым укчы мөселман бригадасы исемле өч полктан торган гаскәр оеша. Бригада сугышның иң авыр урыннарында катнаша. Татар егетләренең батырлыгы турында тарихчылар, язучылар китаплар язалар.

Яңа хөкүмәт вәгъдә иткән тынычлык күп елларга кичектерелә.

Крестьяннар революциядән соң җирле булалар. Әмма үстерелгән иген хуҗасына эләкми. Аны кораллы көч белән кырыпсеберен алалар. Мондый сәясәткә х ә р б и к о м м у н и з м диләр.

ИДЕОЛОГИЯ

Идеология дип дөньяга нинди дә булса фәлсәфи, сәяси карашлар һәм идеяләр җыелмасына әйтәләр. Һәр партия, сыйныф яки җәмгыятьтә үз мәнфәгатен канәгатьләндерә торган идеология тудыра яки әзер идеология кабул итә. Җитәкчесе В. И. Ленин булган большевиклар партиясе Карл Маркс тәгълиматын кабул итә. Хакимиятне кулларына алганнан соң, марксизм илдә хөкем итүче идеологиягә әйләнә. Марксизм тәгълиматы бердәнбер дөрес, фәнни нигезләнгән тәгълимат итеп тәкъдим ителә.

Большевиклар **тигезлеккә, туганлыкка, иреккә** ирешүне үзләренең төп максатлары итеп игълан итәләр. Халыкны шул байрак астына җыялар, революциягә күтәрәләр һәм гражданнар сугышында җиңеп чыгалар.

Тигезлек, туганлык һәм ирек яулау халыкны бәхетле итәргә, бай матур тормышка китерергә тиеш була. Шундый матур тормышның якынрагына — «социализм», аннан да гүзәлрәгенә «коммунизм» диләр.

Марксизм тәгълиматы вәгъдә иткән бәхетле тормыш турында кешеләр гасырлар буена хыялланганнар. Шуңа күрә яңа хакимиятнең кызыктыргыч вәгъдәсен икеләнмичә кабул итәләр. Патша төшерелеп хакимият башына большевиклар килгәч, бу хыял тормышка ашар сыман тоела. Һәркемгә аңлаешлы юл күрсәткән большевиклар әлеге матур тормышның каһарманнары булып күренәләр. Революция һәм гражданнар сугышы елларында большевикларның үз идеяләренә фанатикларча бирелгәнлекләрен һәм сугыш кырындагы фидакарьлекләрен күрү бу ышанычны тагын да арттыра.

Марксизм тәгълиматы өйрәткәнчә, вәгъдә ителгән матур киләчәккә фәкать сыйныфлар көрәше нәтиҗәсендә генә ирешергә мөмкин. Көрәшкә тарту өчен, халыкка, милке күбрәк булган теләсә кемнең дошман булуын исбат итәргә кирәк иде. Большевиклар үз фикерләре булган һәм үзгә юлны сайлаган газета-журналларны ябалар. Башкаларын һәм яңа ачылган пропаганда чараларын сыйнфый көрәш идеясен исбат иттерү эшенә җигәләр.

Кешеләрдә дошманга нәфрәт уяту матбугатның төп бурычына әверелә. Кызганычка каршы, партия эшчәнлегенең бу эше күп еллар буена дәвам итте.

Матур киләчәккә ирешү чараларының икенчесе Россия революциясен бөтендөнья илләренә җәелдерү иде. Алар башка илләр пролетариаты да, Россия пролетариатыннан үрнәк алып, үз илләрендә революция ясаячак дип бик нык ышандылар.

Бөтендөнья революциясе булдыруны үзләренең изге бурычлары итеп санадылар.

Шәфкатьлелекне, миһербанлылыкны, сабырлыкны үзенең яшәү шарты итеп кабул иткән татар халкы өчен бу идеология әхлаксыз тәгълимат иде. Аның бердәнбер дөрес тәгълимат булуын халыкка аңлату бурычы матур әдәбиятка да йөкләнә. Гасырлар буена кешеләрне әхлаклы булырга өндәгән матур әдәбият хәзер үзенең изге бурычына хыянәт итәргә тиеш иде. Татар язучылары бу эшкә бардылармы? Бу сорауга җавапны әдәби әсәрләрне өйрәнгәч кенә әйтә алабыз.

ӘДӘБИЯТ

Татар язучылары Февраль һәм Октябрь революцияләрен шатланып каршы алалар. Гафур Коләхмәтов, Сәгыйть Рәмиев, Мәхмүт Галәү кебек халыкны сыйнфый көрәшкә чакырып иҗат иткән әдипләр өчен революция максатка ирешү юлы була. Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал кебек татар халкын берләштерү теләге белән янган әдипләргә ул теләкләренә ирешү өчен уңайлы шарт иде.

Ләкин революция, җиңү шатлыгы белән бергә, яңа сугышлар, гаделсезлекләр дә китерә. Халыкның тормыш шартлары начарланганнан-начарлана бара.

Язучыларның берише революцияне һәм гражданнар сугышын бөтен бер күркәм күренеш итеп кабул итәләр. Нәфрәт, дошманлык хисен матурлык итеп сурәтлиләр. Татар әдәбиятының бер тармагы шул рәвешле үзенең гадәти эчтәлеген алмаштыра: шәфкатьлелек, туганлык, сабырлык, игелек хисләренең матурлыгы нәфрәткә, дошманлыкка, үчкә күчә. Әдәбиятның бу яңа сукмагы революция тудырган яңа әдәбият дип мактала. Бу сукмактан башлыча яшьләр китәләр.

Әдипләрнең өлкәнрәк буыны халыкны берләштерү юлы белән милләтне үстерү идеяләренә тугрылыклы булып кала. Революция вәгъдәсе белән ул вәгъдәгә ирешү чараларының каршылыгын ачык күрәләр. Большевикларның хакимиятне кулларында саклап калу өчен күргән чаралары белән килешә алмыйлар. Гаяз Исхакый, мәсәлән, большевиклар идеологиясенең нигез ташына — сыйнфый көрәшнең мәҗбүриятлегенә каршы чыга:

«Бу көндә бөтен милләт бербөтен буларак кулга-кул тотышып хәрәкәт итәргә тиеш. Демократы, буржуасы, зыялылары, руханилары — һәммәсе, һәммәсе милләтнең һәрбер сыйныфы бөтенлек байрагы астында сәхнәгә басарга тиеш... Зыялылар

сыйныф байрагы урынына аннан өстә торган байрак күтәрә»,— дип, үзенең юбилей кичәсендә чыгыш ясый. Хәтта 1919 елда да Гаяз Исхакый бәхеткә сугыш аша гына ирешергә мөмкин дигән идеологиягә кыю рәвештә каршы чыга.

«Коллык мөһере ватылды»,— дип шатланып каршылый Фатих Әмирхан Февраль революциясен. Инде автономия алырбыз, татар гимназияләре ачарбыз, мәчетләр төзербез, дип хыяллана әдип. Ләкин милләттәшләрен бар булганны җимерүгә, дошманлашуга түгел, хезмәткә, бердәмлеккә чакыра. «Социаль революциянең төп максаты вату, җимерү түгел, бәлки төзү, төзү — бөтен адәм балалары өчен тигез, уңайлы, рәхәт һәм бәхетле, якты тормыш төзү»,— ди.

«Мобилизовать итми һәм тими торган булсалар, властьның кемдә булуының әһәмияте юк... Китапханәне дәвам иттерәсе иде»,— дип язып куя бу көннәрдә үзенең көндәлек дәфтәренә танылган драматург Мирхәйдәр Фәйзи.

Татар әдипләре шул рәвешле халыкны хезмәт итәргә, берләшергә чакырып чыгалар.

Татар әдәбиятының революциядән соң барлыкка килгән бу ике юлы үзара кушыла-аерыла, үзгәрә-алмашына, күп еллар буена сузыла.

Бу юлларның беренчесе телгә алып сөйләрлек уңышка ирешә алмады. Ләкин бу юлдан киткән әдипләр зурга дәгъвалары, куптарган шау-шулары белән әдәбият үсешенә шактый йогынты ясыйлар. Шуңа күрә әдәбиятның яңа юнәлеше белән дә беркадәр танышып үтик.

Мәҗит Гафури
(1880—1934)

КЫЗЫЛ БАЙРАК

Кара син алга!..
Күрәмсең анда
Кызыл байракны,
Буялган канга.

Көчле эшчеләр
Күтәргән аны,
Буялган аңа
Шәһитләр[1] каны.

Хөрлек, тигезлек —
Аның шигаре[2],
Һәммә байрактан
Тора югары.

Шунда хакыйкать,
Шунда чын иман.
Кузгал, эшчеләр!
Таң калсын җиһан.

Иткән тәҗәссем[3]
Халыкның көчен
Бу Кызыл байрак —
Шуның билгесе.

Кузгал, эшчеләр!..
Дошман җиңелсен,
Көч кемдәлеген
Бар дөнья белсен.

Кара көчләргә
Каршы торган ул,
Бирде бу юлда
Миллион корбан ул.

Бөтен кара көч
Аннан җиңелде,
Шуның чөн бүген
Югары эленде.

Бүген патша ул
Бөтен дөньяга,
Аңа нинди көч
Каршы торала?

Егылды инде
Башка әләмнәр,
Җиңелде инде
Залим адәмнәр.

Әй кызыл байрак,
Нур бир җиһанга!..
Әйдә, эшчеләр,
Алга вә алга!..

1917 ел

---

[1] Шәһитләр — сугышта хак эш өчен корбан булучылар.
[2] Шигаре — лозунгысы.
[3] Иткән тәҗәссем — гәүдәләнгән.

Биремнәр һәм сораулар

1. Әсәрләргә анализ ясауның иң гади алымын исегезгә төшерегез.
2. Шигырьне ике өлешкә бүлү өчен нигез табыгыз.
3. Кызыл байрак сыйфатларын санагыз.
4. Эшчеләргә автор биргән сыйфатларны табыгыз.
5. Ике өлешнең үзара бәйләнеше турында сөйләгез.
6. Бирем җавапларыннан чыгып, М. Гафуриның революциягә карашын белегез.
7. Сезгә бу шигырь ошадымы? Ошаса ни өчен ошады, ошамаса ни өчен ошамады?

Шамун Фидаи
(1902—1920)

Шамун Фидаи (Касыйм Хәсән улы Шакирҗанов) Оренбург шәһәрендә туа. Касыйм мәдрәсәдә укыганда ук шигырьләр язып газета-журналларда бастыра башлый. Революциянең бөек һәм бик кирәкле бер хәрәкәт булуына чын күңелдән ышана. Бик яшьләй аның ялкынлы көрәштәше булып китә. 18 яше дә тулмыйча шул юлда һәлак була.

Шамун Фидаи талантлы шагыйрь була. Менә аның лирик шигырьләре.

ТУКАЙ

Төн иде. Моңнар белән
Чиртеп сазын, ул җырлады;
Моң белән, хәсрәт белән
Тулган иде бар җырлары.

Тыңлады урман вә таулар,
Тыңлады ай, йолдызы...
Шул моңыннан уйга калды
Җир кызы һәм Күк кызы.

Атты таң әкрен генә,
Һәм сүнде йолдыз, сүнде ай,
Шул матур йолдыз белән
Әкрен генә сүнде Тукай.

ҖЫРЛА ӘЛЕ

Сандугачкай, җырла әле,
Нурлы җырлар чәчкәләп,
Шат җырың, ямьле моңың
Берлә күңелне ачкалап...

Бар күңелләрдән агым
Моң ташкынын таштыр әле!
Уй белән, моңнар белән
Аштыр әле, шаштыр әле!

Ә менә түбәндәгесе яңа рухта язылган:

* * *

Мөкатдәс хәнҗәрем төшмәс кулымнан,
Бөтен сәдне[1] кисәрмен мин юлымнан.

Очабыз, без шулай мәңге очарбыз...
Килер бер көн — сәгадәтләр[2] кочарбыз...

Бәхет бакчасына барып керербез,
Сәгадәт чәчкәсен өзеп йөрербез.

Биремнәр

1. Соңгы шигырьнең алдагыларыннан төп аермасын табыгыз.

2. Соңгы шигырьне Мәҗит Гафуриның «Кызыл байрак» шигыре белән чагыштырыгыз. Лирик геройларның охшаш якларын күрсәтегез.

Мәхмүд Максуд
(1900—1962)

Мәхмүд Максуд Татарстан Республикасының Саба районы (хәзерге Теләче районы) Югары Кибәхуҗа авылында мулла гаиләсендә туа. Мәдрәсәдә, училищеда укый. 18 яшеннән газетада эшли башлый. Гражданнар сугышында катнаша. Дәреслектә бирелгән әсәрләрен ул гражданнар сугышы елларында 19 яшендә язган.

ИЗГЕ КӨРӘШКӘ

Рәхим җиңеләеп китте. Үзен бер кайгысы да булмаган сабый дип сизә башлады.

— Күптән кирәк иде! Әллә кайчан ук инде шул кабахәткә каршы корал күтәреп чыгарга иде.

Соң булса да акылга утыруына, соң булса да хакыйкатьне аңлавына, соң булса да изге көрәш юлында үзенең җанын фида кылырга сүз бирүенә шатланды, куанды.

Күңелле һәм күңелсез истәлекләрдән торган уй диңгезенә чумды.

---

[1] Сәд — киртә.

[2] Сәгадәт — бәхет.

Әнә аның сабый вакытлары, иртәдән кичкә кадәр йөгерә-йөгерә уйнап йөрүләре.

Әнә аларның авылындагы кечкенә генә мәктәп, әнә андагы кырган мыеклы, каеш түбәтәйле хәлфә. Аның камчысы. Сабый баланың аркасын чыж-чыж яра торган шәфкатьсез камчысы.

Рәхим шул мәктәптә укып йөри. Әнисенә, әтисенә кайтып елый, садакага алып барырга дип, акча сорый. Аларның: «Каян алыйк соң юк акчаны, чәебез дә юк бит әле,— дип бирмәүләре,— кыйнаса да түз, хәлфәң суккан җир тәмугта янмас»,— диюләре...

Ул унөч яшьләренә җитә. Апасы һәм әнисе белән уракка һәм башка кыр эшләренә йөри башлый. Авылдагы Вәли байларның тиресләрен түгә. Ат дулатуы өчен, бай малаеннан чыбыркы эләгә. Тагы әниләренә кайтып зарлана, тагы елый. Рәхим аптырый. 18 яшьлек бай малаеның тик йөрүенә, унөч яшьлек баладан кыйный-кыйный, тирес ташытуларына аның башы җитми.

14 яшькә җиткәч, аны Казанга, үз авылларыннан китеп баеган Зәйниләргә җибәрәләр. Анда ул идәнен дә, ишегалдын да себерә, карын да көри, еш кына абыстайдан колагын бордыра. Рәхим, күз яшен коеп, әнисенә зарлана: «Әнием, җаным, зинһар, мине моннан алып кит»,— ди.

Шәфкатьле бичара ана үзе дә еламый түзә алмый: «Балам, өйдә синнән башка да өч бала бар. Әтиең картайган, ашарыбызга юк. Менә әле аз гына булса да файдалары тия, чирек чәй бирделәр. Түз, балам, түз!» — ди.

Рәхим барына да чыдарга риза була. «Алла аларны бай итеп, безне ярлы итеп яраткан шул, түзми хәлең юк»,— дип куя.

Менә шул караңгы көннәрнең барын да ул күңеленнән үткәрде. Шкафтагы газеталарга, китапларга күзен төшерде. Аларга әллә нинди бер хөрмәтләү, иркәләү белән карап торды. Җанлы нәрсәгә эндәшкән кук: «Рәхмәт сезгә, сезнең аркада соң булса да уяндым»,— диде. Совет власте һәм большевиклар партиясе турында китаплар биреп калдырган агитатор абыйны хәтерләде.

Үзенең ярлы булуын Алладан түгел, бәлки байның кеше талавы аркасында икәнлеген, үзенең әллә никадәр чыбыркы ашавына һаман да шул байның ерткычлыгы сәбәпче икәнлеген белүенә шатланды. Шул байларга каршы көрәшүнең, дөньяны эшчеләр дөньясы итеп кенә калдыру өчен булган көрәшүнең изге бернәрсә икәнлеген аңлавына куанды. Ата-анасын, алардан да кадерлерәк булган тагын бер кешесен калдырып, дошманга каршы китәргә карар бирүенә шатланды.

Унсигез яшьлек батыр егет, тагын бер тапкыр күкрәген киереп: «Түздем, бик күп түздем. Ярлыларны талау нигезендә генә корылган дөньяларын үземнең көчле кулым белән җимерәм. Җимерәм дә тынычлык, туганлык дөньясы төзим!» — дип ант итте.

1919 ел

КАРАВЫЛДА

Тулган айның серле нуры бөтен дөньяны ямьләндергән. Әкрен генә искән җилдән яр буендагы агачлар җилфердиләр. Әллә кайда, еракта сандугач сайрый. Шул матур төндә әллә кайларга китәсе, матур көймәләрдә йөрисе, аннан теге яктагы калын урманга чыгасы, серле төнне серле урманда үткәрәсе килә.

Ләкин шул калын урманны искә алу белән, күңелдәге матур тойгылар бер минут эчендә юкка чыгалар, алар урынына ачу тойгысы, нәфрәт-җирәнү тойгысы уяна. Әнә шул урманда, шушы матур елганың теге ягында гына дошман торганлыгы, шул матур дөньяда адәм балаларын җәфа чиктерергә теләгән, мең төрле михнәтләр эчендә яшәтергә теләгән дошман торганлыгы искә төшә. Шул дошман тарафыннан анда әллә никадәр эшчеләрнең җәберләнүләре искә төшә.

Искә төшә дә дошманга булган ачу тойгысы кабарганнан-кабара бара; тизрәк әнә шул кабахәт дошманнарны юк итәсе килә; дуслык-туганлык дөньясының ямьле кояшы хезмәт ияләрен иркәләсен өчен, тизрәк дошманны бетерәсе килә.

Күңел дулкынлана. Ай үзенең нурын сибә. Агачлар җилферди. Сандугач сайрый: «Сабырсызланма, туганкай, сабырсызланма. Тиз көннән син аларны җиңәрсең. Тиз көннән биек тау башларында, очсыз-кырыйсыз диңгез буйларында син кадаган кызыл байрак җилфердәр. Минем җырым сафланыр, матурланыр. Мин синең эшеңне, синең көчеңне мактармын. Әлегә кадәр ишетелмәгән җырлар җырлармын, көйләр көйләрмен», — ди ул.

1919 ел

Биремнәр

1. Хикәяләрнең уртак төзелешен табыгыз.
2. Авторның каршылыклы ниятләре турында сөйләгез.

Фәтхи Бурнаш
(1898—1942)

Фәтхи Бурнаш хәзерге Чувашстан Республикасының Батыр районы Бикшик авылында мулла гаиләсендә туа. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, гимназия программасы күләмендә, үзлегеннән әзерләнеп имтихан тота. Казакъ далаларында балалар укыта, хәрби хезмәттә була, гражданнар сугышы елларында яңа чыга башлаган совет газета-журналларын оештыра, «Кызыл Армия», «Татарстан», «Чаян» газета-журналларының редакторы була. Ф. Бурнаш — күп санлы шигырьләр, поэмалар, пьесалар авторы. 1939 елда хаксызга кулга алына һәм төрмәдә үлә.

ЧӘЧӘКТӘН ҺӘЙКӘЛ

I

К ы з.

Кал, тидертмәм дошманыңнан,
Кал минем өчен, күз карам!
Кал — утыннан, укларыннан —
Өскә алам мин —
                коткарам.
Мин табармын аулак өйләр,
Мин табам почмак сиңа.
Төннәрен сакта булырмын,
Мин чүгәрмен каршыңа...
Без торырбыз бергә-бергә,
Ал сүземне — рәнҗемә!
Кал, чибәрем,
Кал, шикәрем,
Шат яшәрбез мәңгегә.

Е г е т.

Ишетәсеңме,
Таш каланы селкетә дошман уты.
Күр әнә
        күпме яралы,
                сызланучы,
                        янучы.
Ишетәсеңме, дошманын сизгән дә
Үксеп ил елый.

Ил елый,
Гөлчәчәкләр белән бизәлгән җир елый.
Ул елар, бәгърем, елар,
Дошман чигенгәнгә кадәр.
Син сорама — мин кала алмыйм,
Мин китәм дуслар белән;
Ташламаска мылтыгын
Ант иткән иптәшләр белән.

Кыз.

Бервакыт бит син мине сөйдең,
Саташтың, назладың;
Ташламаска вәгъдә бирдең бит,
Җаным, күңлең ярын...
Акрын-акрын инде мин
Юкка бәрабәрме сиңа?
Әллә күңлең почмагы тар
Булдымы инде миңа?

Егет.

Син һаман каршымда зурсың.
Тик хуҗасың син генә,
Тик...
барыннан да якын җанга
Ирекле ил генә...
Ул гына...
Тик шул гына
Яшь күңлемә ялкын сала,
Шул азат ил—көн өчен
Сыкрап күңел күркем кала.
Мин китәм эзләп
Туган илнең ирекле юлларын.
Ул мәхәббәттән бөек —
Шул юлда чыксын бу җаным...

Кыз.

Кал, дидем — юк!!.
Кил, дидем — юк!..
Әйт:
Кая соң баш куйыйм?
Ал, алайса!..
Армиягә мин дә бер юлдаш булыйм.



Егет.

Ишетәсеңме:
Инде дошманнар якынлашкан бугай,
Күр, шәһәрнең читләрендә
Дошман урнашкан бугай.

II

Таш каланың өсләрендә
Гөлт тә гөлт ут ялтырый.
Яңгырап туп,
Кыз белән бу яшь егеттән
Җан сорый.
Кыз белән баскан егет шунда —
Икәүләп серләшә;
Сөйләшә дошманга каршы,
Берләшергә гүргәчә;
Инде кыскан кыз бала
Кулда авыр винтовкасын;
Алга тезгән патронын һәм
Янга таккан сумкасын.
— Ут ачарга! —
Дип, кинәт
Егете аның алга чаба;
Ул чаба; күз атмый алда
Дошманыннан башкага;
Йөгерә гаскәр!

Йөгерә кыз, калмый егеттән, ут ача,
Ут ача дошманга,
— Бетерик,—
дип,—
Шуларны таңгача...

III

Гөрли тагын да шәһәр.
Кергән аңарга башка төс:
Башка рух, башка халык,
Башка сугышчы, башка көч.
Ак генерал чат саен
Эшче халыкны астыра,
Ак палачлар
Җан кыеп,
Берсе береннән арттыра.

IV

Шул вакытта
Бу батыр, бу кыз бала
Яшрен генә
Кулларында нәрсәдер китерә
Үзенең йортына...
Кечкенә бер бакчада, чатта
Хәзерләнгән кабер...
Кыз бала килде кабергә —
Шатлана бер, курка бер...
«Бирмәдем бәгърем тәнен дошманга»,—
Ди, бер шатлана;
«Күрмәдем шатлык таңын...» —
Ди дә, күзеннән яшь тама.
Куйды акрын корбанын
Бу кыз соңыннан кабренә,
Койды туфрак өстенә...
Ләгънәтләр әйтте бәхтенә...

V

Һәр көн иртән
Инде шуннан соң
Бу кыз гел таң белән
Чәчкәгә бизи башлады кабрен
Күзендә кан белән.

Бу кызыл чәчкә
Кубәйгәннән-кубәйде
ел саен
Ул кызыл һәйкәл
Кызарганнан-кызарды ел саен.
Үстерер булды
Шулай саклап,
Карадай күздәге;
Һәм сугарды дәртле хатирә белән
Көн саен кыз
Ул гөлләрне.

1919 ел

Биремнәр

1. Әсәрнең сюжетын һәм төзелешен әйтеп күрсәтегез.
2. Әсәр төзелешеннән чыгып, авторның әйтәсе килгән фикерен аңлатыгыз.

Галиәсгар Камал
(1879—1933)

«КЫЗЫЛ АЛМА» КИТАБЫ

Күрең кызыл кодрәтен,
Белсен, диеп, куәтен,
Совет җөмһүриятен
Нинди күрекле кыйлдыя.

Халыкларны кыйлды азат,
Буржуйлар китте назад,
Алпавыттан һичбер зат
Калдырмады, тидия.

Бай, алпавыт яки поп,
Аксөякләр хәзер юк;
Һәммә кеше бертигез —
Серый шинель кидия.

Байлар бик күп йөрделәр,
Төрле рәхәт сөрделәр,
Бу көннән соң эшче йөрер
Дышлаларда[1], тидия.

Бай бик тәкәббер иде,
Карамады мужикка,
Инде ул килә ишеккә
Икмәк сорап, тидия.

Ята алмассыз эшсезгә,
Без табарбыз эш сезгә,
Булмас җәбер көчсезгә
Бу көннән соң, тидия.

[1] Дышла — бер тәртәле арба, фаэтон.

«БӘДӘВАМ» КИТАБЫ

Түш киермәк байга юк,
Шикәр дә юк, май да юк;
Кара икмәккә һәркем тук
Бер чамада, бәдәвам.

Рус, татары, болгары,
Немец, французлары —
Ярлы халыкның бары
Берләшүдә, бәдәвам.

Бай акча өчен җылый,
Чөнки ул — акча колы:
«Калам бит инде коры
Кул белән»,— ди, бәдәвам.

Җәберләнде күп кеше,
Талау иде бар эше,
Җылаганда ач кеше,
Көлеп торды, бәдәвам.

«Мин бай», диеп йөргәне,
Ярлылардан көлгәне,
Үз башына булганы
Күрнә инде, бәдәвам.

Байга үләргә генә,
Безгә көләргә генә,
Малын бүләргә генә
Калды инде, бәдәвам.

ЯҢА «БАШМАК» КӨЕ

Башмагымның башы башка,
Аерылды әләгеп ташка,
Киярлек түгел — чыгарып ташла,
Бирче яңа башмагымны.

Бу эшкә хәйран калырлык,
Олтаны кәгазь калынлык,
Акча юк бит тагы алырлык,
Юкка кидем башмагымны.

Башмак башы бик зур тишек,
Әйтерсең лә ачык ишек,
Киярга инде буны ничек,
Мә, ал кире башмагыңны!

ТАТАРГА

Юкка уздырма көнеңне юк кына гайбәт белән.
Кулда бар көч, эшлә дә тап, эшлә зур гайрәт белән.

Ташла кеше җилкәсе өстеннән ашауларыңны.
Бергәләп бар, калма артка, син дә алгы рәт белән.

Тынма, эшлә, тынма, тырыш, булма, туган, аксөяк,
Эшләмичә тик ятучы селкетә алмас аяк.

Биремнәр һәм сораулар

1. Г. Камал дошманнарның көчен киметеп, ә революция яклы көрәшүчеләр көчен, киресенчә, арттырып күрсәтә. Ни өчен шулай итә? Бу аның үз бәясеме?

2. Такмакларында Г. Камалның тормыш чынлыгы турында әйткән урыннарны табыгыз.

3. Такмакларда идеология дә, тормыш чынлыгы да янәшә киләләр. Шул янәшәлекнең сәбәбен ничек аңлатыр идегез?

Сыйнфый көрәш темасына багышланган әсәрләр

Гражданнар сугышы елларында күләмле чәчмә әсәрләр язылмый. Ә менә пьеса һәм поэмаларның саны арта.

Поэма — әдәбиятның тезмә төренә керә, чөнки шигырь кануннарына буйсындырылып языла. **Шигырь белән язылган сюжетлы, күләмле әсәрләргә поэма диләр.** Фәтхи Бурнашның сезгә таныш «Чәчәктән һәйкәл» әсәре — бу елларда иҗат ителгән поэмаларның типик үрнәге. Гражданнар сугышы елларында иҗат ителгән поэмаларның эчтәлекләрендә охшашлык зур. Хәер, бу елларда язылган шигырьләр, хикәяләр, хәтта пьесалар турында да шундый ук сүзләр әйтергә мөмкин булыр иде.

Мәсәлән, Мәҗит Гафуриның «Кызыл байрак» шигыре халыкны революциянең табигый һәм хаклы җиңү булуына ышандыра. Моңа ул үзе дә чын күңелдән ышана. Февраль революциясе халыкка ирек һәм бәхет алып килде, дип уйлый. Ярлыларны чиксез көчле, байларны мескен, көчсез итеп сурәтли. Фәтхи Бурнаш, Галиәсгар Камал, Мәхмүд Максуд һәм башка бик күпләр шул рәвешле язалар.

Әлеге рухта иҗат иткән әдипләрнең барысы да матур киләчәккә, революциянең көченә, чын күңелдән ышандылар. Халыкны байларга каршы көрәшкә чакырып, матур киләчәккә ирешүдә өлеш кертәм, дип уйладылар. Әдипләр ярлылар көчен күкләргә чөеп мактадылар. Көч үзеннән-үзе хаклыкка әйләнде.

Бу елларда иҗат иткән әдипләр кешеләрне ике капма-каршы якка бүлделәр. Шуларның көчле, димәк, хаклы ягы әдәбиятта пролетариат, Кызыл Армия, халык (масса) рәвешендә сурәтләнде. Язучылар үзләрен дә көчлеләр сафына бастырдылар. Шуңа күрә җиңүче массаны «Без» дип атадылар. Бу елларда хәтта лирик герой да шәхес булмады — массаны гәүдәләндерде. Образның бер сыйфатын гына аеруча күпертеп сурәтләгән әдипләргә, романтик язучылар диләр.

Әдәбиятның бу чоры романтик язучыларга бай булды.

Галимҗан Ибраһимов
(1887—1938)

ЯҢА КЕШЕЛӘР

Драма өч пәрдәдә

КАТНАШУЧЫЛАР:

Хәйри — авыл бае, таза, нык, гайрәтле; яше 55 ләрдә.

Зөһрә — Хәйринең яшь хатыны; чибәр, булдыклы, бераз зәһәрле, куштан; 30 яшьләрдә.

Фәтхия — Хәйринең карт хатыны; юаш, йомшак, оялучан табигатьле.

Батырхан — таза, нык, гайрәтле, үткен табигатьле; бик аз укыган авыл ярлыларыннан, 30 яшьләрдә.

Бибизәйния — Батырханның хатыны, Хәйри байның карт хатынының кызы, сөйкемле, уйчан табигатьле; беренче, икенче пәрдәләрдә авыр уйлаудан йөзе саргая төшкән. Күзләрендә, тавышында бераз хыялый төс бар.

Вәли — Хәйринең карт хатынының улы; яше 30 ларда.

Камәр — яшь, матур, үткен мөгаллимә. Шат, ачык табигатьле.

Шәйбәк бабай — ярлы авыл карты; зур ак сакаллы, киң ачык маңгайлы, изге, суфи, диндар кеше; яше 70 ләрдә.

Тимеркәй — Хәйри байның карт хатынының үлгән кызының улы. Яшьтән ятим калып, Хәйридә ялчы урынында эшләп үскән; үткен, тере йөрәкле егет; яше 20 ләрдә.

Насыйб, Ярми — авыл егетләре, ярлы крестьяннардан.

Шәңгәрәй — авыл Советы рәисе, ярлы крестьян.

Әптерәш — Хәйри байда егерме еллар торган карт ялчы. Акрын кузгала, сабыр сөйли.

Иванов, Шакиров — Батырхан белән килгән кызылармеецлар.

Габдулла — тәрәзәдән икмәк, сөт сорап алучы кызылармеец; Әптерәшнең якын кардәше.

Беренче пәрдә

Пәрдә ачылганда җәйге кич. Хәйри байның яңа өе. Өй авылча бай, матур итеп җыештырылган.

Хәйри бай (*керә. Нәрсәдәндер шикләнгән кеше кебек, як-ягына күз ата да каты тавыш белән кычкырына башлый*). Зөһрә!.. Вәли!.. Сез кайда? Чәнчелгерләре! Сиңа кирәк чакта берсе дә юк! Зөһрә! Вәли!

Зөһрә, Вәли (*ашыгып килеп керәләр. Икесе берьюлы*). Ни бар?

Хәйри (*тәрәзәгә карап ала, лампаны бераз баса да Вәли белән Зөһрәне идән уртасына китерә*). Бар инде, бар, зур эшләр бар. Без хәзер генә Митри Степанычта булдык... Бу бик яшерен сер. Кешегә-карага чыгармагыз, башларыгызны өзәрмен, ишетәмсез? Митри Степаныч бит бер атнадан бирле, большевиклардан качып, байлар очында, Әтәч Садыйкта ята. Анда Аксак бояр, Кәҗә Якуп, Карун Гали, Тукран Хаҗи, тагы әллә кемнәр бар иде. Без анда озак киңәштек...

Зөһрә. Соң? Соң? Әллә безнекеләр килеп җитәләр диме?

Хәйри. Җитәләр генә түгел, җиткәннәр инде! Теге кызыл шайтаннар, яшеннән качкан кебек, тыр-тыр качалар, ди. (*Чөйгә эленеп торган бишмәтенең кесәсеннән бер кәгазь алып килә.*) Котым очты, югалтканмын дип торам... (*Вәлигә.*) Менә моны Тукран малае Сәфәргә хәзер үк илтеп бирерсең. Монда мөселманнан азган большевикларның исемнәре, ди. Калада рәт беткәч, бу явызлар, халыкны котыртырга дип, авылларга таралганнар, ди. Аларны кайда күрсәң, шунда үтерергә, ди. Ярый, бар, чыгыгыз эшегезгә!

Вәли (*шатланып, җиңел атлап ишеккә бара*). Аңладым, киттем... (*Чыга.*)

Зөһрә. Аңладым.

Хәйри (*Зөһрә артыннан ишек ябылуга тагын кычкыра*). Зөһрә, Зөһрә!

Шәңгәрәй (*урам як тәрәзәдән шакылдата*). Хәйри абзый, өйдәме син?

Хәйри. Сәвит прсидәтеле килгән. Шәңгәрәй туган, син икәнсең.

Шәңгәрәй. Син, Хәйри абзый, хәзер пар ат белән яхшы арбаңны ылауга җик.

Хәйри. Бу вакытта атларны каян табарга кирәк? Яхшы арбам минем юк та. Төзәтергә дип урыска — тимерчегә илтеп ташлаган идем, ике айдан бирле шунда ята...

Тимеркәй (*Хәйри белән Шаңгәрәй сөйләшә башлагач та килеп керә*). Их, бабакай, бабакай! Карт башың белән ничек бу чаклы ялганларга оялмыйсың. Кәмитит абзый, ышанма бу картка! Аты да арбасы да бар. Кендекләр, камытлар мунча башында... Тәгәрмәчләр әвен базында. Яхшы тарантас ындырда — кибәннәр арасында саламнарга күмелгән... Атларны караңгы төшкәч кенә елга аръягына тал куагы эченә бәйләп куйдылар.

Хәйри (*аптырап, шашып тора да кинәт Тимеркәйгә ташлана*). Син бала шайтанга ни калган? Җыен тузга язмаганны сөйләп йөрергә?!

Шәңгәрәй. Хәйри абзый, мин ике сөйләргә яратмыйм, мөгаллимә Камәр китәргә ашыга: ярты сәгатьтән атларың җигелгән булсын! (*Китә.*)

Тимеркәй. Ә син, бабай, юкка авызыңны күбекләтәсең: монда калып, сезнең этләрегезгә талатыр хәлем юк... Мин мөгаллимә апам белән китәм... Батыркай җизнине ерак түгел чехлар белән сугыша диләр.

Хәйри. Китмәгәең, кадал! Син этне унбиш ел буенча ашаткан ашларым хәрам булсын!

Тимеркәй. Бик харап ашаттың инде! Әнкәй мәрхүмне ялчы катын урынында тирес түктереп, мал абзарында чертеп үтерттең... Мине җиде яшьтән акчасыз ялчы ясадың.

Тәрәзәдән тавыш (*Батырхан тавышы*). Иванов иптәш, тукта әле, шул йорт бугай.

Тимеркәй. Батырхан җизни тавышына охшый. Әллә дә кайтып җиттеме? (*Шатлыктан атылып чыгып китә.*)

Зөһрә (*коты очып килеп керә*). Атасы, бу нинди хәл тагы? Капка төбенә атлар килеп туктады. Әллә нинди солдатлар күренә. Арада теге каһәр төшкән каторжник Батырхан тавышы да бар кебек. Ходаем, ул разбойникны ник һаман асмадылар икән?!

Батырхан (*ике кызылармеецка култыкланып килеп керә. Зур буйлы, ябык, ләкин үткен, каты карашлы. Өстендә кызыл командирлар киеме. Аяклары, башы, яңаклары, муеннары ак белән бәйләнгән. Аны урындыкка утырталар*). Исәнмесез!

Хәйри, Зөһрә. Аллага шөкер, кияү... Үзең исәнме?

Бибизәйния (*ашыгып килеп керә*). Җаным, бәгырем!.. Синме? (*Иренең кочагына ташлана.*)

Фәтхия (*керә*). Исән кайттыңмы? Балам, бәгырем!.. (*Елый.*)

Батырхан (*иркәле тавыш белән*). Елама, әбкәй, елама, Бибизәйния... Йә, сөйләгез... Нихәлләрегез бар?

З ә й н и я. Ходаем, Ходаем, синме бу? Җиде ел көттем... Сине уйлый-уйлый акылдан шаша яздым... Бик авыртмыймы, бәгырем...

Б а т ы р х а н (*Зәйнияне иркәли*). Аңлыйм, акыллым... аңлыйм. Мин сине бервакытта да хәтеремнән чыгара алмадым. Куркынычлы яра түгел... тиз төзәлер.

З ө һ р ә. Безнең Батырхан кияү бик зураеп кайткан, ахры. Безнең белән юньләп исәнләшмәде. Бу йортка моннан соң аяк басмам дигән идең...

Б а т ы р х а н. Ә, алаймы? Юкка котыгыз очмасын, мин сезгә кайтмадым. Менә Бибизәйнияне күреп чыгыйм дидем... Мин хәзер китәм... Минем ярты сәгать вакытым калды...

З ә й н и я. Ярты сәгать! Ярты сәгать! Ходаем, бу нихәл инде бу?

Б а т ы р х а н. Ни эшлим соң, бәгырьләрем? Безне стансада эшелон көтә... Еламагыз... Мин яңадан тиз кайтырмын...

Ә п т е р ә ш (*килеп керә*). Әссәламегаләйкем!.. (*Ике кулын сузып.*) Әй Батырхан туган, гомер булгач, сине дә күрер көн җитте бит... (*Якын ук килеп, яра бәйләүләрен карый.*) Болар бик каты түгелме?

Б а т ы р х а н. Юк, бабай, юк. (*Зөһрә белән Хәйри берәм-берәм акрын гына чыгып югалалар.*)

Б и б и з ә й н и я (*иренә*). Мин сиңа юл кирәкләре әзерлим әле...

Ф ә т х и я. Бер дә җибәрмәс идек тә бит: Ходайның кушуы шулай күрәсең инде!... (*Акрын атлап Зәйния артыннан чыгып китә.*)

Т ы ш т а н т а в ы ш (*Камәр тавышы*). Батырхан абзый кайткан диләр. Шуны ишетеп йөгердек. Әйдә, Шәйбәк бабай!.. (*Килеп керә; башында кепка, кара юбка өстеннән гимнастерка, муеннан кобур, күн тәмәке савыты асылган. Ишектән керүгә Батырханга ташлана.*) Исемегез тирә-якны яңгыратты. Инде үзегезне күрер көн дә бар икән!

Ш ә й б ә к (*килеп керә; бөтен торышында бер сабырлык, тынычлык сизелә*). Әссәламегаләйкем!.. Батыркай балам, исән-сау кайттыңмы? Бу яраларың бик зыянлы түгелме, балам?

Б а т ы р х а н. Юк, бабай, юк, артык зыянлы эш юк...

Т и м е р к ә й (*якын ук килеп*). Батыркай абзый, мин дә синең белән китәм. Аласың бит мине?

Б а т ы р х а н (*Тимеркәйнең кулын кыса*). Алам, бик алам.

Т и м е р к ә й (*кызулап чыгып китә*). Хәзер, хәзер, ике минутта без әзер булырбыз...

Шәйбәк (*Тимеркәйне күрсәтеп*). Яхшы кеше булып чыгар бу егет. Батыркай туган, мин сиңа башта бик ачуланган идем. Инде фәкыйрь халык өчен тырышып йөрүеңне күргәч, барын да кичердем.

Камәр. Батырхан абый, сезнең хакта әлләниләр сөйләп бетерделәр. Сезне бик караладылар. Чынын гына үзегездән ишетәсебез бик килә...

Батырхан. Аның нәрсәсен сөйлисең. Без күптән яратыша идек. Зәйния, атасының риза булмавына карамыйча, миңа ябышып чыкты... Карт кулак Кәҗә Якупның улы Саткайны беләсездер, шул Бибизәйнияне кодалап йөргән икән... Үзенә эләкмәгәч, Бибизәйния хакында бик күп пычраклар тараткан. Боларны ишеткәч, Зәйния, хурлыгыннан көн-төн акырып елый башлады... Мин түзмәдем... Балтамны үткерләдем дә, көпә-көндез өенә барып, Саткайның башын өзеп чыктым... Миңа рәхмәт әйтмәделәр, богаулап каторгага сөрделәр... Герман сугышы башлангач, мин каторгадан качтым да башка исем белән фронтка киттем... Бер бунтка катнашкан өчен яңадан крепостька ябылдым. Революция мине коткарды... Элек Краснов, Корниловларга каршы сугыштык. Аннан соң Уралга Дутовка каршы сугышка килдем. Чехлар баш күтәргәч, отряд белән аларга каршы киттем. Моннан ике көн элек яраландым.

Камәр (*торып Батырханның кулын кыса*). Сез нинди бәхетле, Батырхан абый!

Шәйбәк. Гөнаһың бик зур иде... фәкыйрь халык өчен түккән каннарың бәрабәренә Аллаһ Тәгалә гөнаһларыңны кичерер.

Шәңгәрәй (*керә*). Исәнме, Батырхан. Бүген таңда чех көткән байлар, синең кайту хәбәреңне ишеткәч, яшеннән качкан шайтаннар кебек, сәке асларына, базларга яшеренгәннәр (*көлә*), безнең төбәкләр бәйрәм итә.

Батырхан. Алайса, сезнең монда халык бер-берсенә каршы ике класска нык аерылышып җиткән. Сез, алайса, нык эшләгәнсез.

Шәңгәрәй. Бездә халык аерылу гына түгел, бай белән ярлы бугазга-бугаз килеп сугышалар инде. Батырхан туган, башка якта хәлләр ничек?

Батырхан. Сугыш ягы шәп түгел, иптәш, Кызыл Армия оешып җитмәгән. Самарадагы сугышларны ишеткәнсездер, анда күпме эшче-крестьян каны түгелде!.. Безнең иптәшләрнең башлары өчәр көн урамда аунады.

Камәр. Нинди вәхшәтләр, ниндиерткычлар!

Шәйбәк. Үз башларына кыланалар. Алар кан дәрьясы аша барып, карун булырга телиләр... Аллаһ Тәгалә андый усаллыкларга түзмәс, балалар!

Батырхан. Хәзерге вакытта без һәр яктан ут эчендәбез. Сез бүген төндә бу авылдан китәргә тиешлесез!..

Шәйбәк. Батырхан балам, кайтуың бик азга икән — син инде Бибизәйнияне юатырга тырыш. Ул бичара бер әүлия катын инде... (*Чыгып китә.*)

Шәңгәрәй. Вакыт бик азайды, безгә ашыгырга кирәк.

Батырхан. Юлда сөйләшербез, бар син, Шәңгәрәй абзый, атларыңны ашыктыр...

Шәңгәрәй. Ярар. (*Китә.*)

Батырхан. Сез шундый матур, шундый кызганучан табигатьлесез! Ничек сез бу канлы көрәшкә атылдыгыз?

Камәр. Мин бик артык ярлы гаиләдәнмен. Мең газап белән укыдым. Уфага курсларга бардым. Анда сөйләделәр... аңладым... Шунда ук партиягә дә язылдым... Хәзер кыйблам билгеле, җаным тыныч... Элек сөюләр, матур чүпрәкләр колы булуымны уйласам, хәзер үземнең йөзем кызара...

Каты туп тавышы килә башлый.

Батырхан (*тирәдәгеләргә күз ташлап*). Һәммәгез әзерме? Әйдәгез, киттек! (*Чыга башлый.*)

Камәр (*Зәйнияне кочаклап, акрын адым белән ишеккә таба сөйләнә-сөйләнә килә*). Елама, Зәйния апа... Дошман җиңелер... Бу кан түгүләр бетәр... Җир йөзе гөл бакчасына әйләнер... Адәмнәр матур, бәхетле тора башларлар.

Чыгалар. Рәттән берничә мәртәбә туп, залп тавышы килә. Зәйния, аның артыннан Шәйбәк бабай килеп керәләр.

Бибизәйния (*елаудан йөзе бозылган*). Тагы китте, еракка, еракка китте! Мин тагы ялгыз калдым!.. Әйт, бабакаем, яңадан кайтырлармы?

Шәйбәк (*Зәйниянең башыннан сыйпый, йомшак тавыш белән иркәли*). Елама, балам. Елама. Озакламаслар, яңадан кайтырлар. Батыркай да кайтыр!

Зәйния. Бабакаем, бабакаем!.. Син нинди изге, нинди яхшы күңеллесең! Нигә һәммә кешеләр дә синең кебек түгел! (*Шул хәлдә сүзсез, хәрәкәтсез калалар.*)

Акрын гына пәрдә төшә

Икенче пәрдә

КАТНАШУЧЫЛАР:

Андреев — зур таза гәүдәле, матур йөзле, зур мыеклы рус офицеры; 38 яшьләрендә.

Галимов — яшь татар прапорщигы, Андреевның урынбасары, хәрби шурачы.

Чех — зур таза гәүдәле, баштанаяк кораллы.

Аксак бояр Колинкин — элеккеге алпавыт; 60 яшьләрдә.

Митри Степаныч Григорьев — элеккеге земский начальник.

Хәйри бай — яхшы киенгән; сәгать чылбыры ялтырый, күкрәгендә иске старшина медале.

Беренче мулла.

Икенче мулла.

Ике поп.

Әхтәм Банаев — милләтче татар зыялысы.

Камәр мөгаллимә — кыйналган, йөзе яралы.

Батырхан — кыйналган, газапланган, яра бәйләүләреннән кан бәреп чыккан.

Шәңгәрәй.

Тимерче Гайнетдинов — совет вакытында волость комиссары; ярлы крестьяннан.

Тимеркәй.

Семенов — Кызыл Армиядә 13 нче полк командиры, контрреволюция белән яшерен мөнәсәбәттә, аларның яшерен агенты, ак офицер һәм башкалар.

Пәрдә ачылганда болытлы, яңгырлы җәйге көн. Авылның бер чите. Волость конторы. Конторның тәрәзәсе турынарак китереп өстәл куелган, аның тирәсендә урындыклар.Иң уртада, зур трубкасын тартып, **чех** утыра; аның уң ягында офицер **Андреев**, сул ягында — **Галимов**. Бер яктан элекке земский начальник **Григорьев**, икенче яктан — **Тимофей Колинкин, Әхтәм Банаев.** Арттагы рәттә **берничә кулак, поплар, муллалар, байлар.** Һәммәсенең артында биегрәк нәрсәгә басып, **Шәйбәк бабай** хәйран булып карап тора. Өстәлнең алдында кылычлы, мылтыклы солдатлар белән уралып, **тоткыннар** тезелгән: **Камәр, Батырхан, Шәңгәрәй, Гайнетдинов, Шакиров, Иванов, Семенов** торалар.

Колинкин (*сүзен дәвам иттерә*). Менә шуның өчен дә, господа, без: «Яшәсен каһарман чех-словак кардәшләребез!» — дибез.

Хәйри, аның артыннан өстәл тирәсендәге һәм алгы сафтагылар: «Яшәсен!.. Яшәсен чехлар!.. Мең ел яшәсен!» Шау-шу дәвам иткән вакытта кемдер арттан бик ачы сызгырып җибәрә. **Чех** урыныннан сикереп тора. Ачулы күзләре белән халыкка кадала. **Аксак бояр, Григорьев** сикереп торалар.

Хәйри бай (*җәмәгать эченә барып керә, йөгерә, эзләнә*). Кем ул? Кайсы ләгънәте безнең бәйрәмебезне пычрата?

Андреев (*кинәт кузгалып уртага чыга, Хәйрине туктата, өстәлдәгеләргә нидер ашыгып әйтә; ризалата, уң кулы белән тоткыннар ягын күрсәтә*). Җәмәгать, менә шул якны бөтенләй бушатыгыз. Боларны (*тоткыннарга күрсәтә*) менә шунда, безнең каршыгарак китерегез! (*Галимовка.*) Башлагыз!

Галимов (*портфель актара. Аннан бер кәгазьне ала да укый*). Габдулла Сәйфулла углы Гайнетдинов; Тимофей Колинкинның имениесен талаган, җир-суын алган, Федор Колинкинны атып үтергән.

Андреев. Кайсыгыз тимерче комиссар Гайнетдинов? (*Гайнетдинов алгарак чыга.*)

Гайнетдинов (*аз гына да каушау әсәре күрсәтмичә*). Мин булам!

Андреев. Колинкинның имениесен талаучы синме? Федор Колинкинны атып үтерүче синме?

Гайнетдинов (*элекке тынычлыгы белән*). Мин волость исполкомының постановлениесе буенча аның йортын мәктәпкә, клубка алдым... Ашлыгын ачларга тараттым... (*Кулы белән Аксак боярга күрсәтә.*) Господин Тимофей Колинкин үзе дә әйтер: без аның агасын бер заговорга катнашканлыгы өчен хөкем белән аттырдык.

Андреев (*елмаеп кына кул селкә*). Разбойник Гайнетдиновны читкә чыгар!

Гайнетдинов (*аз гына да тартынмыйча, Батырхан белән Камәргә кул бирә*). Бәхил булыгыз!..

Андреев. Кеше милкенә кагылучыларга менә бездә шул закон! (*Наганын ала да рәттән ике мәртәбә ата; Гайнетдинов сүзсез-нисез егыла; хатын-кызлар акырып елап җибәрәләр.*)

Иванов, Шакиров (*бу атудан котлары очып, өстәл янына, аяк астына егылалар*). Безне атмагыз... Без белмәдек... Без мобилизованныйлар...

Андреев (*Емельяновка*). Боларны штабка озатыгыз! (*Шакиров, Иванов ишектән кереп китәләр.*)

Семенов (*өстәл каршына һавалы кыяфәт белән килеп туктый*). Мин Ватан каршында үз бурычымны үтәдем...

Андреев (*бераз аптырап*). Сез кем?

Семенов. Мин Кызыл Армиянең 13 нче полк командиры идем... Үземә тапшырылган кызыл банданы сезнең утыгыз астына кертеп бетерттем. Минем фамилиям — Семенов.

Андреев. Семенов? Семенов? Сез Владимир Николаевичмы?

Семенов. Шулай, дөрес.

Андреев (*торып кул бирә*). Бик яхшы, бик яхшы! Мин сезгә атлар бирдерәм. Кичекмичә штабка барыгыз!

Семенов. Рәхмәт, бик рәхмәт! (*Контор ишегенә кереп китә.*)

Андреев. «Туташны» алга чыгарыгыз!

Емельянов мөгаллимәне тотып алгарак чыгара.

Андреев. Сез кем? Ничек эләктегез?

Камәр (*Сабыр, тыныч тавыш белән*). Кем булыйм? Мин — мөгаллимә. Өч ел балалар укыттым. Хәзер партиядәмен.

Әхтәм Банаев. Камәр туташ, сез тирә-яктагы атаклы мөгаллимә. Нинди гөнаһ шомлык белән сез болай милләткә хыянәт юлына кереп киттегез?

Камәр. Атарга көчегез бар, ләкин минем вөҗданыма кагылырга сезнең һичбертөрле хакыгыз юк... Без түгел, сез үзегез — халык дошманы! Сез үзегез халыкка каршы иң зур хыянәтче!

Андреев (*Емельяновка*). Камәр Якупованы читкә ал! (*Камәрне җирдә яткан Гайнетдинов гәүдәсе янына китерәләр... Батырханга күрсәтеп.*) Менә моны китер! (*Емельянов Батырханны алга чыгара. Зәйния якын килмәкче була, каравыл аны читкә этәрә.*)

Галимов (*аягүрә басып укый*). Батырхан Җафаров, каторгадан качкан кеше, 33 яшендә; крестьян; кызыл коммунарлар отрядының командиры.

Андреев. Сез кем?

Батырхан (*һавалы, мәгърур тавыш белән*). Мин мировой контрреволюциягә каршы сугышучы эшче-крестьян Кызыл Армиясенең бер солдатымын.

Галимов Андреевның колагына нидер әйтә.

Андреев (*усал күзләре белән Батырханга йотыла. Бер кулы белән кобурына тыгыла*). Шулаймы? Син каторжник, кызыл разбойник, ата большевик Батырхан Җафаровмы? (*Емельяновка.*) Уң якка чыгар бу собаканы! (*Солдатларга.*) Тиз! Винтовкаларны кулга!

Җәмагать гөж килә. Әптерәш, Насыйб, Ярми тоткын ягына таба кысылып үтәргә омтылалар. Солдатлар ашыгыч-ашыгыч мылтыкларын шытырдаталар. Берсе күккә атып җибәрә.

Бибизәйния (*акырып елап, Батырханны барып кочаклый, өстери башлый*). Тимәгез, атмагыз!.. Ул минем өчен каторда булды... Ул изге кеше! Аңа атмагыз. (*Үзен өстерәп читкә чыгара башлаган Емельяновтан ычкынып, чәче-башы тузган хәлдә өстәлгә таба килергә омтыла.*) Аңа тимәгез! Менә мә мине атыгыз!..

Ак күзәтче (*Андреев, ачудан шашып, Батырханга атар өчен наганын суырып алып кулын сузганда, ашыгып, шашып, козырекка кулларын куйган хәлдә килеп керә дә кызу тавыш белән Андреевка*). Господин командир, Саранов отряды фронт ярып чыкты... аның атлы ротасы хәзер авылны килеп баса!

Аптырап калган җәмагать, бу соңгы сүзне ишеткәч, бөтенләй тәртипне югалта. Йөгерү, качу башлана.

Андреев. Җәмагать, курыкмагыз!.. Бүген кич бу авылны яңадан алачакбыз! (*Үзе арты белән чигенеп качкан хәлдә өзлексез ата. Батырхан, мөгаллимә кызу, кинәт кузгалышлар белән тайчанып йөгерәләр, арттарак калган Шәңгәрәй, Андреевның пулясыннан «Аh! Аh!» дип егыла.*)

Бик еш туп ату, аңа кушылган залп, сугышчы гаскәр тавышы бик каты, бик якыннан ишетелә.

Шәйбәк (*аклар качкан яктан килеп чыга, үлекләрне карап*). Урыныгыз җәннәттә булсын, балалар! (*Дога кыла.*)

Бер агачка таянып, Батырхан, Камәр, өч ак солдат килеп керәләр. Камәр белән Зәйния үлекләргә ташланалар.

Батырхан. Кайда безнекеләр? Тиз, тиз, бөтен авылны аякка бастырсыннар!.. Эләккәннәрне монда китерсеннәр!

Җамали килеп керә.

Ак солдатлар (*Батырханга*). Без аклардан сезнең якка калдык, безгә ни кушасыз?

Батырхан (*кулларын кыса*). Шулаймы?.. Бик яхшы! Җамали, менә бу солдат иптәшләрне ал да тегеләрнең калдыкларын тотып китер!

Җамали. Була, бик була. (*Солдатларны алып, йөгереп чыгып китә.*)

Батырхан җирдә аклардан калган наганны күреп тиз генә ала, урындыкка утыра. Шәйбәк, Камәр, Зәйния аңа киләләр.

Шәйбәк (*үлекләргә таба атлый*). Бу шәһитләрне өйләренә илтеп куйыйк әле. Мин арба китерим.

Ике кызыл күзәтче (*кораллылар керүгә Батырханга таба баралар*). Сез кемнәр, иптәшләр?

Батырхан. Мин кызыл коммунарлар отрядының командирымын... Болар — минем иптәшләрем. Сез Саранов иптәш отрядынннанмы?

Күзәтче. Безнең атлы батальонны Саранов иптәш бүген үз командасында алып килде...

Камәр (*шат, мөлаем йөз белән күзәтчеләргә килеп, кулларын кыса*). Сезнең отрядның килеп җитә алуы бер могҗиза булды, иптәшләр... Күпме халык үлемнән котылды...

Тимеркәй (*шатланып килеп чыга*). Их, агайлар!.. Батырхан абый! Мөгаллимә апа! Шәйбәк бабай! (*Иң элек Батырханга ташлана. Аннан соң Шәйбәк белән Камәрне барып кочаклый.*)

Батырхан. Бу синме, Тимеркәй туган? Үтереп ташлаганнар дип, сине бик кызганыштык без.

Тимеркәй. Тегеләр килеп юлны кискәч тә, агач арасына йөгердем... Аннан чокырга ташланып, үземне комга күмдем... (*Үлекләрне күреп.*) Бичараларның күпме балалары калды!

Саранов (*килеп керә*). Сез кемнәр, иптәшләр?

Батырхан (*таягына таянып, урыныннан тора*). Сез мине беләсездер... Минем отрядым сезнең белән янәшәдә сугышты... Мин — Батырхан Җафаров!

Саранов. Сезне күрүгә мин бик, бик шатмын. Хәзер озаклап сөйләшергә вакыт юк. Мин сезгә үземнең отрядымнан егерме кеше калдырам. Бөтен властьны сезгә тапшырам. Нәрсә кирәк, шуны эшләгез дә бүген кич Таштамакта булыгыз. (*Китә.*)

Батырхан (*Тимеркәйгә*). Сиңа биш красноармеец иптәш бирәм. Авылдан попны, мулланы, Аксак боярны, Хәйри кулакны, Кәҗә Якупны эзләп монда китер. (*Мөгаллимәгә.*) Ә сез Зәйния белән юынып, төзәтенеп килегез... (*Һәммәсе китәләр. Калганнарга.*) Иптәшләр, менә бу үлекләрне өйләренә кайтарырга кирәк...

Кызыл армеецлар үлекләрне күтәрәләр, чыгып китәләр. Берәр минут үтүгә кемнедер кыйнап, шаулашып алып килгән тавыш ишетелә.
Ул арада погоннары ертылган, йөзе яраланган Галимов белән Аксак боярны крестьяннар кыйнап кертәләр.

Җамали (*алдан йөгереп керә*). Батырхан туган, син ачуланма инде... йөрәк түзмәде. Эләккәч, бераз биргәләп алдык.

Батырхан (*тоткыннарның каршына килә, йөзе тимерләнә, күзләренә ачу чыга*). Сезме эшче-крестьян палачлары? (*Наганын чыгара, крестьяннар читкә тая; Батырхан рәттән дүрт мәртәбә ата. Галимов, Аксак бояр йөзтүбән капланалар. Батырхан, хәлсезләнеп, билен тотып, өстәлгә ава.*)

Төенчек тотып, Шәйбәк карт килеп керә. Аксак бояр белән Галимовның үлек гәүдәсен күреп аптырап кала, Батырханга килә.

Шәйбәк. Әй туган! Син тагы кан түккәнсең икән! Ярамас, бер дә ярамас иде!

Батырхан. Җан кыю безгә дә уен түгел, бабай... Саткайны үтергәннән соң, мин кан күрә алмый торган булдым... Туры килеп, кызулык белән бер офицерны аттым: шуннан соң төн йокыларым качты. Шашып калдым. Шул арада контрреволюционерлар бер җирдә безнең утыз иптәшебезне газаплап, авыз-борыннарын кискәләп киттеләр... Бу корбаннарны күргәч, мин яңадан ныгыдым. Бая ишеткәнсеңдер, Әхтәм Банаев нәрсә диде? «Без чех-словакларның канлы штыклары аркасында азатлык алдык»,— дип игълан кылды. Буржуйлар әнә шулай карый, бабай... Безгә дә, безнең эшче-крестьян халкына да контрреволюционерларның башлары өстеннән азатлыкка барырга туры килә... Башка юл юк... Юк, бабай... (*Картның кулыннан тотып, контрларның үлек гәүдәсенә китерә. Кулы белән күрсәтә. Ачык кискен тавыш белән.*) Юл бер генә! Менә шушы канлы юл — изге юл!

Шәйбәк. Белмим, балам, белмим, күп кан түгүдән саклан! Чүпне утыйм дип, ашлыкны әрәм итә күрмә.

Мөгаллимә (*юынып, яраларын бәйләп килеп керә. Өстендә соры шинель, кулында төенчек*). Менә без килеп тә җиттек!.. (*Үлекләрне күреп.*) Ах, тагын кан! Ни эшлик?! Ни генә эшлик? Башка юл юк, юк, юк шул!

Зәйния (*Камәрнең артыннан ук килеп җитә. Авыр уйланып иренә килә.*) Ходаем, мин тагын каламмыни инде?

Батырхан. Елама, Зәйния, без тиз кайтырбыз... Китәргә вакыт.

Мөгаллимә (*шат йөз белән елмаеп, бабайга кул бирә*). Шаһибәк бабай, сиңа бер үтенеч: Карамалыда минем ятим карчык әнкәй бар. Шуңа бер юл уңаенда кереп чыгып, сәламемне әйт! Үзен бераз юат!

Батырхан. Бабай, син минем Зәйниямне дә онытма.

Шәйбәк. Ярар, балалар, ярар...

Камәр (*Зәйниягә килә*). Кайгырма, елама, Зәйния апа... Бу сугышлар бетәр. Матур рәхәт көннәр килер... (*Үбешеп күрешәләр.*)

Батырхан. Иптәшләр, сез әзерме?.. Әйдәгез кузгалабыз! (*Контор артына чыгып китәләр, Батырханны бераз култыклап баралар.*)

Ат куалау, озату шау-шуы ишетелә. Эптерәш, Зәйния белән Шәйбәк, авыр, салмак атлап, сәхнәдән үтәләр. Зәйния елый.

Шәйбәк (*Зәйнияне юата, иркәли*). Елама, балам, елама... Алар тиз кайтырлар...

Пәрдә төшә

Өченче пәрдә

КАТНАШУЧЫЛАР:

Батырхан — N нче кызыл коммунарлар полкының командиры. Аягы бераз аксый, маңгаенда, яңагында бик тирән яралар.

Тимеркәй — рота командиры.

Фәтхия — күп картайган, баштанаяк ак киемдә.

Гөлҗамал — мәрхүм Шәңгәрәйнең хатыны; елак, гасаби (нервлы); үзе дә, балалары да артык ярлы киемдә.

Зәйния — бу пәрдәдә төзәлгән, чибәрләнгән; ачык, сәламәт табигатьле.

Әхтәм Банаев.

Эптерәш карт.

Кәрим — авыл Советы рәисе, ярым гаскәри киемдә, оек-чабатадан.

Насыйб, Ярми — кызылармеецлар.

Җамали.

Үтерүчеләр һ. б.

Хәйри байның өе, ләкин беренче пәрдәдәгегә караганда бик күп дәрәҗәдә ярлыланган. Стена буенда бер юл чемоданы чишелмәгән хәлендә тора. Тәрәзә төбендә кечкенә лампа яна.

Пәрдә ачылганда Фәтхия әби идәндә намазлык өстендә ясту укый. Гөлҗамал, җиде-сигез яшьлек ике баласын ияртеп, ачык, шат йөз белән килеп керә дә карчыкның намаз укыганын күргәч туктала.

Фәтхия (*як-ягына сәлам биргәндә, Гөлҗамалны күрә*). Нихәлең бар, Гөлҗамал килен?

Гөлҗамал (*кулындагы кызылсу төстәге ситсыны күтәреп, шат тавыш белән*). Шатлыгымнан сиңа йөгердем. Кара, әбекәй, миңа ничаклы нәрсә бирделәр бит... (*Ситсыларны туздырып ташлый, карыйлар.*) Безнекеләрне үтереп Себергә качкан теге явызлар бар бит. Шуларның калган малларын безгә өләштеләр. Тимеркәй үзе карап торды. Болар болай гына бирү әле, ди. Менә акларны бетереп, сугышлар тукталгач, Совет сезне байлыкка күмәр, ди.

Фәтхия. Үзеңә дә, балаларыңа да берәр катка иркен җитәр.

Зәйния (*ут алдында нидер хәзерләгән, пешеренгән кебек яныл кызарган*). Ходаем, бөтен кирәк-яракны алып китеп бетергәннәр. Нәрсәгә тотынсаң, шул юк. Нихәл, Гөлҗамал җиңги? Бу ни бу?

Гөлҗамал. Барыбызны да киендерделәр. Мин дә алдым, теге аклар үтергән Шәйбәк бабай карчыгы Сәрби әби дә, мәрхүм тимерче хатыны, көтүче Сафи әнкәсе дә алды...

Насыйб (*Шәйбәк картның таягын, бохар кәләпүшен, камзулын, аркан, чабаталарын, бик иске чапанын күтәреп килеп керә, Фәтхия әбигә*). Фәтхия әби, менә болар — мәрхүм Шәйбәк бабайның әйберләре. Аның карчыгының өе җимерелгән. Башка торыр җире булмагач, Батырхан абый аны бу йортка күчерергә кушты. Сәрби әби үзе иртәгә килә. (*Әйберләрне бирә дә чыгып китә.*)

Фәтхия. Ярар, балам. Өйләребез зур, сыярбыз әле.

Зәйния. Бичара бер әүлия карт иде. Әрәм генә иттеләр бит. Минем Батырханым сөйләп бетерә алмый аны! Шәйбәк бабай — безнең өчен алтын иде, ди. Ул мәрхүм арбасына бер-ике чабата белән берничә аркан сала икән дә, аларның астына Советның китапларын, акларга каршы язылган кәгазьләрен төяп, базардан базарга таратып йөри икән. Менә шулай йөргәндә, аны төнлә теге югары оч байлары урманда үтереп ташлаганнар.

Тәрәзәдән беренче тавыш. Кызыл коммунарлар мондамы? Батырхан абзый кирәк иде. Анда мөгаллимә апаны үтереп ташлаганнар, диләр. Үтерүчеләрне тотканнар, ди... (*Китәләр.*)

Фәтхия. Әй бичара бала, бала!

Гөлҗамал. Барлык яхшы кешеләребезне үтереп бетерәләр, күрәсең.

Зәйния. Инде Камәр дә юк! Бу нинди эш бу?

Тимеркәй (*ачудан шашып килеп керә. Шкафка килә дә ашыгыч кул белән кобурын, юл дәфтәрен алып китә башлый*). Зәйния апа, анда сине чакыралар. (*Зәйния сүзсез, ашыгып чыгып китә.*)

Фәтхия, Гөлҗамал. Ни бар? Мөгаллимәнең хәле ничек?

Тимеркәй. Бүген кич Кызылтамактан, собраниедән кайтып килә икән... Урманда саклап торганнар да, үтереп, гәүдәсен чокырга ташлаганнар. Ярар, мин алардан бергә унны түләтермен... (*Чыгып китә.*)

Фәтхия. Иртәгә әнкәсе янына бармакчы иде... Анасын да күрә алмый калды, мәрхүмкәй!

Тимеркәй (*ишектән атылып керә. Тәрәзәгә барып каты тавыш белән кычкыра*). Монда китерегез собакаларны!

Биш-алты ярлы крестьян кыйнап, суккалап, акыртып ике үтерүчене төрткәләп кертәләр.

Тимеркәй (*ике кулы белән икесенең җилкәсеннән алып, ике якка бәрә*). Сезме үтерүчеләр?

Җамали. Ныграк бир каһәрләргә! Җәһәннәмгә җибәр үзләрен! (*Ашыгып Батырхан килеп керә.*)

Батырхан (*мондагы кыйнашны күргә кинәт бусагада туктый. Коточкыч тавыш белән кычкырып җибәрә*). Бу ни эш бу? Сез ни эшлисез?

Һәммә кеше кинәт туктый. Тын була. Тимеркәй, үзенең эшенең бик артык хаклы икәнлегенә ышанган кыяфәт белән бөеренә таяна төшеп, Батырханга карап тора.

Батырхан. Әйтегез, сезме Камәр иптәшнең палачлары?!

Үтерүчеләр (*Батырханның аягына егылалар*). Без белмәдек, безне котырттылар... Һәммә явызлыкның башы шул кәнтәй марҗада, диделәр... Безне кичер, Батырхан абзый!

Батырхан. Торыгыз! Кеше котырыгына карарга сез балалармыни? (*Насыйб белән Ярмигә.*) Алыгыз боларны.

Насыйб, Ярми (*берьюлы*). Кая илтик?

Батырхан. Эшче-крестьян палачларын кая илтәләр диме? Духонин штабына, Могилев губернасына!

Тимеркәй. Аңламасагыз, үзем әйтәм: җәһәннәмгә! Үзләренең дуслары янына!

Үтерүчеләрне алып чыгып китәләр.

Кәрим (*авыл Советы рәисе, тәрәзәдән кычкыра*). Батырхан иптәш өйдәме? Сезгә баягы кешене китердек.

Кәрим белән ике кызылармеец Әхтәм Банаевны алып керәләр.

Батырхан. Ә, иске таныш, господин Банаев!

Кәрим. Олаулар җыясы бар. Хәзергә сау бул, Батырхан. (*Чыгып китә.*)

Батырхан. Соң сез ничек үзегез дусларыгыз белән Себергә Колчак артыннан китә алмый калдыгыз?

Әхтәм Банаев. Ялгышасыз, әфәндем... Себергә минем элекке дусларым, хәзерге дошманнарым китте...

Батырхан. Алаймы? Соң теге вакытта чекларга ант итүче кем иде?

Тимеркәй (*баядан бирле ачуланып торган җиреннән кинәт кузгалып, револьверын тартып ала да Банаевка таба ташлана*). Нәрсәгә тагы юкны сорап торырга инде?! (*Атарга омтыла.*)

Батырхан (*ике арага кереп, Тимеркәйнең кулларыннан тота, туктата, каты шелтәле тавыш белән*). Тимеркәй, мин сиңа ничә рәт әйттем, башбаштаклык кылма дип!

Тимеркәй (*әрнү катыш каһәрле тавыш белән*). Син теге вакытта да, ялган сүзенә карап, Бәдри мулланы җибәрдең...

Батырхан. Хәзергә чыгып тор: син үзеңә-үзең баш була алмыйсың!

Тимеркәй (*ачулы куркыту белән*). Мин сине, барыбер ячейка судына бирәчәкмен. (*Кызулап чыгып китә.*)

Батырхан (*Банаевка*). Сез үзегезнең чекларга ант итүегезне яшермисез, алайса?

Банаев. Яшермим. Аннан бирле күп сулар акты. Алар эченнән рус бае килеп чыкты. Мин хәзер советчы. Безнең милли азатлыкларымызга Советтан башка юл юклыгы безгә кояш кебек ачык булды...

Батырхан. Ярый, ярый. Сез моннан соң Советка каршы бармаска сүз бирәсезме? Әллә шуны язып та бирәсезме?

Банаев. Язам, язам... Советка ант итеп язам...

Тимеркәй (*тәрәзәдән кычкыра*). Батырхан иптәш, дивизия штабыннан приказ китергәннәр!

Батырхан (*кызуланып чыгып китә. Зәйния белән килеп керәләр. Кулында пакет*). Тиз генә юл кирәкләрен әзерлә, без хәзер китәбез.

Зәйния. Син бит безнең полк ун көн отдыхта дигән идең.

Батырхан. Шулай дигән идем. Ә хәзер приказ килде.

Зәйния. Алайса, мин дә синең белән китәм.

Батырхан. Син анда нишләрсең?

Зәйния. Мин монда калсам, акылымнан язармын. Мин анда сине тәрбияләрмен, авыру солдатларны карармын.

Батырхан (*аз гына вакыт Зәйниянең күзенә сүзсез карап тора, карарга килеп кулын кыса*). Ярый. Алайса, тиз әзерлән!

Зәйния. Менә нинди көтмәгән бәхет! (*Җиңел, шат атлап чыгып китә.*)

Тышта бик якыннан рәттән өч мәртәбә мылтык аткан тавыш килә. Кулына револьвер тотып **Тимеркәй**, аның артыннан ук **Әптерәш карт** килеп керә.

Батырхан. Бу кем эше? Кем шаяра анда?

Тимеркәй (*агарынып, ләкин кискен тавыш белән*). Һичкем шаярмый! Мин Вәли абзыйны атып үтердем.

Батырхан. Кем кушты сиңа очраган бер кешегә атып йөрергә? Бу нинди башбаштаклык! Китер монда! (*Револьверын ала да караватка ташлый.*)

Тимеркәй. Теләсәң ни эшләт: мин барына да риза! Ул явыз кулак әллә кем белән сөйләшеп бара: теге карт иблис Шәйбәкне дөмектергәннәр иде, ди... Ярый, ару булган инде куштан Камәрне дә җәһәннәмгә озатканнар икән, ди. Ишеткәч, түзмәдем... үземне-үзем белмичә аттым...

Әптерәш. Акылың бармы? Ул бит синең агаң! Ул синең атаңның туган энесе бит!

Тимеркәй. Агайны гына түгел, андый урында туган атайны да кызганмам мин!

Әптерәш. Ут белән уйныйсыз, балалар. Алла үзе сакласын!

Батырхан. Агаңмы, атаңмы — эш анда түгел! Син моннан соң болай башбаштакланма! (*Тимеркәйне бер читкә ала. Яшерен рәвештә.*) Штабтан приказ бар. Колчак безнең Ялантау фронтын өзгән. Без хәзер китәбез. Бар, әзерлән. (*Банаевка таба килә.*) Безнең эшләр бик тыгызланып китте... Кая, бетердегезме?

Банаев (*каушап, калтыраныбрак кәгазьне бирә*). Шулай ярармы икән?

Батырхан (*кәгазьне укымый, карамый, тәрәзә төбенә ташлый*). Ярый, ярый... Барыгыз... Мин сезне сынау өчен чыгарам... Аз гына бер эшегез сизелсә, хөкемсез-нисез үз кулым белән атармын мин сезне!.. Барыгыз!..

Банаев. Рәхмәт сезгә! Бик рәхмәт, Батырхан иптәш... Мин Советка тугры, иманлы хезмәтче булырмын. (*Башын ия, чыгып китә.*)

Батырхан. Менә кызганыч бәндәләр!

Җ а м а л и (*аның белән биш-алты ярлы крестьян керә*). Батырхан туган, син китәсең дип ишеттек. Шуңа күрә килдек. Шәйбәк бабайны үтерделәр, Шәңгәрәйне, тимерче Габдулланы үтерделәр... Мөгаллимә Камәрне дә үтерделәр... Шул үтерүгә катнашканнарның күбе якты дөньяда рәхәтләнеп йөриләр... Аларга бернәрсә дә булмый калырмыни шулай? Сез киткәч, кем карар?

Б а т ы р х а н (*крестьяннарга*). Әйтүегезгә бик рәхмәт! Барын да карарбыз. (*Тимеркәйгә.*) Тимерхан туган, син монда иртәгәчә кал: мәрхүм Камәр иптәшне кадерләп, олылап күмәрсез... Менә бу иптәшләр әйткән эшне дә карарсың!

Т и м е р к ә й. Булмас, җизни, булмас. Мине беләсең: ул эшләрне тикшерә башласам, мин йә һәммәсен кырып бетерермен. Мин синең белән сугышка китәм.

Б а т ы р х а н (*җиңелчә елмая, Тимеркәйнең кулын кыса*). Тимерхан туган, син хәзер үзеңне бик яхшы аңлый башладың. Вакыт-вакыт бик артык кызып китүләрең өчен мин сине гаепләмим. Насыйб иптәш, алайса, син иртәгә чаклы монда калырсың, тикшер, гаеплеләрне яп. Ләкин атма. Хөкем ахырдан булыр.

Н а с ы й б. Ярый. Аңладым.

З ә й н и я (*юлча киенеп керә. Батырханга килә*). Менә мин әзер.

Б а т ы р х а н. Безнең белән китү кан эченә барып керү икәнен аңлыйсыңмы?

З ә й н и я (*кискен, нык*). Уйладым, аңлыйм. Синең белән бергә булгач, мин ут эченә дә шатлык белән барып керәчәкмен!

Б а т ы р х а н (*кузгала, аның артыннан башкалар да*). Киттек, иптәшләр! (*Чыгып китәләр.*)

Ф ә т х и я (*тәрәзәдән караган хәлдә*). Ходаем, бар икән кодрәтең! Менә ничә атналар инде, көн үтәләр, төн үтәләр. Илаһым, хуҗам, кайдан килә, кая бара бу бәндәләрең?!

Шул хәлдә акрын гына пәрдә төшә

1920 ел

Б и р е м н ә р һ ә м с о р а у л а р

1. Пьесага анализ ясагыз: тышкы һәм эчке конфликтларын табыгыз.
2. Кабатланган вакыйгаларны эзләгез, шуларга нигезләнеп әсәрнең темасын белегез.
3. Зәйния белән Батырхан мәхәббәте аша автор ни әйтергә теләгән? Шул хакта сөйләгез.
4. Батырхан, Тимеркәй, Камәрнең уртак сыйфатларын күрсәтегез.
5. «Яңа кешеләр» пьесасы әдәбиятка яңалык өстиме?

Гражданнар сугышы драма әсәрләренә булган ихтыяҗны бермә-бер арттыра. Армиягә алынган меңнәрчә татар егетләрен революцион рухта тәрбияләү өчен, театр иң кулай чара иде. Шуңа күрә гражданнар сугышы елларында драма әсәрләре күп языла.

Билгеле бер идеяне пропагандалау күздә тотылганлыктан, бу пьесаларның сюжет төзелешендә һәм конфликтларында охшашлык зур.

Аларның берише традицион мәхәббәт темасына багышлана. Сыйныфлар каршылыгын элеккечә мәхәббәт белән бәйли. Ләкин моңа кадәр ярлы як шиксез җиңелеп кала торган булса, хәзер, киресенчә, яратышучыларның бай ата-аналары җиңелә. «Урал суы буенда» пьесасында (авторы Мирхәйдәр Фәйзи), мәсәлән, бай үзенең кызын ярлы егетенә бирүгә каршы була. Яшьләр бай сүзенә колак салмыйлар. Авылга китәләр. Өйләнешәләр. Бай кызы ярлы крестьяннар белән бергә эшләп йөри. Аны авыл кешеләре яраталар. «Асылъяр» пьесасында да М. Фәйзи конфликтны ярлы егет файдасына чишә. Соңрак язылган «Ак калфак» әсәрендә дә шулай итә. Ярлы егете үлсә дә, ул җиңүче булып кала. Бай кызы үзенең хатасын таный. М. Фәйзи бу әсәрләрендә нәфрәт хисе турында язмый, байларга каршы көрәшкә чакырмый. Киресенчә, берсе бай, берсе ярлы булган яшьләр үзләренең сыйнфый аерымлыкларын бөтенләй оныталар.

Пьесаларның башка беришендә сыйныфлар каршылыгы гаилә эченә килеп керә һәм туганнар конфликтына әйләнә.

Фатих Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» драмасында, мәсәлән, эшче кызы Айсылу Хатыйп байга кияүгә чыга. Айсылуның атасы шуңа күрә кызыннан баш тарта. Ләкин яшь хатын сыйнфый нәфрәтен югалтмаган икән. Ул иренең яман эшләрен органнарга барып хәбәр итә һәм аны төрмәгә яптыра. Бу әсәрдә нәфрәт башка барлык хисләрдән дә өстен булып чыга.

Ләкин туганнар мөнәсәбәтен бозган сыйнфый каршылык күпчелек пьесаларда башкача хәл ителә.

Шамил Усмановның «Канлы көннәрдә» пьесасында туганнарның берише аклар ягында, икенчеләре кызыллар ягында сугыша. Ләкин бу хәл аларның туганлык хисләренә зыян китерми. Туганнар өйләрендә җыелалар, элеккечә бер-берсен хөрмәт итеп, сабыр гына әңгәмә коралар.

Гражданнар сугышында танылган комиссар Шамил Усманов, әлбәттә, дошман якның яман сыйфатларын, ә инде кызылларның яхшы сыйфатларын гына сурәтли. Аклар кансызлар,

рәхимсезләр, әдәпсезләр. Кызыллар исә бар да шәфкатьлеләр, тәртиплеләр. Билгеле, мондый бүленеш заман идеологиясенә тулысынча яраша. Ләкин шуңа карамастан комиссар Усманов үзенең әсәрләрендә укучыларын нәфрәтләндерми.

Галимҗан Ибраһимов та,— Шамил Усманов кебек, большевиклар идеологиясен актив рәвештә пропагандалаучы әдип. Шуңа күрә ул да пьесасының үзәгенә сыйныфлар көрәшен куя. Башкалар кебек үк дошман якны кара буяу белән кызылларны, ярлыларны акка гына буйый. Ләкин сыйныфлар көрәшеннән гыйбарәт булган тышкы конфликт әсәрнең төп конфликты түгел.

Гражданнар сугышы кешеләрне рәхимсезлеккә өйрәткән. Алар хаклыкны көч белән генә урнаштырып була, дип уйлыйлар. Батырхан, Тимеркәй, хәтта Камәр дә ачулары чыкканда, үзләрен тыя алмыйча, коралга тотыналар. Яшьләрне авылның өлкәнрәк кешеләре тыеп тора. Алар мәгънәсез кансызлыкны берничек тә аклап булмый торган гөнаһлы, хаксыз бер эш дип беләләр. Пьесаның төп конфликты шушы ике төркемнең дөньяга карашлары арасындагы каршылыкка нигезләнгән. Шәйбәкләр, Әптерәшләр үтемле итеп әйтәләр һәм Батырханны хатасын танырга мәҗбүр итәләр. Үз чиратында Батырхан Тимеркәйнең юкка гайрәт чәчүен гаепли.

Бу конфликтта шәфкатьлелек хисе нәфрәт хисеннән көчлерәк булып чыга.

Пьесада фәкать мәхәббәте белән генә яшәүче юаш, әүлия кебек шәфкатьле Зәйния дә җиңүче булып чыга. Зәйния үзенең ялкынлы мәхәббәте белән сугышларда, төрмәләрдә бәгъре каткан ире Батырхан йөрәген эретә ала. Ире күпме генә карышса да, үзенекен итә, Батырханнан аерылмас өчен, аның белән сугышка китә.

Шамил Усманов та, Галимҗан Ибраһимов та, Мәҗит Гафурилар, Фәтхи Бурнашлар кебек, революциянең ирек алып килүенә ышандылар. Ирекне, тигезлекне фәкать сыйныфлар көрәше белән генә яулап алырга мөмкин, дип уйладылар. Ләкин, шуның белән бергә, Шамил Усманов, Галимҗан Ибраһимов, күпчелек татар язучылары кебек, идеологиянең аерылгысыз өлеше булган рәхимсезлеккә, кешеләрдә нәфрәт тәрбияләүгә каршы чыктылар. Алар яңа тормышның яңа кешеләрен үзара тату яшәүче, үз ялгышларын үзләре төзәтә алучылар итеп күз алларына китерделәр.

Татар әдәбияты хәтта рәхимсез гражданнар сугышы елларында да бердәмлек идеясен саклап кала алды.

20—30 нчы ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

20 нче еллар әдәбияты гражданнар сугышы тәмамланып, колхозлар төзелә башлау елларын эченә ала. 30 нчы еллар әдәбияты 30 нчы елдан алып Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр дәвам итә.

ӘДӘБИЯТ

Татар әдәбияты да, башка халыклар әдәбияты кебек, хаким итүче идеология басымы астында яшәде. Социализмга фәкать авырлыклар, канлы көрәш аша гына ирешергә мөмкин дип чын күңелдән ышанган әдипләр бөтен сәләтләрен шул эшкә җиктеләр. Әдипләр иске дөньяны яманладылар, яңасын мактадылар, хыялдагы киләчәк тормышны чын итеп яздылар.

Гражданнар сугышы елларында башланган бу юнәлеш, шулай итеп, үзенең эчтәлеген түкми-чәчми 20—30 нчы елларда да дәвам итте. Ләкин 20 нче елларда сыйнфый көрәш темасына тагын бер революцион тема — иске мирасны кире кагу темасы да килеп керде. Гасырлар буена тупланган мәдәни мирастан баш тартучылар үзләрен «пролетариат культурасы»н тудыручылар дип атадылар.

Пролеткульт безгә рус мәдәниятеннән килеп керә. Әдәбиятта үзләрен символистлар, футуристлар, имажинистлар дип атаучылар барлыкка килә. Татар әдипләре дә, күп уйлап тормый, үзләренә шундый ук исемнәр тагалар. Һади Такташ, мәсәлән, үзен символист дип, Кави Нәҗми — имажинист, Гадел Кутуй — футурист дип игълан итәләр. Шундый төрле төркемнәргә кергән яшь әдипләр, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан иҗатларын кире кагып, моңа кадәр күренмәгән эчтәлекне өр-яңа алымнар белән күрсәтергә тырышалар. Әмма яңа эчтәлек тә, яңа алымнар да уйлап чыгара алмыйлар. Әсәрләрен халык укымавын күргәч, дәгъваларыннан кире кайталар.

30 нчы елларда әдәбиятның революцион юнәлеше алдагы еллардагы эчтәлеген саклап калып, аңарга **яшерен дошман белән көрәш** эчтәлеген өсти.

Ләкин көчле идеологик басым астында да әдәбият үзенең асылын саклап калырга тырыша. Галимҗан Ибраһимовның 20 нче елларда иҗат иткән «Алмачуар» һәм «Кызыл чәчәкләр»

әсәрләрен искә төшерегез. Әдип бу әсәрләрендә дә XX йөз башы әдәбияты күтәргән берләшү идеясенә тугрылыклы булып кала. Үзеңне генә яратуның явызлыкка тиңләшүе, дуслык хисенең сыйнфый дошманлык хисеннән өстен булуы турында яза. Кешеләрне дуслаштыру, бер-береңә ярдәм итү темалары башка әдипләр әсәрләрендә дә күп кабатлана. Тормыш авырлыгын күреп, аны үз җилкәләрендә татыган язучыларның күбесе хакыйкатьне төрле юллар белән әйтергә тырыштылар. Татар әдәбиятының реалистик юнәлешен шундый әдипләр дәвам иттеләр.

Сыйнфый көрәш темасы, билгеле, бу юнәлешне дә читләтеп үтә алмый. Сыйнфый көрәш конфликтына корылган шаблон сюжет, хәтта Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Кәрим Тинчурин кебек үз фикерләрен әйтә ала торган язучылар иҗатына да килеп керә. Ләкин әдипләр шул сюжет эченә үзләре әйтәсе килгән фикерне салырга өйрәнәләр. 20—30 нчы еллар әдәбиятында субъектив эчтәлек бик еш кына объектив эчтәлекнең капма-каршысы була.

Бу елларда татар әдәбияты шул рәвешле үсә.

20 нче ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫНДА РЕВОЛЮЦИОН РОМАНТИЗМ ЮНӘЛЕШЕ

Гадел Кутуй

КАРТ ПЫЧКЫЧЫ

Мин карт инде.
Билем — ялан.
Бик күп еллар урман кистем.
Дәштем... Дәшәм:
Кайда сез?
Урман,
Ул әле дә бик яшь әле,
Ә минем биттә еллар сөте каймаксыз!
Пычкы кисә,
Пычкы йөри,
Пычкы пычкый
Пычкылтап!
Пычкы сырлый,
Пычкы керми,
Пычкы чыкмый,
Чыкмый һап!

Еллар белән санаганда
Мин карт инде.
Күңел — шаян,
Пионер кебек шаулый, туймый ул.
Йөрәк коммун улын сагынып тибә.
Ярый, кичкә күрем...
Әйдә, пычкы!
Бераз тагын уйныйк!
Пычкы кисә,
Пычкы йөри,
Пычкы пычкый
Пычкылтап!
Пычкы үткен.
Пычкы күмелә.
Пычкы чыга,
Чыга шәп!

1925 ел

Кави Нәҗми

ИКЕ АНТ

Бәйдән ычкынган арыслан мин бүген.
Сахрадан киң диңгез өстендә йөзеп,
Алдымда көрәш чырагын тергезеп[1],
Уйладым:
Бар төрмәләрнең читлеген
Пыр тетәргә чукмар астына тезеп.

1922 ел

Мансур Крыймов

КӨРӘШ КОЧАГЫНДА

Хәзер иркен сулап,
Эшли җырлап-җырлап,
«Мин» дими ул.
«Миңа» дими ул,
«Без»,— ди.
Шул «безләр» өчен генә
Укый да, эшли дә...

1925 ел

[1] Чырагын тергезеп — чырасын яндырып.

Демьян Фәтхи
(1906—1943)

ЙОЛДЫЗЛАР

Күпме... күпме күзләрне үзеңә текәлдереп макталган зәңгәр күк йөзе!

Чиксез күп бриллиантларны урынлы-урынсыз тезгән хан кызының зәңгәр чабуы кебек чуар бушлык!

Киң, зифа, гүзәл булуына карамастан, синең зифалыгыңа да, матурлыгыңа да бүген исебез китми. Җемелдәгән йолдызларыңны тиеләрчә сокланып карау гына минем күңелгә ләззәт бирә алмады. Аларны кулга алып сыйпыйсы, иркәлисе килде...

Ә син назлы идең... Бер генә йолдызыңны да иркәләргә, кочарга бирмәдең...

Һәр кич, алар чәчәк аткан саен, минем күңелемдә аларга нәфрәт туды.

Мин җиргә күчтем...

Безнең яшәү туфрагыбызда чиксез күп йолдызлар тудылар. Һәр кич, синең белән бер үк вакытта безнең җир дә көләч нурлар белән балкый башлады.

Кичә Волхов, иртәгә Днепр, берсекөнгә Идел... Шулай йолдызлы күккә түгел —

Йолдызлы Җиргә
Әйләнеп балкыр, янар!

Ул җир йолдызлары безнең көндәлек тормышыбызда безгә иркә булдылар.

Ә син?! Хан кызының бриллиантлы файдасыз чабуы кебек ерак бушлык!!

Бүгеннән соң синең хыялый идеаль зифалыгың безнең хисләрдә урын тапмаслар! Безнең үз кочагыбыз, үз иркәбездәге йолдызлар сине җиңделәр... Җиңделәр!..

Корыч музыкалары аркылы мин әнә шуны ишетәм, аңлыйм.

1928 ел

Биремнәр

1. К. Нәҗми, М. Крыймов шигырьләренә бәя бирегез. Шигырьләрнең үзегезгә ошамаган якларын әйтегез.

2. Г. Кутуйның «Карт пычкычы» шигырендә кабатланган урыннарны табыгыз. Шулар аша әсәрнең эчтәлеген белергә тырышыгыз. Шигырьнең ясалма урыннарын күрсәтегез. Г. Кутуйның нигә шулай язуын аңлатыгыз.

3. Демьян Фәтхинең «Йолдызлар» нәсерен укып, эчтәлеген сөйләгез. Авторның ни өчен табигать матурлыгыннан йөз чөерүен аңлатыгыз.

«Ике ант», «Көрәш кочагында» шигырьләре икесе дә лирик шигырь булуга дәгъва итәләр. «Ике ант»та лирик герой үзенең көче белән мактана. Күрәсең, үзенең көчле сыйныф вәкиле булуына горурланадыр. Югыйсә берүзе бөтен төрмәләрне туздыра алмас иде. Төрмә дигәне дә, күрәсең, җыен җинаятьчене яба торган йорт түгелдер. Чөнки каракларны, кеше талаучыларны, үтерүчеләрне иреккә чыгарудан ни файда. Шуннан чыгып, әсәрнең эчтәлеген лирик геройның горурлыгы, шатлыгы дияр идек, әмма әсәрнең стиль үзенчәлеге башка нәтиҗәгә китерә. Монда үзара бәйләнешләрен табу мөмкин булмаган арыслан, сахра, диңгез, көрәш чырасы, чукмар нинди дә булса хис белдереп килүдән бигрәк, авторның үзен күрсәтергә тырышуы, үз-үзенә соклануы турында сөйлиләр.

«Көрәш кочагында» шигырендә дә эчтәлек үзара бәйләнешле детальләр аша ачылмый — турыдан-туры әйтелә. Автор: без шәхес буларак үзебезне югалттык, ди, һәм ни өчендер шул фаҗигагә шатлана. Бу шигырьдә дә автор, хисен сөйләүдән бигрәк, үзенең табышларына соклана.

4. «Карт пычкычы», «Йолдызлар» әсәрләрендә дә шул ук сыйфатлар кабатланамы? Соңгы ике әсәрнең алдагы ике шигырьдән аермасы бармы? Бу сорауларга үзегез җавап бирегез.

Фатих Әмирхан
(1886—1926)

30 яшьтән аз гына узган Фатих Әмирхан бу елларны өлкән әдипләрдән санала. Өлкән әдип, билгеле, үзенең иманына хыянәт итми: дөньяга карашын да, язу стилен дә үзгәртми.

Язучының революцияне шатланып каршы алуын беләсез. Әдип чын күңелдән шатлана, чөнки илдәге бу зур үзгәрешләр татарларны коллыктан коткарыр дип ышана. «Хәрефкә ябышып ятумы, лакейлыкмы» мәкаләсендә ул:

«Октябрь революциясе юлына шулкадәр корбан биргән, олугъ революцияне саклап сугышуда Русия пролетариатының алгы сафында килгән татар пролетариаты, әгәр үз-үзен властьны кулга алырга сәләтсез дип таныса, бу тануның астында Русия эшче сыйныфын, гомумән, властька сәләтсез дип тану, Октябрь революциясен тарихи бер хата дип икърар итү булыр иде», — дип яза. Революциянең мәгънәсен халыкларга милли азатлык бирүдә күрә әдип. Бернәрсәне кат-кат кабатлый: Октябрь революциясен назари һәм гамәли[1] яктан идарә итүче фикер ияләре олугъ революциянең кызыл әләменә язды:

«Һәр милләтнең тәкъдире шул милләтнең үз пролетариаты кулына тапшырыла, һәр милләт мөстәкыйль сәяси яшәү хакына хокуклыдыр», — ди.

Әдип кешеләрне хезмәткә чакыра. Аларның тынычлыкта матур яшәүләрен тели. Шагыйрьләрнең бериште көч белән көрәшкә чакырганда, Фатих Әмирхан кешеләргә матурлык бүләк итәргә хыяллана:

«Китерегез миңа гөлчәчәкләр! Мин аларны күз алдымда җәелгән киң кырларга сибәрмен, шул кырларда мин аларны назлап, иркәләп үстерермен. Минем гөлчәчәк кырымнан таралган хуш ис бөтен арыган, талганнарга шагыйранә ял бирер!» — дип яза үзенең бу еллардагы иң гүзәл «Чәчәкләр китерегез миңа!» нәсерендә.

---

[1] Назари һәм гамәли — теоретик һәм практик.

Фатих Әмирхан 20 нче елларда да киләчәккә өмет белән яши. Көтелгән матур тормыш социализм булырга тиеш дип ышана. Әмма бервакытта да идеалны чынбарлык белән буташтырмый. Акны — ак, караны кара дип яза. «Шәфигулла агай» хикәясе шуңа дәлил.

ШӘФИГУЛЛА АГАЙ

(Дустанә шарж)

Анархия — менә нәрсә генә гакылларга да, тойгыларга да чын хөррият алып киләчәк!

1

Ленин күмелгән көндәге митингтан өенә кайтып кергәндә, Шәфигулла агайның күңеле соң дәрәҗәдә нечкәргән, күзләре яшәргән иде.

— Бүгенге көннең нинди көн икәнен беләсеңме син, катын — диде Шәфигулла агай хатыны Сәрвигә.— Бладимир Ильичны күмгән көн бит бүген. Бөтендөнья эшчеләре ятим калган көн бит бүген, бөтен җир, күк җыларга тиеш көн бит бүген...

Шәфигулла агайның моннан соңгы сүзләре аңлашырлык булмады: елаш, мышкылдаш, борын йомшару һәм күз яшенең көчәюе сүзләрне басканнар иде.

Сәрви, ире елаудан туктаганнан соң гына, сүзгә кереште.

— Байлар бик куанырлар инде, безнең фәкыйрь халыкка тагы көн калмас инде,— диде.

— Юк,— диде Шәфигулла агай, урыныннан сикереп торып, йодрыгы белән күкрәгенә сукты.— Юк, катын, байларга юл бирү юк инде ул! Рәхимов иптәш әле генә менә шуны сөйләп кайтарды: «Бладимир Ильич үлгәнгә карап,— ди,— без буржуйларга юл бирмәбез,— ди,— Ленин үлмәде ул, аның партиясе калды,— ди.— Инде Ленин үлгәч, һәммә сознательный рабочийлар партиягә керергә тиешләр, рабочий халык партиягә язылып, бөтен дөнья буржуйларының котларын чыгарсын»,— ди. Шәфигулла агай Рәхимов иптәшнең сүзләрен кызып-кызып, гайрәтләнеп-гайрәтләнеп, кат-кат, әйтә-әйтә сөйләде.

— Һәй катын! — диде.— Һәй катын, син дә сознательный булсаң иде, диде, аның йөзеннән, күзләреннән бер татлылык, әгәр Сәрви дә сознательный булса, бик татлы булачаклык күренеп тора иде.

Соңгы бер-ике ай эчендә Сәрви картыннан бу сүзне шактый еш ишетә иде. Үз тирә-күршеләрендәге бик күп ирләрнең хатыннарын бик кабахәт сүзләр белән сүгүләрен көн саен ишетеп тора торган Сәрви Шәфигулланың шулай начар сүгенмәвен күңеленнән тәкъдир итсә дә[1], бу сүз аны җәберсендерә, кимсендерә, байлар яклы булуны күрсәтә шикелле иде.

— Бик әкәмәт кеше син, карт, тотасың да шулай дисең. Минем кайчан байлар яклы булганымны күргәнең бар? — диде Сәрви җәберсенү тавышы белән.

— Ул гына җитми, катын! Дурман бар синдә, религиозный дурман! Шул харап итә сине, шул! Товарищ Михайлов әйтә: «Сезнең катыннарыгызда религиозный дурман бар,— ди.— Сезгә дә чын сознательный рабочийларча торырга, коммунистларча «Красный быт» төзергә ирек бирмиләр»,— ди. Рәхимов иптәш әйтә: «Татар рабочийларын да шул эш харап итә. Аларның да катыннары дин белән агуланганнар,— ди,— дин — әфьюн ул,— ди. Сез, ирләр, аларга аңлатырга тиешләр»,— ди.

— Әстәгъфирулла, диген, карт җүләр... Ходай орыр үзеңне. Шәфигулла теленә бүген әүвәл мәртәбә кергән «дурман» дигән сүзнең мәгънәсе аңлашылмауга карамастан, Сәрвигә бик начар тәэсир итте. Бу сүз «не сознательный»га караганда да авыррак шелтә сүзе, каты сүгенү сүзе шикелле тоела иде. Сәрви ачуланды:

— Дурман, имеш! Мин нишләп дурман булыйм, минем, Аллага шөкер, бер гаебем юк! Мине бер кеше дурман дия алмас! Син үзең менә карт башың белән Аллага тел озайтып утырасың. Менә шул кеше настоящий дурман була ул! — дип, шактый ярсыды.

Рабочий Шәфигулланы «син үзең дурман» дип сүгүе аның көләсен китерә иде. Ачусыз татлы көлеш белән көлеп җибәреп ул:

— Һәй катын,— диде, ахырын әйтеп бетермәде.

2

Көннәрнең берсендә Шәфигулла агай төче шатлык һәм ләззәтле рух күтәренкелеге белән өенә кайтып керде. Сәрви өйдә булмаганлыктан, ул уйлап кына ләззәтләнеп утырмакчы булган иде, барып чыкмады.

— Шөкер Ходайга, партийный да булдык бит,— дип уйлана гына башлаган иде, кинәт куркынып китте:

— Тфү-тфү,— дип, ике ягына икешәр мәртәбә төкерде, какой чорт, мин сиңа әйтим, Ходайга шөкер булсын, карт җүләр!

---

[1] Тәкъдир итсә дә — хупласа да.

Синең үзеңнең дурманың чыгып бетмәгән әле,— диде дә үз каршындагы диварга эленгән иске шәмаилгә карап тора башлады. Инде саргая башлаган кәгазьгә чолгап-чолгап бисмилла язылган иде. Шәфигулла хәйләкәр, булдыклы көлеш белән көлеп җибәреп:

— Һһһәй! — диде,— һһһәй, без рабочий халыкны шушы дурманнар хәзергә хәтле харап итеп тордылар шул,— диде һәм рамлы бисмилланы дивардан алып, бераз вакыт нишләтергә белмичә кулына тотып торганнан соң, пөхтәләп кенә кәгазьне рамнан алды һәм, сигезгә бөкләп, кесәсенә салып куйды.

— Пример булыйм әле барсына! — диде.

Ярты сәгать үтәр-үтмәстән, Шәфигулла агай бик ашыгып, завод капкасыннан барып керде һәм җыелышып торган эшчеләр төркеменә килеп җитте дә:

— Иптәшләр, минем сезгә бер гозерем бар, завком председателен, ячәйкә секретарен, үземезнең эшче-хәбәрчеләрне чакырып чыгарыгыз.

Чакырылган кешеләр табып китерелгәнче, Шәфигулла агай көтү сабырсызлыгы белән ары-бире йөренгәли торды. Килеп җиттеләр. Шәфигулла агай, йөзенә серле, төче бер төс чыгарып, уртага басты, татлы гына тамак кырды, тантаналы тавыш белән сүз башлады:

— Иконалар, бисмиллалар безнең эшче халыкны хәзергә хәтле бик күп изеп тордылар. Без, сознательный эшчеләр, ул дурманнарны бетерергә тиешләр. Менә мин сезгә пример! — Шәфигулла кесәсеннән бисмиллалы кәгазьне чыгарды, түгәрәкләп әйләндереп, җыелганнарга күрсәтте дә:

— Мин бу бәдбәхетне стенага эленеп куелган җиреннән тартып төшереп, монда алып килдем,— диде дә урталайга ертып, җиргә ташлап, таптарга кереште:

— Менә! Менә! Менә! — биеп-биеп таптады. Рәхимов белән ячейка секретаре кул чабалар. Тыңлаучылар арасыннан аларга иярүче шактый булды. Таптап туктавына, шулар ук Шәфигулла агайны һавага да чөяләр. Ул үзе чөелә башлау белән, сөйләнәсөйләнә, «Урра!» кычкырырга кереште.

— Урра! Пример булырлык сознательный карт! Урра! Илле дүрт яшендә! Урра! Егерме дүрт ел станокта эшли!

Җиргә баскач, Шәфигулла агай эшче-хәбәрчегә юнәлеп, нотык сыман бернәрсә сөйләде:

— Менә шушындый пример булырлык эшләрне гәзиткә язып торыр өчен бер хәбәрче сайлыйк. Безнең хәбәрчемез гәзиткә

юк-бар такмаза язып тормас, эшчеләр өчен кирәкле менә шушындый эшләрне язар.

Заводтагы эшен тәмамлап өенә кайтканда, әле Шәфигулла агайның татлы, тантаналы кәефлелеге кимемәгән иде. Ул Сәрвигә якынрак килде дә:

— Синең дурманыңны күз алдында күреп, чыдап тору мөмкин дә түгел, катын! Кадеремне белергә тиеш, менә ирең шуның аркасында бөтен эшче-крәстиянгә пример булды. Кем ире дигәндә, Сәрви ире диярләр бит, сиңа да йөз аклыгы, мин сиңа әйтим. Синең дурманың урынына мин Владимир Ильич портретын алып кайтып элеп куям, бөтен эшче-крәстиянгә тагын бер пример, мин сиңа әйтим,— диде.

— Син, карт җүләр, әллә инде котырынып коммунистлыкка да язылдыңмы?

Шәфигулла, үз кәефен бер дә бозмыйча татлы җавап бирде:

— Иреңне берсүзсез партиягә яздылар. Андый бәхетләрне төшендә күрергә зар булып йөрүчеләрнең бетәсе юк. Һәй катын, сознательный булсаң иде син, бу шатлыкларның, бу бәхетләрнең кадерен генә белеп торыр идең.

3

«Кызыл тормыш төзү» турындагы митингтан Шәфигулла агай ячейка секретарен һәм фабрикком рәисен ияртеп кайтты.

— Сәрви иптәш, карт-март дигән сүзләреңне хәзергә куеп тор инде, иртәгә, сәвитски никях укытканчыга хәтле мин сиңа ир түгел, син миңа катын түгел,— дип, Шәфигулла серле, төче көлеп җибәрде. Аннан соң алып килгән кунакларына карап:

— Сез, иптәшләр, шаһит булыгыз: Сәрви миннән талак, талак, өч мәртәбә талак, мең мәртәбә талак! — диде дә, төче елмаеп, Сәрвигә таба якынлаша башлады. Сәрви, җылый-җылый, ирен сүгәргә тотынды:

— Карт эт, котырынды бит, егерме ел торган катыны ярамый башлады бит, балаларны да ятим итә бит.

Шәфигулла агай, көч-хәл белән хатынын елаудан туктатып, аңа үзенең планын аңлатты.

— Рәхимов иптәш әйтә: «Красный быт» төзеп тора башламыйча, иске семьяны җимермичә торып, сезнең һичберегез чын коммунист була алмый, чын сознательный була алмый»,— ди. Менә мин хәзер тагы бер кат эшче-крәстиян иптәшләргә пример булдым. Дурманлы никяхны бозып, чын красный никях укытырам...

Шәфигулла агай ул көнне Сәрвигә бер мәртәбә дә «катын» дип эндәшмәде, «Сәрви иптәш» дип кенә йөрде. Үз-үзенә генә сөйләнү кыяфәте белән уйчан сөйләнде.

— Ничә еллар, мин сиңа әйтим, дурманлы никях белән торып гомер әрәм ителгән, ничә еллар, мин сиңа әйтим, мулла никяхы белән бөтен эшче-крәстиянне изеп, хур итеп тотылган.

Икенче көнне «Гражданлык хәлләрен теркәү бүлеге»ндә никях теркәлеп кайткач, Шәфигулла агай Сәрвине яңадан «катын» дип йөртә башлады.

— Хәзер ячейка алдында, партийный иптәшләр алдында йөз аклыгы инде. «Карт дурак» дисең, дурак кеше бөтен эшче-крәстиянгә пример була аламы соң?

4

Икенче көнне эштән кайтканда, Шәфигулла агайны зур кызыл әләм тоткан хәлдә күрделәр. Ул вәкарьле[1] һәм эре бара иде. Эштән ул шул кыяфәттә кайтып керде. Әләмне зур хөрмәт белән карават өстенә яткырып куйды да:

— Катын, былбылны кичкә әзерләп куй! — диде. Сәрви аңлап җитмәде.

— Нинди былбылны, нәрсәгә әзерләргә? — дип сорады. Шәфигулла агай хатынының аңсызлыгыннан мәзәкчән көлеп җибәрде:

— Кемне булсын, Вәлиулланы әзерлә, дим. Син партийный түгел, сиңа Вәлиулла дип йөрсәң дә, Чуртулла дип йөрсәң дә ярый, ә безгә, партийный кешегә, баланы андый юк-бар дурманлы исемнәр белән атап йөртергә булмый. Бүген кичкә клубка алып барып, бөтен ячәйкә хозурында балага настоящий сәвитски исем куштырам.

— Җыен тузга язмаган нәрсәләр кайдан синең исеңә килә, адәм көлкесе булып бетәмез инде,— дип, Сәрви каршы килеп караган иде дә:

— Һәй дурман баш! — диде Шәфигулла һәм хәйләкәр көлеп җибәрде.— Эшче-крәстиянгә пример булырга теләмисең шул син.

Клубка барыр вакыт җиткәч, Шәфигулла алты айлык Вәлиулланы үз кулы белән кызыл әләмгә төрде дә Сәрвигә тоттырды. Үзе әләмнең таягына тотынды.

---

[1] Вәкарьле — горур.

Клубта Рәхимов иптәш «кызыл тормыш төзү» турында вәгазь сөйләде: вәгазендә Ленин сүзләреннән, Маркс әсәрләреннән, Калинин нотыкларыннан гыйбарәләр[1] китереп, «кызыл тормыш» төзүнең һәрбер коммунистка, һәрбер партийный эшчегә зарур икәнлеген бер дә шик калдырмаслык итеп бәян итте.

Вәгазьдән соң Рәхимов иптәшнең кушуы буенча «Интернационал»ны күмәк җырладылар.

Бу эш беткәч, Шәфигулла һәм Сәрвине, баласын күтәргән хәлдә, сәхнәгә чыгардылар. Җыелганнар боларны бик каты кул чабып каршыладылар. Шатлык һәм күзгә яшь килә башлау тавышы белән Шәфигулла:

— Йәгез, иптәшләр, тагы бер кат «Интернационал»дан җырлап алыйксана! — диде. Җырладылар.

Әүвәлдән төзелеп куелган программа буенча тантаналы эшләр башланды. Шәфигулла агай баланы ячейка секретарена китереп, төче тавыш белән Рәхимов өйрәтеп керткән нотык сыман нәрсәсен сөйләде:

— Бладимир Ильич үлде, әмма аның партиясе үлмәде... Иң кирәклесе әйтелеп бетмәгән иде, шуплыктан аларын Рәхимов өстәде:

— Иптәшләр, бу сознательный семья балаларын Бладимир Ильич кушкан юл белән алып барырга һәм РКП(б)ның корыч сафларына тагы бер сознательный эшче тәрбияләп үстерергә сүз бирә. Ур-ра! — диде.

Балага исем сайлау мәсьәләсе ячейка әгъзаларына тапшырылгач, һәркем үзе мөкатдәс[2] санаган һәм коммунистлык өчен мөнасиб[3] саналган исемне, фазыйләтләрен[4] сөйләп, гарыз итә[5] башладылар.

— Нинел! — дип кычкырдылар берничә тавыш берьюлы.— Ленин фамилиясенең хәрефләре кире яктан тезелүдән хасил була,— диделәр.

— Бу исем бик күбәйде инде, безнең ячәйкада гына кырык өч балага шул исем кушылды, балалар үзара бик саташтырырлар,— диделәр бер-ике кеше.

— Саташтырсалар, бигрәк тә яхшы. Коммунистический обществода берәм-берәм личностьларга игътибар булырга тиеш

---

[1] Гыйбарәләр — цитаталар.

[2] Мөкатдәс — изге.

[3] Мөнасиб — килешле, файдалы.

[4] Фазыйләт — өстенлек.

[5] Гарыз итү — тәкъдим итү.

түгел, личность булмый, коллектив кына була,— диде Коммунистический университетның үзен үзе Колынбайский дип йөртә торган бер шәкерте. Ячейканың зурлары аның сүзләренә игътибар итмәделәр. Аның укымышлылык күрсәтү өчен генә көчәнә торган егет икәнен һәммәсе дә беләләр иде инде. Исем эзләү дәвам иттерелде.

— Икстурт! — диде бер кызыл армияле.— Иптәш Троцкий фамилиясенең хәрефләрен кире яктан тезеп әйтелә.

— Нинилак! — диде картрак эшче.— Иптәш Калинин фамилиясе ахырдан башына таба укыла.

— Чфа фхт латта латтит! — диде үзен имажинист шагыйрь дип йөртә торган бер егет.— Яңа майлаган машинадан чыга торган революционный тавыш.

— Чигртики! — диде бер футурист.— Иске сүзләрне себереп түгеп, яңа сүзләр ясамасак, без бервакытта да «кызыл тормыш» төзи алмабыз, бервакытта да сознательный коммунист була алмабыз.

— Кызыл чүкеч! — хезмәт галәмәте һәм урак-чүкеч эмблемасының бер кисәге.

— Кызыл өргеч! — революция очкынын ялкынландыручы.

— Революция балтасы! — контрреволюцияне төбеннән кисеп аударучы.

— Пар казаны!

— Газ заводы!..

Тагы бик күп шундый исемнәр гарыз иттеләр. Иң ахырдан гына вәкарь белән Михайлов урыныннан торды да:

— Владимир! — диде.— Әнә Владимир Ильич иптәш үлгән елда туган балаларның күбрәге матур һәм яңгырашы шәп булган, шушы һәрбер коммунистка һәммә нәрсәдән кадерле булган исемне үз өстендә йөртсен, әйдә, бу исем күп миллионнар, бәйнәлмиләл[1] эшчеләренең исемнәре булсын, әйдә, бу исем эшчеләр арасында милләт аермасы бетүнең, шовинизм бетүнең галәмәте — символы булсын!

Сәрви мондагы эшләрне аңлап бетмәгәнлектән, кычкыручыларның Вәлиуллага яңа исем гарыз итеп кычкыралар икәнен дә чын-чынлап белми иде. Аның хәзергә хәтле мондый исемне күргәне юк иде.

Шәфигулла агайның бөтен йөзе һәм күзләре ачылып китеп төче елмайдылар. Төче тамак кырып ул:

---

[1] Бәйнәлмиләл — интернационал.

— Владимир! Урра! Владимир! Урра!.. Владимир Ильич үз йортыбызда була. Бәхетле җаннар, мин сиңа әйтим. «Интернационал»дан, җәмәгать!

Җырладылар. Берәү чыгып, Вәлиулла-Владимирның пионерлар сафына кабул ителгәнлеген сөйләп, аңар пионерлык билеты бирде. Балага киемлек һәм чүпрәклек кызыл материя бүләк иттеләр. Ата-анасына завод хисабыннан 30 сум акча бирделәр. Шәфигулла белән Сәрвине һавага чөйделәр.

Шәфигулла агай төче тойгыдан тәмам исергән, сүзләрен бөтен итеп сөйли алмас хәлгә килгән иде. Үз-үзенә сөйләгән кыяфәт белән генә озын-озын, бер-берсенә бәйләнешсез сүзләр әйтеп-әйтеп тора башлады:

— Бәхетле җаннар, мин сиңа әйтим, болар янында җәннәт нигъмәтләре бер тиен тормый, мин сиңа әйтим... Тагы бер кат пример, кадерен генә белик инде. Исләре китсен әле, мин сиңа әйтим, Калинин товарищларга барып ишетелсен әле, мин сиңа әйтим.

Клубтан киткәндә, Сәрви, күз яшьле тавышын күтәреп, иренә бәйләнә башлады:

— Минем балам Владимир булырга урыс баласымыни ул, урыс приказ бирә дип, балаңны тагы чукындырырга да алып бармассыңмы, карт дурак. Мин аларның 30 сумнары өчен баламны урыс ясап торырга соң! Акчаларын да, кызыл чүпрәкләрен дә башларына капласыннар.

5

— Балалар «Интернационал»ларын җырламый ятканнардыр әле,— диде Шәфигулла агай, ячейка җыелышыннан соңга калып кайтып. Йоклап ята торган балалары янына килеп, аларны уятырга тотынды:

— Балалар, былбыллар, торыгыз әле, бәбкәләрем, «Интернационал»ыгызны җырлыйк әле, бәгырьләрем.

Балалар, бик авырлык белән генә уянышып, теләмәстән генә аяк өсткә бастылар һәм, башка көннәрдәге шикелле, йөзләрен Ленин рәсеменә юнәлдерделәр. Шәфигулла агай җитди тавыш белән «Интернационал» җырларга кереште. Балалар да аның артыннан иярә башладылар.

Балалар яткач, Шәфигулла агай Сәрвине шелтәләргә кереште:

— Һәй, наданлык, ничә тапкыр әйтен, үзем юкта балаларга йоклар алдыннан «Интернационал» җырлатырга да ярамыйсың бит син. Әле ул гына җитмәгән, тагы без «Интернационал»

җырлаганда, урыныңнан да кузгалмыйсың, яулыгыңны да салмыйсың. Башыңа дурман оялаган шул синең!

— Харап булган икән! Балалар җыру җырламый йокыга ятканнар икән, күк җимерелеп төшмәсә ярар инде,— диде Сәрвиҗамал мыскыл тавышы белән.

— Күк җимерелмәсә, имеш! — дип, Шәфигулла кызып китте,— күк җимерелүдән дә яман шул, ун тапкыр яман, йөз тапкыр яман, миллион тапкыр яман, адәмнең партийный обязанносте бар, болай итеп торсаң, мин сиңа әйтим, кызыл тормыш төзү кайда да, партийныйлыгың кайда?

Бу көннән соң Шәфигулла агай балаларыннан һәр кич вә иртә икешәр тапкыр җырлата торган булды.

6

Беренче май көнен каршы алырга Шәфигулла агай алдан әзерләнә башлады.

Өй эче җыештырылды, күлмәк-фәләннәр юылдылар, ямалдылар. Ир балаларга кызыл фуражкалар, кыз балаларга кызыл яулыклар, Шәфигулла агайның үзенә кызыл чуклы кызыл кәләпүш алынды.

Сәгать биш тулгач инде Шәфигулла агай чыдамады, балаларны уятырга тотынды:

— Торыгыз, бәгырьләрем, безгә, партийный җаннарга, мондый изге бәйрәмнәрне йокыда уздыру килешми. Әнә анагыз шикелле несознательный кешеләргә генә бу көннәрнең кадерен белми йоклап яту ярый ул.

Сәгать җиде тулар-тулмаста Шәфигулла агай, балаларны тезеп, Володяны кулына күтәреп, өйдән чыгып китте.

Мәйданга барып җиткәнче, юлда берничә мәртәбә Шәфигулла агай, балаларны туктатып, «Интернационал» җырлатып алды.

Мәйданга килеп җитеп, аның буш икәнен күргәч, Шәфигулла агай бер көрсенеп куйды:

— Һай, халыктагы несознательныйлык, һай, наданлык! Шушы шатлыкларның кадерен белми әле халык...

Халык җыела башлаганчы озак вакыт үтеп китте. Балалар ара, ялыга башладылар.

Комсомоллар фиркасенең[1] төркемләнеп килүен күргән Шәфигулла агай җанланып китте.

— Менә киләләр! Бөтен дөньяга пример... Үсәләр соң бәхетле җаннар!

[1] Фирка — партия.

Озакламый пионерлар фиркасе күренде.

— Тәүфыйклары белән үсәләр дә соң, бөтен дөньяга пример булып.

Мәйдан шыгрым тулды. Кешеләр урыннан урынга күчә алмас булдылар. Шәфигулла агайның балалары Беренче майның фазыйләтләрен[1] сөйләүче уникe хатибның[2] нотыклары вакытында үз алларын каплаган зур кешеләрнең аркаларын бөтен вак-төякләре белән өйрәнә тордылар.

Шәфигулла агай революциянең башыннан бирле Беренче май көненең фазыйләтләрен бик күп мәртәбәләр ишетеп, теләсә кай җирдән үзе сөйләрлек дәрәҗәдә күңелдән белсә дә, хатибларның сүзләрен бик ихлас һәм дикъкать белән тыңлап торды.

Шәфигулла агай һәм балалары программадагы маддәләрнең[3] һичберсен калдырмадылар: йөрделәр, басып тордылар, вәгазьнәсыйхәт тыңладылар, җырладылар. Иң соңыннан уртак каберләр каберстанына килделәр.

Өйгә кайтканда Шәфигулла агай, аннан да бигрәк балалар, соң дәрәҗәдә арыганнар, туңганнар иде.

7

Көннәрнең берсендә Шәфигулла агай эштән җыламсырап кайтты:

— Балалар, Энгель товарищны...— диде, сүзен әйтеп бетермәстән күз яшьләрен сөртте,— Энгель товарищны асканнар икән бит.

Балаларның иң олысы бик күп тәкрарланган[4] догалыкны уку шикелле бер аһәң белән атасының сүзенә кушылып китте:

— Әйе шул, Польша буржуйлары, Польша соглашательләре комсомол Энгель товарищны үтергәннәр. Без, комсомоллар, буржуазиядән аның ачуын алачакбыз. Бер комсомол каны бәрабәренә мең провакатор, мең буржуаның җанын алачакбыз. Буржуазия үтергән һәрбер комсомол урынына безнең сафыбызга меңнәр, миллионнар эшче-крәстиян яшьләр тезелерләр. Яшәсен Польша комсомоллары! Яшәсен Интернационал!

Ахыргы сүз әйтелеп бетәр-бетмәс башка балалар кумәк кычкырдылар:

---

[1] Фазыйләт — өстенлек.

[2] Хатибның — ораторның.

[3] Маддәләр — пунктлар, статьялар.

[4] Тәкрарлау — кабатлау.

— Мы все готовы!

Алар белән бергә Шәфигулла агай үзе дә кычкырды: — Мы пчи гатауы! — Аннан соң кунак карчыкка сөйләргә керешге:

— Һи, Мөхиб абыстай, уйласаң җыларсың, бәхетсез заманнарда несознательный ата-ана кулларында бәхетсез җаннар булып кына үскәнбез лә. Безнең яшь заманнарда бу эшләрнең исе дә булмады бит. Дурманлы әгузе-бисмиллалар укып, демонстрация дигән нәрсәләрнең төсен дә күрмичә мәңге хурлыкта үстек.

Демонстрациянең өченче көнендә, Володя үпкә шешү авыруы белән авыр хәлдә ята иде. Сәрви Шәфигулла агайга бәйләнде:

— Син карт дурак кына харап иттең баламны. Үзеңнең котырынып йөрүең генә җитмәгән, бер гөнаһсыз балаларның тәкатьләрен корытып йөртәсең, карт дурак, акылдан шашкан.

Шәфигулла агай үзе дә аптырап калган иде.

— Демонстрациягә чыкканга карап бала авырыймы соң? Бөтендөнья комсомоллары, бөтендөнья пионерлары ул көнне демонстрациягә чыктылар, берсе дә авырмадылар.

Бала гаргарә[1] хәленә килгәндә, Шәфигулла агай аптыраштa иде:

— Нишләтеп багыйк икән соң кызыл былбылымны? Ячәйка секретарена барып әйтеп баксам, ничек булыр икән? Зәгъфран[2] белән язып эчерергә бирәр нәрсә бирмәсләрме?

Аның фикеренә «тәлинкәгә зәгъфран белән «Интернационал» язып эчертеп карасаң шифасы булмас микән?» дигән сымаграк бернәрсә килгән иде, ләкин ул аны Сәрвигә әйтергә җөрьәт итә алмады.

Баланың җан биргүе беленгәч, Шәфигулла агай тавышсыз гына җылап җибәрде дә «Күмү маршы» җырларга тотынды.

Мәетне озатканда, Шәфигулла агай юл буе балалайкачылардан уйнатып, үзе бертуктаусыз «Күмү маршы» җырлап барды. Мәет кабергә куелгач, нотык сөйләде:

— Кадерле иптәш Болудя! Син, кече-кечедән эшче-крәстиянгә пример булып, изге пионерлар эчендә РКП(б)ның корыч сафларында үстең. Ерткыч буржуалар, капиталистлар, байлар, банкирлар аркасында, мин сиңа әйтим, син дөньядан вакытсыз киттең... Син үлдең, синең партияң мәңге калды. Эшче-крәстиян яшьләре меңәрләп-меңәрләп РКП(б)ның корыч сафларына язылып, синең исемеңне мәңге калдырырлар!

[1] Гаргарә — үлем алды гырылдавы.

[2] Зәгъфран — буяу, кызгылт-сары төс.

Өйгә кайткач, аны Сәрви бик борчый иде.

— Син карт дурактан гына булды, син генә харап иттең баланы!

Шәфигулла агай бик аңлатырга тырышып карады:

— Һәй, энкәсе, бер уйласаң куанырлык та бар әле, мондый күмүләр бик аз кешегә насыйп була ул. Юл буе «Күмү маршы» уйнап, җырлап бардык. Бер пионер үлсә, мин сиңа әйтим, аның урынына меңләп эшче-крәстиян яшьләре РКП(б)ның корыч сафларына. Һәй, анасы, бәхетле җан инде ул безнең кызыл былбыл, мәңге йөз аклыгы барымызга да...

8

— ...Барам дигәч барам... Авылдагы йортымның каралтыларын сатам да барам! — диде Шәфигулла агай.

— Кире беткән карт дурак! — диде Сәрви,— партийный кеше бер син генә түгел, синнән башка бер кеше дә болай котырынып йөрми.

— Һәй, несознательныйлык, һәй, дурман башлык,— диде Шәфигулла агай төче сыкранып. Алты айдан бирле инде төннәрен йокламый шуны уйлап чыгам. Мәскәү дигән калаларга барып, Владимир Ильичның йөргән урамнарын, торган йортларын күреп, кабер туфракларына йөзләремне куйсам иде дим.

Йорт-каралтыларын сатарга барган җиреннән, авылыннан, Шәфигулла агай бик ашыгып кайтты:

— Ашыгу белән каралтыларны очсызрак сатып ташладым инде.

— Ике-өч көн соңга калсаң, Мәскәүдәге бәлеш суынып иде шул! Әйтерсең лә хаҗга бара,— дип шелтәләде аны Сәрви.

— Һәй, дурман баш! — диде Шәфигулла агай, кәефсезләнеп,— хаҗга бару түгел, имеш! Хаҗга бару шул. Синең дурманлы хаҗларыңнан мең мәртәбә, миллион мәртәбә изгерәк хаҗ шул, партийный хаҗга барам шул.

Шәфигулла агай үзенең ашыгуының сәбәбен Сәрвигә аңлатырга кереште:

— Шул көннәрдә партийный бәндәләр Коминтернга җыелган дөнья эшче-крәстияннәренең нурлы йөзләрен күрәчәк, аларның изге сүзләрен ишетәчәк... Һи, мин сиңа әйтим, шул көннәрдә изге калаларда булып, бәхет-шатлыкларга ирешсәң, мин сиңа әйтим, бер көн кичекми китәм!

Юл хәзерләнүе тәмам булгач, Шәфигулла агай хатыны һәм балаларына соңгы сүзләрен әйтте:

— Ерак сәфәрләргә китәм инде, сау-сәламәт күрешсәк иде! Владимир Ильич каберләре өстендә мин сезнең өчен дип атап та «Күмү маршы» җырлармын, йөземне кабер туфракларына куярмын, аның кабереннән изге чишмә чыкмый калмагандыр, әле сезгә дә, боерган булса, шул изге чишмәләрдән су да алып кайтырмын. Изге илләрдә үлә-нитә калсам, хәтерегездән чыгармагыз, әледән-әле «Күмү маршы» җырлап, миңа багышлый торган булыгыз.

Шәфигулла агайның күңеле йомшарган иде: ул артык сөйли алмады, «Интернационал» җырларга тотынды. Җыр тәмам булгач, балалары һәм хатыны белән кочаклашып күреште дә, бөктәрен аркасына тагып, кулына озын таяк тотып, өеннән чыгып китте.

Өч көннән соң «Красный тыл» исемле җирле гәзитәдә Шәфигулла агайның портретын басып, түбәндәге сүзләрне язып чыгардылар:

Рабочий-крәстиянгә тагы бер пример.

Массалардагы сознаниянең артуы удивительный бер темп белән бара. Почти алтмыш яшенә достигать иткән татарин-рабочий Шәфигулла, әле недавно гына партиягә расписаться иткән булса да, религиозный дурманнарны к черту җибәреп, полный сознательность проявить итте. Татар буржуйлары, муллалары, кулаклары праздновать итә торган праздникларны к черту җибәреп, советский праздникларны итә башлады. (Пасха праздниген да новый стиль белән живая церковь иткән времяда праздновать итте.) И, наконец, товарищ Ленинның гробын зиярәт итәр өчен, авылындагы хозяйствосын сатып, Москвага поехать итте. Бу сознательный картның станокта эшләвенә скоро пятьдесят лет туладыр. Фабрик ячейкасының предложениесе буенча фабрик администрациясе аны Герой труда итеп объявить итәчәктер...

1924 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Сатирик әсәрләргә анализ ясау үзенчәлеген исегезгә төшерегез. Хикәянең сатирик әсәр булуын исбат итегез.

2. Хикәядә кабатланган урыннарны табыгыз. Нәрсәләр күпме кабатлана?

3. Фатих Әмирханга бер үк нәрсәләрне күп мәртәбә кабатлау нигә кирәк булган?

4. Сәрви карчык картын «дурак» дип кат-кат яманлый. Ул хаклымы? Хаклы дип исәпләсәгез, әдипкә бер тиле карт турында хикәя язу нигә кирәк булган?

5. Бу хикәядә кайсы урыннарны авторның иң зур табышы дип бәяләр идегез?

6. Фатих Әмирхан хикәясен анархияне мактап башлый. Ни өчен шулай итә?

«Шәфигулла агай» хикәясе

Фатих Әмирхан хикәясен «дусларча шарж» дип атаган. «Шарж» атамасы белән танышып үтик.

Шарж — юморның бер төре. Димәк, юмор төшенчәсендә иның иң гомуми, иң әһәмиятле сыйфатлары бар дигән сүз.

Шарж дип билгеле, таныш шәхеснең яки күренешнеңниндидер сыйфатларын аерып алып, аларны күпертеп, арттырып көлке тудыру алымын атыйлар.

Әмене дусларча шарж дип үз итеп, усалланмыйча гына шаярып алуга әйтәләр.

Әдип әсәрен, йомшак кына итеп, дустанә шарж дип атый. Ләкин, әсәрне укыгач, күрдегез, 20 нче еллар чынбарлыгыннан усал, ачы итеп көлә. Андый юморга **сатира** диләр.

Фатих Әмирхан бу хикәясе белән рәсми сәясәткә ящеренмичә, күкрәк киереп каршы чыга. Ул аны бастыра алмаячагын да яхшы белгән, билгеле. Шуңа күрә басарга бирмәгән дә. Алай гына да түгел, хикәя, әдип үзе үлгәннән соң да, күп еллар буена архивта ята. Ул нибары 1991 елда гына беренче мәртәбә дөнья күрә. Алай да юморист холкы үзенекен иткән, ул тормыш яманлыгын героена мактату белән генә чикләнмичә, хикәясенә дә көлке күзе белән караудан тыела алмаган. «Күреп торасың, хөрмәтле укучым, янәсе, мин, ачы сатирамны «дустанә елмаю» дип атап, шул гөнаһсыз сүзләр артына посып калмакчы булам». Әдип киләчәк заман укучысының аны аңлавына нык ышанган.

Хикәя, сатирик әсәрләргә хас булганча, ике өлешкә — яманлыкка һәм шул яманлыкны матурлык итеп күрсәтүгә бүленә.

Гадәттәгечә, өлешләрне берәм-берәм өйрәник.

Шәфигулла агай һәм аның улы, попугай кебек, товарищ Михайлов һәм Рәхимов иптәшләрдән ишеткән җыен тузга язмаган сүзләрне кабатлап, алар кушкан мәгънәсез боерыкларны үтәп йөриләр. Аларның бөтен яшәеше кабатлау һәм боерык үтәүдән гыйбарәт. Алар җыелыштан җыелышка йөриләр, дога укыган кебек революцион җырлар җырлыйлар, эшче-крәстиянгә пример булып «красный быт» төзиләр.

Аерым-аерым караганда, Шәфигулла агай кылган эшләр мәгънәсезлекләре белән көлке. Ул, мәсәлән, иптәш, товарищлар-

дан ишеткән сүзләрнең күбесенең мәгънәсен бөтенләй аңламый. Әйтик, «дурман» сүзен урынсыз, кирәкмәс җирләрдә куллана. Пример булыйм дип хатынына кабат өйләнә, улына рус исеме куша, яттан белгән ораторлар нотыгын исе китеп кат-кат тыңлый. Йорт-җирләрен сатып, Мәккәгә баргандай, Ленин каберенә бара. Калининга һәм башка дәүләт җитәкчеләренә Кызыл байрак бүләк итә. Аның дөньяны танып белүе коточкыч беркатлылыгы белән көлке.

Шәфигулла агай өчен дөнья икегә бүленгән. Бер якта — партийныйлар — образованныйлар, икенче якта — калганнар — необразованныйлар. Аның өчен яшәүнең мәгънәсе партийныйларны мактап, партийный булмаганнарны яманлап торудан гыйбарәт. Теләсә нинди вакыйгага ул бер үк сүзләр, бер үк җөмләләр белән бәя бирә. Шуңа күрә ул әйткән җөмләләрнең ата-анасы юк. «Ничә еллар дурманлы никях белән торып гомер әрәм ителгән, мулла никяхы белән бөтен эшче-крәстиянне изеп, хур итеп тотылган», ди.

Ахмаклыгы белән көлке тудыра торган шундый ук сүзләрне аның улы да, җитәкчеләр дә сөйли, ә халык хуплап тора. Бөтен җәмгыять ахмаклыкны җитди һәм кирәкле нәрсә итеп кабул итә.

Хикәясенең исемен «Шәфигулла агай» дип куйса да, Фатих Әмирхан җәмгыять турында яза. Милләтнең үзаңы, психологиясе, идеалы җимерелүен күреп хәсрәтләнә. Эшләр болай барганда, милләтнең теле дә, үзе дә бетәчәк дип кисәтә. Шәфигулла агайны хезмәт батыры итеп күтәргән җәмгыятьнең яшәргә хакы юклыгы турында әйтә.

Мондый очракта әсәрнең авторы турында: ул яшь аралаш көлә, диләр.

Көлү авторның үзмаксаты түгел, дидек. Ләкин көлү — бу очракта илгә төшкән фаҗигане аңлату өчен иң көчле алым.

Кызыл буяу хикәянең башыннан ахырына кадәр сузыла. Әсәрдәге көлү угын әдип беренче чиратта бөтен ахмаклыкның сәбәбе булган **кызыллыкка**, ягъни хакимиятнең төп символына юнәлдерә.

Кызыллык — Шәфигулла агайның теләсә кая күтәреп йөри торган байраклары, тормыш үзе (кызыл тормыш, красный быт), бәйрәм киемнәре, хәтта авыру балага эчертә торган дару да. Шәфигулла агайның «Интернационал»ны кызыл кара белән язып, юынтык суын авыру баласына эчертү теләге (аны партия җитәкчесе язарга тиеш) — әсәрдә кеше ахмаклыгының көлке дәрәҗәсенә җитүен күрсәтүче менә дигән табыш.

Лəкин кызыллык символын тəмам адəм күлкесенə калдыру өчен, Фатих Əмирхан тагын да саллырак, искитмəле башка образ уйлап таба. Бала исемен кызыл исемгə алыштырганда, аңа тантаналы җыелышта, яңа тормыш символы итеп, кызыл күлмəклек белəн астын сөртə торган кызыл чүпрəк тə бирдертə.

Хикəядə кызыл буяудан соң җыр күп кабатлана. Шəфигулла иртəн торгач та, көндезлəрен дə, йокыга ятар алдыннан да җырлый. Кеше күмгəндə дə җырлый. Əле «Интернационал»ны, əле «Күмү маршы»н суза. Балаларын да шуңа өйрəтə. Агай җырын намаз уку, дога кылу, Коръəн чыгу кебек дини гамəллəргə охшата. Мəскəүгə дə ул хаҗга баргандай бара. Аннан изге чишмə суы алып кайтырга ниятли. Баласын дəвалау өчен дə докторга түгел, партия җитəкчесенə мөрəҗəгать итəргə тели. Аның кулы белəн «Интернационал» язып, шуның юынтык суын баласына эчертмəкче була. Шул урыннарны укыганда, кылт итеп Фатих Əмирханның «Фəтхулла хəзрəт» повесте искə төшə. Шуннан соң Шəфигулла агай белəн Фəтхулла хəзрəтнең бер-берсенə бик нык охшаганлыгына һич тə шик калмый. Алар икесе дə — киребеткəн, ахмаклык дəрəҗəсенə җиткəн фанатиклар. Фəтхулла хəзрəт үзенең каралыгы, наданлыгы, искелеге белəн яңалыкка, үсешкə, гомумəн, кешенең яшəешенə каршы булган кебек, Шəфигулла да — шундый ук сыйфатлары белəн халыкның гадəти яшəешенə каршы кеше. Бу ике персонажның охшашлыгы аша авторның əйтəсе килгəн тагын бер фикерен табабыз. Бу бəйлəнеш аша Фатих Əмирхан: Шəфигулла кебек яңа заман кешелəре безнең өчен һич тə яңалык түгел, алар элек тə бар иде. Элек тə тузга язмаган телəклəре белəн кешелəрнең башларын катыралар иде. Шəфигулла һəм аның юлбашчылары — шул ук Фəтхулла хəзрəтлəр алар. Нибары диннəрен генə алыштырганнар, лəкин кара мулладан да яманрак фанатиклар. Тик элегрəк андыйлар бармак белəн генə санарлык булсалар, хəзер бөтен илне тутырганнар, шуңа күрə чиктəн тыш яманнар, ди.

Бу ике əсəр мисалындагы күренешне истə калдырыйк. Бер əсəр үз эчендəге эчке бəйлəнешлəрдəн тыш, башка əсəрлəр белəн дə бəйлəнешкə керə ала икəн. Эчтəлеклəре үзара бəйлəнешкə кереп, яңа эчтəлек тууга сəбəп булган бəйлəнешкə тышкы бəйлəнеш дилəр.

Һади Такташ
(1901—1931)

Сез татар халкының бөек шагыйре Һади Такташ әсәрләренең шактые белән алдагы сыйныфларда таныштыгыз. Шагыйрьнең чынбарлыкка аек караштa торуын белдегез, хәйләкәр елмаюы астына әйтәсе килгән туры сүзен һәм күз яшен яшерүен күрдегез.

Шагыйрь 1921 елда ук иҗат иткән шигырендә мәхәббәт хисенең матурлыгын язып чыга. «Җир уллары трагедиясе»ндә күп корбаннар биреп кенә ирешергә мөмкин булган социализмның чынлыгына ышанмый, аны «мираж» дип атый.

20 нче еллар башындагы иҗатында Һ. Такташ революцияне бер генә тапкыр да хуплап язмый. Киресенчә, гражданнар сугышы елларындагы кан коюларга үзенең ризасызлыгын белдерә. Сугышка каршы чыга һәм явызлыкка каршы куярлык матурлык эзли.

НӘЛӘТ

Пролог

Күк читендә, канлы пәрдә,
Әллә кемнәр:
— «Таң» диләр,
— «Таң түгел ул, җиргә төшкән
Шомлы каргыш, кан» диләр.

I

Бер әмер — шуннан тәмуглар
Сакчысы тиз-тиз генә
Килде дә ут ташлады
Илнең сарае өстенә.
Ташлады, аһ! Мең нәләт!
Чү! Кемнәр анда көлделәр?
Мәсхәрәләп илне, көлде
Канлы уклар, сөңгеләр...

III

— Кит, болыт! Ай, сип нурың,
Күргәз тагын —
Нинди золмәт, вәхшәт алды
Ил багын[1]...
Алда, артта шаулый туплар,
Уйный уклар шәүләсе,
Баскан эз — гүрлек-каберлек,
Канлы илнең гәүдәсе...

IV

Кит, кояш! Чыкма
Бүген син дөньяга —
Куркынырсың... Куркыныч, аһ! дөньяда!!.
Тау башында күп халык һәм канлы дар,
Нинди корбан? Кемне китергән алар?
Кем елый?.. Кем яшь түгә? Кем?..
— Эшче ул...
Сүн, кояш! Сүн,—
Сүн дә син бер шәүлә бул,
Шәүлә бул да, бар, көйлә шәфкать көен;
Бар аларга:
— «Җирдә шәфкать бар!» диең.

V

Күкнең уртасында нурлы Ай тора,
Ай тулы. Бар җирне нурлый, яктырта.
Төшми Җиргә шәүләсе. Җир болгана,
Болганып, канлы төтеннәргә яна,
Ай түрендә кайгылы Гайса нәби
Утыра, канлы йөзе, ул уйлана...
Тек күзеңне Җиргә, Гайса, күр әнә!
Син сөйгән эшче халык утта яна...
Текмә, тукта!..

VII

Кайда сез, әй илне
Саклаучы баһадирлар? — Нигә
Чыкмыйсыз алтын сарайга
Каршы канлы бәйгегә?!

[1] Багын — җимеш бакчасын.

Әллә сезнең үз кулыгыз берлә
Койган сөңгеләр,
Чәнчелеп саф бәгърегезгә,
Вәхшианә[1] көлделәр?!
Әллә сезне җир йөзеннән
Мәңгелеккә сөрделәр?!.

VIII

Кайда сез, әй, йортны
Саклаучы баһадирлар?! — Нигә
Чыкмыйсыз алтын сарайга
Каршы канлы бәйгегә?!.

IX

Чыктылар... Тик соң иде
Һәм зур сарай янган иде,
Ил сараеннан фәкать көлләр генә
Калган иде...
Инде илнең кырларында
Канга баткан каргалар,
«Кар!» диләр дә каргыйлар
Үлгән сөякләрне алар...

X

Бер баһадир чыкты мәйданга —
Кылычын ташлады,
Кайгылы илгә торырга
Йорт корырга башлады...
Тик аның йорт нигезенә
Куйган авыр ташлары
Булды гәүдә һәм батырларның
Киселгән башлары...

XI

— Ха-ха-ха-ха...
Көлмә анда, әй Кара Көч,
Ул төзер бер зур сарай,
Үч итеп сезгә куяр ул
Нәкъ түренә канлы ай...

---

[1] Вәхшианә — вәхшиләрчә.

Ул сарайда мәңге шатлык
Һәм ирек шаһлык сөрер;
Ул сарайда хөр йөрәк,
Көчле батыр ирләр торыр.
Ул сарай мәңге булыр киң,—
Хөр күңелләр кәгъбәсе[1]
Һәм дә анда мәңге кайнар
Үч алу, кан шәүләсе...
. . . .

XII

Мин караңгы сахраларда
Канлы күз яшьләр җыям,
Ил каны һәм күз яшеннән
Зур бөек һәйкәл коям...
Туктагыз! Мин һәйкәлемнең
Кайгылы йөзен уям,
Маңгаена канлы яшьләрдән
Янар күзләр куям...
Күкрәгенә мин хаиннарның[2]
Фәхеш исемен язып
Җырларым;
Таушым минем
Бар җир-зәминнәрне ашар,
Дәһшәтеннән тәңреләр, гыйфрит, пәри җеннәр
Шашар.

XIV

Яшь балаларын аналар
Сөт имезгәндә һаман,
Күз тегәр каргыш белән
Алтын сарайларга табан...

1922 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Лирик герой хисенең сәбәбен табыгыз.
2. Һ. Такташның «Юану» шигырен укып чыгыгыз. Менә ул:

Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны
Еглатырга, әйе, миндә көчле Байроннар җаны.
Көн килер, күз яшьләрем тормыш күгендә ялтырар...

---

[1] Кәгъбә — Мәккә шәһәрендәге изге мәчет.
[2] Хаин — хыянәтче.

Дәртле җырларым моңыннан ил елар...
Әйе, минем көчле рухымнан җир вә күкләр калтырар.

Шигырьнең исеменә игътибар итегез. Бу әсәр эчтәлегеннән чыгып, «Нәләт» шигыренең эчтәлеген ачыклагыз.

3. Шигырь эчтәлегенең чынбарлыкка нинди бәйләнеше бар?

4. Баһадирлар төзегән бәхет сарае авторның идеясе булырга мөмкинме?

5. Шигырьнең стиль үзенчәлеге турында ни әйтә аласыз?

КОЯШ КҮКТӘ ШУЛАЙ МӘҢГЕ ЙӨЗӘР

(«Зәңгәр күзләр» шигыреннән)

Бакча ясыйм,
Менә карагызчы!
Бакча ясыйм нәфис гөлләрдән;
«Зәңгәр күзләр» көен көйли-көйли,
Сулар агызам тирән күлләрдән.
Айны каплап ап-ак болыт белән,
Йолдызларын сибеп күгенә,
Болыт үтә төшкән ай шәүләсен
Төшереп куям күлнең төбенә.
Тын калыгыз!
Менә кинәт кенә
Йоклап яткан күлнең төбеннән
Ашыгып бер кыз чыгар,
Сирень гөленнән
Күлмәк кигән,
Шундый, шундый матур итеп киенгән.
Алай түгел —
Ничек, ничек башлыйм соң
«Зәңгәр күзләр» дигән җырымны,
Ничек кенә матур итеп сөйлим
Туып үскән урман-кырымны?
Аһ, әгәр мин бер зур рәссам булсам,
Тәрсим итеп[1] ул кыз баланы
Бүләк итәр идем сезгә,
Бүләк итәр идем мин аны.

Җир йөзенең бөек рәссамнары!
Килегез дә миңа сөйләгез!

---

[1] Тәрсим итү — рәсемен төшерү.

Аның тузган чәчен буяганда,
Нинди буяу белән буйыйм да,
Зәңгәр күзкәйләрен, җанлы итеп,
Ничек кенә буяп куйыйм да,
Ничек тәрсим итим мин аны?!

*

Иркә җир кызларын буяу белән
Җанлы итеп буяп буламы?
Булса,
Ничек буйыйм, ничек кенә буйыйм мин аны?

1923 ел

ТАКТАШ ҮЛДЕ

Көчле кояш күптән баткан инде,
Караңгылык баскан җир өстен —
Ә ул һаман утын якмый, тик утыра.
Бәлки... кем белсен,
Аның көчле кулы бик күп еллар
Шулай эшли-эшли талгач та,
Күкрәгендә хәят нурларыннан
Соңгы нуры сүнеп калгач та,
Аның иректле күңле тынар өчен
Караңгылык тели торгандыр?
Бәлки, шулайдыр да,
Бәлки...

Өстәлендә аның бер хат тора —
Карт анасы язган;
Хатында
Шундый юллар:
...Хәләл сөтен имезеп төннәр буе
Йокламыйча сине саклаган,
Авырганда, үлем кочагына
Үзен атып, сине яклаган
Ул кем иде?
Соңгы сынык нанын сиңа биреп,
Ач калса да «балам» диюче,
Бөтен дөнья синнән качканда да,
Берьялгызы калып сөюче
Ул кем иде?..

— Мескен әнкәң!
Ул әле дә өзелеп сагына сине,
Ә син?..

Әткәң,
Ул әле дә шулай сөренә-сөренә,
Таяк тоткан килеш, урамда
Туктап ютәлли дә:
«Мин әле дә сезнең өчен
Салкын буранда
Һаман йөрим»,— ди ул.
Аның күләгәсе һаман йөри,
Һаман, һаман да.
Бер ул гына түгел,
Бире бик күп алар;
Ач, ялангач килеш яланда
Тик йөриләр...
Тик йөриләр...
«Син кайт, балам!
Син кайт безнең янга,
Әүвәлгедәй сине сөярбез,
Балам, иркәм, бәгърем, диярбез!
Син кайт, балам!»
Төн үтә дә,
Иртәнге җил аңа җавап яза:
— Улың үлде.
Сагынып хатлар язма, бәхетсез карт,
Зәңгәр күзле улың исеменә;
Ул юк инде...
Сагынып хатлар көтмә, «изге» карчык!
Көзге төндә,
Тәрәзә төбендә;
Тәрәзәңне кагып:
— Аңардан!—дип,
Хат китермәс хәзер беркем дә...
Иске тормыш!
Синең кырларыңда
Зәңгәр күзле уйчан яшь егет —
Ул юк инде...
Гаиләң тар синең аның өчен,
Йортың — төрмә,

Ишекләре корыч-тимердән.
Балаларың — исрек,
Исреп-исреп,
Нәселең черегән!
Барсы тилергән!..
Әй сез, калдык нэпман уллары!
Базар корольләре!
Шарлатаннар!
Череп беткән сыра кортлары!
Сез табынган алтын-көмешләрне
Тәңре итеп үзенә алалмый;
Сез аунаган пычрак баткаклыкта
Үзе өчен урын табалмый.

Көрәшчеләр!
Сезнең арагызга яшь бер егет килә,
Аның да
Һичбер нәрсәсе юк:
Малы да,
Атасы да,
Анасы да...

1923 ел

Биремнәр

1. «Нәләт» һәм «Кояш күктә шулай мәңге йөзәр» шигырьләрендә сөйләнгән вакыйгаларның урыны һәм вакыты турында әйтегез.

2. Һади Такташның алдагы сыйныфларда өйрәнгән «Газраилләр», «Төркстан сахраларында», «Антым» әсәрләрендәге урын-вакыт үзенчәлеген исегезгә төшерегез. Аны «Нәләт» һәм «Кояш күктә шулай мәңге йөзәр» шигырьләрендәге урын-вакыт үзенчәлеге белән чагыштырып карагыз.

3. Чагыштыру нәтиҗәсеннән чыгып, Һади Такташның башлангыч иҗатына гомуми бәя бирегез.

4. Шигырьләрдән лирик геройның юануын табыгыз.

ЕРТЫК БҮРЕК

Дөнья матур,
Шуның өчен дә шул
Сүгенә-сүгенә кайтам салкыннан.
Ә җил, сызгыны,
Ни өчендер,
Иярген дә килә артымнан.

Тфү!
Көзге җилләр тиде теңкәгә.
Яз янгыны җиргә кабынганчы,
Җир иркендә калды урамнар...
Ә җил — моржа сандугачы,
Эче пошкан саен,
Алып килер салкын бураннар...

Кышны ямьсез диләр,
Ялганлыйлар,
Матур була шәпләп киенгәч;
Ә мин бу ел кышын үләрмен күк,
Сезнең өчен
Бик күңелсез калыр мин үлгәч...
Беренче кар, белмим, кайчан явар,
Тик
Үләрмен мин ул көнне.
Бүген әле, тиздән кыш килә, дип
Ямап куйдым ертык бүркемне...
Беләм,
Ертык бүрек кыштан саклый алмас,
Үләрмен мин, бу ел кыш килгәч;
Дөнья матур,
Ләкин...
Сезнең өчен
Ни кызыгы калыр, мин үлгәч?

1927 ел

БОЛАЙ... ГАДИ ҖЫР ГЫНА

Гомер әрәм китте,
Юк эш эшләп чәчләр агарды;
Үлем микроблары хәзер күкрәгемдә,—
Алдап булмас, ахры, аларны.

(Авырулар җыры)

Үпкә дә юк,
Артык ачу да юк,
Болай гына борын салынган;
«Барабыз»да кайтып киләм әле
Асылып үлгән берәү яныннан...

Ах, «барабыз»,
Кай җирдән син?
Атың начар, малай, синең дә,
Син дә, ахры, асылып үләрсең;
«Гомере утта янсын...» диярсең.
Карлар яусын йөргән юлларыңа,
Авыр юлда атың армасын,
Кичер мине усал сүзем өчен,
Ходай өчен хәтерең калмасын.
Кешеләр менә:
Өйләнәләр,
Матур киенәләр,
Кызлар сөяләр,
Чәй эчәләр...
Ә беркөнне безгә ачу итеп
Тоталар да асылып үләләр...
Ачу килә.
Мин этләрне беләм,
Алар менә
Собраниегә,
Театрга барып йөрмиләр,
Сөяк кимереп гомер уздыралар,
Ә шулай да асылып үлмиләр...
Ах, «барабыз»,
Мин үлмәскә булып йөрим әле,
Кызыктыра бабай булуы,
Кызык булыр әле малайларның
Эшләүләрен карап торуы.
Ашкынып җырланган теләкләрнең
Чәчәкләрен килә күрәсе,
Канатымны еллар каерса да,
Каерса да...
Ах,
Үләсе килмәс, үләсе...
Бәхетлемен, ахры,
Җир үзенең
Сөйдерә алды бөтен ваклыгын,
Һәр почмагы миңа урын җәйде,
Күргәзмичә миңа ятлыгын.
Кармак салсам суга, балыклары
Ятсынмыйча килеп каптылар;

Маржалары да, бер авырсынмый,
Чалбар-фәлән алсам саттылар...
Урамнарда йөрсәм, милицияләр
Ачуланып тотып япмыйлар;
Данлы дуслар — кызыл каракошлар
Чемберленнан мине саклыйлар.
Их!
Кан эчендә туган зур илемнең
Киләчәген килә күрәсе,
Канатымны еллар каерса да,
Каерса да...
Ах, үләсе килмәс, үләсе...
Әле карлар ява,
Әле
Карлы кышның
Ак канаты җирне каплаган,
Әле
Килер язның, матур язның
Шомыртлары чәчәк атмаган...
Күкрәгемне киереп, кышкы көннең
Туялмыйча сулыйм һавасын...
Их, «барабыз»,
Әйдә, ку атыңны,
Әллә нигә авыр барасың.
. . . .
Синең атың кебек җирән атта
«Аны» озатып бардым киткәндә,
Аерыласы килми сарылды ул,
Соңгы кабат мине үпкәндә...
Хатын-кызлар безне үпкән чакта,
Сагынсын дип, ахры, үбәләр...
Еллар...
Бөек еллар шаулый-шаулый
Сагындырыр өчен үтәләр...
Ах, син, илем,
Ничек үләргә соң,
Сагыныр кешеләр синдә булганда;
Ничек үлим,
Берләр меңнәр өчен —
Меңнәр берләр өчен торганда!..

1928 ел

Биремнәр

1. «Ертык бүрек», «Болай... гади җыр гына» шигырьләрендәге урын-вакытны «Нәләт» һәм алдагы дәрестә өйрәнгән башка әсәрләрдәге урын-вакыт белән чагыштырыгыз. Аерманы табыгыз һәм үзгәрешне аңлатып карагыз.

2. «Ертык бүрек» һәм «Болай... гади җыр гына» шигырьләрендәге лирик геройның хисе (кичереше) турында сөйләгез: хиснең сәбәбен, геройның юанычын табыгыз.

3. Шуннан соң бу шигырьләр эчтәлеген «Нәләт», «Кояш күктә шулай мәңге йөзәр», «Такташ үлде» шигырьләренең эчтәлеге белән чагыштырыгыз. Соңрак язылган әсәрләрдәге үзгәреш турында сөйләгез.

4. Үзгәрешнең сәбәбен аңлатырга тырышыгыз.

5. Авторның үзенә һәм чынбарлыкка мөнәсәбәтен белегез.

Һади Такташның яза башлаган еллары

Бу елларда Һади Такташ дөньяны бөтен бер бәхетсезлек итеп күрә.

«Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт, монда үлем» ди ул «Газраилләр» шигырендә. «Фәхеш җир! Куеныңа шомлы Еланнар ояласын инде!» ди «Караңгы төннәрдә» әсәрендә. «Нишли дөнья, нишли ул? Ник күренми якты көннәр? Ник томанлы алгы юл?» дип «Төркстан сахраларында» шигырендә үзенә үзе һәм бер үк вакытта укучыларына да сорау бирә. «Күктән сөрелгәннәр», «Үтерелгән пәйгамбәр», «Ачлык патша», «Нәләт» шигырьләрендә дә Һ. Такташ чынбарлыкка ризасызлыгын белдерә.

Күп әсәрләрендә бер үк тема кабатлануын искә алып: **бу елларда Һ.Такташ иҗат иткән әсәрләрнең даими эчтәлеген тормыштан канәгатьсезлек тәшкил итә** дигән нәтиҗә ясый алабыз.

Шундый авыр шартларда нәрсәгә өметләнеп яшәргә? Күңелне ничек тынычландырырга? Бу елларда язылган шигырьләрнең берише шул сорауларга җавап эзләүгә — юануга багышлана.

Иң тәүге шигырьләрендә Такташ үзен гадәттән тыш бер кеше итеп сурәтли. Үзенең бөтендөнья кешеләрен елатырлык шигырьләр яза алачагына ышана. Юанычы шул «куркыныч» шигырьләре була. Бер мәкаләсендә әдип: «Бөтен дөньяга мәшһүр шагыйрь булырмын дип уйлый идем. Тора-бара... ул теләгемнең ерагая барганын сиздем»,— дип яза.

Әдип соңрак мәхәббәт турында яза башлый. «Антым» шигырендә «Түзә алмый канга, вәхшәткә Мәхәббәт байрагын алдым», ди һәм шуның белән юануның башка төренә күчүен

белдерә. Бер-бер артлы мәхәббәт турында «Таң кызы», «Урман кызы», «Кояш күктә шулай мәңге йөзәр», «Зәңгәр күзләр» шигырьләрен яза. Аннары мәхәббәт темасы көрәш темасына алышына.

«Көрәшчеләр! Сезнең арагызга яшь бер егет килә»,— ди әдип «Такташ үлде» шигырендә. «Нота» шигырендә, яңа хакимият идеологиясе кушканча, дошманнардан үч алырга чакыра. Ленинга мәдхия җырлап «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын яза.

Күрәсез, Һ. Такташның **тормыш явызлыгына каршы куйган матурлыгы — өмете һаман үзгәреп тора.** Үзгәреш аңлатма сорый.

Баштагы идеалын мәхәббәт матурлыгына алмаштыру сәбәбен бу елларны әдип укыган китаплардан эзләргә кирәк. Һ. Такташ рус әдәбиятын аеруча күп укый. Яшь егетне бигрәк тә бөек рус әдәбиятындагы мәхәббәт темасы кызыксындыруы бер дә гаҗәп түгел. Мәхәббәт Такташның үз әсәрләренә дә явызлыкка каршы торырлык матурлык булып килеп керә. Ләкин китаптан кергән мәхәббәт матурлыгы шагыйрьнең үзен дә канәгатьләндерми башлый.

Ә менә көрәш темасы тормышның үзеннән, дөресрәге, хөкем итүче идеологиядән килә. Көрәшче булу теләге Такташта күп еллар буена эзләнүләрдән, газаплы эчке каршылыклардан соң гына туа.

Һади Такташ иҗатының икенче яртысы

1924 елдан соң язган әсәрләрендә шагыйрьнең дөньяга карашында җитди үзгәреш күренә. Пропаганда көн-төн мактаган яңа тормышны якыннанрак өйрәнгәч, көрәшче кешенең идеал була алуына шикләнә башлый. Халыкның бүгенге газабы белән вәгъдә ителгән матур киләчәк арасында бернинди дә бәйләнеш юклыгын сиземли. «Сыркыды авылы» шигыреннән башлап, әдип, тормышның бүгенгесен матур киләчәктән аерып сурәтли башлый. Кайчандыр кешеләрнең бәхетле булуына әдип чын күңелдән ышана. Бу хакта ул «Әйдә, энем!» шигырендә «Җәен үсәр зәңгәр чәчәкләр» ди. Ә «Нәни разбойник» шигырендә «Ерак калмый инде майга да, Яз ясарбыз салкын тайгада», дип фикерен куәтли. «Болай... гади җыр гына» шигырендә «Килер язның шомырт чәчәкләре» ди. «Киләчәккә хатлар» поэмасында «Коммунизм кыры күренә» дип берничә мәртәбә кабатлый. Бу шигырендә дә Такташ кешеләрнең михнәте турында яза. Ул елларда

тормышны яманлаган өчен кулга алганнар, ә андый шигырьне бастырмаганнар. Такташ дөреслекне ничек язган соң? Хәйләләп, әсәренең объектив эчтәлеге артына субъектив эчтәлеген яшереп язган.

«Ертык бүрек» шигыре,— бер карасаң, дөньяның матурлыгы турындагы әсәр. Шул бәхетле матур тормышта шат күңелле шагыйрь, үзеннән көлеп, мактанган булып, матур хисләрен юмор аша күрсәтә кебек. Ләкин җентекләп укыган кеше матур дөньяның Такташ үлү белән ямьсезләнәчәген абайлап ала.

Лирик шигырьләрнең эчтәлеге хис булуын беләбез. Бу шигырендә Такташ, елмая-елмая, күз яшьләрен сөртә.

«Болай... гади җыр гына» шигырендә дә шундый ук хәл. Әдип үзенең ашкынып яшәү теләген дөньядан туйган кешеләргә каршы куя сыман. Тормыш матурлыгы, киләчәкнең гүзәллеге, үзен яратучы кешеләр барлыгы турында ярсып-шатланып яза кебек. Ләкин монда да, укучысы чын хисен аңласын өчен, махсус фокуслар әзерләп куя. «Мин үлмәскә булып йөрим әле» ди. Бу җөмләнең үз эчендәге каршылыгын укучы бик тиз сизеп ала. Бу җөмләсе белән Такташ, үлмәскә теләмим, дими, киресенчә, үләргә карар кылдым, ләкин әллә исән калыргамы соң, дип уйланып кына йөрим әле, ди. Бу хисен «Канатымны еллар каерса да, Каерса да» дип кабатлый-кабатлый, тагын бер мәртәбә ныгытып куя. «Әле карлы кышның Ак канаты җирне каплаган», «килер язның шомыртлары чәчәк атмаган» дип укучысына үзенең даими символлары аша да эндәшә.

Шагыйрьне илдәге хәерчелек, гаделсезлек, андагы тәртипсезлек борчый. Бәхет каядыр еракта. Бүген кешеләр, тормыштан туеп, үзләренә кул салалар. Ә соң ил киләчәккә ничек бара? «Авыр барабыз», «Атың начар», «Ку атыңны!» ди лирик герой кучерга. «Барабыз», шулай итеп, илнең шул замандагы халәтен күрсәтүче тагын бер символ — фокус түгелме?

Такташ әле аның белән генә дә чикләнми. Укучысына, үзара аңлашу өчен, тагын бер фокус әзерләп куя: эпиграфка үлемгә дучар ителгән кешеләр җырын яза һәм шигыренең исемен «Болай... гади җыр гына» ди. Үлем җыры, шулай итеп, гадәти, күп кабатланган җырга, ә үзенә кул салучы кеше типик кешегә әйләнә. Шагыйрь менә шушы фикерен укучысына аңлатырга тели. Кучерга да, хәлләрең начар, үл инде, ди. Үзенең шул хакта уйланып йөрүен кинаяләп аңлата. «Кешеләр беркөнне безгә ачу итеп тоталар да асылынып үләләр» дип гомумиләштереп, үлемнең сәбәбен ачыклап та куя.

СУБЪЕКТИВ ЭЧТӘЛЕК

ПОТЕНЦИАЛЬ ЭЧТӘЛЕК

ШӘХЕС-ҖӘМГЫЯТЬ КАРШЫЛЫГЫ

ЧОРЛАР БӘЙЛӘНЕШЕ



ОБЪЕКТИВ ЭЧТӘЛЕК

Матур дип саналган тормышта үлемнең гадәти бер күренешкә әйләнүен күреп торган шагыйрь күңелендә нинди хисләр дулавын абайлау кыен түгел. Бу хисләре турында Һ. Такташ көлеп, елмаеп, күз яшьләрен сөртә-сөртә яза.

Һади Такташның язу стиле

Сез өйрәнгән шигырьләрнең Һ.Такташ өчен типик шигырьләр булуын искә алсак, әдипнең стилен ачыклый алабыз.

1. Һ.Такташ шигырьләренә объектив һәм субъектив фикерләр янәшәлеге хас.

2. Объектив эчтәлеген ул көлеп, шаярып яза. Шуңа күрә лирик геройның күңелендә чынбарлык тудырган авыр хисләр белән шаяру хисе каршылыкка килә, һәм бу каршылык шигырьдә эчке киеренкелек тудыра.

3. Һ.Такташ шигырьләрендә фокуслар күп. Алар әдипкә укучысы белән әңгәмәгә керергә ярдәм итәләр.



Хәсән Туфан
(1900—1981)

Хәсән Туфан 1900 елның 27 ноябрендә Татарстан Республикасының Аксубай районы Иске Кармәт авылында крестьян гаиләсендә туа. Әтисе, җир эшләреннән бушаган арада, авыл кешеләренә мич чыгара, бура бурый — авылның бер остасы була. Аның уллары барысы да берәм-берәм Урал заводларына эшкә китәләр. Абыйларыннан күреп, унынчы бала булып туган Хәсән дә ундүрт яшеннән Урал заводларына эшкә китә. Монда ул бакыр чыгара, токарь булып эшли. Татар язучыларының күбесе кебек бик яшьли үз көнен үзе күрә. Х. Туфан, өйрәнчек әсәрләре белән үк, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәехзадә Бабич кебек танылган әдипләр игътибарын җәлеп итә. Мондый бәхеткә ирешкән башлап язучыларны бармак белән генә санарлык. Галимҗан Ибраһимов белән Шәехзадә Бабич Туфан шигырьләренең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтәләр. Язуын дәвам итәргә, ләкин язганын бастырырга ашыкмаска киңәш бирәләр. Остазлар киңәшен Хәсән Туфан дөрес аңлый. Язган әсәрләренә тәнкыйть күзе белән карарга өйрәнә.

Беренче шигырен әдип 1924 елда гына бастыра. Бу елларда әдәбият мәйданына килгән шигырь язучылар арасында Хәсән Туфан, бәлки, күп еллар буена югалып торыр иде. Әмма язмышы аңа тагын бер тапкыр елмая. Туфанны күренекле тәнкыйтьче, галим Галимҗан Нигъмәти күреп ала һәм, иң талантлы шагыйрьләрнең берсе дип, башкалардан аерып куя. Шуннан соң Хәсән Туфан иҗатына игътибар бермә-бер арта.

Хәсән Туфан тиз арада күп санлы шигырьләр һәм «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Иске Рәсәй үлде», «Бибиевләр» исемле поэмалар язып бастыра. Шагыйрь иң тәүге әсәрләре белән үк әдәбиятта үз сүзен табарга омтыла: хисләр байлыгын ачарга

тиешле шигъри алымнар белән эшчеләр холкын күрсәтмәкче була.

Шигырьләрендә әдип үзен Урал эшчеләренең берсе итеп тәкъдим итә. Лирик шигырьләрендә дөньяны яңача күрүче эшче хисләрен сурәтләмәкче була. Эшче хисләрен футуристларга, имажинистларга ияреп, көтелмәгән метафора, чагыштырулар белән ачып карый:

Сезнең кул кабарса, егетләр,
Төзү эшендә,
Безнең хисләр кайный
Кимчелекне җиңмәү үченнән;

(Көндәлек дәфтәреннән)

Ә давыл тагын яңадан
Кузгалырга җилкенә.
Тиздән
Көннәрне елларга бәреп
Набат сугарбыз җир йөзенә!..

(Мопр атнасына)

Сугыш гаммасында
Бәлләүләнгән нәни геноләр,
Кайгыларны таптап,
Көлә-көлә,
Урамнарга бәйрәм сибәләр.

(Татарстанда)

Нияте барып чыкмаганны күреп ала һәм, күпләр кебек, үзе дә сизмәстән, Һ.Такташка охшатып язарга кереңә:

Җил. Куе җил.
Җил саламны —
Ертык йортның йонын тарата.
Болытлар кар или.
Юлаучылар кайта каладан...

(Еллар итәгендә)

Миллиард ваттлы Идел турында мин
Утыра идем
Шигырь сызгалап,
Ай
Чыкты да,
Язу таныган кук,
Дәфтәремә минем
Күз сала.

(Көнчыгышның яңа баласы)

Тиздән әдип кешегә ияреп әдәбиятта яңа сүз әйтә алмаячагына тәмам ышана. Үз җырын булдыру өчен, җирне җәяүләп гизеп, тормышны үз күзең белән күрергә кирәк дигән фикергә килә. Тәвәккәл егет күп уйлап тормый. Биштәрен аса да Кавказ һәм Урта Азия якларына чыгып китә. Арыган урында туктап, акчасы бетсә, эшкә ялланып, Хәсән чит җирләрдә үзен үзе эзләп озак йөри. Ләкин язмышы аны шул заманның иң яман тәмугы аша үткәрә.

Татар халкының яраткан җырлары аерылу, сагыну турында. Ләкин Сталин төрмәләрендә атылган, черегән якташларның, аларны саргаеп көткән туганнарының чиксез кайгы-хәсрәтләрен хәтта кайгы тулы җырлар да, бәетләр дә ачып бетерә алмагандыр. Чөнки андый җырлар фәкать Сталин тәмугларын үткән кеше күңелендә генә туа ала. Шундый җырлар бәрабәренә милләт үзенең иң талантлы шагыйренең гомерен, бәхетен корбан итә.

Хәсән Туфанны, тузга язмаган эшләрдә гаепләп, сөргенгә озаталар. Партиягә җаны-тәне белән бирелгән, һәр шигырендә диярлек совет властен мактап язган Хәсән Туфан бер көн эчендә халык дошманына әйләнә. Ел ярым Казан төрмәсендә утыра. 1942 елны аны үлемгә хөкем итәләр. Шагыйрь, ике ай буена бүген аталар, иртәгә аталар, дип үлем көтеп ята. Шуннан соң гына үлем карары ун ел каты режимлы колониядә утыру белән алмашына. Шагыйрь шул китүдән туган якларына 1956 елның җәендә генә әйләнеп кайта.

Хәсән Туфанны Такташлар, Тукайлар югарылыгына күтәргән шигырьләре шул елларны языла. Ул шигырьләр белән сез 11 нче сыйныфта таныштырсыз. Быел без сезнең белән әдипнең 20—30 нчы елларда иҗат иткән шигырьләрен өйрәнәчәкбез.

БАРАБЫЗ

...Безнең лирабыз[1] — тимер юл зигзагы,
Ә байрак — болытка кадалган ялкынлы торбалар.

Барабыз! —
Бас әйдә,
Кайгыны таптаган паровоз! —
Тынлыкны сындырган трамвай!

---

[1] Лира — *бу урында:* сәнгать.

«Мәхәббәт» пыш-пышы
Төннәрне ураган...
Әй шоф-фер!
Шуларны өркетеп,
Яле бер гармун тарт! —
Кешнә бер,
Эш-хезмәт туена
Делегат ташыган тимер ат!
Барабыз! —
Тапта кайгыны, паровоз!
Сындыр тынлыкны, трамвай!
Кимер һаваны, пропеллер!
Ялкынлат болытны, торбалар!

Бас, завод,
Безнең көн барышына!
Өр, Казан, гудогың авызына!
Зәңгәр күк — барабан ул.
Бәр, яшен,
Барабанда
Безнең көн маршына!

1925 ел

Биремнәр

1. «Барабыз» шигырен Һ. Такташның «Болай... гади җыр гына» шигыре белән чагыштырыгыз. Уртак якларын һәм аермасын табыгыз.

2. Бу ике әсәрнең уртак һем аермалы якларын тапканнан соң нинди нәтиҗә ясый аласыз, дәфтәрләрегезгә язып куегыз.

ТЕГЕЛӘРНЕҢ КЫЗЫ

Шулай инде, кызый,
Минем йөрәк каты,
Кулларым да йомшак түгелдер.
Ә син менә
Җәйге чәчәк төсле
«Иркә» җанлы, «нечкә» күңелле.

Ары үттең — миңа күз сирпедең,
Бире үттең — күзең төшердең.
Күз нурыңа тәнем рәхәтләнде,
Юган белье кигән шикелле.

Иреннәрең, никтер, роза кебек,
Чәчләрең дә... бөдрә күренә.
Ни дисәң дә,
Безнең кызлар мондый түгелләр.
Кайда безгә
Синдәй «матур» уйлау,—
Әкият кебек
Синең уйларың.
Синең телдә: бакча, оперетта,
Аллеялар, диңгез буйлары...
Безнекенә кайда болай булу!
Син бик чиста кызый икәнсең:
Мин вокзалдан
Журнал алып кердем,
Син аңарга аяк сөрткәнсең.
Безнең кызлар үзе анда хәзер
Авылларны алга җитәкли!
Ә син?
Вагоннан да ялгыз төшәлмисең,
Җитәкләүче
Егет кирәк бит!

«Культуралы» синең
Иреннәр дә...
«Химияле» синең бөтен бит.
Кыскасы, син
Бары алиментка
Җай табарга йөргән элемент.
Уңмаган син, кызый,
Булмаган син!
Чын әйткәнгә хәтерең калмасын:
Безнең сафлар кызын —
Көрәш кызын
Нинди җүләр
Сиңа алмашсын?!

1927 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырь «Тегеләрнең кызы» дип атала. Кемнәр алар «тегеләр»? Җавап табылгач, җаваптан чыгып, Хәсән Туфанның дөньяга карашы турында ни әйтә аласыз?

2. Беренче биремдә әдипнең дөньяга карашы турында нәтиҗә ясадык. Нәтиҗәнең дөреслеген ничек исбат итә алабыз?

3. «Тегеләр» кызының автор күрсәткән кире сыйфатларын санап чыгыгыз. Сез автор бәясе белән килешәсезме? Килешсәгез дә, килешмәсәгез дә ни өчен икәнлеген әйтергә онытмагыз.

4. «Тегеләрнең кызы» шигырен Һ. Такташның «Такташ үлде» шигыре белән чагыштырыгыз. Әсәрләрнең охшаш якларын күрсәтегез.

5. Бу ике шигырьнең охшашлыгыннан чыгып, нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?

БЕЗДӘ ТУА ЯҢА КЕШЕЛЕК

Безнең бәйрәм — миллион ел эчендә
Беренче кат килгән
Зур бәйрәм.
Без бәхетле булмый кем бәхетле?
Ач йөрәкне — җырлап уз әйдә!

Җырла әйдә! —
Дошман кара көяр,
Чит илдәге дуслар
Елмаер.
Унҗиденче елгы кебек итеп
Селкетик бер тагын дөньяны!

Сәлам сезгә!
Ерак илләрдәге
Ал байраклы эшче урамнар!
Сәлам бүген
Үзен, безне яклап
Корал алган ерак дусларга!

Яңа чорга — җиңү гасырына
Чуен нигез безнең унлыбыз[1]
Әй, әзер бул
Килер җиңешләргә,
Партиянең үсмер ул-кызы!

Дөньяның иң даһи акылларын
Үзенә тарта
Безнең төзелеш;
Бездә үсә якты, сау акыллар,
Бездә туа яңа кешелек.

1927 ел

---

[1] Унлыбыз — Октябрь революциясенең ун еллыгы турында сүз бара.

Биремнәр һәм сораулар

1. Хәсән Туфан бу шигыре белән революциядән соң урнашкан тормышны мактый. Ничек мактый?

2. Шигырьнең эчтәлеген тапканнан соң, аны Хәсән Туфанның сез өйрәнгән башка ике шигыре белән чагыштырыгыз. Ул әдипнең дөньяга карашы турындагы сезнең нәтиҗәгә ни дә булса өсти аламы?

ЛУ-И-ЗААА...

Төшләремдә күреп җанкаемның
Мине анда сагынып ятканын,
Тезләреңә куеп башларымны,
Ял итим бер, сеңелем Аккаен.

Сагынадыр ла, Каен, мине анда
Яр булырга вәгъдә биргән кыз:
«Туй ясыйбыз гына дип торганда
Китте ич,— дип, тагы, имансыз!»

Сөю, беләм, үзенекен итәр,
Үпкәләтер аны, елатыр;
Дус кызлары янына алып китәр,
Бакчаларда йөртеп юатыр.

Бөтерелер аның тирәсендә
Богемалар[1] — «юеш талантлар»;
Күкрәгенә килеп бәрелү белән:
— «О богиням!» — дигән карашлар.

Тешләренә кысып «катись» сүзен,
Малайларча кашын киерер;
Һәм кызларча итеп, үз егетен,
Үз «җүнсезен» исенә китерер...

Сагына булыр, Каен, мине анда,
Иптәшлеккә вәгъдә биргән кыз:
«Исән микән, искә ала микән,
Юк микән,— дип, мине, имансыз!»

1929 ел

[1] Богемалар — үзләрен талант иясе дип эшсез йөручеләр.

Биремнәр һәм сораулар

1. Әсәргә анализ ясагыз.

2. 1927 елда язган «Ташла, кызый!» шигырендә Х. Туфан:

Сөяр идем,
Булмый:
Тирән дуслык җинде
Сөюне.
Килдең минә, кердең,—
Бөтен яшьлек буе сагынып көткән
Гомерем дусы булып күрендең.
Көнге эшләреңне
Сөенеп сөйли-сөйли
Иңнәремә кулың салганда,
Сине шундый кысып кочар идем,
Әгәр дә бу
Иптәшлекне вату булмаса...
Уралымдагының
Кофтасына нефть, эмаль тамган,
Ә шулай да аны
Сагынам...—

дип ышандыра.

Хәсән Туфан яраткан Луиза опералар турында сөйләп кенә калмаган, үзе дә артистка булган. Шуны истә тотып: «Лу-и-зааа...» шигырендәге мәхәббәт белән «Ташла, кызый!» шигырендәге «кофтасына нефть, эмаль тамган» кызга мәхәббәт каршылыгын ничек аңлатырга?

3. Ни өчен Хәсән Туфан «Луиза» исемен әсәренең исемендә бүлгәләгән?

ОЗАТУ

(Җыр)

Кайрады егет кылычны,
Атланды ярсу атка.
Озата халык егетне
Илбасар килгән якка.

Карады кызның чибәре:
Аерылып каламмы? — дип,
Юлыңа дигән бүләкне
Тапшыра аламмы? — дип.

Туфрагын илнең төйнәп кыз
Кулъяулык очларына,
Килде дә чая егетнең
Сыенды кочагына.

Киенеп поход киемен,
Ярсыган атка менеп,
Яу килгәнякларга китте
Йөрәге кайнар егет.

1933 ел

Биремнәр

1. Шигырьнең фокусын табыгыз.

2. Әсәрнең фокусы булган символ эчтәлегеннән чыгып, әсәрне ике өлешкә бүлегез.

АК КАЕН

Яфраклары яшел ак каенга
Юл буеннан аклар килделәр.
Ак каенның ярлы авылдашын
Билбавына асып киттеләр.

Асучылар киткәч, сорый каен:
— Авыртмыймы муеның, Хәйбулла?
— Авыртуга түзәр идем, каен,
Тын алуы бигрәк авыр ла.

Билбау кыса, каен, сулышкайны,
Бушатсана шушы билбауны!
— Бушатыр да идем билбавыңны,
Мин каенда андый кул бармы?

— Бөгелсәнә, каен, иелсәнә,
Аякларым җиргә тимәсме?
— Бөгелер идем, буем каты минем,
Үтәр хәл юк синең киңәшне.

— Сәлам тапшыр, каен,— диде егет,
Тынып калды шунда аннары...
Бер эндәште каен, өч эндәште,
Бүтән бер сүз ишетә алмады.

Яфраклары коела ак каенның,
Яфраклары коела яшь кебек.
Әле булса тирбәләдер төсле
Шул каенга аскан яшь егет.

Әйтсәгез лә шушы ак каенга:
— Елама син, каен, аппагым,
Киң кырларда үзе генә түгел,
Эзе дә юк инде ятларның.

1933 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырьнең эчтәлеген ничек табасыз? Табу юлын сөйләп күрсәтегез.

2. Сезгә шигырьнең ахыры ошыймы? Аны үзгәртеп үз вариантыгызны языгыз.

СУ АСТЫНДА БЕР ЕГЕТ БАР

Бер егет упкын төбендә
Баштүбән басып тора...
Моң камыш башын ия дә
Сүз куша агым суга:

— Көн агасың, төн агасың,
Тын агасың, Амурым.
Кем турында, ни турында
Уйланасың, Амурым?

Агым су әйтә камышка:
— Зур минем кайгы-сагыш...
Башкаен түбән ия дә
Амурны тыңлый камыш.

Упкынымда бер егет бар,
Яшәргә хаклы егет;
Кытайлар ягында үскән,
Кызыллар яклы егет...

Ә камыш әйтә Амурга:
— Упкыннан чыксын соң ул,
Итеге ярда ята бит,
Кисен дә шылсын соң ул!

Агым су тирги камышны:
— И камыш, сабыр камыш,
Үзең дә күрдең ләбаса,
Вакыйга сиңа таныш.

Күрдең ич... аңа тегеләр
Авыр таш асканны да,
Муенына ташлар асылгач,
Дәрьяга атканны да.

Кияр дә китәр иде дә
Советка табан тагы,
Японнар аскан авыр таш
Чыгармый судан аны...

Кытайлар иле ягында
Ярда бер өйчек тора,
Кызыллар яклы егетне
Әнисе көтеп тора...

Тыңлады камыш Амурны,
Тыңлады исе китеп;
Тыңлады да үкседе ул
Аналар төсле итеп.

Өч егет тора бу ярда,
Безнең ил егетләре,
Кызыллар иле чигенең
Арыслан кебекләре.

Аларның берсе — кечесе,—
Йөзләре алсу егет,
Күзләре ай төсле тыныч,
Йөрәге ярсу егет.

Җырлады бик тын гына ул.
Тик камыш ишетә аны,—
Камыш та ишетми аны,
Тик Амур ишетә аны:

«Ярдагы өйчек ягына
Бар, Амур син, бар, Амур;
Баласын көткән әбине
Тап, Амур, син тап, Амур.

Елама, әбкәй, елама:
Улыңны күрдем, диген;
Улыңны күрдем дә, әбкәй,
Саулыгын белдем, диген...

Мин синең үз улың, әбкәй,
Мин — хезмәт халкы улы!»
Җырлады шуны егетләр
Өчесе дә берьюлы.

1935 ел

Биремнәр

1. Әсәргә анализ ясагыз.

2. Әсәрнең идеясен әйтегез.

3. «Озату», «Ак каен», «Су астында бер егет бар» шигырьләренең уртак якларын табыгыз. Әдипнең көтмәгәндә яңа темага күчү сәбәбен аңлатыгыз.

Ә ЙОЛДЫЗЛАР ДӘШМИ

Ваемсыз җил килеп керде кырдан.
Туздыра җил
Кибән түбәсен.
Иләс җилгә дәвер күпмегәдер,
Тулы ирек биргән, күрәсең...

Кайда соң сез
Шундый җилле төндә,
Кайларда сез, изге дусларым?..
Яңа яра сала йөрәкләргә
Илебезнең иске дошманы.

Дене түгел, көне өчен генә
Яшәп илнең кайбер кибәге
Дегетли дә дөмгә сөйри бүген
Иң кадерле эре ирләрне...
Ил йөрәге матәм кичергәндә,

Бәйрәм итә кемдер типтереп.
Дозорлыкны — гадел изге эшне
Явызлыкка сугым иттереп.
Кояшка син, йөрәк, йолдызларга:

— Бу ни хәл? — дип сорау бирәсең.
Алар дәшми...
Гамьсезлекнең дәвер күпмегәдер,
Бәйле кулын чишкән, күрәсең...

1937 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Һ. Такташның «Ак чәчәкләр» шигырендәге Җил образын исегезгә төшерегез. Бу шигырьдәге Кышның һәм Җилнең Такташ күз алдында торган мәгънәсе турында сөйләгез.

2. Х. Туфан дусты иҗатын бик яхшы белгән һәм, әлбәттә, аның фикерләрен дөрес аңлаган. Әдип Такташ дусты тапкан Җил образына нинди мәгънә өстәгән?

3. Лирик герой хисенең сәбәбен мөмкин кадәр кыска итеп әйтегез.

УЗЫП БАРЫШЛЫЙ

*

Дала, дала!
Туган җир дә түгел,
Торган җир дә түгел син минем.
Тезләндем мин изге туфрагыңа,
Нишләттең соң мине син бүген?

Киезләргә сузылып яткан сыман
Тәгәрисе килә үләндә...
Нәрсәнедер хәтерләгән кебек
Уйга калам сине күргәндә.

Нәрсә соң бу? Өч-дүрт мең ел элек
Далаларда гомер кичергән
Бабайларның хәтерләре әллә
Уянамы минем хисемдә?..

*

Аксу ягы волостнойларыннан
Комык иле чүле эченә
Качып килеп,
Шунда мәрхүм булган
Бабайларның гүре өстенә
Кызыл гөлләр куеп узып киттем,
Җырлый-җырлый «Сибелә чәчәк»не.
Нәкъ аларча — эчкә йоттым яшьне,
Бозмадым мин безнең гадәтне:
Васыять безгә,— хәтта кызларга да,—
Ни күрсәк тә тормыш юлында,
Күрсәтмәскә яшьне, сыгылмаска,
Сабыр, чыдам, кырыс булырга!

*

Аксубайдан шундый ерак җирдә,
Кавказ сырты киртләчләрендә,
Кем уйлаган шундый биеклектә
Очрармын дип илдәшләремә.

Көтмәгәндә күреп каушап калдым,
Шуа яздым кыя астына:
Якташларым — аппак кыналарым —
Ак каеннар тора каршымда!!

Йөри-йөри арыдым, аппакларым,
Текә таулар иде юлымда.
Яллар итеп, уйлап ятыйм әле,
Тезегезгә башны куйыйм да.

Күптән сүнгән, үлгән вулканнарның,
Эльбрусларның көле өстенә
Биеккәрәк күтәрелгән тормыш
Бүген монда гөлләр үстерә.

Болытларның аргы якларына
Күтәрелгән таулар очында,
Берәр чакрым тирәнлегендәге
Үзәннәрнең тынычлыгында,
Ниндидер бер
Тирән сергә чумып,
Уйга калып тору сизелә.
Эндәшергә, берәр сүз әйтергә
Телиләр күк алар
Кешегә.

Таулар, таулар...
Адәмнәрнең гомере
Сезнекеннән кыска бугай да,
Кеше булып җирдә яши алу
Матур нәрсә үзе шулай да.

1939 ел

Билгесезлекне өйрәнү

(«Узып барышлый» шигыренә анализ)

Шигырьдә лирик геройның хис дәрәҗәсен автор, «уйга калып», «эчкә йоттым яшьне» дип, үзе әйтеп бирә. Юануы да тиз табыла: герой каеннары янында ял итмәкче була.

Ләкин лирик герой нигә хәсрәтләнә соң? Нигә Кавказ тавы башына менеп юаныч эзли?

Хиснең сәбәбе билгесез. Димәк, шигырьнең эчтәлеге турында берни әйтә алмыйбыз.

Шигырен Хәсән Туфан өч өлешкә бүлә. Өчесендә дә укучы алдына әллә никадәр сораулар куя. «Дала, дала» дип башланган беренче өлешендә лирик герой күңелендә бабайларның хәтерләре уяна. Нинди хәтер? Бу хакта берни әйтелми.

«Аксу ягы» дип башланган икенче өлештә хәтер беркадәр ачыклана: кайчандыр безнең бабайлар туган илләрен ташлап китәргә мәҗбүр булганнар һәм читтә үлеп калганнар. Менә шундый күңелсез хәтер. Безнең бабайларны туган илдән куучы, күрәсең, явыз Ивандыр. Ничек кенә булмасын, бабайлар хәтереннән лирик геройга күчкән хис баскыннарга, кеше үтерүчеләргә нәфрәт, туган илдән аерылу хәсрәте генә була ала. Ләкин бабайлар хәтерен искә алу шагыйрьгә нигә кирәк булды соң әле? Ни өчен герой, бабайлар кабере яныннан узганда, «Сибелә чәчәк» җырын җырлый?

«Аксубайдан» дип башланган өченче өлешендә лирик герой ни өчен, текә таулардан үрмәли-үрмәли, Кавказ тавына менгән? Әсәрнең исеменә игътибар итик: адәм баласы үтеп барышлый текә тауга менә димени?

«Узып барышлый» дигән сүзләр очсыз-кырыйсыз дала белән дә, текә кыялар белән дә каршылыкка килә. Өстәвенә ул бит әле әсәрнең исеме! Димәк, бу сүзгә автор ниндидер мөһим мәгънә биргән. Нинди мәгънә? Хәсән Туфан бу хакта да берни әйтми. Әсәрнең исеме дә билгесез урын булып кала.

Лирик геройга тау кыясы артындагы упкын-үзәнлек нидер әйтергә тели. Ни өчен еракка качкан үзән уйга талган? Ул ни әйтергә тели?

Сорауларга җавап, бәлки, әсәрнең ахырында бардыр? Укыйбыз: киресенчә, автор кинәт, бөтенләй көтмәгәндә, җирдә яшәү матурлыгын мактарга керешә.

Шигырь билгесезлек белән башланды, билгесезлек белән тәмамланды. Димәк, бу шигырь бик күп билгесезлектән төзелгән, һәм без аларны, ягъни билгесезлекләрне барлап, өйрәнеп чыктык. Әсәрне аңлар өчен бик мөһим эш башкардык. Нәрсә билгесез булуын ачыкладык, лирик герой хәсрәтенең сәбәбе билгесез дидек.

Бу билгесезлек йомгагын сүтүне нәрсәдән башларга? Әсәрдәге каршылыкларны аңлау өчен нинди юл сайларга?

Анализ ясау юлы — әсәрнең төзелешен бик гомумиләштереп (абстрактлаштырып) кабатлау ул. Әсәр төзелешен бик абстракт рәвештә күзаллауга м е т о д диләр.

Моңа кадәр сез, дәрес саен диярлек, анализ ясау алымнарын, ягъни методны өйрәндегез. Күп әсәрләр өчен уртак алымнар булуга карамастан, аерым әсәргә анализ ясауның җиңел эш түгеллеген күп мәртәбәләр күрдегез. Чөнки һәр әсәр үзенчә билгесез һәм үзенчә катлаулы. Шуңа күрә сез үзегез белгән алымнар

арасыннан шушы әсәргә генә тиң (адекват) алымнар табарга тырыштыгыз. Икенче төрле әйткәндә, билгесезлекне билгеле итәр өчен, сез әле метод билгесезлеген җиңәргә тиеш буласыз. Бу эш сабыр, игътибарлы булуны һәм теория белүне сорый.

Әйдәгез, шул сыйфатларыбызны эшкә җигик һәм анализның икенче яртысын башкарыйк.

Теорияне искә төшерик: шигырьнең барлык җепләре фокуска килеп тоташа. Ә фокус — шигырьдәге иң киеренке, иң каршылыклы урын. Соңгы строфаның эчтәлеге дә, интонациясе дә — алда сөйләгәннәрнең капма-каршысы. Алда кайгы турында сөйләнә, ә монда җирдә яшәү яме турында әйтелә. Бәлки, йомгакның очы шундадыр? Фокус дип исәпләп, соңгы строфа эчтәлеген алдагы өлешләр белән бәйләп карыйк.

Кеше булып җирдә яши алу
Матур нәрсә үзе шулай да,—

ди автор. Әйтерсең лә тауларга менеп юаныч эзләвенә үкенә. Ләкин бу юлларга игътибар белән-рәк карасак, башта күзалланган эчтәлек шик астына алына башлый. «Кеше булып» дигән сүзләрдә юньле кеше булып, намусыңны саклап калып яшәү мәгънәсе дә бар бит әле. «Яши алу» яшәү кыенлыгы турында да сөйли. Ә менә «җирдә» дигән сүз, кылт итеп, башка бер билгесез урынны искә төшерә:

Биеккәрәк күтәрелгән тормыш
Бүген монда гөлләр үстерә,—

дип, Туфан җирдә тормыш юклыгын әйтә түгелме соң? Шулай дип фараз кылсак, бик күп сорауларга җавап табыла: әйе, җирдә тормыш юк, шуңа күрә анда кеше булып калырга мөмкин түгел. Кеше булып җирдә калу матур, ләкин калып булмый, шуңа күрә текә тауларга, тормыш кеше күзеннән еррагракка күтәрелгән урынга менәргә кирәк була. Хәзер әсәрнең исеме тиешле мәгънәсен ала: юк, лирик герой таулар аша узып бармый, тормышның үзе аша узып бара бит. Тормыштан узып китү — трагедия. Һәм бу трагедиянең эчтәлеген тагын бер метод — тышкы бәйләнешләр методын кулланып ачыклый алабыз. «Ә йолдызлар дәшми» шигырендә Хәсән Туфан «иң кадерле эре ирләр»нең дөмгә, ягъни караңгылыкка китеп югалуы турында яза. Җирдә гамьсезлек хөкем сөрә, кешегә дегет-гайбәт ягучылар тулган, ди. Хәзер тормыштан узып барышлый дөмгә юнәлүче кеше итеп Хәсән Туфан үзен исәпли. Үзенең дә эре ирләр артыннан дөмгә китәсен сиземли. Үзенең илдән аерылачагын шагыйрь борынгы

бабайларның илләреннән куылуы белән чагыштыра. Үзендә туган яңа хиснең бабайлар хәтерендәге хис икәнен әйтеп, гамьсезләргә нәфрәт хисе белән януын белдерә.

Шул рәвешле, анализның баштагы өлешендә күренгән билгесезлекләргә җавап алынды. Моңа шигырьдәге эчке һәм тышкы бәйләнешләрнең эчтәлекләрен ачу ярдәм итте. Без, шулай итеп, әсәрдәге билгесез урыннарны билгеле иттек. Иҗади эш башкардык. Әсәргә тиң (адекват) метод эзләп таптык һәм аны файдаландык.

СӘЛАМ ӘЙТЕГЕЗ

Көннәр һаман җилли дә давыллый,
Урман шаулый, Идел моңлана...
Бәхилләшкән сыман баш иям мин
Дулкынланган яшьлек дөньяма.

Үзем монда — сездә, ял йортында,
Күңел ләкин читтән, ерактан —
Кайларгадыр илткән юл чатыннан
Күз сала күк безнең бу чакка.

Хәлне сорап, җанны сыйпап китә
Уйга калган иске танышлар.
Сүзләрендә—серле саубуллашу,
Күзләрендә—яшерен сагышлар.

Нидер тоя күңел, нидер юрый.
Юраганы, бәлки юш булыр:
Хушлашырбыз... Бәлки, бик озакка
Мин утырган урын буш булыр.

Кайчан булса исегезгә төшеп
Безнең шушы көзге җәебез,
Сездә берәр сагыну хисе туса,
Миннән аңа сәлам әйтегез.

Көннәр җилле, төннәр өермәле,
Урман шаулый, Идел шомлана...
Ерактагы юллар ташына басып,
Кул изим күк иркен дөньяма.

1940 ел

Бирем

Әсәргә анализ ясагыз.

20 нче елларда башлап язган шигырьләре

Бу елларда әдип иҗатында өч җитди үзгәреш барлыгын күрдегез.

1. Матбугатта басылып чыккан иң беренче әсәрләрендә автор тормышка революцион карашлы эшче булып бәя бирә, дидек. Хәсән Туфан белән әлеге алдынгы эшче кешеләрне бөтендөнья пролетариатын азат итәргә көрәшкә чакыралар, коммунизмны күз алдына китереп сокланалар, тормышта бәләкәй генә үзгәреш күрсәләр дә шатланалар.

Әдипнең реаль чынбарлыктан ераклашкан шигырьләре бу елларда иҗат иткән башка язучылар әсәрләреннән әллә ни аерылмыйлар.

2. Тормышны якыннан торып өйрәнү Х.Туфанны уйланырга мәҗбүр итә. Тормыш чынлыгы, һичнигә карамый, егет аңындагы идеологияне кысрыклый. Хәзер паровоз белән хәерчелек бер үк шигырьдә янәшә тора алалар:

> Паровозлар керә алмый торган
> Почмаклары күп шул илемнең,—

ди «Каспий яры» шигырендә. Әдип бер үк вакытта бер-берсенә капма-каршы эчтәлекле шигырьләр иҗат итүен үзе дә сизми кала. «Ташла, кызый!» шигырендә:

> Сөяр идем,
> Булмый:
> Тирән дуслык җиңде сөюне...
> Уралымдагының
> Кофтасына нефть, эмаль тамган,
> Ә шулай да аны
> Сагынам,—

дип яза һәм күп тә үтми, артистка кыз Луизага чиксез мәхәббәтен белдереп, «Лу-и-зааа...» исемле шигырен иҗат итә.

3. Такташ — 20—30 нчы елларда хакимияткә ошамаган фикерләрен әйтә алырлык стиль тапкан шагыйрь. Әдип үзе исән чакта ук аңа иярүчеләр күп булган. Бу йогынтыдан Хәсән Туфан да читтә калмый. Башта ул да Такташ шигыренең сөйләм теле, образлары кебек формаль ягын гына кабатлый. Ләкин соңрак, әйтергә ярамаган хакыйкатьне укучыларга җиткерү ихтыяҗы тугач, Такташның иң зур стиль табышын — укучысы белән хәйләкәр диалог алымнарын өйрәнә. Шул рәвешле, сорау, билгесезлек белән тулган шигырьләр иҗат ителә.

Укучысы белән сөйләшү алымнарын үзгәртә-үзгәртә, камилләштерә-камилләштерә үз стилен булдыра. Кавказ таулары, аланнар, ял йортлары турындагы объектив эчтәлекнең әле бер урынына, әле икенче җиргә субъектив эчтәлек өлешләрен кертеп куя. Ял йорты турында язган булып яшьлеге белән саубуллаша. Шигыренә «Узып барышлый» дип исем бирә һәм дусты Һ. Такташның «Үтеп барышлый» дигән шигыренә ымлый.

Хәсән Туфан укучысы белән сөйләшү алымнарын арттырганнан-арттыра бара. Яңа төр төзелешле шигырьләр шул рәвешле заман таләбе белән туалар. Бу шигырьләрнең иң матур үрнәкләрен Хәсән Туфан бирде дисәк ялгышмабыз.

Галимҗан Ибраһимов
(1887—1938)

Әдипнең тормыш юлын сез җиденче сыйныфта өйрәндегез. Аның бик күп әсәрләр авторы булуын, ягъни көчле рухлы әдип икәнлеген белдегез. Сез шулай ук аның революция җиңүе өчен күп көч куюын һәм үзе җан-фәрманга яклаган идеологиянең корбаны булуын да хәтерлисездер. Галимҗан Ибраһимов К. Маркс тәгълиматы милләт һәм әдәбият тарихын өйрәнүдә бердәнбер дөрес принцип дип исәпли. Шуны исбат итеп дистәләрчә мәкалә, «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы», «Татарлар арасында революция хәрәкәте», «Пролетариат әдәбияты турында» исемле күләмле фәнни хезмәтләр яза. Матур әдәбиятның үз эчтәлеге дә, идеология раслаганча, сыйнфый көрәш булырга тиеш дип өйрәтә. Язучылар иҗатын идеологик шарт белән чикли:

«Бер шарт бардыр ки, ул да язучының марксизм аркылы күрүе, андагы (ягъни чынбарлыктагы.— *А. Я.*) сыйнфый каршылыкларны ачуы». «Пролетариатның көрәше бу әдәбиятта иң кыйммәтле эчтәлек булачак»,— дип яза әдип «Пролетариат әдәбияты турында» исемле хезмәтендә.

Галимҗан Ибраһимов — яңа идеологияне татарларга мәҗбүри кертүче генә дә түгел, аның бик ышанычлы сакчысы да. Партия карашыннан тайпылган һәр фикерне тәнкыйть утына ала. Үз фикере булган әдипләргә заманча яман бәя бирүдән дә тартынмый. Зур әдипнең фикере Фатих Әмирханның «Шәфигулла агай» хикәясендә тәнкыйтьләнгән каһарманнарга охшап кала.

Сез моңа кадәр өйрәнгәннәрдән Галимҗан Ибраһимовның бик талантлы, кыю фикерле әдип булуын да белдегез. Аның «Яңа кешеләр», «Алмачуар», «Кызыл чәчәкләр», «Татар хатыны ниләр күрми» исемле әсәрләрендә мәхәббәт, дуслык, игелек, шәфкатьлелек кебек кешене кеше итә торган сыйфатларның матурлыгын күрдегез.

Әйткәннәрдән чыгып, Галимҗан Ибраһимовның сәнгатьчә фикерләве белән фәнни фикерләве арасында каршылык бар, дигән

нәтиҗә ясый алабыз. Сәнгатьчә фикерләвенең нигезе вөҗдан, хис булганга, шул ук нәтиҗәне: әдипнең иманы белән акылы арасындагы каршылык дип ачыклый алабыз. Бу нәтиҗәнең дөреслеген язучы иҗатын тулысынча өйрәнгәннән соң гына исбат итәргә мөмкин. Әдипнең сез укымаган «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр» романнары, «Казакъ кызы» исемле повесте бар әле. Хәзер сез шуларның берсен, яңа тормышка турыдан-туры бәя биргәнен өйрәнәчәксез.

«Тирән тамырлар» романын Галимҗан Ибраһимов 1926 елда яза. Әдипнең иманы бу әсәрендә дә акылыннан өстен чыга аламы? Әллә әдип, үзе башкаларны өйрәткәнчә, тормышны «марксизм аркылы карап» сыйнфый көрәшне ачу белән генә чикләнәме?

Бу сорауларга романга анализ ясаганда җавап бирербез.



ТИРӘН ТАМЫРЛАР

(*Тугры сүз*)

I

Фәхрине үтереп ташладылар.

Гайшәнең күзләренә йокы кермәде. Самавырын сүндермичә, әнә кайта, менә кайта дип, ирен көтте. Ярты төн аугач, түзмәде, күршедә комсомол Шәяхмәт бар иде, шуңа керде. Аның белән бергә Совет башлыгы Тимеркәев иптәшнең өенә киттеләр.

Гайшә борчулы, акрын тавыш белән:

— Шәнгәрәй абзый, күңелем бик куркып тора, берәр хәл булмаса ярар иде,— диде.

Хатынның сүзенә ялгап, Шәяхмәт тә басынкы, аптыраулы тавыш белән:

— Фәхри абзыйга теш кайрап йөрүчеләр күп иде,— дип өстәп куйды.

Аягына чабатасын, өстенә чикмәнен киде дә, Гайшә белән комсомол егетне ияртеп, совет йортына китте.

Һәм шул төннән эзләү башланды.

Иделнең таулы-ташлы, урманлы биек ярлары эчендә «Байрак» белән «Хезмәт» арасында Яманкул атлы озын, тирән чокыр бар. Тирән чокырның төбендәге үләннәр, киң яфраклы кыска агачлар арасыннан Фәхрине табып чыктылар.

Аның йөзе изелеп, канга баткан, баш сөяге ватылган, сул як кулбашы канлы туфрак белән укмашып беткән иде. Янында ук зур, калын тимер кендек тә табылды. Моның нечкә башы бөтенләй кара канланып каткан иде.

Фәхрине яраталар иде. Үз итеп, туган итеп, авыр йөккә төптән җигелеп өстерәүче итеп яраталар иде. Канга буялып яткан коточкыч төстәге үлекне күргәч, телдән язган кебек булдылар.

Башкалар белән Җиһанша бабай да килгән иде. Аның күзләренә канлы тимер кендек чалынды. Кендекнең калын башына сүс җеп уралган, кечек тишек аркылы кәкре кадак үткәрелгән иде.

Җиһанша, каушаулы тавыш белән бераз калтыранып:

— Җәмәгать, бу кендек минеке бит! — диде.

Гайшә белән Шәнгәрәй икесе бер үк вакытта, нидер әйтмәк булып, авызларын ачтылар. Ләкин аларны яшь гаскәри курсант Шәяхмәт бүлде. Ул Җиһаншаның җиңенә барып тотынды:

— Ни сөйлисең, бабай?! Баш китәрлек сүз әйттең бит! — диде дә киселде. Аз гына катып торып өстәде: — Кендек синеке булса... ни эшләп ул Фәхри абзый каны эчендә?

Бабайның тормыш юлы авыр булды. Тугыз йөз бишенче елда аның туган энесе Тимершаны, кое баганасына асып, тәнен кискәләделәр. Бу аның чәчләрен агартты. Пролетариат революциясенә ул ике улын корбан итте.

Җиһанша бабай сокланып үстергән егетләрен уйлый иде дә: «Мин сәвиткә ике арыслан бирдем! Мин сәвитне үз каным белән саклаштым!» — дип күңел эченнән тирән бер хак белән мактана иде.

Шәяхмәтнең әллә нинди шөбһәле каты сүз әйтүенә рәнҗүе — бабайның менә шул тамырларына килеп бәрелүдән иде.

Ләкин карт сабыр адәм иде. Сүзне тиз икенче якка борырга үзен бурычлы санады:

— Җәмәгать,— диде,— әйтсәм — телем бармый, әйтмәсәм — ярамый, бу кендекне миннән Садыйк кияү алып торган иде... Шимбә көн иде бугай... Бер итеген кигән, берсе кулында...

Чатанлап килде... Итегемнең үкчә кадаклары тишеп чыкканнар. Шуларны төйгечләп алыйм, син миңа кендегеңне биреп тор, диде.

Садыйкны беләләр, яраталар. Авылның кияве итеп тә, җирсу алып бирешүдә юл күрсәтүче итеп тә, Фәхригә булышлык кылучы итеп тә яраталар.

Аның турында яман тел әйтергә берәүнең дә авызы ачылмады. Ләкин Шәнгәрәй хатыны Рәгыя, гомер барынча кочегарны чит күрә иде. Чыдамады:

— Харап! Күршеңә кунак булып киләләр дә үзеңне үтереп китәләр бит? — диде.

Шәнгәрәй хатынының сүзен кисте:

— Телеңне тый, Рәгыя! Ни эшләп Садыйк кияү булсын? Алар гомерлек иптәшләр ич? Тиле!

Сүз кыза башлады.

Баядан бирле бер читтә торган, кечек буйлы, кылый күз Гыймади карт та чабатасын ышкытып уртага керде:

— Минем бер шигем бар иде. Мин әйтәм, бергә эчкәннәрдер, исергәннәрдер, икесе дә, мин әйтәм, бик карахтырлы нәрсәләр... Алар бит, мин әйтәм, гомер буенча бер-берсенә теш кайрап йөрделәр бит, мин әйтәм. Кәчәгәрнең маңгаенда яра кем кулы дип беләсең?

Гайшә кинәт йокысыннан уянып киткәндәй булды:

— Шул гынамы? Егет чакта андый гына эчеп сугышу кем арасында булмый дисең? Минем Фәхрием һаман-һаман әйтә иде, кәчәгәр минем революция хәлфәм ул, ди иде.

Шәнгәрәй авыр чуалчык эшләренең уйлап-уйлап та, очына чыга алмыйча аптырады. Ул иртә үк, Фәхринең гәүдәсе табылгач та, волбашкармага хәбәр җибәрткән иде. Һәр минут көтә иде.

II

Чумар карак дигәннең эзенә төштеләр. Тирә-якның теңкәсенә тиеп беткән байтак бандитлар эләктеләр.

Менә шул зур җинаятьнең төбен тикшерер өчен, каладан чуваш коммунисты Паларусов иптәш җибәрелгән иде.

Ул дүрт тәүлек шуның эчендә кайнады. Илле дүрт кешене җавапка тартты. Эшнең беренче баскычы бетте дип, ул бүген калага кайтып китәргә җыенган иде. Шулвакыт волбашкарма ишегеннән озын, сары чәчле ябык бер егет кычкырды:

— Паларусов иптәш? «Байрак»тан кеше җибәргәннәр... Фәхри табылган икән.

Бүген-иртәгә шәһәрдә партконференция ачыла. Ул анда әгъза булып сайланган. Әлбәттә, вакытында кайтып җитәргә кирәк.

Җинаять турында хәбәр алынгач, тикшерүченең бармый калырга яки кичектерергә ярамавы икенче яктан китереп кыса. Петровтан сорады:

— Пароход ничәдә үтә?

— Язу буенча җидедә...

Башка чара калмады. Тикшерүче үз эченнән: «Бәлки, өлгерермен»,— дип уйлады.

Петров белән Паларусов икәү, Тимеркүккә утырдылар да каулый биреп, Байракка таба юл тоттылар.

III

Паларусов үтерелгән Фәхри белән яхшы таныш иде. Ат килеп туктауга арбадан төште дә картлар белән татар телендә исәнләште. Гайшәгә Фәхри үзенең дус кешесе булганын әйтте.

Иделнең текә яры башында ялгыз карт имән бар. Гомере ничә йөз еллар белән санала. Тамырлары тирән, калын ботаклары киңәеп, түгәрәкләнеп таралалар. Яфраклары куе. Җәйнең иң кызу чакларында да аның төбендә салкынча күләгәлек була.

Әйберләрен шул зур имән төбендә күләгәдә калдырдылар да текә ярдан Фәхри гәүдәсе табылган җиргә төштеләр. Паларусов портфеленнән кәгазьләр чыгарды. Карау тәмам булгач, протоколны укыды да юлдашларына кул куярга бирде.

Тышта булганда, шаһитлардан да, гаепләнүчеләрдән дә ялгызялгыз сорау бик кыен булачак. Мәрхүмнең хатыны Гайшәгә:

— Енгәй, әйдәгес, песне өйгә алып керегес,— диде.

IV

Фәхри атасыннан бер казык та алмый чыкты. Чөнки юк иде. Хатыны артыннан да бернәрсә дә килмәде. Чөнки кызның ата-анасының теләвенә каршы өйләнештеләр. Кемдә туры килсә, шунда өйдәш торып гомер иттеләр. Аннан Фәхри фронтлардан юньләп кайта алмады. Менә шул арада инде Гайшә үзенә аерым оя кору чарасына төште.

Революция килгәч, алпавытны басып байтак урман кискәннәр иде. Гайшә менә шуннан тигән бүрәнәләрне каезлап, киптереп өйде. Ире сугышларда йөргәндә, илдән урын сорап алды да агайэнесенең, күрше-күләннең булышлыгы белән, менә шул хәзерге өйне бетереп керә алды.

Паларусов, түргә атлап, сәке янындагы зур, буяусыз агач өстәлгә портфелен ташлады. Гайшәне сәке буендагы урындыкка утыртып, Фәхри үтерелүе турында җаваплар алуны башлады.

— Ну, енгәй, турысын әйтегес: кемнән шикләнәсес? — диде.

— Бик күп инде.

— Ул дошманнар нидән булды?

— Нидән булсын? Җир-суларны тартып алды дип, әртилгә, коммунага котырта дип.

Болардан соң Паларусов Фәхринең яшен, кәсебен, тормышын сорап, шул турыдагы материалларга кереп китте.

Сүз гаилә тарихына күчте.

— Татарларда кысны көчләп бирәләр. Сесне дә шулай иттеләрме?

Гайшә көлде. Үз эченнән бу сөальнең кирәге барын аңламады.

V

Гайшә Паларусовка болай киңләп сөйләмәде. Аңа бирелгән сөальгә:

— Юк, көчләп такмадылар. Мин әткәйләрнең ризалыгыннан башка үзем теләп чыктым,— диде. Ул күңел дөньясын сөйләүгә саран иде. Җырлап-җырлап сабан сөрүләрен, иген чәчәргә өйрәнүләрен бер дә телгә алмады. Ирләр белән ярышып печән чабуларын да сөйләмәде. Ялгызы урман кисеп утын ташуларын, ашлык сатарга калага йөрүләрен авызга да алмады.

Гайшә протоколга кул куеп чыгып китте. Паларусов, тәрәзәдән башын тыгып, Петровка әйтте:

— Гыймадетдин Бикмурзинны кертегез!

VI

— Фәхретдин Гыйльмановның үтерелүе турында ни беләсес? Сөйләгес!

— Минем белгәнем — шул кәчәгәр инде! Бандит нәрсә ул: теге чакта да һичбер гөнаһсызга Габдулла дигән бер кешене атып үтерде.

Гыймади болар өстенә маңгайдагы яраны сөйләде. Кендек вакыйгасына озак туктады. Фәхри югалачак көндә, кичкә каршы, аларның икесенең Идел яры буенда Яманкул чокырына таба талаша-талаша китеп баруларын хикәя кылды.

— Моны Әхми дә күрде,— дип сүзеннән туктады.

Бу соңгы әйткәне бөтенләй яңа нәрсә иде. Тикшерүче моңа аеруча кыйммәт белән карады. Берничә яктан кузгаткыч сөаль биреп, картның сүз тегермәнен әйләндереп җибәрде.

— ...Менә шулай,— ди.— Безнең совхозга хәзрәт килеп төште. Фәрит дигән хәзрәт. Вәли бай (байраклар аңа тирече Вәли диләр) мине чакырта да әйтә: хәзрәт килгән. Идел буйларын күреп йөрер идем, ди, син, ди, аны йөртеп кайтар, ди. Көймәнең ишкәкләрен кулбашына күтәрдем, икәүләп текә яр буеннан киттек. Яманкул өстендәге карт имәнне карап үттек. Хәзрәтем сөйләнә бара: борын-борын заманнардан, ди, бу җирләрдә безнең бабаларыбыз Болгар, Казан ханнары хөкем сөргәннәр иде, ди. Мәскәү патшасы җиңгәч, боларның һәммәсен дә, ди, безнең кулдан тартып алып, ди, урыс байларына, урыс түрәләренә өләштеләр, ди. Әле, ди, күптән түгел, бу изге тупраклар өстендә, ди, Аликси дигән кяфер алпавытларның, кенәз Гагариннарның хәрам дуңгызлары ауныйлар иде, ди. Менә хәзер инде бу заманның үткен, гайрәтле яшьләре, ди, бу урыннарда Татарстан җөмһүрияте төзеделәр бит, ди. Мин ишетәм, ди, мондый җирләргә, Идел, Чулман буйларына, ди, фәкыйрь мөселманнар күчеп килеп авыл-авыл утыралар, имеш, ди...

Паларусов сабырсызланып сәгатенә карады: һәрбер шаһит болай дөнья яратылганнан алып сөйли торган булса, болар, әлбәттә, партконференциягә өлгерү планын кымәчәкләр... Ул бүген китә алмаячак.

Шул уйлар белән борчылып, картның сүзен кисте:

— Бабай, болар нигә кирәк? Сез миңа әкият сөйләмәгез...

Гыймади, аз гына да каушамыйча, нәкъ бая туктаган сүзеннән ялгап китте:

— ...Син, ди, Гыймадетдин кордаш, ди, миңа шуларның Байрак дигән авылларын күрсәтер идең, ди. Яңа күчкән мөселман авылын үз күзем белән күрер идем, тупрагына битемне сөртеп, Аллага бер дога кылыр идем, ди. Шулай сөйләнә-сөйләнә авылга кердек. Ул йортларны санап бара. Бер яктан унсигез, каршы якта унҗиде йорт икән, ди. Шулай, мин әйтәм, Фәхри дигән юньле егетләр бар. Иске Акташ авылыннан монда кырык гаиләне күчереп утырту эшендә шул җитәкчелек итте, мин әйтәм. Болар, мин әйтәм, хәзрәт, камунага тартым халык, һаман-һаман, өмәләп, күмәкләп, әртилләшебрәк эшләү ягын каералар, дим.

Мин көймәмне йозаклап азапланганда, югарыдан ике тавыш ишетелде. Ачык таныдым: берсе шул кәчәгәр Садыйк дигәннәре, берсе мәрхүм Фәхри иде. Котырынган этләр кебек талашып баралар иде. Ул арада: «Нигә бу чаклы озак йөриләр, тизрәк кайтсыннар»,— дип, бай минем арттан Әхмине дә җибәргән икән. Ул да күреп калды.

Паларусов, язганнарын укып, Гыймадетдин Бикмурзинга кул куярга бирде дә, үзе тәрәзәдән башын тыгып кычкырды:

— Петров, Шәнгәрәй, Тимеркәев иптәшләр, совхоз эшчесе Әхмәт Уразов белән каладан килгән Садыйк Миңлебаевны тизрәк табып китерегез,— диде.

Хәзер җавапка Җиһанша бабай чакырылды.

VII

Җиһанша карт — зур буйлы, киң җилкәле, кыска кырылган ап-ак чәчле, күкрәгенә төшеп торган көрәктәй киң ап-ак сакаллы крәстиян. Яше җитмешкә җитсә дә, әле гәүдә таза, йөреше ныклы.

Ул, иртәнгечә, кендекнең бөтен тарихын сөйләп бирде. Сүзен бетереп, карт чыгып китте. Аның артыннан Шәнгәрәй, аннан шәһәрчә киенгән яшь хатын Нәгыймә җавапка керделәр. Тагы шул шимбә, маңгайдагы яра эзе, канлы кендек, дошманлашу турында сүз булды.

Сорауларның һаман-һаман шуларга кайтуы Нәгыймәне борчуга төшерде. Ахыр, чыдамады, кулындагы алты айлык кызы Фатихәне Гайшәгә тоттырды да ире артыннан тимерлеккә таба йөгерде.

VIII

Ләкин күп барырга туры килмәде. Түбәннән ике баш калыкты. Боларны күрүгә хатынның йөзе ачылып ук китте. Балалар кебек канатланып, иренә каршы очты. Шәяхмәт белән бергә кайткан озынча буйлы, ябыграк, ләкин нык гәүдәле, маңгаенда тирән яралы кеше Нәгыймәнең ире Садыйк иде.

Болар Фәхри өенә җиткәндә, тикшерүче янында Шәнгәрәй хатыны Рәгыя утырадыр иде.

Ул арада, Паларусовның чакырганын көтмичә үк, Садыйк Миңлебаев өйгә килеп керде. Рәгыяне чыгардылар.

Кочегар ишектән үк, исәнләшер-исәнләшмәстән, урысча:

— Сез нигә мине эзләттегез? — диде.

Тикшерүче өчен хәзер мәсьәлә ачык. Кочегарның гаепле булуы турында аның мие үзенә кискен караш эшләп куйган. Шулай да ул, төп асылда, болай булуга үзе риза түгел. Зур фактлар килеп чыгарлар. Миңлебаев өстенә авып барган гаепне җимереп ташларлар дип өметләнә.

Җавап алуны шаблон буенча башлады. Исемен, монда нигә килүен, һөнәрен, хәзер кайда эшләүләрен сорап бланкыга язды.

һөнәре турындагы сөальгә: «Химик!» — дип җавап алгач, бераз шик белән тукталды.

— Алайса, сескә нигә «кочегар» дип кушамат биргәннәр?

— Мең тугыз йөз уникенче елның язында Лена буендагы алтын приискаларында эшчеләрне аттырдылар бит. Шуңа протест итеп безнең завод өч көн эшләмәде. Мине, Василий Петровичны, тагын унбер эшчене, котыртучылар дип, кулга алдылар, урыннан кудылар. Күп заман эшсез йөрдем. Күп ... өстерәлгәч, Алафузовка кочегар итеп алдылар... Минем кушамат менә шуннан калган.

Ни өчен монда килүе турында сүз тиз үтте. Миңлебаев үзенең хатыны менә шул Байрак авылыннан икәнен, җәйге айлык хәл җыюны каенесе Шәяхмәттә үткәрүен әйтте. Балалар да, хатын да бераз һава иснәсеннәр дидем, ди.

— Алайса, тимерлектә ни эшләп йөрисез?

— Моннан өч-дүрт чакрымда «Маяк» дигән артель бар. Шуларның тимерчеләре Иделгә батып үлгән. Миңа картлар килеп ялындылар: атның дагасы бушый — тимерче юк. Арбаның шины какшый — тимерче юк, диләр. Ничектер кузгалып бардым да эшләргә тотындым.

— Шимбә көн тимерлектән ялгыс кайттыгысмы?

Садыйк иренми тулы җаваплар бирде.

Ялгыз каенгача Фәхри белән бергә килгәнен сөйләде: аннан аерылыштык. Мин «Байрак»ка кайттым, Фәхри «Хезмәт» совхозына китте. Анда эшчеләр белән тирече Вәли арасында ызгыш чыккан икән, Фәхри шуны тикшерәчәк булды, диде.

Паларусов яза-яза уйланды. Аның көткәне ничектер чыкмый. Утырган кискен караш җимерелми тора. Шулай аптырабрак, ул өстәлдәге портфелен бер якка этәрде. Аның астыннан канлы кендек килеп чыкты.

— Моны таныйсыңмы?

Садыйк беренче тапкыр сискәнеп китте.

— Менә шул кендек Яман чокырдан табылган. Үзе канлы...

Моны ишеткәч, Садыйк Миңлебаев бөтенләй агарынды. Ул, бер сүз әйтми, ачулы караш белән кендеккә текәлде.

Гаепләнүченең йөрәгендә, миендә башланган бу үткен процесс Паларусовка бик таныш хәл иде. Садыйкны шул утлы процесс эчендә калдыру өчен, ул тышка кычкырды:

— Килгән булса, Әхмәт Уразовны кертегез! — диде.

Аның исәбе гаепләнүче белән шаһитны күзгә-күз сөйләштерү иде.

Озын буйлы, бик ярлы киемле крәстиян бөгелә-сыгыла керде. Гәүдәсе зур, ләкин йомшак, сыек. Йөзе бик керле. Күз кабаклары кире кайтарылып, кызарып торалар. Өстендә иске чуваш чикмәне. Билендә тышау. Аягында каралып беткән иске бәйләм оек белән чалышаеп беткән, киндерәсе өзелгән начар чабата. Паларусов кыска-кыска сөальләр бирә башлады. Яр буеннан үзара талашып барган ике кешегә күчте.

Әхми пычрак җиңе белән канлы күзләрен угалады.

— Күрмәдем дияр хәлем юк. Берсе анык Фәхри абзый иде... Икенчесе менә җизнигә охшаган кебек иде. Сүгенеп баралар иде.

Садыйк ерткыч күзләре белән Уразовка карады. Гаҗәпләнү катнаш борчулы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Күрәләтә ялганлый бит!.. Кем өйрәткән моны?! — диде.

Тыштан Гыймадины чакырдылар. Ул буталыбрак булса да, баягыларны кабатлап бирде.

IX

Җаваплар алу планы шуның белән үтәлгән иде инде. Аның башы ашыгыч-ашыгыч кайный иде. Портфелен култык астына алды, сәгатенә карады да кочегарга әйтте:

— Садыйк Миңлебаев, сез киенегез, хәзер калага китәбез,— диде.

Халыкның йөрәгенә ниндидер куркулы әрнү дулкыны барып кагылды. Арадан берсе торып: «Юк, булмас, кәчәгәрне бирмибез»,— дип акырып күтәрелсә, һәммә кеше ак-караны аермыйча, уртага сугышка ыргытылырдай хәлгә килде.

Садыйк кычкырып үзенә ташланган хатынын, кулыннан тотып, кире сәкегә утыртты.

— Юкка елама! Мине иртәгә үк чыгарырлар,— дип, аны юаткан хәлдә, үзе киенә башлады.

Атлар әзерләнеп өлгерделәр. Зур Тимеркүкне аксата-аксата, Петров волбашкармага юнәлде. Садыйк Миңлебаев, милиционер, Паларусов, өчесе бергә утырып, пароход пристанена таба йөгертеп киттеләр.

Җиһанша бабай болар күздән югалганчы карап торды-торды да кире Фәхри мәрхүмнең капка төбендәге бүрәнәгә килеп утырды. Авыр караңгы уйлар аның карт миен тирәннән борчып, чолгап алдылар.

Аның алдында кешеләр икегә — дуска, дошманга бүленәләр. Ихлас күңелдән советчылар — болар дуслар. Болай булмаганнар —контрлар, дошманнар! Совет контрларны яба. Контрлар

большевикны, эшче-крэстиянне асалар, кисэлэр. Бу да табигый. Эмма менэ Садыйк кебек бер кешегэ советның кул салуы — бу инде бабайның зиһененэ бертөрле дэ сыймый. Карт уйлап очына чыга алмады, үзенэ сөземтэ ясап куйды:

— Сэвит үз баласын үзе ашый башлады. Бу хэерлегэ булмас! — диде.

X

Өй саклап калган карчык бер ай хэл җыярга дип киткэн хуҗаларның болай кинэт кайтып төшүлэрен бик гаҗэпсенеп каршы алды.

Балаларның боеклыгы, Нэгыймэнең кискен борчылу эчендэ күренүе аның күңелендэге шиген тагын арттырды.

Лэкин хатын аңа мэсьэлэнең нэрсэдэ икэнен эйтеп торырга кирэк тапмады. Чөнки ул менэ хэзер үк Садыйкны коткарып алырга мөмкин дип ышана иде. Шул исэп белэн, кызуланып, шэһэр урамына атылды, зиндан ягына очты.

Нэгыймэ караңгы тимер рэшэткэ куелган тэрэзэле сары таш йортка, революциягэчэ, иренең хэлен белер өчен, күрешер өчен күп-күп тапкырлар килгэн иде. Шул авыр көннэрнең шомлы хэсрэте яңадан баскан кебек булып калды. Калтырап барып биек мапара астындагы агач капкага сукты. Аннан кечкенэ күз ачылды:

— Ни бар?

— Ирем монда. Шуның янына килдем...

— Шимбэ кил. Чэршэмбе кил. Көндез сэгать уникедэн ике арасында гына. Башка вакыт кертелми. Лэкин хатын тынычланмады:

— Минем ирем коммунист бит,— дип җавапларга уйлады.— Фабзавкомда эшлэде, хэзер дирекциядэ,— диярге исэплэде. Райкомда, ячейка бюросында җаваплы хезмэтче икэнен сөйлэмэк булды.

Лэкин капкач күтэрелмэде. Хатын эрнүеннэн ни эшлэргэ белмэде. Баскан җирендэ байтак катып торды да: «Ул берэр нэрсэ җайлар эле»,— дип, Василий Петровичка китте.

Аның карчыгы:

— Сэгать алтыда партконференция ачылды бит. Пароходтан кайтуга чэй дэ эчэ алмады, шунда китте,— диде.

Аннан Татар-Башкорт команда курсларына телефон шалтырату өчен почтага керде. Курстан Шэяхмэтне сораса:

— Ячейкада бүген аның докладды, пароходтан килеп төшүгэ шуңа тотынды,— дип җавап бирделэр.

— Бер генә минутка чакырыгыз, мин аның апасы,— диде.

— Юк, булмый. Хәзер аның доклады буенча бик кызу аңлаш бара. Мөмкин түгел,— дип кырт кистеләр.

Нәгыймә Козлов номерларына китте. Монда хәзер Советның беренче өе иде. Шәрәфи шунда тора иде.

Пыяла ишекне ачып кергән җирдә хатын швейцар каршы алды:

— Сез кемгә?

— Утыз икенче бүлмәгә, өйдәдер бит?

— Ячейкага китте.

Монда тагы берничә таныш татар коммунисты бар иде. Аларны сорады. Шундый ук җаваплар алды. Нәгыймә кыза башлады:

— Бу ни эш бу? Берсе дә өйдә тормыйлар!

Хатын швейцар көлде:

— Шулай булмый ни эшләсен?! Алтыда партконференция ачылды. Билет ала алганнар шунда китте, башкалары ячейка җыелышында... Бүген сишәмбе ич: партконференция! Беләсезме? — диде.

Башка чара тапмады: «Бәлки, берәрсен очратырмын»,— дип, партконференциягә барырга булды.

Матур архитектура белән эшләнгән ике катлы биек ак бинада элек заман мирза дворяннар җәмгыяте иде. Революция моның тышына да, архитектурасына да тимәде. Матурлыгын да сакларга тырышты. Тик аның эчке мөндәриҗәсе[1] генә алмашынды. Иске заманның дворяннары урынына хәзер эшчеләр, крәстияннәр, кызылармеецлар тулды. Зур җыелышлар, корылтайлар, конференцияләр — һәммәсе шунда үтәләр.

Нәгыймә килеп кергәндә, комклубның, таяк тыгылган кырмыска кебек, кызу яшәгән сәгатьләре иде.

Хатын туры өске катка менәргә теләде. Ләкин аны туктаттылар. Баскычның югары ягында тәмәке тартып утырган бер күн кием күренде. Ипләбрәк караса, бу Иванов булып чыкты. Хатын аны үтенеп үзенә таба чакырды да берничә урыс, татар фамилиясен әйтте.

— Кайсысын күрсәгез дә, менә шул кәгазьне бирә күрегез,— диде.

Берничә минут та үтмәде, ябык Шәрәфи күренде. Ул ячейкага барып, бер докладны үткәргән дә, президиумнан сорап, монда килгән икән. Хатынның йөрәгенә өмет кереп китте. Башыннан үткәнне ашыгып сөйләде дә:

[1] Мөндәриҗә — эчтәлек.

— Йә, сез ни эшләдегез? — дип, егетнең күзләренә карады.

Шәрәфи өзеп бер сүз дә әйтә алмады. Һәммә нәрсәне конференциягә аударды, һичкем белән һичбер сүз сөйләшер хәл юк икәнен аңлатырга тырышты.

— Тагын талашып карыйм, берәр эш чыкмасмы? Сез түбәндә, көтепханәнең залында көтегез,— дип, өске катка китте.

Президиум артында бүлмә бар. Шуның ишеге төбендә күзләре белән кемнедер эзләп, зур буйлы, калын гәүдәле берәү тора. Шәрәфи барып җиңеннән үк тотты:

— Бер генә минут! Бер генә сүз!

Ләкин Гайфуллинның бер генә минут түгел, бер секунд та вакыты юк иде. Аны конференциянең мандатлар комиссиясенә рәис итеп сайладылар. Бер сәгать тынычлык юк. Шул сәбәпләрне әйтеп, егеттән качарга уйлаган иде, Шәрәфи ирек бирмәде, прокурорны теге арткы бүлмәгә өстери-өстери сөйләргә кереште:

— Беләсездер, Садыйкны яптылар бит...— диде.

Бу вакыт залда Үзәк Комитет докладлы бәйнәлмиләл[1] пролетариат хәрәкәте һәм Коминтернның конгрессы турына килеп җиткән иде. Гайфуллин үзалдына:

— Менә докладны тыңларга да возможность юк бит!— дип сукранды. Ләкин башка чара юк иде. Миңлебаев турында кыскача аңлатып бирде:

— Мин,— диде,— ул эш белән отчасти знаком. Кичә Паларусов аягүрә генә докладывать итте. Мин аңа әйттем: син, дидем, неправильно поступать иткәнсең, дидем. Ул бит — каты кеше. Миңа возражать итте: минем, ди, арестовать итәргә довольно ышанычлы основаниеләрем бар, ди. Следователь мондый позиция тоткач, мин үзем генә аны боза алмыйм. Следователь белән прокурор арасында «меры пресечения» турында разногласие чыкса, бу эш распорядительный судның решениесенә биреләдер...

Шәрәфи аптырап карады:

— Ул кайчан булыр? — Аны бик тиз эшләргә можно иде... Тик менә мандатный комиссиядә, конференциядә кайныйбыз бит!

— Алайса, ни эшләргә? Беләсең, Садыйк бит конференциягә дә сайланган иде...

— Беләм, ул безнең районнан үткән иде. Без аны үзебез проводить иттек... Сезгә хәзер одно из двух: сез безнең распорядительный судның результатын көтәсез... Или Садыйк

---

[1] Бәйнәлмиләл — *бу урында*: халыкара.

Миңлебаевны поручительствога алып чыгарасыз... Ике авторитетный лицо... Или берәр рабочий организация, кулыннан подпись биреп, аңа поручитель була...

Гайфуллин сүзен бетерер-бетермәс сызды. Шәрәфи, утырып, кечкенә кәгазьгә нидер язды да яңадан залга керде. Анда тирән тынлык эчендә һаман Үзәк Комитетның докладь бара иде. Хәзер сүз Социал Советлар Җөмһүриятенең эчке эшләренә, хуҗалык һәм мәдәният төзелеш мәсьәләләренә күчкән иде.

Шәрәфи үзенең тыңлый алмавына әрнеде, ләкин тегендә кеше көткәнгә, ахыргача барып чыкмый мөмкин түгел иде. Арт яклап килде дә кулындагы кәгазен, президиумга кереп, кулбашы аркылы Василий Петровичка төртте. Карт әйләнеп карады. Бармак белән янына чакырып алды да урысча:

— Үзәк комитетның докладь бетсен. Сәгатьтән артмас. Шуннан соң үзем чыгып сөйләшермен, мине түбәндә көтепханәдә көтсен,— диде.

Шәрәфи тиз-тиз чыкты да Нәгыймәгә ни булганын сөйләп бирде. Тик прокурорның Садыйкны гаепле күрсәтүче әйберләр көчле икәнлеге турындагы сүзен үзе йолып калды. Бу конференция сәбәбеннән Миңлебаевның эшен ашыктырырга юл юклыгын аңлатты да, егет үзе, ашыгып, залга доклад тыңларга йөгерде.

Нәгыймә моны көтмәгән иде. Һаман бергә кайнаган бу иптәшләр мәсьәләгә ничектер салкын караган кебек күренделәр. Берсе дә: «Чыгарам, менә хәзер үзем барам да чыгарам»,— дигән кебек өзеп сүз дә әйтә алмый, эш тә кыла алмый икән!

Бер сәгать үтте. Василий Петрович чыкты. Ләкин ул да вәгъдәдән үтмәде. Ул да шул конференциягә сылтады. Прокурорны, секретарьны күрәчәк булды.

Нәгыймә бөтенләй ватылды, изелде. Дөньяның иң бәхетсез адәме кебек бер тойгы басты. Комклубтан чыкты да шәһәрнең таш урамнары буйлап тагы өенә, балалары янына кайтты.

Нәгыймә бөтен төнне ире турында, үткән гомере турында кайгылы уйлар белән, күз яше белән кичерде.

XI

Нәгыймә Акташта үсте.

Үсеп буйга җиткәч, аның яшь йөрәгенә беренче кереп утырган егет Садыйк булды.

Җәйнең матур бер көне иде. Җиту кыз Нәгыймә, тән тамырларында яшьлек канының тулып ташуына рәхәтләнеп, үз эчендәге

шатлыкка үзалдына елмая-елмая, матур көйләр көйли-көйли, ындырга барып, бәрәңге алды да кое төбендә ялгызы әйбәтләп юа башлады. Шулвакыт күршенең читәненә теге яклап бик сак кына ике аякның якынлашканы ишетелде. Ул әйләнеп карамады, ләкин кем икәнен йөрәге белән сизенде.

Каладан җыенга дип үзенең кардәшләренә килгән бер егет бар. Төскә үтә чибәр түгел. Ләкин буе-сыны килешле, йөрешкыланышы күңелгә ятышлы. Менә шул егет һаман-һаман бу йортка таба күз ата. Аның карашларында ниндидер аерым бер җылылык, ягымлылык бар кебек.

Читәнгә якынлашкан егет — шул иде. Нәгыймә як-ягына каранды:

— Сак бул, егет, авыл егетләре күреп калсалар, иңсәңне сындырырлар! — диде.

Ачу белән түгел, бик аз гына, бик аз гына яклау аһәңе белән әйтте.

Егет бу куркынычны үзе дә белә иде. Сизсәләр, әлбәттә, рәхмәт әйтмәсләр. Кала килмешәгенең авыл матурларына кагылуын авыл яшьләре, әлбәттә, күтәрмәсләр. Ләкин болар аны туктатмады. Ул ныграк саклану чараларын гына күрде.

Күңелдәге тойгы үзалдына үсеп барганда, егет кинәт югалды. Нәгыймә аптырады, күңеленә төрле шикләр, кара уйлар утырды.

Ләкин ай үтмәде, күрше өйдә, үзенең кардәшләрендә, шул егет тагын күренде. Нәгыймә тагын чәчәкләнде.

Көннәрнең берендә, шул шатлыклы тойгылар ялкынында дулкынланып, абзардан атка печән күтәреп килә иде. Күршенең читәне шартлады. Егет атылып килде дә печәнен төшерде. Кулыннан тотып, күзенә карады, ашыгыч тавыш белән:

— Мин сине яратам... Тиздән башкода барыр. Оялма, риза дип чатнатып әйт,— диде.

Садыйк яшьтән үк ике сөйләргә яратмый иде. Әйткәнендә торды, икенче көнне үк үзенең әбисе Маһирә карчыкны эшнең җаен чамаларга җибәрде.

XII

Бу көннәр Нәгыймә өчен аның гомеренә килеп кергән матур бәхетле төшләр кебек тоелды.

Авылда бер карчык бар иде. Исеме Гөлҗиһан иде. Нәгыймә аның агачлар, үләннәр, чәчәкләр, матур кошлар турында сөйләвен ярата иде.

Көннәрнең берендә урманнан менә дигән кура җиләге белән чиләкләрен тутырып чыктылар да, ипләп, яфраклар салырга дип, урманның яланга караган читендә бер аланга, яшел чирәм өстенә утырдылар.

Тирә-як чәчәк белән тулы. Болар тәмле иселәр, үзләре апаклар. Киң канатлы ак, зәңгәр күбәләкләр, чәчәктән чәчәккә очынып, уйнашып йөриләр.

Карчык сөйләп китте:

— Дөньяда күп үсемлек бар. Һәммә нәрсәдә ярату бар,— ди.— Менә, ди, күбәләкләр чәчәкләрне яраталар, аларга барып иркәләнәләр,— ди.

Бу сүз Нәгыймәнең йөрәгенә кереп утырды. Аның яшь миендә күбәләкләр әти булып, чәчәкләр әни булып калдылар. Шуннан алып кайчан гына бер күбәләк күрсә, кайда гына күзе күбәләкнең чәчәккә кунганына төшсә, ул үзалдына уйлана торган булды. Һәммә нәрсәгә мәхәббәт орлыклары чәчелгән икән. Хәзер менә шуларның икесе очрашты да ялкын булып кабынды, ди. Шуның белән аның үз йөрәгендә дә ниндидер күңелле дулкын кузгала, хыялы, уянып, нәрсәдер эзли, нәрсәдер юксына башлый.

Күкрәгендәге ут дулкыны үзенә каршы килеп бәрелә торган икенче дулкын булмаганга, күңелендә ниндидер бер бушлык сизелә иде.

Туйның беренче көненнән Нәгыймәнең йөрәге ул югарыгы сорауларга җавап килгәнен сизде. Шуның белән бергә, ул үз гомеренең ниндидер матур әкиятләр, хыялый бәхетле төшләре башланган кебек, алсу иркәлекләр эченә чумды. Нәгыймә гомеренең икенче баскычына менә шулай керде.

XIII

Ләкин дошманнар Нәгыймәнең бу матур бәхетен көнләделәр. Кызның урам капкасын, бик зур итеп, эштән чыгарып, кара дегет белән буяп киттеләр.

Бөтен өйне дегет кебек кара бәхетсезлек каплады. Нәгыймә башын, йөрәген кая куярга, бу мәсхәрәдән дөньяның кай тишегенә кереп качарга белми, балалар кебек өзгәләнеп, бәргәләнеп елый иде. Садыйк моңа башта ук аз гына да борчылмады.

— Тиле, нигә ул чаклы исең китә? Авыл хулиганнарының этлеге өчен шулай елыйлармы? — дип, яшь кәләшне тынычландырырга тырышты.

Яшь кәләшнең бераз тынычланганын күргәч, Садыйк йортка — капкага чыкты. Капканы сүтте, баганаларын екты да эшкә

тотынды. Уңай җирен ышкылады, ышкы ала алмаган урынна-рын үткен балта белән кыеп төшерде. Ул арада кияү егете булып йөргән Фәхри белән Шәнгәрәй дә килеп җиттеләр. Бары бергә эшне бетереп, капканы элекке рәвешенә кайтарып утырттылар.

Садыйк алдан аңлатып куйган иде: «Мин завод кешесе, ике көн кияүләгәч, Нәгыймә белән калага китәрбез»,— дип килешкән иде.

Бу капка трагедиясе килеп чыккач, Нәгыймәнең анасы алай тиз җибәрергә якын килмәде:

— Баганадагы дегет бетсә дә, телләрдәге гайбәт алай тиз бетмәс... Бүген китеп барсагыз, кияү ачуланган, имеш, шуңа күрә калага сызган, имеш — менә шундый сүзләр белән дөнья тулыр... Дүрт көнсез җибәрмим,— диде.

Садыйк ике ут эчендә калды. Әгәр дүшәмбе көн кайтып җит-мәсә, тотарлар да башка берәүне кертерләр.

Икенче яктан мондагы хәлләр белән дә килешмичә мөмкин түгел.

Тагы дүрт көн шулай үтте.

Монда эш эзләп йөрүчеләр Садыйк турында хәбәр чыгар-ганнар:

— Миңлебаев хәзер анда кала икән. Ул шунда, авылда, иген чәчеп, тимерче булып торып кала икән!

Һәм шуның буенча дүшәмбе көн үк аның урынына кеше алганнар. Бу авыр кайгыны белгәч, Садыйкның өстенә су койган кебек булды: яңа өйләнде, бер тиен акча юк. Урыннан да ку-дылар. Садыйк үзенең хәлен башта Нәгыймәдән яшерде. Көн-нәрнең берендә исереп кайтты. Бу Нәгыймә өчен бөтенләй яңа әйбер иде. Кайгырырга да, еларга да белмәде. Садыйк чуалчык, исерек сүзләр белән үзенең кайгысын: менә ничә ай урынсыз, эшсез йөрүен, шуңа күрә яшь хатыны өчен бертөрле дә күңел ачарлык нәрсә кыла алмавын сөйләп ташлады.

Бу минутлар хатынның яшь йөрәгендә гомерлек эз калдыр-дылар. Ул шунда Садыйк белән үзе арасында тирән бер багла-ныш барлыгын бөтен җаны белән сизенде. Бәхетле, җиңел кузгалу белән сикереп торды да иренең күзенә көлеп карады.

— Кайгың шул гынамы?! Шуның өчен эчеп йөрисеңме? Ташла юкны! Ачка үлмәбез...

Берничә минутта яшь хатын Садыйкның маңгаендагы җыер-чыкларны таратты.

XIV

Ир-хатын булып торуларының өченче елында Садыйк тагын эшсез калды. Аны, заводтагы эш ташлауларда котыртучы дип, урыныннан чыгардылар. Байтак вакыт ни туры килсә шуны эшләп, кара хезмәтләргә тотынды. Алафузга кочегар булып керде.

Менә шул бер яктан икенче якка ташланулар чорында Садыйк эчәргә сабышты. Яңа кайгы килеп төште. Кочегар тагын урыныннан чыгарылды, сәбәбен үзе дә белә алмады.

Миңлебаев бу тирәдә юньле эш табудан өмет өзде.

— Бакуга китәм. Булмаса, Уралга борылырмын. Тапканымны җибәрермен,— диде.

Нәгыймә беренче мәртәбә зур шәһәрдә ялгызы калды.

XV

Ире эш эзләп Бакуга киткәч, беренче балалары үлде. Яшь хатын кибетче Сиражига барып, иренә хат яздырды: «Үзең кайт. Шул айда кайтып җитмәсәң, бөтен әйберләрне сатам да синең артыңнан китәм»,— диде.

Шул атнадан башлап хатын Садыйгыннан җавап көтә башлады. Шундый авыр, шикле, чуалчык уйлар эчендә ун көн үткәрде. Унберенче көндә болар һәммәсе дә берьюлы таралды:

Садыйктан кечкенә генә хат бар: «Сине бик сагындым, дигән. Баку шәһәрендә нефть борауларында бер түрәмен. Үзең минем янга кил»,— дигән. Җитмәсә тагын, юлга тугыз сум акча да җибәргән. Хатынның күңел түрендә нур уйнады. Йөрмәде, канатланып очынды. Ике көн эчендә әзерләнеп бетте.

Менә шулай сәфәргә аяк атлаган сәгатьтә тагын хат килеп төшмәсме! Укып бир дип, Сиражига йөгерде. Хәбәр күңелле түгел. Садыйк үзе җибәрмәгән.— Садыйк иптәш Миңлебаевны, дигән, Баку шәһәреннән сөреп җибәрделәр. Ул бүген этап белән Пермь губернасына озатылды,— дигән.

— Шулай гынамы? Башка юкмы?

Хатынның йөзендәге кайгы пәрдәсе алынды.

Садыйк бар. Аның Садыйгы бар. Садыйкның өлкән йөрәге бар. Нәгыймә, кечкенә кадерле бала кебек, шул зур йөрәкнең эченә берүзе, тик берүзе кереп, бөтәрләнеп яткан да, шуның иркә тирбәтүләрендә үзен рәхәт, бәхетле сизеп, гомер юлында ага бирә.

Ул Садыйкны ярата иде. Ир итеп ярата иде. Ләкин бу урыннан урынга куылуларны, коткы салып, эш ташлап йөрүләрне, сөргеннәрне Нәгыймә аңламый иде. Болар язмышның җибәргән бәхетсезлекләре булып күренәләр иде.

Революция дулкыны кайнап киткәч, хатын ул үткәннәрнең мәгънәсен берьюлы, бер сәгать эчендә аңлап алды. Менә хәзер кайнаган көчле пролетариат революциясе белән ул Миңлебаевларның элекке зинданнары, сөргеннәре, эш ташлаулары — һәммәсе бернәрсә, һәммәсе бер диңгезгә төшә торган ермаклар, бер агачны үстерәчәк тамырлар кебек күрде.

Хәзер ул үзенең мәхәббәтенә үзе шатлана. Кайбер вакыт газап булып күренгән ул ярату тойгылары аңа якты нур кебек булдылар.

Ире солдат киемендә арып, ватылып кайтты. Ләкин Казан аны исәпсез хезмәт белән каршы алды. Кайтып төшкән көне белән баштанаяк эшкә, көрәшкә чумды.

Нәгыймә күп уйланды. Ара-тирә йөрәге җилкенеп-җилкенеп куйды. Бу Фәхри эше белән ире килеп капкач, ул тагы әрнеде. «Менә бит, зинданга бардым — кертмәделәр. Конференциягә бардым — контроль җибәрмәде. Шәрәфигә барсаң — ул ячейкада, Василий Петровичка керсәң — ул конференциядә; Гайнетдиновны күрмәк булдым — ул көн-төн комклубта, конференциянең президиумында. Инде ни эшлисең? Кая сугыласың?»

Хатын бу төнне шулай үткәрде. Иртә торгач, ишек шакыдылар. Караса, энесе — гаскәри курсант Шәяхмәт икән.

— Мин, апай, сиңа бер генә минутка,— ди.— Теге үземнең чуваш комсомол белән сөйләштем. Ул әйтә: без, ди, Паларусовка каршы, ди. 14 кеше кул куеп, аның өстеннән Мәскәүгә бирдек, ди. «14»ләр әйтәләр, ди, ул кулак малае. Сатлык ул, дип әйтәләр икән. Бу «14»кә каршы көрәшә торган «24» нең дә документлары бик зәһәр, ди. Хәзер менә шулар талашалар...

Шәяхмәтнең туктар чамасы күренми иде. Нәгыймә энесен кычкырып бүлде:

— Сүз... сүз... Бер бетмәгән сүз! Берегезнең кулыннан да бер юньле эш килми икән! Юкка күкрәк киереп йөргән буласыз икән!

Нәгыймә утырып уйланды. Садыйк зинданда булган вакытта кул кушырып өйдә тик торырга аның йөрәге түзмәде. Исәбе прокурорның үзенә туры керү иде.

XVI

Тиле Әхмәт үз ирке белән диярлек килеп бирелде.

Кооператив тапшырган эшләреннән бушаган араларда, Җамали абзый: «Бусы сыралык булыр!» — дип, иске киемнәрне ямый, өр-яңа кебек иткәнче өтели дә сатарга алып чыга иде. Ә аның кодасы Камали да шул юлда бара иде. Ул да иске куныч

таба, табан сала, баш саба, үкчә утырта, крем белән каралта да базарга юнәлә.

Бу якшәмбе Җамали аеруча бәхетле булды. «Алып чыккан чалбарым бермә-бер табыш китерде. Тукта, Камалины эзләп табыйм... Берәрне төшерми кайтып булмас...»

Менә шулай уйланып китәргә борылган гына иде, җилкәсе белән берәүгә бәрелде. Аның киемендәге каптырмасы эләкте. Шуны ычкындырып азапланганда, бу каптырмалы казаки, ничектер, таныш кебек тоелды. Эчен, кесәләрен, кулбашын әйләндереп карады да үзалдына кистереп куйды: «Шул, шул!.. Бөтенләй шул!»

— Мин моны алам. Шунда көт. Барып кодамнан акча гына китерим,— дип вәгъдәләште дә базар эченә Камалины эзләргә кереп китте.

Теге адәм сүзендә торган, китмәгән икән. Тегүче, Камали килүгә, бишмәтне әйләндереп күрсәтә башлады:

— Менә кара. Бары да минем кул: туры утыртылган кесәне кара. Кулбашын кара. Мин моны кыл белән өч кат каеп утырттым.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Җамали кесәсеннән кечкенә пәке чыгарды да бишмәтнең күкрәгендәге, җиң очындагы кара тапларны кырып күрсәтте:

— Менә күрдеңме? Кан бит, кан! Инде сиздеңме эш кая бара? Вәли байга түгелме? Бу канлы киеме белән мин хәзер Вәли байның иманын укытам инде.

Җамали тиз генә милиционер алып килде. Милиционер боларның өчесен дә районга алып китте. Анда боларның җавапларын яздылар. Җамалиның уе ялгыш булмады: якын арада бу бишмәтне Вәли бай совхозда үз кул астында эшләүче Әхмигә дога кылдырган икән.

Җамалиның башы күккә тиде:

— Мондый зур эшне юмый ярамый. Әйдә, бер-икене бушатыйк, акча миннән,— диде.

Болар ишекне атлап өлгерә алмадылар, почмактан бер тавыш чакырды:

— Ә, сезме, Җамали абзый, Камали абзый, әйдәгез минем өстәлгә!

Карасалар, Сиражи икән. Ул нык исерек иде:

— Бу Паларусов дигәннәре,— ди,— начар чуваш, эт булып чыкты. Кемгә очраса, шуңа ташлана башлады,— ди.— Вәли байны тотып яптылар. Кичә кич Салахиевны фатирыннан алып

киткәннәр. Ивановны Паларусов туры таш капчыкка озаткан.

XVII

Вәли Хәсәнов кичкә каршы ялгызы шәһәрнең зур урамы буйлап китеп бара. Баштагы уйлар көннең, һаваның хәленнән дә күңелсезрәк. Тартып алынган миллионнарның яңадан кайтуының чамасы күренми. Авыр тойгылар эчендә басылып барганда, арттан куып җитеп, Иванов исәнләште. Бу аның күптәнге танышы иде. Хәзер җир оешмаларында җаваплы хезмәтче.

Вәли кайгылы елмаю белән аңа күңелен ачты:

— Дөньяда торырга рәт калмады. Ашарга да кирәк. Эшсез дә эч поша. Берәр урын табып бирер идең, Федор Кузьмич,— диде.

Иванов моның күзләренә бетеп карады:

— Бездә «Хезмәт» совхозын аякка бастырырга кеше эзлиләр. Иртәгә кил.

Шуның белән аерылыштылар. Вәли Хәсәнов «Хезмәт» совхозына башлык булып билгеләнде.

Мәрьям, «Хезмәт»кә барып, ирен карарга бер карчык эзли башлады.

Арада, әгәр сүз тыңласа, иң кулае, әлбәттә, Миңзифа әби иде. Ул килене белән бик начар да тора бугай. Бәлки, сүзне кире какмас.

Шулай уйлады да, үзе белән сөйләшеп кайтыйм дип, итекче Камалиның квартирына китте.

Сатулашу озак барды. Ахыр, чыдый алмады әби, җиңелде.

XIX

Зифа карчык «Хезмәт»кә килеп төште.

Көннәрнең берендә калын җилкәле, яңа итекле таза бер мужик килде. Бай, калын җилкәле крәстиян белән келәткә кереп, тазартылган орлыкны күрсәтте. Соңра:

— Син, Низами, мин кайтканны көт... Мин яланда эшләүче ялчылар янына гына барып киләм,— дип, иярле атка сикереп менде.

Зифа әби үзалдына куркып уйланды: «Бу Низами дигәне кем икән? Кайда гына күрдем соң мин бу калын җилкәне!»

Шул кич нәрсәгәдер талаш чыкты. Фәхри дигән бер мужик, Вәлине эт урынына сүгеп ыргытты:

— Син нәрсә монда,— ди,— әллә үзеңне алпавыт Алексей урынына килдем дип беләсеңме? Бик алай кылансаң, ничек очканыңны сизми дә калырсың! — ди. Сүзгә Гыймади да катнашты. Кычкырып, кул болгап әрләшеп китте.

XX—XXV

Миңзифа әбинең теңкәсенә тиеп бетте бит шул каһәр төшкерләре! Кайчан гына, кайда гына очрашмасыннар, хәзер этләр кебек үзара әләгешергә генә торалар. Трактор Шәяхмәт дигән малайның әйтерсең авызына иблис түкергән инде. Алла да юк, мулла да юк, оҗмах та юк, тәмуг та юк — бары да шып-шыр, тип-тигез дип әйтә икән, ди.

— Әртил,— дип,— коммун,— дип бер-ике сүз әйтүгә, шулай кызу талаш, кычкырыш ялкынлы ут кебек гөрләп тә китте.

Башыннан ахырына кадәр бу ызгышларны тыңлап торган Зифа әби бөтенләй шашты.

Әби кечкенә чакта ук теге Ситдыйкларның авылына баргалый иде. Шунда каяндыр бер дивана килеп чыкты. Аңа Әүлиясуфи дип исем бирделәр. Менә шул дивана, намаз вакыты җитте исә, өйдән-өйгә кереп, һәммә кешене мәчеткә куып йөри. Базар булса базарны тарата. Бервакыт өйлә җитте. Мәчеткә барыгыз дип Сабан туен таратты. Ул үзе ябык, кечкенә иде. Шулай да аңардан куркалар. Карулашмыйлар. Ул килгән чакларда халык мәчеткә сыймый иде...

Менә бу Фәхринең дә әллә кай җире шул диванага охшый кебек түгелме? Юк, юк... Охшый да, охшамый да. Бу — зур буйлы, каты каешланган куллы. Йөзендә, күзендә иман нуры юк. Әллә ничек батырып карый. Аягында итек, кулында гәҗит. Телендә җыен тузга язмаган сүз. Аллага каршы әйтә. Кире якка чакыра. Бер белгәне: имеш, әртил дә каммун, әртил дә каммун... Юк, тәүбә, әстәгъфирулла... Әүлия-суфига аз гына да охшамый... Теге — әүлия, бу — эт.

XXVI

Канлы бишмәт хәбәре «Хезмәт»кә дә басып керде. Зифа әби гомер буенча каннан, үлектән курка иде. Аның йөрәге бөтенләй урыныннан кузгалды: «Бу кан эчендә бер минут торырга да хәлем калмады...» — диде. Берничә минут эчендә барлык әйберләрен җыйнады, капчыкка тутырды, сыймаганнарын төйнәде дә йортка чыкты. Артына әйләнеп карамастан, яр буендагы тар сукмак белән «Байрак»ка таба йөгерде.

Теге канлы хәбәрне сөйләүче Рәгыя, бишмәт белән бергә, волком секретаре Шакир Рамазановның килгәнен әйтеп киткән диде. Карчык шуңа үзенең барлык гөнаһларын тизрәк ачып бирергә ашыкты. Ул ахылдап, шашып «Байрак» урамына барып кергәндә, Шакир, Фәхринең өенә таба китәргә әзерләнгән иде. Карчык бутап, саташып, ни булганын сөйләп бирде,

Аның сөйләгәннәреннән ачылган нәрсә шул булды: моннан бер атна гына элек һаман акчасызлыктан зарланып йөргән Әхми бу әбигә егерме сум акчасын сакларга биреп торган... Фәхри югаласы төнне Гыймади совхозда булмады, таң сызыла башлагач кына әллә кайдан арып кайтты, ди. Иртә белән су арбасының кендеген тапмадылар.

Шәнгәрәй карчыкның сүзен бүлеп сорады:

— Әби, соңгы атнада Әхми ни эшләп йөрде?

— Ни эшләсен, балам, иртә эчте, кич эчте, көн эчте, төн эчте...

— Акча кайдан ала иде?

— Ава-түнә килә дә әле теге кылый күз Гыймадидан, әле Вәли байдан акча сорый. Сүгәләр иде. Актыгы булыр! Яңадан сорама дип тиргәп чыгаралар иде. Икенче көн тагын сорый, тагын сүгәләр, тагын бирәләр.

Гайшә үзенең кечкенә бакчасында кайнаша иде. Улы пионер Самат:

— Әнкәй, кайт!.. Шакир абзый килде,— дип кычкыргач кына өенә кайтты.

XXVII

Гайшә самавыры, табасы тирәсендә маташа биреп, өстәлгә чәй әзерли-әзерли, каланы сөйли башлады. Садыйкны ябарга алып киткәч, крәстияннәр бик зур ризасызлык күрсәттеләр.

Җиһанша карт, атын җигеп, иске авылга — Акташка юнәлде. Анда егет чакларында эчеп, маңгай яру вакыйгасында катнашкан кешеләр әле дә исән икән әле. Бабай шуларның җидесен дә эзләп тапты.

Шул сәфәреннән кайтканда, керәшен картын очратты. Кайгырып сөйләште. Бу ялгыз каен төбендә күргәнен әйтте.

— Садыйк «Байрак»ка китте, мин Фәхрине совхозга илтеп калдырдым,— диде.

Бу бөтенләй яңа һәм бик кирәк сүз иде.

Болар өстенә малайлар да бик зур нәрсә ачып җибәрделәр. Алар Гыймади картның, як-ягына каранып, җирдә яткан тимер кендекне җиңенә тыгып киткәнен күрәләр.

Паларусовның яңадан чакыруы буенча, Гайшә ике пионерны, керәшен картын, маңгай ярасын белгән ике крәстиянне ияртте дә калага барып кайтты. Анда һәммәсеннән җавап алдылар.

Чәй бетте. Сүз икенчегә күчте, тагын әртилгә кайтты.

Бу эшне башлаучы Фәхри булган икән. Ул исән чагында әртилне коручылар югарыдан расланып үтелгән икән. Хәзер инде моны тартып алып китү Шәнгәрәйгә калган. Ул бу хакта сөйләп килде дә өзеп әйтте:

— Эштән курыкмыйм,— диде, тик, бер яктан, хатыны Рәгыянең коммунадан качып газаплануы, икенче яктан, белем җитмәве аяктан ега дип сөйләде.

Менә тиздән волкомның җыелышы була. Анда Шәнгәрәйнең «Язгы чәчү планының ничек үтәлүе» турында докладды бар. Бу аңа бик авыр йөк иде. Кайбер вакыт йокы арасында ул мәсьәлә күз алдына килеп, бөтен тынычлыгын ала иде.

Рамазанов сәгать буенча вакыт биреп, ачык директивалар калдырды.

XXVIII

Болар сүз белән мавыгып утырганда төньяктан, аяз күкнең бер читеннән нечкә генә бер ак болыт күтәрелде. Аңа икенчесе кушылды. Үзе артыннан кузгалган таркау болытларны тартып алды да, зур-зур ак мамык таулары кебек катлауланып, матур, зәңгәр күк йөзен каплый башлады.

Ап-ак матур болытлар күгелҗем-карага әйләнеп, җил белән Идел өстенә таба ишерелеп-ишерелеп актарылдылар. Тиз арада кояш әллә кая яшеренде. Дөнья өстендә уйнаган якты нурлар әйтерсең куркып качтылар. Җир, күк — һәммәсе югарыда җилләнеп, дулкынланып, тау-тау җимерелеп аккан болытлар белән караңгы төскә чумдылар. Каты тавышлар белән күк күкри башлады. Ялтыр-йолтыр яшен утлары уйнарга тотынды.

«Байрак» белән «Хезмәт» арасында, теге Яманкул чокырының югары башында, ташлы тау өстендә, ничә йөз еллар яшәгән тирән тамырлы, киң ботаклы, калын, каты яфраклы бик зур, юан карт имән агачы бар иде. Башка һәммә нәрсәне кырып барган балталар, пычкылар ялгызлыгы өчен дә, картлыгы өчен дә бу имәнгә кагылырга батырчылык итә алмыйлар иде. Ләкин яшен моны уйламады. Җирдән күтәрелгән көчле өермә Яманкул чокыры буйлап биек тауга ташланды. Ялгыз имәнгә уралып, аның тирәсендә дөнья чаклы тузан, туфрак болыты кузгалды. Шуңа каршы яман күк күкрәде. Идел өстендә көчле ялтыраган яшен

утлары карт агачның төбеннән башына таба уралып ярылдылар. Тау-таш җимерелгәндәй бәрелешү, коточкыч тавышлану һәм ялкынлану кайнашты. Табигать көчләренең шул утлы бәрелешләре эчендә моңарчы каты җилләрне уйнап кичерә торган тирән тамырлы бик карт имәнне бөтен тирә-як туфраклары белән суырып ыргытты. Зур агач, өлкән ботаклары, хисапсыз калын, озын тамырлары белән әйләнеп төшеп, Яманкул чокырының бер ярыннан икенче ярына кара көеп сузылып ятты. Әйтерсең шуның өчен генә монда кайнашканнар иде. Ялгыз карт имәнне егып салдылар да, күкрәүләр, җилләр, утлы яшеннәр киң Идел аша кисеп, Камага таба шаулап үттеләр. Монда давыл басылды. Күк йөзе тигез, тыныч куе болытлар белән капланды. Коеп-коеп яңгыр ява башлады. Яланнар, басулар, болыннар, таулар, урманнар, кырлар — һәммәсе, киң күкрәкләрен ачып, көчле яңгырның рәхәтенә чумдылар.

Идел буенда өч атнадан бирле яңгыр юк иде. Бөтен табигать сусаган иде. Игеннәр яңгыр сагынып саргайганнар; җир кипкән, тузанланган, урыны-урыны белән аркылы-буйлы яргаланган да иде. Яңгырсыз ач үлемле еллар тагын үзенең бөтен куркынычлары белән авылның йөрәген ала башлаган иде. Беренче ак болытны өмет белән каршыладылар.

Гайшәләр, Шәнгәрәйләр, Шакирлар да шул бөтен язмышы яңгырга бәйләнгән крәстияннең бер кисәге иделәр. Ләкин тәннең, йөрәкнең яңгырдан алган шатлыгы белән бергә, боларның миләрендә икенче бер уй күтәрелде: «Кайчан моңардан котылырбыз?.. Кайчан авыл яңа техникага күчә алыр?»

Яңгыр озак, тигез, рәхәт яуды. Китәргә мөмкин булмаудан Шәнгәрәй нык файдаланды. Үз эшләре турында Шакирдан баягылары өстенә тагын әллә ничаклы киңәш суырып чыгарды. Шакирның үзенә дип кичә генә каладан алдырган дәфтәре бар иде. Шуны бирде, һич иренмәстән:

— Менә бусы болай, бусы болай,— дип, дәфтәрне төрле әйбер язарга бүлгәләп, сызгалап күрсәтеп бирде. Нигез директивалар сөйләде.

Шәнгәрәйнең өстеннән авыр шөбһә төште. Бөтен эше тәртипкә кереп, үзеннән-үзе тәгәрәп киткән кебек булды. Эченнән: «Их, малай, мин әзрәк укыган булсам, әйләндерер идем дөньясын!» — дип уйлады.

Яңгыр туктады. Күк ачылды. Тагын ялтырап кояш чыкты. Әйтерсең дөнья яңадан туды. Маллар, адәмнәр, үләннәр, чәчәкләр — һәммәсе җанландылар.

Шакирга китәргә бик вакыт иде. Иң ахыргы сүз итеп шуны әйтте:

— Тирече Вәли алынды. Аның урынына совхозга безнең волбашкармадан Сафа Гыйльманов куелса кирәк. Сафа камыты, Шәнгәрәй, сиңа киелер... Шәнгәрәй урынына ячейка менә Гайшәне үткәрергә уйлый. Минем килүем сезнең икегез белән шул турыда сөйләшеп үтәр өчен иде,— диде.

Зифа әби калага кайтты. Паларусовның камерасына каушап барып керде. Озак, бик озак сөйләттеләр. Җавапларын язып бетергәч:

— Рәхмәт, әби, кайт инде... Тиздән хөкем булыр... Сүзләреңне онытма, шаһит булып барырсың,—диделәр.

Миңзифа әби камерадан чыгып китте. Шуннан туры кечкенә тыкрыклар буйлап үзләренә йөгерде. Җамали кычкырып каршы алды:

— Әй Зифа әби! Синең дә кайтыр көнең бар икән! — диде.

Чәй белән бергә сүз китте. Карчык үзенең анда үткәргән гомере эченә йөзеп кереп китте.

— Харап, харап анда! Кая карасаң — үлем, кая карасаң — кан...— диде. Гыймадиларны, Низамиларны, Фәхриләрне, Шәнгәрәйләрне сөйләде.

— Соң бит анда безнең Ситдыйк та барып тыгылган.

— Ул, әнкәй, болай тоташа. Шәнгәрәйнең хатыны Рәгыя бармы? Әнә шул Рәгыянең абзасы Әкбәр дигән крәстиян безнең Ситдыйкның сеңелесенә өйләнгән. Ситдыйкның кызы — Низаминың хатыны. Низаминың суга батып үлгән апасы белән Вәли байның Мәрьямбикәсе бик якын кодачалар.

— Йа Ходаем! Кайдан белеп беттең, Камали, син боларны?

XXX—XXXI

Кооперативтан әллә кайчан алган эшләр бар. Күп тә калмаган. Егерме бишмәткә җиң утыртасы да төймә тагасы.

Җамали, бүгеннән калдырмау исәбе белән, кызган баштан бик нык тотынды... Ишек шакылдады. Милиционер килеп керде: бер кәгазь бирде. Зәңгәр каләм тоттырды:

— Алдым,— дип кул куй!

Бу — Фәхринең үтерелүе турында булачак хөкемгә Җамалины шаһит ясап чакыру кәгазе иде.

Кемдер какмыйча ук ишекне ачып керде. Ишектә Вәли байның карчыгы Мәрьямбикә иде.

Йөгереп Сафура керде. Бу — ябыгып кипкән саргылт йөзле, куркак карашлы, тузган күлмәкле, иске кызыл яулыклы бер кызганыч хатын. Ике кул белән күреште.

Кунак карчык аягын бөкләп утырды да, акрынлап, сынап, сүз башлады.

— Менә абзагыз нахак тоткын булды бит!.. Менә әле абзагыз янына барган идем... Ул сорашып торды. Җамали туганның хәле ничек икән, ди. Эшең булса, башкага йөрмә. Үз кешебез — Җамалига гына бир; аның кебек оста да юк, аның кебек хыянәтсез кул да юк, ди... Үзен күрсәң, миннән күп сәлам әйт ди...

Җамали гадәтләнгән түбәнчелекле бичара тавыш белән көлде.

— Шулай диген, ә? Онытмаган икән, онытмаган икән, ә? Гаҗәп бит бу?

Карчык сүзендә дәвам итте:

— Ничек онытсын! Бергә гомер иткән, яхшылыгын, яманлыгын бергә кичергән, бергә аш-су күргән кешеләр онытыламыни?

Сафура чынаяк савытларын тезә башлады. Җамали карчыкка сүз кайтарды:

— Шулай шул! Бик башлы кеше иде шул. Ул миллионнарны җыярга кечкенә баш кирәкме? Аның салдырган мәчетләренең исәбенә чыга алмассың бит! Мине онытмаган икән үзе! Җамали туганның хәле ничек диме?

— Шулай ди. Кием тектерсәң, башкага бирмә, ди. Кунак карчык үзенең төенчеген актарды. Аннан бик зур иске калын шәл, нечкә астар, ярты кадак дөя йоны, дүрт төймә, бер тәгәрмәч җеп чыкты.

— Менә,— диде,— салкыннарда кияр өчен менә шуны тегеп бирер идең,— диде.

Чәй озак барды. Карчык бер елады, бер яман телләрне каргады. Күз яшьләрен сөртә-сөртә урыныннан кузгалды. Исәнләшеп чыгып китте.

Җамали бөтенләй изелеп, башын югалтып калды.

«Инде ни эшләргә? Ник тыгылдым мин моңа? Мине эт тә чакырмады бит! Җүләрләнеп үзем бардым... Канлы бишмәтне үзем таптым... Бу нигә кирәк иде? Беләм мин — Вәли эт ул! Ул иманыңны тартып алыр. Актык кабым икмәгеңне тартып алыр! Тегеләр соң, тегеләр фәрештәмени? Башым җитмәде. Катнашмаска, читтән карап торырга кирәк иде. Нигә генә тыгылдым?!.»

Аптыраган йөз белән Камали кода килеп керде.

— Ни бар? Ни бар?

Камали кул селекте:

— Миңа Сираҗи килде... Сез ике җүләр, ди, башыгызны үзегез кискәгә саласыз! Ни күзегез белән татар базарына күренерсез, ди.

Җамалиның йөзе агарынып катты. Күзләрендә тереклек туктады. Безнең сабын заводында кырык татар эшчесе, ди, кул куеп, кәгазь бирелер, ди. Укып күрсәтим, ди: «Без Садыйк Миңлебаев урынына башка бер иптәшнең сайлануын сорыйбыз. Садыйк үзенең элекке хулиганлыгына кайтты. Үчен кайтару исәбе белән, Фәхри кебек крәстиян коммунарларны үтереп йөри башлады...» Ә сез анда, эшчеләргә каршы барып, бандитларны яклап йөрисез.

Җамали белән Камали, кат-кат сөйләшеп, икәү тирән уйда, авыр кайгыда утырдылар.

Сәгать төнге икене сукты.

Камали урыныннан кузгалды:

— Башым әйләнде минем... Алла ни язган булса, шуны күрербез... Безнең эш харап!..— диде.

Шуның белән чыгып китте.

Җамали авыр төшләрдән ватылып уянды:

— Анасы,— диде,— мин каты авырыйм. Сорап килсәләр, шулай диген. Мин барыбер хөкемгә бара алмыйм.

Җамали куркудан шашкан бичара Сафураның бу мәшәкатьләренә күз салмады. Чөнки аның башы чуалчык кара саташулар, куркынычлар белән тулы иде.

XXXII

Сәгать ун. Зал шыгрым тулы. Сул бүлмәдән хөкем ияләре чыктылар. Залга гаепләнүчеләрне керттеләр.

Нәгыймә электән үк Әхми белән Гыймадины белә иде. Болар бүген аеруча кызганыч күренделәр. Болар артында ук торган Салахиев әйтерсең җинаяте тикшереләчәк гаепле кеше түгел. Кабарынып, башын югары күтәреп залга карый.

Залдагы эшчеләр, һөнәрчеләр, гаскәриләр башка һәркемнән бигрәк, менә шул Салахиев белән аның янында юаш кына торган Ивановка текәлделәр. Бу ике әле күптән түгел иптәшләр, ышанычлы кебек күренгән коммунистлар иде.

Җәмәгать эчендә Вәли байның улы студент-медик Мостафа да бар иде. Аның миендә күп куркыныч бар. Арада иң зуры шул университеттан куылу турында иде. Атасы эләгү хәбәрен ишетү белән иң элек шул курку килде.

Рәис секретарьга гаепләү актын укырга боерды. Мостафа өчен бу утлы бер документ булып тоелды.

— Нәрсә ди? Бу — ике кеше арасындагы ызгыш түгел, социализм белән капитализмның авыл хуҗалыгында көрәше! — ди.

XXXIII

Акт укылып бетүгә, рәис, ике як белән киңәшеп, тикшерүнең планын билгеләде. Хуҗалык, сәяси момент, үлем — менә шул тәртип буенча барырга булдылар. Бу өчнең беренчесеннән — «Хезмәт» совхозындагы хуҗалык белән бәйләнгән җинаятьләрдән башладылар. Вәли Хәсәнов сүзгә чакырылды.

Карт адвокат Арджанов рәиснең рөхсәте белән кирәкле материалларны тулырак ачарга сәбәп булырдай сөальләр бирә башлады:

— Сез,— диде,— әйтсәгез иде: «Хезмәт» совхозына барып эшли башлаганда, ничә дисәтинә иген чәчелгән иде, хәзер күпме? Сез барганда аяклы мал күпме иде, хәзер күпме?

Вәли Хәсәнов эченнән рәхәтләнде. Бу аның яраткан мәсьәләсе иде. Киң колачлап йөзде:

— Аяклы мал болай иде: бер корчаңгы бия, ике карт алаша, җәй көне дә ябагасын коймаган бер бетле тай. Кысыр калган дүрт сарык — менә барлык җан иясе шулар. Исерек кул белән чәчелгән, шундый тигезсез чыккан дүрт дисәтинә арыш аламасы ята. Билчән белән эт эчәгесе баскан җир ярым тары... Әйтер хәлем юк, Сәвит бик нык булышты. Үзем дә тәүлегенә унсигезәр сәгатьтән ким эшләмәдем. Хәзер совхозда аяклы мал йөз башка җитте. Болар эчендә җимертеп җигәрлек унике баш ат бар. Менә дигән холмогор үгезләр, яхшы нәсел, таза кан айгырлар бар. Мин башлап трактор китердем. Ел саен күршеләргә арзан хак белән тазартылган яхшы орлык өләштем. Дүрт ел эчендә һәммәсен торгыздым. Төзәттем. Буяттым.

Прокурор шаһитлардан Гайнетдиновның чакырылуын рәистән үтенде. Ул, профсоветта эшләгән чагында, «Хезмәт»тә ялчылар тормышын тикшергән иде.

Метранпаж[1] берничә әйбергә тукталды.

— Мин,— ди,— барып та төштем, туп-туры совхоз эшчеләренең торган җирләренә басып та кердем. Ашаганнары — чи арыш икмәге, чәйгә — кук сөт. Шикәр юк. Көндезге аш дигәннәре — эчәк, үпкә-бавыр турап, тары ярмасы сибеп кайнатылган бер куе су. «Хезмәт» дүрт ел эчендә байтак төзәлгән. Ләкин монда

[1] Метранпаж — типография эшчесе.

каш төзәтәм дип күз чыгарганнар. Мин үзем яшь чакта крәстиян булдым. Мондый әйберләрне нык аңлыйм. Вәли Хәсәнов, үзенең агентлары аркылы бармак йөртеп, бөтен байлыкны «Хезмәт»кә суырып яткан.

XXXIV—XXXVI

Садыйк соңгы көннәрдә үзенең яңа эше артыннан көн-төн чаба. Кайтып, ашыгыч ашый-эчә, шуннан ниндидер материаллар, цифрлар эзләнеп, бөтен әйберләрен астын өскә китерә дә рәтли алмый чыгып китә. Хатын бүлмә җыештырганда, ишек шакылдаттылар. Ире Садыйк кайткан. Үзе белән Василий Петровичны да алып килгән икән. Атлары урамда калды. Кочегар кучерга әйтте:

— Без хәзер чыгабыз. Шунда гына көт,— диде.

Нәгыймә, шаярып-көлеп, язу өстәлендәге гәзитләрне бер яккарак этәрде дә ак салфет җәйде. Кәрәзле бал белән ак күмәч куйды. Эссе чәйле ике чынаяк китерде дә үзе теге якка, балалар янына чыгып югалды.

Шул арада телефон шалтыраттылар. Парткомнан икән. Кочегар сөйләште, сүгешеп карады. Ләкин тегеннән кисеп әйттеләр:

— Парткомда сәгать алтыда Миңлебаевның докладны куела. Бу — бер. Аңарчы мәсьәлә парткомиссиядә каралып үтәргә тиеш. Планы, резолюциянең проекты әзер булсын. Парткомиссияне җыю Миңлебаевка йөкләтелә.

Садыйк, портфелен күтәреп чыгарга әзерләнгән хәлдә, хатынына кычкырды:

— Ашка мине көтмәссең. Мин вакытында кайта алмам,— диде.

Ләкин сүзен бетерә алмады, Нәгыймәнең йөзе бөтенләй бозылды, күзләренә әрнү чыкты:

— Бу ни эш инде бу? Хатын алып, мич буена утыртнансың да, үзең туктаусыз чабасың... Иртә юк, кич юк, рәхәтләнеп бергә ашау да юк... Өйгә бер аягың кайтып керми, икенче аягың чыгып китәргә генә карый! — диде.

Хатын эшләрнең һәрвакыт шулай тыгызланып, өелеп килүен белә иде. Шулай да бит — һаман эш тә эш! Нәгыймә монда өй саклап, балалар карап яши! Кая рәхәт! Кая гаилә тормышы белән яшәү?! Яшь гомер ялгыз үтә. Шулар сәбәбеннән кызып, ачуланып, кайбер чакларда ире белән каты-каты бәрелешләр дә булып ала. Ләкин бүген моңа җитә алмады. Кунакка ярым елмаеп, ишектән озатты.

XXXVII—XL

Шаһитлардан пешекче карчык Миңзифа әбине чакыртып керттеләр... Карчыкның сүзе бетте. Кочегар Садыйк Миңлебаев чакырылды. Салахиев аны үз эчендә утлы дулкын белән каршы алды.

Рәиснең:

— Бу эш турында белгәнегезне сөйләгез! — диюенә каршы, Садыйк акрын тавыш белән җавабын башлады.

— Фронт авызында,— диде,— алар икесе бергә безнең кулга килеп каптылар. Берсен шунда ук аттык. Икенчесе, крәстиян кебек киенеп, Колчак ягына качып котылды. Менә шунысы хәзер сезнең алдыгызда инде,— диде. Салахиев шаһитның җавапларын юньләп миенә сыйдыра алмады. Аның башы ут иде.

XLI

Фәхри үтерелү вакыйгасына бәйләнеп кочегар кулга алынгач, Салахиев эченнән шатланды. Ләкин тыштан кергән хәбәрләр аны бөтенләй аптыраттылар.

Большевик Хөсәен Ямашев исемендәге заводның элекке директоры авырып егылган. Чире каты, ди. Завод эштән чыгып бара. Партком секретаре кочегар Садыйкны үзенә чакырып алган да әйткән: «Иртәгә бюро җыелышында Ямаш заводы турында доклад бар. Яңа директор куелачак. Бу урынга секретариат сезнең кандидатураны тәкъдим итә»,— дигән. Миңлебаев, дулап, киреләнеп, талашып караган. Ләкин ахырында буйсынган. Большевик өчен булдыра алмый торган эш юк дип, аны директор итеп җиккәннәр. Хәзер ул менә шул батып бара торган корабны коткару юлында көн-төн туктамый көрәшеп, ут эчендә кайнап яши, ди.

Бу имеш-мимеш хәбәрләр тоткын Салахиевның миен алдан ук бик зәһәрләндерделәр.

XLII—XLVII

Хуҗалык белән сәяси момент кичте. Иртәдән үлем башланды.

Җавапка беренче чакырылган кеше Фәхринең хатыны Гайшә булды. Гайшәдән соң керәшен бабай кертелде. Аның артыннан пионер Сабит Тимеркәев дигән унике яшьлек малайны чакырттылар.

Рәис аның алдына шунда ук сөаль куйды:

— Кендек турында ни беләсең?

Малай ачык җавап бирде:

— Без пионерлар әтрәде белән яланга, трактор эшләгәнне карарга җыенып йөри идек. Шунда Гыймади бабай күренде... Як-ягына каранды да җирдә яткан бер кендекне алып җиң эченә тыкты. Аннан кайтып китте.

Кайбер вакыт ялгыз бүрене аучылар ераклап әйләндереп алалар. Качарга җай булмый.

Вәли Хәсәнов соңгы сәгатьләрдә үзен менә шул бүре хәлендә сизә башлады. Тимер кыршау кысканнан-кысты. Хөкем башындагы өметләр берәм-берәм югалдылар.

Мәйданга кендек чыкты.

Рәис Әхмидән түбән өстәлдәге кендекне күрсәтеп сорады:

— Шулмы?

Әхми, түгел дип, баш селекте:

— Миңа биргәннәре җепсез, кадаксыз иде,— диде.— Үтерергә уйлаганым да юк. Яманкулга барганым да юк... Куак артыннан чыгып, ике тапкыр селтәндем дә кендекне шунда ташлап качтым...

Аннан мари авылына барып, акча беткәнче эчү, типтерү... Аннан байның бүләге аксыл бишмәтне сатып эчү!..

Әхмидән шуннан артыкны ала алмадылар.

Рәис гаепләнүчеләрдән Гыймади картны сөальләр астына куйды:

— Гыймадетдин Бикмурзин, монда ничек ике кендек?

Картның торышы, төсе байтак кызганыч күренде. Аның болай да ябык, кечкенә гәүдәсе тагын да зәгыйфьләнә төшкән кебек булды. Сөальгә каршы бераз эндәшми торды да ачык, тулы җаваплар белән һәммәне хәйранга калдырды:

— Берсе — безнең совхозныкы, берсе — «Байрак»ның Җиһанша картныкы! Мин Әхмигә бар үтер, димәдем. Бераз өйрәтергә, бераз акылга утыртырга кирәк, дидем. Безнең «Хезмәт» белән «Байрак» арасында бер сукмак бар. Әхмигә әйттем: шул сукмак буенда, куак артында сагалап ятарсың, дидем. Кулына әнә шундагы җепсез, кадаксыз кендекне тоттырдым. Әхми китте дә югалды. Мин йоклый алмый яттым, исереклек белән берәр хәлгә очрамасын дип, ярты төн булгач эзләп чыктым... Барсам, ни күзем белән күрим: сукмак аркылы бер кеше сузылып ята; карыйм — Фәхри! Котым очты. Җан әсәре юк. Харап булдык, мин әйтәм. Эзне яшерергә тотындым. Иң элек Фәхринең канлы гәүдәсен Яманкул чокырына илтеп ташладым. Кан күп иде. Аны ипләп кырдым. Әхми кендеген куак астына ташлаган да күрше мари авылына китеп эчәргә тотынган.

— Алайса, Җиһанша бабайның кендеге ничек Яманкулга барып төшә?

Гыймади кендекнең тарихын сөйләп китте:

— Минем күз алдымда кәчәгәр Садыйк килеп, Җиһанша картның кендеген алды да итегендәге кадакларны төйгечләде. Эш беткәч, картка илтеп бирмәде. Мин кеше күрмәгән арада шул кендекне җиң эченә тыгып сыздым. Кулымны кисеп, Җиһаншаның кендеген канга буядым да Яманкул чокырына илтеп ташладым.

XLVIII

Алдагы урындыкларда Нәгыймә белән Гайшә тыгызланып сыенганнар. Аларның артыннан ук үзенең гаскәри курсант киемендә Шәяхмәт урынлашкан. Аның янында Шәнгәрәй утыра. Кесәсеннән блокнот белән каләм кисәге чыгарды да тезенә куеп язарга тотынды. Аннан шул кәгазьне алдагы кешегә сузды. Шәяхмәткә җибәрергә икәнен аңлатты. Кәгазь курсантка тапшырылды. Анда гарәп хәрефләре белән: «Бу эш су буе сузыла бит. Иртәгә минем язгы чәчү турында волкомда доклад була. Бүген пароходка өлгермәм дип котым оча. Син безгә Иделгә төшәргә автомобиль юнәтә алмассыңмы?» — дип язылган иде.

Шәяхмәт залдан чыгып сызды.

Түбән катта аерым бүлмәдә телефон бар. Егет шуңа керде дә бер-бер артлы төрле кешеләргә шалтыратырга тотынды. Үзәк башкармадан, машиналар буш түгел дип, бер сүз белән кырт кистеләр. Шәяхмәт сүгенде. Ышанмады. Берәрсе аркылы таптырырмын дип уйлады. Шул исәп белән Василий Петровичны сорады.

— Кичә Мәскәүгә, Үзәк Контроль Комиссия пленумына китте,— диделәр.

Паларусовны чакырып карады. Гайфуллинны эзләтте. Тапмадылар. Садыйк Миңлебаевка шалтыратты. Фабзавкомда, икътисади киңәшмә җыелышында, дип җавап бирделәр. Фабзавком телефонын сорап, анда шалтырата башлады. Бирми азапладылар. Аннан ялгыш тоташтырганнар... Курсант:

— Кара син, бюрократларны! Стена гәзитенә, әлбәттә, кадаклыйм үзләрен, бюрократлар! — дип сүгенде.

Хатыннар янына барып утыргач, апасы белән җиңгәсенә бөтен тарихны пыш-пыш сөйләп алды.

Мостафа бөтен бу вакыйганы баштан ахыргача карап утырды. Тукта, прокурорны тыңларга кирәк. Ул нәрсә сөйли?

— Монда кан белән сыйнфый сәясәт бергә укмаша, ди. Монда социализм белән капитализмның авыл хуҗалыгы эчендә көрәше бара, ди.

Мостафа бу үткен күзле, ташкын сүзле прокурорны электән үк күреп белә иде. Аның турында, рәхимсез адәм икән дип, байтак хикәяләр дә ишеткән иде. Әйтәләр: ул иске заманда үз тирәсе белән килешә алмыйчарак, сүгенебрәк йөргән, шул характеры аркасында ректор белән талашып, университеттан куылган студент-юрист имеш, диләр. Октябрь булгач, үзе теләп, кызыллар белән фронтка киткән. Шуннан бервакыт хәбәр итәләр: атаң зур сәяси эш белән Чекага эләкте, җинаяте өлкән, әгәр ышанычка алсаң, язмышы җиңеләюе мөмкин, диләр. Юк, ди, булдыра алмыйм, теләсәгез нишләгез, ди. Атасын аталар. Егет, элеккедән болайрак, акларга каршы сугышында дәвам итә.

Фронтта ничек булгандыр, белмим, ләкин бу эшләрдә агуы белән йөрәкләрне ашый. Башлар белән, язмышлар белән туп кебек уйный.

«Мин моны оныта алмам! Гомер булса, бер аның исенә төшерермен! Төшерермен дигәч төшерермен!» — дип зәһәрләнде.

Гаепләнүченең сүзе ахырга таба якынлашып килә иде инде. Ул җинаятьнең эчке катлауларын актарып чыгарды. Мондагы төп вакыйгаларның сәяси һәм икътисади контрреволюция нигезләре өстендә үскәнен ачты. Боларның тирән тамырларын тарихи, иҗтимагый туфраклар эченнән суырып чыгарып, залны каплаган эшче-крәстияннең алдына тезеп куйды.

XLIX—L

Көндезге ашка таралып, кичке алтыда яңадан хөкем ачылгач, гаепләнүчеләрнең актык сүзләре башланды.

Вәли Хәсәнов арыган акрын тавыш белән тирән борчылу астында сөйләде:

— Фәхри белән килешә алмадык, һаман талаштык. Шулай да аны үтерү дигән кара уй минем башыма ялгыш та кереп чыкмады. Аның каны хаталык белән түгелде. «Хезмәт»кә куелганнан алып, мин Советка ихлас күңел белән эшләдем... Тәкъдирдә ни язган булса, шуны күрербез,— диде.

Үз сүзләреннән күз яше бугазына килеп тыгылды. Тавыш өзелде.

Әхми бөтенләй кыска бетерде:

— Эчерделәр бит! Шул харап итте!.. Безгә якты көн калмый дип куркыттылар шул!.. Киң, кызыл кул яссуы белән йөзен каплады да кызганыч тавыш белән үкереп елап җибәрде.

Иванов озын сөйләде:

— Минем,— диде,— күземдә искедән калган бер пәрдә булган икән. Бу трагедия шул пәрдәне ертып ташларга ярдәм итте. Гафу да, мәрхәмәт тә сорамыйм — хөкемнең объектив карашына тапшырылам,— диде.

Аның артыннан сүз бирелгән Гыймади:

— Әгәр хөкемияләре, минем фәкыйрьлегемне, картлыгымны уйлап, берьюлга кичерсәләр, калган гомеремдә Сәвиткә дөрес күңел белән эшләргә ант эчәм! — диде.

Салахиев сикереп торды:

— Минем,— диде,— җинаятем юк! Булса, хатам гына бар: Фәхри белән Вәли Хәсәнов арасындагы көрәшне мин ике кешенең үзара ызгышы гына дип карадым.

Рәис, кыңгыравын шалтыратып, тикшерүләрнең тәмам булганын, хәзер хөкем коллегиясе киңәшкә керәчәген белдерде.

Залны каплаган җәмәгать, тыгызланып, бер-берен кысрыклап, коридорга, баскычка, урамга һава алырга, тәмәке тартырга агылды.

LI

Кич булды. Караңгы төште.

Мәрьямбикә иренең язмышын тыңларга дип, яңадан зур соры йортка килде.

Карчык килеп кергән минутта рәис тантаналы тавыш белән хөкемнең карарын укып тора иде.

Бикә утырган урынында агарынып катты. Мие, йөрәге гүя туктады. Мостафа куркуны онытты. Гаҗәп ачыклык белән, аның колагына түгел, йөрәгенә, рәиснең әйткәннәре берәм-берәм утлы ялкын кебек килеп бәрелә тордылар. Гыймади белән Әхмиләргә, Салахиев белән Ивановларга бирелгән өч ел — алты ел арасындагы зинданнарны бәхет санады. Үзенең атасына җиткәч, мие ни булачагын алдан ук әйтте.

Рәиснең:

— Иҗтимагый саклану чараларының иң югарысы! — дигән сүзе егетнең алдына язмыш булып, тәкъдир булып килеп басты.

Шул килеш хөкем тәмам булды. Залдан, берсен берсе таптап, җәмәгать чыга башлады.

Алдан ук хәзерләнгән планы буенча, карт адвокат Мәрьямбикә белән Мостафа алдында өмет яктысы ачты. Җитмеш ике сәгать эчендә карчык белән улы исеменнән Мәскәүгә, Үзәк Башкармага гафу сорап үтенеч җибәрде.

Аннан хөкем карарын раслап җавап алынды.

Башкалар зинданга урнаштылар.

Вәли Хәсәнов караңгы төндә урманга чыгарылып атылды. Үлекне шунда чокырга күмгәч, тау артыннан сызылып таң атты. Киң Идел өстендә, нуры белән дөньяны балкытып, якты кояш күтәрелде.

1926 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Әсәрендә Г. Ибраһимов ачкан темаларны әйтегез.

2. Галимҗан Ибраһимов иҗатын бәяләп, аның сәнгатьчә фикерләве белән фәнни фикерләве арасында каршылык бар, дидек. Сез санап чыккан темаларда шул каршылык чагыламы?

3. Тормышка бирелгән бәяләрнең төрлелегенә карап, әсәрне ике өлешкә калдырыгыз. Вак вакыйгаларны шул өлешләргә кертегез.

4. Галимҗан Ибраһимовның башка әсәрләрен исегезгә төшерегез. «Тирән тамырлар» романы әдипнең башка әсәрләре төзелешенә охшыймы?

5. Әсәрнең исемендә карт имән вакыйгасы күзаллана. Ә менә тирән тамырларның мәгънәләре башка вакыйгалар белән бәйләнештә ачыла. Әсәрендә авторның шул бәйләнешне күрсәткән урыннарны табыгыз.

6. Галимҗан Ибраһимовның башка әсәрләрендә вакыйгаларга автор бәясен табарга метафора ярдәм итә иде. «Тирән тамырлар» романындагы метафораны табыгыз һәм шуның ярдәмендә авторның әлеге ике вакыйгага биргән бәясе турында сөйләгез.

7. Романның фокусын табыгыз.

8. Әсәрдә Җамали, Камали, Зифа әби турында күп сөйләнә. Бу персонажларны кертү авторга нигә кирәк булган? Бу персонажлар белән бәйле вакыйгалар фокуска ничек бәйләнәләр?

9. Җамали, Камали, Зифа әбинең уртак сыйфатларын табыгыз. Бу сыйфатны әсәрнең темасы дияргә буламы?

10. Романда Нәгыймәгә аеруча күп урын бирелгән. Димәк, тирән тамырлар метафорасының бер мәгънәсе бу образда да ачыла ала. Нәгыймәнең шул бәйләнешләрен ачып инша языгыз. Аңа үзегезнең бәягезне бирегез. Сезнең бәя автор бәясеннән аерылырга да мөмкин. Роман җинаятьчеләргә хөкем чыгару белән бетә. Нәгыймә — Садыйк каршылыгы чишелми кала кебек. Романны үзегез дәвам итеп, бу каршылыкны ни рәвешле чишәр идегез? Иншагызда шуны да языгыз.

«Тирән тамырлар» романы. Анализ нәтиҗәләре

1. «Тирән тамырлар» исеме романда үзенә бер вакыйга булып кертелгән карт имән язмышына ишарә ясый. Роман исеме бу вакыйганы алыштырып килә һәм символга әйләнә.

2. Тирән тамырлар шул рәвешле Фәхрине үтерү вакыйгасына ялгана. Вәли байның җинаятен Галимҗан Ибраһимов контрреволюционерның табигый сәяси җинаяте итеп бәяли. Югары сыйныф кешеләренең ярлы халыкка дошманлыгын карт имәндәй гасырлар буена үсеп, тамырларын тирән җибәргән сыйфат итеп күрсәтә. «Тирән тамырлар» дип автор шул сыйфатны атый.

3. Галимҗан Ибраһимов революция җиңүе өчен бирелгән корбаннарны да «тирән тамырлар» дип атый. Фәхрине, аның әтисе Тимершаны, Җиһанша картның улларын, Садыйкның төрмәдән төрмәгә йөреп гомерен әрәм итүләрен дә шул корбаннарга кертә. Шулай итеп, миллионлаган корбаннар, сынган, өзелгән язмышлар революциянең «тирән тамырлар»ына әйләнәләр.

4. Тирән тамырлар дип әдип, элек сүгелгән, ә хәзер тәмам чәчәк аткан бюрократлыкны да атый. Романда җитәкчеләр, иң түбәннән алып иң югарысына кадәр, җыелыш, конференция, ячейка җыелышы, парткөн дип шашалар. Җитәкчеләр халыкның авыр тормышы турында кайгырту түгел, хәтта үзләренең иптәшләре язмышы белән дә кызыксынмыйлар, җыелышка ашыгалар, җыелышта көннәр, атналар буе утыралар. Галимҗан Ибраһимов хакимиятне бюрократлар дип ачыктан-ачык фаш итә. Яңа хакимиятне халыктан аерган нәрсә җыелыш булуын әйтә.

5. Җәмгыятьнең әдипне борчыган тагын бер чире — куркаклык, аумакайлык. Җамали, Камали, Зифа карчыклар куркаклыгын күрсәтүгә романда күп урын бирелгән. Шуңа күрә әсәрдәге метафора вакыйгасы, куркаклыкның тирән тамыры булып, бу вакыйганың да мәгънәсен ача.

6. Күрәсез, күңел күзе әдипнең намусына хыянәт итмәгән. «Тирән тамырлар» романының бер өлешендә байларның юньсезлеге исбат ителсә, икенчесендә коммунистларның кешелек сыйфатларын югалтулары тагын да дәлиллерәк итеп күрсәтелә.

Контроль эш өчен сораулар һәм биремнәр

1. «Алмачуар» хикәясенең темасын һәм идеясен әйтегез.

2. «Кызыл чәчәкләр» әсәренең темасын һәм идеясен әйтегез.

3. «Алмачуар» һәм «Кызыл чәчәкләр» әсәрләренең төзелешендә нинди охшашлык бар?

4. «Тирән тамырлар» романында күтәрелгән темаларны әйтегез.

5. Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә тема һәм идея уртаклыгы турында сөйләгез.

6. «Тирән тамырлар» романына анализ ясау тәртибен сөйләп (язып) күрсәтегез.

7. Садыйк персонажына автор бәясе нинди?

8. «Тирән тамырлар» романында бюрократизм темасы ничек күрсәтелә?

9. Тикшерүче Паларусовка бәя бирегез.

Өстәмә сораулар

10. Галимҗан Ибраһимовның язу стиле турында сөйләгез. Стиль дип нәрсәгә әйтәләр? Аңлатыгыз.

11. «Яңа кешеләр» пьесасындагы яңа кешеләр белән «Тирән тамырлар» романындагы яңа кешеләрне чагыштырыгыз. Уртак якларын табыгыз.

12. Романның сыйнфый көрәшкә багышланган өлешләре уңышсыз язылган, диләр. Шуны исбат итегез.

Гомәр Бәширов

(1901—1999)

Гомәр Бәширов Бәшир улы 1901 елның гыйнварында элекке Казан губернасы Арча волосте Яңасала авылында туган. Ул да, башка малайлар кебек, башлангыч белемен мәдрәсәдә ала. Башлангыч сыйныфларда укытып та йөри. 1920 елда Кызыл Армиягә алына. Гражданнар сугышында катнаша.

Шул китүдән туган якларына тагын дүрт елдан соң гына әйләнеп кайта. Бер генә еллык милиция мәктәбен тәмамлый да милициядә хезмәт итә, халык тикшерүчесе, халык судьясы булып эшли. Казанга килеп укуын дәвам итә. Марксизм-ленинизм институтын тәмамлый. Төрле редакцияләрдә хәбәрче, җаваплы секретарь, редактор вазифаларын башкара.

Бу елларны газеталарда бик күп санлы мәкаләләр, очерклар язып бастырса да, «Соңгы сугышу» дип исемләнгән беренче китабы 1934 елда гына дөнья күрә. Гомәр Бәшировны язучы итеп таныткан әсәре — 1937 елда басылган «Сиваш» повесте. Соңрак әдип «Намус», «Җидегән чишмә» романнарын, «Туган ягым — яшел бишек» исемле повестен иҗат итә. «Намус» романы өчен аңа Сталин премиясе бирелә.

Гомәр Бәширов халык иҗаты әсәрләрен җыеп бастыруга да күп көч куя. Аның «Йөз дә бер мәзәк», «Мең дә бер мәзәк» исемле мәзәкләр җыентыклары татар һәм рус телләрендә күп мәртәбә басылып чыкты.

Әдип күп еллар буе Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе вазифасын башкарды. РСФСР Верховный Советы депутаты булып сайланды.

СИВАШ

(Повесть)

I

Шәмси, күзләрен угалап, як-ягына карады. Ул юлдан читтәрәк тирән бер ызанга кереп ауган иде. Һе! Шәп, бик шәп! Соң шунда махночылар күрсә, йә акларның разведкасына юлыкса?!

Хәер, монда булмаса, кайда да булса алдарак барыбер егылмыйча түзә алмаган булыр иде. Аны санитарлар курсына җибәргәннәр иде. Ун көн укыганнан соң, кичә, курсны ябып, аларны үз полкларына кире озаттылар. Озатканда аңа полкны, Сивашка таба чыгып китте, дип әйткәннәр, юлын да өйрәткәннәр иде. Шәмси әллә илле чакрым, әллә артык та куды. Полк дигәнең юк та юк. Инде тәмам эштән чыгып арыганнан соң, аяклары бөтенләй атламый ук башлагач, ул шушы ызанда ял итмәкче булган иде.

Өзелеп-өзелеп ашыйсы килә иде. Капчык почмагында аз гына икмәк валчыгы калган икән, аны, бер бөртеген дә калдырмыйча, учына аударды да чәйнәргә тотынды.

Ул туңудан бөгелмәс булган салкын бармаклары белән сүтелә башлаган обмоткасын яңадан урады, ямьшәйгән, кояшта төсе уңган яшел фуражкасын төзәтте, пряжкасы аркага таба борылган брезент каешын рәтләде дә, капчыгын аркасына чөеп, йөгерәатлый юлга чыкты.

Алда һаман авыл-фәлән юк. Тирә-як һаман шул шәп-шәрә дала. Кибеп корышкан кылган, тузанлы соры юл. Шушы Врангель фронтына килгәннән соң, Шәмсиләр Тавриянең бу очсызкырыйсыз тигез басуларын ничә тапкыр гына узмадылар! Тәүлегенә алтмышар-җитмешәр чакрым, һаман җәяү дә җәяү. Барып кына җитәләр — тагын чыгып китәргә.

Шулай да бар иде бу кырларның соклангыч чаклары! Бер ягында — үз авырлыгына үзе сыгылып торган табак хәтле көнбагыш башлары. Икенче ягында — карбыз басуы. Кайчагында шул көнбагышлар арасыннан көнбагыш сабагына охшаган нечкә билле, Таврия күге төсле зәңгәр күзле украинкалар елмаеп кала торган иде... Зәңгәр күзләре, ничектер, уңа барды, үзгәрде, хәзер инде Шәмсигә әллә кайдан, бик ерактан моңаеп, кара кашлы зур коңгырт күзләр кыюсыз гына карап тора иде. Егетнең йөрәге сулкылдап куйды, бер үк вакытта бик моңсу да, рәхәт тә булып китте. Оялып башын игән килеш кайнар кулларын сузган иде бит. Аннары колак төбендә чулпылары чылтырап китте, битенә

кайнар сулышы бәрелеп калды, пышылдап әйткән сүзләре ишетелде: «Мине дисәң, мине сөйсәң, үзәгемне өзмә, хатлар яз!..»

Егет үзеннән-үзе дәртләнеп, кызурак атлый башлады. Әйтерсең аны озаткан кичтәге шикелле зарыгып Нәсимәсе көтеп тора. Шәмси, бара торган көенә башын чайкый-чайкый, күңеленә килгән җырны көйләп җибәрде:

Йөгереп китәрдәй булам,
Кайтып җитәрдәй булам,
Кичке салкын җилләрдә
Туган-үскән илләргә шул,
Туган-үскән илләргә.

Их! Ничек итептер менә күз ачып йомган арада авылга кайтырга иде. Шунда ничектер үзеннән-үзе анасы күз алдына килде. Арча станциясендә, Шәмсине озаткандагыча...

Әни, әни!.. Ул бит Шәмсинең атасын да әнә шул ук станциядән, шулай ук елый-елый герман сугышына озатып калган. Озатуын озаткан, әмма каршы алырга туры килмәгән... Ана күңеле ниләр генә кичермәгәндер?! Һай, әни, әни! Ичмаса, берәр җылы сүз әйттеме ул аңа, юаттымы, ичмаса!

Шунда ул ботинка олтанының шапылдавына гаҗәпсенеп, бөкрәеп карарга мәҗбүр булды: олтанны беркетеп бәйләгән телефон чыбыгы, күп йөри торгач, өзелгән икән дә олтан бөтенләй төшеп кала язган...

Аннары ямаулы тезләренә күз төште, шинеленең терсәгендәге тишеккә бармагын тыгып карады, авыр сулап, ботинка олтанын бәйләргә тотынды.

Кайту дигәннән, политрук Исмаев әнә нәрсә ди бит:

— Сугыш бик туйдырды инде, туганнар, ай-һай туйдырды. Никадәр халыкның башына җитте, илне бөлдерде, халыкны ачьялангач калдырды. Врангель — афәт, Врангель — сугыш ул. Врангельне бетерсәк, бу инде сугыш бөтенләй бетте дигән сүз була. Сугыш беттеме, тыныч көннәр башланачак.

II

Аны бик шәп чабып килүче пар ат җигелгән тачанка куып җитте. Аңа исеме белән дәштеләр:

— Әй Гайфуллин!

Борылып караса, пулеметчы Митричев белән взвод командиры Гриша Данилов икән. Шәмсинең авызы ерылып китте:

— Һа! Менә бәхет! Ничек болай? Сез кайдан?

Ат башына утырган Митричев, ярсып җиткән атларны көчхәл белән тыя төшеп:

— Тиз бул! — дип кычкырды. Күп шапылдап торсаң, җәяү генә барырсың!..

Шәмсинең сикереп менүе булды, атлар тагын элеп алып чаба башладылар.

Данилов, артка таба каратып утырткан пулеметның шәрә көпшәсе аша Шәмсигә иелеп, алгы якка ымлады:

— Полкны бик тиз куып җитәргә әйттеләр. «Максим»ны төзәттереп алдык, менә кияү егетен туйга өлгертергә дип чабабыз.

Шәмси әле дә хәтерли: Данилов аларның ротасына беренче тапкыр килеп күренгәндә аның өстендә һәйбәт күн пинжәк, башында кара күн фуражка иде. Хәзер исә аның ул киемнәре тузып беткән, башкаларныкы кебек үк, аның аягында да чүпрәк обмоткалы иске ботинка, өстендә гади соры шинель иде.

Шәмси күреп тора: Даниловның тартасы килә. Әмма ул бүтәннәр шикелле әрсез түгел. Шәмсидә үзе тартмаганлыктан тәмәке өзелмәсен белсә дә, ул бервакытта да үзе сорап алмый иде. Төптән юан чыккан базык гәүдәле, аю кебек алпан-тилпән атлап йөрүче бу кешенең сугыш вакытында каты куллы булып та, әнә шундый вакытларда әдәп саклаучан кешегә әверелүе Шәмсигә бик ошый.

Шәмси кулында бер пачка махорка күргәч, Даниловның йөзе берьюлы яктырып китте:

— О, менә байлык! Значит, көйрәтәбез?!

Ул тәмәкесен бик тәмләп суыра да туплар улаган якка карап бара. Аннары уйланып утыра-утыра да тагын суырып куя. Нигә болай авыр итеп уйлый икән командир?

Аларның монда кадәр дә сугышта булганы бар иде инде. Бер генә тапкыр да түгел. Алар полкының да канга батканчы, ярты сугышчысы кырылып беткәнче сугышкан чаклары булгалады. Әмма бу сугыш тагын да рәхимсезрәк буласы, диләр. Врангельнең барлык офицер полклары ач бүре шикелле ташланачак, аның йөзләрчә туплары, меңнәрчә пулеметлары берьюлы үкерә башлаячак. Ә безнең монда патроннар да саегып бара, пулеметлар да бик аз. Авыр артиллерия Таганрогта ук тоткарланып калган.

Шулар турында уйланамы икән әллә командир?

Митричев, чабыш ат өстендәге сыман, бөтен гәүдәсе белән алга йөгенгән, аның шинель итәкләре, зур кош канатлары сыман, чабулары белән лып-лып бәрә...

Митричев, бу полкка килгәнче, Будённыйның атлы армиясендә хезмәт иткән, диләр. Озын колактан ишетелә: Митричев анда чабыш аты белән акларның штабы янына ук барып чыккан да граната белән бөтенесен җимерткәч, аз гына үзе дә әләкми калган. Аның бу башсызлыгы аркасында ниндидер сугыш сере ачыла язган, имеш. Атлы гаскәрне оныта алмавын Митричев үзе дә яшерми иде.

Шәмсине бу егетнең чаялыгы белән батырлыгы кызыктыра иде. Аның фуражка астыннан бөселеп чыгып торган кара бөдрәләре үк: «Мин — мин инде ул, сез түгел!..» дигән сыман, масаеп торалар бит.

III

Юлны иңләп агылган соры шинель, яшел фуражкалар өстендә штыклар урманы чайкала. Сугышчылар, арып башларын игән хәлдә, аякларын көч-хәл белән атлыйлар.

Ротаның алдыннан баручы биек соргылт папахалы таза гәүдәле командир турысына килеп җитүгә, Митричев атларны туктатты. Рота командиры Пахомов боларның сәламенә җавап бирде дә иң элек пулеметны килеп карады. Ул арада полкның башыннан, ротадан ротага күчә-күчә, команда ишетелде:

— Привал![1]

Команда тавышы тынып та өлгермәде, колоннаны әйтерсең көчле җил бәреп аударды. Роталар, сөрлегеп, юл кырыена егыла бардылар.

Шәмси белән Данилов үз взводлары туктаган урынга барып утырдылар. Данилов йокымсырап яткан дусты Миша Борисовны күреп алды. Тегесе баш астына китаплар, газеталар тутырган брезент сумкасын салган, куеныннан тагын бер китапның почмагы күренеп тора. Монысы үзе укый торган китабыдыр инде. Аз гына буш вакыт булдымы — ул үз янына бер төркем сугышчыларны җыеп ала да йә китап, йә газета укырга тотына. Данилов белән алар бик дус иде. Ул аңа яратып, якын итеп карап торды. Ягымлы егет, матур да. Озынча ак битле, мыек та әле яңа гына чыгарга җыена, иреннәре дә бик юка гына.

Шәмси эзләнеп як-ягына карады. Ул юк арада взвод шактый кечерәеп калган. Иксез-чиксез походларда сугышчыларның өс-башлары, аяк киемнәре таланып беткән. Мондагылар арасында Шәмсинең иң якын, иң яраткан бер дус кешесе күренми иде.

---

[1] Привал — гаскәрнең юлда туктап ял итеп алу вакытлары.

Борисовка аркасын терәп яткан шинельле кинәт калыкты да, түгәрәк коңгырт сакалы, тынычсыз шаян күзләре, таушалган озынча бите белән болайга таба борылып, Шәмсигә кулын сузды.

— Ә, син бит бу, якташ! Ничек болай истә-оста югында? Син бит доктор булып кайтасы кеше идең. Ничек алай бик тиз?!

Шәмси шушы барлы-юклы ике атна эчендә дә иптәшләрен чын-чыннан сагынуын хәзер бигрәк тә ачык сизде. Әхмәдине ротадан киткән көнне үк юксына башлавын исенә төшереп, хәзер аннан күзен алмыйча карап утыра иде. Чөнки, бердән, алар икесе дә Татарстан кешеләре, шуның өстенә, Шәмси әле яз көне генә алынган яшь сугышчы булганлыктан, кыен чакларда тәҗрибәле олы кеше итеп Вәлитовка сыена торган иде. Шәмсине ул чая телле, кыю холыклы булуы белән дә үзенә тарта иде. Чыннан да, аның кыяфәте дә, тавышы да шулайга охшый. Менә хәзер җилтерәп торыр да, һәммәсен кузгатып, сүгеп ташлар шикелле. Озын буй, таза гәүдә, озынча матур бит, әрсез коңгырт сакал, шуның төсле үк калын мыек, тынгысыз үткен күзләр — менә шундый иде Әхмәди.

Тик Шәмси озакламыйча бу очрашу куанычы берүзе генә түгел, аның янында ук күңелсезлекләр дә көтеп торуын сизә башлады. Әхмәди абыйсы бик үк таза түгел икән. Аның өстенә шинеле тузган, юка, җәйге гимнастеркасы телгәләнеп беткән. Әхмәди үзе бик ябыккан, каралып, ничектер, бөрешеп калган, йөткергәли дә башлаган.

Вәлитов бераз арттарак туктаган поход кухнясына күз салды:

— Мм. Азык китермәгәннәр. Бер генә кадак булса да тамак ялгарга ярап куя торган иде...

Шәмси үзе дә кичәге көн өчен алган икмәген кичә үк ашап бетергән иде. Нишләргә соң? Капшана торгач, ул Әхмәди абзасына капчык төбендә кысылып калган бер шакмак шикәр сузды.

— Онытып та торам икән. Миннән күчтәнәч тиешле. Тик бар булганы шул гына, мә, суыр шушы тәмле шакмакны!

— Рәхмәт, энекәш...— Әхмәди, шикәрне суырып, балалар сыман иреннәрен ялмагач, телен чартлатып куйды.— Эх, булса иде шушында бер табак кайнар бәрәңге! Галимә апаң көн саен ярмаланып торган сары бәрәңге пешерә торган иде. Өстеннән буы бөркелеп тора, бармакларыңны пешерә-пешерә, учыңда сикертә-сикертә аласың... Ашъяулыкта күкрәккә терәп, калын итеп кискән арыш әпәе. Эх, әпәй, әпәй. Әпәй белән бәрәңге! «Пух» иткәнче ашап чыгасың да эшләп торып җибәрәсең, әй, якын-тирәдә бураннар гына уйный!..

Тачанкасы белән пулемётын обозда калдырып, болар янына Митричев та килеп җитте. Вәлитовның ышыгына кереп бөрешеп утырды да шинель җиңендәге тишектән бармагын чыгарып күрсәтте.

— Шинельгә тишек ябыша башлады. Киярлеге калмады. Нинди җылы торсын монда?

Ул арада болар янына рота командиры да килеп чыккан иде. Ул:

— Взвод командирлары! — дип кычкырды.— Полкны шунда туйдырырга приказ бар. Хәзер үк склад мөдиренә икмәк алырга җибәрегез!

Аннары ул боларның төркеме янынарак килде дә, шинеленең чабуын кире кайтарып, ызан буена килеп утырды.

Пахомов элек патша офицеры булган, имеш, дип сөйлиләр. Киң иреннәрендә элек бик хәтәр тәпи басып торган бөтерүле мыек булган да хәзер, аның урыны шәп-шәрә калгач, ул кимсенә кебек. Аны биек папахасы да башка командирлардан аерып тора.

Патша офицеры... Кем белә, бәлки аның, Шәмсиләр янындагы алпавытныкы шикелле, үз имениесе, юртак атлары булгандыр?..

Шәмсигә дә, бүтәннәргә дә командирның кайсы якларыдыр аңлашылмый, ул, ничектер, үзен бик салкын, бик коры тота. Шулай да соңгы вакытларда аның сагаеп кына булса да үзләренә якынаерга тырышуы барысына да ошый иде.

Башкалар кебек үк Әхмәдинең дә командирның телен ачып җибәрәсе килә иде.

— Кырымга ерак та калмадык бугай инде, иптәш командир, шулайдыр бит? — диде.

Пахомов алга таба кулын сузып күрсәтте:

— Перекопка барып җиткәнче бик каты бәрелешәсе бар әле. Бәлки, менә бүген үк, шушында ук... Сез Фрунзеның, акларга Кырымга чигенергә ирек бирмичә, Таврияда камап алып бетерергә дигән приказын ишеттегез бит? Без әнә шул приказны үтәргә җыенабыз инде. Аңлашылдымы?

Пахомов шуның белән эш беткәнгә санап, портсигарына сузылды. Ул солдат белән приказ телендә генә сөйләшергә күнеккән иде. Шул җитмәгәнмени?

Әйе, шул җиткән. Солдат белән солдатча сөйләшергә кирәк. Ләкин, як-ягындагы тынлыкның артык озакка сузылуына игътибар итеп, шунда ук күтәрелеп карады. Сугышчылар аннан тагын нидер көтәләр иде. Шулдыр, әлеге теге кызыл командир

дип йөртелгән яшь әтәчләр кебек, аның да такылдавын көтәләрдер. Иптәшләр, янәсе. Буржуйлар шундый да, буржуйлар мондый... Кызыл сугышчыга аңлы булырга кирәк, фәлән булырга кирәк... Юк инде, бик рәхмәт. Өндәү-димләүләр — политрук эше, ул шуның өчен паек ала, шуның өчен казна киемен туздыра. Хәер, бүтән эше дә юк. Сөйли бирсен...

Командир, нәрсәгәдер үзен дә бераз гаепле санагандай, сугышчыларына тагын да җентекләбрәк карый башлады. Күбесенең иреннәре күм-күк, үзләре бөрешкәннәр. Аларның бит кичәдән бирле бер сынык икмәк капканнары юк. Җылы өйдә йокламаганнарына шәт унбиш көн бардыр. Менә хәзер сугыш башланып китсә, ул бит боларны һөҗүмгә алып барачак, атакага, үлгәнче сугышырга! Ә аларның кичәдән бирле ашаганнары гына түгел... тәмәке тартканнары да юк!

Пахомов тәмәкесен ашыгып берәр генә суырды да, ничектер уйлап та тормыйча, үзеннән-үзе уң ягында тәмәке төпчегеннән күзен ала алмастан иреннәрен ялмаштырып утырган Митричевка сузды. Анысы берәр суыруга аңа күршесе сузылды. Тәмәке төпчеге түгәрәкне әйләнеп чыгарга да җитмәде, тартылып бетте.

Пахомов эчтән генә авыр сулап куйды:

— Алай... Кырым турында сорадыгыз бит әле?

— Әйе, иптәш командир.

Пахомов Борисовның мылтыгыннан штыгын алды да туфракка нидер сызарга тотынды.

— Монысы Украина, монысы Белоруссия. Моннан бер-ике ай гына элек безгә каршы Польша да сугыша иде бит әле. Менә! — Штык очы Польша ягыннан Советлар иленә таба озын бер ук китереп кертте. Шуннан соң аста бер дүртпочмак ясады.— Бусы Кырым булды.— Аннан Советлар җиренә таба тагын бер ук сузылды.— Монысы Врангель армиясе! — диде.— Ленин бу ике укны буржуйларның Советлар Россиясен буарга дип сузган ике кулы дип атаган иде... Монысын...— Польшадан кергән укны штык очы аркылы сызды.— Кызыл Армия кисеп ыргытты.— Ә монысы ничек?

Пахомов, үзенә үзе гаҗәпләнүенә каршы, сугышчыларына һаман якыная баруын, ике арада җылылык урнаша баруын хис итә башлады. Кинәт аңа бик рәхәт булып китте. «Ышаналар,— дип уйлады,— минем белән утка да, суга да керәчәкләр!»

— Врангель Кырымнан кырык мең гаскәр белән бәреп чыккан иде. Никадәр артиллерия, никадәр танк. Ләкин без аны Днепр буенда, хәтерлисезме, ничек изеп ташладык?

Митричев, рухланып китеп, приклады белән җиргә бәрде:

— Әй! Хәтерләмәгән кайда ул! Издек! Ярты гаскәрен кырып ташладык!

— Исән калган ярты гаскәре белән Врангель, хәзер без утырган җирләр аша Кырымга чигенеп, Перекоп артына посмакчы була. Без хәзер аның чигенү юлына аркылы төштек. Аңлашылдымы?

Йөзләре ачылып киткән сугышчылар, күңелләнеп, төрлесе төрле яктан тавыш бирделәр:

— Менә хәзер аңлашылды, иптәш командир.

— Төшендек!

Обоз ягыннан берничә бөтен икмәк күтәреп килүче Шәмси күренде. Икмәкне шунда ук бүлеп тә ташладылар.

— Ул да түгел, култык астына газеталар кыстырып яңадан политрук Исмаев калкып чыкты.

— Иптәш командирның болай төшендереп бирүе бик әйбәт булды әле,— диде.— Шуңарга өстәп мин сезгә дошманнарның үзләре язган хәбәрләрне укып карыйм әле...

Исмаевның Борисовка күзе төште. Политрук аны әңгәмәгә катнаштырасы килеп:

— Менә безнең Борисов ни әйтер тагын,— дип куйды.

— Минме?.. Мин сугышны тизрәк бетерү ягында.

Политрукның аны әңгәмәгә тартырга тырышуына кайбер сәбәпләр бар иде.

...Борисов, армиягә алынганчы, Тамбов губернасындагы шәһәрләрнең берсендә укытучы булып эшләгән. Монда килгәч тә ул, полк ялда вакытларда, кызылармеецларга рус теле һәм арифметика укытты: Вәлитов белән Шәмси дә русча укырга-язарга аннан өйрәнә башладылар. Ул иптәшләре өчен актык сынык икмәген дә урталай бүлеп бирә торган иркен күңелле, юаш бер егет иде.

Менә шул күңелле егетне моннан унбиш көннәр элек, кара болыт төсле булып, зур бер кайгы килеп басты.

Авылда кунган бер төнне Исмаев аны үз янына чакырды.

— Кулдан килә торган икән — булышырбыз, әйтергә яраса, безгә белдерүең яхшы булыр,— диде.

Борисов аңа, кайгысын уртаклашырга хәзер торуы өчен, рәхмәт әйтте.

— Минем,— диде,— атам-анам да, туганнарым да юк. Мине якын иткән бер генә кеше бар иде...

Аннан соң ул үз теле белән берни дә әйтмәде, политрукка шаян елмайган бер кыз рәсемен һәм хат чыгарып бирде. Ул хатта аны язган кулның калтыравы күренә иде.

«Миша! Бу хатны язарга кулым бармыйча озак икеләнеп йөрдем. Бу хәлне язып, синең күңелеңне җәрәхәтләргә вөҗданым җитмәде. Хәлем бик аяныч, Миша. Мине дошманнар мыскыл иттеләр.

Миша! Оныт мине. Саф күңелеңне моның белән таплама».

— Хәзер ничек соң?

— Больницада, сәламәтләнүенә өмет аз,— дип язалар.

Политрук уйланып утырды:

— Бәлки, сиңа кайтып килергә кирәктер? Күрерсең, сөйләшерсең...

Командир, гәпне дәвам иттергәндәй:

— Шулай да, Борисов, кайтып килсәң ничек булыр икән, ә? Белмәссең, бәлки инде тазарып та килә торгандыр. Яшь кеше бит ул!

Борисовның күңеленә беренче тапкыр өмет чаткысы керде.

Әңгәмә бетеп тә өлгермәде, юл уртасыннан тиз-тиз атлап болайга таба килүче берничә командир күренде. Мәһабәт һәм матур гәүдәлесе килде дә:

— Командир! — дип кычкырып җибәрде.

Пахомов җәһәт кенә сикереп торып, кулын папахасы турысына менгереп алды:

— Тыңлыйм, иптәш комбат!

— Хәзерләнегез, кузгалабыз! Безнең өскә Кырымга таба чигенеп баручы ике полк ябырыла. Синең пулеметың берәү генә бит. Тиз бул, гранаталар алырга кеше җибәр. Озакламый атакага күтәрелергә туры килмәгәе.

Тагын бер минуттан бөтен полк аякка баскан, атлый-йөгерә алга таба ашыга иде.

IV

Бер сәгать тә, сәгать ярым да узып китте, полк шулай кызулап баруында дәвам итте. Әмма арулары җиткән иде инде.

Хәлсезрәкләр, аягы бозылганнар яисә картрак сугышчылар арткарак кала башладылар.

Үргә менеп җитүгә, алда бер авыл күренә башлады. Миша Борисов барысыннан да артыграк арыган иде. Ул, Шәмсинең иңбашына таяна төшеп, аякларын көч-хәл белән генә сөйри. Авылны күргәч, салынган башын беренче тапкыр күтәреп, елмаеп карады:

— Уф! Авыл! Мин дә егылып калмыйча барып җитәм бугай.

Әхмәдинең дә хәле җиңелдән түгел иде. Аның аяклары әллә нинди кодрәт белән генә атлыйлар.

Авылның уң ягындагы үр артыннан килеп чыккан ике-өч эскадрон чамасы атлының авылга таба чапканы күренде. Алар артыннан ук җәяүлеләр колоннасы калкып чыкты. Ике батальон, йөгерә-йөгерә, юлның ике ягына таралырга да өлгермәде, аклар үр өстеннән ата да башладылар. Рота, сирәк көнбагыш арасыннан посынгалап, алга үрмәли башлады. Атышның көчлесе, авыл белән аклар арасын өзәргә дип, туп-туры авыл читенә карап йөгергән шушы рота өстенә күчте. Әхмәди моңа бик борчылса да, яшьләргә сиздерәсе килмәде:

— Башыгызны саклагыз, фуражкагызга тиеп әрәм итмәсен! — дип сөйләнә-сөйләнә, Шәмси белән Борисов арасындагы ызанга кереп ятты.

Ул арада үрнең артыннан кинәт кенә акларның броневигы килеп чыкты. Батальон командиры яланбаш килеш тезмәгә таба йөгереп килде. Акларның болайга таба үрмәләүләре күзенә чалынды. Ул ярсулы чыелдык тавыш белән рота командирына кычкырды:

— Контратакага! Чигендерергә! Хәзер ук! Живо!

Пахомовның ротасы, үрмәләп аклар өстенә барганда, пулеметын сөйрәп Митричев та килеп чыкты.

Атакага килүчеләр, бер өскә калкып, бер аска посып, пулеметның мушкасы тирәсендә чайкалдылар. Митричев аларның сафларына, бер кырыйдан икенчесенә хәтле пуля сиптерергә тотынды.

Шәмсинең Митричевны сугыш эчендә болай якыннан күргәне юк иде әле: фуражкасының ертык козырегы артка борылып җилкәсенә терәлгән, җиргә таянган куллары пулемет аткан тибеш белән дерелдиләр, ботинкасының ертык табаныннан, песи борыны төсле кызарып, аяк бармагы карап тора. Ә ул ярсыганнан ярсый барып, үзенең шушы ярсуы һәм «башсызлыгы» белән сокландырып ата да ата иде.

Рота командиры Пахомов аклар ягына бер күз ташлау белән дошманның күп яктан өстен булуын шундук күреп алды. Күрше ротаның алдында батальон командирының кылыч айкаганы күренде. Вакыт!

Пахомов сикереп торды да маузерын болгап кычкырып җибәрде:

— Алга! Алга! Ура!

Кинәт бөтен дөнья тынып калды: ике як, штыкларын төбәп, берсен берсе чәнчергә җыенып, штык сугышына ташланды.

Борисов та, ярсып йөгерә торгач, бер-берсенә прикладлар белән бәрешкән соры төркем эченә атылып керде. Ул нашивкалы ике солдатның бер кызылармеец өстенә ташлануларын күрде дә солдатның берсен үзенә каратып чәкәләшергә тотынды. Тик ул як-ягына каранырга да өлгерми калды, погонлылар аның үзен камап алдылар.

Каршыдагы солдат кизәнүгә Борисовның фуражкасы атылып төште. Аның шинеле чишелеп китте, обмоткасы чуалды. Ярсудан, ачудан үзеннән-үзе җиңеләеп, бер солдатка кадады да артка сикерде.

— Мә, паразит!

Тик Борисов шул минутта ук күкрәгендә кинәт бер ачы сызлау сизде: ачумы, сыкраумы билгесе булып аның чырае сытылды. Ул да түгел аның йөрәге «жу» итеп китте. Әгәр «ул» ертылган булса? Штык аны да тишеп чыкса?! Аның күкрәгендәге кесәсен, ул кесәдәге кечкенә рәсемне капшап карыйсы килде. Бармагына сөеклесенең йөрәк җылысы тияр, күз карашларыннан бөркелеп торган мәхәббәт ялкыны сизелер кебек иде. Шунда кинәт аның өзелеп-өзелеп яшисе килеп китте.

Караңгы күптән төшкән иде инде. Атыш гөрелтесе дә, һаман ерагая барып, тора-бара бөтенләй тынды.

Акларның атлысы һәм җәяүлесе, Кырымга таба чигенү юлларына аркылы төшкән бу полкны көч-хәл белән ерып, юл өстендәге авылларны яндыра-җимерә Перекопка ташланды.

Даниловның взводы, дөресрәге, взводның исән калган сугышчылары, гәүдәләрен көч-хәл белән сөйрәп, авыл буендагы салам кибәннәре төбенә килеп егылдылар.

V

Караңгы кыр юлыннан тын гына бер төркем сугышчы атлый. Иң алда рота командиры Пахомов белән Исмаев арасында, юан таякка таянган калын гәүдәле бер карт бара. Карт йомшак украин телендә акрын гына сөйләп китте:

— Мин үзем Сиваш буенда туган кеше. Сивашны безнең тирәдә «каһәр төшкән сазлык» диләр, йә «Черек диңгез» дип тә йөртәләр. Сивашның тозлы суы үләннең тамырын корыта, җан иясенең канын агулый.

Сугышчыларның, барыннан да бигрәк, Сивашны кичеп чыгу мөмкинлеген беләселәре килә иде.

— Сивашны диңгез култыгы, диләр. Ул бит Азов диңгезенә тоташкан. Диңгез ягыннан җил истеме, аңа су тула. Җил диңгез

ягына таба борылдымы, су кире чигенә. Ул чагында инде Сиваш кереп булмастай сазга әйләнә.

— Хәзер нәрсә соң әле ул: сазмы, диңгезме?

— Хәзергә саз әле. Әмма озаккамы, түгелме, анысын тагын да әйтеп булмый: диңгездән җил исә башладымы, ул берничә сәгать эчендә котырынган диңгез култыгына әйләнә.

Исмаев барысын да кызыксындырган бу зур мәсьәләне тизрәк ачыкландырырга ашыкты:

— Шулай да, Данило бабай, Сиваштан ничек чыгарга булыр икән соң?

Карт бераз вакытка тагын сүзсез калды. Дивизия штабында аннан Кырым ягына гаскәр белән чыгарлык юл эзләшүне үтенгәннәр иде. Карт моны ишеткәч үк сизеп алды. Әһә! Кызылларның Фрунзе дигән генералы Перекопның артына шыпырт кына бәреп чыгарга уйлый икән!

— Моңа хәтле беркемнең дә Сивашның сез әйткән урыныннан гаскәр белән чыкканы юк.

Көн тагын яктыра төште. Көнчыгыш ягы алсуланды. Бу вакытта әлеге төркем, сөзәк үрне узып, Сиваш иңкеленә таба төшә башлаган иде.

Данило карт кулы белән алга күрсәтте:

— Әнә Перекоп!

Политрук, бинокльдән бераз карап торганнан соң, кулын селтәде:

— Бер дә искитәрлек урыны юк икән. Шәһәр димәсәң, хәтере калыр, урта авылдан һич тә зур түгел,— диде.

Пахомов политрукның биноклен үзенә алды:

— Син алай ашыкма әле, диде.— Перекоп табигый яктан да бик җайлы урында. Аны чит ил инженерлары соңгы вакытта тагын да ныгыттылар. Чит ил сугыш белгечләре аны «ала алмаслык крепость» дип атыйлар. Монда бик күп кан коелуы мөмкин.

Карт, нидер әле генә исенә төшкәндәй, кабалана башлады:

— Ашыга төшик әле. Безгә тизрәк кичү табарга кирәк. Киттек, оланнар, барыйк.

Ул да түгел, аларның артларыннан үкереп килгән броневик белән җиңел автомобиль болардан ерак түгел бер урында туктап калды. Броневиктан өстенә гади солдат шинеле, башына соры папаха кигән калын коңгырт мыеклы бер командир килеп чыкты.

Пахомов кинәт үзгәреп китте:

— Беләсезме, иптәш Фрунзе бит бу! — дип пышылдады.

VI

Авылда көн буе хәзерләнделәр.

Дивизия штабы Сиваш яры өстендәге җимеш бакчасына, андагы балчык өйгә урнашты.

Авылга иртә таңнан башлап берсе артыннан берсе өзлексез төрле хәрби частьлар агылып торды. Поход кухнялары итле аш һәм карабодай боткасы пешерергә тотынды. Ун градус салкынга шакыраеп каткан арыш икмәген, бүкәнгә куеп, балта белән ваттылар. «Бу кемгә» не кычкырттылар. Шунда ук, аягүрә генә торып, өшегән икмәкне ашый да башладылар. Шулай ук итеп шикәр дә, яртышар пачка махорка да бүленде. Әле генә бирелгән җылы күлмәкләрне киделәр. Караңгыда төшеп-нитеп калмагае дип, ботинка олтаннарын телефон чыбыгы белән беркетеп куйдылар.

Сүз арасында кинәт кенә тынып калып:

— Андый-мондый булсам... нитәрсең инде, туган, өйдәгеләргә язарсың: шулай-шулай булды, фәлән урында җирләдек диярсең,— дип, бер-берсенә өй адресларын бирештеләр.

Шәмси тез башына куеп кына, карандашының очын тешли-тешли, Нәсимәсенә кечтеки генә хат язып ташлады:

«...Каз өмәсенә кайтып җитәрсең бәлки, дигәнсең икән дә, кайтып булмас, ахрысы, Нәсимә. Кырым безнеке булсын, аннары менә кайтсаң да оят булмас. Ә хәзергә — бигайбә. Икенче хатны, исән калсам, сугыштан соң язармын. Бүген таңда сугышка керергә торабыз. Бик, бик сагындым үзеңне. Көндезләрен күз алдымда, кичен төшкә керәсең. Ярый, җаныем, исән бул...»

Байтак кына вакыт, тәрәзәгә караган килеш, уйланып, Нәсимәсен күз алдына китереп утырды. Каз өмәседер... Кичен алар янына егетләр керер. Нәсимә янында бүтән егет утырыр... Шәмси авыр сулап куйды да иптәшләренә таба борылып утырды. Шаулашып, көлешеп алдылар. Көлешү, шау-шулар Әхмәдинең күңелен күтәреп җибәрделәр булса кирәк, нидер әйтәсе килүе күренә иде.

— Эх, егетләр! Сезнең урында булсам, беләсезме нишләр идем мин сугыш беткәч? Китәр идем укырга, командир булырга. Фәлән авылдан фәлән агайның улы, әйтик, дивизия командирына укып чыкса, ә? Яңа тормыш шуны сорый, энекәшләр. Күтәрелергә кирәк безгә. Һәммәсен дә үзебезнең кулга алырга!

Данилов идәндәге саламда кырын ята иде:

— Дөрес әйтәсең, туганкай,— диде.— Сугыш бетүгә, барыбызның да эш муеннан булачак. Ә мин сезнең һәммәгезне дә үзебезнең Донбасска чакырам.

Шәмси, сүзгә кушылып:

— Донбасс бик шәптер анысы, сүз дә юк,— диде.— Шулай да авылда да эш күп бит хәзер. Сугыш белән ачлык илне әнә ничек бөлдерде. Хәзер безгә бик күп итеп иген үстерергә, терлек үрчетергә кирәк...

Митричев боларның әңгәмәсенә сул кулын гына селтәде:

— Мескеннәр, бичаралар! — дип куйды.— Канатыгыз юк бит сезнең, ичмасам, хыяллана да белмисез, мүкәләп кенә яшисез бит сез. Сугыш беттеме, барам, Будённыйга да әйтәм: «Семен Михайлович! Ал мине кавалериягә! Бөтендөнья буржуйларына каршы җибәр, барам, йөз Махнога каршы берүземне җибәр, анда да курыкмыйм, барам!.. «Эх! Астыңда шыгыр-шыгыр иткән яхшы ияр, яныңда кылыч, билеңдә маузер...»

Данилов, нәкъ Митричев тавышы белән:

— Кесәң тулы борчак!..— дип өстәп җибәрүгә бөтен өй эче гөрләп көләргә тотынды...

Өйдә калганнар янына, кулына хат тотып, Данилов кайтып керде. Аңа төрле яктан куллар сузылды.

Әхмәдинең өеннән хат алмавына байтак вакыт булган иде. Ул озак йөрүдән читләре киселә башлаган соры конвертны кабаланып ачарга тотынды. Итәгенә ике саргылт кәгазь кисәге килеп төшүгә, ул аларны тирән дулкынлану белән кулына алды. Бу кәгазьләр матча ярыгына кыстырылып озак торганга шулай саргайганнар бит. Алардан аның өенең исе, аның үзенә генә билгеле бер якын ис килгән сыман. Таушалган бу саргылт кәгазьләр аңа хатыны Галимәсен, күптәннән бирле юньләп күрергә җай килмәгән олы кызын, ике бөртек кечкенәләрен, гөлчәчәкләрен, күз нурларын хәтерләтәләр...

Шәмсине йокысыннан уятып, хатны аңа тоттырды!

— Укы әле, энем, мә әле!

Шәмси, «Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү хәләл җефетемез Әхмәдигә...» дип башлап китте. «Янә шул да мәгълүм булсын үткән кече атна көн таң алдыннан баладан котылдым монысы малай булды инде Алла боерса бәхете-тәүфыйгы белән туган булсын. Нинди ат кушарга белми йөрдек-йөрдек тә куштык Илдус дип...»

Әхмәди урыныннан торды, тагын утырды:

— Значит малай? — Ул хатны Шәмси кулыннан тартып алды да, үз күзе белән күрергә теләгәндәй, бик җентекләп әйләндерә-әйләндерә карагач, кире бирде.— Мә, шул төшен тагын укып кара әле, тәгаен малаймы?

— Һа! Тәгаен малай, алайса, ә якташ? Менә сиңа мә, ә? Кая әле, төрик әле берне, йөрәк түзми! Бир әле!

Шəмсинең аны мондый хəлдə күргəне юк иде әле. Озак еллар сугышта йөреп каты куллыланган, кырысланган бу гаярь[1] кеше балаларны шулай өзелеп ярата торгандыр, йөрəгендə шундый нечкəлеклəр саклагандыр дип кем уйлаган?

Көйрəтеп җибəргəч, Əхмəди яңадан Шəмси янына тезлəнеп, тагын тыңларга тотынды.

— «...Сарык ике бəрəн китерде берсе саулык берсе тəкə инде бишəү булдык кашык саны ишəйде яңа җиткəнче ашарга бер подаука он бер капчык бəрəңге биргəннəрне халык өчен үзен кызганмаган кешегə бернəрсə дə җəл түгел дип бик сөендерделəр. Хəлəл җефетең Галимə дип белəсең».

— Бир, Шəмси туган! — Вəлитов сикереп торды да, кызу-кызу атлап, урамга чыгып китте. Бу шатлыкны ул үзенə генə сыйдырып кала алмады.

VII

Менə түземсезлек белəн көтелгəн кич тə якынлашты. Кояшның кызыл түгəрəге калку артына кереп юк булды. Сиваш өстен куе томан басты.

Меңнəрчə сугышчыларны эченə алган гаскəр берлəшмəлəре бер-бер артлы кузгала башладылар. Иң башта, озын һəм киң колонналарга тезелеп, тавышсыз-тынсыз, җəяүлелəр чыга башлады. Алар артыннан тачанкаларга көйлəнгəн пулеметлар, иң актыктан тупчылар кузгалды.

Пахомов ротаны тыгызлап дүртəр кешедəн тезде дə өзеп-өзеп кенə бер-ике сүз əйтте:

— Бер-береңнəн аерылмаска, артка калмаска! Тартырга ярамый!

Кузгалып киткəннəн соң, Шəмсинең тəне иң беренче булып сизгəн нəрсə — Сивашның юеш салкыны булды. Аяклар таеп киткəли, табанга салкын дым үтə иде.

Ара-тирə сагаеп кына, шыпыртлап кына сөйлəшкəлəп алалар, аннары нидер буласын көткəндəй, як-якка карангалыйлар. Монда ни дə булса булырга тиеш бит. Ул «нидер» менə шунда, шушы минутта, менə хəзер үк булырга мөмкин. Шулай да нəрсə ул?

Эчкəрəк киткəн саен, пычрак тирəнəя барды, аяклар бата башлады. Ботинкаларга авыр балчык сыланды, шинель итəклəре авыраеп, аяк арасында лыпырдап йөдəтте.

Үзенең артында кемнеңдер бик авыр сулавына пошынып, Шəмси борылып карады. Əхмəди абзасы икəн. Олы кешегə аз

[1] Гаярь — батыр.

булса да ярдәм итү өчен җае чыгуга күңеле булып Шәмси аның мылтыгына сузылды.

Әхмәди шыпыртлап:

— Сиңа авырга килер бит? — диде.

Шәмси Вәлитовның мылтыгын иңбашына асып, аның белән янәшә атлый башлады.

Әхмәдинең хәле, чыннан да, җиңел түгел иде. Аягының тәзәлеп бетмәгән ярасына Сиваш суы үттеме, бүтән берәр нәрсә булдымы, аягы яман ачыта башлаганлыктан, тешен кысып, үкчәсе белән генә атлый башлады.

Шулвакыт сул яктан елаганга охшаш бер тавыш ишетелде. Бу тавыш йөрәкләргә килеп бәрелде, аянычбулып ишетелде.

— Полк командирына хәбәр итәргә кирәк,— диде берсе.

— Анда барыбер кереп булмый бит.

— Әйтте бит командир: бер адым читкә атладың, беттең...

Сугышчылар, гаепле кеше сыман башларын иеп, аска карап кына атлыйлар. Кешенең бата башлавын белә торып аңа ярдәм кулыңны суза алмавың нинди гаҗизлек!

Комсыз Сивашка озакламыйча тагын бер корбан бирергә туры килде. Комбатның колоннага орыныр-орынмас барган аты, нидәндер өркеп, читкә тайпылды, ул да түгел аның аяклары кинәт сазга батты. Комбат атының башы аркылы егылып төште. Алаша бөтен көче белән тыпырчынды. Әмма аның саен төпкәрәк батты.

Бара торгач, юл буенда гына пычракка тезләнгән ялгыз бер кеше күренде. Ул телефонист булып чыкты. Ул узып баручы колоннага дәште:

— Иптәш командир! Рота командиры! Элемтә өзелде. Сивашның пычрагы кабельне ашый икән.— Үзенең телефон аппаратын ташлап китә алмавын әйтеп, шушыны белдерер өчен, дивизиягә бер кызылармеец җибәрүне үтенде.

Данилов, донесение илтү өчен, яшьрәк, талчыкмаганрак сугышчылар арасыннан Шәмсине җибәрергә булды. Шәмси телефонисттан язу алып, кире Строгановка йөгерде.

VIII

Бара торгач, Сиваш сазының тагын бер хыянәте ачылды. Моңа Митричевның коточкыч сүгенә башлавыннан соң гына игътибар иттеләр.

Данилов түзмәде, аны каты гына әрләп ташлады:

— Ничек түзә, ничек чыдый синең ул телең?

Митричев, кинәт тураеп, Даниловның борын төбенә ниндидер бер сәләмә әйбер сузды:

— Мә, күрәсеңме менә моны? Монда сугышчының итеге таралган, сугышчы ялангач аягы белән пычрак ера, ә ул тегеләй бул да, болай бул...

Митричев, ачуыннан төкерде дә авыз эченнән бөтен дөньясын каргап, төпсез итеге белән шапыр-шопыр су ерып алга китте.

Тора-бара аяк атлавы мең бәлагә әйләнде. Үтелгән чакрымнарның исәбе күптән үк чуалган, алданиләр көтүен берәү дә белми иде.

Менә алдагы сафларда кинәт кенә барысы берьюлы тавышлана башладылар. Ни бар? Колагына кергән өзекләрдән Вәлитов сүзнең ниндидер җил турында баруын абайлады.

— Җил борылган!

Сул яктан дымлы авыр җилнең шактый ук көчле бәрә башлавына ул шунда гына игътибар итте. Ул арада диңгез ягыннан,ерактагы ташкын тавышы сыман, тонык бер шаулау ишетелде.

— Күбек! Су баса!

Ул арада күбек буразнасы полкның барасы юлын кисеп тә чыкты.

Менә су аяк йөзенә менде, балтырга үрмәләде... Тавыш чыгарырга ярамаганны искәрмәстән, комбат кинәт кычкырып җибәрде:

— Командирлар! Компас бирегез, тиз, тиз!

Пахомов кесәләрен актарган арада, кинәт бик якында гына пулемет тавышы ишетелә башлады. Комбат сискәнеп башын калкытты, нәрсәгәдер куанып командасын кычкырды:

— Булды! Әйдәгез, минем арттан! Йөгер!

Үзе пулемет тавышы килгән якка борылды да йөгерә башлады.

Су туктаусыз арта барды, бераздан тезгә менде, аякларны читкә сөйри башлады.

...Бугазын пешереп чыккан кайнар сулыш Әхмәдинең иреннәрен киптерә, суларга ирек бирми иде.

Унда, Перекоп ягында булса кирәк, атыш тагын да көчәя башлады. Артиллерия канонадасына пулеметлар тавышы кушылды.

Вәлитовның хәзер үз кайгысы кайгы, кургашын таккандай авырайган аякларны бер генә атлау да бик кыен.

Шулчак аңа авыр бер дулкын килеп бәрде дә, Әхмәди тезләнде. Икенче дулкын аны баштанаяк коендырып узды. Авызына, борынына су тулды... Ул шунда гомерендә беренче мәртәбә, үзенә үзе бик кызганыч, бик бәхетсез кеше булып тоелды.

«Их, кеше булдым дигәндә генә...»

...Менә кемдер, арттан килеп, аны торгызды, кемдер винтовкасын алды. Дулкыннар шаулавы арасында ул Исмаевның ягымлы тавышын ишетте.

— Әйдә, киттек кеше-кара күргәнче!..

Исмаев аны култыгыннан эләктереп алды да алга таба әйдәде.

Яр буена җитәрәк, суга тезләнгән тагын берәү күренде.

Арттан Данилов килә икән. Ул әлеге сугышчының аркасыннан кочаклап алды да җиңел генә аягына бастырды.

— Ах, Петрусь туган! Бу ни эшең бу? — диде. Данилов аз гына иелде дә Митричевны җитез генә аркасына атландырып яр буена таба китте.

— Менә хәзер син, Петрусь туган, почти кавалерист инде. Тик минем аркада ияр булмавы гына бераз фасонны боза.

Яр өстендәге дошман пулеметлары тончыга-тончыга аттылар. Су өстенә, эре яңгыр кебек, шыбырдап пуля ява башлады.

Яр буена аяк басуга, Вәлитов тезләнде. Ул җирнең каты балчыгын кулы белән капшады, аның туфрагына битен куйды.

Бу вакытта алданрак чыккан роталар, яр буена ышыкланып, дошман өстенә ташланыр өчен өскә таба үрмәлиләр иде.

IX

Текә яр кырыеннан кармаланып диярлек атлый торгач, Шәмси, ниһаять, менеп җитте. Карт алмагачлар арасында тәбәнәк кенә кечкенә балчык өй. Ишекне ачуга, Шәмсинең борынына махорка төтене килеп бәрелде. Озынча йөзле бер командирга якынлашты. Шәмсигә аны штаб башлыгы диделәр. Шәмси штаб башлыгының каршысына барып, алып килгән хәбәрен әйтеп салды. Аннары әйтергәме, юкмы дигәндәй, бераз икеләнеп торды да бер-ике сүз үзеннән өстәде:

— Мин монда килеп җиткәндә, Сивашка су бәрә башлады.

Башлык сискәнеп киткәндәй, Шәмсигә кинәт кенә күтәрелеп карады.

— Мм... Бик начар хәбәр алып килгәнсең син, бик, бик!

Штыгына таянып стенага сөялгән озын буйлы, сакаллы сугышчы, берсенә дә карамыйча, тирән борчу белән әйтеп куйды:

— Бу яктан су басса, теге яктан аклар китереп кысса, менә сиңа!

Ишектән урта буйлы, йомры гына гәүдәле, түгәрәк битле бер кеше килеп керде, туктап тормастан, нык басып өйнең эчке өлешенә узды.

— Иптәш Фрунзе!

Фрунзе килеп кергәч, эчке бүлмәдәгеләр аягүрә бастылар. Штаб башлыгы тантана белән рапорт бирергә тотынды. Командующий аны шунда ук бүлдерде:

— Алары турында беләм. Иң соңгы хәбәрләрдә нинди яңалыклар бар?

— Дивизия Литовский ярымутравына чыгып җиткәннән соң һөҗүм башлады. Атаканың нәтиҗәсе билгеле түгел, чөнки Сивашка бәреп кергән диңгез суы дивизияне теге якта бүлеп калдырды, элемтә өзелде, Сиваш суы телефон кабелен ашый...

Фрунзе штаб башлыгына борылды:

— Строгановның ревкомына командующий исеменнән әйтегез: авылның эшкә яраклы барлык халкын Сиваш кичүен ныгытырга алып чыксын. Дивизиягә атлы элемтәчеләр җибәрегез.

Озак та үтмәде ишектән кылычлы бер командир килеп керде.

— Җиденче кавдивизия сезнең боерыгыгыз буенча килеп җитте, иптәш командующий.

Фрунзе чыкканда, кавалерия дивизиясе, берничә саф булып, бакча алдындагы мәйданга тезелгән иде. Командующий аларның алдында йөри-йөри басынкы гына тавыш белән берничә сүз әйтте:

— Сезнең җәяүле иптәшләрегез теге якта бүленеп калды. Дошманның каршылыгын сындырыр өчен, аларга ярдәм кирәк, сезнең, атлыларның, шул якта булулары кирәк!

Фрунзеның бу сүзләренә меңнәрчә сугышчы гүләп җавап бирде. Михаил Васильевич, атлыларны озата барып, Сиваш ярына килеп басты.

Командующий, башына нindидер әһәмиятле бер уй төшүгә, җәһәт адымнар белән әлеге кечкенә өйгә кайтып керде.

Шәмси ишек яңагына килеп сөялде.

Командующий, өстәлгә таянган килеш, тәрәзә аша каядыр карап, әйтә-әйтә боерык яздыра иде. Яздырганнарын укып чыкты да кул куйды.

Штаб башлыгы язып утыручыдан пакетны алгач, Шәмсигә сузды:

— Инза дивизиясенең командирына бирәсең, үз кулына!

Фрунзе Шәмсигә сорау бирде:

— Сивашның суы һаман тирәнәя. Юлны таба алырсыңмы?

Шәмси «смирно» басты.

— Табармын, иптәш командующий!

— Тиз чыгып җитәргә кирәк, бик тиз!

— Йөгерәм генә, иптәш командующий.

X

Бая килгән туры сукмактан Сивашка төшкәч, Шәмси чыбык-чабык һәм салам төягән атлар, көрәк-сәнәк күтәреп эчкә таба кереп барган бик күп авыл кешеләрен күрде. Аларның байтагысы балчык белән салам өеп юлны нығыталар иде.

Аңа фронт ягыннан кайтып килүче яралы сугышчылар очрый башлады. Шәмси, дулкынланып һәм борчылып, атыш тавышына колак салды. Аның дивизиясе сугышкан якта да каты бәрелеш бара иде булса кирәк.

Менә аның уң ягында кинәт кенә бер шәүлә калыкты. Бераз гына баргач, юл кырыенда тагын бер карамчык күренде. Кызылармеец бер кулын куенына яшергән, нәрсәнедер изгәндәй аягын алмаш-тилмәш атлый, аның аяк астында баскан саен су шупырдый. Бер кулы белән ул, бик кадерле нәрсәне саклагандай, иңенә салынган телефон кабелен тотып тора иде.

Баганалар урынына ертык ботинкалы, алама киемле, дерелдәп, туңып беткән кызылармеецлар үзләре басканнар. Кыргый утрауда бүленеп калган дивизия җиңсен өчен, алар, бер төркем гади кешеләр, үз карамакларында булган иң соңгы һәм иң кыйммәтле, башка берни белән дә алмаштырып булмый торган нәрсәне — үзләрен, җаннарын корал итеп, авыр постка басканнар.

Төн. Су уртасы. Тозлы суның зәһәре тәнне ашый, салкыны сөякләрне сызлата. Аякларны Сиваш сазы суыра. Аның суы һаман югарырак үрмәли. Ә алар баскан урыннарында нык торалар.

Шәмси телефон чыбыгы күтәреп торучы сугышчыларны утыз-кырык адым киткән саен очрата башлады.

Перекопта туплар гөрселдәде, пулеметлар тавышландылар, Шәмси шунда таба йөгерде.

XI—XII

Кояшның кызыл-сары түгәрәге ундагы түбә артына иңә башлады. Йомшак бер тынлык урнашты.

Данилов окобыннан торып утырды. Бу гаҗәеп тынлыкка сәерсенеп як-ягына колак салды.

Ләкин шундук яр астыннан ыңгырашкан тавышлар ишетелде. Взвод командиры бөрешеп утырган сугышчыларына күз салды... Унөч, ундүрт, унбиш, уналты... Егерме биштән уналты... Бер көн эчендә... Сугышчыларның чиктән тыш эштән чыгып арудан һәм тирән кайгыдан әнә шулай башларын иеп утырулары тагын бер фаҗигане исенә төшерде. Командир урыныннан торып, карабинын иңенә алды.

— Кемнәр бара?

Винтовкаларына таянып Шәмси белән Әхмәди, алар янына тагын берничә сугышчы торып басты. Алар акларның ашыгыч казылган сай окоплары буеннан киттеләр.

Данилов, як-ягына карангалап, дошман белән кай төштә якага-яка килешүләрен күз алдына китерергә тырышты. Әнә шул тирән чокыр эченнән күтәрелгәннәр иде бугай. Менеп җитүгә, тынны буардай пулемет уты җиргә егылырга мәҗбүр итте. Менә монда менеп җитүгә, күп кеше кырылды, арырак узгач, икенче атака вакытында — тагын да күбрәк.

Әмма иң кыены алдарак булып чыкты. Таң алдыннан алар чәнечкеле тимерчыбык киртәсенә килеп төртелделәр.

Күтәрелеп карауга, башларын иеп туктап калдылар: аларның иптәшләре иртә беләнге хәлендә үк тимерчыбык киртәсе өстендә йөзтүбән ята иде.

Митричевның шинелен кизәнеп торып тимерчыбык киртәсе өстенә ыргытуы Шәмсинең дә күзенә чалынып калган иде. Тик ул шинеле өстенә сикереп менүгә, кинәт пулеметтан аттылар. Әйе, теге якка сикереп төшеп, пулеметка граната ыргытыр өчен тагын бер генә сулыш вакыт та җитәсе иде...

Тимерчыбык киртәсенә тәмам якынлашып, үле гәүдәне алырга кулларын сузганда, дошман ягыннан пулемет ут ачты. Җиргә ауган чагында, Шәмсинең сул балтырын нидер үзәгенә үткәреп пешереп алды.

Данилов коры гына:

— Кайчы! — дип кычкырды.

Иптәшләре кабер казыганда, Саша гаҗәпләнгән карашын караңгы күккә текәп, үзенә соңгы өйне җитештергәнне көтеп ятып торды.

Ялкыннар шәүләсе аеруча көчле балкыганда, кинәт күзенә чалынып калды: Шәмси нигәдер аксый башлаган иде.

— Тукта, ни булды сиңа?

Шәмси сак кына аны читкә этәрде:

— Бетәр әле.

Данилов үз янына санитарны дәшеп китерде. Брезент сумкасын асып, бер баһадир килеп керде. Шәмсинең аягына баса алмыйча егылып китүен күрүгә, кычкырып җибәрде:

— Ты же ранен!

— Исегез киткән икән. Чебен тешләп китте... тегендә, бая. Данилов төкеренде, сүгенде:

— Молокосос! Тапкан кыланыр вакыт! Чыдам, имеш, революция өчен һәммәсен тавышсыз гына күтәрә, имеш! Дурак! Аяксыз калсаң, синең кемгә кирәгең бар?

Санитар арбасында Шәмси акрын-акрын ойый башлады.

Ялкынлы, гөрелтеле фронт сызыгы һаман якыная барды. Уңда да, сулда да ашыгып алга баручы роталар, батальоннар. Яр астындагы тар сукмактан йөгерә-атлый узганнан соң, ниндидер чокырлар, үзәннәр кичеп, сугыш кырының нәкъ артына килеп чыктылар.

Данилов, сугышчыларын окопларга урнаштырып бетергәннән соң, Әхмәди янына килеп утырды.

— Йә, нихәл, картлач?

Вәлитов, окопка сузылып яткан җиреннән тамак кырып алды:

— Менә дигән, егетләрчә... Тиз керербезме, синеңчә?

— Каян беләсең? Бәлки, хәзер үк, бәлки, ярты сәгатьтән. Күршеләр әле генә китте бит әле. Загражденигә үтә алырлармы, юкмы... Егетләр бик арыды, ничек беразга гына йоклатмыйча түздерергә?

Вәлитовның җавап бирмәвенә гаҗәпсенеп иелебрәк караса, картлач шул арада үзе дә йоклап киткән.

Шәмси шомланып һәм гаҗәпләнеп күзен ачты. Юк, ул үлмәгән икән, исән икән! Әйе, кичә аягы яраланган иде бит. Ләкин балтырның ул төше хәзер әйтерлек авыртмый.

Ат йөртүче чөңгереп еш-еш дилбегәсен тарта. Ниндидер бер авылга килеп керделәр. Авылның урамнары, ындыр артлары, авыл янындагы күл буйлары — бөтен җир атлылар белән тулган.

Ат тотучы, як-яктагы тәгәрмәч тавышларын бастырырлык итеп, Шәмсигә кычкырды:

— Күрдеңме? Будённый армиясе бу! Җәяүлеләр заграждение генә өзсеннәр, аннары болар ташлана. Өермә болар, ташкын!

Ул да түгел, кинәт, баш өстеннән бер снаряд сызгырып үтте. Аның артыннан тагын бер, аннары тагы...

— Безнекеләр! Без башладык! Ура!

Артиллерия канонадасы минут саен кыза барды. Бу дәртле, көчле ташкын Шәмсине дә үзенә тарта иде.

Шәмси шулай икеләнеп, пошынып һәм борчылып барды-барды да, ниһаять, түзмәде, ат тотучының колагы төбенә кычкырды:

— Туктат!

— Нәрсә син? Кая болай?

— Иптәшләр янына!

— Сыңар аяк беләнме? Юләр син! Аксак тиле!

— Юк, минем аяк төзәлде инде.

Арбадан төшеп басуга, Шәмси, сул аягының балтырына энә кадалгандай, сыны катып сүзсез калды. Шулай да яшьлек горурлыгының ансат кына бирешәсе килми иде.

— Әйтәм бит,— диде.

Ат тотучы икенче борылып караганда, ул инде, патрон әрҗәләре төялгән яшел арбага утырып, алгы сызыкка таба чаба иде.

XIII

Аклар окобы бөтен буе белән утлы өермә астында калды. Ул арада кузгалырга команда булды. Полк дошманга йөзе белән борылып, озын бер сафка тезелде.

Командир Пахомов ротаның каршысына чыгып басты, бераз карлыккан тавыш белән:

— Мин сафтан чыксам, ротаның командиры политрук Исмаев булыр!— диде.

Исмаев көтелмәгән бу хәлдән бераз каушабрак калды.

— Аполлинарий Петрович! Мин бит...

Пахомов аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— Политрук Исмаев! — диде.— Стройда мин Аполлинарий Петрович түгел, ә иптәш командир! Бу — бер. Икенчедән, командирның сүзе — приказ.

Исмаев берьюлы юашланып калды:

— Тыңлыйм, иптәш командир!

Пахомов взвод командирларының һәркайсына урынбасарлар билгеләргә кушты.

Командир артиллерия тавышына колак сала. Пахомов, акларның бетонланган ныгытмаларын җимертү өчен, мондый кечкенә калибрлы пушкалардан ату гына җитмәвен алдан ук сизеп тора, шуңа борчыла иде. Полк та бик кечерәйгән, хәзер ул зуррак батальон кадәр генә калган иде.

Ул күңеленә үрмәли башлаган борчуга тамыр җәяргә ирек бирәсе килмичә, сугышчыларына сыныйрак карый башлады. Үрнең аръягындагы сугышның җир тетрәтеп үкерүе аларны борчый. Әмма алар бер-берсенә сүз кушкан булалар, баскан урыннарында сикергәлиләр, куркуларын бер-берсеннән яшерергә тырышалар иде. Пахомовка болар һәммәсе дә әллә кайчан ук таныш. Әмма хәзер аның үзенең дә сугышчыларга бик якын да, ягымлы да буласы килде.

— Йә, менә озакламыйча кузгалабыз...— диде, әмма рота алдыннан берничә мәртәбә әйләнеп узса да, теле ачылып китмәде, тел очына гына җыелып торган ягымлы сүзләрен әйтеп бирә алмады.

Полк кузгалды, хутор белән аклар арасындагы үр өстенә күтәрелә башлады. Үнда да шундый ук озын бер тезмәнең атакага баруы күренде.

— Тизрәк!

Тезмә тагын да кызулый төште. Йөгерергә команда булды.

«Нигә ата башламыйлар икән, нигә?..»

Барлык командирлар, наганнарын айкап, тезмәнең алдына чыктылар. Кайсыдыр кычкырып җибәрде:

— Иптәшләр, революция өчен, ура!

Сугыш кырын «ура» тавышы яңгыратты. Шул секундта ук тезмә өстенә берьюлы кинәт йөзләрчә пулеметның котырынган утлы ташкыны килеп бәрелде. Бер генә адым атлау да исәпсез корбаннар сорый башлады, әллә нихәтле сугышчы егылып калды.

— Ложись!

Хәзер инде кантарларгаябыша-ябыша мүкәләп үрмәли башладылар. Пулеметлар баш калкытырга да ирек бирмичә һаман кыралар, әле анда, әле монда яралылар, үлгәннәр сузылып кала, минут саен тезмә сирәкләнә бара иде.

Пахомов ачынып һәм ярсып тезмәгә күз салды. Болай булса, тагын берничә минуттан бөтен полкның кырылып бетүе мөмкин иде. Карт солдат шундук катгый карарга килде: кинәт сикереш ясап тимерчыбык киртәсенә барып ышыкланырга! Ул җәһәт кенә сикереп торды да кычкырып җибәрде:

— Рота, минем арттан!

Исән калган сугышчылар бердәй алга ташланды.

Пахомов бөкрәя төшеп йөгергән уңайга, сугышчыларын әйдәп, әле бер якка, әле икенче якка карап кулын болгый. Тимерчыбык челтәренә якынайган саен аның күңеле күтәрелә, аның саен өмете зурая бара иде. Менә тагын егерме генә адым, ун гына... Аннары — кайчы, гранаталар, штык...

Ләкин командир, ике-өч кенә адым атлагач ук, башын нидер кыздырып узган кебек сизде. Аннан соң гәүдәсенең тотрыксызланып авып төшүен, җиргә килеп бәрелүен тойды. Кинәт кенә төпсез, йомшак караңгылыкка чумган кебек булды...

Хәзер инде һәммәсе дә ачык күрделәр: артиллерия өч катлы тимерчыбык челтәрен җимертеп бетерә алмаган булып

чыкты. Шулкадәр кыенлыклар белән монда килеп җиткәч, шулкадәр җан кыелгач та кире чигенү йөрәкне әрнетә, җанны кыйный иде.

Шулай да команда чигенергә кушты.

Шәмсигә кайсыдыр фамилиясе белән кычкырды. Дәшүче әлеге пәһлевандай зур гәүдәле санитар икән.

Ул, түземсезләнеп:

— Тот тизрәк? — диде.

Носилкада рота командирының үле гәүдәсе ята иде. Носилканы күтәреп пулемет уты астында бөгелә-сыгыла бик озак йөгергәннән соң, хуторга җитәрәк туктадылар. Пәһлеван носилка янына тезләнеп папахасын салды.

— Нинди әйбәт кеше иде...

Аның яңаклары буйлап күз яшьләре тәгәрәде.

Даниловны ротаның яңа командиры Исмаев үзенә ярдәмгә чакырганлыктан, ул взводны Вәлитовка калдырып киткән иде. Вәлитов, шинель итәген бил каешына кыстырып, сугышчыларының әле берсе, әле икенчесе янына үрмәләде. Аларның артындагы хутор өстендә өзлексез туп ядрәләре ярыла. Дошман баш калкытырга да ирек бирми, пулеметлардан өзлексез сиптереп тора. Әмма Вәлитов шунда да үзен тыныч тотарга тырышты, вакыты белән шаяртып алгалады.

Шулвакыт, янып ята торган тегермән калдыгына ышыкланып йөгерә-йөгерә, беренче батальон командиры килеп чыкты.

Исмаев командирның янына ук барып колагына кычкырды:

— Иптәш командир, патрон бетте!

Командир тегермән артында аты һәм олаучысы үлеп кырынаеп яткан патрон арбасын күрсәтте:

— Әнә патрон, әнә! Бар, йөгер, нишләп монда син?!

Исмаев берничә сугышчы белән ротасына патрон китергәндә, аклар ягыннан бер машина килеп чыкты.

— Броневик! Броневик! — дип кычкырдылар.

Зур гына яшел машина, каршысына пулеметлардан һәм винтовкалардан атуга һич исе китмичә, бик тиз якынлаша башлады. Кырык-илле адым калгач, кинәт сулга борылып, пулеметлардан ата-ата, тезмә алдыннан чабып китте.

— Их, астына граната җибәрергә! — диде берсе.

Исмаев ике сугышчының, тезмәдән аерылып, ашыга-ашыга броневикка таба шуышуларын күреп калды. Бу икенең берсе Вәлитов иде. Алар тирәсендә күз очырмаслык пуля бураны купты.

Бераздан аларның берсе, үрмәли торгач, чокыр эчендә ятып калды. Исән калган сугышчы ызанга кереп яшеренде. Машина ызанга таба юнәлде. Тик шунда гөрселдәп граната ярылуга, өреккәндәй, кинәт бер якка ыргылды. Ырылдап, тагын алга ташланды, әмма шунда ук тагын туктап калды.

Машина белән кешенең шулай үлем сугышы башлауларын тыннарын да алмыйча күзәтеп торган сугышчылар кинәт җанланып киттеләр. Кайсыдыр кычкырып җибәрде:

— Әһә! Чукынды броневик, кадалды!

— Кара, кара! Вәлитов икән бит ул! Исән, картлач, исән!

Ләкин куанырга иртәрәк булып чыкты. Вәлитов кире иптәшләре янына кайтырга дип яшеренгән ызаннан чыкты да сузылып яткан килеш хәрәкәтсез калды.

Шәмси, йөрәге әрнеп, җиргә капланды.

— Аайй!..

Полк янсә, дөресрәге, полкның исән калган берничә йөз сугышчысы икенче тапкыр һөҗүмгә күтәрелде. Иптәшләре узышлый Вәлитовны носилкага салдылар. Шәмси, аның калтыранган юеш кулларыннан алып, битенә иелде.

— Әхмәди абый! Хәлең ничек?.. Кай төшең?

Әхмәди авыр итеп ыңгырашты да тынып калды. Шәмси атасы кебек яраткан Әхмәди абыйсын кочаклады, гүя суына башлаган кулларына үз җылысын бирергә теләгәндәй, кулларын кысып, маңгаен сыйпады. Аннары кычкырып елап җибәрмәс өчен тешләрен кысып, ротасы артыннан йөгерде.

Икенче һөҗүмгә бару да җиңел булмады. Пулемет уты һаман да көчле иде әле.

Сугышчыларның байтагы яраланган иде инде. Хәлләре беткәннәре котомкаларын ташлыйлар. Бара торгач, эштән чыгып, егылып калалар. Тик яраларын бәйләтәләр дә тагын торып китәләр. Тирләрен, каннарын сөртә-сөртә, тешләрен кысып, аксый-аксый үрмәлиләр.

Урталыкка җиткәндә Даниловка бер кызылармеец дәште:

— Иптәш командир, кулыңда кан.

Данилов кулының әчетүен шунда гына сизде. Менә күп булса тагын йөз илле адым калгандыр. Аннан соң атака башланырга тиеш. Шундый вакытта артта калырга ничек күңел түзсен? Тагын ун минутка чыдарга...

Ләкин үзе никадәр тырышса да, взвод белән барырга хәле калмады.

Даниловның взводы алга китте. Алда ике броневик күренде. Алар икесе янәшә тезмә өстенә килә башладылар.

Ул да түгел броневикларның ике ягыннан кисәк кенә атлылар төркеме атылып чыкты. Ике броневик тезмәнең буеннан-буена аттырып йөриләр, шуннан файдаланып атлылар һаман якынлаша килә иде. Иң кырыйда калган Данилов взводының хәле аеруча авыр иде.

Шулвакыт, тыны-өне бетеп, рота командирыннан вестовой йөгереп килде.

— Командир! Кайда Данилов?

Сугышчылар, ни әйтергә белмичә, бер-берсенә караштылар.

— Данилов юкмыни? Кем калды соң командир урынына?!

Уртадан Шәмси күтәрелде.

— Күрәсең, мин калганмын инде болай булгач!

— Тыңла! Рота командиры кавалерияне артка уздырмаска кушты. Кырылып бетсәгез бетәсез, әмма урыннан кузгалмыйсыз! Аңлашыламы? Сезгә бер пулемет килә.

Шәмси дулкынланып, беренче тапкыр команда бирде:

— Взвод, минем янга!

Шәмси Гайфуллинның мондыйны башыннан уздырганы бар, кавалериягә каршы торганда, көчне бер йодрык итеп тупларга һәм залп белән атарга кирәген ул белә иде.

Взвод өстеннән, гөрселдәп, беренче залп күтәрелде. Ул арада пулемет та килеп җитте. Ләкин атлылар беренче залпны сизмәделәр. Кылычларын айкап, акырышып, тагын да шәбрәк чабарга тотындылар.

Гөрселдәве белән күңелләрне рәхәтләндереп тагын берничә залп яңгырады.

Бу вакытта әлеге пәһлеван санитар Даниловның ярасын бәйләргә тотынган иде.

— Кан күбрәк киткән. Кулбашың да яраланган икән синең!

Атышның кинәт кенә тукталуына сәерсенеп, Данилов торып утырды. Алга таба күзе төшү белән сискәнеп китте. Атлылар ташкыны туп-туры аның взводы өстенә килә иде. Ул, бәйләнеп җитмәгән бинтын сөйрәп, взводы артыннан йөгерде. Коты чыгып: «Бетерәләр! — дип уйлады.— Артта калып начар иттем». Берничә мәртәбә егылды. Тагын торып йөгерде.

Якында гына команда тавышын, взводның залп белән атып ятуын ишеткәч, эченә бераз җан керде. Атлыларның буталуын күреп, шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

— Кррой, ребята!

Бу вакытта уң канат, ике броневикны да кире чигендереп, алга бара башлаган иде. Шәмси взводы да, башкалар белән бергә, тимерчыбык киртәсенә атакага ташланды.

Иң кискен минутлар җитте. Янәшә барган кешенең тавышы ишетелмәс булды. Шрапнель шартлавы, гранаталарның гөрселдәве астында яраланган, эштән чыгып арыган сугышчылар актык көч белән ялкынлы өермәне ерып, тимер киртәсенә таба үрмәләде.

Шәмсинең өстенә балчык кисәкләре яуды, авызына, күзенә ком тулды. Нәрсәдер аның фуражкасын чөеп ыргытты, тимерчыбык әле шинелен, әле обмоткасын ертып алды, тәне тоймас, үзе тирә-яктагы дәһшәтләрдән курыкмас булды. Ул бөтен көче белән шуышты, тырмашты. Аның күңелендә бертуктаусыз бер генә уй бөтерелде: «Тизрәк бәреп чыгарга, тизрәк атакага ташланырга!»

Менә, ниһаять, тимерчыбык киртәләренең аргы ягына бәреп чыктылар. Кинәт «ура» тавышы күтәрелде. Исән калган сугышчылар, ярсып, кычкыра-кычкыра, аклар окобы өстенә ташландылар. Ротаның иң алдында Исмаев йөгерә иде.

Окоплар өстенә гранаталар ява башлады, прикладлар чыркылдады, кемнәрдер акырып җибәрде, кемнәрдер шәфкать сорап кулын күтәрде.

Шулвакыт шатлыклы тавышлар ишетелде:

— Будённый!..

— Ура, Атлы Армия!..

Күз күреме җирне иңләтеп, ат аягы астында кырны гүләтеп, тыелгысыз көчле агым булып, өермәдәй тизлек белән үр артыннан Будённый атлылары килеп чыкты. Окоплар бер тилпенүдә артта калды. Атлы ташкын качып барган дивизияләр өстенә ташланды.

Бу — бер мең тугыз йөз егерменче елның унберенче ноябре иде.

1937—1957 еллар

Гомәр ага Бәшировның «Сиваш» повестен ничек язуы турында бик гыйбрәтле мәкаләсе бар. Мәкалә әдәби әсәр язу серләренә кагылып үтә һәм повестьның эчтәлегенә ачыклык кертә. Дәреслектә ул, повестьның үзе кебек, кыскартылып бирелә.

«Сиваш» повесте ничек язылды

Беренче карашка, китап язу өчен «читкә чыкмаска» да була, үз башымнан үткәннәр дә бик җиткән кебек иде. Чыннан да, гражданнар сугышы елларында безнең буын кайда гына булмады, ниләр генә кичермәде! Мин, ярым-йорты гына русча белгән гади авыл малае, Казанда оешкан дивизиянең солдаты буларак, беренче тапкыр туган авылымнан ерак китеп, ярты Россияне диярлек әйләнеп чыктым. Полкташ иптәшләрем — руслар, татарлар, украиннар һәм башка милләт уллары белән бер сафта без, аклар армиясен куа-куа, Кара диңгезгә барып җиттек. Днепр камышларын айкадык. Черек диңгезнең (Сивашның) серле дәһшәте алдында да туктап калмадык. Перекопта һәм Сивашта ун меңнәрчә батыр сугышчыларыбыз мәңгегә егылып калды. Ул сугышларның ни дәрәҗәдә авыр булуына бер генә мисал: Сивашны кичкәч, акларның соңгы позицияләрен штурмлаганда, безнең ротадагы җитмеш биш сугышчы һәм командирдан берике сәгать эчендә нибары унсигезе генә исән калды. Шулай да Кызыл Армиянең ярсу атакаларын яңгыр урынына яуган пуляләр да, үкереп килгән снарядлар да, кавалерия атакалары да — берсе дә туктата алмады. Безнең һәммәбезгә дә ифрат та авыр, чиктән тыш кыен иде. Әмма әгәр дә шулвакыт Туган ил кирәк тапкан булса, шул ук кыен, хәвефле юлларны без, һич икеләнмичә, яңадан бер мәртәбә үткән булыр идек.

Китапның нигезенә күңелдә уелып калган менә шушы истәлекләр салынды. Ләкин мондый зур, тарихи әһәмиятле вакыйгаларны киләсе буыннарга һич ялгыштырмыйча, тормышның үзендә ничек булса, шулай җиткерү өчен истәлекләр генә җитенкерәми иде. Сугыш булып узган урыннарга яңадан барып чыгарга, сугышта катнашкан кешеләр белән сөйләшергә, архив документлары белән танышырга кирәк булды.

Менә язарга утырдым. Тик шулвакыт өстәл янында мин үзем генә түгел кебек хис итә башладым. Сугышның кыенлыкларын да, җиңү шатлыкларын да бергә кичергән, бер сынык икмәкне икегә, өчкә бүлеп капкан, бер шинель ябынып йоклаган якташларым, дусларым, иптәшләрем бар иде бит. Без алар белән сугыштан чыгып торган көннәрне кичке тынлыкта, Украина

кызларының җырларын тыңлый-тыңлый, авылда калган сөйгән ярларыбызга хатлар яза идек.

Кызганычка каршы, минем якташ, иптәшләремнең, танышбелеш, дусларымның күбесенә туган-үскән илләренә әйләнеп кайту насыйп булмады. Инде мин исән калып китап язарга тәвәккәлләгән икәнмен, ул иптәшләрем исеменнән дә нидер әйтергә, аларның ярты юлда бүленеп калган уй-хисләрен дә укучыга җиткерергә тиеш түгелме?

Кайбер сугыш операцияләрен көненә генә түгел, сәгатенә кадәр тормышның нәкъ үзендә булганча язарга тырыштым.

Шулай да бу әле сугыш вакыйгалары, фотога төшергән кебек, ничек булса шулай, һич үзгәрмичә язылган икән дигән сүз түгел. Әдәби әсәр язганда әдәбият кануннары белән эш итеЛә. Мәсәлән, кинода язгы ташуның котырынып агуын күрсәтергә кирәк булды, ди. Моның өчен елганың ничек ташуын башлаган җиреннән тамагына кадәр, лентага төшереп алуның һич тә кирәге юк. Бәлки, аеруча ашкынып, котырынып аккан берәр урынын җентекләбрәк күрсәтү дә бик җитә.

Сиваш белән Перекоп тирәсендәге сугышлар җәй көне үк башланып киткән иде. Мин исә ул сугышларның фәкать берничә көнен генә күрсәтергә кирәк таптым. Иң соңгы, хәлиткеч көннәрен генә...

Дивизиябезнең ярты гасырлык юбилее уңае белән сугыш ветераннарын кунакка дәштеләр. Җәйге көннең матур иртәсендә дивизиябезгә барып төштем. Вокзал каршында күкрәкләре орденнар белән тулган офицерлар, солдатлар, гади киемдәге иптәшләр төркеме ветераннарны каршы алырга чыккан иде. Бу минутларда нидер кичерүем, ничек дулкынлануым шәт аңлашылса булса кирәк. Шушы каршы алучылар арасында моннан илле өч ел элгәре минем белән бергә Сивашта утны-суны кичкән карт сугышчылар да булуы мөмкин бит! Әгәр дә мин шуларның берсен генә булса да очрату бәхетенә ирешсәм?

Бәхеткә каршы, бар иде алар, бар иде минем сугышчан кордашларым! Өч кенә бөртек калган булсак та, шатлыгыбыз тау кадәр булды. Без, үзебез өчен дә, якты киләчәк өчен авыр көрәштә һәлак булган иптәшләребез өчен дә, бер рота солдаты кадәр шаулап, кочаклашып күрештек.

1974 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Авторның әсәре турындагы мәкаләдә ничә тема күтәрелә? Шуларның барын да дәфтәрләрегезгә языгыз.

2. Бер үк тема турында берничә урында сөйләнсә, аларны бергә җыегыз. Шул рәвешле, әсәрне, тема аерымлыкларына карап, өлешләргә бүлегез.

3. Мәкаләдә авторның сөйләү интонациясе нинди? Интонация үзгәргән урынны табыгыз. Үзгәрүнең нигә кирәк булуын аңлатыгыз.

4. «Китап язу өчен «читкә чыкмаска» да була», ди автор. Гомәр Бәширов «эч» һәм «читкә чыгу» дигәндә нәрсәне күздә тота?

«Сиваш» повестена анализ нәтиҗәләре

Повестьта хөкем итүче идеологияне аклауга һәм мактауга күп урын бирелгән. Политрук Исмаев — төп персонажларның берсе. Әхмәди атака алдыннан үзен коммунист итеп күрергә тели. Автор Сивашны фәкать большевиклар гына кичә ала дип күп мәртәбә кабатлый, сугышчыларның батырлыгын партиягә һәм советларга тугрылыгы белән аңлата. Повестьның нәкъ менә шул урыннары ясалма чыккан да.

Соңгы елларда басылган мәкаләләрендә Гомәр Бәширов Коммунистлар партиясе тоткан юлга һәрвакыт ышануы турында яза.

Гражданнар сугышында Гомәр Бәширов үзе катнаша. Сугышның бөтен афәтен үз күзе белән күрә һәм үз башыннан кичерә. Сугыш вакыйгалары яшь сугышчы күңеленә хәсрәт, җәфа, фаҗига булып кереп калган. Хәтер үзенекен итә, әледән-әле идеологиягә каршы килә һәм күп очракта өстенлек ала.

Гомәр Бәширов Кызыл Армия сугышчыларының аяныч хәлен үзе күргәнчә яза: аяк киемнәренең табаннары төшкән, шинельләре тишек-тошык, ашарларына юк, ял күрмиләр, кораллары бик начар. Шундый кешеләрне командирлар адәм йөрмәс бозлы суга куып кертәләр, баткан кешене коткармаска дигән приказ бирәләр. Пулеметларга, броневикларга, бетон ныгытмаларга каршы җибәрәләр.

Шулай булса да Кызыл Армия җиңеп чыкты, чөнки большевиклар ала алмаган крепость юк, дип нәтиҗә чыгара әсәрдәге идеология.

Тарихи хакыйкать шундый: Кызыл Армия, Гомәр ага язганча, бик күп корбаннар бирә-бирә һөҗүм итсә дә, Кырымны бары тик кызыллар ягында сугышучы Махно отрядлары ярдәме белән генә ала.

Гомәр Бәширов язган чынлык гражданнар сугышы фаҗигасен кешеләр күңеле һәм язмышы аша үткәрүдән гыйбарәт. Сугышка аларның кичерешләре аша бәя бирә. Кешеләрне үткән тормыш хатирәләре белән аерып куя да асыллары белән бу бертөсле соры шинель кигән сугышчылар — гап-гади игенчеләр, шахтерлар, укытучылар, ди. Һәркемнең үз хыялы, үз мәхәббәте барлыгын аерым-аерым сурәтли һәм барысын да бер гомуми теләк белән берләштерә. Бу кешеләрнең һәммәсе дә тилмереп сугыш бетүен көтәләр. Сугышчылар тыныч тормыш турында хыялланалар. Пулеметка каршы да, батырлык күрсәтү турында уйламыйча, соңгысы дип баралар.

Персонажларны бер-берсе белән чагыштырып карасак, алар арасында тагын бер охшашлык табабыз: Әхмәди, Митричев, Борисов, Данилов, Пахомов, Шәмсиләрнең юанып искә ала торган хатирәләре белән фаҗигале язмышлары каршы куела икән. Сугышчыларның күбесе һәлак була. Исән калганнарының йөрәгендә мәңгелек тирән яра кала. Бу кешеләр сугышның үзләре дә аңлап бетерми торган мәгънәсезлеге аркасында үләләр — еллар буена кадерләп саклаган хатирәләр, өметләр юкка чыга. Үлемнең мәгънәсезлеге исәннәрне елата. Күңелләрендә Әхмәди, Борисов, Пахомовлар ни өчен үлделәр? Аларның үлемнәре хаклымы дигән сорау туа.

Шул рәвешле, әсәрдә кеше гомеренең матурлыгы хаклык буларак сугышка каршы куела. Повестьның фәлсәфәсе табыла.

Гомәр Бәширов мәкаләсендә күп вакыйгаларның берсен генә сайлап алдым, бер вакыйга эченә башкаларын да кертергә тырыштым дигән фикер әйтә.

Нәтиҗә ясыйк: әдип әйткән «читкә чыгу» күргән-белгән вакыйгаларга архивтан җыйган, сорашып белгән фактларны кушу гына түгел, ә чикләү дә икән.

Әйдәгез, хәтердә калдырыйк:

Әдәби әсәрдәге вакыйгалар диварда эленгән сурәт рамы кебек чикләнә икән. Өстәвенә бу чикләнгән вакыйгалар тәмамланырга тиешләр. Шуңа күрә әсәр эчендәге чикләнгән санлы персонажлар чикләнгән вакыт арасында һәм чикләнгән урында хәрәкәт итәләр. Шуңа күрә аларның язмышлары үзара бик еш кисешә. Аз кешеле, аз вакыйгалы сюжетына өстәмә мәгънә бирү өчен, автор әсәре эчендәге вакыйгаларны мәгънә бирүче бәйләнешләр белән ялгый. Шуның өстәвенә язучы нәрсәнедер читтән тыш киметә, нәрсәнедер читтән тыш арттыра, «читкә чыга».

Чикләү, вакыйгаларны үзара бәйләү, метафоралардан, синонимнардан файдалану, арттыру, киметү, гомумиләштерү алымнары белән хакыйкатьне ачуга сәнгать чынлыгы диләр.

Биремнәр

1. «Сиваш» повестена анализ нәтиҗәләре» бүлегендәге нәтиҗәләрне 1, 2, 3... дип санап чыгыгыз. Һәркайсының темасын нәтиҗә исеме итегез.

2. Гомәр Бәшировның «Сиваш» повесте ничек язылды» мәкаләсендәге үзегез тапкан темаларны анализ нәтиҗәләре белән чагыштырыгыз. Аларның уртак якларын һәм аермаларын табыгыз.

3. Дәреслек авторы язган нәтиҗәләр әйтелгән генә, исбат ителмәгәннәр. Әсәргә үзегез анализ ясап, һәркайсын исбат итегез. Анализ вакытында, дәлилегезне көчәйтү өчен, әсәренә карата әдип үзе әйткән фикерләрне дә файдаланыгыз.

Гадел Кутуй
(1903—1945)

Гадел Кутуй сугышта алган ярасыннан Польшада хәрби госпитальдә үлә. Ул үлгәч, Казанга хат килеп төшә. Анда мондый сүзләр язылган була:

«...Минем берләшмәгә килгәндә, Кутуев гади солдат иде, табигате белән тыйнак, үзенең югары белеме белән, язучы булуы белән беркайда да һәм беркайчан да һаваланмады. Фронтның кырыс чынбарлыгы таләп иткән һәр эшне намус белән үтәде. Иптәш Кутуев сугышта батыр һәм кыю иде. Үзенең түземлелеге, шат күңеллелеге белән башкаларга үрнәк булды...»

Хатны җибәрүче полковник Михайлов, хәрби кеше булуын онытып, үзенең әдипкә булган ихтирамын яшермәгән, аның кешелек сыйфатларын санап чыккан.

Һади Такташның иң якын дусты, үзе исән чакта ук идеология кысаларына эләгеп кимсенүләр күргән, тиз арада халыкның яраткан язучысына әйләнгән Гадел Кутуй, полковник язганча, гомере буе тыйнак, шат күңелле, шәфкатьле, тыныч кеше була.

Гаделша Кутуев 1903 елның 28 ноябрендә элекке Саратов губернасының Кузнецк өязе Татар Кынадысы авылында һөнәрче гаиләсендә туа. Башлангыч белемен, башка язучылар кебек, әнисеннән ала. Самара университетының тарих-филология факультетында укый. 1920 елда Казанга килә. Монда педагогия институтын тәмамлый һәм соңрак шунда укытучы булып эшли.

Беренче китабы 1924 елда чыга. Бу елларда әле әдип шигырьләренең тышкы яңгырашына аеруча игътибар итә. Үзен футурист дип атый. Соңга таба шигырь формасының эчтәлектән аерылмавына, бәлки аның яшәеш ысулы булуына төшенә.

Гадел Кутуй — күп санлы пьесалар, шигырьләр, рецензияләр, публицистик әсәрләр авторы. «Тапшырылмаган хатлар» повесте

белән ул чит илләрдә танылa. Повесть Европа илләренең күбесендә тәрҗемә ителеп басыла. Әле дә булса укучыларыбыз тарафыннан яратып укыла торган әсәрләрнең берсе.

ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР

Беренче хат

Искәндәр!

Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт. Мин аны каткат укып чыктым. Бу сагыну хатыңны укыган чакта минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел, бәлки моннан 8 ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис»,— дип килеп танышкан Искәндәр иде.

Нинди матур истәлек. Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да сиңа, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә. Миндә яңа хисләр тудырган, күңел күзләремә матурлык буяулары биргән бу кадерле минутларны мин бик еш искә төшерәм. Тормышның тискәре яклары белән көрәшкәндә туңсам, арысам әгәр — шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям.

Исеңдәме беренче танышуыбыз?

1923 ел иде. Аяусыз тормыш камчысы астында төрле шәһәр, авылларны гизеп туйганнан соң, мин Казанга килеп чыктым. Казан университеты рабфагына укырга кердем.

Тормышка юл табуыма мин шат идем. Ул елларны тормыш минем өчен ал да гөл генә, бөтен бәхетләр бергә минем йөрәгемә җыелгандай тоела иде. Мин бары тик ирек, матурлык көчен генә хис иттем. Мин үземне чәчәкле бакчада күрдем. Бер сынык икмәк белән ике бәрәңге ашап, алтышар сәгать дәрес тыңларга туры килгәндә дә, мин шат һәм köләч идем. Чөнки мин күзләремне киләчәкне күрергә өйрәтә башладым. Ә киләчәкне күрү, шуны күрәм дип хис итү иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә.

Менә шунда, бәхеттән шашып рәхәттә йөргән чагымда, мин сине очраттым. Һәрбер сөю һәм сөелүнең: «Эх, яратасы иде, сөясе иде»,— дип хисләр ташкан чагы була. Алмагач та, тула һәм пешә башлагач, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый. Шомырт та чәчәк ата. Сандугачлар да сайраша. Чияләр дә, вакыты җиткәч, кызаралар, тулылыктан матураялар. Мин дә үземнең матурлык тойгыларыма тулганымны сиздем. Минем дә яратасым, яраткан кешем белән:

— Без нинди бәхетле, безгә шундый рәхәт,— дип, тын беткәнче кочышасым килде.

Озак та үтмәде — студентлар арасында зур кичәгә хәзерлек репетицияләре башланды. Без бер бүлмәдә биш кыз тордык. Кичә була дигәч тә, без бөтен бүлмәбез белән анда катнашырга язылдык. Беренче репетиция ТКУ студентлары тулай торагында билгеләнде. Без барып кергәндә, син анда идең инде. Сине күрү белән үк, без синең турыда яшерен сер итеп сөйләшә башладык. «Бу кем?» — дип соравыбызга, шундагы бер студент:

— Артист Искәндәр,— дип җавап бирде. Яшермим, син безнең күбебезгә ошадың.

Әйе, син матур идең. Безнең бүлмә кызлары исә синең бу матурлыгыңны хыял буяулары белән тагын да бизәргә, бизәп баетырга тырыштылар. Афишада синең фамилияңне күргән саен, без, актык тиеннәребезне җыеп, театрга чаба торган идек.

Сөю кешегә шатлык һәм көч бирә. Чөнки кичәгә хәзерләнеп йөргән көннәрдә, мин рәтләп йоклаган чагымны да хәтерләмим. Бу зур кичә өчен мин «Тормыш турында җыр» әзерләдем. Бу җыр минем башымда бик күптәннән бирле йөрсә дә, көен таба алмыйча җырламый тора идем. Ләкин синең йомшак мөгамәләң, зәңгәр күзләреңне тутырып елмаеп каравың миңа көч бирделәр, уйланган җырымны көйгә салдылар. Бу җырда мин азатлык һәм матурлык, табигать һәм сөю турында күп кенә нәрсә әйтергә теләдем. Мин җырымның һәрбер сүзенә ачык буяу һәм тавыш яктылыгы бирергә тырыштым. Кырга чыгып, буш биналарга кереп репетиция ясадым. Җырланасы җырымны мин иртәнге һава җилләрендә назладым, кояш нурларында җылыттым. Хезмәтем бушка китмәде. Зал мине тиз аңлады. Мине кат-кат сәхнәгә чакырдылар. Ә мин, нишләргә белмичә, сәхнә артына чыгып, үзем тудырган җыр тәэсиреннән исереп, декорацияләр арасына кереп качтым. Шулвакыт берәү:

— Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис, җылы,— диде.

Бу «берәү» — син идең. Мин, синең шулай якын булуың шатлыгыннан бернәрсә дә әйтә алмыйча, синең зәңгәр күзләреңә карадым. Йотыла-йотыла матур итеп карарга тырышканымны хәзер дә хәтерлим. Шул ук вакытта бу зур бәхеттән әллә кая качасы, чыгып китәсе килгән иде. Ләкин баскан урынымнан кузгала алмыйча тордым. Чөнки сул аяктагы оегымның сүтеге ботинкама тыгып куелган иде. Менә шул чыккан төсле тоелды. Мин аны, сиңа күрсәтмәс өчен, уң аягым белән капларга тырыштым.

Концерттан соң танецлар булды. Син вальска чакырдың. Танец вакытында син:

— Галия, сезгә артистка булырга кирәк... Сез үзегездә булган талантның кадерен белмисез... Мин сезне шефка алырга телим... Сез атаклы җырчы булырсыз... Мин сезнең кара күзләрегезне яратам... Алар әллә ничек ягымлылар... Сезнең күзләрдә мин үземне күрәм. Рөхсәт итсәгез мин сезне озата барыр идем,— диден. Мин шатлана-шатлана риза булдым.

Без чыгып киткәндә, безгә таба бик күп күзләр текәлделәр. Безне озаткан күзләр арасыннан аермачык күренгәне студент Вәли Сафиуллинның кара күзләре булды. Сафиуллин мине ярата иде. Дөрес, ул үзе бу турыда миңа бервакытта да әйткәне юк. Киресенчә, ул һәрвакыт миннән качарга, миңа күренмәскә тырыша иде. Ә мин Сафиуллиннан көлеп йөрдем. Мин бу акыллы студентта, бөтен фәннәрдән иң алда барган укучыда, хатын-кызларның байтагын сокландырган кыюлык, батырлык сыйфатларын күрмәдем. Ул күп вакытта йокымсырап йөри иде. Минем карашымда мондый йокымсыраган салмак кеше озак яши алмас, хәрәкәт яраткан заманыбыз андый кешеләрне онытыр дигән фикер туган иде. Безне озатып калган чагында да, Вәли Сафиуллинның күзләрендә әнә шул бетү, сүнү эзләре күренде.

Искәндәр!

Бу кичне син гаҗәп игътибарлы идең. Сүзләрең җылы, тавышың йомшак иде. Төн буе сине тыңлыйсы килде. Мин бу кичне сине култыклап барганда:

— Нинди бәхет! Мин үземнең киләчәк тормышымны күрәм. Акыллым Искәндәр, мин сине үлгәнче яратырмын, мин сиңа яхшы иптәш булырмын,— дип уйладым.

Син мине тулай торакка хәтле озаттың. Парадный төбенә җиткәч, син йөрәккә ятышлы гаҗәеп бер елмаю белән минем иреннәремә карадың. Ә мин оялып читкә борылдым. Син: «Галия... син нинди акыллы... бу онытылмаслык кичәнең дәвам итүен телим»,— дип, мине кочагыңа алдың. Шушындый рәхәт кочактан соң баскыч буйлап ничек менгәнемне, бүлмәгә ничек кайтып кергәнемне дә хәтерли алмыйм.

Мәхәббәт кешене матур итә. Бүлмәгә керү белән үк, мин көзгегә карадым. Үземнең йөзем-кыяфәтем белән канәгатьләндем.

Төнге сәгать икедә бүлмәдәшләрем кайттылар. Алар, өстәлгә күз төшерү белән үк:

— Оһо, эш зурга киткән икән. Хәер, зарар юк, егете чибәр,— диделәр.

Мин, уйланып утыра-утыра, өстәлгә җәелгән кәгазь өстен «Искәндәр», «Искәндәрем» шикелле бөдрә сүзләр белән язып тутырганмын.

Беренче мәхәббәт яраткан кешеңне матур итеп күрсәтә. Чөнки бу төнне мин, синең турыңда уйлаганда, синдә бер генә дә кер, начар як күрмәдем. Тик Фатыйма гына:

— Яхшы кара, Галия, ул синең җырыңа гына гашыйк түгелме? — диде.

Мин иртүк беркемгә бернәрсә әйтмичә урамга чыктым. Кабан күле буе урамына киттем. Ник? Белмим. Бу көнне дөнья якты, көн җылы иде. Миңа карап күп кенә халык үтте. Янымнан ирлехатынлы бер пар үтеп китте. Эх, кешеләр дә соң... Баруларына гына кара: берсе — алдан, икенчесе — арттан, эт белән мәче шикелле. Кем белә? Бәлки, алар да, бер-берен тизрәк күрер өчен, озын төннәрен сәгатькә карап утырганнардыр.

Искәндәр!

Бу уйлар мине хәзер дә ташламыйлар. Әйе, матур гаиләләр дә бар. Ләкин аларны күп итәсе килә. Юкса начар гаилә аркасында тормышлар ватыла, кешеләр биртелә, гарип тойгылар җәмәгать эшенә начар тәэсир итә.

Үзем хат язам, үзем Кабан күле күперенә басып торгандагыдай уйланам. Яңадан күз алдыма шул чагымны китерәм. Әнә бер пар бара. Нинди бәхет. Бу ике кеше бер-берсенә кысылып, чит кешеләр ишетмәсен дигәндәй, нәрсә турындадыр сер итеп сөйләшеп баралар. Тукта... Әллә күзләрем саташамы? Булмас, ялгышамдыр...

Әйе, күпме генә аһ-ваһ итсәм дә, бу кешенең берсе син идең. Сине тану минем иң матур уйларымны пычратты. Күпме катып торганмын, ачык хәтерләмим, ләкин шул минутта күз алдымнан нинди картиналар узганы исемдә. Әле мине үпкән эзләрең бетәргә дә өлгермәгән... инде аны, янында бара торган кызны үбәсең, кочасың төсле тоелды.

Шуннан соң без гаҗәп озак тоелган ике атна буенча очрашмый тордык.

Мин тормышта, Искәндәр, сөйләп бетергесез кыенлыклар күрдем. Сигез яшемдә ата-анасыз калдым. Тугыз яшемдә туганнарым тәрбиясенә күчеп, бала чагымны, сабый көннәремне бишек тирбәтеп үткәрдем. Мин үксез балалар белән бергә урамда йөрдем. Хаксызга кыйналганым, гаепсезгә иң әшәке сүзләр белән сүгелгәнем бар. Ләкин болар бар да синең ялганыңны белүдән җиңелрәк иделәр.

Синең ялганыңны сизгәннән соң, мин ябыктым, суырылдым.

Икенче очрашуыбызда мин синнән кем белән булуыңны сорадым. Син: «Күрше йортта торучы танышым»,— дидең. Аннары, сораганны көтмичә үк: «Аның белән минем арада шикләнерлек бернәрсә дә юк»,— дип, шикләндерерлек әйберләр сөйләдең. Яшермим, мин сиңа ышанмадым. Чөнки кешеләрнең бозык өлешендә булган әхлаксызлык аларны ялганга өйрәтә. Ялганлау сезне кызартмый да. Сез, ирләрнең бозык өлеше, бер үк «сөям» сүзен ике-өч көн эчендә өч-дүрт кешегә әйтә аласыз.

Казан университетында укыган чакта, мин җәмәгать эше буенча Елга аръягы эшчеләре арасында йөрдем. Анда миңа Галиәкбәр дигән бер эшчене өенә йөреп укытырга туры килде. Гаҗәп бәхетле гаилә иде бу. Квартирасына керсәң — чыгасың килми: коры һавалы, яп-якты өч бүлмә, ванна, кухня. Зур улы — Кызыл Армиядә командир, икенче улы — инженер-төзүче, бер кызы — инженер-химик. Кече кызы музыкага өйрәнә.

Беренче баруымда Галиәкбәр абзый бер миңа, бер карчыгына карап:

— Балаларым командир да инженер булгач, надан калу ничектер килешми. Нехорошо. Хәреф танып булмасмы дим,— дип, дәрес арасында үзенең тормышын сөйләп китте.

Ул өч ай эчендә укырга-язарга өйрәнде. Менә шушы карт белән карчыкның, Советлар илендә яңадан яшәргән, яшьлек белән чәчәк аткан ике кешенең шатлыгын күрсәң — шаккатыр идең. Мин аларга бик тиз ияләштем.

Икенче хат

Искәндәр!

Беренче хатымны сиңа җибәрмәдем. Хатымны җибәрерменме, юкмы — анысын да белмим. Менә хәзер дә синең өчен түгел, үзем өчен язам, үземнең тормышым белән сөйләшкәндәй утырам.

Икенче очрашуыбызда син:

— Галия, мин сине генә яратам. Минем матур тормыш төзисем килә. Яшермим, мин бик күп хатын-кызны күрдем. Ләкин андый тормыштан туйдым. Хәзер бер генә кешене яратасым килә. Ул бер кеше — син, әйдә, бергә тора башлыйк,— дидең.

Мин сине, Искәндәр, артык якын күрдем. Үзең дә үзгәргән, бунтарьлыгың басыла төшкән кебек тоелдың. Без еш очраша башладык. Һәрбер очрашуыбыз матур төш шикелле үтә иде.

Шушындый кадерле минутлар белән матур кыш үтеп тә китте. Яз... чәчәкле яз... Мәхәббәтле яз җитте. Сирень агачлары

чәчәк атты. Сандугачлар сайравы ишетелде. Яшь йөрәкләр йолдызларга карап төрле телләрдә, төрле тавышта «сөям», «яратам» сүзләрен әйтә башладылар.

Бу язда мин рабфакны бетердем. Бу язны без бергә кушылдык.

Очрашу кичәләре гадәткә кереп киткәнгә, син мине зур самавырыңны куеп, тәмле күчтәнәчләреңне хәзерләп көтә идең. Торабара оялуым да бетте. Квартира хуҗаларына да ияләштем. Бу кичәләрдә байтак матур китаплар укылды, күп кенә рольләр өйрәнелде. Спектакльләр булганда, мин, синең бүлмәңдә ялгыз калып, китаплардагы каһарманнар белән сөйләшә-сөйләшә синең кайтканыңны көтә идем. Мин үземнең белемемне арттырырга өйрәндем. Әдәбият, фән, техника китапларын, тарих-политика журналларын һәрвакыт күздән кичереп бардым.

Яшермим, мин алдынгы совет хатыны гына түгел, гүзәл хатын булырга да теләдем. Менә шуның өчен дә мин сине театрдан кайтканда белемемне арттырып кына түгел, матурлыгымны сакларга тырышып та каршы ала идем. Син дә мине буш итмәдең. Бик еш, гримыңны да сөртмичә, миңа, минем яныма, кочагыма ашыга идең.

— Нигә болай? — диюемә, син, мине үбә-үбә:

— Галиям, мин бу рольне син күрсәткән төзәтмәләр белән, сине сөеп, синең турыңда уйлап, син биргән шатлык эчендә уйнадым. Залда яңгыраган алкыш бер миңа гына түгел, сиңа да иде,— дип җавап бирдең.

Кайбер көннәрне мин дә спектакльләргә бара идем. Синең белән бергә шатлана һәм кайгыра торган идем. Ләкин син, Искәндәр, сәхнәдә генә түгел, тормышта да артист булгансың.

Көз көне мин Казан университетының медицина факультетына укырга кердем. Бу көзгә хәтле безнең тормыш яхшы барды. Ә көз көне иртә чәчәк аткан мәхәббәтебезнең хуш исле яфраклары арасында сары яфраклар күренә башладылар.

Иң элек син минем укырга керүемә каршы тордың.

— Артистка булырга теләмисең икән, миңа яхшы иптәш бул... Белемең болай да җитәрлек... Күгәрченнәр күк гөрләшеп торыйк, укыма,— дидең.

Бу беренче бәрелешүдә синең сүзләреңдә ата-бабаларыбызның тавышлары ишетелгәндәй булды. Ләкин мин үземнең иркемне, теләгемне, киләчәгемне корбан итәрлек дәрәҗәдә түгел идем. Чөнки мин, синең әмерләреңә карамастан, университетка укырга кердем.

Шуннан соң без бер бүлмәдә торсак та, сирәк, бары тик төнлә белән генә очраша торган идек. Иртә белән, мин дәрескә киткәндә, син йоклап кала идең, ә кичләрен сине театрдан көтә-көтә мин йокыга китә идем. Чөнки син уникедә кайтасы урынга, бик еш икедә, өчтә кайтырга өйрәндең. Җимерелә башлаган гаиләне ныгыту өчен, «Гаилә дәфтәре» уйлап чыгардым. Минем уемча, без бу дәфтәргә гаилә эчендә булган барлык кимчелекләрне яза барырга, шуны укып төзәлергә тырышырга тиеш идек. Син бу дәфтәргә әйләнеп тә карамадың. Ә мин сиңа болай дип җавап биргән идем:

«Минем характерымны өйрәнеп бет, сорауларыма игътибар ит, ярдәм күрсәт»,— дигән сүзләреңне ничек аңларга? Нигә мин сине өйрәнергә тиеш тә, син мине түгел? Синең бу сүзләрең: «Миңа буйсын, миңа кол бул»,— дию белән бер бит. Бу — бик иске караш. Шулай ук мин синең турыда ялгыштыммыни?»

Әйе, ялгышканмын шул. Чөнки без икебез дә ул чакны мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңлап җитә алмаганбыз. Без бер-беребезгә сокландык. Шуның исереклегендә икенче сайланышны, идея сайланышын, аның кирәклеген сизми калдык. Идея сайланышына тормышка, җәмгыятькә, эшкә карашның бер булуы, сәяси караш бердәмлеге кирәк. Безнең арада идея сайланышы юк иде. Киресенчә, синдә, Искәндәр, бергә тора башлагач та, тышкы матурлык астына яшеренгән иске карашлар чәчәк атарга тотындылар.

Озакламый мин балага уздым. Бу хәл икенче бәрелешүгә сәбәп булды. Башта ике-өч көн эндәшмичә йөрдең. Ә соңыннан:

— Без әле яшь. Синең укыйсың да бар. Мин артист, мин иҗат кешесе. Бала икебез өчен дә тере богау булачак,— сүзләреңнән,— мине яратсаң, минем белән торырга теләсәң, бала китермә! — дип куркытуга күчтең.

Әйе, мин риза булмадым. Мин кыз таптым.

Бала да булгач, кыз да тугач, син әллә нишләдең. Синең һәрбер кыланышыңнан «менә көтмәгән бәла» дигән фикерне укып була иде.

Син көн саен диярлек:

— Бүген дә рольне өйрәнеп булмады. Бу шау-шуда иҗат итеп буламыни?! — дия башладың.

Әйе, гаиләдә бала тавышы яңгырагач, син мине татар кызы булуым өчен дә тирги башладың. «Татар кызы матур итеп сөя белми. Болай да аз матурлыкны балага биреп, үзе буш кала» шикелле сүзләр синең төп сүзлегең булып киттеләр. Шул рәттән

үк минем җәмәгать эшенә катнашып йөрүемне дә тәнкыйть итә башладың:

— Җил куып йөрисең шунда. Шайтан кушамыни сиңа әллә кемнәрне укытып йөрергә? Җыелышларга чабарга берәү дә кушмый, үзең чабасың. Дәрестән башка җиргә йөрергә мин сиңа запрещаю,— дип бармак янадың.

Җәмәгать эшен ташлау, заман агышыннан аерылып калу, синең «запрещаю»ларыңа буйсыну минем өчен үлем белән бер булыр иде. Җәмгыять хисе, җәмгыять өчен яшәү фикере синең «запрещаю»ларыңа буйсынудан өстен булырга тиеш икәнлеген мин сизгән идем инде. Минем гаилә, мәхәббәт турында булган карашларым да әнә шул хисне — җәмгыять өчен файдалы булу тойгысын үстерергә теләүдән туган нәрсәләр. Идея сайланышы булмау аркасында безнең гаиләбезнең җимерелүенә төп сәбәп — җәмгыятькә карата мөнәсәбәтне төрлечә аңлау булды. Мин үзем моны бик соң аңладым. Һәм шуны яхшы итеп аңлагач кына, гаилә фаҗигасе нәтиҗәсендә туган яраларым тиз һәм җиңел төзәлделәр.

Балама мин Кадрия дип исем бирдем. Бу да сиңа ошамады.

Дөрес, сиңа җиңел булмады. Ләкин син бер генә тапкыр да гаиләнең кытыршы яклары турында күзгә-күз карап сөйләшергә, аңлашырга теләмәдең. Тик расходның күплеге турында гына зарлана идең. Авырга алма, Искәндәр, бергә торган чагында мин сине чыгышың, тәрбияң белән шелтәләмәдем. Инде хәзер, ул елларны син бик еш атаң мәзингә охшап китә идең, дип әйтә алам. Син бит балага сөт алырга биргән акчаны да, садака акчасын караган шикелле, әйләндереп-әйләндереп, мең кат карый идең.

Мин бик еш: «Искәндәрнең яхшы яклары да күп, ул үзгәрер әле»,—дип уйлый идем. Һәм, кулымнан килгәнчә, сине үзгәртергә тырыштым. Мин, сиңа төшкән расходны җиңеләйтү өчен, аз сәгатьләр белән генә чикләнгән ялымны төрле учреждениеләргә плакатлар, лозунглар язып үткәрдем.

Кышкы салкында, әче буранда, иртәнге сигездә бер кулыма китаплар кыстырып, икенче кулыма бала күтәреп, яслегә ашыга идем. Син татлы йокыда кала идең. Миңа булышу түгел, «Болай торуның ахыры булырмы, юкмы? Ашарга хәзерләмичә киткәнсең»,— дип, тиргәү сүзләрен генә әйтә идең.

Мин баламның көндәлек дәфтәрен язудан, язылганын укудан рәхәтлек таба идем. Ләкин син, Искәндәр, бу дәфтәргә бер генә тапкыр да күз төшермәдең. Безнең арабыз ерак хәзер. Ләкин

Кадрия синең дә балаң бит. «Көндәлек»нең кайбер өземтәләрен уку файда китерергә мөмкин. Менә алар:

3 ай, 10 көн.

Кадриям мине таный. Нинди шатлык. Димәк, кызымның башы эшли. Тик Искәндәргә иярәшмәве генә мине борчый.

4 ай, 24 көн.

Бүген ял көне. Балам белән сөйләшеп утырдым. Кич белән Галиәкбәр абзыйларга барып кайттым. Бүген Кадриягә бер букет чәчәкләр алдым. Кадрия ачык, якты, ялтыравыклы әйберләр ярата.

6 ай, 20 көн.

Мин биегән чагында, Кадриям кычкырып көлә. Яследә дә үзен бик яраталар.

7 ай, 18 көн.

Кадрия «әннәннә» дип әйтә башлады. Бүген (ял көне) көн буе янымда шаярып утырды. Мин стена газетасына килгән мәкалә-хәбәрләрне төзәттем.

Бер яшь.

Тазалыгына сокланмаган кеше юк. Бүген мин аңа яңа күлмәк кигездем. Иптәшләр дә котларга килделәр. Тик Искәндәр генә Кадриянең туган көнен оныткан. Ул бүген төнге икедә генә кайтты. Бүген еладым.

Бер яшь, 2 ай.

Кадрия йөри башлады. Китап сорап йөдәтә.

Бер яшь, 4 ай.

Кадриям кызамык белән авырый. Больницага салдым. Һәр көн янына барып йөрим. Өйдә шундый күңелсез...

Бер яшь, 9 ай.

Кичә Кадрияне демонстрациягә алып чыктым. Өйгә кайткач, бик озак «шулай, шулай» дип, урамдагыча маршлап йөрде.

Искәндәр!

Хатыңда балаларның көндәлек тормышлары турында язуымны сорыйсың. «Миндә дә аталык хисе кузгалды»,— дисең. Эч пошканнан гына әйтелгән сүз түгелме бу?

Балаларым яхшы үсә. Атасыз үсүләреннән башка зарланырлык нәрсәләре юк. Кадриям МТС янындагы балалар бакчасына йөри. Бик күп җырлар белә.

Кичләрен без аның белән икәүләп җырлыйбыз. Безгә карап Рафаэль дә җырлаган булып кылана.

Искәндәр!

Син Рафаэль тугач, нинди тамаша ясаганыңны хәтерлисеңме? Аны онытуы кыен. Син бит больницага мине каршы алырга да бармадың.

Мин больницадан кайтып хәл җыярга да өлгермәдем, син:

— Сиңа, Галия, артист хатыны булырга түгел, яслегә бала караучы булып кирәргә иде, хәер, мин сине гаепләмим, үзем гаепле, уйламыйча өйләнүем өчен гаепле, сәхнә кешесе һәрвакыт ирекле булырга тиеш... Ә мин гаилә белән, балалар белән богауландым... Мин синең белән артык тора алмыйм... Үсмәгән балалар өчен үземне корбан итә алмыйм... Хуш... Мине эзләмә,— дидең дә чыгып киттең.

Дөрес, йөрәгемнең әллә кай почмагында сиңа карата җылы хисем бар иде әле. Шулай да мин сине туктатмадым. Син, ихтимал: «Бу елар, муенымa асылыныр, миннән башка тора алмас, чакыртыр, ялварыр»,— дип уйлагансың.

Мин ялварырга да, тезләнергә дә теләмәдем. Башта миңа бик кыен булды. Син чыгып киткәндә, минем бөтен байлыгым— ике балам иде.

Мин синнән бер тиен дә сорамадым, үзең аңлап бирмәдең. Хәер, сине хәзер театрда эшләми, киткән дип тә сөйләделәр.

Мине бәладән коткаручы кешеләр университет директоры Даутов иптәш белән партком секретаре Николаев булдылар. Галиәкбәр абзый белән студентлар коллективы да күп ярдәм иттеләр. Аларның миңа күрсәткән туганлыклары сыйнфый туганлык иде.

Бу соңгы бер ел эчендә без бөтенләй күрешми тордык. Ахырысында институт тәмам булды. Бер айдан соң, ике баламны күтәреп, Әдрәс районына врач булып эшләргә киттем.

Өченче хат

Искәндәр!

Син үзеңнең хатыңда: «Тормышың ничек уза? Балалар мине сагынамы? Авылда күңелсез түгелме? Берсен дә калдырмыйча яз»,— дисең. Кызыксынуың өчен чын күңелдән рәхмәт.

Мин район үзәге булган Әдрәс авылына килеп төштем.

Бу авыл миңа бик ошады. Монда иске авыл эзләрен күрсәтеп торган мәчет тә, фәлән дә юк. Авыл уртасыннан боргаланып-сыргаланып агым су үтә. Су буена алмагачлар, чия һәм шомырт

агачлары тезелгән. Яз көннәрендә авыл ап-ак чәчәкләргә күмелә. Авылдан бер километрда урман эчендә ял йорты урнашкан. Авыл уртасыннан поездлар уза. Кырларда тракторлар җыры яңгырый. Таш юлдан грузовик һәм җиңел машиналар йөри.

Ләкин авылда тора башлау белән миңа бик күп кыенлыкларга очрарга туры килде. Амбулатория — врач пункты — ташландык хәлдә иде. Бинасы җимерек, салкын. Миңа хәтле пункт белән бер фельдшер мөдирлек иткән. Ул пунктка килгән спиртны эчү һәм ялган справкалар язып өләшүдән башка бернәрсә белән дә кызыксынмаган. Башка медицина эшчеләре дә эшкә салкын карарга гадәтләнгәннәр.

Райздрав урындыгына вакытлыча утырган тәҗрибәсез 20 яшьлек кыз үзеннән чыгып бернәрсә дә эшли алмый.

— Монда мин ничек эшләрмен икән,— дип котым очты. Аптеканың ярлылыгы эчне пошырды. Берничә тапкыр: «Әллә ташлап качып китимме?» — дип тә уйладым. Ләкин китмәскә, киртәләрне җимерергә булдым.

МТС эшчеләренең ярдәме белән тиз арада гына амбулатория бинасын чистарттым, түшәмен, стеналарын агарттым. Аптека мөдиренә кискен рәвештә иң кирәкле даруларны булдырырга куштым. Авыруны тыңлап карау, градусник куллану, авыруга карточка тутыру шикелле нәрсәләрне керттем. Авылларга чыгып йөрергә план төзедем.

Ашлык җыю вакыты җитте. Авылда берүзем калып, эшчеләремне участокларга беркетеп, төрле авылларга чыгарып җибәрдем.

Шулвакыт эчендә районыбызда медицина эшен югары дәрәҗәгә күтәргән өч вакыйга булып алды.

Беренче вакыйга — 6—7 яшьлек бер кыз баланың Әдрәс суына бату вакыйгасы. Бу кызны мин элегрәк тә белә идем. Аның исеме — Нәфисә. Ул бик еш минем Кадриям белән уйный иде. Нәфисә йөзә белмичә су кереп, тирән чокырга очрап баткан. Балалар шау-шуына җыелган халык аны берничә минуттан соң гына судан үлек килеш чыгарган.

Хәзер дә күз алдымда. Әнә ул өстәлдә ята. Тәне күгелҗем төскә керә башлаган. Баласының юеш чәчләрен үбә-үбә ана елый. Аяк очында нәрсә эшләргә дә белмәгән ата:

— Доктор, берәү генә бит... Шулай ук үлдемени?— ди.

Халыкны чыгарырга, ананы алып китеп тынычландырырга куштым. Баланың авызын ачып сулыш алу эшләргә тотындым. Пульс бөтенләй юк. Тәрәзәне ачтырып, һаваны алмаштырдым.

Кулларым талганчы сулыш ясадым. Күзләремнән яшьләр тамарга тора. Йомшаклыгыма ачуланам. Докторга болай изрәргә ярамый дип, үземә батырлык кертергә тырышам. Ә үзем сулыш ясый-ясый авыз эченнән генә: «Терел, терел, бәгырем, яңадан уйнарсың, Кадрия белән йөрерсең... терел...»,— дим. Баланың атасы нәрсәдер сөйли: «Ардыгыз инде, доктор, булмый, күрәсең»,— ди бугай. Ләкин мин ишетмим. Күрше бүлмәдә баланың анасы — Зәйтүнә апа акыра: «Баламны җәфалыйсыз гына...» Монысын да ачык ишетмим. Һаман сулыш ясыйм, һаман авыз эчен арчыйм.

Һәм... шатлыгымнан күз яшем тамды... Йөрәк тибеше кузгалды.

Бөтен өмет өзелгәч, бичара ана елый-елый тавышсыз калгач, бала үзенең тере икәнен белгертте, сулыш алган кебек булды, авызыннан су акты. Күз кабакларын селкетте. Әйе, баланың йөрәге тибә башлады. Шуннан соң миндә көч арткандай булды. Мин бөтен көчемне баланы саклап калырга, тибә башлаган йөрәкне туктатмаска тырыштым. Бала исән калды.

Икенче вакыйга күрше авылда булды. Беркөнне үземне Чымты авылына авыруны карарга алып киттеләр.

Сәкедә, толыплар белән томаланып, бармаклары белән мендәргә ябышып, 18—20 яшьлек бер кыз ята. Температурасын карадым — 39°. Пульсын санарга дип кулына сузылсам — кан. Карчык:

— Кузгатмагыз, узар... Зыяндашлы бала ул... Һәр ел шулай була торган иде,— ди.

Кулларымны юып авыруга ярдәм бирергә тотындым. Ул бала тапкан. Ләкин соңгылыгын алмыйча калдырганнар. Мин тиешле ярдәмне күрсәттем дә карчыкка:

— Авыруга тынычлык кирәк, беркемне дә кертмә,— дип, авыл Советына киттем.

Авыру бер атнадан аякка басты.

Өченче вакыйга — төрле җирдә дәваланып та сәламәтләнә алмаган бер картның Әдрәскә килүе булды. Аны: «Синдә рак»,— дип куркытканнар. Карт миңа килгәндә бөтенләй ябык иде; яңаклары ябышкан, күзләре эчкә баткан, үзе көчкә йөри.

— Ашый торган ашымны йота алмыйм,— ди. Шул уңай белән ике-өч көн эчендә үземдә булган бөтен әдәбиятны яңадан карап чыктым. Һәм шуннан соң гына картка:

— Куркырлык бернәрсә дә юк. Синдә рак түгел,— дидем. Кулымнан килгәнчә үзен дәваларга тотындым. Шушындый

чаралардан соң авыруым аз гына булса да ашый башлады, баш чатнавы бетте, тыныч йоклый торган булды.

Бу өч вакыйга минем рухымны күтәрде, кыюлыгымны арттырды.

Ахырысында квартирага да күчтем. Мең бәла белән аннан такта, моннан кадак, тегеннән бур җыеп, ремонтны очлап чыктым. Аптеканы икенче бинага күчердек. Ләкин бу эшләрнең ахырына чыгар өчен күп көч түгәргә, йокы калдырырга туры килде. Болар һәммәсе дә беренче айларымда ук минем өстемә төшкән иде. Авылларга да чыгарга туры килә иде. Аннан арып, тузанга батып кайтасың. Өйгә килеп керү белән ике яктан ике балам сарыла. Алар белән рәхәтләнеп, уйнап-көлеп йокларга ятасың.

Үткән ел балаларым өчен радио куйдырдым. Еш булмаса да, балаларым белән бергә су керергә барам, урманга чыгам. Пианино алырга җыенуымны яздым шикелле. Ләкин балалар өчен болар гына җитми. Аларга тере кеше дә, ата да кирәк.

Синең белән аерылуга өч еллап вакыт узгач, Кадрия бик еш:

— Әнкәй, нигә безнең әтиебез юк? Минем әтием кемгә охшаган? Ник ул хат язмый? — дип сораштыра башлады.

«Без аерылдык, сез ятим калдыгыз»,— дип, иске заман сүзләре белән кәефләрен бозасым килми. Ата турында сүз чыккан саен мин аларга:

— Ул Мәскәүдә укый. Укып бетергәч кайтыр. Сезгә бүләкләр китерер,— дип сөйлим.

Балаларга шулай сөйләгәч, гаилә тормышым белән кызыксынган кешеләргә дә «ирем читтә» дип ялганнарга өйрәндем. Кем белә, бәлки гайбәттән саклану өчен генә дә мин «ирем бар» дияр идем. Чөнки авылда тол хатынга — ире булмыйча балалар асраган кешегә — начар күз белән карау бетмәгән әле.

Искәндәр!

Бу хатны мин, өзеп-өзеп, ялгыз калган минутларымда язам. Кайчагында шундый хатлар язуыма кәефем дә китә. «Ни өчен язам?» — дип, үз-үземә сораулар бирәм. Йөрәккә тулган шул. Бушанасым килә.

Мин сиңа балаларыма «әткәй» табуым турында язарга уйлаган идем. Бу гаҗәп эш болай булды:

Кичләрнең берсендә, студентка чагымнан калган дәфтәрләрне актарганда, корзина төбеннән бер рәсем килеп чыкты. Бу рәсем минем белән бергә укыган, миңа яшерен мәхәббәт тотып йөргән рабфак студенты Вәли Сафиуллин рәсеме иде. Рабфакта чакта мин стена газетасында эшли идем. Шуннан эләгеп калган рәсем,

ахры. Рәсем караган кичне, Искәндәр, мин сине уйламаска тырыштым. Ирекле-ирексез гел Вәли Сафиуллин тирәсендә әйләндем. Һәм кинәт яңа дөнья ачкан шикелле: «Вәлинең фамилиясе дә минем фамилиям белән бер, мин дә Сафиуллина бит. Кадрия: «Әткәй кайда? Ул кемгә охшаган?» — дип сорый. «Менә синең әткәең. Менә минем ирем»,— дип, Вәлине үземә «хыялый ир» иттем. Бу кичне мин Сафиуллин рәсемен, рамага куеп, стенага элдем. Ә иртәгесен Кадрия белән Рафаэльгә:,

— Карагыз, әткәегез нинди чибәр. Ул тиздән кайтыр,— дип, аларны хыялый аталары белән таныштыра башладым.

Рәсем төшерергә яратуымны син яхшы беләсең. Тора-бара Вәли рәсемен үз рәсемем белән янәшә куеп төшердем — икәү бергә төшкәндәй чыкты.

Бервакыт үтенеп сорагач, син минем белән рәсемгә төшәргә барган идең. Шунда син Кадрияне итәгеңә алып төшкән идең. Бу рәсем миндә әле дә саклана. Алар икәү. Шуның берсеннән синең башыңны кисеп алып, Сафиуллин башын куеп төшердем.

Бу рәсемнәрнең барысы да стенага эленделәр. Аларга үзем дә, балалар да, күршеләр дә ияләштек.

Яшермим, бик еш Вәлине күрәсе килгән көннәрем була. Хәтта кайтып кергәч, аның рәсеменә карап: «Вәли, син хәзер кайда? Галия исемле «хатының» барлыкны үзең беләсеңме? Галия — синеке!» — дип хыялланам.

Балаларга ата табылды. Ләкин «хыялый ата»ны чын ата итеп саклап баруы бик кыен булды. Кадриянең: «Әткәй ник хат язмый?» — дип соравына каршы, үз-үземә хатлар язарга туры килде. Соңра һәр ун көн саен мин, башымнан уйлап чыгарып, Вәлидән дип, үземә һәм балаларга сәлам хатлары китерергә өйрәндем. Хат алгач, җавап та язарга кирәк була. Айга бер-ике тапкыр минем белән бергә Кадрия дә «ата»сына хат яза.

Бу эшнең ахыры куркыта. Балалар үскәнче бу «сер» ачылмасын гына иде. Ә үскәч, мин аларга үземнең юләрлегемне әкият итеп сөйләрмен.

Ләкин үткән ел әлеге суга баткан Нәфисәнең анасы Зәйтүнә апа, газета китереп, бик каты куркытты:

— Кара әле, Галия, монда синең иреңне язганнар, рәсемен дә төшергәннәр,— диде.

Вәли Сафиуллин, Казан рабфагын бетергәннән соң, Мәскәүгә киткән. Университетның физматында укыган һәм төннәр буена математика өстендә утырган. МГУны бетергәч, Мәскәү урта мәктәпләренең берсенә математика укытучысы булып кергән. Анда

вузлар да сокланырлык рәвештә математика кабинеты оештырган. Укыту эшенә үзенең модельләрен керткән, профессорның әйтүенә караганда, Сафиуллин математиканы иң күңелле, иң җиңел дәрес иткән. Аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләгәннәр. Мәкаләдә әнә шулар язылган.

Күпме уйланып утырганмын — ачык хәтерләмим. Тик, болай булгачтын, Вәлинең «хыялый ата» булуы ачылыр, миннән көләрләр, дип курка башлавым гына исемдә. Аннары «Вәлине Әдрәстә кем күрсен соң?» — дип, үз-үземне юатып та куйдым.

Ярый. Тыныч йокы яки хәерле иртә, Искәндәр. Вәли турында уйлап, өченче хатымны шуның белән тәмам итәм.

Дүртенче хат

Искәндәр!

Хатларымда язган вакыйгалардан соң, үз-үземә ачуым артты: «Син, Галия, иске карашлардан арчынып бетмәгәнсең, гаиләне бик югары күтәрәсең, романтикага бирелеп, тормыштан читкә тәгәрисең»,— дип үземне тиргәргә тотындым.

Ял көннәремдә балаларымны җитәкләп, Мәфтуха апайга барам. Ул колхоз председателе булып эшли. Без аның белән колхоз турында сөйләшәбез. Китаплар укыйбыз. Мин Мәфтуха апайның көннән-көн үсә барганын күрәм.

Кайчагында бу сөйләшү чәенә күрше хатын-кызлар да, хатын-кызлар баш булганны карап тору өчен, ирләр дә керәләр.

Мәфтуха апай — бик зирәк кеше. Икенче баруымда, ул мине, авыру карарга дигән булып, Миңниса әбигә алып китте. Тик юлда барганда гына:

— Син инде бернәрсә дә белмәгән бул. Миңниса әби сине бик ошаткан. Кунакка чакыра үзеңне. Башка хатын-кызлар да булачак. Син безгә авырудан саклану, балаларны ничек тәрбия итү турында сөйләрсең,— диде.

Без барып кергәндә, Миңниса әби бер хатын белән өстәл хәстәрләп йөри иде. Өе чиста. Идәннәр сап-сары итеп юылган. Тәрәзәләргә ап-ак пәрдәләр корылган. Стенада Ленин рәсеме.

Озакламый егермеләп кеше җыелды. Мин санитария-профилактика турында сөйләп алдым. Миңниса әби, иске заманны искә төшереп, ачлы-туклы яшәвен сөйләде. Аның улы — районның иң яхшы тракторчысы — Мәрданша гармонь алып уйный башлады. Җыр күтәрелде.

Авылга килгәннән бирле бер генә тапкыр да җырлаганым юк иде. Ә монда түзмәдем — җырлап җибәрдем.

Җыр бетүгә бии башладылар. Тәрәзә алды халык белән тулды. Бер минутлык тынлыктан файдаланып, Мәфтуха апай ашлык җыю кампаниесенең җитүе һәм ничек эшләргә кирәклек турында сөйләде. Үзенең колхозындагы алдынгы кешеләрнең исемнәрен дә әйтеп үтте...

Искәндәр!

Мин сиңа байтак нәрсә турында язарга уйлаган идем. Ләкин көтмәгән бер вакыйга килеп чыгып, хатымны чуалтты.

Беркөн амбулаториядә авыруларны карап бетереп китәргә җыенганда гына, ял йорты докторы кереп:

— Ирең безгә ял итәргә килде. Синең турыда сөйләгәч бик шатланды. Бүген яныңа килә,— диде.

Кулымда градусник иде — төшеп ватылды. Телсез калдым. Нинди ирем? Искәндәрме? Вәлиме?

Ял йорты докторы чыгып киткәч, ярты сәгать чамасы кабинетымда бикләнеп утырдым. Авыр уйлардан башым авырта башлады. Өйгә кайтырга җыенып, амбулатория ишеген ачтым. Ишек төбендә Вәли Сафиуллин иде.

— Мөмкинме? — диде.

— Рәхим итегез...

Без кабинетка кердек. Ул бик нык үзгәргән. Йокымсыравы беткән. Олылык төсе кергән. Тик аның күзләрендә генә элекке Сафиуллин билгеләре калган. Йөзендә — шатлык.

— Әдрәстә очрашырбыз дип, кем уйлаган? Сез мине оныткансыз да инде. Ә мин рабфакны, рабфак белән бергә сезне дә бик еш искә төшерәм,— дип сөйләп китте, мине уңайсызлыктан чыгарырга тырышты.

Бер ярты сәгать сөйләшкәннән соң:

— Буш булсагыз, мине чәй белән сыйлар идегез. Ял йортында чәйне көнгә бер генә тапкыр бирәләр, гаиләгез белән дә таныштырырсыз,— диде дә урыныннан кузгалды.

Башта мин аны өемә чакырырга да, чакырмаска да белмәдем, чөнки балаларым әткәй дип Вәлинең муенына асылынулары мөмкин. Рәсемнәрне күреп мине дә, үзен дә уңайсыз хәлдә калдырыр. Мин шулай уйладым. Ләкин шулхәтле озак көрешми торганнан соң, «вакытым юк» дип, Вәлине дә кайтарып җибәрергә теләмәдем.

— Әнә теге ак йортны күрәсезме? Мин шунда торам инде. Өс башны алыштырасы бар. Ун-унбиш минуттан соң шунда килергә булсагыз, мин сезне вареньелап чәй белән сыйлармын,— дидем.

Ул риза булды.

Мин, өйгә кайтып, балаларны урманга җиләккә җибәрдем. Самавыр куеп, өстемне алмаштырдым. Стеналарга эленеп куелган рәсемнәрне кузгатмаска булдым. Сер ачылгачтын ахырына кадәр ачылсын, дидем.

Самавыр өстәлгә менү белән, Вәли килеп керде.

— Сезнең квартирагыз шәһәр квартираларыннан бер дә ким түгел,— дип, керүенә бүлмәләремне мактый-мактый, күзен стеналарга төшерде. Рәсемнәрдә үзен күрүгә гаҗәпсенде. Ләкин эндәшмәде. Чәй алдында гына, бер-беребезгә ияләшә төшкәч кенә, түбәндәгечә сөйләшүләр китте:

— Карагыз әле, Галия,— диде ул,— мин ял йортына килеп төшкәннең икенче көнендә үк миңа: «Сезнең хатыныгыз биредә доктор булып эшли»,— диделәр. «Мине берәр кеше белән бутыйлар, күрәсең, әйдә, кызык булсын»,— дип уйладым да, «Хатының монда» дип әйтүчеләргә: «Әйе шул, минем хатыным монда эшли»,— дия башладым. Ләкин ял йорты докторы да шул ук сүзне әйткәч, «Сезнең хатыныгыз Галия Сафиуллина»,— дигәнне дә ишеткәч, борчылырга тотындым һәм сезне күрәсем килде. Чөнки рабфакта чакта мин хыял итеп йөргән Галиянең хәзер кешеләр тарафыннан «Синең хатының Галия» дип йөртелүе минем өчен рәхәт иде. Стенада үземнең рәсемнәремне күрәм. Ләкин бит минем сезнең белән бервакытта да рәсемгә төшкәнем юк. Миңа охшаган кеше кем ул? Ялгышмасам, сез артист Искәндәргә чыккан идегез. Аерылдыгызмы әллә?

— Искәндәр белән мин күптән аерылдым. Шуннан соң берәүгә дә чыкмадым, дияр идем — хата булыр. Чөнки рәсемдәге кеше «ирем» булып хисаплана. Балаларым аңа «әткәй» диләр.

— Кем соң ул?

— Ул — сез. Мин ул рәсемне рабфактан калган дәфтәрем арасыннан таптым.

— Димәк, сезне минем хатыным дип йөрүләре дөрес?

— Әгәр дә бу эш сезне борчыса, мин хәзер үк рәсемнәрне алып яшерә алам һәм, телисез икән, ял йортына барып: «Бу Сафиуллин минем ирем түгел»,— дия алам. Ләкин сез монда күп булса тагын бер ай торырсыз. Авырсынмасагыз, мин сездән бу «кәмит»нең дәвам итүен сорар идем.

— Ягъни?

— Ягъни гаиләгез турында сүз чыкканда...

— Мин өйләнмәгән, минем гаиләм юк...

— Минем турыда сүз чыкканда, дим мин. Галия минем хатыным, иптәшем, дип әйтегез.

— Ни өчен? Нигә? Һич аңламыйм.

— Вәли, сез миңа бик авыр сораулар бирәсез. Курыкмагыз, мин сезгә ике баламны тагарга, сезгә кияүгә чыгарга уйламыйм. Бу бары сезне һәм үземне кешеләр алдында кыен хәлдән чыгару өчен генә. Юкса йә сез, йә мин, икебезнең берсе хәзер үк моннан китәргә тиеш.

— Беребез дә китми, мин риза. Тик үзем белмичә, мин ничек итеп сезнең ирегез булганмын? Шуны беләсе килә.

— Анысын хәзергә сорамагыз. Мин аны сезгә... Димәк, риза?

— Риза.

— Рәхмәт,— дидем дә кулымны суздым һәм аны балаларның яшьләре, исемнәре белән таныштырдым. Үз өенә килгән кебек, миңа кереп йөрүен сорадым. Балалар белән әткәйләре шикелле сөйләшүен үтендем.

Шуннан соң ул көн саен безгә килеп йөри башлады. Балалар аңа бик тиз ияләштеләр. «Әткәй», «әткәем» дип, артыннан калмыйча йөриләр. Бергә урманга чиягә йөрдек. Төрле китаплар укылды. Студент чаклар искә төшерелде. Мин үземнән курыктым. Вәлине чын-чынлап ярата башлаганымны сиздем. Аның белән ничек саубуллашырмын, кушылмас борын ничек аерылырмын, дип йөрәгем сызлады.

Менә хәзер дә, шушы хатны язып утырганда да борчылам. Вәли көн саен миннән үземне аның хатыны дип халыкка белдерүемнең сәбәбен сорый. Мин «иртәгә», «иртәгә» дип сузып килдем. Соңгы соравына «китәр көнеңдә әйтермен» дидем. Иртәгә ул китә. Ничек аңлатырга? Кайчагында миңа ул мине элеккечә үк ярата төсле тоела. Хәтта шаярып утырганда:

— Галия, чынлап та мин синең чын ирең — иптәшең булсам, ягъни без бергә кушылсак, ни әйтер идең? — дип сораулар да бирә.

Ләкин мин мондый сораулар бирелгәндә шаярып әйтелгән сүзгә борам. Чөнки мин аның мәхәббәтенә җавап бирә алмам төсле. Ике балалы булуым, рабфакта аңардан көлеп йөрүем — синең белән торуым аның исенә төшәр, ул борчылыр, борчылса да әйтмәс. Әйтми калуы аңа газап булыр. Ә мин аның газап күрүен теләмим.

Иртәгә Вәлинең китү көне. Башым һич эшләми. Гел аның турында уйланам. Бу хатны шунда өзеп: «Вәли, мин сине яратам

бит, лэкин без синең белэн хыялда гына ир белэн хатын булып калырбыз»,— дип, хатны аңа борасы килэ.

Берэү ишек шакый.

Вэли: «Иртэгэ соңгы кич, озак утырырга килермен»,— дигэн иде.

— Ярыймы? — ди ул.

Искэндэр!

Күрше бүлмэдэ Вэли утыра. Яза алмыйм, кулларым калтырый. Вэли:

— Иртэгэ китэм, Галия, лэкин китэсем килми. Иялэштем. Шулай да китэм. «Хыялый ирең» булуымның сэбэбен белэсем килэ. Тагы да ярты айга калырга мөмкин иде. Калсам, бөтенлэй китэ алмам дип куркам. Серне ачыгыз,— ди.

Мин, «хэзер» дип, икенче бүлмэгэ керэм һэм шушы сүзлэрне язам. Болай гына сөйлэп, мин аңа барыбер аңлата алмам. Чөнки үземне бик начар хис итэм. Шуңа күрэ дэ сиңа язылган хатларны Вэлигэ бирергэ булдым. Укысын да телэсэ ничек аңласын. Хэзер янына чыгам да:

— Мэ, дустым, шуларны укып чык. Бу — минем тормышым. Шуннан барысын да аңларсың,— дим.

Хуш, Искэндэр. Сау бул! Хуш, Вэли! Синең белэн саубуллашуы миңа бик авыр булыр.

Галия

Автордан

Кадерле укучым!

Быел яз көне миңа бер гаилэдэ кунакта булырга туры килде. Бу гаилэ үзенең шатлыгы, бэхетлелеге белэн мине бик кызыктырды. Шулхэтле тату торган гаилэлэр эле бездэ хэзер генэ күбэеп, чэчэк атып баралар. Мин аларга һэр кич саен кереп йөри башладым. Һэм соңгы баруларымның берсендэ:

— Сез бик яхшы торасыз. Беренче танышуыгыз ничек булды? Сөйлэргэ ярыймы? — дип сорадым.

Яңа дусларым миңа сез укып чыккан элеге хатларны чыгарып бирделэр һэм:

— Сез язучы бит, файдаланырга мөмкин,— диделэр.

Мин, хатларны укып чыгу белэн, фамилиялэрне һэм район, авыл исемнэрен алмаштырып, аларны, дусларымның рөхсэте белэн, матбугатка чыгарырга уйладым.

1935 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Хатларында әсәрдәге вакыйгаларга Галия үзе генә бәя бирә. Әгәр дә хатларны Галия урынына Искәндәр язган булса, бу вакыйгаларга ул нинди бәя бирер иде?

Галия белән Искәндәргә автор бәясе нинди?

Галиягә, Искәндәргә һәм автор бәясенә сезнең карашыгыз нинди?

2. Өченче хатында Галия Миңниса әбиләргә кунакка килүе турында яза. Гармун тавышы ишетү белән, йорт янына авыл халкы җыела. Мәфтуха апай аларга эш турында сөйли һәм җыелган халыкка сораулар бирергә тотына. Сораулар һәм җаваплар мондый:

— Камәр апа, синең Фатыйма исемле кызың бар иде, ул хәзер кайда һәм кем булып эшли?

— Беләсең ич, Буа районында агроном ул хәзер.

— Ә син нәрсә тик торасың? Синең дә бит, Гайшә җиңги, Шәмсенур исемле кызың бар иде. Кайда соң ул?

— Ул Казанда инженер булып эшли.

— Ә синең кызың Халисә кайда?

— Халисә Мәскәүдә укый. Судья була ул.

— Ә син, Җиһанша абый, ник дәшмисең? Синең дә бит Майшәкәр исемле кызың бар. Ул хәзер кайда?

Җиһанша абый башта мыек астыннан елмайды, тамак кырды. Шуннан соң гына:

— Минем Майшәкәрем — трактористка. Менә минем кызым кем,— дип мактанып җавап бирде.

Миңниса әби йорты белән бәйле бу вакыйгаларның барысына да бәя бирегез. Аларның әсәрдәге башка вакыйгалар белән бәйләнеше турында сөйләгез.

3. Әсәренең исемен Гадел Кутуй «Тапшырылмаган хатлар» дип атаган. «Тапшырылмаган» дигән сүзгә басым ясаган. Повестьтагы тапшырылмаган хатлар турында язылган урыннарны табыгыз һәм авторның ни өчен әсәрен шул исем белән атавын аңлатып карагыз.

4. Әсәрдә күтәрелгән темаларны атагыз.

5. Сез атаган темалар арасында үзара конфликтка килгәннәре булмаса, димәк, сез әсәрдәге темаларның барысын да күреп бетермәгәнсез дигән сүз. Әсәр сюжетын тагын бер тапкыр күз алдыгыздан кичерегез һәм үзара каршылыкка килгәннәрен табыгыз.

6. Садри Җәләлнең «Дим буенда» повестенда күтәрелгән теманы исегезгә төшерегез. Бу әсәр темасын «Тапшырылмаган хатлар» повестендагы мәхәббәт темасы белән чагыштырыгыз. Охшашлыкны һәм аерманы әйтегез.

7. Галия мәхәббәте турында сөйләгез.

Контроль эш өчен биремнәр һәм сораулар

1. Г. Бәшировның «Сиваш» повесте ничек язылды» мәкаләсе әсәрнең үзен өйрәнүгә ярдәм итәме?

2. Әсәрнең чикләнгәнлеге дип нинди сыйфатка әйтәләр?

3. «Сиваш» повестенда идеологиянең чагылышын ничек күрергә була?

4. Пахомовның кичерешләре һәм үлеме турында сөйләгез.

5. «Тапшырылмаган хатлар» повестеның исеме әсәр эчтәлеген ачарга ничек ярдәм итә?

6. «Тапшырылмаган хатлар» әсәренең эчтәлеге.

7. Повестьның татар әдәбияты традициясен дәвам итүе.

8. Стиль дип нәрсәгә әйтәләр?

9. «Тапшырылмаган хатлар» әсәренең стиле.

10. Галия мәхәббәте турында сөйләгез.

Мәхмүт Галәү
(1886—1938)

Мәхмүт Галәү 1886 елның сентябрь аенда Казан губернасының Арча өязе Ташкичү авылында туа. Башлангыч белемне авылда хәлфә хезмәтен башкаручы этисе Галәветдиннән ала.

Казанга килеп, мәдрәсә тәмамлый. Әстерханга барып, укытучы булып эшли. Монда булачак әдип революционерлар белән таныша. Аны хәтта РСДРП әгъзасы итеп тә алалар. Шул ук вакытта Мәхмүт Галәү партия чыгарган «Туп» исемле сатирик журналны оештыручы һәм аның иң актив авторларының берсе була.

Журналга охранка тарафыннан берничә мәртәбә арест салына. Революциягә ачыктан-ачык чакырып язган мәкалә авторларын эзәрлекли башлыйлар. Алар арасында Мәхмүт Галәү дә була.

Ул, охранканың очлы күзеннән качып, Оренбург шәһәренә китә. Монда типографиядә, нәшриятта эшли һәм мәгариф эшләре белән кызыксына. Газеталарда, журналларда шул темага күп санлы мәкаләләр язып бастыра. Шәкертләр өчен «Төрки уку» исемле дәреслек тә чыгара.

1914 елны үзе яңа нәшрият оештыра һәм аңа, дәреслекләр бастырып чыгару юнәлешен күздә тотып, «Белек» дип исем бирә. Бу елларны әдип «Кармак» исемле сатирик журнал чыгаруда актив катнаша.

Октябрь революциясеннән соң Мәхмүт Галәү Башкортстандагы мәгариф оешмаларында һәм Кызыл Армиянең политик идарәсендә җаваплы эшләр башкара.

1925 елда әдипне, хәреф җыючылар укыту мәктәбен оештыру өчен, Мәскәүгә чакыралар. Мәктәпне оештырып, эшен җайга салгач, Мәхмүт Галәү фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый. 1924 елда «Пугач явы», тагы ике елдан «Салам

торханнар» исемле пьесаларын иҗат итә. Тагын бер елдан «Каяу», аннан соң «Төеннәр» исемле хикәяләр җыентыкларын бастыра. 1933 елда беренче зур әсәре — «Кабулсай» исемле романы дөнья күрә.

Үзенең иң мәшһүр «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнарын әдип гомере буена яза. 1877 елгы ачлык вакыйгаларыннан башланып киткән бу зур хезмәт барлыгы дүрт кисәктән торырга тиеш була. Баштагы икесен тәмамлап, китап нәшриятына тапшыра. Әмма романнар Казанда басылмыйлар. Бу әсәрләрдә сыйнфый көрәшкә игътибар аз бирелгән дип, әсәрләрне кире кайтаралар. Шуннан соң әдип романының берсен башка кешедән тәрҗемә иттереп, берсен үзе тәрҗемә итеп, Мәскәүдә русча бастыра.

Мәхмүт Галәү, бик күп башка талантлы татар әдипләре кебек, 1938 елда төрмәдә һәлак була. Үзе белән бергә аның кулъязмалары да югала.

Татар телендә язылган кулъязмалар табылмау сәбәпле, романнарны русча вариантыннан татарчага тәрҗемә итеп бастырырга мәҗбүр булалар.

Мәхмүт Галәүне татар әдәбияты тарихында күренекле язучыларның берсе дип бәяләргә мөмкин. Аның «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнарын татар әдәбиятының иң күркәм әсәрләре рәтенә кертә алабыз.

БОЛГАНЧЫК ЕЛЛАР

ИЛ ТЫНЫЧ ЧАКТА

I. Каклаган казны коймакка төреп, коймакны каймакка манып

Төш вакытлары җитәрәк, көн кисәк үзгәреп китте. Тау-тау ак болытлар, куерып, салынкы кара-кучкыл яңгыр болытларына әверелделәр. Каты җил өй түбәсе саламнарын тузгыта, тирәкләр, яшь ботакларын җиргә чаклы иеп, зарланышкан сыман шаулаша башладылар. Һавага, күбәләк өере шикелле, ап-ак шомырт чәчәкләре тузгып очты. Аннары шыбырдап яңгыр яварга тотынды.

Җылы бөркеп, тирес исе аңкытып яткан буразналар өстеннән кешеләр башларын күтәрделәр. Яңгыр коеп яварга керешкәч, алар ышык урыннарга кереп постылар.

Буразна араларыннан гөрләвекләр ага башлады. Җир камыр кебек күперде, кабарды. Утыртырга дип ярып салган бәрәңге



чиләкләренә яңгыр суы тулды. Көрәк-тырма саплары коеп яуган яңгырда юылып агарып калды.

Яңгыр, кисәк кенә башланган кебек, кисәк кенә узып та китте. Ялт итеп яңадан кояш чыкты. Яшел яфраклар өстендә энҗе бөртекләредәй тамчылар җемелдәшә башлады. Йомшак кына сары мамыклы нәни бәбкәләрен ияртеп, казлар яңадан урамга чыктылар.

Көнчыгышка таба китеп барган яңгыр болыты өстендә, дугайланып, салават күпере сызылды. Күк күкрәгән тавышлар кайдадыр еракта тынып калдылар.

Шулвакыт ындырлар арасындагы юлда җигүле ат күренде. Арбага ике кеше утырган иде. Җигүле ат, тоякларыннан пычрак чәчрәтә-чәчрәтә, авыл башына җитеп, басу капкасы төбенә килеп туктады.

Арбадагыларның берсе, капканы ачып, атны керткәч, капканың мунчала бавын яңадан казык башына элде, арбага утырып, дилбегәне какты.

Авылның уртасында юан гына манаралы таш мәчет кукраеп утыра. Шул мәчеткә җитәрәк, юлчылар өстенә кечерәк кенә такта түбә тоткан урыс капкага таба борылдылар.

Арбадагыларның берсе капканы ачты, йортка керүчеләрнең каршысына таза гына бер карчык чыкты. Солдат, аның янына ук килеп:

— Исәнме, әнкәй! — диде.— Бу — мин! Танымыйсыңмы әллә? Әхмәтсафа ич.

Карчык:

— И Аллам! Танымадым шул, балакаем, танымадым! — диде дә улына килеп сарылды.

Өйдән солдатның абыйсы Вафа йөгереп чыкты. Ул арада хәбәр бөтен авылга таралып өлгерде. Һәр йортта Миңлебайлар турында, Сафаның кайтуы турында сөйләштеләр. Ана кешеләр шул уңай белән үзләренең солдат балаларын искә төшерделәр, ата кешеләр дә патша хезмәтенә киткән улларын телгә алдылар. Ир туган — ир туганын, кызлар сөйгән егетләрен искә алдылар.

Ишегалды бала-чага белән тулды. Сафа, арбадан кечкенә капчыгын алып, малайларга учлап-учлап кызыл билле прәннек, эрбет чикләвеге сипте.

* * *

Тиз генә самовар куелды. Бөтен өй җәмәгате чәй эчәргә утырды: иң түргә йөз яшьлек Зөһрә әби, аның бер ягына Сафа, икенче ягына Патый карчык утырды. Вафа самовар артыннан урын алды.

Солдат белән күрешергә дип, әледән-әле күршеләр керә торды. Килүчеләрнең һәркайсы, Сафа белән күрешеп, мич буена чүгәли, дога кылып, битен сыпыра да тегене-моны сорашырга керешә иде.

Сафа, мактанмыйча, күргән-белгәннәрен әйбәтләп сөйләп бирде, белмәгәнен «белмим» диде.

Сафаның өйдә утырасы килмәде. Ул, зиратка барып, әтисенең кабере өстендә Коръән укып кайтырга булды.

II. Сөлекләр

Шәмси мулланың челтәрләп бизәлгән, төрле төсләргә буялган алты почмаклы, чарлаклы йорты мәчет каршына салынган. Бүрәнәләре юан, таза. Сарыга буялган биек-биек ике капка йортны тагы да мәһабәтрәк итеп күрсәтә.

Ул капкаларның берсе бервакытта да ачылмый диярлек. Аның каравы икенче капка турысы тапталып беткән. Кешеләр хәзрәт янына шушы капкадан керәләр. Шәмси мулланың үз гаиләсе дә шушыннан йөри.

Мулланың хәер-фатихасын алырга килүче Сафа да шушы капкадан керде.

Мулланың хатыны читтә эшләп яки солдатта хезмәт итеп авылга кайткан егетләрне яратмый иде, чөнки аларның кайткан берсе өйләнми калмый. Бу егетләр иң яхшы кызларны сайлап

алалар, төн буе ашъяулык-сөлге сугып, юк-бар муенса-беләзекләр хакына буй зифалыкларын бетереп, үпкә чире алучыларны Әсмадан коткаралар иде.

Әсманың бөтен тирә-юньгә баш буласы килә иде. Шәмси исә — йомшак холыклы бер кеше, кайгы-мәшәкатьсез, тыныч кына яшәргә ярата иде. Әсмага аны үз кулына алып, үзе теләгәнчә борып йөртүе әллә ни кыен булмады. Шулай итеп, Шәмси, тора-бара гарәпчә басылган китапларны ташлап, Әсманың бөтен эшендә ярдәмчесе булып китте. Ул еш кына чарлагына менеп, йомшак келәм өстендә ялтыравыклы ука йомгакларны сүтә яки җепкә пыяла муенсалар, таш мәрҗәннәр тезеп утыра торган булды.

Хатыны Әсма Сафа килгәнен әйтергә дип менгәндә дә, Шәмси мулла шул эш белән мәшгуль иде. Мулла:

— Вәгаләйкемәссәлам! Рәхим ит, Әхмәтсафа! —дип, йомшак ак кулларын күрешергә сузды.

Икәү бергә бакчадан чыктылар. Капка төбенә җиткәч, мулла:

— Мәзингә кермәдеңме?—дип сорады.—Аның да фатихасын алырга кирәк.

Сафа, мулла белән саубуллашып, капкадан чыгып китте.

* * *

Сабирҗан мәзиннең указы юк иде. Заманында Шәмси мулланың яхшы карашы аңа дин әһеле булып китәргә ярдәм итте. Аның атасы Гариф мәзин дин эшен сәүдә эше белән бик оста аралаштырып яши иде. Сабирҗан әтисенә бик яхшы ярдәмче иде. Сабирҗан мәзин булып китте, мәгәр сәүдә эшләрен дә ташламады. Авылдагы бердәнбер кибет һаман аныкы булып кала бирде. Ул һәртөрле чимал, күкәй җыйды, икмәк белән сату итте. Чыпта суктырды.

Сарыга буялган ян капканы ачып Сафа килеп керүгә, зур кызыл эт атылып чыкты да котырынып өрергә тотынды. Сафа сәлам биргәннән соң, әзерләп куйган егерме тиен көмешен мәзиннең учына салды.

Мәзин, дога кылып, битен сыпырды.

Шулвакыт капка ачылып, кычкырып сәлам биргән тавыш ишетелде.

— Азан әйтер вакыт җитте бит,— дип, авылның бай куштаны, умартачы Гыймади килде. Сафа, икесе белән дә саубуллашкач, өенә кайтып китте.

* * *

Умартачы Гыймади авылның иң бай, иң дәрәҗәле куштаны иде. Гыймади күп еллар буена, үз авызыннан өзеп дигәндәй, бөтен булган акчасын баю эшенә җикте.

Берничә елдан соң инде Гыймадиның байлыгы Сабирҗан белән ярышырлык дәрәҗәгә җитте.

Мир эшләрендә Гыймади, гадәттә, үзенә файдалы фикергә кушыла, әле мәзин ягында, әле мулла ягында була.

III. Миңлебайныкылар

Зөһрә карчык элекке яхшы заманнарны бик әйбәт хәтерли әле. Миңлебае исән чакта, ул бөтен йортка үзе хуҗа иде. Ире аны ярата иде. Ире Миңлебайны бөтен тирә-як халкы хөрмәт итә иде. Кешеләр аны туры сүзле, намуслы һәм гадел булганы өчен ярата иде. Ул Салихка да шундый бул дип васыять әйтеп калдырды. Ләкин Салих беркатлы, юаш егет булып үсте. Староста кызына — кырыс холыклы һәм хәйләкәр Фатыймага өйләнгәч, ул бик тиз аның йогынтысына бирелде һәм үлгәнче хатыны сүзеннән чыга алмады.

Күршеләр Патыйның холкы белән усал теленнән куркалар, гел аның күңелен күрергә тырышалар, кунакка чакырып, аны түргә, остабикә белән янәшә утырталар иде.

Еллар үтә торды. Патый карчыкка әйләнде. Улын өйләндерде, кызын кияүгә бирде. Аның гадәт-холкы үзгәрмәде, йортта бөтенесенә берүзе баш булып килә бирде. Ул Вафаны кече улыннан күбрәк ярата. Аны куштан итәргә омтыла иде.

Патыйның өлкән улы төсе-бите белән генә түгел, холкы белән дә әнисенә охшаган.

Миңлебайныкылар турында сүз чыкса, һәммәсе:

— Вафа коеп куйган Патый инде, ә Сафа — нәкъ Салих абзый,— дия торганнар иде.

Сафа, чыннан да, абыйсының капма-каршысы иде. Юаш холыклы бу эчкерсез егеткә үз кирәгеңне генә чамалау, хәйлә дигән нәрсәләр бөтенләй хас түгел иде.

Әгәр дә Сафа бер-бер эшкә бирелсә, чын күңеленнән, озакка бирелә. Абыйсы белән әнисеннән ул мин-минлекле, комсыз булмавы белән дә аерылып тора иде.

* * *

Патый Салихның икенче хатыны иде. Беренче хатыны бик яшьли үлеп, аңардан Таҗи исемле бер малае калды. Патый

кулына эләккәч, тугыз яшьлек Таҗи бөтенләй ярдәмчесез калды. Тамагы һәрвакыт ачлы-туклы, өсте-башы сәләмә, өйдә үз почмагы юк. Аңар гел авыр эш кушалар һәм сәбәпсез диярлек аны орышып-тиргәп торалар иде.

Зөһрә карчык, Патыйга сиздермичә генә, оныгының күлмәген ямый, төймәләрен тагып бирә, аны сөя, иркәли.

Бу җәбер-кимсетүләргә Таҗи дәшми генә түзә килде, бөтен кешеләрнең явыз һәм мәкерле икәнлекләренә ышана барды. Ул, үскәч, бөтен кешедән, хәтта Патыйдан да явызрак, мәкерлерәк булыр, беркемгә дә рәхим-шәфкать күрсәтмәс, бу кимлек-хурлыкларның үчен кайтарыр.

Үз тирәсенә ул бер төркем малай җыйды һәм таларга, келәт басарга, вак-төяк нәрсә урларга кереште.

Таҗины өйләндерделәр. Әтисе аңа авылның бер читенә йорт салып бирде, сыер, ат, ике баш сарык бирде. Ел ярымлап торганнан соң, Таҗиның хатыны үлде. Озакламый ул, бөтен мөлкәтен сатып, өен кадаклады да авылдан читкә чыгып китте.

Биш-алты ел югалып торганнан соң, бөтенләй икенче кеше булып кайтып килде. Үз йортына урнашып, кечкенә генә җирендә эшләп, көн итә башлады.

Вафа җыеннарда Таҗига явыз дошманын очраткан кебек карый. Сафа исә абыйсын әллә ни яратмый да, дошман да күрми. Ара-тирә аның белән очрашкалап тора.

Менә хәзер дә ул Таҗи абыйсының хәлен белешә килде.

IV. Ирдәүкә

Йосыф картның кызлары турында сүз чыкканда, һәр кеше аларны «Йосыф чебиләре» дип кенә атый. Әмма бу кушаматны Саҗидәгә карата әйтергә беркемнең дә теле бармый иде. Аны бөтен кеше башка кызлардан аерып куя, аның «Ирдәүкә» дигән үз кушаматы бар иде.

Әгәр Йосыф карт хасталабрак торса яки вакыты булмаса, ирләр хәленнән генә килердәй эшләрне Саҗидә эшли. Ул җир сөрә, иген чәчә, печән чаба, арбага көлтә төйи, кибән дә куя, «эһ» тә итмичә, аркасына бишәр потлы капчыкларны күтәреп ташый.

Саҗидә телгә үткен, сүзгә аптырап тормый. Хатын-кыз эшенә дә бик уңган, бик булган кыз Саҗидә. Өй эчендәге эшләрне дә, хуҗалык эшләренә дә, тегү-чигү эшенә дә кулы ябышып тора аның.

Әйтәсе дә юк: шомырт кара күз, өскә кайтарылып торган керфек, озын толым, зифа буй, алсу ирен, тезелеп торган ап-ак

теш бик сирәк кызларда гына очрый, өстәвенә тагы аның шаян холкы, яңгыравыклы тавышы, гомергә күңелгә кереп кала торган сөйкемле, матур күз карашы да бар.

Егетләр аның тирәсендә бөтерелеп йөриләр. Әмма ул аларның берсен дә өметләндерми.

* * *

Сафа су эчертергә алып төшкән атын җитәкләп, әкрен генә сукмактан менеп килә иде.

— Сафа абый! — дип эндәшкән тавыш ишетелде. Бәрәңге сабакларын аралап, аңа таба җирән чәче өстеннән каешланып беткән түбәтәй кигән сипкелле бер малай килә иде. Малай башындагы түбәтәен иплән кенә салды да, аннан бөгәрләнеп беткән берничә хат алып, Сафага бирде.

— Бусы аксак Сәлахи кызы Мәфтуха ападан. Бусы, зуррагы, Йосыф карт кызы Кәримәдән, ә менә кызыл кара белән язганын Сәлимә апа бирде.

Сафа хатларны алып чалбар кесәсенә тыкты.

— Карале, энекәш, кызларга дигән хатны кемнән яздыралар хәзер?

— Сакау Галим яза.

— Миңа да язып бирмәс микән, матуррак итеп?

— Ник язмасын, язар. Аның әзер хаты да бар, бик матур, бизәкләр төшергән. Тик бәясе бик кыйммәт.

Малай, акчаны учлап, җиңе белән борынын сөртеп алды да:

— Ә хатны кемгә бирим соң? — дип сорады.

— Йосыф кызы Саҗидәгә.

— Саҗидә егетләр биргән хатны алмый. Ай-һай! Алырмы икән? — дип, малай икеләнә-икеләнә генә риза булды.

Сакау Галим кызларга яза торган хатларын «Күктәге йолдызым, судагы кондызым, алтын бармагым, көмеш тырнагым»,— дип, гел бертөрле яза иде. Сафа укый-яза белми иде. Ул хат җибәрүчеләрнең үзләрен генә күз алдына китереп уйлый иде.

V. Шайтан сандугачы

Менә җыен атнасы да килеп җитте. Авылның барлык яшьләре җыенның икенче көнен инеш буенда каршыладылар. Анда гармун тавышлары яңгырап тора иде. Менә өздереп-өздереп уйнаган гармунга бии дә башладылар.

Күрше авыл егетләре шау-гөр килеп бәйрәм иткән яшьләр төркеменә кушылдылар. Миңлебай Сафасы да шундый бер төркемгә килеп кушылды.

Ул килүгә, «Йәле, солдат, осталыгыңны күрсәт!» «Патша итеге яхшы типтерә микән?» дигән тавышлар яңгырады.

Кайсыдыр аны түгәрәк эченә таба төрткәләргә тотынды. Гармунчы, сыздырып, бию көе уйнап җибәрде. Сафа бер кулына кызыл яулык тотып, икенче кулы белән бөеренә таянды да шапшоп җиргә типкәләп биеп китте. Ул әле шап иттереп учын учка сугып ала, әле чырылдатып сызгырып җибәрә, әле чүгеп куя.

Шулвакыт яшьләр төркеменнән түгәрәк уртасына бер кыз йөгереп чыкты. Шундук танып та алдылар аны:

— Менә бусы шәп! Маладис! Шулай кирәк, Саҗидә! — диештеләр.

Сафа белән Саҗидә бии-бии тәмам кызып җиттеләр. Аларның бер дә арыр чамалары юк шикелле иде. Сафа белән Саҗидә, җитәкләшеп, түгәрәк уртасыннан чыккач, так-каравыл уенын уйнаучыларга кушылып, беренче пар булып бастылар.

Менә аларга да чират җитте. Кулларын ычкындырып, икесе ике якка йөгерделәр. Каравылчы зәңгәр күлмәкле, сипкелле битле, ямьсез генә бер егет иде. Ул Саҗидә артыннан йөгерде. Теләмәгән кешесенә тоттырамы соң Саҗидә? Егет, аны тота алудан өмет өзеп, кул селтәде дә Сафаны куа китте. Ләкин анысы да бирешмәде. Ахыр чиктә Сафа белән Саҗидә яңадан икәү бергә бастылар. Шулай берничә мәртәбә кабатланды. Аннары алар, җитәкләшеп, бер читкә ял итәргә киттеләр.

Икесе дә ашыкмыйча, әкрен генә сөйләшә-сөйләшә атладылар.

* * *

Сафа белән Саҗидә шулай икәүләп йөри торгач, кич тә якынлашты. Уеннарның кызган чагы, болын өсте яшьләр белән кайнап тора.

Шунда кинәт «Егетләр, мулла килә, таралашыгыз!» дигән тавыш ишетелде.

Бер читтәрәк гармунчы егет утырып тора иде. Ул әле һаман да озак утырып оеган аякларын яза алмый иде.

Шәмси мулла бөтен ачуы белән гармунчыга ябырылды.

— Ах, шайтан сандугачы! — дип, таягы белән кизәнеп, гармунга китереп сукты. Икенче тапкыр кизәнүгә, таяк егетнең иңбашын яндырып алды. Гармун тәгәрәп китте, дөп итеп ташка барып бәрелде.

VI. Ходайның мәрхәмәте зур булса да, хатын... туендыра

Әкрәм карый — Шәмси мулланың бертуган энесе — Бохарадан укып авылга кайтканда, Шәмси инде мулла булган, ә Әсма бөтен нәрсәне үз кулына алган иде.

Әкрәм карый озын буйлы, таза гәүдәле, аңгырарак, беркатлырак кеше иде. Ул мактанырга шулхәтле ярата, үзе сөйләгәннәргә ахыр чиктә үзе дә ышана башлый иде. Теле белән кылны кырыкка ярырдай булып сөйләнсә дә, эшкә килгәндә утын агачын да урталай яра алмый иде.

Аңа якындагы бер авылга мулла булырга тәкъдим иттеләр, ләкин Әсма моңа каршы төште.

— Атаклы Мөбин ахун улына кечкенә генә ярлы бер авылда мулла булу лаек эш түгел,— дип тукый торды. Шуннан соң инде аны бөтенләй дә чакырмый башладылар.

Мулла белән остазбикә Әкрәм карыйны күрше авылның мәрхүм мулласы кызына — Җиһан исемле, сабыр холыклы булса да үткен, чибәр бер кызга — өйләндерделәр. Яз җиткәч, Җиһан икесенә дә тансык булган беренче баласын тапты.

Иренә өмет юк. Алдагы кышта ач калмыйк дип, Җиһан эшкә керешергә карар итте. Беркөнне, кулына баласын күтәреп, авылның ярыйсы гына хәлле кешеләренә китте.

Хуҗа хатын үз зарын сөйләргә кереште:

— Тын алырга да вакыт юк. Менә өй эчен, балаларны күр. Тегәргә дә вакыт юк, киенергә дә вакыт тими...

Җиһанга шул сүз генә кирәк иде.

— Минем барыбер эшем юк. Бир, үзем тегәм, рәнҗемәссең,— диде.

Берничә көннән соң Җиһан аларга килешле генә, ыспай гына итеп теккән күлмәк-ыштаннар китерде. Шуннан соң ул хуҗа хатынның үзенә һәм иренә күлмәкләр тегәргә алды.

Озакламый аның оста тегүе турында бөтен авылда сөйли башладылар.

Ул өс киемнәре дә тегә башлады. Мәзин хатыны килеп, Җиһанга бер кочак эш калдырып китте. Аның артыннан байлар да китерә башладылар. Шулай итеп, Җиһан кышка кергәндә берничә пот он җыйды, утын сатып алды, хәтта кием юнәтергә дип беркадәр акча да салып куйды.

Берничә елдан соң инде Җиһан өч бала анасы булды, һаман да армый-талмый эшли бирде. Әкрәм исә:

— Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте чиксез, җан биргәнгә җүнен дә бирер! — дип кабатлавын гына белде.

* * *

Сабирҗан мәзин, мулланың хәйләкәр, өлгер Әсмасы җыйган байлыкны исенә төшерсә, ачудан нишләргә белми башлый. Ул Шәмси мулла белән аның хатынын ничек акылга утыртырга хыяллана иде. Бу эштә Әкрәм карый корал булырга тиеш иде.

Беркөнне шулай, чәй эчкәндә, мәзин үзенең планын тормышка ашырырга кереште.

— Карый,— диде,— кайчанга хәтле хатының эшләгәнне генә ашап ятарсың. Безнең мулла байлык җыю белән мәшгуль, ә балалар көнозын эшсез йөриләр... Менә син шуларга сабак укытыр идең. Хатының кыз балаларны укытыр иде.

Сабирҗан мәзин, үзеннән арткан бураны элекке янган мәдрәсә урынына китереп, мәктәп салдырды. Шулай итеп, әрәмтамак Әкрәм карый хәлфә булды, ә Җиһан абыстайга әверелде. Ягымлы, йомшак күңелле булганга, укучылары аны бик тиз яратып өлгерделәр.

Әкрәм карый белән Җиһан абыстай аш мәҗлесләрендә мулла һәм мәзин белән иң түрдә утыра башладылар. Аларга Шәмси мулла белән остабикә генә ашларына төшкән таракан кебек итеп карыйлар иде. Авыл халкы, Әкрәм карый белән Җиһанны балаларының остазлары санап, үзләренә ашка чакырырга онытмыйча, йоладагы барлык садакаларны бирә торалар иде.

VII—VIII. Атың кәнфит ашый беләме?

Урак өсте җитте. Арыш урагының беренче атнасында ук Җиһан өмә җыярга булды. Иртәнге чәйгә байтак кына кызлар, егетләр җыелды. Анда Миңлебай Сафасы белән Ирдәүкә Саҗидә дә бар иде. Яшьләр, җыр җырлап, гармун уйнап, Әкрәм карыйларның мари зираты буендагы җиренә килделәр.

Өмәчеләр, шаяра-көлә, беләкләренә ак җиңсәләр кия-кия, эшкә керешергә әзерләнә башладылар.

— Егетләр! Бирегә килгән-килгән, зират янында берәрсен сихерлибез! — диде егетләрнең берсе.

Бер кыз:

— Чынлап, Фәхри, су буена барып белеп кил әле: синең атың кәнфит ашый беләме икән? Белмәсә, сине сихерлибез,— диде.

Көлешә башладылар. Фәхри ни дип җавап бирергә белмәде, уңайсызланып дәшми калды.

— Телеңне тыя белмәсәң, шулай була ул. Оста капладылармы үзеңне кызлар! — дип, кайсыдыр көлеп кычкырды аңар.

Бер-берен шулай шаярта-көлә, кызлар, егетләр, аралашып, эшкә керештеләр.

Сәҗидәнең уң ягына Фәхри, сул ягына Сафа басты.

Фәхри бик яшьли әтисез калып, байтак нужа күрде. Әнисенең уңганлыгы аркасында гына аякка баса алды. Фәхри Сәҗидәгә күз төшереп йөри иде.

Өмәчеләр тора-бара ярышып эшли башладылар. Сәҗидә белән Сафа тигез баралар. Фәхри исә баштарак көлтәне алдарак урып өлгерә иде. Озакламый калыша башлады. Фәхри кишәрлегендә анда-санда урылмаган арыш башаклары калып бара иде.

Сәҗидә белән Сафа үз алларын бетерделәр дә, борылып, Фәхригә каршы урып килә башладылар.

Ара якыная төшкәч, Сәҗидә:

— Фәхри абый, юл бир! Тапталасың! — дип кычкырды.

Фәхри оятыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булды.

Яшьләр, арышны урып бетереп, көлтә куеп, авылга кайтканда, көтү кермәгән иде әле.

Җиһанның аш бүлмәсендә тирә-күршедән җыйган төрле зурлыктагы унлап самовар кайнап утыра. Тышта яшел чирәм өстендә табын әзерләп куелган иде.

Сафа белән Сәҗидә Йосыф карт өенә чаклы бергә кайттылар.

IX. Илчегә үлем юк

Беркөнне Әсма Патыйны кунакка чакырды. Болай дип сүзгә керешге:

— Малаең, Аллага шөкер, исән-сау йөреп кайтты... Аны башлы-күзле итәргә җыенмыйсыңмы? Мин әйтәм, Сәләхи кызы бик тә чибәр, бик тә уңган кыз булып чыкты. Шуны димләргә кирәк, мин әйтәм.

Мулла белән остабикә, Сәләхине Миңлебайныкылар белән туганлаштырып, аларны үз йогынтысына алырга, мәзин белән умартачы Гыймадига каршы көрәштә үзләренә корал итәргә ниятлиләр иде.

Сабирҗан мәзин, Вафаны үзләренә чакырып, туп-туры сүз башлады:

— Туй ясарга вакыт бит... Егетнең яше җиткәндер ич инде? Безнең Гыймади кызының кай җире килмәгән? Үзем яучы булырмын...

Иртәгесе көнне үк, Сафа өйләнергә җыена икән дип, бөтен авылда сөйләшә башладылар.

Хәзер инде Сафа үз сүзен әйтергә тиеш иде. Беркөнне иртән чәй эчеп утырганда, бу мәсьәләне туп-туры Сафа алдына китереп куйдылар. Сафа:

— Йосыф карт кызы Сәҗидәне алам! — дип җавап кайтарды.

Сафаны үгетләп тә, куркытып та карадылар. Сафа һаман үзенекен итте.

— Әйткән сүземнән кайтмыйм. Егет сүзе бер булыр,— диде.

Хәзер инде өйләндерү мәсьәләсен озакка сузуның мәгънәсе юк иде. Әмма алда әле аның бик кыен бер ягы бар — кызның атасы Йосыф карт белән сөйләшәсе иде. Бу эшкә Әкрәм карыйдан да кулайрак кешене табып булмас иде.

Әкрәм карый үзенең ни йомыш белән килгәнлеген берничә чынаяк чәй эчкәннән соң гына сөйли башлады.

Сәҗидә исемен ишеткәч, карт йөзенә кан йөгерде, куллары дерелди башлады. Йосыф карт каушавын җиңеп, болай дип сорады:

— Зинһар, әйт әле: биш апасын калдырып, төпчек кызны кияүгә бирергә ярый дип, кайсы китапта язылган?

Әкрәм карый мондый сорауны көтмәгән иде. Болай дип әйтүне кирәк тапты:

— Мин — илчемен, Йосыф агай. Картлар әйткәннәр бит: илчегә үлем юк, дигәннәр.

X. Хурлыгы әтигә булыр

Беркөнне Йосыф карт калага солы сатарга киткәч, кызлары аулак өй ясарга булдылар. Әкрен генә тәрәзә чирткән тавыш ишетелде. Сәҗидәгә өлкән апасы:

— Бар! Солдатың килгән, ахры,— дип пышылдады.

Сәҗидә, баскычта туктап, як-ягына каранды. Өй артыннан бер шәүлә килеп чыгып, баскычка таба атлый башлады. Кыз, баскычтан сикереп төшеп, Сафаның кочагына килеп керде.

— Үз теләгебезгә ирешергә бирмәсләр микәнни алар безгә? — диде Сафа, пошынып.

— Әти каладан кайткач, кил дә тагын бер тапкыр сора. Мин дә сөйләшермен.

— Шуннан?

— Шуннан соң да ризалык бирмәсә, үзенә үпкәләр... Киемнәремне төйним дә сезгә киләм... Хурлыгы миңа булмас, әтигә булыр... Кире куып җибәрмәссез бит?

* * *

Өй түбәләренә тия язып, күктән авыр кар болытлары агыла. Ара-тирә шул болытлар арасыннан кызгылт кояш нурлары ялтырап китә. Озакламый буран кузгалырга җыена иде.

Йосыф карт эвененнән бөтерелеп төтен чыга иде. Сафа эвен янына килде.

Карт, баздан чыккач, Сафа кычкырып сәлам бирде һәм аңа таба атлады. Ниһаять, Сафа сүзен әйтеп бетерде. Карт басынкы бер тавыш белән сүзгә кереште:

— Эх, энем! — диде.— Әгәр бу сүзне синең урында башка берәү сөйләсә, мин аның кабыргаларын санап җибәрер идем. Була торган булса, мин сиңа бер кызымны гына түгел, өч кызымны биреп җибәрер идем. Әмма син булмастайны сорыйсың. Мин сүземнән кире кайтмыйм.

* * *

Иртәгесе көнне Йосыф өйгә бер кочак юкә кертеп тар гына итеп телде дә чабата ясарга утырды. Сәҗидә өйдә үзенә урын таба алмыйча әрле-бирле йөрде.

— Әти! — Сәҗидә үз тавышыннан үзе сискәнеп китте.— Синең янга кичә Сафа килдеме? Аңа син ни дип җавап бирдең?

— Минем ни дип җавап бирүемдә синең ни эшең бар? Әллә оятыңны җуйдыңмы, атаң белән кияү хакында сөйләшмәкче буласыңмы?.. Чыгып кит моннан! Минем сиңа да, Сафага да көчем җитәр...

Кыз урыныннан селкенмәде дә. Тагы телгә килде:

— Әнә синең аркада апаларым корып-кибеп беттеләр инде!.. Синең кирелегең аркасында!.. Мин алар шикелле булырга теләмим, теләмим!..

Кыз ялт кына өйдән атылып чыгып китте. Авыр чабата калыбы ябылып өлгергән ишеккә килеп бәрелде.

* * *

Сәҗидә, өйдән исән-сау чыгып качкач, бер әйберсез Миңлебайларга барып керергә яхшысынмады. Җиһаннар йортына барып кына кеше гайбәтеннән качып калачак иде. Кыз шунда китте. Сәҗидә әкренләп хәлгә килде:

— Әти мине Сафага бирергә теләми... Миңа бер генә чара кала: Сафага ябышып чыгам.

— Үзең белгәнчә эшлә... Берничек тә киңәш итә алмыйм сиңа, балам,— диде Җиһан.

XI. Туй

Миңлебайныкылар йортының капка-ишекләре бикләнмәгән әле. Тышта шыгырдап ян капка ачылганы ишетелде. Берәү, тиз генә тәрәзә буеннан узып, ашыга-ашыга, өйалдына керде.

— Хәерле кич!

Тикмәгә көтмәгән икән Сафа: Сажидә иде бу.

Туган-тумача, бергә җыелышып, бик озак киңәштеләр. Миңлебайныкылар белән Йосыф карт йорты арасында тыз-быз хәбәрчеләр йөри башлады.

— Муеннары аска килеп, җәһәннәмгә олаксыннар! Моннан ары бернәрсәгә дә катнашмыйм. Теләсә ни эшләгез! — диде карт, ачу белән.

* * *

Йосыф карт каладан кайтканчы, туйны икенче көнне үк ясарга булдылар.

Иртәгесе көнне өйлә вакытында Миңлебайлар йортына кызның туганнары кодаларын алырга дип җибәргән җигүле атлар килде. Шуннан соң мулла белән мәзинне алырга ат җибәрделәр.

Кыз ягыннан вәли-вәкил итеп Йосыф картның энесе Ильяс чакырылган иде. Ул, йоланы башларга вакыт икәнен белдереп:

— Кунаклар килеп бетте, мулла абзый,— диде.

Шәмси мулла, кулларын тез өстенә салып, күзен йомды, тамак кыргалап алды да гарәпчә Коръән сүрәсен укый башлады...

XII—XIII. Миңлебайлар ыруы чапаны

Сабан туе алдыннан аяз матур язгы бер көн иде. Кояш чыгып, җылы нурлары җиргә төшә башлаганда, бөтен авыл инде аякка баскан, бәйрәм ыгы-зыгысында кайнап тора иде.

Менә урам очында атка атланган ике кеше күренде. Алар, һәр йорт каршысына туктап, Сабан туенда җиңүчеләргә бүләк итеп бирү өчен берәр нәрсә чыгаруларын сорыйлар. Чыгарган әйберенә рәхмәт әйтеп алгач, аны билләренә урыйлар яки ат муенына бәйлиләр дә алдагы йортка китәләр.

Әлеге ике атлыны күргәч, малайлар, уеннарын ташлап, әйбер җыючылар артыннан ияргән төркемгә кушылдылар.

Төркем Миңлебайлар йорты янына туктады.

Шундук ишектән Сафа йөгереп чыгып, куштанга баш-башы чиккән озын сөлге сузды. Ләкин бүләк җыючы куштан сөлгене Сафа кулыннан алырга ашыкмады. Бөеренә таянды да тирә-юнендәге бөтен кеше ишетсен дигәндәй кычкырып:

— Сезнең кебек Миңлебай карт токымы өчен мондый бүләк кенә аз. Бөтен йоласын китереп, авылда бер дигән кызга өйләндең, ә үзең нибары бер сөлге бирәсең. Болай булмый, Әхмәтсафа! Халык сездән чапан көтә...

Сафа уңайсызланып, кызарынып китте. Аптырап, сөлге тоткан кулын кире төшерде дә, ашыга-ашыга, өйгә кереп китте.

Сафа, өйгә кереп:

— Нишлибез инде хәзер? — диде.

— Чәнчелеп китегез! Хәзер генә утырып чапан тегеп бирә алмыйм лабаса мин! — дип кычкырды Патый.

Сафа өмет белән абыйсына карады. Вафа исә, мыскыллы гына көлеп:

— Бик булган егет ич син! Бар, Бохарага барып, чапан алып кайт,— диде.

Тыштан «Әхмәтсафа! Чапаның әзерме?» дигән тавыш ишетелде.

Сәке түрендә дәшми-тынмый тәсбих тартып утырган Зөһрә карчык сүзсез генә киштәгә таба үрелде. Киштә астында зур кадакта мәрхүм иренең бердәнбер истәлеге — Миңлебай картның төсе уңып беткән чапаны эленеп тора иде.

— Мә, улым, чыгарып бир,— диде карчык, калтыранган куллары белән чапанны сузып.— Тынычлансыннар... Бу кадәр намуссызлыкка мәрхүмнең җаны рәнҗемәсен.

— Ай-ай-ай, нинди юмарт! Әйтәсе дә юк! — дип тезеп китте Патый.

Вафа авыз эченнән нидер мыгырданып куйды. Сафа, әбисе кулыннан иске чапанны алып, тиз генә урамга чыкты да кушташга сузды.

Куштан:

— Бу чапан Зөһрә карчыкның туе елында Сабан туена бүләк итеп әзерләнгән булгандыр әле. Ярый, бушлай биргән атның тешен карап тормыйлар! — дип сөйләнә-сөйләнә, чапанны алып иптәшенә бирде.

Ызгышны Патый белән Вафа башлады. Алар Зөһрә карчыкны артык юмартлыгы өчен ачуланырга керештеләр. Карчыкны яклап, сүзгә Сажидә кысылгач, тегеләр аңа икәүләп ябырылдылар.

Халык инде, кайсы атка атланып, кайсы җәяүләп, кырга, уенга китеп бетте, ә Миңлебайлар йортында гауга һаман басылмады.

Сафа:

— Сезнең болай мәсхәрә итүегезгә бүтән түзеп тора алмыйбыз! — дип кычкырды да, ишекне шап иттереп ябып, өйдән чыгып китте.

Сәҗидә дә аның артыннан иярде.

* * *

Мәйданны авылдан ике-өч чакрым читтәрәк, басу янындагы болында оештырганнар иде.

Менә көрәш башланды. Беренче булып көрәшкә балалар чыкты. Балаларны үсмер малайлар, үсмерләрне үсеп җиткән егетләр алмаштырды. Аннары мәйданга чын көрәшчеләр чыкты.

Аягына чабата, өстенә иске генә чикмән кигән һәм төп шикелле тәбәнәк, таза, сакаллы бер кеше үзенә каршы көрәшергә чыккан берен искиткеч җиңел күтәреп алып җиргә сала тора. Ахырда бу көрәшче белән көч сынашырга теләүче кеше дә калмады.

Халык:

— Вафаны чыгарыгыз! Вафаны! Миңлебай Вафасын! — дип, моңа каршы тора алырдай кешене әйтеп шаулый башлады.

Бу сакаллы көрәшче чит авылдан килгән иде. Беренче батыр булып ул калганда, хурлыгы бөтен Мәүла Колыга төшәчәк. Мондый хәлгә берәүнең дә юл куясы килмәде.

Кемнәрдер Вафаны тотып алып, этә-төртә мәйдан уртасына кертеп җибәрделәр.

Көрәшчеләр билдән алышып, әкрен генә әйләнеп йөри башладылар. Сакаллы көрәшче кинәт талпынып, Вафаны кузгатып карады. Вафа бирешмәде. Вафа, дошманының биленнән кысып алып, аны уңга таба каерды да шундук искәрмәстән чын бер көч белән икенче якка ыргытты. Ничәмә кеше белән көрәшеп арыган сакалбай җиргә барып төште.

Тамаша кылып торучылар шатлануларыннан үкерергә керештеләр.

Бер кеше дә көтмәгәндә, мәйдан уртасына тагын бер көрәшче чыкты. Бөтенесе шаккатып тынып калды. Бу кеше Миңлебай Сафасы иде. Баягы гауга ачуы белән ул бөтен халык алдында абыйсыннан үч алырга җыена иде.

Вафа, шаяртып, кул гына селтәмәкче булган иде дә, алай итмәде, үзенең көченә ышанып, Сафага таба китте. Билләрдән алыштылар. Вафа хәйлә белән алмакчы булды. Ләкин көрәшне мавыгып карап торган халык:

— Вафа, хәрәмләшмә! Аяк чалма! — дип кычкырды.

Сафа кинәт, сизелмәслек бер җитезлек белән, абыйсын җиргә егып салды да күкрәгенә менеп утырды.

Халыкның шаулашуы авылга чаклы ишетелгәндер.

Шулай итеп, Сафа беренче батыр булып калды.

Иртән бүләк җыеп йөргән теге куштан, аны дәшеп алып:

— Батырлыгың өчен ни кирәк? Бабаң чапанын аласыңмы? — дип сорады.

— Миңа берни кирәкми... Чапанны әнә беренче килгән ат иясенә бирегез, — диде Сафа.

XIV. Җәбраил фәрештә өстенә языйммыни мин аны?

Сафа белән Сәҗидәгә бу йортта яшәрлек рәт калмады. Сәҗидә түземсезләнеп көткән вакыт, ниһаять, килеп җитте. Җае чыкканда файдаланып калып, бер минут та соңламыйча, бүленүне таләп итәргә кирәк иде. Сәҗидә, җае чыкканга бик сөенеп, эшкә керешә. Аның фикере белән Сафа да килеште. Аларның, башка чыгып, үз тормышларын корып җибәрергә көчләре җитәчәк иде.

Мондый зур эшкә тәвәккәлләгәнче картлар белән әйбәтләп киңәшик дип, алар мәйданнан Йосыф карт йортына киттеләр.

* * *

Йосыф карт төпчек кызының үз ризалыгыннан башка кияүгә чыгуы хурлыгын байтак вакыт оныта алмады. Шулай да Сәҗидәнең йомшак теле, Сафаның картны хөрмәт итүе үзенекен итте.

Карт аларны:

— Хуш киләсез, рәхим итегез! — дип, ачык чырай белән каршы алды.

Сафа сүз башлады. Әнисе белән абыйсының кыш буена үзләренә кон күрсәтмәүләрен сөйләп бирде, ахырда, моннан ары әнкәй йортында кала алмыйбыз, сездән киңәш сорарга килдек, диде.

Йосыф карт уйга калды. Аннары катгый итеп әйтә куйды:

— Мин кызымны каенана типкесендә яшәр өчен үстермәдем. Бүленегез. Тазалыгыгыз булса, ач калмассыз. Миннән фатиха, — диде.

Сафа белән Сәҗидәгә шул гына кирәк иде.

XV. Иләк тә минеке, чиләк тә минеке

Вафа Сабан туенда үзенең җиңелеп калуын һаман оныта алмый иде әле. Шуңа күрә ул дәшми-тынмый гына чәй эчеп утырды.

— Әни, абый, тыңлагыз әле, сөйләшәсе бар иде,— диде кинәт Сафа.— Ике сарык башы бер казанга сыймый, диләр. Эт белән мәче шикелле яшибез... Бүленешәсе иде. Кем аерылып чыга? Минме, абыйммы?

— Бу йортны мин сезнең өчен саклап килмәдем, моннан чыгып китәргә җыенмыйм. Безнең белән сыеша алмыйсың икән, чык та кит,— диде Вафа.

— Яхшы! Мин анысына да риза,— дип җавап кайтарды Сафа.— Ә минем өлешкә ниләр тия?

Йорт бүлү башланды. Моңарчы дәшми генә утырган Патый телгә килде, өлкән киленнең дә теле чишелде. Сажидә дә сүзсез калмады. Шулай итеп, талаш китте.

— Иләк тә минеке, чиләк тә минеке.

— Тәпәнем үзем белән бергә картайды. Күәс чиләген мәрхүм ирем сатып алган иде! — дип чәрелдәде Патый, яхшы әйберләрнең берсен дә Сажидәгә бирергә теләмичә.

Тәмам ярсыган ике туган бер-берсенең бугазына ябышырга җитештеләр, әмма шулай да әйбер бүлешкәндә карап торырга дип картларны чакыра киттеләр.

Картлар килеп җитте. Сафа төрле яктан яуган үгет-киңәшкә каршы килә алмады. Сажидәнең дә озакка сузылган бу талашны тизрәк бетерәсе килә иде.

— Ярар, алайса, шулай булсын, картлар! Соңгы сүзем шул: теләсәгез ничек итегез,— диде Сафа.

Картлар мал-мөлкәтне бүләргә керештеләр. Дөресрәге, үзенә кирәкмәгән әйберләрне генә биргән Вафаны җөпләп кенә тордылар. Ватык, җимерек, иске әйберләрнең барысы Сафага булды, яхшы, төзек, яңа әйберләр Вафага калды.

— Мал-мөлкәтне бүлүен бүлдек. Ә менә карчыкларны нишләтәбез? Кем карар аларны? — дип сорады берсе кинәт.

— Икесе дә төп йортта калырга тиеш,— диде картлардан берәү.

— Әнине үзем карармын. Әбине әнә ул алсын. Чапанны аңардан ул алды, шулай булгач, аның үзен дә алсын,— диде Вафа.

Картлар, көлемсерәп, күзгә-күз караштылар.

Сафа абыйсына җавап бирергә өлгермәде, Сажидә горур гына итеп җавап кайтарды:

— Йөзгә җиткән карчыкны гына карарга хәлебездән килер. Бала йодрыгы чаклы гәүдәсе бар... Әбине үзебезгә алабыз,— диде.

— Менә бу акыллы сүз әйтте! Менә рәхмәт! — диештеләр картлар.

Ике гаиләгә дә бәхет теләп, алар тиз генә чыгып киттеләр.

Сажидә белән Сафа шул кичне үк бер тол карчыкның кечкенә генә өенә күченделәр. Сажидә Зөһрә карчыкны да шунда житәкләп алып килде.

Сабан ашлыклары чәчелеп беткәч, бер җомгада Сафа мәчеттә картлардан үзенә йорт урыны бирүләрен сорады. Аңа йортны авыл читендәге буш урынга салырга рөхсәт иттеләр.

Сафа шул урынга бура келәтне күчереп, аны җылытты, ишек-тәрәзәләр уеп, түбә япты.

Терлек-туар өчен вакытлыча абзар-киртә корып куйды, кечерәк бер баз казыды. Башкаларын алдагы елга калдырырга туры килде.

XVI. Бал эчәләр үзләре, тәрәзәдә күзләре...

Әкрәм карый, мәзин белән бергә базарга килгәч, товар карап, сөйләшкән сүзләргә колак салып, рәтләр буйлап байтак йөрде. Ул, һәр кибет алдына диярлек туктап, товарларның бәясен сорашты, аларны кулына алып карады, сатулашты, шуннан соң икенчесенә китеп барды.

Кибетче алдан ук әзерләп куйган төргәкне карыйга алып сузды. Бусы әфьюн иде.

Әкрәм карый, кибетчегә акча түләп, Сабирҗан туктаган мәзин йортына китте.

Йорт хуҗасы, каршы чыгып, аны Сабирҗан белән Гыймади янына, чарлакка менгезеп җибәрде.

— Кара син боларны, бал эчәләр үзләре, тәрәзәдә күзләре... Әссәламегаләйкем! — дип шаяртып сөйләнде Әкрәм карый, бүлмәгә керә-керешли.

Әчегән татлы бал җитәрлек иде. Мәҗлес кыза барды. Күңелле әңгәмә туктаусыз дәвам итте. Әңгәмәнең кызган бер җирендә Сабирҗан мәзин, Гыймадига туры карап, нык тавыш белән:

— Юкка карышасың, Гыймади абзый! Теләгебезне башкарырга күптән вакыт инде безгә! — диде.

— Нәрсә әйтәсең? — диде Гыймади.

— Нәрсә булсын! Карыйны икенче мулла итүне әйтәм инде.

Гыймади, чигүле сөлге башы белән маңгаен сөртә-сөртә:

— Башлап җибәр, эш миннән калмас. Кайсы як чәйлекне күбрәк бирсә, мин гел шул якта,— дип кеткелдәп көләргә керәште.

— Каршы килмәскә сүз бирсәң, мин эшкә керешәм. Карыйны мулла итәргә бик вакыт инде... Вәгъдә алайса, Гыймади абзый?

— Вәгъдә!

Әкрәм карый, чокырга салган балны бер тын белән эчеп, савытны ашъяулыкка куйды да:

— Амин! — диде.

Сабирҗан мәзин, Әкрәм карыйны Шәмси мулланың ярдәмчесе итеп куеп, мулла белән үзсүзле Әсмадан күптән үч алырга хыялланып йөри иде инде.

XVII. «Твая баранчук жич? Кәнфит вәзмүш!»

Алдагы җомгада, намаз беткәнче үк, картлардан берәү, урыныннан торып:

— Җәмәгать, таралмагыз әле! Киңәшәсе бар! — дип кычкырды. Дога кылгач, алдан ук мәзин тарафыннан өйрәтеп куелган бер куштан сүзгә кереште:

— Авылыбыз шактый зур. Һәрбер вагы-төяге өчен дә хәзрәтне борчыганчы, аңа ярдәмче куймыйк микән, картлар?

— Тотабыз да тамга җыябыз! — дигән тавышлар ишетелде төрле яктан. Шунда Шәмси мулла сөйли башлады:

— Каян алдыгыз әле сез моны? Минем җитешә алмыйм дип зарланганым юк бит. Миңа ярдәмче кирәкми,— диде.

Әмма мулланың сүзләре мәзин тарафдарлары күтәргән шаушуда йотылып калды.

Мәзин ялгышмаган иде. Гыймади белән бергәләп төзегән планы бик шәп килеп чыкты. Шунда ук тамга җыю һәм эш артыннан йөрү өчен кешеләр сайладылар.

Иртәгесе көнне күп кеше Шәмси мулланың, тарантас артына ныгытып бәйләгән зур гына тәпән белән бал алып, авылның киң урамы буйлап каядыр китеп барганын күреп калдылар.

АШЛЫК УРЫНЫНА БАЛЧЫК

I. Ходайның кодрәте җитмәде, шайтан да ярдәм итмәде

Авылда, гадәттәгечә, Сабан туен бәйрәм иткәч, басуга эшкә чыктылар. Әмма күк йөзе чалт аяз, бер генә болыт әсәре дә күренми. Кояш иртүк кайнарланып чыга, басулар өстеннән эссе җил исә. Үләннәр шиңеп саргая, җир кибеп яргалана иде.

Авыл халкы, басуга чыгып, намаз укып, Ходайдан яңгыр теләде. Яңгыр боткасы пешерделәр. Су сибешергә керештеләр. Ә яңгыр һаман да яумады.

Ходайның кодрәте җитми, шайтан да ярдәм итми иде.

Берише кешеләр, йортларын ташлап, кая туры килсә, шунда чыгып киттеләр. Икенче берәүләр, арзанга гына йорт әйберләрен сатып, читкә эшкә киттеләр.

Миңлебай Вафасы калага эшкә китте. Сафа, хатыны белән киңәшкәннән соң, авылда калырга булды.

Өлкән абыйсы тол Таҗи да:

— Ярлыга кая барса да бер язмыш,— дип, беркая кузгалмады.

Бөтен тирә-якта якынлашып килгән ачлыктан курыкмаучы бердәнбер кеше шушы тол Таҗи гына иде.

II. Ач күләгәләр, тук бүдәнәләр

Көз туклык, муллык китермәде. Ташландык әвеннәр җимерек стеналары, тишек түбәләре белән ыржаеп утыралар. Аларның базлары ишелеп, мичләре яртылаш җимерелгән.

Халык өеннән чыкмый.

Салым түләр вакыт та килеп җитте.

Фәйзулла староста сотский белән десятскийларга халыкны каравыл өенә җыярга кушты.

Ачлыктан кипшенеп агарынган, шешенгән кешеләр, салкын мич башларыннан көч-хәл белән төшеп, сәләмәләрен киделәр дә каравыл өенә киттеләр.

— Җәмагать, начальство салымны соңгы тиененә чаклы түләп бетерергә куша,— диде староста.

Гыймади гөрелдәтеп бер кикерде дә:

— Игеннең уңмавы патшага, начальствога кагылмый. Ансы Ходай Тәгалә эше, тәкъдир эше...— диде.

Өстенә тула чикмән, аягына тишек итек кигән Фәхри кинәт:

— Ашарына икмәге булмаган кешеләр бетләрен сатып түләсеннәрме? — дип кычкырды.

Фәйзулла, катгый итеп:

— Соңыннан миңа үпкәләмәгез. Барыбер түләтәбез,— дип, сүзен бетерде.

Салым түләүне уена да китермәгән кешеләр калтыранып куйдылар. Шуның белән җыен таралды.

Иртәгесе көнне Фәйзулла староста, сотский һәм десятскийлар белән бергәләп, салым түләмәгән кешеләрнең йортларына кереп, аларның соңгы арык сыерларын, бозауларын яки аягында көчкә басып торган арык атларын алып чыгып китте. Мал-туарлары булмаганнарның соңгы алабута онын, соңгы мендәрен һәм чүпрәк-чапракларын алып чыктылар.

* * *

Калага эшкә киткән Миңлебай Вафасының да сыерын алып чыктылар. Сафаның да ике яшьлек башмак танасы Фәйзулла староста ишегалдына күчте.

III—VII. Адәм кыяфәтле маймыллар

Сафаларның хәлләре көннән-көн авырая барды.

Аларның инде җыйган алабуталары бетеп килә, каралтылары да утынга ягылып беткән диярлек, чират яңа келәткә җиткән иде. Сафаның көннән-көн чырае караңгылана барды. Ач үлем аларга да якынлашып килә иде.

Тик бер Саҗидә генә эчтән бу хәлгә бирешмәскә тырыша иде. Ул үзенең исән каласына, исән-сау яңага барып җитәчәкләренә ышана, хәтта үзенең карт әти-әниләренә, апаларына да ярдәм итәргә өметләнә иде.

Беркөнне ире белән сөйләшкәндә, ул:

— Карале, без соңгы минутка чаклы шушылай кул кушырып утырырбыз микәнни? — диде.

— Нишлик соң?

— Вафа көзеннән үк китеп яхшы итте. Аның җәмәгате дә тук, әйберләре дә исән. Безнең дә берәребезгә китәргә кирәк иде.

— Китәргә хәзер дә соң түгел әле.

— Кем китә соң? Синме, минме?

— Акылың бармы, Саҗидә? Үзем исән чакта, мин сине чит кеше каршына җибәрәмме?

Икенче көнне Сафа, кулына таяк тотып, карлы юл буйлап калага таба юл тотты.

* * *

Ике көннән соң Сафа, тәмам арып-талып, калага барып җитте. Үзе шикелле үк эш эзләп, туган авылларыннан чыгып киткән крестьяннар белән бергә, ул бер постоялый дворга килде. Тәртип урнаштыручы кеше Сафага буш урын күрсәтте.

Сафа, иртән торгач, чәй эчеп, урамга эш эзләргә чыгып китте. Барлык постоялый дворлар, чәйханәләр, мөсафирханәләр эшсезләр һәм хәерчеләр белән тулган иде.

Бердәнбер чара Вафа абыйсын эзләп табу иде. Ләкин ике туганның моңарчы һаман татулаша алганнары юк иде әле.

Сафаның Вафа абыйсы каршына барып ялынасы килми иде, шулай да, байтак уйлаганнан соң, «Ярар! Иелгән башны кылыч чапмас!» дигән карарга килде.

Бик күп кешеләрдән сораша-сораша, байтак адашып йөргәннән соң, Сафа, шыгырдап торган капканы ачып, ишегалдына керде.

VIII—X. «Кеше» булды

Әрләи үзе турында зур уйлаучы, тискәре һәм саран бер хуҗа булып китте. Башка татар байлары кебек, Габдулла да ишегалды түренә хезмәтчеләре өчен кечкенә генә, тәбәнәк кенә бер өй салдырды. Приказчиклар эштән соңгы вакытларын шунда уздыралар. Әгәр дә Әрлән приказчиклардан берәрсенең аштан яки эш күплектән зарлануын сизсә, шундук шыр-ялангач чишендереп, бер тиен дә түләмичә куып чыгара.

Башка сәүдәгәрләрнеке кебек, Габдулланың да исәп-хисап эшләре чуалып беткән иде. Бигрәк тә аның вак бурычлар яза торган кенәгәсе буталчык иде. Бу кенәгә мондый сүзләр белән язылып тулган иде:

«Җирән урыстан ун сум аласы калды.
Аксактан дүрт сум аласы.
Шадра түти биш сум тиешле.
Тешсез карчыктан бер сум да егерме биш тиен аласы».

Әмма шулай да Габдулланың сәүдәсе көннән-көн үсә бара иде.

Өеннән чыгып киткәндә, Габдулла бер хезмәтчесенә икенчесе өстеннән шымчылык итәргә кушып калдыра; хатынына приказчикларга күз-колак булырга, ә приказчикларга хатыны белән балаларын караштырып торырга куша. Аннары барысы өстеннән дә баш шымчы куя иде.

XI. Чиләгенә күрә капкачы

Вафа Әрләнгә, дворниклыкка ялланып, күздән алып язга чаклы эшләргә сүз бирде. Аның әле байда беренче тапкыр хезмәт итүе иде, шуңа күрә ул байга ярар өчен җаны-тәне белән тырышып йөри башлады.

Хезмәтчеләр Вафаны, әле кырык яше тулмаган булса да, «бабай» дип атадылар. Ул кеше күз алдында бик диндар, әйбәт «бабай» булып күренергә тырыша иде.

Вафа һәр сынауны яхшы узды. Ул Габдулла белән Сәрвәрнең күңеленә тәмам ошады, приказчиклар белән хезмәтчеләр дә аңа ышанып карый башладылар. Вафа турында сүз чыкса, һәркайсы:

— Безнең бабай — ышанычлы кеше.

— Вафа ул гайбәт йөртә торган кеше түгел, сер саклый белә,— диляр иде.

Вафа бер йомыштан да баш тартмый. Үзенә ышаныч арткан саен, йомыш үтәгән хакы да арта бара иде.

Габдулла бай Вафаны үзенең баш шымчысы итеп, ара-тирә аңа унбиш-егерме тиен акча бирә, вакыт-вакыт хәтта кием-салым да бүләк иткәләп куя иде.

Вафа Әрләннең ышанычын ныгытырга, шул ук вакытта хезмәтчеләргә курку салырга да тырыша иде. Ул байга:

— Фәлән приказчик бүген иртән намаз укымады...

— Фәлән малай итекләрен киптермәде.

— Пешекче хатын чүлмәк ватты,— дип әләкли башлады.

Ул хәтта Габдулла байга хатыны өстеннән дә:

— Хәерчегә зур бер телем ипи бирде...

— Чапанын капкадан чыккач кына бөркәнде,— дип әләкли иде.

Сәрвәр аңардан курка башлады. Вафага мул булып тәмле азыклар, вак-төяк әйберләр, хәтта киелгән киемнәр дә ява торды. Аның сандыгында Сәрвәр бикәнең иске күлмәкләренә дә, Габдулла байдан тама-тама җыелган бер төенчек акчага да урын табылды. Аның бу сандыгында приказчиклар биргән түбәтәй, исле сабын, тасма, чәй кебек әйберләр дә саклана. Вафа боларны атна саен диярлек калага килүче хатыны аркылы әкренләп авылга озата тора иде.

Аның урынына туры сүзле, йомшак күңелле икенче бер кеше эләксә, ул монда ярашып яши алмас, бик тиз куып чыгарылган булыр иде.

Бөтен сыйфатларны әнисеннән алган бозык табигатьле, икейөзле Вафа исә җинаять эшләүдән дә курыкмый, аны хәтта гөнаһ дип тә санамый,— ул нәкъ урынына килеп эләккән иде. «Чиләгенә күрә капкачы» дигән мәкальдә әйтелгәнчә. Вафа нәкъ үзенә ярашлы җиргә туры килгән иде.

XII. Ходай китергән кунак

Сафа абыйсын эзләп тапкан вакытта, Вафаның эшләре иң көйле барган чак иде. Сафа, кыяр-кыймас кына ян капканы ачып, Әрләннәр ишегалдына килеп керде.

Өйдән Вафа чыкты. Сафаны күргәч, ул: «Барыйм микән, юк микән?.. Сөйләшим микән?» — дип уйлады. Аннары тиз генә энесе янына килә башлады.

Аралары нда берни булмаган кебек, кул бирешеп күрештеләр. Вафа Сафаны хезмәтчеләр өенә алып китте.

— Сайга утырдым, абый! — диде Сафа.— Ашарга берни калмады. Әби белән хатын ярым ач утыралар. Саклап тоткан атыбыз да җилдә чайкала... Менә бирегә килдем. Берәр эш табып булмасмы, дигән идем.

Шулвакыт кыңгырау чылтырап, Вафа ишеккә йөгерде. Ул хезмәтчеләр өенә кире әйләнеп кергәч, ике туган сүзне дәвам иттерделәр.

— Безнең бикәнең этисенә, хәзрәткә, дворник кирәк икән. Тик син ярап бетәрсең микән, белмим...— диде Вафа.

— Нигә?

— Әй энекәш! Байларга ярау ансат түгел ул... Кала халкы ул кайбер кяфер эшләмәгәннәрне дә эшли. Исең китәр.

Сафа аптырашта калды, эндәшмәде.

— Сабыр ит. Бикә янына барып килим әле. Синең бүген ашаганың да юктыр,— дип, Вафа чыгып китте...

Вафа ашалып бетмәгән бәлеш, паштет, каткан күмәч салган зур бер поднос күтәреп керде.

Берничә ай буе ачлы-туклы яшәгән Сафага искереп күгәрә башлаган бәлеш кисәкләре дә җәннәт азыгы булып тоелды. Сафа боларның барысын бик тиз юк итте.

* * *

Приказчиклар йокыдан торганда, тышта әле караңгы, таң атып өлгермәгән иде.

Вафа ишегалдын себерде, тротуарларны себерде, абзарны җыештырып, сыерларга азык салды, аларга җылы су эчертте, утын ярып куйды, кучерга атларны карарга булышты, шуннан соң гына, хезмәтчеләр өенә кайтып, суынган самоварны җылытты. Чәй эчкәннән соң, Вафа, бикә янына барып, рөхсәт сорады да энесен бикәнең атасы янына алып китте.

— Кеше кирәген кирәк тә, тик нишләргә инде менә: хакын бик зур сорамаса, шәт, алырмын да... Синең энең дә бугай әле,— диде мулла, Вафаның сүзен тыңлаганнан соң.

— Ала күр инде берүк, хәзрәт. Алла боерса, үзем шикелле үк әйбәт, тырыш хезмәтче булыр...

— Күпме сорыйсың соң?

— Күпме бирәсең инде, мулла абзый. Рәнҗетмәссең, шәт,— диде Сафа.

— Ярар. Ашау миннән, үлем Ходайдан, дигәндәй... Җәйгә чаклы эшләсәң, ун сум бирермен...

— Әз бит, мулла абзый... Авылда хатыным белән әби карчык калды. Аларны да ашатырга кирәк.

— Әзрәк шул, хәзрәт. Киемен дә бирмисең. Ярар инде... Энем карлар эри башлаганчы эшләр, унбиш сум түләрсең инде,— дип, сүзгә Вафа да кушылды.

Хәзрәт күңеленнән исәпләп-чамалап торды да:

— Кыйммәтрәк инде кыйммәтен дә, шулай да ярый, хәерле булсын. Синең энең дә икән. Тик намус белән әйбәт хезмәт итсен,— диде.

Сафа, постоялый дворга барып, аннан әйберләрен алып килде һәм шул минуттан соң дворник булып китте. Берничә көн эшләгәннән соң бик озак үтенеп сорагач һәм Вафа да ярдәм иткәч, ул задаткага биш сум акча алып, авылга җибәрде.

Сафа көченнән килгән кадәр, һичбер карышусыз, бөтен эшне эшли бирде, тик, абыйсы шикелле ертлач бер кеше булмаганлыктан, ул бу йорттагы кешеләрнең гаепләреннән файдаланырга уйламады да. Шуңа күрә Сафага берәүдән дә әҗер тимәде. Аны берәү дә сыйламый, аннан берәү дә курыкмый иде.

XIII. «Баҗалар»

Минзәлә ярминкәсеннән Әрлән бик кәефе кырылып кайтып төште. Сәүдә бик начар булды. Сатудан җыйган акча кредиторларга түләргә дә җитмәде.

Юлдан кайтып, ял итеп алганнан соң, ул, йортындагы хезмәтчыларын чакырып, сорау алырга кереште. Вафаны иң соңыннан гына дәштереп алды.

— Бикәнең тегенди-мондый эшләрен сизмәдеңме?

— Нахак сүз сөйли алмыйм... Берни дә сизмәдем.

— Кунакка баргалагандыр ич?

— Унике тапкыр кунакта булды, биш тапкыр әтиләренә барды, өч тапкыр үзе кунак җыйды.

Әрлән кибетендәге барлык приказчикларны тетеп сүкте, берничә малайны кыйнап ташлады, ышанычлы кешесенә дә әллә нинди гаепләр тагып каныкты.

Бу көнне Габдулла бай ярминкәдәге дулаган аю шикелле котырынды.

Кич җиткәч, шул хәлендә өенә кайтты. Комганга тутырып куйган су артык салкын кебек тоелды. Шуннан ул комганны ыргытып бәрде. Кайнап торган самоварны тибеп аударды. Өй эчендәгеләр һәммәсе куркышып, дер калтырап тора башладылар.

Шуннан соң ул, ачу-ярсу белән:

— Нәрсә карыйсың син? Асраулар әйберләрне урлый, приказчиклар уйнашлык итә, ә син берни белмисең...— дип, хатынына ябырылды.

— Ни булды сиңа бүген?.. Йорт эчендәге караклардан сакланып бетеп буламыни? — диде хатын.

— Теләгән кеше саклана. Син йортта хуҗа була белмисең. Асраулардан куркып торасың! Килмешәк! Ялкау!

Бу сүзгә инде Сәрвәр бикә дә түзмәде:

— Нишләп мин килмешәк булыйм? Ниткән ялкау мин?

— Ах, син, мулла калдыгы! Миңа каршы киләсеңме әле?! — дип, Габдулла хатынының яңагына чалт-чолт сугып җибәрде.

Хатын, үкереп елый-елый, ирен каргарга тотынды:

— Йа Раббым, миңа суккан өчен кулың корысын иде! Мин мондый җәберләрне күрергә өйрәнмәгән.

— Өйрәнмәсәң, бар, кит! Иртәгә үк куып җибәрәм. Талак сиңа, талак, талак! Мең тапкыр талак! — дип ярсып кычкырды.

Сәрвәр бикә мамык мендәргә капланып, үкереп еларга кереште. Ниһаять, бай, кычкыра-кычкыра хәле бетеп, тамагы карлыгып, икенче бүлмәгә чыкты да чишенми-нитми диванга ауды.

Иртәгесе көнне иртән ул, чәй дә эчмичә, кибетенә китте.

Сәрвәр бикә этиләренә китте.

Озакламый Сәрвәрнең этисе дә килеп җитте. Күрешеп исәнләшкәч, мулла дога кылып алды да ипләп кенә сүзгә кереште:

— Сездә бик күңелсез хәлләр булган икән, кияү. Ходай кушып, ахыры хәере белән бетсен инде,— диде.

Габдулланың, эшне зурга җибәрмичә, бу хәлдән тизрәк котыласы килә иде.

— Гаеп миндә, бабай! Булды да бетте. Бер юлга гафу ит инде. Мондый хәл бүтән булмас,— диде.

— Мин гафу итәрмен дә, менә Ходай гафу итәр микән? Ахмак!

Габдулла бай, юаш кына итеп:

— Бәлкем, никахны яңартырга кирәктер? — дип сорады.

— Ул гына аз,— диде хәзрәт.— Син бит ул сүзне өч тапкыр әйткәнсең. «Мең тапкыр...» дип тә кычкыргансың, шулай булгач, хәзер тәхлил[1] кирәк инде...

— Тәхлил?! — диде Габдулла бай, коты алынып. Бу сүзнең мәгънәсен бик яхшы белә иде ул. Аның үз хатынын икенче бер кешегә һич тә биреп торасы килми иде.

[1] Тәхлил — «Талак, талак» дип аерган хатынга кабат өйләнү өчен, хатынны башка кешегә кияүгә биреп аеру.

— Андый эшкә бер дә җаным тартмый шул, бабай. Берәр башка чарасы юкмы соң? — диде ул.

— Тинтәк! Ахмак! Ходайны алдамакчы буласыңмы?

Шулай итеп, Габдулла байга ризалашырга туры килде.

Ике як та тәхлил өчен кулай кеше табарга тиеш иде. Габдулла бай да, бабасы да кеше эзләргә керештеләр. Әрлән, уйлана-эзләнә торгач, Вафага тукталды. Мулла да Вафаны хуп күрде. Вафа бу эшкә һичбер карышусыз риза булды.

— Кара аны, соңыннан киреләнеп маташасы булма. Хатынны аерырга теләмим дип әйтмәссең дип ышанам мин сиңа. Ә? — диде мулла.

— Алла сакласын, хәзрәт. Әллә мин кеше алдап йөрүче бер бәндәме? — диде Вафа.

Шаһит итеп ике приказчикны чакырдылар. Шулар алдында Сәрвәрне дворник Вафа белән никахлаштырдылар.

* * *

Икенче көнне иртән Сәрвәр Вафага:

— Сине кысарлар. Талак дигән сүзне әйтергә ашыкма! Бирешмә! — диде.

Вафа, моның азагы начар булыр бит, дип курыкканлыгын әйтте.

— Берни булмас. Бик кирәк булса, ике көннән соң әйтерсең. Кара аны, оттырма, акчаны күбрәк сора. Кирәк була ул акча.

Шул рәвешле, Сәрвәр бикә иреннән үч ала иде.

Икенче көнне иртән Габдулла бай, ишекне шакып, хатыныннан: «Әйтмәдеме?» — дип сорагач, бу юлы да «юк» дигән җавап ишетте.

Карт хәзрәт тә, Габдулла бай да тәхлил өчен Вафаны сайлап бик каты ялгышканлыкларын аңладылар. Беркөнне кич алар Вафаны чакырып алгач, мулла аңардан:

— Нишләп син, агай, сүзеңдә тормыйсың? — дип сорады.

— Мин бит синең кызыңны урлап та, алдап та алмадым. Шаһитлар алдында үзең никахладың.

— Син кирегә борып маташма,— дип, сүзгә кушылды Габдулла бай.— Форсаттан файдаланып, миннән күбрәк акча каерырга чамалыйсыңмы? Күпме кирәк, әйт?

— Биш йөз сум көмеш.

Байтак кына тарткалашып, ахырында ике йөз сумга килештеләр.

Икенче көнне иртән Вафа, әйберләрен җыеп, Габдулла бай йортыннан чыгып китте. Мулла, киявенең соравы буенча, Сафаны эшеннән куды.

XIV. Саулыгың булса, аты булыр

Җиһан абыстай, нишләргә белмичә гаҗиз булып, беркөнне Саҗидәләргә килде.

— Ашарга бер тәгам ризыгыбыз калмады. Сезнең дә шулайдыр инде... Сезгә киңәшкә килгән идем. Нишләргә инде? Балалар кызганыч бит... Ачтан үтерербез микәнни инде аларны?..— диде Җиһан, тынлыкны бозып.

Саҗидә уйга калды. Ят бер тавыш белән диярлек иренә эндәште:

— Әгәр дә атны... алашаны суйсак дим. Әтиләр дә, Ильяс абыйлар да ач, үзебез дә, абыстайлар да... Итен дүрт йортка бүләрбез. Халыкка паек бирәседер, ди. Бәлкем, шуңарчы җиткербез. Үзебез үлсәк, ат кемгә хаҗәт? Ичмасам, бер изгелек эшләрбез.

Бердәнбер таянычыннан да колак кагу бик авыр иде, шуңа күрә Сафа берни дип тә җавап бирмәде.

Җиһан абыстай әкрен генә ишеккә таба китте.

Сафа аңа карап торды да, сүзләрен ачык итеп:

— Абыстай, иреңә әйт, килсен... Бераз булышыр,— диде. Аннары Саҗидәгә:

— Бар, бабай белән Ильяс абзыйны чакырып кил,— диде.

Сафа атны суеп бетергәнче өеннән чыкмады.

Сафалар ишегалдына, берәр сөяк тимәсме дип, хәлсез ач күршеләр дә керделәр.

XV. Басуда Сабан туе

Хөкүмәтнең ярдәмгә дигән икмәге авылга барып җиткәнче, ярлыларның барысы диярлек кырылып бетте.

Язгы ташу сулары да агып бетте. Җылы кояш астында җир кибә башлады.

Ниһаять, казна паегы Мәүла Колыга да кайтып җитте. Ашлыкның байтак өлешен олаучыларга бирделәр. Мулла белән мәзингә дә берәр капчык илттеләр. Калганын җыенда бүген кешеләргә бүлә башладылар. Шау-шу, кычкырыш-талаш купты. Куштаннарның сүзе өскә чыкты. Ачларга кеше башына егермешәр-утызар кадак чүпле арыш тиде, байлар исә берничәшәр пот алдылар.

* * *

Арыш биргәннән соң, озакламый чәчүлеккә солы, арпа һәм бодай да өләштеләр.

Сабан ашлыкларын чәчәр вакыт узган булса да, крестьяннар:

— Үлсәм үләм, барыбер җиремне чәчәм! — дип, ашыга-ашыга, җирләрен чәчеп чыктылар.

Яз бөтен нәрсәгә тереклек сулышын өрде. Урман, болыннарда хәзер яфрак, яшь үрентеләр, сутлы кайры, ашарга яраплык үлән тамырлары, суда балык бар.

Быел басулардагы авыр эш халыкның күңелле Сабан туен алыштырды.

* * *

Каладан алып кайткан акча белән мал Миңлебай Вафасына көч-куәт һәм ышаныч бирде. Хәзер инде ул җыеннарда һәрвакыт, масаеп кына, үз фикерен әйтә башлады. Аның ике көр аты каладан паек һәм чәчүлек ашлык ташыды. Ниһаять, Вафа да чын куштан булып китте. Һәм, бүтән куштаннар шикелле, ат биреп торган өчен ашлыгын да, ачтан үлгән ярлыларның бер өлеш җирен дә алды.

Авыл хәзер ике генә төркемгә — ачлар белән тукларга һәм атлылар белән атсызларга гына бүленгән иде. Ярлылар ачтан үлеп бетте, урта хәллеләр алар хәленә төште, байлар исә тагы да баеп китте. Уртаклык калмады.

Сафа ярлылар арасында калды. Сажидә белән, ындыр артына чыгып, җиренең тиресләгән өлешен китмән, көрәк белән казыды да казна биргән орлыкны чәчте.

XVI—XVII. Корбан

Сафа белән Сажидәнең тормышлары түгәрәк түгел иде: балалары юк иде.

Хәзер инде тормышлары бөтен яктан да рәтләнгәч-җайлангач, аларны әнә шул кайгы гына борчый иде. Ислам динендәге бөтен ырымны кулланып бетергәч, мәҗүси Аллаларга мөрәҗәгать иттеләр. Мари багучыларының барлык киңәшен эшләп карадылар. Ләкин берсенең дә файдасы тимәде.

Ахырында ул үзенең бала анасы була алмаячагын аңлады, шулай да бирешергә теләмәде.

Беркөнне ул ире белән сөйләшергә булды:

— Әллә тагы бергә өйләнәсеңме?.. Балабыз булыр иде, ичмасам,— диде. Сафаның ачуы килде:

— Юкны сөйләмә әле! Каян килә синең башыңа шундый тузга язмаган сүз?

Сәҗидә сүзен куәтли бирде:

— Гомергә баласыз каласың килмәсә, өйләнергә кирәк... Талашмыйча, тату яши торганын үзем табып бирәм.

— Әйтмә дә, уеңа да китермә! Мин андый эшне эшләмәячәкмен,— диде Сафа.

Мәгәр Сәҗидә уеннан кайтмады, җае чыккан саен шул хакта әйтә торды. Аның үз йортларында бала күрәсе килү, бала сөю теләге артканнан-арта бара иде.

* * *

«Керпе» кушаматлы Сәлим ачлык елны исән калган бик аз ярлыларның берсе иде. Ул бөтен тирә-юньдә иң яхшы такта ямучылардан санала. Һәр елны, көз җиткәч, Сәлим, озын пычкысын аркасына асып, авылдан читкә чыгып китә. Кышкы бураннарда, көзге әшәке яңгырда да, язгы пычракта да ул, аркасындагы пычкысының шыңлавын тыңлап, җайга гына атлыйатлый, авылдан авылга йөреп, кешеләргә такта яра.

Сәлимнең кечкенә генә өе тирәсендә абзар-кура да, читән дә юк. Аның чәчкән җире дә юк.

Ачлык елны Сәлим җәй көне үк авылдан чыгып китте. Такта яру заводына эшкә яллаңып, җәен-кышын шунда эшләп уздырды.

Базык буйлы, киң җилкәле бу ир, күндәм, юаш бер кеше булса да, башкалар белән дуслашырга яратмый иде. Кешеләрдән читләшә торган гадәте өчен аңа «Керпе» дигән кушамат биргәннәр иде. Аларны якты йөз белән каршы ала торган бердәнбер йорт Миңлебай Сафасы йорты гына иде.

Сәлим, биек кузлага салган юан бүрәнә өстендә, канатларын җәйгән бөркет шикелле җилпенеп-җилпенеп пычкыны салмак кына йөрткәндә, Вәли астан әтисенә булыша. Сәлим авырыбрак китсә, аның урынына өскә улы менеп, абыйсына булышырга Хәтирә килә. Күбрәк вакыт кыз әтисе белән абыйсына аш пешерә, керләрен юа яки берәр җиргә көнлекче булып эшкә яллана иде.

Кай ягы беләндер Хәтирә Ирдәүкә Сәҗидәгә дә охшаган иде. Сөйкемле, чая, аның шикелле үк кыю иде ул. Ихтимал, шуңа күрәдер Сәҗидә аны аеруча ярата иде. Шуның өстенә Сәҗидәгә аның тырыш, сабыр булуы да ошый иде. Тормышның бик күп ачысын-төчесен күргәнгә, Хәтирә булганы белән канәгать була белә, авырлыкларга түзә белә иде. Ирен Хәтирәгә өйләндереп, Сәҗидә үзенә яхшы дус табасына ышана, йортына көндәш түгел, киңәшче китерәсен яхшы белә иде.

* * *

Җәйнең кояшлы, эссе бер көне. Талгын гына искән йомшак җил авыл башыннан чәчәк атып утырган үләннәрнең тәмле, баллы исен алып килә.

Сафа белән ныгытып сөйләшкәннән соң, Саҗидә икенче көнне иртүк Сәлимнәргә китте.

Сәлим зур гына таш өстендә пычкы кайрап утыра иде.

Саҗидә шундагы икенче бер ташка утырды.

— Мин бер зур эш белән килдем әле.

— Нинди эш белән?

— Яучы булып...

— Алай булгач, нигә аны миңа әйтеп торасың? Бар, үзенә әйт.

— Хәтирә үзе риза булса, син каршы килмәссеңме соң?

— Нишләп каршы килим ди мин?

Саҗидә, таш өстеннән торып, өйгә таба китте.

Җир идән чиста итеп себерелгән. Бөтен өй эчен диярлек биләп алган сәке кырыенда Хәтирә кул эше эшләп утыра. Вак-төякне сөйләшеп алганнан соң, Саҗидә туп-туры төп эшенә кереште:

— Беләсеңме, Хәтирә, мин сиңа яучы булып килдем бит әле,— диде.

Саҗидә, кызның аптырашта калуын күреп, ни сәбәптән ирен өйләндерергә теләвен һәм ни өчен Хәтирәне сайлаганын сөйләп китте.

* * *

Бөтен авыл шау-гөр килеп җыенга хәзерләнгән көннәрдә Керпе Сәлим йортында кечкенә генә туй ясадылар. Никах укылган кичне үк Хәтирә Сафа йортына күчте.

Хәтирәне үзенә көндәш итеп сайлап ялгышмады Саҗидә. Сабыр холыклы, тырыш Хәтирә Саҗидәнең яхшылыгын онытмады, юаш табигатьле Сафаны да яратып китте. Алар өчәү дустату яши башладылар.

Кыш урталарында Сафа белән Саҗидә тансык баланы каршы алырга хәзерләнә башладылар.

МӨҺАҖИРЛӘР

(Ил эреккәндә)

I

1897 елның башы иде. Халык шау килде:

— Бөтен халыкны көчләп чукындырасылар, имеш.

Бөтен авылларның старосталары волость төбәгенә җыелып, аларга, тупас казна теле белән:

— Егерме җиденче гыйнварда бөтен халыкның саны алына; халык шуңар хәзерләнсен,— дип игълан ителде.

Старосталар, куштаннар өчен дә бу боерык көтелмәгән бер нәрсә иде. Телләрдә яшерен рәвештә генә сөйләнеп дөрескә чыккан бу шомлы хәбәрне халыкка ничек итеп белдерергә җай таба алмыйча аптыраштылар.

Ул арада киң халык катлавының шомланып шаулашуы артканнан-арта барды. Каравыл өендә, мәчет алдында, чат башларында һәркемнең телендә шул бер генә мәсьәлә иде:

— Көчләп чукындырасылар икән...

— Чукындырыр өчен халык санын аласылар икән...

Күп вакыт үтмәде, һичкемнең димләвеннән башка, үзлегеннән җыйналган халык төркеме, Фәйзулла куштан өенә барып, карт куштанны җилтерәтә башлады. Фәйзулла староста халыкны бераз тынычландырырга тырышып карады:

— Картлар! — диде.— Халыкның санын алу турысында патшадан боерык булган икән... Озакламый безнең авылга да язучы түрәләр киләсе... Безнең мөселман халкын гына түгел, урысын, чирмешен, мимечен — барысын да язасылар, ди. Керәлечыгалы җикеренүдән бер мәгънә дә чыкмый. Ирек куеп, кушканнарына күнәбезме? Әллә башка берәр чара табып буламы? Минә шул турыда киңәшик...

— Килсеннәр! Буып бәкегә тутырырбыз!.. Бик күп чыдадык инде, җитәр!

— Җәмәгать,— диде мулла.— Китап патша кушкан эштән баш тартмаска өнди. Патша үз теләген эшләмичә калмас, җәмәгать! Мин үзебезгә авырлык килмәгәе дип куркам...

Ләкин ул сүзләр халыкка тәэсир итә алмады:

— Ассын, киссен, суйсын — без үз динебездән кайтмыйбыз, ата-баба динен ташламыйбыз!

— Чукынып, күрәләтә урыс булганчы, ата-баба юлында җан бирәбез! — дигән төсле сүзләр белән, ярсыган килеш таралыштылар.

Бу ярсу йөз еллар буенча төрле җәбер-золым, азап һәм мәсхәрәлекләр күреп алҗыган, сугылган, таланган, тапталган, изелгән мужикның нәүбәттәге баш күтәрүе; ә сан алу мәсьәләсе һәм ата-баба дине өчен куркыныч туу дигән сүз исә сылтау гына — коры салам өчен бер шырпы шикелле корал гына иде.

Акылга сыймаслык һәм күбесенчә берсе икенчесенә капма-каршы килә торган хәбәрләр искиткеч дәрәҗәдә тиз күбәйде. Кара халык һәммәсенә дә ышанды, барысыннан да шомланды. Котырынуы артты, ярсуы көчәйде.

Фәйзулла староста да, билгеле, тик ятмады. Халыкның уен Сапый старшинага аңлатты. Старшина хәлне үзе дә белә иде. Шулай булса да әхвәл һич үзгәрмәде. Билгеләнгән көндә сан алучы-язучыларны каршы алып, булышлык күрсәтергә генә кушылган иде.

Менә билгеләнгән сан алучылар тиешле вакытында авылларга таралдылар.

Башка авылларда бу кешеләрне кыйнап җибәрү, үтереп бәкегә салу шикелле эшләр булса да, Мәүлә Колы авылына килүчеләрнең берсе таныш кеше булганлыктан, аңа берьюлы каты бәрелмәделәр.

— Яхшы чакта үкчәң күтәр, агайне! Моннан болай безгә мондый эш белән киләсе булма!.. Үз кешебез диеп тормабыз! — дип кайтарып җибәрделәр.

* * *

Тагын бер-ике көн узгач, кыңгыраулар тагып, пар ат җигелгән һәйбәт чананың эченә чумып утырган становой, атларын ияләп кенә менгән берничә стражник иярткән килеш, Фәйзулла староста өенә килеп туктады.

Бу эш ярсыган халыкны үчекләү, юри мыскыллау шикелле тоелды. Яралы күңелләрдәге үч алу дәрте тагын да ныграк кайнап ташый башлады.

Муеннарына мунчала баулы калайларын кигән сотский һәм десятскийлар, тагын өй саен туктап, тәрәзә-ишек кагып:

— Җыенга! Җыенга! — дип кычкырып уздылар. Халык каравыл өенә таба юнәлде.

Һава салкын һәм тын, көнбатыш яктан ала-кола кар болыты күтәрелеп килә. Ниндидер каты буран һәм өермә алдындагы тынлыкны аңдырып[1] тора иде.

---

[1] Аңдырып — аңлатып.

Менә становой да, стражникларын ияртеп, Фәйзулла старостаны янына алып, каравыл өенә килде.

Җыелган халыкның күплегенә һәм аларның тышкы кыяфәтләренә карап күп нәрсә аңларга мөмкин булса да, становой аны аңлау дәрәҗәсеннән түбән иде. Ул мужикны бернәрсә дә белми, аңламый, аларны түрәләргә бүләк-күчтәнәч ташучы, берберсе өстеннән чагучы, ни кушылса, шуны үтәргә торучы дип кенә белә иде. Шуңа күрә ул бу юлы да һичнәрсәдән курыкмады, шикләнмәде, шөбһәләнмәде. Ачулы һәм мәсхәрәле тавыш белән, тешләрен кысып:

— Ә... бунтовщиклар!.. Йә? — диде.

Эндәшүче булмагач, ул, тагын да җикеренеп:

— Ник патша боерыгына каршы киләсез? Ник бунт чыгарасыз? Күрсәтегез миңа башлыкларыгызны? — дип кычкырды.

Кыска кайры тун өстеннән кызыл пута бәйләгән тәбәнәк бер кеше:

— Ах, син, корчаңгы елан!.. Әле һаман да иске әкиятне сөйләмәкче буласың икән!— дип кычкырды да: — Карагыз, егетләр, тегеләрен! — дип, ишек төбендәге стражникларга ишарәләде. Үзе, бияләй эченә тыгылган биш кадаклы герен югары күтәреп, становойга омтылды.

Бу кеше чатан Сәләхи кияве Бүкән Фәхри иде. Тагын кемдер становойның ике кулын да аулап тотып алды да бөтереп артка каерды. Бусы Миңлебай картның улы тол Таҗи иде.

Башларына төшкән чукмарлар, герләр, ташлар тәэсире белән каршы тору көчләре юк ителгән кешеләрне, өстерәп, дүртәвен бер урынга — каравыл өенең җир идәне уртасына өйделәр дә кабарган ачулар басылганчы, гасырлар буена күңелләргә төен булып оялаган усал үчләр кайтканчы кыйнадылар, изделәр.

Авылның байлары, куштаннары әллә кайчан каравыл өеннән чыгып сызганнар иде.

* * *

Становой үтерелгәч, сан алу мәсьәләсе дә үзеннән-үзе юкка чыккан һәм ата-баба дине өчен туган куркыныч та бераз кимегән төсле булды. Түрә үтереп алган савапның җәзасы да шактый зур һәм азаплы буласын сизенсәләр дә, әлегә үч алынган, халык җиңеп калган. Шуңа күрә дә ул шактый зур куаныч-юаныч булган иде.

Базарга барган кешеләр өр-яңа бер хәбәр китерделәр:

— Имеш, фәләнчә көндә бөтен тирә-яктагы авыллар бояр утарын таларга баралар...

Бу хәбәр дә шул көндә үк бөтен йортларга таралып өлгерде.

— Бояр малын талау гөнаһ түгел... Ул безнең үзебезнеке,— диештеләр.

Билгеле көндә күз күреме җирдәге авыллардан төпсез чаналарга төялгән яки балта, сәнәк күтәреп җәяүләгән халык һәрьяктан бояр утарына агылды.

Боярның матур, биек йортлары алдындагы киң бушлыкка җыйналган халык ашыкмыйча гына, һәркем үзе белгән хәбәрен сөйләп гәпләшкәндә, эчке яктан бикле капканы ачтырып, управляющий килеп чыкты. Аның җилкәсенә асылган ике көбәкле ау мылтыгы авызы белән күккә карап тора. Управляющийга ияреп чыккан каравылчылар да бөтенләй үк буш түгелләр иде.

Аларны күргәч, халык гөрләп китте. Бояр белән эш итә торган крестьяннарның бөтен йомышлары тик аның кулыннан үткәнлектән, файдаланырга җир алганда булсын, көтәчәккә азык-төлек сораганда булсын — һәрвакыт управляющий алдына барыла һәм бөтен эш аның «мәрхәмәтенә» терәлә иде. Урманнан чыбыркы сабы һәм берәр казыклык кисеп тотылырга туры килгәндә дә, крестьяннар аны күбесенчә шушы кыяфәттә — җилкәсенә мылтык аскан хәлдә очраталар иде.

Шул сәбәптән бүген дә аны шул кыяфәттә күрү җыйналган халыкның күңелендә әллә кайчангы һәм әллә нинди яраларны кузгатты. Баштарак бик тыныч төсле күренгән халык диңгезе управляющий һәм каравылчыларга таба елышып, аларны сарып алды.

— Нихәл, картлар, ни йомыш? — диде управляющий.— Мин сезнең белән бераз сөйләшим дип чыккан идем...

— Мылтыксыз чыгарга ярамадымыни? Безне һаман да мылтык белән куркытмакчы идеңмени?

Управляющий ык-мык итеп җавап бирергә өлгермәде, кемдер, көчле тавыш белән:

— Тотып бәйләгез үзен, егетләр! Каныбызга бик күп тоз салган иде,— дип кычкырды.

— Кибәргә элү мәслихәт булыр! — дип әйтә салды тагы берәү.

Управляющийны кулда күтәреп китерделәр дә, элмәкле бауны муенына кигезеп, буй җиткән кадәр югары күтәреп тордылар. Шаркылдап көлделәр дә, кулларын ычкындырып, читкә тайпылдылар.

Халык, әллә кемнәрдән үзенең тагын әллә нинди үчләрен алган төсле булып, үзендә ниндидер бер сәер рәхәтлек тойгысы сизенде.

Бикле, йозаклы ишекләр ватылып, бояр-алпавытның йорт, амбар һәм сарайлары әрчелде. Йортта табылган нәрсә-кара барысы да чаналарга төялде. Аяклы мал чана артларына тагылды. Шуннан соң зур йорт белән ашлык амбарларына, сугылмаган кибәннәргә ут төртелде.

* * *

Утар талап кайтуның икенче көнендә, мулла-мәзин киңәше белән, Фәйзулла староста тагын җыен җыйнады.

— Инде ни булса булды,— диде староста,— баш коткару җаен кайгыртасы иде бит, ни әйтәсез, картлар?

— Ни күрсәк тә бөтен ил белән күрәбез! Үлсәк тә үкенмибез! Азрак үч алдык, ичмасам!

— Аласы үчләребез һаман да беткәне юк әле...

Арадан берәү:

— Әллә патшага прошение биреп карыйк микән?— диде.

Мондый вакытта очраган бер фикергә, ни туры килсә, шуны эшләргә торган халык бу сүзгә теш-тырнак белән ябыша куйды.

— Патшага прошение бирик... Ул безнең хәлләрне белми дә торгандыр әле.

— Түрәләрнең безгә күрсәткән җәберләрен барысын да күрсәтик.

Патшага прошение бирергә булдылар.

Шәмси мулла, тамак кырып, поднос өстенә җәелгән кәгазьгә шытырдатып, әллә нинди утлы-яшелле тавышлар чыгарып яза башлады.

Тышта һава тын, салкын һәм кояшлы; бөтен дөньяны баскан ап-ак кар диңгезе якты кояшның салкын нурлары белән ялтырап җемелди, күзләрне чагылдырып талдыра иде.

Халыкның бер өлеше тышта — каравыл өенең эргә нигезенә тезелгәннәр. Карт-коры, өй эчендә булып, прошение язарга булыша иде.

«Олуг мәрхәмәт вә мәртәбә иясе, газаматлу падишаһы әгъзаи Икенче Николай бине Александр хәзрәтләренә...

Олуг-кечүк ир һәм хатын — барчамыз ялварып сорыйбыз: безнең дин вә иманнарыбыз тәгаррыз ителмәсә икән[1]. Газиз балаларымызны солдат хезмәтенә бирәбез. Имана вә башка бурычларыбызны вакытында түлибез. Гайре әмер вә фәрманнарыңызны да үти киләбез вә бондан суңра да үтәячәкбез. Түрәләр сез падишаһмызның фәрманнарын сез боерганча гаделлек белән

[1] Тәгаррыз ителмәсә икән — тыкшынмасыннар иде.

үтәмиләр. Безне көчлиләр, динебездән дүндермәкче булалар. Баскан туфракларыгызны үбеп сорыйбыз...»

Кул кую башланды. Инде шушы эш артыннан йөрер өчен кеше генә сайлыйсы калган иде. Кеше таба алмыйча байтак азапланганнан соң, берәү, шаярынкырап:

— Әнә карый хәлфәдән үтеник булмаса,— дигән иде, һәркем, муафыйк кеше табылганны белгән шикелле, чынлап ук:

— Үтенәбез дә үтенәбез! — дип кычкыра башлады.

Бу мәсьәлә дә чишелде. Әкрәм карый исеменә вәкаләтнамә язылып, аңар да Фәйзулла староста «кәҗүнни мөһер» басты. Патшага прошение бирүнең төрле чыгымнары өчен җан башына ун кадак арыш хисабы белән салым салынды.

Әкрәм карый иртәдән калмыйча калага китәчәк булды.

II—VII

Менә беркөнне, иртән яктырып килгәндә генә, басу капкасы төбендә чанага җигелгән атлар, әллә нинди ят кыяфәттәге кешеләр күренде. Иң арттагылары алга килеп җиткәч, җеназа укыгандагы шикелле, рәт-рәт булып тезелделәр. Рәткә тезелгән мылтыклы солдатлар, барабан көенә кызу-кызу атлап, Фәйзулла куштан йорты турысына туктадылар.

Килүчеләр халык телендә «обжор командасы» дип йөртелә торган җәза фиркасе[1] иде.

Тикшеренүләр шул көндә үк башланды.

Үтерелгән становойга башлап һөҗүм итүчеләр — Таҗи белән Фәхри — каядыр качып өлгергәннәр иде. Ә стражникларны арт яктан кочаклап алучылар, аяк-куллары богауланып, шул көндә үк калага озатылдылар.

Аннан соң чуалышка катнашмаган кешеләрнең исемлеге төзелде.

«Без ил белән бергә инде, ни күрсәк тә бергә күрербез!» — дип шапырынган мулла-мәзин һәм куштаннар, астыртын гына берәм-берәм волостька барып, үзләрен яздырган һәм хөкүмәт боерыгын үтәгән булып чыктылар.

Шулардан кала бөтен халык чуалышка катнашучы саналды. Болар эченнән дә, бояр утарын таларга баручыларны аерып алып, үзенә башка бер исемлек төзелде. Утар талауга катнашмый калучыларга унбишәр, тегеләренә егерме бишәр камчы сугылачак булды.

---

[1] **Фиркасе** — партиясе; *бу урында:* командасы.

Төн узды. Авыл уянды. Десятский, сотскийлар, тагын тәрәзә-ишекләр шакылдатып:

— Җыенга, җыенга! Берәү дә калмаска! — дип кычкырып уздылар. Халык теләр-теләмәс кенә тагын каравыл өенә агылды.

Берничә стражник, кереп, ишек төбенә басты. Берсе мич буенда торган озын эскәмияне уртадагы бушлыкка китереп куйды. Тагын берәвесе пешекләгән чи карама чыбыгын, кочаклап китереп, эскәмия янына салды.

Фәйзулла староста алдындагы язулы кәгазьләрнең берсен алды да, өй ишеген ачып:

— Шәфигулла Хәсбиулла улы! — дип кычкырды.— Әйдәле, энем Шәфикъ. Монда сиңа тамга саласы бар икән...

Шәфикъны ике яктан ике стражник эскәмия янына төрткәләп китерде, һәм берсе, төксе генә итеп:

— Әйдә, сал бишмәтеңне!.. Ят шунда! — дип, эскәмияне күрсәтте.

Шәфикъ стражникның сүзен аңлап җиткермәде. Чөнки ул старостаның сүзеннән «Берәр кәгазьгә тамга саласы бардыр» дип аңлаган иде.

Становой:

— Нәрсәгә катып торасың? Әллә ишетмисеңме? — дип, аяк тибеп кычкыргач кына, ул мәсьәләне тәмам аңлады. Стражниклар аны җилтерәтеп чишендерделәр дә, күтәреп алып, эскәмиягә йөзтүбән сузып салдылар. Бер стражник башына атланып утырды. Икәвесе аның ике аягын түбәнгә басып чүгәләп тоттылар. Дүртенче стражник чын көче белән Шәфикъның ялангач аркасына бер тартты.

Сугылучы яман ачы тавыш белән кычкырып җибәрде. Урамның икенче читенә җыйналган хатын-кыз, бала-чага төркемендә дә чырылдап кычкырышкан, әрнеп елашкан тавышлар ишетелде.

— Җитте!.. Төгәл егерме биш булды!

Бу вакытта инде Шәфикъ кычкырмый, тыпырчынмый, ул әллә кайчан исеннән язган иде. Аны бишмәтенә урадылар да старостаның җигүле атына салып өенә озаттылар.

Аннан соң тагын берәү чакырылды. Ул да шул рәвешле сугылып, истән язган хәлендә өенә озатылгач, башкасы кертелде. Анысының да эше бетерелгәч, тагын...

Становой, старшина, писарь һәм стражниклар төн уртасы якынлашканда күрше авылга юнәлделәр. «Обжор командасы» — җәза фиркасе шунда калды. Солдатлар, рөхсәтсез-сораусыз,

әләккән бер әйберне тартып алып, йортларның актык сыерын суеп ашаудан да тартынмаска кушылып, йортларга таратылды.

* * *

Шушы вакыйгага бер атна узгач, Гыйбад писарь, тагын үзенең иптәшләре белән сан алыр өчен, Мәүла Колы авылына килде. Бу юлы карышучы булмады. Сан алучылар теләгәннәрен эшләделәр. Кирәкле мәгълүматны тоткарсыз алдылар.

Башка йортлар рәтеннән алар Миңлебай Сафасы йортына да кергәннәр иде. Аркасы һаман да төзәлмәгән Сафа солдат, сәкегә йөзтүбән яткан килеш, сан алучыларның сорауларын, хатыны Сажиданең аларга биргән җавапларын тыңлый.

Шул көннең иртәгесен үк Зөһрә карчык авырый башлады һәм барлы-юклы бер атна чамасы авырып яткач үлеп тә китте.

Сырты төзәлеп җиткән кешеләр, ил ирке һәм халык азабы белән сату итмичә, илгә нинди генә борчу килсә дә, бергә уртаклашып, саф намусы һәм керсез күңеле, ак күкрәге белән дөньядан үткән аксакал Миңлебайның актык төсмере булып торган бу карчыкның җеназасына барып олылап күмделәр.

Кайсыбер шаянрак кешеләр:

— Газраил фәрештә Зөһрә әбине дә эзләп тапты, ахры,— диделәр.

— Безнең газапларны күрсәтер өчен генә аны Ходай шушы көнгә чаклы саклаган икән...— дип әйтүчеләр дә булды.

Ләкин ул турыда иң дөрес сүзне Әкрәм карый әйтте:

— Үлмәктән калмак юк, бу дөньяда һичбер нәрсә мәңге түгел... Барысы да фани...

Бу аның үз гомерендә беренче һәм ахыргы мәртәбә әйтә алган бердәнбер фәлсәфи сүзе иде.

Әйе шул! Бу дөньяда һичбер нәрсә мәңге түгел. Патша да, аның түрәләре дә, законнары да...

* * *

Тикшерүләр башланасы көнне Таҗи белән Фәхри авылдан качып киттеләр. Күршедәге рус авылында күпмедер вакыт яшеренеп яткач, ары кузгалдылар. Көне буе аяк өсте йөрүдән арып-талып, кичкенә генә бер татар авылына барып җиттеләр.

Кыйшаеп утырган йортларның берсенең болдырында яшь кенә хатын басып торганын күреп, Фәхри:

— Киленкәй, без мөсафирларга чәй эчереп чыгармассызмы икән? — дип сорады.

Хатын ишектән кереп югалды һәм бераздан кире әйләнеп чыкты да:

— Әйдәгез, керегез, Хода бәндәләре,— диде.

Түрдә, тәрәзә янында, олы яшьләрдәге бер хатын җеп эрләп утыра; сәкенең баш-башларында исә берсе яшь, икенчесе картрак кыяфәтле ике ир кеше йөзтүбән сузылып ята иде.

Таҗи белән Фәхри юл капчыкларын ишек бусагасы төбенә куйдылар да сәке читенә килеп утырдылар.

Шулвакыт ишек ачылып, өйгә озын буйлы, пөхтә киемле ниндидер бер кеше килеп керде; ул сәлам биреп, ян сәкегә утырды да дога кылгач:

— Кая юл тотасыз, егетләр? Авылыбызга исән-сау гына килеп җитә алдыгызмы? — дип сорады.— Биктимер өендә мөсафир кешеләр бар дигәч кенә керүем иде... Мәйтәм, берәр яңа хәбәр әйтмәсләрме, кереп чыгыйм әле...

Бераз сөйләшеп-сукранып утырганнан соң, ул саубуллашып чыгып китте. Сәкедә яткан егет, яралары сызлауга да игътибар итмичә, урыныннан сикереп торды да ачу белән сөйләнергә тотынды.

— Менә нинди сатлык җан бит ул! Башта халыкны котыртып йөргән булды, кабахәт, һәр урам чатында бугазын киереп: «Ассын, суйсын — без үз динебездән кайтмыйбыз!» — дип әтәчләнде. Ә үзе ул арада, астыртын гына кантурга барып, кирәкле мәгълүматны биреп кайтырга да өлгергән икән... Түрәләр аларның соңыннан башларыннан сыйпадылар, ә безне, эскәмиягә яткырып, чыбык белән сыйладылар.

Чәй эчелеп бетеп, табынны җыярга гына торганда, кинәт ишек яңадан ачылды һәм өйгә ике солдат ияртеп офицер белән староста килеп керде.

— Паспортларыгызны күрсәтегез! — дип боерды офицер Таҗи белән Фәхригә.

Таҗи Фәхригә күз кысты. Алар ишек катында идәндә яткан капчыклары янына килеп, әйберләре арасында актарынгандай бераз чүгәләп тордылар, аннары кинәт өйалдына атылып чыгып, ишекне тыштан келәсе белән бикләделәр дә ындырга таба чаптылар.

Солдатлар да ындырлар ягына карап йөгерделәр. Алар артыннан кулларына күсәк-сәнәк тоткан бер төркем ирләр — сугылу җәзасыннан котылган авыл куштаннары иярде.

* * *

Кич житте. Урам чатларында, капка төпләрендә җыелып торган хатын-кызлар, бала-чагалар һәммәсе бу вакыйганың ахырын көттеләр.

Ниһаять, авылга таба бер төркем кешеләр килгәне күренде. Каравыл өе турысына җиткәч, төркем тукталды. Бер кеше старостага эндәште:

— Ничек, Ибрай ага, эләктердегезме асыл кошларны?

— Эләкми кая китсеннәр?! — дип җавап бирде староста. Берсе әвенгә кереп утырган иде, икенчесе — салам чүмәләсенә. Көч белән алырга туры килде.

Симез битле кеше Таҗиның йөзенә бик җентекләп карап торды-торды да кинәт:

— Җәмәгать! Бу Мәүла Колы авылының Миңлебай карт малае лабаса! — дип кычкырып җибәрде.

— Әйе, зур җинаятьчене эләктердек! Становойны үтерүчене! — дип аңлатты староста һәммәсенә.

XIII

«Обжор» командасының җәбер-золымнары чиктән ашты. Бер генә йортта, хуҗалыкта да күзгә күренерлек терлек-мал калмады — сарык, сыерларга кадәр һәммәсе суелып ашалды. Орлыкка калдырасы ашлык та шул ук солдатларны ашату өчен тотылып бетте, һәркемне шомлы бер уй биләп алды:

— Бу «обжор» командасыннан ничек котылырга?

— Яңа салымнарны түләр өчен каян акча табарга?

Прошениеләрнең берсенә дә әлегәчә хәбәр килгәне юк. Озак сүз көрәштерү, шаулашулардан соң авыл халкы уртак бер фикергә килгәндәй булды:

— Төркиягә күчеп китәргә кирәк!

— Изге хәлифә җирендә тормыш яхшырак та, җиңелрәк тә булырга тиеш!

Шулай итеп, халыкның барлык теләк-омтылышлары бер максатка юнәлдерелде.

Хөкүмәт күченеп китүчеләргә тоткарлык итмәячәк дигән озынколак хәбәре, чыннан да, дөрес булып чыкты. Бу турыда, күченү шартларын белешер өчен, калага барган илчеләр кайтып сөйләделәр.

Мондый хәбәрне ишеткәч, халыкның шатлыгы эченә сыймады. Халык шау килде:

— Тизрәк җыенып бетәргә кирәк! Үзебезнең мөселман мәмләкәтенә китәбез!

Авылда мал-мөлкәт сату ыгы-зыгысы башланды. Сатучылар күп, ә алучы аз булганлыктан, бәяләр бик тиз түбән тәгәрәде.

* * *

Сәҗидә хәлифә җиренә күченеп китү турында имеш-мимешләр тарала башлагач та, һич икеләнмичә, китү фикерен яклаучылар ягына кушылды. Ул да башкалар кебек үк, ерактагы изге хәлифә җирендә үзләрен көткән матур бәхетле тормыш турында хыялланды һәм үзенең ирен ничек тә шунда китәргә күндерергә тырышты. Кызып-кызып дәлилли торгач, Сафа күнде һәм ерак сәфәргә әзерләнә башлады.

Йорт йөз сумга күрше авылның бер чирмешенә сатылды. Сафа аты белән сыерын да яхшы гына бәягә сатып җибәрде. Шулай әкренләп бар әйбер сатылып бетте, алып барасылары барысы да төйнәлеп, кузгалып китәсе генә калды дигәндә, кинәт такта яручы Керпе Сәлим кайтып төште.

Гадәттә, аз сөйләшүчән Сәлим карт бу юлы бик ачулы күренә иде. Ул, өйгә килеп керүе белән, кызып-кызып киявен ачуланырга тотынды, күченеп китүнең мәгънәсезлеге турында озаклап дәлилләгәч, сүзен дәвам итте:

— Хәлифә җирендә мондагыдан җиңелрәк булмаячак. Кояшы да, ачлыгы да һәр җирдә бертөсле.

Сафа белән Сәҗидә Сәлимнең сүзләрен таң калып тыңладылар. Ерак ил турындагы матур хыяллары кисәк кенә сүрелеп калгандай булды. Әгәр дә Сәлим Мәүла Колыга бераз алданрак кайтса, ул, ихтимал, кияве белән Сәҗидәне күчеп китмәскә күндерә дә алган булыр иде. Әмма хәзер соң иде инде.

— Күрәм, сез уегыздан кире кайтасы түгел, ахры. Ярар, алайса, китә бирегез! Әмма Хәтирә монда калачак! — дип кырт кисте карт Керпе.

Сафа белән Сәҗидә мондый карарны һич көтмәгәннәр иде. Хәтирә үзе дә аптырый калды. Сафа, үзенең ирлек хокукларын ярдәмгә чакырып, үз хатынымны мин теләсә кая алып китәм дип, төрлечә дәлилләр китереп карады. Әмма алары да Сәлим картка тәэсир итмәделәр.

— Хәтирә сиңа хатын булса, миңа ул — үз кызым! Синеңчә, мин аны күрәләтә ач үлемгә чыгарып җибәрергә тиешмени? Ә Хәтирәнең вакыты шундый: аңа тынычлык кирәк. Әллә инде шуны да аңламыйсызмы?

Авылдагы чуалышлар, күчену мәшәкатьләре ыгы-зыгысында, алар Хәтирәнең йөкле булуын һәм аны ерак юлга алып киту-

китмәү турында ныклап уйларга кирәклеген, ничектер, истән чыгарганнар иде.

Беркемдә дә картны күндерерлек дәлил табылмады, һәм аның карары белән килешергә туры килде.

Шактый озакка сузылган күңелсез тынлыктан соң, Саҗидә үзенең иренә таба борылды да:

— Сәлим абзый дөрес әйтә: Хәтирәне, чынлап та, үзебез белән алырга ярамас, әйдә, әлеге монда калсын,— диде.— Яңа җирдә урнашып, тормышны җайлап җибәргәч, син аны кайтып алып килерсең. Ул вакытта инде бала да үсә төшкән булыр, Алла боерса.

— Юлы кыен, ерак, бәлкем, кайтып та булмас,— дип көйде Сафа.

— Юк, кайтасың, Сафа... Барып төпләнгәч тә, Хәтирәне алырга кайтасың... Хәер, мин үзем дә аны алырга кайтырмын әле... Ерак юлдан курыкмыйм мин.

Ниһаять, күченеп китүчеләрнең беренче төркеме кузгаласы көн дә килеп җитте. Сандыклар, төенчекләр, самовар, бала бишекләре төялгән олаулар кәрваны бөтен авыл буена сузылды. Инешнең һәрбер борылыш, тугае, ярларындагы һәрбер агачы-куагы, юл буйларындагы һәрбер ташы-түмгәге элек-электән таныш һәм кадерле булган туган җирне ташлап, крестьяннар ерактагы чит-ят илгә карап юл тоттылар. Авылда калучы бар халык аларны озата чыкты. Басу капкасын узгач, азан әйтү өчен, кәрван бераз тукталып торды да яңадан юлын дәвам итте.

Хәтирә дә ерагая барган кәрван артыннан моңсуланып карап калды, аның колагына әле һаман Саҗидәнең юатып әйткән йомшак сүзләре ишетелеп торгандай булды:

— Ямансулама, Хәтирә... Матур, таза бер кыз бала тап безгә... Сафаны көт.



IX

Төрле тикшерү йортлары буйлап берсеннән икенчесенә күчереп азаплый торгач, Таҗи белән Фәхрине, ниһаять, төрмәгә китерделәр. Көннәрдән бер көнне аларны допроска алып килделәр. Тикшерүче Таҗига берничә сорау бирде. Тылмач казакъ татарча язылган ниндидер хатны кычкырып укырга керешкәч, Таҗиның аркасы буйлап салкын бер кымырҗык йөгереп узды.

Хатның эчтәлеге түбәндәгечә иде:

«...Таҗетдин Миңлебаев — безгә үзенең инсафсызлыгы белән күптән мәгълүм адәмдер. Бер заманны ул хәбәрсез-хәтерсез күздән югалып торды. Сөйлиләрдер, имеш, югалып торган елларында ул ниндидер шикле адәмнәр белән аралашкан, җинаятьле эшләрдә катнашып, яманлыклар кылып йөргән.

Арабызда Таҗетдин Миңлебаев ише бозык адәм булмаса, безнең тарафтан андый җинаятьле эшләр кылынмаган булыр иде. Бар гаеп аңардадыр...»

Прошениенең ахырында утызлап имза һәм тамга куелган иде. Алар арасында Таҗиның бертуган энесе Вафа куштан имзасы беренчеләрдән булып, аннан соң Шәмси мулла, Сабирҗан мәзин, умартачы Гыймади һәм Фәйзулла староста кебек авыл байларының имзалары да тезелеп киткән иде.

* * *

Төн уртасы якынлашып килә иде. Тоткыннар тынычсыз йокыга талганнар.

Таҗи йокламый. Аны күңелсез уйлар биләп алган иде. Тормыш аңа бернинди бәхет, шатлыгын күрсәтмәде. Менә ярты гасырга якын инде ул, дөньяда үз хакын даулап, бертуктаусыз көрәш алып бара, көче-сәләтенчә үз тормышын җайга салырга тырыша иде. Ләкин һичкем аны аңламады һәм аңларга теләмәде. Тормышта үзенә бер юаныч яки тынычлык та таба алмады.

Янәшәдә яткан Фәхри кыймылдап куйды.

— Күзгә йокы керми, уйландыра,— дип пышылдады Фәхри.

— Кешеләрнең әшәкелегенә гаҗәпләнмә син! Була торган хәл. Ә менә мин уйга калсам да ярый.

— Ник алай дисең, Таҗи абзый?

— Прошение борчый мине, Фәхри туган. Үткән белән кызыксынулары минем файдага булмаячак... Хатыным үлгәч, алты ел буе читтә югалып йөргәнемне хәтерлисеңдер бит? Иң элек мин Мәскәү тирәсендә чуен юлда эшләдем. Аннары сал бәйләп йөрдем... Шул чакта мин бер егет белән дуслаштым. Бик шәп

егет иде, мескен. Бервакыт кичен, эштән бушагач, су коенып кайтырга дип, Иделнең аргы ягына чыктык. Бер урында елга суы бөтерелә-бөтерелә ага. Иптәш егетем башы белән туп-туры шул күбекле суга сикерде. Күрәм: иптәшемнең башы күренеп китте дә янә югалды. Аны чоңгыл бөтереп алган да төпкә өстерәгән икән... Дустымны кызганып, җиргә йөзтүбән капландым да үксеп еларга керештем. Нишләргә, кая барырга? Торакка кайтып, фаҗигале хәлне сөйләргәме? Ә миңа ышанырлармы соң? Иптәшемне мин үзем үтергән димәсләрме? Димәк, мин үзем үк үз башымны төрмәгә илтеп тыгам булып чыга? Шулай дип уйладым да иптәшемнең киемнәрен кидем, ә үземнекеләрен таш асып су төбенә батырдым.

Шуннан соң поездга утырдым да Харьков ягына китеп бардым. Минем кесәдә мәрхүмнең паспорты ята иде. Мин дөньяда Хәмзә Бикмуллин булып яши башладым. Мин берзаман, шахтага эшкә кердем. Безнең арада Сәйфи дигән бер кочегар бар иде. Берәүләр ни сәбәптән бай яши дә, икенче берәүләр ни сәбәптән ач-ялангач яши — боларның һәммәсен дә ул гади генә итеп төшендереп дәлилләп сөйли торган иде. Шахтерларга акчаны аз түлиләр иде. Бер кичне Сәйфи килеп керде дә — әгәр жалуньягезне кистертәсегез килмәсә, иртәгә эшкә чыкмагыз,— ди. Без аның белән килешергә, ягъни забастовка ясарга булдык.

Бер атнадан кешеләрне кулга ала башладылар. Кулга алынучылар арасында кочегар Сәйфи дә бар иде. Аны мөселманнардан кемдер саткан булуы көн кебек ачык иде. Иснәнеп йөри торгач, белдек: ул приставның әшнәсе мулла икән. Өенә барып, мулланы шундук җәһәннәмгә олактырудан чак тыелып калдык.

Кичен безнең янга бер урыс эшчесе килде. Ул Сәйфине яхшы белә иде. «Кулга алынганнарны иртә таңда, калага озатыр өчен, станциягә алып барачаклар, коткару чарасы күрергә кирәк»,— диде.

Караңгы төндә юл буена тезелешеп яттык. Менә бервакыт юлда аяк тавышлары ишетелде. Күрәбез: унбишләп солдат сагы астында безнең иптәшләр килә. Сикереп тордык та дәррәү сакчылар өстенә ташландык. Коралларын тартып алдык, аяк-кулларын бәйләдек. Иптәшләребезнең һәммәсен йолып алуыбызга карамастан, минем ачуым сүрелмәгән иде әле. Шуңа күрә поселокка кире кайткач, мин туп-туры мулла өенә киттем, ишеген шакып: «Мулла абзый! Чыгып кына кер әле»,— дидем.

Мулла күзләрен угалап ишеген ачты да нинди йомыш белән килүемне сорады. Ә минем кулда —бая бер солдаттан талап алган

кылыч. Мулла сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, мин шул кылычны туп-туры аның күкрәгенә батырдым.

Шуннан соң мин яңадан Таҗи исеме белән Мәүла Колыга кайттым.

Хәмзә Бикмуллин исеменә бирелгән паспорт шахта конторасында торып калды. Менә шул паспорт буенча йомгакны сүтә башламагайлары дип куркам... Шахтада берничә мәртәбә рәсемгә төшүемне әйтмәдем бит әле мин сиңа. Ул рәсемнәр шахтада калды. Рәсемнәрне Хәмзәнең туган-үскән җиренә җибәреп белешмә сораулары бар...

* * *

Таҗиның барлык шик-шөбһәләре дөрескә чыкты.

Берничә көннән соң аны, аяк-кулларын богаулап, охранкага допроска алып киттеләр. Сорау алу беткәч, Таҗины протокол язмасына кул куярга, ягъни карага манчылган бармагы белән кәгазьгә тамга салырга мәҗбүр иттеләр.

Таң беленер-беленмәс үк, Казан округ судының шыксыз зур бинасы янына төркем-төркем кешеләр җыйнала башлады.

Бүген округ судында татар авылларында булып узган крестьян чуалышлары һәм түрә үтерүләр турындагы эш каралырга тиеш иде.

Халык хөкем залына кереп, эскәмияләргә утыруша башлады. Залга бер-бер артлы присяжныйлар керде.

Солдатлар, кылычларын шәрәләндереп, ишекнең ике ягына тезелеп бастылар. Залдагы гөжелдәү берьюлы тынды. Шул үлем тынлыгы эчендә залга, богауларын чыңлатып, тоткыннар төркеме килеп керде.

Кинәт бөтен залны:

— Әти! — дип кычкырган бала тавышы яңгыратты.

Моны, богауланган әтисенең ишектән керүен күреп, Фәхринең кечкенә кызы кычкырган иде. Фәхри үзе дә, дулкынлану, әсәрләнү кичергән хәлдә, хатынын һәм кызын сәламләү өчен кулын югары күтәрергә теләгән иде дә, авыр богау ирек бирмәде.

Бераздан кыңгырау шалтырады һәм тәртип караучының:

— Хөкем килә! Торып басыгыз! — дип кычкырган ачы тавышы ишетелде.

Шуннан соң гадәттән тыш озын, ялыктыргыч гаепләү актын уку башланды. Уку ике сәгать дәвам итте. Ниһаять, хөкем рәисе, гаепләнүчеләр утырган якка таба башын борып:

— Таҗетдин Мөхәммәтсалих Миңлебаев,— дип эндәште.

Таҗи урыныннан торды.

Хөкем рәисе өстәлдә җәеп салынган кәгазьләрне актаргалап, Таҗига сорау бирде:

— Хәмзә Бикмуллин дигән кешене үтерүдә, сакчыларга корал белән һөҗүм итүдә, мулланы үтерүдә һәм, ниһаять, авылга хезмәт вазифасын үтәү өчен килгән становой белән стражникларны үтерүдә сез үзегезне гаепле санныйсызмы?

Таҗи җавап бирмәде... Соңгы сүздән бөтенләй баш тартты.

Җир өстенә төнге караңгылык төште.

Төрмә камераларында барысы да йоклыйлар. Болытлар арасыннан ай калкып чыкты да көмеш нурларын тәрәзә аша камера эченә сирпеде.

Шулвакыт ишегалдында ниндидер ыгы-зыгы башланды. Таш идәнгә дөп-дөп басып надзирательләр узды.

Фәхри, богау чылбырлары шалтырамасын өчен, аяк очларына гына басып, тәрәзә каршына килде һәм гәүдәсен ия төште. Габдулла, аның җилкәсенә менеп басып, куллары белән тәрәзә рәшәткәсенә тотынды да салкын ай нуры яктырткан ишегалдына карады.

— Кемнедер асарга алып баралар бугай,— диде ул, ләкин сүзен әйтеп бетерә алмады, астан каты итеп кычкырган тавыш ишетелде:

— Хушыгыз, дуслар! Үлемгә барам! Хуш, Фәхри, сау бул!

Бу Таҗи иде.

Тавышка бөтен төрмә уянды, тоткыннар дулкынлана, шаулаша башладылар.

Габдулла, акылдан шашкан кешедәй кызу-кызу атлап, камераны айкап йөренергә тотынды.

Ә Фәхри боргалана-өзгәләнә идәндә ауный һәм елый иде.

Каторгага озатылыр алдыннан Мәфтухасы белән күрешкәч, Фәхри аңа беренче сүз итеп:

— Таҗи абзыйны астылар! — дип белдерде.

XII—XIII

Хаҗга баручыларга һәм чит илгә күчеп китүчеләргә ярдәм күрсәтүче Одесса конторасы гөрләп эшләп ята иде.

Контораның башында Ибраһим Әдигәев дигән гаять хәйләкәр һәм мәкерле бер адәм тора иде.

Чит ил паспортын биш-алты сум түләп бернинди мәшәкатьсез һәркемгә алырга мөмкин. Ә Ибраһим Әдигәев булышлыгы белән

алганда исә, паспортның бәһасе егерме биш сумнарга күтәрелә иде. Хаҗга баручылар, ни хөкүмәт тәртипләрен, ни рус телен белмәүче кешеләр буларак, һәммәсе котылгысыз рәвештә Ибраһим Әдигәев куйган җәтмәгә эләгә торалар.

Татар авылларын дер селкеткән фетнә-чуалышлардан соң күп кенә крестьяннарның Төркиягә күчеп китәргә теләк белдерүе Ибраһим өчен күктән төшкән бер бәхет булды.

Ибраһим Әдигәев, бераз соңгарак калып булса да, күченеп китүчеләрнең һәммәсенә паспортлар юнәтә алды. Мәүлә Колы кешеләренә, Греция пароходының дүртенче классына утыру өчен, билетлар алынды. Ибраһим һәрбер билетны үз бәясеннән кыйммәтрәк сатты, билгеле.

Менә кузгалыр вакыт җиткәнен белдереп, пароход кычкыртты... Хатын-кызлар, колакларын учлары белән каплап, чәрелдәп җибәрделәр, бала-чага елаша башлады.

XIV

Бүген пароход Истанбулга килеп җитәргә тиеш!

Каяндыр каты җил чыгып, су өстендә куәтле дулкыннар күтәрелде. Офык ягыннан кара болытлар кузгалып, тиз арада алар бөтен дөньяны каплап алдылар. Кояш күздән югалды, тирә-якны шомландыргыч соры караңгылык басты. Бу чын-чыннан давыл башлануы иде.

Сафа белән Саҗидә пароходның койрык өлешендә, тирә-якны тамаша кылып, сүзсез генә басып баралар.

Кинәт пароход борынында басып торучы пассажирлар арасында җанлану башланды, шатлыклы авазлар ишетелде.

Сафа белән Саҗидә шул якка борылып карадылар. Еракта, офык читендә, тар кара тасма булып, Төркия ярлары сызылып киткән иде. Пароход Босфор бугазына якынлашкан саен, Истанбул шәһәре үзе дә аермачык булып күренде.

— Истанбул! — дип кычкырып җибәрде Саҗидә, эченә җыелган шатлыклы хисләрен тыя алмыйча.

Аның шул бер сүзе электр тогы сукандай һәммә кешене тетрәнергә мәҗбүр итте. Тормышта соңгы өметне гәүдәләндерүче бәхет иле, сагынып көтеп алынган җир — менә ул, күз алдында!

Шәһәр инде уч төбендә яткан кебек аермачык булып күренә иде. Кая гына күз ташлама — зиннәтле сарайлар, манаралар, мәчетләр...

Менә ул көтеп алынган «изге» җир туфрагы! Ләкин кайда соң аларны каршы алырга тиешле кешеләр?

XV—XVI

Нindидер шикле кыяфәтле һәм эш-кәсепләре билгесез кешеләр, саранча өередәй, мөһаҗирләрне төрле яктан сырып алдылар да, колакларына пышылдап, берсеннән-берсе гаҗәбрәк киңәш-тәкъдимнәре белән бимазалый башладылар.

Истанбулның бу «яхшы ниятле» адәмнәре арасында мөсафирханә хуҗасы Хәмзә хаҗи да бөтерелә иде. Инде кулга төште дип исәпләгән табышның юкка чыгу ихтималын күз алдына китереп, хаҗи яшен тизлеге белән мөһаҗирләр төркеме эченә атылды:

— Ышанмагыз сез ул Ходa бәндәләргә! — диде ул, кисәтеп.— Бөтен өерләре белән алдакчы, әшәкеләр алар!

Мөһаҗирләр Хәмзә хаҗиның сүзләренә игътибар белән колак салып, тормышны җайлау мәсьәләсендә ашыгыч адымнар ясамаска һәм һәммәсе бер җирдә — Хәмзә хаҗи мөсафирханәсендә яшәп торырга карар кылдылар.

Күңелләре бераз тынычлангач та, мөһаҗирләр Истанбул белән танышып керергә дип урамга ашыктылар. Сәҗидә дә иң һәйбәт киемнәрен киеп, керфекләренә сөрмә тартып, Сафасы белән бергә урамга чыкты.

Аларга киеме белән татар мөһаҗирләренә охшаган тагын бер кеше очрады.

Бу кешенең сүзләре, инсафлы төс-кыяфәте Сафа белән Сәҗидәне тынычландырып җибәрде. Алар ачылып китеп, аның белән сөйләшә башладылар. Яңа таныш үзенең Хатип исемле булуы һәм монда Иделнең тау ягындагы бер авылдан күчеп килүен әйтте.

— Сез кая барырга җыенган идегез соң әле?

— Болай гына, шәһәр карап керикме әллә дигән идек! — диде Сафа.

— Тик карагыз аны, итәкне җыебрак йөрегез,— дип кисәтте Хатип,— халкы яман... Монда ялган өстенә ялган... Бөтен эш-тормышлары алдауга корылган... Каршы килмәсәгез, мин дә сезнең белән бара алам. Барыбер эшем юк.

Шаярта-көлә алар юлларын дәвам иттеләр.

Кинәт каяндыр полицейский калкып чыкты.

— Сез мөселманнармы? — дип сорады ул, юлга аркылы төшеп.— Бу хатын да сезнең беләнме?

— Эвет!

— Алайса, рәхим итеп, минем арттан барыгыз.

Полиция участогында ниндидер бер чиновник бик кырыс һәм ачулы тавыш белән аларны битәрләргә тотынды.

— Безнең мәмләкәт кануннары мөслимәләргә урамда ачык йөз белән йөрергә кушмыйдыр.

— Белгән булсак соң... Белмәдек бит, агай-эне!

Сафа чит илдән килгән кеше булуы аркасында гына бәлагә тарымый калды.

XVII

Мөһаҗирләр өзлексез агылып килә тордылар. Төрек хөкүмәте тәмам аптырашта калды. Акча юк, качакларны урнаштыру өчен алдан бернинди чара күрелмәгән. Мөһаҗирләр чит-ят бу илдә үз тормышларын кору, җайлауны тулысынча үз көчләре, үз белдекләре белән хәл итәргә мәҗбүр булдылар. Куркып, пышылдап кына, үзләренә даими торыр урын һәм эш табу турында үзара кайгырышырга тотындылар.

Ә качаклар һаман килә, күбәя бардылар. Әгәр гел шулай килә торсалар, озакламый ниндидер төзәлгесез бәла-каза туачагы көн кебек ачык иде. Шул сәбәпле хөкүмәт әһелләре ахыр чиктә «Һәйәте мөһаҗирия»[1] исемле бер комиссия төзергә мәҗбүр булдылар.

Башка барлык мөһаҗирләр шикелле Мәүла Колы крестьяннары да Ходайның һәр якты көнен «Һәйәте мөһаҗирия»дә йөреп уздырдылар.

Мәүла Колыларга җай туры килде: күптән түгел генә — «Һәйәт»тә эшли башлаган бер татар мөһаҗире — «Пеләш Кадыйр» ярдәмендә алар үзләренең рус паспортларын төркинекенә алыштырып, Анадолуда урнашу хокукы бирә торган рәсми кәгазь алуга ирештеләр. Дөрес, моның өчен аларга шактый зур ришвәт бирергә туры килде килүен!

Сафаның авылдашлары Хатипны үз араларына алуга каршы килмәделәр. Эш тик Кадыйрның риза булу-булмавында гына тора иде. Шуңа күрә аны яңадан эзләп табарга туры килде. Хәлне аңлаткач, Кадыйр Хатипка:

— Ярар! Җайларбыз! Бир паспортыңны! — диде.

Барлык шик-шөбһәләргә карамастан, мөһаҗирләр яңа паспортлар һәм күчену өчен кирәкле башка язуларны кулларына алдылар.

[1] Һәйәте мөһаҗирия — чит илдән килүчеләр эше буенча комитет.

XVIII

Җәйнең сулыш юлларын капларлык эссе, бөркү бер көнендә, мөһаҗирләр төялгән поезд Искешәһәр вокзалына килеп туктады.

Озак та үтми, Мәүла Колы крестьяннары туктаган мөсафирханә бинасы янына халык төркеме җыела башлады. Ирләр, бераз тамак ялгап алгач та урыннарыннан кузгалып, Мөтәсарриф канцеляриясен[1] эзләргә дип яңадан урамга чыгып киттеләр.

Мөһаҗирләрне сәркатип — карт төрек — кабул итте. Ул коры гына:

— Бай әфәнде буш түгел, иртәгә килегез,— диде.

Кичен мөсафирханә янына тагын ачык авызлар өере җыйналды. Шулвакыт кинәт төркем эчендә саф татарчалап дәшкән көр тавыш ишетелде.

Крестьяннар, якташ кешене уртага алып, аңа сораулар яудыра башладылар.

— Мин Гариф атлы. Тегермәндә хезмәт итәм,— диде ул.

Гариф, озын юл үтеп тәмам алҗыган крестьяннарның өметышанычларын бөтенләй җимереп ташларга теле бармыйча, хәлне берникадәр матурлабрак сурәтләргә тырышты.

— Аллаһы бирсә, тора-бара барысы да рәтләнер,— диде ул.— Ләкин кыенлыклары да күп булыр, билгеле. Мөтәсаррифка, мәсәлән, чәйлек бирергә кирәк, бирмәсәң, ул сезне бөтенләй уңдырышсыз җиргә илтеп тыгачак. Ә анда тагын волость начальнигы, ягъни аларча әйтсәк, нахия мөдире һәм башка шундый түрәләр бар. Аларын да бәхшишсез[2] калдырып булмый.

— Бәхшишен бирербез бирүен. Ә менә тел белмәү җәфалый, беркем дә безне аңламый,— дип куйды крестьяннардан берәү.

Гариф, үз якташларының хәсрәтле йөзләренә карап торды да көтмәгәндә:

— Безнең тегермән әлегә эшсез тора. Теләсәгез, мин бу эштә булыша алам,— дип тәкъдим итте.

Мөһаҗирләр Гарифның тәкъдимен шатланып кабул иттеләр.

Иртәгесен мөһаҗирләр, калдык-постык ризыклары белән тамак ялгадылар да таңда ук килеп җиткән Гариф җитәкчелегендә яңадан Мөтәсарриф канцеляриясенә юнәлделәр.

Мөтәсарриф килеп җитте. Ул Гарифны да үз янына чакырып, аның белән озак кына нидер сөйләшеп торды. Тегесе, якташларына таба борылып:

---

[1] Мөтәсарриф канцеляриясе — җирле идарә.

[2] Бәхшишсез — *бу урында:* ришвәт мәгънәсендә килә.

— Хәл кылынды, ди. Акча бирергә куша!

Икенче көнне иртән, офык читләре кояш нурларына манчылыр-манчылмас, мөсафирханәгә янә Гариф килеп җитте.

Мөһаҗирләр кәрваны, ниһаять, кузгалып китеп, Анадолу ярымутравының борынгы бер сукмагы буйлап сәфәр чыкканда, утлы шардай кызарып янган кояш офык читеннән әле аз гына югары күтәрелеп килә иде.

Өйлә вакытларында, тәмам арып-талып, үлеп тамаклары ачкан һәм сусаудан авызлары кипшергән бер хәлдә, алар наһия үзәгенә — хәрабәләрдәй таралып утырган ярым җимерек бер авылга килеп керделәр.

Ул арада мөдир үзе дә күренде. Ул бернинди кинаясез-нисез ришвәт сорады. Мөһаҗирләр, берникадәр вакыт ык-мык килеп, офтанып тордылар да куеннарына тыгылдылар...

Мөдир үзенә бирелгән акчаларны һәммәсенең дә күз алдында берәмләп санап чыкты. Аннары коңгырт-көрән төстәге бәләкәй ишәгенә менеп атланды да мөһаҗирләргә, үзе артыннан иярергә кушып, кулын болгады.

Кояш көйдергән соргылт үләнле буш дала буйлап күпмедер баргач, кечкенә генә урманлы һәм инешле уйсу җиргә җиттеләр. Мөдир кулларын киң итеп җәйде дә нидер әйтеп куйды. Мөһаҗирләр шундук сораулы күз карашларын Гарифка текәделәр.

— Ул әйтә, менә шушы җир, урман-сулар һәммәсе дә сезнеке, ди.

Бар кеше тантаналы бер төстә тынып калды. Аларны гүя кинәт кенә кодрәтле бер хис биләп алды. Алар һәммәсе берьюлы җиргә тезләнделәр, кулларын кушырып, белгән догаларын укырга керештеләр. Тормыш яңабаштан башлана иде — һәрхәлдә, аларга бу шулай булып тоелды.

Ишәкләр өстендәге йөкләр төшерелеп беткәч, куучы төрекләрне кайтарып җибәрделәр. Аннары җир өстенә келәм-юрганнар җәеп, учак яктылар, чәй кайнатырга куйдылар.

Күңелле бәйрәм кичке караңгыга кадәр дәвам итте.

XIX

Икенче көнне мөһаҗирләр йокыдан дәрт һәм шат күңел белән тордылар. Сәҗидә һичкем көтмәгәндә, үзенең авылдашларына:

— Әйдәгез әле, башта якындагы берәр авылга барып кайтыйк,— дип әйтеп куйды.— Күрик әле, мондагы халык ничегрәк яши икән?

Башкалар да бу эшне бик мәгъкуль күрде.

Озак та үтми, сайлап алынган унлап илче Гариф җитәкчелегендә төрек авылына карап юл тоттылар. Бераздан авылга барып та җиттеләр. Авылда бер генә төзек йорт та күзгә чалынмады диярлек. Урамда аларны үгез кебек таза, юан бер төрек каршы алды. Шушы авылның старостасы — көй мохтары иде бу. Ул, мөһаҗирләргә моннан егерме еллар элек үк Төркиягә күчеп килеп, якында гына авыл булып утырган татарлар янына барып килергә киңәш итте.

Әлеге татар авылы тирәсендә яшел басулар да, ашлык тулы ындырлар да күренми. Шалаш-куышлар янында гына чүп үләне басып киткән бәрәңге түтәлләре күзгә чалынгалый иде. Авыл читендәге калкулыкта берничә һәйбәт таза йорт күренә. Арада татар авылларындагы йортларны хәтерләткән бер өй янында туктадылар.

Төбәкнең иң бай, дәүләтле кешесе — авыл старостасы Гафият хаҗи йорты иде бу.

Ишегалдындагы каралты-кура белән таныштырып чыккач, хуҗа кеше кунакларны өйгә керергә чакырды. Үзен бик кунакчыл тотты, һәркайсына ихтирамлы булды, ачык чырай күрсәтте.

Кунакларның берсе сагаеп кына сорап куйды:

— Хаҗи абзый, тик менә авылыгыз гына ничектер фәкыйрь күренә. Нигә алай?

— Хезмәт иткән — морадына ирешкән. Ә ялкау-иренчәкләр, алма пеш, авызыма төш дип яттылар. Каян килгәндер аларга шундый ялкаулык.

Гафият хаҗи, кунакларны озата чыгып, һәрберсенә:

— Андый-мондый кыенлык-мазар туса, туп-туры миңа килегез,— дип үгет-нәсыйхәт биреп алды.— Бодай, бәрәңге ише нәрсәләр миндә һәрвакыт табылыр... Сез якташларыма бәһане кыйбат куймам...

Авыл читендәге кыйшык өй-куышларның берсе яныннан узганда, аларга камыш чыпта үреп утыручы бер татар карты очрады.

Юлчылар туктап картка сәлам бирделәр.

— Син, бабай, ник иген икмисең? Иген иксәң файдалырак булыр иде бит?

— Ә җирне ничек эшкәртмәк кирәк? Хәзер иген игү турында уйларга соң инде.

— Ә элегрәк, килгән шәпкә, ни өчен җир эшенә тотынмадың? Әнә Гафият хаҗи, тырыша-тырыша торгач, баеп ук киткән бит.

— Ә син аңардан сорап карамадыңмы: монда килгәндә, аның күпме акчасы булды икән? Өч мең акча белән килде ул монда, беләсең килсә. Шундый акча булса, без дә, шәт, бу көнгә калмаган булыр идек.

XX

Күрше авыллардан күреп-белеп кайткан гыйбрәтләр Мәүла Колы крестьяннарын зур хафага салды. Берәүләр моннан тизрәк табан ялтыратырга һәм берәр җирдә көнлекче хезмәтенә ялла-нырга киңәш итте. Икенчеләре Төркиядән китүне яклады. Өченчеләре сабыр булырга өндәде.

Бәхәс озакка сузылды, кешеләрнең кычкырыша-тарткалаша тамаклары карлыгып бетте. Ниһаять, җыенны иртәгә дәвам итәргә булып, йокларга яттылар.

Сажидә дә, башкалар шикелле, башваткыч сорауларга җавап эзләде. Таңга кадәр ниндидер бер ачык фикергә килергә кирәк. Һәм Сажидә яңадан үзенең газаплы уйларына чума иде.

Карар кабул ителде. Сажидә, ашкынулы бер хискә буйсынып, кисәк кенә үзенең иренә таба борылды:

— Йә, нәрсә уйладың? Берәр төрле уйга килдеңме?

Сафа «юк» дигәнне аңлатып башын чайкады.

Сафа шундук хатынының фикер юнәлешен аңлап алды: хатыны аны күңелен төшермәскә, дөньяда яхшырак тормыш даулап, армый-талмый тырышырга, хезмәт итәргә чакыра иде.

* * *

Кояш чыгып та өлгермәгән иде әле, Сафа белән Сажидә, мыштым гына җыендылар да, кулларына балта тотып, якындагы әрәмәлеккә китеп бардылар. Шундук кызу эш башланды. Сажидә бәйләм-бәйләм тал чыбыгы әзерләде, ә Сафа юанрак агачларны кисеп казыклар юнды.

Башка мөһаҗирләр Сафа белән Сажидәнең каядыр китеп югалуын бары чәй табыны янына утыргач кына сизеп алдылар. Кая китәсе иттеләр икән?

Берәвесе гөман кылып:

— Безнең Ирдәүкә берәр хикмәтле эш артыннан йөри торгандыр. Ире аңа ияреп киткәндер. Озакламый кайтып та җитәрләр,— диде.

— Әнә кайтып та киләләр!

Инеш яры буйлап ике кеше ниндидер зур-зур бәйләмнәр тартып килә иде.

Шабыр тиргә баткан Сафа белән Саҗидә җәйләүгә кайтып җиттеләр.

Сорашу-аңлашулар башланды:

— Нәстәгә апкайттыгыз бу чыбыкларны?

— Читән тотарга.

— Әллә сез, чынлап та, монда калырга булдыгыз?

— Хуҗалыкны башлап җибәрү кайда да бертөсле авыр. Шулай булгачтын, нигә анда кайтырга, лутчы инде бәхетне монда сынап карарга.

Кешеләр тынып калдылар. Сафа белән Саҗидәнең кисәк кенә эш башлап җибәрүләре күбесенә дөрес юл кебек тоелды.

— Хатын-кызга дөрес сүз сөйләсә дә ышанма! — диде шулчак шыгырдавык тавышлы берәү. Ләкин Саҗидә аны шундук куырып-өтеп алды:

— Шаһи абзый! Бар кайта бир. Сине монда беркем дә көчләп тотмый. Әмма инде башкаларга киртә булма.— Аннары ул Сафага таба борылды:

— Әйдә, бераз тамак ялгап алыйк та тагын эшкә тотыныйк.

Саҗидә, иелеп, җирдән чәйнекне алды да, җәһәт-җәһәт атлап, инеш буена төшеп китте. Сафа, учак ягар өчен, чыбык-чабык туракларга тотынды.

— Менә, ичмасам, хатын! — диде Хатип, сокланып.— Теләсә кайсыбызның борынына чиртә торган!

Чәй эчкәннән соң Сафа, Хатип һәм тагын берничә ир баулар алып камышлыкка киттеләр. Калган ирләр таллыкка чыбык чабарга юнәлделәр.

Саҗидә исә, савыт-сабаны юып, табынны җыештыргач, казыклар очларга керешге. Бу эшен бетергәч, җиңнәрен сызганды, толымнарын баш артына чөеп куйды һәм җир өстенә казык очы белән тирән сызык сызды да, су сибеп, туфрагын йомшартты. Аннары, бөтен көченә селтәнеп, шушы чокыр-сызыкка беренче казыкны китереп кадады. Беренче казык артыннан икенчесе, өченчесе утыртып куелды...

XXI

Куышның түбәсен кәз белән ябарга булдылар. Бу эшкә Саҗидә алынды. Сафаның исә үз эше — инеш буена төшеп, кирпеч сугарга кызыл балчык әзерлисе бар иде.

Кичен, һәммәсе бергә җыелып сөйләшкән вакытта, Гариф ык-мык килеп утырды-утырды да кинәт тәвәккәлләп сүз сорады.

Гариф сүзне ерактан башлады:

— Без монда сезгә хәтле үк килгән кешеләр. Монда килеп урнашкач та, без, бөтен көчебезне куеп, рәтле тормыш корып булмасмы дип тырыштык. Әмма бернигә дә ирешә алмадык. Бердәмлек булмады бездә. Һәркайсыбыз үз ягына каерды. Сезгә, шушы үткәннәрдән гыйбрәт алып, бүгеннән үк җиң сызганып эшкә тотынырга, хуҗалыкны җайлый башларга кирәк. Ләкин һәрбер эштә ниндидер тәртип, максат булуы шарт бит. Әйтик, сезгә берничә йөз китмән алырга кирәк, ди. Беләсезме, моңа күпме акча кирәк булачак? Аннары тагын һәр хуҗалык үзендә берәр ишәк булдырырга тиеш. Боларга да күпмедер акча чыгарып салмый булмый. Ә бу мәсьәләне башкача хәл итеп булмыймы соң? Була, минемчә. Әгәр дә мәгәр сез, барыгыз бергә оешып, өч пар үгез белән өч сабан сатып алсагыз, очсызга да төшәр, мәшәкате дә азрак булыр иде. Эшне дә үзара оешкан төстә алып барырга мөмкин. Әйтик, бер төркем кеше бөтен бер мәхәллә халкы өчен җир сөрә, икенче бер төркеме буралык бүрәнә әзерли, өченче төркеме кирпеч суга...

Гариф сүзен тәмамлады. Бүтәннәр, таң калып, беравык дәшми тордылар. Аннары ризасызлык белдереп кычкырган тавышлар ишетелә башлады:

— Булмас нәстә сөйлисең син, Гариф.

— Җир яралганга күпмедер, белмим, әмма шундый тузга язмаган тәртипләр турында без беренче ишетәбез.

Сажидә Гарифның сөйләгәннәрен тын да алмый тыңлады. Әйтерсең лә Гариф аның кайдадыр күңеле төбендә басылып яткан һәм әле үз-үзенә дә ахырынача аңлашылып җитмәгән яшерен серләрен сөйли иде.

Аның сабырлыгы калмады.

— Картлар рөхсәт итсә, күңелемдәге бер уйны әйтер идем,— диде ул, тынлыкны бозып.

Барысы да Сажидәгә борылып карадылар.

— Хуш, әйтеп кара уеңны, киленкәй. Бәлкем, чынлап та, акыллы сүз ишетербез.

Сажидә кырмыска, бал кортлары турындагы балачак хатирәләрен сөйләп чыкты да ахырда сүзен болай дип тәмамлады:

— Кырмыскалар да, бал кортлары да үзара гел ярдәмләшеп эшлиләр. Бәләкәй генә җан ияләре булсалар да, аларның тормышларында гыйбрәтле хикмәтләр бар. Алардан үрнәк алуның безнең өчен һич гөнаһсы булмас. Гариф абый киңәшен тотсак, начар килеп чыгар дисезме? Әйдәгез, тәвәккәллик, җәмәгать!

Бәхәс төн уртасына хәтле сузылды. Шулай да халык уртак фикергә килә алмады. Аннары кешеләр әкренләп таралыша башладылар. Хатип белән Гариф кына Сафаның учагы янында чүгәләп калдылар. Бераздан аларга тагын берәү килеп кушылды. Монысы әле кичә генә Мәүла Колыга кайтып китәргә дип атлыгып йөргән Камали абзый иде.

— Һәммәбезнең дә акылы төштән соң шул безнең, җәмәгать,— диде ул, сүзгә кушылып.— Менә мин дә әле генә уйлап куйдым: якташның сүзенә колак салып, әллә монда калыйммы икән, дим. Бергәләп тотынсак, җиңеп чыгарбыз бит, син ничек уйлыйсың, якташ, ә?

Бу сөйләшү икенче көннең иртәсендә дә дәвам итте. Иртә таңнан алар янына Сафаның Мәүла Колыдагы элекке күршесе Җәләй абзый килде.

— Саумысез, якташлар! Ни гәп корып утырасыз? —диде ул, Сафага эндәшеп.

— Бергәләп зур эшкә тотынырга исәп,— дип куйды Сафа.

— Алла ярдәм бирсен, алайса! — диде Җәләй абзый. Аннары якташларына сынаулы күз карашы ташлап алгач сүзен дәвам итте:

— Шул, җәмәгать: кесәмдә йөз сиксән тәңкә акчам бар да, эшләргә ике кулым бар. Әгәр каршы килмәсәгез, мине дә үз арагызга алыгыз.

Шулай итеп, мөһаҗирләрнең кечкенә генә әртиленә тагын бер гаилә килеп кушылды.

XXII

Сабан ашлыгы соңгарып чәчелсә дә, озак та үтми, тишелеп, яшел хәтфә сыман күпереп үсәргә тотынды.

Беркөнне җәйләүгә Гафият хаҗи килде. Гафият хаҗидан соң, тәсбихын тотып, тагын бер кунак килеп төште. Монысы — күршедәге төрек авылы Мохтары — зур корсаклы бер карт иде. Крестьяннарның баш күтәрми тырышып эшләүләрен күреп, ул чынлап торып гаҗәпләнде һәм, аларны хуплагандай, әледән-әле башын чайкады. Ә мондагы бөтен эшнең атаманы хатын-кыз кеше — Саҗидә икәнлеген ишеткәч исә, балаларча шатланып:

— Алайса, бу авыл мотлака Кадын-көй[1] дип аталмалы,— дип кычкырып җибәрде.

Һәм, чыннан да, шуннан соң авылны Кадын-көй дип атап йөртә башладылар.

[1] Кадын-көй — хатын-кыз авылы дигән мәгънәдә.

Икенче җәйне инде Кадын-көй авылы халкы, тормышларын ярыйсы гына җайга салып, Сабан туе, җыеннарны да бәйрәм итә башлаган иде.

Егерме ел буена бернинди күңеллелек күрми гомер иткән Гафият хаҗи авылы кешеләренә бу җыен бигрәк тә ошады.

Әйе, бу җәй эчендә Кадын-көй танымаслык булып үзгәргән иде. Яңа йортлар, каралтылар үсеп чыккан, йорт яны бакчаларында яшелчә һәм җиләк-җимеш агачлары утыртылган. Мунчалар да күренгәли. Мәчет салдыру турында да сүзләр бара.

Җәй үтеп, яңгырлы салкын көз килде. Бу көзне Кадын-көй кешеләре, туган ил гадәте буенча, яңа җирдә беренче тапкыр каз өмәсе уздырдылар.

XXIII

Бу елны Анадолуда кыш аеруча салкын килде. Елгалар боз белән капланды, җир өстеннән кыш буе кар китмәде. Боларга тагын, үч иткәндәй, йогышлы тиф килеп өстәлде.

Тиф Кадын-көй авылын да читләтеп узмады.

Башкалар белән беррәттән, тиф Саҗидәне дә үзенең рәхимсез тырнагына эләктереп алды.

Әле салкыннан калтырана-калтырана, әле кызышудан үзен-үзе кая куярга белмичә чәбәләнә-чәбәләнә бик озак хаста булып ятты ул.

...Хатыны авырый башлаганнан бирле Сафа тәмам акылдан шашты. Кулына бернинди эш тотмады, сәгатьләр буе хатынының ятагы янында, күзләрен ниндидер бер ноктага төбәгән килеш, моңаеп утыра торган булды.

Саҗидәне авылда һәммәсе дә бик ярата, үз итә иде. Шуңа күрә күрше-күлән, таныш-белешләр, үзләрендә дә авырып ятучылар булуга да карамастан, әледән-әле Саҗидәнең хәлен белешеп тордылар, аңа ризыгын китерделәр, өендәге эшләрен эшләштеләр.

Авырып китүнең унөченче көнендә Саҗидәнең хәле бигрәк тә начарланды. Иртәдән каты саташу башланды. Аның терелүенә өметен җуя башлаган Сафа, тәмам куркуга калып, хатыны яныннан бер адым да читкә китмәде. Кинәт Саҗидә күзләрен ачты. Аннары ул, Сафаны танып, кипшергән иреннәре белән чак-чак кына елмайгандай итте. Сафа якынрак килеп, аның өстенә иелде. Саҗидә коры сөяккә калган ябык кулларын ничек кирәк алай югары күтәрде дә Сафаның муенына сарылды. Аның бөтен төсе-кыяфәте ниндидер сүзе барлыгын күрсәтеп тора иде. Хәтта аның

иреннәре дә кыймылдап куйды шикелле, ләкин сүзләре ишетелмәде. Бары тик күзләреннән генә ике бөртек яшь мөлдерәп чыкты.

— Хәтирәне...

Бу сүзне Сафа ишетүдән бигрәк үзе чамалады шикелле.

— Беләм, беләм, акыллым! Хәтирәне алып килергә!

Сәҗидәнең куллары, Сафаның иңбашыннан шуып төшеп, сәкегә бәрелделәр. Сафа су алып килергә дип почмакка ташланды. Ләкин соң иде инде. Ул әйләнеп килгәндә, Сәҗидәнең күз кабаклары яңадан ачылып, тонык күзләре бер ноктага төбәлгән килеш хәрәкәтсез катып калган иде.

XXIV

Анадолу күгендә, ниһаять, язның җылы кояшы хакимлек итә башлады.

Сафага гына бу яз шатлык китермәде. Сәҗидәсе гүр иясе булганнан соң ул үзе дә, тиф эләктереп, өч ай буе түшәк өстендә яткан иде. Рәхимсез үлемне ул бары үзенең рухи ныклыгы белән генә җиңә алды.

Менә ул, таягына таянган килеш, чалыш-чолыш атлап үтте дә тәрәзә янындагы эскәмиягә килеп утырды.

Сафа уйга калды. Әйе, аның сөекле Сәҗидәсе юк инде. Сафага хәзер Хәтирә кирәк. Хәтирә генә аны ялгызлыктан коткарачак.

«Әйе, Хәтирәне, һичшиксез, монда алып килергә кирәк!» — дип уйлады Сафа.

Шулвакыт аның башы очында:

«Саумы, күрше, хәлләрең ничек?» дигән ирләр тавышы ишетелде.

Аның каршында Гариф белән Хатип басып тора иде.

— Ә сездә ни хәлләр бар? Мин бит берни дә белмим.

— Хода рәхмәте белән кышны исән-сау уздырдык,— диде Хатип.

Шулай да алар, авыру Сафаны борчымас өчен, авылдагы кайбер күңелсез хәбәрләрне әйтми калдырдылар. Хәлбуки бу вакытта инде илгизәр Гариф һәм мәрхүмә Сәҗидәнең хыялы белән барлыкка килгән әлеге күмәк әртил соңгы көннәрен яши, аны кичекмәстән тарату турында югарыдан боерык килеп төшкән иде. Аның өстенә Гафият хаҗи үзеннән алган бурычларны вакытында түләмәгәннәре өчен әртил әгъзаларының хуҗалыктагы барлык калдык-постык әйберләрен яздырып чыккан иде.

Сафа үзенең дусларына бик озак күзләрен төбәп торды.

— Минем сезгә әйтәсе сүзем бар иде,— диде ул аннары.— Минем туган илгә кайтасым килә. Бу эштә миңа сез генә ярдәм итә аласыз. Үтенечем шундый: сез миңа юллык акча бирегез. Мин хатыным белән баламны алып килергә телим. Мәрхүмә Саҗидәнең васыяте шундый. Мин ул васыятьне үтәргә тиеш.

Сафаның туган илгә кайтырга карар кылуы шул ук көнне бөтен авылга билгеле булды. Халык бердәм рәвештә аны акылсызлыкта гаепләде. Ләкин терелеп җитеп бераз хәл алгач та, Сафа юлга җыена башлады.

Истанбул Сафага элеккегә караганда да шау-шулырак һәм шомлырак булып тоелды.

Дахилия назаратында Сафага чит ил паспортлары бирелми дип әйттеләр.

Тәмам аптыраштa калган Сафа, ни кылырга белмичә, туптуры Хәмзә хаҗи мөсафирханәсенә юнәлде.

Хәмзә хаҗи беравык уйланып торды.

— Син монда кире әйләнеп кайтам дип Коръән тотып ант итәргә тиеш, аннан мин сиңа ярдәм итәрмен.

— Мондый изгелегегез өчен берни дә җәлләмәс идем дә бит, хаҗи абзый, тик минем акчам бик чамалы шул.

Хәмзә хаҗиның йөзе шундук караңгыланып китте.

— Алайса, эш барып чыкмастыр, энем. «Коры кашык авыз ерта...»

Кая барырга? Сафа авыр сулап куйды һәм, кемнеңдер үзенә таба төбәлгән үткен карашын тоеп, башын күтәрде. Аның каршында бер әфәнде басып тора иде.

— Русиягә, өйгә кайтасы килдемени? — дип сорады ул.— Кил әле бире. Эш нәрсәдә? Паспорт кирәкме?

— Ие, өйгә кайтыр өчен үземә пашпорт ала алмыйм. Сугыш буласы, ди, җибәрмиләр.

— Болай булгачыннан, сиңа чынлап та өйгә кайтырга кирәк, якташым,— диде әфәнде.— Әйдә, кит. Монда синнән башка да сугымга җибәрер кешеләр табылыр.— Шуннан соң ул тирә-ягына сагаюлы күз карашы ташлап алды да сүзен дәвам итте:

— Өйгә кайтыр өчен сиңа, якташкаем, бернинди паспорт та кирәкми. Аның юлларын гына белергә кирәк.

— Зинһар, миңа да шул юлларны өйрәт, әфәнде, бу игелегең өчен сиңа гомерем буе дога кылыр идем,— дип пышылдады Сафа.

— Инде тыңла,— диде әфәнде җитдиләнеп.— Син моннан Фракия аша Болгариягә барырсың, аннары Румыния аша

җәяүләп Россиягә китәрсең. Синнән беркем дә паспорт сорамас. Сафа вакытны сузып тормастан, шул ук көнне Истанбулдан Болгариягә таба юл тотты.

XXV

Сафа белән Саҗидә күченеп киткәннән соң күп тә үтмәде, Хәтирә кыз бала тапты. Ләкин бу вакыйга үзе ничек кенә шатлыклы булмасын, Сафалардан аерылу кайгысы Хәтирәне борчый иде. Ярый әле бер юанычы — нәни кызы, Галиясе бар. Аның белән булганда ул үзенең ялгызлыгын да оныта. Ләкин Сафа белән Саҗидә аның күз алдында барыбер шәүләләнеп тордылар. Аңа — Хәтирәгә — карата нинди ихтирамлы, нинди ягымлы иде бит алар.

Озакламый менә хат-хәбәрләре килер... Аннары күп тә үтмәс, Галия белән аны алырга үзләре дә кайтып җитәр...

Ләкин хат-хәбәр һаман килми дә килми. Хәтирәнең җиде төн урталарында, һәрбер кыштырдауга уянып, бәрелә-сугыла урамга йөгереп чыгулары, капка төбендә тилмереп басып торулары — һәммәсе дә заяга гына булды.

Сизелмичә генә көз килеп җитте. Халык, җәйге мәшәкатьләрдән арынып, инде ишек төбендә көтеп торган кышны каршылау хәстәренә керешге. Хәтирәнең әтисе Сәлим абзый белән абыйсы Вәли, аркаларына озын пычкыларын асып, читкә акча эшләргә чыгып киттеләр. Сәлим карт Хәтирәне үзе белән бергә такта яру эшенә алып китәргә карар бирде.

XXVI

Бу юлы да Сәлим карт кайчандыр инде үзе бер-ике тапкыр эшләп киткән такта яру заводына ялланырга булды.

Сибгать карт Сәлимгә таба борылып:

— Син, Сәлим кордаш, быел бөтен оян белән купкансың, ахрысы,— дип куйды.

— Ие, быел кызны да алып килергә булдым,— диде Керпе.— Авылда берүзе нишләп ятсын? Киявем хаҗга китеп барды...

— Әти шаярта гына, Сибгать абзый,— дип сүзгә кысылды Хәтирә.— Минем ирем Төркиягә күченүчеләр белән китте... Ирем мине кайтып алырга тиеш.

Сибгать карт Хәтирә янында бераз тоткарланды.

— Яраткан хатынын өйдә ялгызын калдырып читкә киткән кешене кайда күргәнең бар синең? — дип сөйләнде ул.— Шулай ташлап киткән икән, димәк, аны кире кайтыр дип көтәсе юк,

ул анда үзенә хатын табар. Ә мин сиңа, кызым, менә дигән кияү табам.

— Минем ирем барыбер кайтачак, барыбер кайтачак,— дип үрсәләнде Хәтирә, башка әйтер сүз таба алмыйча, һәм аның күзләренә яшь тыгылды.

XXVII

Инде менә өченче кыш рәттән Хәтирә такта яру заводы казармаларында яши. Кеше һәрнәрсәгә ияләшә диләр. Хәтирә дә шулай үзенең яңа тормышына ияләшә барды. Такта ячучыларның керләрен уды, өс-башларын ямаштырды, ашарларына пешерде. Хезмәте өчен үзләре белеп түләсәләр — алды, түләргә онытсалар — сорап йөдәтмәде. Тора-бара ир-аттан да ятсынмый башлады.

Көн төнгә, төн көнгә алышына торды. Шул рәвешчә, сизелми генә атналар, айлар үтте.

Кыш урталарындарак кинәт Сибгать абзый каты авырып китте. Аны инде терелмәс дип тә уйлый башлаганнар иде.

Ләкин карт һәммәсенең гаҗәпләнүенә каршы, терелеп аягына басты.

Бу «могҗизалы» терелүнең бердәнбер сәбәпчесе Хәтирә иде. Ул беркемгә бер сүз әйтмичә, картны карарга-багарга кереште. Тырышлыгы эзсез калмады — авыру әкренләп-әкренләп булса да һаман сәламәтләнү ягына таба барды. Ниһаять, Сибгать карт тәмам ныгып, урын-җирдән торып ук йөри башлады.

Шул көннән башлап Хәтирәгә ихтирам, игътибар арта төште.

Сибгать абзый терелеп, бер атна да узмагандыр, кинәт Сәлим карт авырый башлады. Сәлим карт хаста булып яткан көннәрдә, кешеләр Хәтирәнең тагын бер яхшы ягы белән таныштылар. Һәр иртәне, авыруга кирәкле бөтен нәрсәләрне җайлап, хәстәрләп куйгач, Хәтирә ирләр киеменә киенә дә абыйсы Вәли белән бергә эшкә китеп бара иде. Абыйсы кузла өстенә этисе урынына менеп баса, Хәтирә түбәндә Вәли урынын ала. Тотыналар шуннан чаж да чож такта ярырга!

Хәтирәнең хатын-кыз арасында сирәк очрый торган бу маһирлыгына бөтен казарма халкы таң калды.

Шушы вакыйгадан соң Хәтирәнең абруе тагын да күтәрелде. Хәзер Хәтирә белән дорфа мөгамәләдә булырга берәү дә батырчылык итмәде. Алай гынамы, кайбер буйдак егетләр чын-чынлап аңа өйләнергә уйлап йөри башладылар.

Лəкин Хəтирəнең җавабы аларның һəркайсына да бертөсле булды.

— Минем ирем бар. Озакламый кайта ул, мине алырга кайта.

Бервакытны Халикъ исемле ниндидер егеттəн яучы булып Сибгать абзый үзе килде.

Хəтирəне үз кызы кебек яратып йөргəн һəм шундый əйбəт егеттəн яучы булып килгəн Сибгать абзыйны кире борып җибəрү, ниһаять, Сəлим карт белəн Вəлинең сабырлыгын шартлатты. Алар, дəррəү кубып, Хəтирəгə ябырылдылар:

— Əллə кая китеп югалган ул иреңне гүр иясе булганчы көтəргə уйлыйсыңмы əллə?

— Без сине кызың белəн гомер буе шулай ашатып, тəрбиялəп торырга тиешмени? — дидейлəр.

Əтисе белəн абыйсыннан мондый сүз ишетү бик кыен булса да, Хəтирə үз карарыннан кайтмады. Аны кияүгə чыгарга берничек тə күндерə алмадылар.

— Мин бит ир хатыны. Сафа кайткач, мин аңа нəрсə əйтермен? — диде ул.

Яз җиткəч, Сəлим карт та, барлы-юклы мал-мөлкəтен җыйнап, улы Вəли, кызы Хəтирə һəм оныгы Галия белəн үзенең туган-үскəн авылына — Мəүлə Колыга юл алды.

Көз көне Керпе Сəлимнең авылдан китүенə беркем игътибар итмəгəн шикелле, яз көне дə аның кире əйлəнеп кайтуына игътибар итүче булмады.

XXVIII

Кичкелекне ашап, өйдəгелəр йокыга талгач, Хəтирə баскыч төбенə чыгып утырды.

Авыл йоклый иде. Бары тик кайбер йортларда гына берəн-сəрəн утлар күренгəли. Еракта-еракта агач тукмаклар белəн шап-шоп киндер тукмаклаган тонык тавышлар ишетелə. Кызлар инде бу, үзлəренə бирнəлек киндер тукмаклыйлар. Ə менə Хəтирəгə андый шатлыкларны беркайчан да күрергə туры килмəде. Аның балалык еллары да, кыз чагы да ялгызлыкта, аз сүзле, караңгы чырайлы əтисе һəм абыйсы кулы астында узды. Бары кияүгə чыгып, Сафа, Саҗидə янында тату яшəгəн бер еллык гомере генə, караңгы төн күгендə җемелдəгəн якты йолдыз кебек, аның хəтеренə бердəнбер шатлык булып сеңеп калган. Лəкин нинди кыска булды бу бəхет! Һəм аны инде беркайчан да кире кайтарып булмастыр.

Урыныннан да кузгалмыйча бик озак утырды Хәтирә. Күк караңгылыгы әкрен генә эри барып, йолдызлар бер-бер артлы сүнә башладылар. Җир өстенә иртәнге чык төште.

Хәтирәнең бөтен тәне чирап китте. Каяндыр салкынча җил исеп куйды. Хәтирә урыныннан торды да өйгә кереп, йокларга ятты.

Ләкин ул йоклап китә алмады. Тышта инде кояш чыгып килә иде. Авыл уянган иде.

Шулвакыт Хәтирә көтү китәсе юлга каршы яктан урам буйлап әкрен генә атлап килгән сәләмә киемле бер хәерчене күреп алды. Һавага тузан болыты туздырып барган көтү турысына җиткәч, ул беравык күздән югалып торды. Аннары тагын күренде. Менә ул ниндидер әбине туктатты.

«Юл күрсәтүен сорый, ахры!» — дип уйлады Хәтирә.

Кинәт әби йөзе белән борылып басты да, кулын күтәреп, Хәтирәләр ягына төртеп күрсәтте. Хәерче туп-туры Хәтирәләргә таба килә башлады. Хәзер инде аны аермачык күрергә була иде. Чаларган чәч, яңак сөякләре бүлтәеп торган ябык йөз, чуалып, укмашып беткән озын сакал. Өс-башы да сәләмә, бер аягында киндерә белән бәйләп куелган иске галош, икенчесендә — әллә куныччы киселгән читек, әллә кәвеш, аңламассың. Аркасында биштәрле капчык, кулында юл таягы.

«Туп-туры безгә таба килә. Өйдән садакалык берәр нәрсә алып чыгасы булыр, ахры»,— дип уйлап алды Хәтирә.

Ул арада хәерче карт, бөтенләй якын ук килеп, Хәтирә каршына туктады да, таягына таянган килеш, күзләрен томырып аңа карап тора башлады.

«Ник миңа болай текәлеп катты әле бу?» — дип уйлады Хәтирә, гаҗәпләнеп. Ул инде, өйдән садака алып чыгарга дип, урыныннан кузгалган иде, ләкин шулчакны карт калтыранган тавыш белән аңа эндәште:

— Танымыйсыңмы, Хәтирә?

Хәтирәнең йөрәге дерт итеп куйды, тыны кысылды:

— Сафа!

— Ие, мин!..— диде Сафа һәм, тамагына төер тыгылып, кинәт тынып калды. Сакал баскан ач яңаклары буйлап яшь бөртекләре тәгәрәде. Хәтирә исә, бөтен дөньясын онытып, иренең муенына сарылды. Сафаның кулындагы таягы шап итеп җиргә төште...

Шулай кочаклانышкан килеш алар шактый озак басып тордылар; исләренә килгәндә яннарына инде бер төркем бала-чага җыелып өлгергән иде. Ләкин алар юкка гына өметләнеп көттеләр: Сафа бернинди бүләк, күчтәнәч алып кайтмаган иде.

Ярлы-ябагай Төркиягә күчеп киткән елның көзендә үк Бохарадан Шәмси мулланың улы Барый мәхдүм кайтып төште. Ул Уфага барып имам хатип мөгаллим[1] дәрәҗәсенә имтихан тотты. Иске мәктәп авылның яшь имамы кулына күчте.

Хәер, Әкрәм карый үзе дә, хатыны Җиһан абыстай да моңа артык пошынмадылар. Карый һәрвакыттагыча Ходага сыенды, аңардан рәхим-шәфкать көтте, ә эшчән, тырыш Җиһан абыстай үзенә бүтән төрле кәсепләр тапты.

Әнисенең холкы, табигатендәге барлык яхшы сыйфатларны үзенә алган уллары Исмәгыйль дә картларга зур таяныч булды.

Озын, зифа буйлы бу егет үзенең гадәттән тыш тырышлыгы, бернинди авырлыклар алдында да баш имәс ныклыгы һәм өлгерлеге белән яшьтәшләре арасында бик нык аерылып тора иде.

Җәйге каникул вакытында авылга кайтып хәллерәк бер хуҗалыкка батрак булып ялланды. Байга хезмәт иткән арада үз җирен дә сөреп чәчәргә өлгерде. Йокы, ял күрмәде, әмма аның каравы ул инде көзен үзенең мәдрәсәсенә тыныч күңел белән чыгып китә ала, әти-әнисе кышын ач-ялангач калыр дип курыкмый иде.

Сафаның Төркиядән кайтып керү хәбәрен ишеткәч тә, Исмәгыйль шундук Керпе Сәлимнәргә йөгерде.

Исмәгыйль туп-туры Сафа янына якынлашты, сәлам бирде.

[1] Имам хатип мөгаллим — мулла һәм укытучы була алу өчен бирелгән исем.

— Саҗидә апага туган илләрне кайтып күрү насыйп булмаган икән! — диде Исмәгыйль.— Ә безнең башка авылдашларыбыз ничек анда?

— Төгәл генә әйтә алмыйм, Исмәгыйль энем. Минем аннан чыгып киткәнемә ике ел булды инде.

— Ике ел?! Кайларда йөрдең соң син, Сафа абзый?

— Миңа пашпортны бирмәделәр. Киттем җәяү. Болгариядә акчам бетте. Эшкә ялландым, юллык акча тупладым. Румыния дигән илгә килеп җиткәч, янә акчам бетте. Тагын эшкә ялланып акча әмәлләргә туры килде. Бессарабиядә берзаман урятник эләктереп алды. Мине пашпортсыз адәм дип, ятап белән Казанга озаттылар. Кыш буе шулай бер каладан икенчесенә куалап йөрттеләр. Аннары, янә ятап белән, безнең булыска күчерделәр. Алланың рәхмәте, ярый әле мине күреп белүчеләр табылды. Бабаң Миңлебай хакына дип, минә кичәгенәк кенә ирекккә чыгардылар.

— Тагын анда кире китәргә исәп юкмы соң, Сафа абзый?

Сафа аптырап калды. Киту-китмәү мәсьәләсе әле аның үзенә дә ачык түгел иде.

Исмәгыйль һичкем көтмәгәндә:

— Сафа абзый, син чабата үрә беләсеңме? — дип сорады.

— Кайчандыр белә идем. Ә нәрсә?

— Минемчә, сиңа беркая да китәргә кирәкмидер, Сафа абзый. Без синең белән икәүләп чабата ясарга керешсәк, ничек булыр? Без икәү үрә торыр идек, Хәтирә апа базарга сатарга йөрер иде. Аннары урак урырбыз, печәнен чабарбыз — беткәнмени авылда эш...

Исмәгыйль китәргә дип урыныннан кузгалды.

— Син бүген һәйбәтләп уйла да, иртәгә җавабын әйтерсең, ярыймы, Сафа абзый? — диде ул хушлашканда.

Туган-үскән йорты турысына килеп җиткәч тә, Сафа капкага кадакланган язулы калайга игътибар итте. Анда кәкре-бөкре хәрефләр белән татарча һәм русча «Староста» дип язып куелган иде.

Хәер, Сафа моңа артык гаҗәпләнмәде, чөнки үткән ел вафат булган Фәйзулла урынына Вафаның староста булып калуын ул ишеткән иде инде.

Сафа ян капканы ачып, ишегалдына күз төшерде: әллә монда ялгыш килеп эләктеме соң ул? Аның каршында алты почмаклы, калай түбәле өр-яңа йорт тора иде.

Соңгы тапкыр күрешкәннән соң, Вафа юанаеп киткән, корсак үстергән, кызара-бүртә төшкән иде.

Энекәш белән абый кеше ике куллап күрешеп алдылар.

Күңелендә беркемгә карата кинә тотмаган, беркатлырак табигатьле Сафа монда килгәндә үзен ачык йөз белән каршы алырлар дип өмет иткән иде. Ләкин Вафаны очраткач, аның бу өметләре кинәт сүрелеп калды. Хәерче дәрәҗәсенә төшкән Сафа каршысында хәзер бөтенләй икенче дөнья — байлар, туклар, бәхетлеләр басып тора иде.

— Кайтуың турында ишеткән идем,— дип сүз башлады Вафа.— Барып чыга алмадым инде, гафу ит. Хәзер мин эш кешесе бит, әле тегесе, әле монысы дигәндәй... Әйе, әйтергә дә онытканмын, яз көне әнкәйне җирләдек. Үләр алдыннан һәммәбезне бәхилләде. Тик менә сине генә искә алмады, мәрхүмә.

Сафа абыйсының бу сүзләрен җавапсыз калдырды.

Сафа ян капканы ачып урамга чыкты. Капка ачылып ябылган тавышка тагын эт өрергә тотынды.

XXIX

Янә өч ел вакыт узып китте. Мәүла Колыга тагын җәй килде. Бу җәйне берөзлексез яңгыр койды. Ике-өч көнгә яңгыр туктап, күк йөзе аязып китсә, бөтен авыл халкы болыннарга, басукырларга ашыга иде.

Болын башыннан иген басуларына таба култык сыман ерып кергән киң тирән бер чокыр сузыла иде. Бу чокыр заманында зур агым сулы елга булган диләр.

Елга өсте елдан-ел тоташ саз үләне белән каплана бара, шуның белән бергә, аның алдавыч хәтәр урыннары да күбәйгәннән-күбәя бара.

Яр өстендәге учарланып үскән карама агачы күләгәсенә көтүче карт белән бер яшь хатын һәм тагын сары чәчле кечкенә бер кыз бала килеп туктадылар. Көтүче карт, иңбашына атландырып салган чыбыркысын һәм аркасындагы биштәр капчыгын җир өстенә куеп, билендәге кечкенә чәйнеген чишеп алды да аны хатынга тоттырды, аннары агач төбенә сузылып ятты. Хатын кеше чәйнекне алып чишмәгә төшеп китте, ә кыз бала учак ягар өчен чыбык-чабык җыярга кереште.

Бераздан инде учак өстеннән төтен күтәрелеп, ялкын телләре чәйнекнең корымлы төбен ялый башлаган иде.

Шул вакытны кинәт көтү эчендә ниндидер ыгы-зыгы купты. Кәҗәләр колакларын торгызып як-якка каранырга тотындылар.

Сарыклар, куркынган тавыш белән бакырып, уңга-сулга ташландылар.

Агачлар арасыннан бер ят кеше килеп чыкты. Ул өстенә чикмән сыман бер нәрсә кигән, аягында ертык күн итек. Башында — бүрек. Бөтен битен куе кара сакал, төк баскан.

Мөсафир кеше көтүченең утырырга кыставын әйтерсең лә бөтенләй ишетмәде, баскан җирендә тик басып торды. Аның йөзендә гадәттән тыш бер гаҗәпләнү чагыла иде.

— Карале, бу син түгелме соң, Сафа? — диде кинәт мөсафир.

Көтүче карт урыныннан сикереп торды:

— Ә син... син Фәхриме?

— Шул үзе... Мин качып кайттым...

Алар, күз яше аралаш, бер-берсенең кочакларына ташландылар.

— Мин синең Сафа икәнеңне Хәтирәне таныгач кына чамаладым,— диде Фәхри.— Бик нык үзгәргәнсең, Сафа... Ни булды сиңа?

— Язмыш шулай булды инде... Менә өченче елым инде көтүче булып йөрим. Кышын чыпта-кап сугам, җәен — менә үзең күрәсең... Абый кебек карун булып яшәгәнче, көтү көтүең мең мәртәбә артыграк... Карале, нәрсә һаман аягүрә басып торабыз әле? Әйдә, утыр, чәй эчәрбез! Шунда үзең турында сөйләрсең. Ничек шулай ычкына алдың син, сөйлә әле!

— Ике урыс егете белән бергәләп качтык. Бөтен Себерне җәяү уздык... Күп газаплар күрелде... Һәммәсен берьюлы сөйләп бетерерлек тә түгел.

— Сине монда мәңгегә югалган кешеләр хисабында саныйлар,— диде Сафа.

— Мәфтуха! Алар исән-саулармы?

Сафа аягүрә торып басты да болын ягына күзләрен текәде.

— Әнә анда Сәләхи абзыйның биясе күренә. Бар, ашык, әбәд вакытларына өлгерерсең әле.

Фәхри әрәмәлеккә барып җиткәндә, аның гаиләсе төшке ашны төгәлләп, табын янынннан торып килә иде. Аны берәү дә танымады. Кечкенә кызы Миңсылу хәтта, ят кешене күреп, куркып калган иде.

— Курыкма, кызым, мин синең әтиең бит! — диде аңа Фәхри.

Кызы артыннан әрәмәлектән чыгып килгән Мәфтуха баштта Фәхринең бу сүзләрен ялгыш ишеттемме әллә дип уйлады,

аннары аңа таба текәлеп карап торды-торды да, кинәт шатлыктан кычкырып җибәреп, мөсафирның муенына барып сарылды.

Шундук бүтәннәр дә йөгерешеп килеп җиттеләр.

Икенче көннең иртәсендә инде аның кайтуы турындагы хәбәр бөтен авылга таралып өлгергән иде.

XXX

Яз җитәр-җитмәс үк авылга, бер-бер артлы, кыш буе читтә сезонлы эшләрдә йөргән агай-эне кайта башлый. Быел урак өстендә Мәүла Колыга могътәбәр кунакларның берсе кайтып төште. Сабирҗан мәзиннең абыйсы Мостафа бай иде бу.

Авыл халкы арасында Мостафа бай турында мондыйрак сүзләр ишетелде:

— Аны ни өчен болай бер урыннан икенче урынга чабып йөри дисең? Чөнки акчасы күп.

Берәвесе хыялланыбрак әйтеп куйды:

— Үткән кайтуында бик шәп булган иде — бөтен авылны пылау белән сыйлаган иде,— диде.

Мостафа үткән кайткандагы кебек үк, бу юлы да авыл халкын пылау белән сыйларга булды.

Икенче көнне иртүк инешнең аргы ягында учаклар ягып җибәрделәр. Авыл халкына:

— Иртәгә, җомга намазыннан соң, Мостафа бай авылның барлык ир затларын пылау мәҗлесенә чакыра,— дип хәбәр иттеләр.

Инеш буендагы зур алан өсте төрле төстәге шакмаклы ашъяулыклардан чуп-чуар булган иде.

Коръән укылып беткәч, садака өләшү башланды. Халык кулларны дәррәү югары күтәреп, битне сыйпап, дога кылды.

Бер рәт тамак туйгандай булгач, моназара[1] башланып китте.

Сабирҗан мәзин, Сәләхи картка таба борылып:

— Синең киявең кайткан дигәннәр иде. Ник әле ул мәҗлестә күренми? — дип сорады.

— Тәгаен әйтә алмыйм, хәзрәт... Күрәсең, эшен ташлап китәсе килмәгәндер.

Умартачы Гыймади, яшьле күзләрен чекерәйтеп, ачу белән әйтеп куйды:

— Сак булыгыз, җәмәгать!.. Авылда катырҗан качырып ятабыз! Моның өчен безнең башыбыздан сыйпамаслар!

[1] Моназара — әңгәмә.

Барысы да сагаеп, тынып калдылар. Ниһаять, Вафа староста сүз алды:

— Минем фикер шундый: Фәхрине тотарга да булыска илтеп тапшырырга кирәк!

Табын дәррәү гүелдәп куйды:

— Күптән тотып бирергә кирәк иде инде!

Шулвакыт көтмәгәндә, бөтен шау-шуны күмеп, һавада көчле яшь тавыш яңгырап китте:

— Җәмәгать!

Исмәгыйль дулкынланган бер кыяфәттә урыныннан торып баскан иде.

— Җәмәгать! Акылыгыздамы сез? Фәхри абый кайчан да булса угрылык кылганмы? Яисә бүтән берәр кара кәсепкә тотынганмы? Аның катыр китүе безнең барыбыз өчен түгел идемени? Ул бит анда бөтенләй нахактан китте. Андый кешене кызганырга, аңа ярдәм итәргә кирәк иде, ә сез аны тотып, каядыр илтеп тапшырырга телисез. Тагын бер кат уйлап карагыз!

Әле генә Фәхрине тотып бирергә дип кычкырган кешеләр башларын түбән иеп, тынып калдылар. Бары Вафа староста гына түзмәде:

— Нәрсә сөйли ул малай актыгы? Акыл өйрәтеп маташкан була бит, хәерсез!

Куштаннар да телгә килделәр:

— Авызында ана сөте кипмәгән, шулай да олылар сүзенә тыгыла!

— Атаңнан оялыр идең!

Исмәгыйль үзенә садака итеп бирелгән биш сумлык кәгазь акчаны куеныннан чыгарып табын уртасына ыргытты да, кырт борылып, кызу-кызу адымнар белән авылга таба китеп барды.

Ниһаять, авыл халкы, көндезге эшләрдән тәмам арып-талып, йокларга ята башлады. Шул вакытны Сәләхи карт йортының ишеген кактылар. Сотский белән пүнәтәйләр ияртеп, Фәхрине кулга алырга дип килгән Вафа староста иде бу. Ләкин бөтен йортны, ишегалларын айкап чыксалар да, Фәхрине таба алмадылар. Фәхри әйтерсең лә суга төшкәндәй каядыр юкка чыкты.

XXXI

Шуннан соңгы көннәрдәге эзләнүләр дә бернинди нәтиҗә бирмәде. Фәхри һаман табылмады.

Яңгырлы, караңгы көзге көннәр килде. Бертуктаусыз яңгыр койды. Керпе Сәлим белән Вәли читкә такта яру эшенә киттеләр.

Сафа белән Хәтирә яңадан чыпта-кап сугу хәстәренә керештеләр, ә Исмәгыйль Казанга, үзенең мәдрәсәсенә китәргә җыена башлады.

Төн иде. Әкрәм карыйлар өендә бөтен кеше инде йокыга киткән иде. Шул чакны кемдер әкрен генә ишек шакыды. Исмәгыйль урыныннан торды, бишмәтен иңенә элеп, өйалдына чыкты.

— Кем ул анда? — дип сорады шәкерт.

— Бу мин, Хәтирә. Сине Сафа чакыра, безгә кил. «Ул» бездә.

Сибәләп яуган яңгыр астында алар сөйләшмичә генә бардылар. Керпенең тәбәнәк, кыйшык өе янына килеп җиттеләр дә ут алынмаган караңгы бүлмәгә керделәр.

— Бу синме, Исмәгыйль? — дип эндәште берәү караңгыдан.

— Ие, ие, Фәхри абзый, мин. Ни булды?

— Киңәшергә кирәк иде, Исмәгыйль,— диде Фәхри.— Урманда кышларга хәтәррәк булыр дим. Чәүкәле качаклары, кышка калага мине дә чакыралар. Китим микән, дим. Сафадан сораган идем, тәгаен әйтә алмый, кыенсына.

— Паспортың юк инде синең, ә? — дип сорады Исмәгыйль.

— Каян булсын инде ул миндә...

— Ә синең, Сафа абзый?

— Миндә дә юк.

Шулчакны Хәтирә кыюсыз гына әйтеп куйды:

— Әгәр яраса, Вәли абый әнә иске паспортын онытып калдырган...

Исмәгыйль шатлыктан чак кына кычкырып җибәрмәде.

— Булды бу, алайса, Фәхри абзый. Шул иске паспорт белән син безнең мәдрәсәгә берәр эшкә урнаша алырсың дип уйлыйм. Бездә алай төпченеп тормыйлар. Үзем булышырмын. Казанга килгәч, Кәрим ахун мәдрәсәсе кайда дип сорарсың. Калганын мин үзем рәтләрмен.

Кыш бик тиз керде, аз гына вакыт эчендә инеш суларын катырып, йорт-кураларны көрт басып китте.

Койма буйларында, көртләрне казып, көл чокырлары ясадылар. Ике атнага бер мәртәбә Мәүла Колыга көл җыючы бер абзый килә иде.

Соңгы килүендә ул авыл халкы арасында коточкыч шомлы бер хәбәр таратты:

— Япун патшасы безнең патшага хат җибәргән, имеш. Бөтен халкың белән безнең дингә күч дип. Безнең патшаның бик тә ачуы чыккан. Тегене сугышка чакырган.

Озак та үтми, волостьтан белешеп кайткан Вафа староста, җыен җыеп, Япония белән сугыш башлануы турындагы хәбәрнең, чыннан да, дөрес икәнлеген белдерде.

Япун армиясе ярым ач, ярым ялангач, һәм ярты-йорты коралланган рус солдатларын йөзәрләбен-меңәрләбен берьюлы кыра торды. Тәмам куркуга калган халык арасында берсеннән-берсе шомлырак яңа хәбәрләр туугa сәбәп булды.

Тышта җәяүле буран улаган яз алды төннәренең берсендә Сафалар өенә качак Фәхри килеп керде. Шаккатудан телсезәнсез калган Сафа һәм Хәтирә белән күрешкәннән соң, ул тотлыга-тотлыга үзенең шатлыгын сөйләргә керәште:

— Менә ул! Башлана башлады. Күрерсез, бу сугыш безнең өчен файдага гына булачак. Шундый чакта ничек мәдрәсәдә бикләнеп ятмак кирәк?.. Чәүкәледәге иптәшләр белән киңәштабыш иттем дә менә туп-туры монда кайттым.

Фәхринең сүзләренә Сафа ышанырга да, ышанмаска да белмәде; авыр итеп бер көрсенде дә:

— Ходай кушып, шулай гына була күрсен инде,— диде.

Ә ул Фәхри әйткән заманнар, чыннан да, якынлашып килә иде.

Авыл яңа дәвер — «бөек алмашынулар» дәвере алдында тора иде.

Исегездә калдырыгыз.

Р о м а н дип катлаулы сюжетлы, персонажлары һәм вакыйгалары күп булган күләмле чәчмә әсәрләргә әйтәләр.

Бу гомуми билгеләмә романны күләм ягыннан гына ачыклый.

Иң зур чәчмә әсәр буларак, аның җитди, асыл сыйфатлары да бар. Шул сыйфатлар белән танышыйк:

1. Роман беренче чиратта башка жанрлардан үзенең төзелеше белән аерылып тора. Аның сюжет кысасын шәхес-җәмгыять каршылыгы тәшкил итә.

2. Романдагы вакыйгалар җәмгыятьне (шәхеснең тирә-юнен) төрле яктан күрсәтәләр. Шәхес (герой) бу вакыйгаларга катнашып, аларны үзара бәйли һәм шул рәвешле сюжет тудыра.

3. Романдагы шәхес үзенең холкы һәм дөньяга карашы белән тирә-юнендәге башка кешеләрдән аерылып тора. Аның җәмгыять белән (тирә-юне белән) каршылыкка килү сәбәбе дә шуннан гыйбарәт. Шуңа күрә геройның тормыш юлы да башкаларның гадәти, типик биографиясенә охшамый.

4. Сюжет дәвамында герой үзенең рухи халәтен яки дөньяга карашын үзгәртә.

Романның билгеләмәсеннән чыгып, Мәхмүт Галәү әсәрендәге (ике китабын бер роман итеп өйрәнәбез) вакыйгаларны: җәмгыятьне төрле яктан күрсәтүче һәм геройның үзенчәлекле сыйфатларын күрсәтүче вакыйгалар дип ике өлешкә җыя алабыз. Шулай итсәк, геройның тирә-юне белән каршылыкка килгән вакыйгалар бу ике өлешнең бәйләнеше (конфликты, ярашуы) була.

Романны укыганда вакыйгаларны шул рәвешле җыеп карарга тырышыйк.

Биремнәр һәм сораулар

1. «Каклаган казны...», «Сөлекләр», «Миңлебайныкылар», «Ирдәүкә» дип аталган бүлекчәләрнең темаларын табыгыз. Автор куйган исемнәрне шул темаларны ачыклап килгән башка исемнәр белән алыштырыгыз.

2. Ни өчен М. Галәү бер бүлекчәсен «Сөлекләр» дип атаган? Аңлатыгыз.

3. Бу бүлекләрдәге кабатлануларны табыгыз. Кабатлануларның нигә кирәк булуын аңлатыгыз.

4. Бүлекчәләрдә сөйләнгән өч гаиләнең уртак ягын табыгыз. Бу гаиләләргә үзегезнең бәягезне бирегез.

5. Өч гаилә эчендәге каршылыклар турында сөйләгез.

Каршылыклар, конфликтлар тусын өчен, аларның сәбәпләре булырга тиеш.

Роман авторы, конфликт сәбәпләрен арттыра-арттыра, әсәр сюжетын чуалтып, чәбәләндереп бетерә. Конфликтның шундый чуалган, төенләнгән сәбәпләренә **интрига** диләр.

6. VI—XVII бүлекчәләрнең эчтәлеген гомумиләштереп, бер вакыйга итеп карагыз. Бу гомумиләштерелгән вакыйгага исем бирегез.

I—VI бүлекчәләрдә әдип укучыларны җәмгыять төркемнәре һәм төп персонажлары белән таныштырды. Җәмгыять төркемнәре — авыл халкы да, гаилә әгъзалары да торгынлык хәлендә калды. Ләкин VII—XVII бүлекчәләрдә бар да хәрәкәткә килә: гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр конфликт дәрәҗәсенә күтәрелеп ала. Бәйләнеш гаиләләр арасында да туа башлый.

7. Әле генә гомумиләштереп исем биргән вакыйганы конфликтлары төрле булган ике вакыйгага бүлегез. Вакыйгаларның икесендә дә тирәлек белән шәхес каршылыгын күрсәтегез. Конфликтларның ике төрле нигезен ачыклагыз.

8. Романдагы төп геройны әйтегез.

9. «Ашлык урынына балчык» дип исемләнгән бүлекне вакыйгаларга таркатыгыз. Вакыйгаларның темаларын атап исемнәр бирегез.

10. Вафаның шәһәрдә ничек баюы турында сөйләгез. Баю юлларын санап чыкканнан соң, аңа кеше буларак бәя бирегез. Сыйфатларын санап чыгыгыз.

11. Сажидәнең Сафаны өйләндергән вакыттагы кичерешләре турында сөйләгез. Бу вакыйганы Г. Исхакыйның «Остазбикә» әсәрендәге шундый ук вакыйга белән чагыштырыгыз һәм ике вакыйганың аермасын әйтегез.

12. «Мөһаҗирләр» романының XIV бүлеккә кадәрге өлешен мөмкин кадәр зуррак вакыйгаларга бүлегез.

Вакыйгалар охшаш яклары (темалары, төзелешләре, яки проблемалары) булганда гына, берләшеп, зур вакыйгага җыела алалар.

13. Сан алу вакыйгасындагы фаҗиганең сәбәпләрен әйтегез. Сан алу һәм утар талау вакыйгаларында җәмгыятьнең нинди сыйфатлары ачыла? Анда җәмгыятьнең бер генә өлеше катнаша. Ни өчен шулай?

14. Тажи белән Фәхригә бәя бирегез.

15. Әсәрне тулысынча укып чыктыгыз. Ләкин аны өйрәнүне дәвам итәбез. Роман жанры таләп иткәнчә, автор ни турында язса да үзенең төп темасын ача: җәмгыять — шәхес мөнәсәбәте турында сөйли.

Җәмгыять — шәхес мөнәсәбәте ахыр чиктә кешенең тормышы, көндәлек яшәеше ул. Шуңа күрә шәхес — җәмгыять каршылыгының сәбәпләрен эзләү «ничек яшәргә?» дигән сорауга җавап эзләү белән бер.

Төркиягә килеп урнашу белән бәйле булган вакыйгалар да шул сорауга җавап табарга ярдәм итә.

Мондый сорауга җавап бирегез:

Төркиягә күченеп килү белән бәйле вакыйгаларда М. Галәү нинди яңа темалар күтәрә?

16. «Мөһаҗирләр» романында Сафа, Сажидә, Хәтирә сыйфатларына нинди яңа сыйфатлар өстәлә? Сажидәнең, Сафаның, Хәтирәнең холыкларындагы уртак һәм аермалы якларны табыгыз. Авторның бу геройларга мөнәсәбәте нинди булырга мөмкин?

17. «Романда Хәтирә образы» дигән темага инша языгыз.

Аерым бер образга багышланган иншаны ничек язарга?

Иншаны язарга керешкәнче, вакытны кызганмыйча, озак итеп аның эчтәлеге турында уйлыйбыз. Уйның юнәлеше мондыйрак булырга мөмкин: Мин Хәтирәнең ниндидер бер бик мөһим ягына тукталырга тиеш. Аның бу мөһим сыйфаты образның асылын, хатынның холкын күрсәтәчәк. Хәтирәнең башка сыйфатлары мин әһәмиятле дип бәяләгән сыйфатны ачыклап, тулыландырып килергә тиеш. Фәкать аларны шул рәвешле бәйли алганда гына, мин үземнең иншамны бәйләнешсез җөмләләр белән тутырудан коткарам.

Әйтик, мин, уйлана торгач, ул сыйфат тыйнаклык дигән нәтиҗәгә килдем ди. Хәзер минем бурыч — шул нәтиҗәмне

исбат иту. Әсәрнең образлары үзләренең холыкларын төрле вакыйгаларда катнашып, төрле кешеләр белән мөнәсәбәткә кереп ачалар. Иншада мин сюжет сөйли алмыйм бит инде, димәк, вакыйгаларның иң мөһимнәрен сайлап алырга тиеш булам.

Тыйнаклык сыйфатына иң якын торган матур сыйфатларның башта кайсын, аннары кайсыларын әйтим һәм исбат итим? Уйланам да шул вакыйгаларны кәгазьгә язып куям.

Хәтирәдәге сыйфатлар аны төп герой дип исәпләргә нигез була аламы? Була ала, дигән нәтиҗәгә килсәм, аның җәмгыять белән каршылыгын табарга кирәк. Була алмый, дип уйласам, Хәтирәнең төп теманы ачудагы вазифасы турында сөйләргә тиеш булам.

Хәтирәгә автор нинди бәя биргән, һәм мин нинди бәя бирәм? Менә шул хакта уйланырга кирәк.

Нәтиҗә ясап, бу образны әсәрдәге башка герой — аңа каршы торган, яки охшаган герой белән чагыштырам. Аннары Хәтирәне татар әдәбиятындагы үзенең төп холкына охшаган башка образлар белән, әйтик, Ф. Әмирханның Хәяты һәм Г. Исхакыйның Сәгыйдәсе белән чагыштырам. Бу геройлар белән охшашлыгын һәм аермасын күрсәтәм. Шуннан соң авторга кабат әйләнеп кайтам һәм аның татар әдәбиятында хатын-кыз образын тасвирлауда традицияне дәвам иттерүе, бу темага яңалык кертүе турында әйтәм. Ә яңалык — Хәтирәнең төп сыйфатында, аның холкын тасвирлау стилендә һ. б. булырга мөмкин. Шулай итеп, мин йомгакта иншаның башында әйтелгән фикеремне кабатлыйм. Әйбәт иншаның башы белән ахыры бәйләнергә тиеш.

Шуларның барысын да кыскартып, кәгазьгә теркәп куйгач, ул план була.

План иншаның үзенә язылырга да, язылмаска да мөмкин. Ләкин ул булырга тиеш. План белән язганда гына инша төзек, фикерле һәм башкаларныкына охшамаган була.

Уйланылган план әзер булгач, эш җиңеләя. Уйны кәгазьгә төшерәсе генә кала.

Иншаның кереше булырга тиешме?

Иҗади эш турында сүз барганда «тиеш» дигән сүз куллану дөрес түгел. Иншада укучының фикере чагыла. Инша хатасыз итеп, матур төзек җөмләләр белән язылырга тиеш. Калганы укучының үз ихтыярында.

Инша язганда бервакытта да минем бу фикерем дөрес булырмы дип шикләнергә ярамый. Инша язу — язарга өйрәнү ул. Иң мөһиме — фикерегезне исбат итү.

Ә шулай да кереш язаргамы, язмаскамы? Теләсә ничек итегез. Ләкин иншагызны кереш белән башлыйсыгыз килә икән, иншамны ни белән башларга дип баш ватмагыз. Хәтирә турында гомуми төшенчә бирегез. Аның романда тоткан урынын күрсәтегез, туганнарының кемлеген әйтегез. Холкының сәбәбен ачыклагыз, ягъни тәрбиясе турында әйтегез. Хәтирәнең төп сыйфатлары турында сөйләгәндә, керешне искә алырга мөмкин һәм, әйтик, аның холкы әтисенекенә охшаган дип нәтиҗә ясый аласыз.

Инша планын күз алдына китерерлек дәрәҗәгә җиткәч, мондый эш башкарыгыз:

«Романда Хәтирә образы» исемле иншага план языгыз. План бик кыска җөмләләрдән генә торса әйбәт була.

Планның һәр маддәсен, параграфын киңәйтеп, ачыклабрак языгыз.

18. Өйдә «Романда Сәҗидә образы» исемле иншаның планын ныклап уйлап килегез. Дәрес вакыты инша язарга гына сарыф ителерлек булсын.

«Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» романнарына анализ нәтиҗәләре

Роман жанрына хас төзелеш җәмгыять — шәхес мөнәсәбәтеннән гыйбарәт булганга, анализны шул ике өлешне аерым-аерым өйрәнүдән башладык.

Эчтәлекләре ачыкланган бу ике өлешнең үзара бәйләнешендә автор фикере ятканлыгын сез инде беләсез.

Җәмгыять

Җәмгыять дип мәнфәгатьләре (интереслары) уртак булган кешеләр җыелмасына әйтәләр.

Җәмгыятьнең гаилә кебек кечесе дә, милләт, ил кебек зурысы да үзен тотрыклы хәлендә саклап калырга тырыша. Әдип милләтнең таркала баруына чын күңелдән борчыла. Татар халкының чит илләргә чәчелүенең сәбәбен патша хакимлегенә буйсынып, кол хәлендә яшәвендә күрә. Зур налоглар һәм ачыктан-ачык талаулар, мәсхәрәләүләр, гаепсезгә җәзалаулар — тышкы җимергеч көч. Тышкы бу борчуларны хокуксызлык дип гомумиләштерә алабыз. Бу бәяне Мәхмүт Галәү авылның исемендә үк бирә. Авылның исеме — Мәүла Колы, ягъни хуҗа, Алла колы.

Шуның белән бергә, М. Галәү романнарында милләтнең үз эчендәге таркату, җимерү көчләрен тасвирлауга да күп урын бирә.

Намус, горурлык, игелек, гаделлек, шәфкатьлелек кебек кешене кеше итә торган сыйфатларга кул болгап, теләсә нинди юл белән баеп дәрәҗә алучылар да җәмгыятьне таркаталар. Бу эчке җимергеч көч сыйфатларын әхлаксызлык дия алабыз.

Җәмгыятьнең аеруча куркыныч бер чирен әдип халыкның вакыты-вакыты белән, җыен тузга язмаган коткыга бирелеп, акылсызлык эшләп ташлауларында күрә. Халыкның сабырсызланып акылсызлык эшләп ташлавын әдип «өркү» дип атый. Өркү беренче чиратта өреккән кешеләрнең үзләрен бәхетсез итә. Өркү аркасында авыл кешеләре арасында дошманлык арта, халык читкә чыгып китә.

Җәмгыятьнең шундый тотрыксыз халәтенә **төркем (толпа) психологиясе** диләр.

Халыкның, өркеп, җимергеч көчкә әйләнүе бөтенләй кирәкмәгән тарихи борылышларга китерә. Хакимиятләрне, системаларны алмаштыра.

Җәмгыятьнең әнә шундый бик куркыныч тотрыксызлыгын, беренчеләрдән булып, «Шәфигулла агай» хикәясендә Фатих Әмирхан сурәтли. Коткы аркасында купкан көнчелек хисенең җимергеч көчкә әверелүенә борчылып, Мәҗит Гафури «Кара йөзләр» повестен иҗат итә.

Мәхмүт Галәү һичничек тә аклана алмый торган халык җинаятенең социаль һәм рухи тамырларын эзли. Аларны гаилә эченнән дә табарга тырыша.

Гаиләнең үзен эченнән дә, тышыннан да тарката торган көчләр бар. Тәкәбберлек, ваемсызлык, булдыксызлык, ямьсез теллелек — гаиләләрне эчтән борчып тора торган күренешләр.

Гаилә тотрыклыгын ничек сакларга? Авылны ничек итеп бердәм ярдәмчел халык итәргә? Милләтне ничек саклап калырга? Андый көч бармы?

М. Галәү романнарының төп проблемасы шундый сораулардан гыйбарәт.

Шәхес

«Мөһаҗирләр» романында милләтне берләштерергә омтылучы ике даими көч: милли хис һәм дин бар. Татарлар чит илдә дә берсен берсе эзләп табалар һәм мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга торалар. Төркия чиновниклары татарларга күпме генә кыенлык тудырмасыннар, алар нибары татар һәм рус чиновникларына хас юньсезлекләрне генә эшлиләр. Ришвәтсез бер генә мәсьәлә дә хәл ителми.

Милләт таркалуның сәбәпләре бик күп һәм җитди. Аны милли хис белән дин генә дә коткара алмавы ачыклана. Авылдашлар үз авылларында дини һәм милли хисләре, үз мулламазиннәре белән сыешып яши алмаган кебек, чит илдә дә тынычлык таба алмыйлар.

Милләтне нинди көч саклап кала ала?

Бүгенге көндә дә актуаль булган бу сорауга Мәхмүт Галәү бөтенләй көтелмәгән җавап бирә: «Милләтне — тотрыклы нык гаилә, ә гаиләне хатын-кыз консерватизмы гына саклап кала ала»,— ди.

Мәүла Колы авылындагы гаиләләрне яшәтүче шәхеснең хатын-кыз булуын алдагы дәресләрдә күреп үттегез. Гаиләгә нинди дә булса куркыныч туу белән, аның язмышын хатын-кыз үз кулына ала.

Таҗи белән Сәлим карт — тол кешеләр. Икесенең дә тормышлары аяныч хәлдә. Йосыф карт гаилә алып бару эшен үз кулына алган һәм һәммәсен дә бәхетсез иткән. Ләкин романдагы парлы гаиләләрдә дә ирләр «Мин гаиләмне бәхетле иттем» дип мактана алмыйлар. Әкрәм карый тормышын искә төшерегез. Үзе акыллы, намуслы кеше. Ләкин хатыны Җиһан абыстай тырышмаса, ачтан үләр иде.

Авыл халкы бунтына бер генә хатын-кыз да катнашмый. Аның каравы, Төркия җиренә аяк баскач, кешеләрнең иң авыр чакларында Сажидә ярдәмгә килә. Сажидә үзенең сабырлыгы белән башкаларны да тынычландыра, практик акылы белән эшләрен оештырырга ярдәм итә.

Тумыштан ук хатын-кызга бала тәрбияләп үстерү — милләтнең буыннарын дәвам иттерү бурычы йөкләнә. Шундый зур, изге бурычны ул гаилә эчендә, тынычлыкта гына башкарып чыга ала. Шуңа күрә гаилә тотрыклылыгын саклау хатын-кызның яшәү мәгънәсенә әйләнә. Гаиләне ата-бабалар тәҗрибәсен кабатлап кына саклап була: ә тәҗрибә хатын-кызга өйдә хуҗа булуга аз гына да дәгъва кылмыйча, бөтен хуҗалык һәм бала тәрбияләү, картларны карау, туганнар, күрше-күлән белән элемтәгә керү эшләрен үз кулына алырга куша. Гаиләдә хатын шулай итә дә.

Гаилә тотрыклылыгын авыл халкының өркүе, милләтнең хокуксызлыгы һәм таркалуы кебек ямьсез күренешләр дә борчып торалар. Хатын-кыз теләсә-теләмәсә дә милләт язмышын үз кулына алырга мәҗбүр була. Ләкин моның өчен милләтнең Сажидә кебек батыр хатын-кызлары күбрәк булырга тиеш.

Мәхмүт Галәү романнарындагы идея шуннан гыйбарәт.

Миңлебайлар гаиләсе

Миңлебай улларына артык зур байлык калдыра алмаган, чөнки гадел, юмарт кеше булган. Ләкин бу яхшы кеше улларына үзенең хөрмәтле исемен мирас иткән. Авылдашлары хәтта Вафага да, Таҗига да этиләренә булган хөрмәт җылысы белән эндәшәләр.

Шундый абруйлы гаилә, романның барлык вакыйгаларында катнашып, үзара бәйләнмәгән вакыйгаларны бәйләп сюжет төзи. Илдәге, авылдагы һәр вакыйга шушы гаилә язмышы булып, андагы кешеләрнең шатлыгына, хәсрәтенә, үкенеченә әйләнеп китә. Шул рәвешле, Мәхмүт Галәү Миңлебайлар гаиләсен татар җәмгыятенең гадиләштерелгән өлгесе, көзгесе итә. Бу гаиләдәге һәр кеше җәмгыятьне таркатучы һәм берләштерүчеләрнең бер тибын гәүдәләндерә.

Вафа урлашып, хыянәт итеп, дәрәҗәгә ирешүче байлар ягында, Таҗи — халыкны Вафа кебек хакимият кешеләренә каршы котыртучы, Сафа,— этисе кебек, кул көче белән көн күрүче намуслы бер крестьян.

Бу гаиләдәге өч килен дә — җәмгыятьтәге өч төрле холыклы хатын-кыз вәкилләре. Патый — киребеткән, усал телле, үзен генә хуҗа итеп исәпләүче хатын. Бу ягы белән ул Шәмси мулла хатыны Әсмага охшаган. Хәтирә — Әкрәм карый хатыны Җиһан кебек юаш, башлап сүз катмас, ләкин кулыннан бар нәрсә килә торган хатын. Саҗидә романдагы берәүгә дә охшамаган. Үзенең кыюлыгы, ирек сөючәнлеге, акылы һәм чибәрлеге белән ул автор күрәсе килгән милләт анасы.

Миңлебайлар гаиләсендәге һәр туган үзгә холыклы социаль тип. Шуңа күрә мондагы туганнар бер гаилә булып килешеп яши алмыйлар, өч төрле бер-берсенә бөтенләй охшамаган гаиләләргә аерылып чыгалар. Туганнар арасындагы каршылык башта бер гаилә эчендәге холыклар каршылыгы булып кына күренә, ләкин соңрак гаилә эчендәге дошманлык гаиләләр арасындагы каршылыкка күчә һәм авылдагы өч социаль төркем каршылыгы булуы ачыклана.

Туганнарның дошманлык хисе, туганлык якынлыгы хисе белән аралашып, әсәр персонажларының эчке конфликтын тудыра.

Саҗидә

Романдагы персонажлар үзләренең ниндидер бер социаль төркем тибы булуын раслар өчен кемгә дә булса охшый. Мәсәлән: Патый белән Әсма, Шәмси белән Сабирҗан, Сәлим карт

белән Тажи, Хәтирә белән Җиһан, Әрлән белән Вафа бертөсле холыклы кешеләр. Сажидә романдагы персонажларның берсенә дә охшамаган. Сажидә — авторның идеалы. Аның бер генә килмәгән җире дә юк.

Сажидә кешеләрдәге барлык күркәм сыйфатларга ия: ул чибәр, акыллы, зирәк, тыйнак, кыю, эшчән хатын. Ләкин Сажидә бигрәк тә гаилә тотучы хатын буларак матур. Сафа белән кавышуда да Сажидәнең тәвәккәллеге ярдәм итә. Сафаның әбисен үзләренә тәрбияләргә дип алып кайта. Бик кыен чакларда да, күңелен төшермичә, гаиләсенең ныклыгы өчен көрәшүен дәвам итә. Сафасының беркадәр юашлыгын, әкренрәк селкенүен күреп алса да, бу хакта берәүгә дә, Сафаның үзенә дә белдерми. Гаилә өстенә төшкән иң кыен мәсьәләләрне хатын чишә. Ләкин бервакытта да: мин уйлыйм, мин карар кылдым, шулай итәргә кирәк, болай итәргә кирәк дип чәчрәп чыкмый. Сафасына киңәш рәвешендә генә уен әйтә дә: «Без Сафа белән шундый уйга килдек»,— дип, ире артына поса.

Сажидә, гаиләсен балалы итү өчен, ирен башка хатынга өйләндерә. Бу — аның иң зур батырлыгы. Шул изге максатын тормышка ашыру өчен, ул үзенең көнчелек хисен дә, кимсенү хисен дә җиңә. Бу яктан Сажидә Фатих Әмирханның Хәятына охшый. Ләкин Хәят үзендә мәхәббәт хисен җиңәрлек көч тапса да, мәхәббәте өчен көрәшерлек кыюлык күрсәтә алмый. Сажидә Хәят кебек үк чибәр, хисле хатын, ләкин кыюлыгы, үз бәхете өчен көрәшә алуы белән аңардан өстен.

Гаиләдә бала булдыру өчен, үз бәхетеннән баш тарта алган хатын образын Гаяз Исхакый да иҗат итә. «Остазбикә» хикәясендәге Сәгыйдә иренең туена йөрәген телгәләгән көнчелек хисләрен, кимсенү хәсрәтен яшереп, горур җиңүче булып килә. Гаяз Исхакый бала тудыру бәрабәренә үз бәхетен корбан иткән хатынны милләт анасы, хатын-кыз идеалы итеп сурәтли. Аны күкләргә күтәреп зурлый. Кыяфәтенә фәрештәләр төсмере бирә.

«Маңлаена әллә нинди бер зурлык чыккан.

Балкышы — падишаһлар балкышы...

Йөреше — баһадирлар йөреше.

Ул алга атлаган саен шундагы кешеләрне, өйне, бөтен тирәюньне вакландыра бара.

Ул якынайган саен зурая, үсә бара»,— дип яза.

Сажидә Сәгыйдәдән үзенең гадилеге, гадәтилеге белән аерылып тора. Язмышы белән бәйле бик кыен мәсьәләләрне дә

ул гади генә итеп чишә. Көндәше Хәтирәне дә үз баласы итеп, ихлас бер ярату белән ярата.

Сажидәнең мәһабәтлелеген, гүзәллеген Мәхмүт Галәү аның гадилегендә, гадәтилегендә күрә.

Контроль эш өчен сораулар һәм биремнәр

1. Роман ни өчен тарихи роман дип атала? Тарихи роман дип нинди әсәрләргә әйтәләр?

2. Романда күтәрелгән төп проблема нинди?

3. «Мөһаҗирләр» әсәренә М. Галәү «Ил өреккәндә» дип исем бирә. Ни өчен «Наданлык», «Ялгышу», «Фаҗига» түгел? Нигә «Өркү»? Бу сүздән нинди мәгънә чыгарырга була?

4. Романда «капка» образының күп тапкыр кабатлануын аңлатыгыз.

5. Ни өчен автор авылга Мәүла Колы исеме кушкан?

6. Сафаның, Төркиядән авылга кайтып, Хәтирә белән очрашуын исегезгә төшерегез. Бу күренешне М. Галәү болай тасвирлый:

«Хәтирә исә бөтен дөньясын онытып, иренең муенына сарылды. Сафаның кулындагы таягы шап итеп җиргә төште».

М. Галәүнең бу урында таяк турында язуы нигә кирәк булырга мөмкин?

7. Романда тасвирланган җәмгыятьне таркатучы сәбәпләрне әйтегез.

8. Гаиләне саклап калучы көчләр турында сөйләгез.

9. Җәмгыять дип нәрсәгә әйтәбез. Романдагы җәмгыять бүленешен күрсәтегез.

10. Сажидәне ни өчен милләт анасы дип әйтергә була?

11. Романга анализ ясау ысулы (методы) турында языгыз.

12. Роман жанрының таләбе буенча герой соңыннан үзгәрергә тиеш. Сафа үзгәрәме? Үзгәрсә, ничек үзгәрә?

13. Таҗи образына бәя бирегез. Аның драмасы нәрсәдән гыйбарәт? Сөйләгез.

Бөтен бер әсәргә багышланган иншаны ничек язарга?

Инша язучының фикереннән һәм шул фикерне исбат итүдән гыйбарәт. Әсәр турында әйтелгән фикер исә — анализ нәтиҗәсе, ә исбат итү анализ үзе була. Иншаны шигырь, хикәя, повесть, пьеса турында язганда да шулай итәбез. Әсәрләргә кыскача гына анализ ясыйбыз һәм анализ нәтиҗәсен әйтәбез. Ләкин «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» кебек күләмле һәм катлаулы роман анализы 4—5 битлек иншага сыя алмый. Ни эшләргә?

Әсәрдәге бөтен вакыйгаларга һәм темаларга азлап-азлап, өстән-өстән генә язып тукталуга караганда, бер генә нәрсә турында тулырак итеп язу хәерлерәк. Роман эчтәлеген кыскача гына ничек ачып була?

Сез инде беләсез, вакыйгаларның җеп очлары фокуска килеп очрашалар. Димәк, сез иншагызда әсәр фокусы турында яза аласыз. Ә фокус аша вакыйгаларның эчтәлекләре турында сөйлисез.

Мәсәлән, капка символы, әсәрдә күп мәртәбә кабатлануы белән, үзеннән-үзе үзәккә чыга. Капка әсәрдә авыл халкын һәм аерым гаиләләрне күрсәтеп, аларны алмаштырып килә.

Исегездә калдырыгыз.

Башка бер вакыйганы, күренешне, әйберне алыштырып, аның урынына билге булып килгән образга символ диләр.

Гадәти образ үзен үзе генә белгертеп, үзенә үзе тигез булып кына килә.

Метафора башка бер күренеш белән янәшә килгәндә генә эчтәлеген ача.

Символның эчтәлеге бервакытта да символ булып килгән предмет эчтәлегенә тигез булмый, ә предметының эчтәлегеннән күп мәртәбә артык була. Символга башка бернәрсә белән янәшә килү мәҗбүри түгел. Ул үзе, нинди дә булса предметның билгесе буларак, аерым бер предмет булып килә.

Романдагы басу капкасы, мәсәлән, авыл халкын, авылның үзен алыштырып килә. Ләкин шуның белән бергә, капкаларның һәрберсенең үз сыйфатлары һәм вазифалары да бар бит әле. Билге булып килүче предметның (образның) үз сыйфатларының байлыгы символны чиксез күп мәгънәле итә дә.

Романдагы капка образын фокус дигән идек. Хәзер, символның ни икәнлеген белгәч, капканы символ булып килүче фокус дип ачыклап әйтик.

Иншаның үзәгенә капканы алдык исә, план төзегәндә, аның символ буларак мәгънәләре турында уйланырга кирәктер. Әйтик, капкалар төрле булалар: искеләре, яңалары, буялганнары, буялмаганнары, мунчала белән бәйләнгәннәре, тимер элгечлеләре, биекләре, тәбәнәкләре, шыгырдап ачыла торганнары, тавышсызлары, коймалылары, коймасызлары, түбәлеләре һәм түбәсезләре, бикле булганнары, биксезләре. Символ булуы ачыкланган капканың юклыгы да хәзер аерым мәгънәгә ия.

Иншаның башыннан ахырына кадәр капка образын күздә тотып, әсәрнең төп темасын — җәмгыять белән аерым гаилә арасындагы каршылык сәбәбен әйтеп исбат итә алабыз.

Укучыларның барысы да капка турында язып эчтәлек ачса, иншалар бертөрле булмасмы?

Иншаларны бер-берегездән күчерсәгез генә бертөсле була ала. Символның билгеләмәсендә мәгънәнең чиксез булуы әйтелә.

Аннары әйбәт әсәрләрдә символлар да, фокуслар да берәү генә булмый. Мәсәлән, объектлар фокусы, эчтәлек яссылыгындагы фокус, интонация фокуслары бар.

«Болганчык еллар» романында гаилә, авыл, милләт — җәмгыять бүленешләре буларак тема да, проблема да, идея дә түгел. «Ничек яшәргә? Ничек бәхетле булырга» дигән проблема кую, бәхет темасын ачу объекты гына. Җәмгыятьне бүлгәләп һәм шул ук вакытта кушып, аңа билге рәвешендә килгән капка — объект фокусы була.

Беренче мәртәбә укыганда ук кабатлауларга игътибар иткән укучы романда «т а м г а» образының да күп тапкыр кабатлануын күрә. Йортлар капкасында урак, чалгы, балта кебек тамгалар эленеп тора. Кешеләр төрле прошениеләргә тамгаларын куялар. Әдип Мәүла Колы авылы кешеләре аркасындагы камчы эзләрен дә тамгалар билгесе белән алмаштыра.

Шул рәвешле, балта, көрәк, урак кебек тамгалар, кешеләрнең асылын алыштырып, аларның коллыгын, җинаятен, кимсенүен, бәхетсезлеген дә күрсәтеп килә.

Тамгалар — авторның үзе тарафыннан сайланган символ. Без моны образның кабатлануы һәм әсәр исеменә чыгуы белән исбат итәбез. Искә төшерик, романның баштагы исеме «Канлы тамгалар» булган.

Автор күз алдында тотканмы, юкмы, әмма иншаның ахырына без тамгаларның милләт хәтерендә тарихлар буена сакланып калган кимсенү, изелү, хыянәт итү белән бәйле вакыйгалар булуын нәтиҗә итеп язып куя алабыз.

Күрәсез, тамгаларның эчтәлеге капкалар символыннан да киңрәк. Бу символ объектларга бәя бирү белән генә чикләнми, алар арасындагы каршылыклар эчтәлеген дә ача. Шуңа күрә «тамгалар» символын эчтәлек яссылыгындагы фокус дибез.

Берәү иншасына кешеләрнең коллыгын күрсәтүче авыл исемен сайлый ала.

Сәнгать әсәрендәге геройны тип дидек, ягъни күпләргә хас холыклы кешеләргә охшаганлыгын әйттек. Димәк, әсәр турында гомуми фикерне аерым бер шәхес язмышы аша да ачып була дигән сүз. Шуңа күрә роман эчтәлеген берәү Сафа язмышы аша ачса, бу табыш та бик уңай күренеш булыр иде.

Төп геройның берсе буларак, Сафа, романдагы барлык вакыйгаларга да катнашып, аларны бәйләп тора, дидек. Үзәккә Сафаны алып, ул катнашкан вакыйгалар турында язу шулай ук фикерне исбат итүнең уңышлы алымы була.

Әсәрдән инша үзәге итеп алынган фокус, хәзер иншаның үз фокусына әйләнә. План төзегәндә үк уегыз фәкать шул үзегез сайлап алган фокус тирәсендә генә йөри. Фокусның бөтен нурларны бер ноктага җыю табигате үк шуны таләп итә. Иншаны фокус белән язу эшне күпкә җиңеләйтә.

Таҗи Гыйззәт
(1895—1955)

Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәтуллин 1895 елның 3 сентябрендә Татарстан Республикасының Әгерҗе районы Барҗы Омга авылында туа. Укыйсы бик килсә дә, Таҗи төпле белем алу бәхетенә ирешә алмый. Башта ул, үзе укый-яза белмәгән абыстайдан дәрес алып, ике елын бушка диярлек үткәрә. Үз авылларында ачылган яңача укытыла торган мәктәпкә дә ике генә ел йөреп кала. Тормыш хәлләре авыраеп киту сәбәпле, читкә китеп, Ижевск заводында эшләргә мәҗбүр була. Заводтан Кызыл Армиягә алына. Монда ул гаскәриләр оештырган үзешчән театрларда актив катнаша.

Яшь егетнең иҗат һәвәслеген драматург Кәрим Тинчурин күреп ала һәм Шамил Усманов ярдәме белән аны театр студиясенә укырга җибәрә.

Студияне тәмамлагач, Таҗи Гыйззәт Оренбургтагы татар театрында артист булып уйный. 1922 елда Казанга кайта һәм Кәрим Тинчурин төзегән Татар дәүләт театрына эшкә керә.

Монда ул пьесалар иҗат итә башлый.

Таҗи Гыйззәт драматург булу өчен белеме җитмәвен яхшы аңлый. Шуңа күрә үзлегеннән бик күп укырга тиеш була. Ялсыз, эш белән укуны бәйләп алып бару аның сәламәтлеген нык какшата. Ләкин драматург бирешми. Укый, эшли, яза.

1923 елда тәмамлаган «Талир тәңкә» исемле беренче пьесасыннан соң бер-бер артлы «Каһәрле мөһер», «Наемщик», «Бөек борылыш», «Керәш», «Акбаш вакыйгасы», «Бишбүләк», «Ударник Мөхтәр», «Җиңү бәйрәме», «Фамилиясез тимерче», «Мактаулы заман», «Чаткылар», «Кыю кызлар» пьесаларын иҗат итә.

Күп еллар дәвамында драматург үзенең иң мәшһүр дип исәпләнгән, күп еллар буена сәхнәдән төшми уйналган «Ташкыннар» исемле трилогиясен яза.

Бу пьесаларның конфликты байлар белән ярлылар каршылыгыннан гыйбарәт. Пьесаларның беришендә революциягә кадәрге тормышта ярлы халыкның байларга булган нәфрәте бунтка китерсә, калганнарында ярлы халык бик оста яшеренгән халык дошманын — кулакны фаш итә. Нәфрәт белән уяулык бу әсәрләрнең төп эчтәлеге дия алабыз.

Әсәрләренең бер-берсенә нык охшаганлыгын Таҗи Гыйззәт үзе дә күрә. Соңрак аларны үзе үк рәхимсез рәвештә тәнкыйтьли. Кайсын өлгереп җитмәгән ди, кайсын ашыгып язылды ди. Яңа әсәрен башкача итеп язмакчы була. Ләкин чираттагы әсәрендә дә кешеләрнең нәфрәте белән уяулыгы турында сөйләүдән уза алмый. Тагын яза, тагын шундый ук хәлгә дучар була.

Ни өчен күңелгә ошарлык әсәр тудырып булмый? Бу сорау әдипне өзлексез борчып тора.

Уңышсызлыгының сәбәбен әдип идеология таләпләрен үтәп җиткермәвендә күрә. Һәм ялгыша. Чын сәбәп, киресенчә, ул таләпләрне үтәүдә була.

Бу елларда иҗат ителгән бик күп әсәрләрнең конфликтлары, персонажлары, сюжетлары, идеяләре дә бер-берсенә нык охшыйлар һәм охшарга тиеш тә булалар. Ләкин Таҗи Гыйззәт кебек талант иясенең дә тапталган юлдан китүе белән татар язучылары үзләре дә килешә алмыйлар.

Драматург иҗаты турында күп санлы рецензияләр, мәкаләләр язалар. Аңа ярдәм итәргә тырышалар.

«Темасы гына түгел, хәтта аерым сюжет моментларын, аерым образларны кабатлау килеп чыга»,— дип яза рецензияләренең берсендә Муса Җәлил. Һәм «сыйнфый көрәш» сүзләрен әйтми генә, бу темадан башкасына күчәргә куша.

Персонажларының эчке конфликтларын таба алмый борчылган бу талант иясенең иҗаты — тоталитар режим тудырган меңнәрчә фаҗиганең берсе.

«Чаткылар» — Таҗи Гыйззәтнең иң уңышлы әсәрләреннән санала. Бу пьесада аның зур таланты да, җитешсезлеге дә ачык күренә.

ЧАТКЫЛАР

Драма биш пәрдәдә

КАТНАШУЧЫЛАР:

Гаяз — тимерче егет.
Хәсби — аның анасы.
Рамай — ярлы, бунтарь егет.
Дәүли — староста.
Гарифә — аның хатыны.
Маһисәрвәр — аларның кызы.
Сәетгәрәй — уку яшендәге бала.
Сабир — авылның зур сәүдәгәре.
Фәрхәнә — аның анасы.
Тимай — каравылчы карт, инвалид.
Хәмдия — аның кызы.
Орлов — сөргенгә җибәрелгән Мәскәү эшчесе.
Дерюгин — урядник.
Макар — стражник.
Гобәй — авыл бае.
Тимергали — ярлы егет.
Шәриф — гармунчы егет.
Гыйльмениса — ярлы карчык.
Иван Васильевич — следователь.
Фәйзулла — батрак.
Сәләхи — Сәетгәрәйнең иптәш малае.
Хөснижамал } яшь кызлар.
Миңҗамал }
Мочтак — хаҗи малае.

Кызлар, егетләр, хатыннар, ирләр.
Вакыйга 1908—1912 елларда.

Беренче пәрдә

Сабир байның өе. Яхшы мебельләр, матур җиһазлар белән бизәлгән. Бер якта кибеткә чыга торган ишек, ишек башында кечкенә кыңгырау, икенче якта кереп-чыгып йөри торган ишек. Пәрдә ачылганда сәхнәдә Сабир белән Фәрхәнә.

Сабир. Шулай итеп, әни, мин өйләнергә булдым.

Фәрхәнә. Ярый, улым, ярый. Шушы кадәр зур дәүләтне алып бару миңа да бик авыр иде. Бу ниятеңне хәзрәтләр дә ишеткән икән, кичә шул турыда сөйләшеп утырдык, кызлар сайладык.

Сабир. Кызык. Әйтеп кара әле, кемне сайладыгыз икән?

Фәрхәнә. Остазбикә, чулак мәэзин кызын алыйк, ди. Кызы бик чибәр, диләр. Курнус булса да, борыны бик матур, ди абыстаң,

зур битенең уртасында песи борыны кебек килешеп кенә тора, ди.

Сабир. Юк, әнкәй, кирәкми.

Фәрханә. Хәкимҗан кызы ничек булыр икән.

Сабир. Яратмыйм, бите сипкелле.

Фәрханә. Мортаза Хәдичәсе.

Сабир. Ярар иде дә, ләкин бераз гына шадрасы бар.

Фәрханә. Булат Нәгыймәсе.

Сабир. Кирәкми, кипкән балык төсле, үзе озын, үзе чандыр.

Фәрханә. Шәйхи Фәхернисасы.

Сабир. Анысы кирәгеннән артык юан.

Фәрханә. Ай Алла, берсен дә яратмыйсың, өч хатын аерган кешегә әллә кемне бирмәсләр инде.

Сабир. Бирерләр, әнкәй, талчыбыктай зифа буйлы, гөлҗимеш чәчәгедәй алсу йөзле кызны алырмын.

Фәрханә. Ул кадәрле искитәрлек кем соң ул?

Сабир. Ул, әнкәй, Маһи. Әтүтән Дәүли кызы, Маһисәрвәр.

Фәрханә. Ай-һай, улым, үткән елны да сүз салдырып карадык бит, тел төпләре бирмәскә булды.

Сабир. Быел тагы сорап карарбыз. Яхшылыкта бирмәсәләр, башка юлларын да табарбыз.

Фәрханә. Белмим шул, ул кызның башын тимерче Гаяз чуалткан, диләр.

Сабир. Зарар юк, ата-аналарын күндерсәк, беркая да китә алмас. Маһисәрвәргә өйләнеп, хуторга күчеп алсак, дөньяда бер теләгем дә калмас иде.

Фәрханә (*тәрәзәдән күреп*). Теге Әхмәтша малае килә. Акча сораргадыр. Ай-ваена карамыйча, бая мин әйткәннәрне басып кал.

Фәрханә кибеткә кереп китә. Рамай керә.

Рамай. Исәнме, Сабир абзый! Фәрханә абыстай кирәк иде.

Сабир. Ул өйдә юк, ни йомыш?

Рамай. Бер атнадан бирле, кибәннәрегезне суккан артель акчасын бирми йөртә.

Сабир. Суккан арышларыгызны амбарга чыгып караган идем, чүбе-балчыгы белән тутыргансыз.

Рамай. Машинагызның иләге начар булуга без гаепләмени? Фәрханә абыстайга әллә ничә мәртәбә әйттек, берәрсеннән машина алып чыгыйк, дидек.

Сабир. Шуның өстенә өч капчыкны ярып, ике көрәкне сындыргансыз, бер тырманы ваткансыз.

Р а м а й. Их, Сабир абзый, сезне күзгә карап җан сатучылар дип сөйлиләр иде, дөрес икән. Суккан саламнарыгызны ындыр буена өяргә сөйләшкән булсак та, таш утар түбәсенә күтәртеп чөебезне чыгардыгыз. Капчык ташырга ат бирергә вәгъдә итте, аны бирмәде. Эш беткәч, сыйларга булды, аны эшләмәде. Карт башы белән ялганлап йөргәне өчен битенә төкерер идем, бәхете, өйдә юк икән.

С а б и р. Ярый, ярый, теленә салынма, акчаңны ал да үкчәңне күтәр. Мә!

Р а м а й (*акчаны алып*). Тагы. Ике сум җитми. Ун сум тиешле иде, монда сигез сум гына.

С а б и р. Өч капчыгың егерме бишәр тиеннән — җитмеш биш тиен. Ике көрәк, бер тырма — илле биш тиен. Кибеттән җитмеш тиенлек бурыч бирелгән. Барысы була төгәл ике сум.

Р а м а й. Ул нинди бурыч тагы?

С а б и р. Ун кадак клиндер ашагансыз.

Р а м а й. Имансыз икән... Кибән башлаган көнне, гадәт буенча, өегезгә чакырып, чәй белән сыйлап маташкан иде, инде шуны да безнең өскә саласызмы? Юкка маташасың, Сабир абзый. Барыбер бирерсең. Бише белән кайтарырбыз. Бугазыңнан каерып алырбыз! (*Чыгып китә.*)

Фәрхәнә керә.

Ф ә р х ә н ә. Бик усал нәрсә диләр иде, дөрес икән. Урядниккә хәбәр итәргә кирәк, син югында йортка зыян салмасын. (*Кибеткә китә.*)

С а б и р. Минем белән эш иткәне юк әле, күрсәтермен мин аңар.

Гыйльми керә.

Г ы й л ь м и. Исәнме, улым Сабирҗан. Нигә чакырткан идең.

С а б и р. Гыйльменисаттәй, синең тормышыңны начар дип ишеттем.

Г ы й л ь м и. Сөйләмә инде, Сабирҗан. Юньләп ипигә дә туйган юк.

С а б и р. Әнкәй белән киңәштек тә сиңа ярдәм итәргә булдык. Ерактан булса да, син бит безнең туганыбыз.

Г ы й л ь м и. Ерак дип, алай бик ерак түгел инде, синең бабаңның әбисе белән минем әбинең бабасы туганнан туган балалар гына бит.

С а б и р. Әйе, әйе, шулай шул. Әнкәй, бушаган булсаң, монда чык әле.

Фәрхәнә керә.

Сабир. Менә нәрсә, әнкәй, Гыйльменисаттәйгә ун кадак ярма, бер кадак шикәр, чирек чәй биреп җибәр әле... Гыйльменисаттәй, оныта язганмын икән, Гобәй байга иманаңны[1] сатарга йөрисең дип ишеткән идем, шул сүз дөресме? Күпмегә килештең?

Гыйльми. Әйе, улым, дөрес. Биш сум акча, өч пот арыш оны, бер күлмәк һәм вак-төяк нәрсәләр.

Сабир. Бирән, комсыз... Ул бит сине алдаган. Ул хакка имана саталармы? Бүген үк үзенә бар да, иманамны сатмаска булдым, диген.

Гыйльми. Ярый, улым Сабирҗан, яхшы киңәшеңә рәхмәт.

Фәрхәнә Гыйльмине кибеткә кертеп җибәрә дә Сабир янына килә.

Фәрхәнә. Син ни эшлисең, улым?..

Сабир. Шаулама, әнкәй, аның сере бар. Ансын соңыннан белерсең. Әйткәннәрне үлчәп бир. Бар, бар, әйберләреңне кыстырмасын. (*Фәрхәнә китә.*)

Зур төен күтәреп, Мочтак керә.

Әйдә, Мочтак дус, рәхим ит. Ни эшләр бетереп йөрисең.

Мочтак. Хәлләр шәптән түгел, малай, казалы булдым, атым үлде. «Пәнҗәр» ярминкәсенә барган идем бит. Эчкән баштан атны куганнан-куып яндырып үтергәнмен. Ат шәп иде. Менә шул ат алу теләге белән эткәйдән калган кием-салымнарны, өй җиһазларымны сиңа сатарга китергән идем. (*Төенен чишеп күрсәтә.*) Бөтенесе йөз илле сум акча дим.

Сабир. Уһу!.. Кыйбат икән. Минемчә, менә нәрсә, Мочтак дус: син боларны сатып, Хаҗи абзый төсен әрәм итмә. Хәзергә син аларны бездә калдыр. Ат алырга сиңа вакытлыча бер утыз сум акча биреп торырмын.

Мочтак. Ничек, ягъни закладка. Түли алмасам?

Сабир. Анда күз күрер. Без бит чит кешеләр түгел. Бер-беребезне җәберләмәбез.

Мочтак. Ярый, хәерле булсын. Кая, акчаңны бир.

Мочтак китә. Фәрхәнә керә.

Фәрхәнә. Алдыңмы, улым? Күпмегә?

Сабир. Утыз сум. Закладка салды.

Фәрхәнә. Закладка? Ул кадәр зур суманы бәйләп куюың бер дә яраган эш түгел.

---

[1] Имана — җир бүлгәндә җан башына тигән җир участогы.

Сабир. Әллә син аны түләп алыр дип уйлыйсыңмы. Ул бит аны бер атнага да җиткермәс, барысын да эчеп бетерер. Хатыны да пар килгән, бертуктамый кәнфит суыра.

Фәрхәнә. Атасыннан күпме байлык калды. Һәммәсен дә очлап киләләр.

Дерюгин, Макар керәләр.

Сабир. Әйдә, Николай Федорыч, әйдә, рәхим ит.

Дерюгин. Исәнмесез, Фәрхәнә Давыдовна.

Фәрхәнә. Шөкер әле, Николай Федорыч.

Дерюгин. Макар, атларны туар, кунарбыз.

Макар. Тыңлыйм, господин урядник. (*Китә.*)

Кибеттә кыңгырау шалтырый.

Сабир. Әнкәй, кибеткә килделәр.

Фәрхәнә китә.

Дерюгин. Но, Сабир Хасанович, барышлар булдымы?

Сабир. Аллага шөкер, Николай Федорыч. Ун олау тире белән барган идем, һәммәсен дә яхшы хакка җибәрдем. Тик менә син югында авылда булган хәлләр генә...

Дерюгин. То есть, нинди хәлләр.

Сабиров. Тимерче Орлов кешеләргә социал-демократларның җир программалары турында сөйләгән. Депутатларыбызны да яманлаган.

Дерюгин. Так, так, дальше?..

Сабир. Шәймәрдәнов дигән егет Столыпин җәнапларының җир төзү законына каршы өндәп, алпавытларның җир-суларын үзебезгә алырга кирәк, дип халыкка сөйләгән.

Дерюгин. Кайсы Шаймарданов ул?

Сабир. Орловның помощнигы булып алачыкта эшләүче Гаяз Шәймәрдәнов. Шуның өстенә тимерче Орлов, үз квартирасында яшьләрне җыеп, урысча укыта башлаган.

Дерюгин. Ах, сволочь!.. Хәзер үк бер кеше җибәреп Орлов белән Шаймардановны чакыртыгыз.

Сабир. Хәзер була ул, Николай Федорыч. Хәмдия, Хәмдия!..

Хәмдия керә.

Мәүләви абзыйга әйт, алачыкка барып тимерче Орлов белән Шәймәрдән малаен чакырып китерсен. Господин урәдник көтә диген.

Хәмдия. Ярый... (*Китә.*)

Сабир. Дөньялар болай булса, юл йөрергә дә куркыныч... Бер башкисәр килеп миңа да янап китте.

Дерюгин. Кем икәнен танымадыңмы?

Сабир. Рамай Ахметшин дигән егет.

Дерюгин. Тыныч бул, Сабир Хасанович, мин ул сукин сынны иртәгә үк правлениегә чакыртып җанын алырмын.

Сабир. Безгә Гобәй старостаны алыштырырга кирәк.

Дерюгин. Да, да, алыштырырга иде, ләкин кемне куябыз?..

Сабир. Дәүли солдат. Үзе простой мужик булса да, дәрәҗәне ярата торган кеше. Солдатта да булган, тотарга да шуны куярга кирәк.

Дерюгин. Үзен күреп сөйләшмичә бер сүз дә әйтә алмыйм.

Сабир. Дәүли солдатны чакыртыйммы?

Дерюгин. Ярый, чакыртыгыз.

Сабир китә. Орлов керә.

Господин Орлов, рәхим итегез, утырыгыз... Хәтерегездәме, моннан ике ел элек Москвада кораллы восстаниегә катнашуыгыз өчен безнең волостька сөргенгә җибәрелгән идегез. Сез шул чакта крестьяннар белән аралашмаска, политик темаларга бер сүз дә сөйләшмәскә дип подписка биргән идегез.

Орлов. Әйе, биргән идем.

Дерюгин. Шулай булуга карамастан халык арасында агитация таратып ятасыз икән.

Орлов. Нинди агитация?

Дерюгин. Большевикларның аграрный программалары турында сөйләгәнсез.

Орлов. Юк, господин урядник, бу турыда минем берни дә сөйләгәнем юк.

Дерюгин. Конечно, юктыр. Мин үзем дә аңа ышанмадым. Ләкин жалобаларны тикшермичә мөмкин түгел. Үзегез беләсез, каһәр төшкән служба. Мин рус, икенчедән христиан. Әллә нинди Мамай нәселе өчен үз русымны, үз христианымны бервакытта да батырмам.

Орлов. Мондый приемнар белән маташмагыз, мин аларны бик күп ишеткән, ни булса да башка берәр нәрсә уйлап табыгыз.

Дерюгин. Яхшылыкның кадерен белмәсәң, мин сиңа башка приемнар да табармын...

Орлов. Менә монысына ышанам!.. Күптән шулай кирәк иде, юкса сарык тиресе ябынган бүре төсле кылануың...

Дерюгин. Молчать!.. Утырыгыз, политический темаларга сөйләмәскә, яшьләр укытуны бу көннән туктатырга сүз бирәм дип языгыз.

Орлов язарга утыра.

Орлов. Яздым, башка сүзегез юкмы?..

Дерюгин. Барыгыз.

Орлов китә. Дерюгин арлы-бирле йөри. Гаяз керә.

Син нәрсә сөйләнеп йөрисең, чучка колак? Молчать!..

Гаяз. Тукта әле, господин...

Дерюгин. Тик тор, Мамай калдыгы!.. Императорның законнарына риза булмый, Тимерлан дәүләте төзергә уйлыйсыңмы?..

Гаяз. Нинди Тимерлан? Мин аны ишеткәнем дә юк.

Дерюгин. Җитәр дим, сволочь!.. (*Йодрыгын Гаязның борын астына тери.*)

Гаяз. Сузма кулыңны... (*Кулын читкә этеп җибәрә.*) Юкбарга кулың белән уйнасаң, тешләреңне учлап китәрсең.

Дерюгин. Ах, гадина... (*Камчы белән кизәнә.*)

Гаяз. Килеп кенә кара... (*Урындык күтәрә.*)

Сабир керә.

Сабир. Чу, Гаяз. (*Тота.*) Алай кызу канлы булырга ярамый.

Дерюгин. Кил, кулыңны куй, берсекөнгә допроска килерсең.

Гаяз килеп кул куя.

Кара аны, малайка!.. Гомерең буе төрмәдә черисең килмәсә, Орлов коткысына ияреп йөрисе булма. Бар кит!

Гаяз китә.

Допроска килсен әле, мин аның җиде бабасын таныйтырмын. Болар бар да социал-демократлар чумасы, Орлов агитациясе. Ул гад белән нишләргә инде? Моннан позорный рәвештә куарлык нинди дә булса берәр җинаятькә бәйләргә иде дим, аңлыйсыңмы?..

Сабир. Аңлыйм, Николай Федорыч, бик яхшы аңлыйм. Әйдә тотыгыз. (*Эчәләр.*) Анысы да монысы, безнең тирәдә акча ясаучылар күбәеп китте бит. Минемчә, ул акча ясаучылар шушы безнең авыл шайкасы түгел микән? Тимерче Орлов белән Шәймәрданов дим.

Дерюгин. Так, так, так... Бик возможно...

Дәүли керә.

Сабир. Әйдә, Дәүли абзый, түрдән уз.

Дәүли. Безгә монда да ярар.

Дерюгин. Син беләсеңме, без сине ни өчен чакырдык. Без сине староста итеп куймакчы булабыз.

Дәүли. Мин нинди староста булыйм, ди. Минем бит грамотам юк. Кул да куя белмим.

Дерюгин. Староста булырга грамота кирәкми. Каракларны, мошенникларны, патша законына тел тидерүчеләрне вакытында хәбәр итеп торсаң, безгә шул җитә.

Дәүли. Мин риза булыр идем дә, авыл халкы ни әйтә бит?

Дерюгин. Ул ягын син безгә калдыр. Иртәгә үк сельскийдан җыен җыйдырабыз да сайлатабыз.

Дәүли. Ярый алайса, риза...

Дерюгин. Бар, Тимиршин, хәзергә башка сүз юк.

Дәүли. Рәхмәт, хушыгыз!.. (*Китә.*)

Сабир. Әйдә, Николай Федорыч, яңа староста саулыгына күтәрик...

Стаканнарын чәкештереп эчәргә дигәндә, түр тәрәзәгә кусәк белән сугалар. Пыялалар чәчелеп, рамалары эчкә коела. Дерюгин белән Сабир сикереп торалар.

Икенче пәрдә

Дәүли староста өе. Дәүли, Тимай керәләр.

Тимай. Ник чакырдың, Дәүләтша?

Дәүли. Десәтникләргә йөреп чыгарсың, кичкә халыкны җыенга кусыннар.

Тимай. Җыенга? Нәрсә бар тагы?

Дәүли. Җир турында яңа закон чыккан. Авылга старшина белән сельскийлар килә.

Тимай. Шулаймыни? (*Китә.*)

Гарифә керә.

Гарифә. Кайттыңмыни, этисе?

Дәүли. Печать кая?! (*Әтәчләнеп кычкыра.*)

Гарифә. Тәрәзә кашагасында.

Дәүли. Ужым бозавы, шунда куйма дип ничә тапкыр әйтелгән сиңа. (*Сәкегә менә башлый. Кызлар калдырган ата каз куыгына басып шартлата.*) Бу ни бу?..

Гарифә. Кызлар, шаярып, ата каз куыгы калдырганнар.

Дәүли. Быелдан болай шул икмәк убырларыңны асрыйсы булма, муеннарыннан тотып бәрермен.

Гарифә китә. Рамай керә.

Рамай. Исәнме, Дәүли абзый! Паспорт алырга Ибәтулла писердән язу алган идем, тамгаңны куеп, печәтеңне басып бир әле.

Дәүли. Басуын басар идем дә, тик бит сиңа волостьта паспорт бирмәсләр. Синең, энем, чатакларың бар икән...

Рамай. Нинди чатакларым?

Дәүли. Ишбулды Сабирының тәрәзәсен сиңа сылтадылар бит. Сине авылдан чыгармаска куштылар.

Рамай. Бирмисеңмени?

Дәүли. Булдыра алмыйм. Үзең беләсең, нәчәльство сүзен тыңламыйча булмый бит. Мин бит казна кешесе.

Рамай. Әй, чукынып китсәң иде шул казнаң белән!.. (*Китә.*)

Гыйльми керә.

Гыйльми. Мине Сабирҗан җибәргән иде. Менә шушы кәгазьгә тамгасын куеп, печәтен басып җибәрсен, дигән иде. Иманамны аңар бирдем бит.

Дәүли. Иманаңны бирергә булсаң, язышмый да була бит, нигә соң кәгазь язышасыз?

Гыйльми. Әллә тагын. Сабирҗан язышыйк дигәч, каршы килмәдем. Законча булсын ди торгандыр.

Дәүли. Әйе, законча шул, законча... (*Печать басып бирә.*) Булды бу. Әүвәле-ахыры хәерле булсын.

Гыйльми китә.

Ай бу Сабирны... Вак балыкларны йотып йөргән чуртан кебек, төрле яктан каптыра.

Фәрханә керә.

Фәрханә. Исән генә торасызмы, Дәүләтша? Вакытсызрак килдем бугай, каз өмәсе икән.

Дәүли. Шулай иде дә, зарар юк. Шулай итеп, хутор булырга риза булдыгыз, ахры?

Фәрханә. Яхшы әрәмәлек су буеннан яңа җир кисеп бирәләр дигәч, каршы килмәдем. Аллага тапшырып, күчәргә булдык.

Гарифә керә.

Гарифә. Кунак бар икән.

Фәрхәнә. Исәнме, Гарифә? Мин сезгә мендәрле кунак булып килгән идем.

Дәүли. Яучы булып, кемгә?

Фәрхәнә. Билгеле инде, Сабирҗаныма.

Дәүли. Фәрхәнә абыстай, нәсел-ыру белән уйлашып, иртәгә җавабын бирербез.

Гарифә. Уйлашасы-нитәсе юк. Кешене ышандырма. Шулай, Фәрхәнә абыстай, бирә алмабыз. Бердәнбер кызымны өч хатын аерган кешегә бирер хәлем юк!..

Дәүли. Җитәр дим!.. Салма савытыңа биргәнне көтәсеңме әллә?

Фәрхәнә. Ярый, Дәүләтша, сау булып тор хәзергә.

Дәүли. Хуш иттек, Фәрхәнә абыстай, хуш. Зинһар, гаепләп китә күрмә. Аның бүген башы өянәкле көне. Җавабын иртәгә үзем бирермен. Хуш, хуш, Фәрхәнә абыстай, хуш... (*Фәрхәнә китә.*) Син ни эшләдең, әйтче миңа, син ни эшләдең? Бетердең, бетердең... Болай булгач, старосталыгымны да алдырыр бит ул.

Гарифә. Алдырсын!.. Ике бозауга кибәк аера алмаган башың белән староста итеп куя башлагач та шикләнгән идем. Яшь балага тәти күрсәтеп кызыктырган кебек, староста калай медаленә кызыңны алмакчы булганнар бит.

Дәүли. Теләсә ни булсын, Сабир кебек яхшы кияүне читкә җибәрмәм.

Сәет керә.

Сәет. Әти, сельский белән старшина килде, сине чакыралар.

Дәүли. Өйне җыештыр. Самовар куй, нәчәльствоны чәйгә алып керермен. (*Китә.*)

Маһи керә. Гарифә кочагына ташлана.

Гарифә. Елама, балам, елама. Башым исән чакта ул кансызга биреп елатмам.

Маһи. Рәхмәт, әни... (*Гарифә китә.*)

Тәрәзәдән Гаяз күренә.

Маһи. Әйдә, өйгә кер. Әти өйдә юк. Әни мунчада.

Гаяз өйгә керә.

Гаяз. Тукта, Маһи, сиңа ни булды?

Маһи. Хәзер генә Ишбулды Фәрхәнәсе, Сабирына сорап, яучы булып килгән иде. Әти җавапны иртәгә бирермен дип вәгъдә куеп җибәрде. Гаяз, акыллым, иртәгә үк яучы җибәреп кодала.

Гаяз. Яучы җибәреп бирмәсәләр,ябышып чыгарга ризамы?

Маһи. Сиңа бирергә риза булмасалар, ул чагында мин синең белән әллә кайларга барырга да риза!

Пәрдә

Өченче пәрдә

Гаяз өе, бай булмаса да чиста итеп җыештырылган. Пәрдә ачылганда кайгылы хәлдә Гаяз, Рамай керә.

Рамай. Әтүтән Дәүли дисәң дә Әтүтән шул, байлыкка кызыгып, тәки кызын саткан икән. Йә, нишләргә уйлыйсың? Минемчә, тотарга да урларга иде. Кыз урлап бирәүнең дә Себер киткәне юк әле.

Гаяз. Мин алай эшли алмыйм. Безнең Маһи белән куйган вәгъдәбез бар. Ул үзе килергә тиеш.

Тимергали керә.

Тимергали. Хуторчыларга җир сорап авылга земский начальник килә. Захарыч әйтә, хәзер үк аякка басып, халыкны кулга алырга кирәк, ди.

Гаяз. Әйдәгез, егетләр, эшкә. Үз байгураларын хуторга күчерәселәре килсә, тотсыннар да бояр, казна урманнарыннан кисеп бирсеннәр, үз басуыбыздан бер карыш җир бирмибез.

Маһи керә.

Маһи. Менә, Гаяз, мин килдем.

Гаяз. Рәхмәт, Маһи, сүзеңдә торгансың. Яшь мулла белән сөйләштек, никах укырга булды. Хәзер ындыр артыннан гына керәбез дә укытып чыгабыз.

Маһи. Әйдә, Гаяз, Аллага тапшырдык. (*Китәләр.*)

Хәсби. Тукта инде, токмач кабартырга утыным юк икән. (*Китә.*)

Бераздан әкрен генә ишек ачыла, як-ягына карана-карана, Гыйльми керә. Өйнең бөтен җирен җентекләп тикшерә.

Гыйльми. Берсе дә өйдә юк икән, яхшы чакта урнаштырыйм әле. Баз капкачлары кая соң... Менә ул кайда икән... (*Базны ачып төен ташлый.*) Минем өчен нәрсә? Дәүли кызын Сабир алса ни дә, Тимерче Гаяз алса ни. (*Китә.*)

Хәсби, Маһи, Гаяз керә.

Гаяз. Өсләреңне сал, Маһи, үз өеңдәге шикелле чишенеп утыр. Безне хәзер беркем дә аера алмас. Җыен башланган, мин анда киттем. (*Китә.*)

Маһи. Әни, мин сиңа әнкәй диярмен инде, яме? Мин сине Гаязны яраткан кебек яратырмын.

Хәсби. Юк, юк, кызым, тәнемдә җаным, кулымда көчем бар чагында өй эшләрен синнән эшләтмәм. Ай-яй, башым әйләнә башлады...

Маһи. Кил, әнкәй, түргә ятып тор. (*Сәкегә ястык салып бирә. Хәсби менеп ята.*)

Хәсби. Килен, токмачымны гына басып бирерсең инде.

Маһи. Ярый, әнкәй, ярый, басармын. (*Җиңнәрен сызганып эшкә керешә.*)

Хәсби. Килен, бераздан, мин әйтәм, идәнне юып чыгарсаң да ярар иде. Минем Миргаязым чисталыкны ярата.

Маһи. Ярый, әнкәй, юармын.

Хәсби. Бераз бодай оным бар, иртә беләнгә коймак изеп җибәрербез. Кыл иләктән иләп куярсың.

Артта көлешә-көлешә сөйләшеп узган кешеләр тавышы ишетелә.

Маһи. Җыеннан кайталар.

Гаяз керә.

Гаяз. Сабирлар җиңелде. Җыен таралды. Земский начальникны кудылар.

Рамай, Шәриф, Тимергали һәм Сәет керә.

Рамай. Ягез, бер дога, илаһи амин, күпер башы Әмин, күршегез Тимерша, кардәшегез Батырша кебек алты улыгыз, җиде кызыгыз булсын, имәндәй картаеп, юкәдәй муртаеп, билләр бөкрәйтеп, күзләр чекерәйтеп, исәнлектә, саулыкта, байлык белән муллыкта, кергән кебек әчкелтем, чөгендердәй төчкелтем гомер итегез. Аллаһы әкбәр.

Орлов керә.

Гаяз. Әйдә, Захарыч, өсләреңне сал.

Утырышалар.

Гаяз. Әйдә, Захарыч, тот.

Орлов. Тукта әле, Гаяз, бераз хәл алыйм...

Рамай. Эчкәч алырсың, әйдә, крой.

Орлов. Ярый алайса, яшь кияү белән уңган килен саулыгына.

Хәсби аш кертеп куя.

Рамай. Әйдә, Шәриф, тарт колагын, моңлансын.

Шәриф гармун уйный. Тимергали җырлый. Бию көе уйнала. Тимергали биеп Сәетне чакыра. Сәет биеп Гаязны чакыра. Гаяз бии, Захарычны чакыра.

Гаяз. Анысы да монысы, егетләр, Захарыч китсә, нишләрбез?

Рамай. Тагын тимерчесез калабыз икән.

Гаяз. Әйе, Захарыч, синең белән бергә эшләү рәхәт иде... Син бит кешеләр арасында булган тигезсезлекләрне бетерергә юллар күрсәтеп, бозланып каткан йөрәкләребезгә көрәш чаткылары кабыздың. Китмә син, Захарыч, хатыныңны, балаларыңны монда китерик тә бергә-бергә эшләрбез.

Артта свисток кычкырткан тавышлар ишетелә.

Маһи. Гаяз, безнең капка төбендә кешеләр бар.

Орлов. Әйдә әле, Гаяз, яннарына чыгып керик. (*Китәләр.*)

Маһи. Әнкәй, минем өчен килгән булсалар, нишләрбез?

Тавыш. Макар!

Хәсби. Керәләр, әйдә, кызым, теге якка. (*Китәләр.*)

Револьверын төзәгән хәлдә ишектә Дерюгин күренә.

Дерюгин. Закон исеменнән игълан итәм: берегез дә урыныгыздан кузгалмагыз.

Бик саклык белән генә өстәл янына килә. Аның артыннан Макар, ике казак, Дәүли һәм понятойлар узалар.

Макар, по всем правилам тентүне башларга, идән астын... Башка җирләрне җентекләп карарга!

Макар. Слушаюсь. (*Базга төшеп китәләр.*)

Макар баздан чыга.

Господин урядник, баздан бер төен таптык. (*Төргәк бирә.*)

Дерюгин. Төен таптыгыз?.. (*Чишеп карый.*) Батюшки... Ялган акчалар... Так-так-так. А ну-ка, атаманнарын монда кертегез.

Макар китә. Орлов белән Гаязны алып керә.

Шаймарданов, бу акчалар синекеләрме?

Гаяз. Нинди акчалар?..

Дерюгин. Көмеш акчалар! Менә алар ниндиләр, чылтырамыйлар да, фальшивыйлар.

Гаяз. Андый акчаларны минем күргәнем дә юк.

Дерюгин. Господин Орлов, бу фальшивкаларны бергә ясадыгызмы? Тентү вакытында шушы өйнең базыннан табылдылар, черт возьми! Бу гололобыйлар үзләре генә болай оста итеп

ясый алмаслар иде, әлбәттә инде сезнең мастеровойлык ярдәм иткәндер. Йә, ни дисең?

Орлов (*өстәл янына килеп, акчаларны тоткалап караганнан соң.*) Паразит, негодяй!

Дерюгин. Да, против факта не попрешь. Староста, подводы давай!..

Дәүли. Господин урядник, барысын да алып китәсезме?

Дерюгин. Что за вопрос?.. Әллә син боларның эшен шутка думаешь? Әйдәгез, киттек.

Хәсби. Балам!.. (*Барып Гаязның муеныннан коча.*)

Аргы яктан, чәчрәп, Маһи чыга.

Маһи. Гаяз, бәгърем!..

Гаяз. Хуш, әни! Сау бул, Маһи!..

Хәсби. Алмагыз минем баламны, тимәгез аңар!

Барып ябыша, алып ташлыйлар. Чыгып китәләр. Маһи белән Хәсби идәндә аунап калалар.

Пәрдә

Дүртенче пәрдә

Каравыл өе. Төрле кәгазьләр эленгән. Бер якта яртылаш җимерелгән мич. Стеналарның кайбер җирләре, ишек яңаклары, тәрәзә бруслары үтмәс балта белән юнып алынган. Тәрәзәнең кайбер өлгеләренә чүпрәк, кәгазь ябыштырылган. Түшәм сайгаклары каралып, пычранып беткән. Пәрдә ачылганда бер төркем халык Тимай бабайны чорнап алганнар да бәет тыңлыйлар. Рамай белән Тимергали керә.

Рамай. Тимай бабай, әйдә әле, Тимергали белән бер җиргә барырсың. Гаяз өенә ялган акчаларны Гыйльми карчык ташлаган дигән хәбәр бар. Ничек булганны үз авызыннан сөйләтә алмабызмы?

Тимай. Әйдә, улым, әйдә. (*Китәләр.*)

Фәйзулла. Молодец, Рамай, алай иттең, болай иттең, атсыз калып булса да үзеңнекен эшләдең.

Рамай. Кучереннән алып, прокурорына кадәр бирә башлагач, бетә икән ул, егетләр.

Фәйзулла. Кайгырма, Рамай, башың сау булса, атын табарсың, ичмасам, урядник кадәр урядникне чукындырасың бит.

Шәриф. Ул тикшерүче дигәннәре кая соң әле?

Рамай. Дәүли абзыйларда чәй эчә калды.

Артта Мочтакның җырлаганы ишетелә.

Мочтак. Әйттер, типтер, сиптер әйдә, дөнья үзебезнеке. Рамазан, рәхмәт сиңа, Ишбулды Сабирын акылга утыртасың икән. Ул минем затлы әйберләремне алдап алган иде, мошенник!

Дәүли керә.

Дәүли. Таралыгыз, җәмәгать. Тикшерүче килде.

Тикшерүче керә.

Тикшерүче. Староста!.. Хәзергә чыгып торсыннар.

Дәүли. Храша. Әйдәгез, әйдә. (*Тикшерүчедән, старостадан башкалар чыгалар.*)

Следователь. Тимергали Шәрифуллинны җибәрегез.

Дәүли. Тимергали! Кая дөмектең, господин следователь чакыра.

Тимергали керә. Дәүли китә.

Тикшерүче. Ну, Шәрифуллин, сез нәрсә әйтергә телисез?

Тимергали. Шушы кәгазьдә тамга салган йөз сиксән капка кешеләре, Гаяз белән Орловның нахакка Себер китүен әйтеп, Ишбулды Сабиры белән урядникнең хөкемгә тартылуын сорыйлар.

Тикшерүче. Аларның гаепле икәнлекләрен күрсәтер өчен нинди фактларыгыз бар?

Тимергали. Моннан ике ел элек Сабир күрше авыл Тимкә Ниязовтан тиреләр алганда ялган акчалар биргән. Ул акчалар аның кулында саклана. Тентү вакытында Гаяз Шәймәрдәнов өеннән табылган акчаларны да Сабир Ишбулдин ташлаткан. Ышанмасагыз, төен ташлаучы карчыктан сорагыз. Ул монда.

Тикшерүче. Монда?.. Ну-ка, давай сюда.

Тимергали китә, Рамай белән Гыйльми керә.

Тикшерүче. Ә сез нәрсәгә?

Рамай. Карчыкның тылмачы булам.

Тикшерүче. Кирәкми, тылмач староста булыр. Староста!..

Дәүли. Ждич...

Рамай. Кара аны, Дәүли абзый, бутый күрмә, тыңлап торабыз. (*Китә.*)

Тикшерүче. Бабушка, как тебя зовут?..

Гыйльми. И Ходаем, казамат диме?

Дәүли. Юк, ни атлы ди.

Рамайлар, следовательгә күренмичә, тәрәзәдән карап торалар.

Г ы й л ь м и. Ә... үзең беләсең инде. Чикерткә Гыйльменисасы, иремнеке Әфләтүн иде.

Т и к ш е р ү ч е. Что бормочет, переведи.

Д ә ү л и. Кабилка дуч бает.

Т и к ш е р ү ч е. Как то есть, кабилка?

Д ә ү л и. Вот бит летом на травах гуляет, чикерт-чикерт, тырт-тырт... (*Сикереп күрсәтә.*) А мужика Әфләтүн.

Т и к ш е р ү ч е. Бернәрсә дә аңламыйм. Бабушка, в избу Шаймарданову узел ташлаган?

Г ы й л ь м и. Ә?..

Д ә ү л и. Гаяз өенә төен ташладыңмы, ди.

Г ы й л ь м и. Гөнаһ шомлыгына каршы ташлаган идем шул.

Дәүли тәрәзәгә карый. Рамай йодрык күрсәтә.

Д ә ү л и. Против греха бросал, говорит, господин следователь, бросал.

Т и к ш е р ү ч е. Спросите, кто велел бросать?

Д ә ү л и. Анда илтеп ташларга кем кушты, ди.

Г ы й л ь м и. Кем булсын, Ишбулды мөртәте, Сабир имансыз.

Д ә ү л и. Сабирка мөртәт, Сабирка без... иман, говорит.

Т и к ш е р ү ч е. Как то есть, мөртәт, без иман?

Д ә ү л и. Вот бит, мусульман сначала молитва укыган, потом грешился богу, чукынган. Потом...

Т и к ш е р ү ч е. Ладно, понятно... она хорошо знала, что имеется в этом узле?

Д ә ү л и. Ул төендә ни барлыгын белдеңме, ди.

Г ы й л ь м и. Юк, белмәдем, сүтеп карамадым. Үзе миңа, сихер кәгазьләре, сөйдергеч бөтиләр, диде.

Д ә ү л и. Не знала. Сам сказал — против чорта, шайтан бумаги, калдонски бугамалится баранчуклары, бает.

Т и к ш е р ү ч е (*бик каты өстәлгә сугып*). Врешь, дохлая ведьма!..

Г ы й л ь м и. Ләхәүлә вәлә куәте...

Т и к ш е р ү ч е. Почему она через такой промежуток времени әйтергә булган?

Д ә ү л и. Ни өчен хәзер генә әйтергә уйладың, ди.

Г ы й л ь м и. Иманамны алдап алганнан соң, ашарга-эчәргә бирми башлагач, аның өчен гөнаһлы булып, мәхшәр көнендә дуңгызлар белән кубарылып тәмуг утында янасым килмәде.

Дәүли аптырап кала.

Д ә ү л и. Гыйльменисаттәй, бутамыйча, юньләп кенә әйт әле.

Гыйльми. Аның өчен гөнаһлы булып, мәхшәр көнендә дуңгызлар белән кубарылып, тәмуг утында янасым килмәде, дим.

Дәүли. Если грехами умирает булса, там-та-ра-ра далуки дөньяда, нашеныкы Мөхәммәтанский бух, как ваш свинья, тәмугта җарит буҗет, говорит.

Тикшерүче. Как, как?..

Дәүли. Нашеныкы Мөхәммәтанский бух, как ваш свинья, тәмугта җарит буҗет.

Тикшерүче. Уф, ничего не понимаю. Идите к черту!..

Гыйльми. Нәрсә ди?

Дәүли. Шайтаннар янына китегез, ди.

Гыйльми. Дәүләтша, иманамны алып бирәме?

Дәүли. Бирә, бирә, зинһар өчен күземнән югал.

Китәләр. Сабир керә.

Тикшерүче. Эшләр сезнең өчен серьезный төс алып бара.

Сабир. Ничек серьезно?

Тикшерүче. Бөтен авыллары белән өстеңнән приговор җыйганнар. Шуның өстенә Шаймардановның өенә ялган акчалар ташлаган карчык килеп үз теленнән миңа сознаваться итте.

Сабир. Иван Василич, күпме алсагыз да алыгыз, ләкин мине бу бәладән коткарыгыз. (*Акча бирә.*)

Тикшерүче. Кирәкми, кирәкми. (*Акчаларны алып кесәсенә тыга.*) Бу бит бик зур эш. Бөтен өяз, губерна чиновникларына беленсә, нишләрбез?

Сабир. Мәгез, аларга да бирегез. Тик, зинһар өчен, мине аклый гына күрегез. (*Күп итеп тагын акча бирә.*)

Тикшерүче. Ярый, мин алар белән сөйләшеп карармын, ну шулай да мин сезне хәзер арестовать итеп өязгә алып китәргә тиеш. Кайгырма, өязгә баргач җайларбыз.

Тимай, Рамай, Тимергали, Шәриф, Фәйзулла һәм башкалар керәләр.

Тикшерүче. Ишбулдин, мин сине кулга алам, әйдә, атла.

Рамай. Тарттыр, әйдә тарттыр, алдыңнан артың!..

Башкалар. Ха-ха-ха!..

Сабирлар чыгып китәләр. Рамайлар сызгырып озаталар.

Пәрдә

Бишенче пәрдә

Урам. Бер якта Рамайның тәрәзәләре тамашачыларга карап торган иске өе күренә; икенче якта салам түбәле келәт, уртада киртә-койма һәм җил капка. Вакыт кич. Ачык тәрәзә аша Маһиның шыңшып, киндер сугып утырганы күренә. Сәхнәдә беркем дә юк. Ашыгып Гарифә керә.

Гарифә. Исәнме, кызым? Рамай өйдәме?

Маһи. Гобәй байларга ышна әрчергә киткән иде. Әти өйдәме?

Гарифә. Урядник белән ясак түләмәүчеләрнең әйберләрен җыялар. Сезнең дә самоварыгызны язганнар иде бугай... Ялгыштың шул, балам. Бер бәхетең җимерелгәч, күрәләтә моныcына килеп эләктең. Саварга сыерың, җигәргә атың да булмагач, тормышмыни бу? Әхмәтша Рамае дип даны чыкканга килеп абындың.

Маһи. Ярый инде, әни, өлешемә тигән көмешем, үзе егылган еламас диләр бит.

Гарифә. Мә әле, кызым, атаңнан яшереп җыйган акчам бар иде. Рамай кияүгә бирерсең, самоварыгызны йолып калыгыз.

Маһи. Кирәкми, әни, Рамазанны ярлы дисәгез дә, кеше ярдәменә мохтаҗ түгел ул.

Бәйрәм киеменнән Сабир күренә.
Маһи тәрәзәсен яба.

Сабир. Нихәл син, күтәрмә борын, кук тәтәй!..

Гарифә (*салкын гына.*) Әйбәт әле, әрем авыз, сыткы сагыз.

Сабир. Син дә, мин әйтәм, чуклы кияү көткән идең, тәтемәде.

Гарифә. Аллага шөкер, ярлы булса да, менә дигән уңган егеткә юлыктык.

Сабир. Егет уңган, сүз дә юк, тик шул кадәресе бар, ыштыр алырлык та хәле юк. Бичараның чабатасы үкчәсен кыра.

Гарифә. Ни әйтсәң дә син түгел инде, кеше хакы ашап, нахактан яшь түктерми.

Гарифә чыгып китә. Сүгенә-сүгенә, Мочтак керә.

Сабир. Берәр яры китәргә уйлыйсыңмы әллә?

Мочтак. Әти белән бертуган түтәйнең малайлары Оренбурда сату итәләр, шулар янына китәргә җыена идем, юлга акчам юк.

Сабир. Мостафа, минем сиңа бер йомышым бар иде. Караңгы төшкәч, ындыр артлап кына миңа кер әле, шунда сөйләшербез.

Икесе ике якка китәләр, Рамай кайтып керә, өйдән Маһи чыга.

Маhи. Әйдә, кое суы белән юынып җибәр, хәл керер. (*Юындыра.*) Гобәй абзыйларга онга кергән идем, әти кушмады дип, өлкән улы бирмәде.

Рамай. Ярый, үзем кереп алырмын.

Урамнан мәчет картлары киеменнән **Гобәй** узып бара. Рамай кычкырып туктата.

Гобәйдулла абзый, ышнаңны әрчеп бетердем, төпләрен кагып, ызанга өеп куйдым. Маhисәрвәр онга кергән икән дә, малаең бирми чыгарган.

Гобәй. Син кечкенә чакта әтиең мәрхүм, әҗәткә дип бер пот он алган иде, бичара карт шуны түли алмый үлде бит. Ышна әрчегән акчаңнан шуны тотып калырга булдым.

Рамай. Ялганлыйсың, карт тәре!.. Яхшылыкта атна буе тамыр чапкан хакымны бирәсеңме, юкмы?!

Гобәй. Әй!.. Сафиулла, бире кил әле...

Бер **кеше** керә.

Менә бу, буш бугаз, миңа ут салам дип янады. Әйдә урәдниккә, шаhит булырсың.

Рамай. Ах син, елан, мине урәдник белән куркытмакчы буласыңмы?!

Гобәй. Караул, үтерәләр!.. (*Йөгереп китә.*)

Рамай балта белән куа башлый. **Маhи** чыгып тота.

Маhи. Юләрләнмә, ташла балтаңны, тынычлан, син акыллы бит, әйдә ашарга кер. (*Кереп китә.*)

Дерюгин белән **Дәүли** керә. Урамда бер читтә **Гобәй** карап тора.

Дерюгин. Ахметшин, атаңнан калган недоимкаларыңны түләмәгән өчен, әйберләреңне алып чыгабыз, это раз. Во-вторых, казна урманыннан бүрәнә урлап тотылгач, мировой суд бер ай ятарга, унбиш сум штраф түләргә ясаган.

Рамай. Беттеме?

Дерюгин. Юк әле. Нигә син Гобәй байга балта күтәреп hөҗүм ясадың?

Гобәй. Ут салырга янады, господин урәдник, менә шаhитым бар.

Дерюгин. Макар!.. Староста белән өенә керегез дә самовар белән мендәрләрен алып чыгыгыз.

Макар. Тыңлыйм, господин урядник.

Дәүли белән кереп китәләр.

Маhи. Рамазан, алып чыгалар бит. Нигә эндәшмисең? Менә, мә, кыз чагымдагы чулпымны бирәм, түлә үзләренә, бугазлары тыгылсын.

Рамай. Кирәкми, Маhи, хатын-кыз өшәнчекләре белән ясак түләү Рамай кебек егетләргә хурлык ул. (*Самовар, мендәр күтәреп чыгучы Макар белән Дәүли каршына барып баса.*) Калдырыгыз минем әйберләрне!

Дерюгин. Ах син, гололобый. (*Камчы белән суга.*)

Рамай. Әле син шулаймы?.. (*Урядникны сугып ега.*)

Дерюгин, Макар, Дәүли, десятниклар әйберләрен ташлап йөгерәләр. Рамай балта белән артларыннан куа бара. Маhи чыгып каршы төшә.

Маhи. Рамазан, юләрләнмә, ташла балтаңны...

Рамай. Абзыйлар!

Тимай белән ясактан таланган кешеләр керәләр.

Тимай абзый, әйберләрегезне алыгыз.

Тимай. Молодец, улым Рамазан, молодец. Урядник итеп сине генә куясы бар икән.

Әйберләрен алып таралалар.

Маhи. Рамазан, син нишләдең? Тагын тотып ябарлар бит.

Рамай. Маhи, бар, әйберләрне җыйна, китәбез. Тимергалиләр шахтага китәләр, алар белән без дә качабыз. Бар, әзерлән. Мин Тимергалиләргә белешергә барам. (*Чыгып йөгерә.*)

Ишегалды яктан сакал-мыеклары җиткән Гаяз керә. Саклык белән килеп ишек шакылдата.

Маhи. Ах! Бу кем?

Гаяз. Курыкма, Маhи, бу мин.

Маhи. Гаяз?

Гаяз. Әйе, Гаяз... Шулай да таныдың.

Маhи. Син ничек монда, котылып кайттыңмы?

Гаяз. Захарыч белән Себердән качтык. Мәскәү ягына үтеп барышыбыз. Сине алырга дип кергән идем, ләкин...

Маhи. Гаяз, син миңа үпкәләмә. Рамайга да ачуланма. Ул да, мин дә гаепле түгел. Мин бөтен көчем белән тырыштым. Тик кара бәхетемне аклый алмадым. Сине алып киткәннән соң, әниең янында торырга теләдем, ирек бирми кыйнап алып кайттылар. Артыңнан Себергә китәргә булдым, сизеп алдылар да ике балалы тол иргә көчләп бирә башладылар. Менә шуннан соң Рамайга ябышып чыкмый чарам калмады.

Гаяз. Ярый, Маһи, елама... Мин барысын да ишеттем... Барысын да сораштым... Рамай кая соң?

Маһи. Тимергалиләргә киткән иде, чакырып кайтыйммы?

Гаяз. Авырсынмасаң чакыр. Минем аңар йомышым бар.

Маһи. Мин хәзер кайтырмын. Син аңарчы келәткә кереп тор. Анда җәйгән урын да бар.

Гаяз. Ярый алайса. (*Келәткә кереп китә.*)

Маһи урамга чыгып югала. Икенче яктан Сабир белән Мочтак керә.

Сабир. Әйдә, Аллага тапшыр, менә бу келәт артына керәсең дә амбар астына саласың.

Мочтак. Ярый, ләкин без исәп-хисапны бетерик әле. Аннан туп-туры Оренбургга таям.

Сабир. Кара аны, алдарга уйлама, әҗәлең миннән булыр. (*Акча бирә.*)

Мочтак. Курыкма, алдамам. (*Китә.*)

Сабир. Булды бу. Ут салуны бу хәерчегә сылтарлар да, ун ел Себергә. (*Келәттә дөбердәгән тавыш ишетеп, барып тыңлый.*) Әһә... Монда йоклыйлар икән. Бигрәк тә яхшы. Ишекне бикләп алырга кирәк. (*Keләсен элә.*) Тычкан балалары шикелле чыелдашып янсыннар әле. (*Келәт артына поса.*)

Бакча ягыннан Сәет белән Сәләхи керә.

Сәет. Сәләхи, Гобәйнең кыярлары да, кыярлары! Утыйк әле туйганчы. Менә моннан гына керәбез дә кыярлар безнеке. Әйдә, чумдык.

Китәләр, бераздан йөгереп кире чыгалар. Рамайга очрыйлар.

Сәет. Җизни, җизни, сезнең келәт артында бер кеше ут салып маташа!

Рамай. Ут салып? (*Мочтак киткән якка китеп югала.*)

Малайлар кычкырып урамга йөгерәләр.

Малайлар. Ут бар!..

Рамай белән Мочтак куышып чыга. Гаяз келәт ишеген дөбердәтә.

Рамай. Качма, барыбер котыла алмассың. (*Сугып ега.*) Ут салучы бар!

Гаяз келәт ишеген ватып чыга.

Сабир. Кычкырма, эт!.. (*Балта белән суга.*)

Рамай егыла.

Гаяз. Сабир! Кеше үтердең?..

Сабир. Каторжан?.. Әйдә, Мочтак, тот, качмасын.

Һөҗүм итәләр.

Гаяз. Ташла балтаңны, кабахәт! (*Тотып ала.*)

Мочтак арткы яктан килеп ябыша. Тимергали, Шәриф һәм башкалар керә.

Тимергали, бу мин, Гаяз.

Башкалар. Гаяз?

Шәриф. Бусы кем? Рамай?..

Маһи керә.

Тимергали. Маһи, Рамайны үтергәннәр.

Дәүли, Дерюгин керә.

Шәриф. Господин урәдник, Рамайны үтергәннәр.

Дерюгин. Рамайны? Кем үтерде?

Сабир. Господин урядник, без, Мочтак, Рамай белән өчәүләп, менә бу каторжанны ут салганда тоткан идек, Рамайны балта белән сугып үтерде.

Мочтак. Дөрес, җәмәгать, әнә балтасы да кулында.

Маһи. Гаяз, синме шуны эшләдең?

Гаяз. Юк, Маһи, мин түгел, алдыйлар!

Мочтак. Ялган! Ут салучы син...

Сабир. Рамайны үтерүче дә син!

Сәет. Әти, без ут салучыны күрдек.

Дәүли. Күрдегез? Кем иде?

Сәет. Ул кеше Мочтак абзыйга охшаган иде.

Сәләхи. Шулай шул, әнә башында салам эшләпәсе дә бар.

Мочтак качмакчы була.

Фәйзулла. Тукта, сабыр итеп тор!

Тимергали (*Мочтакның якасыннан алып*). Җаның исән чакта дөресен әйт, синме салдың ул утны?

Мочтак. Әйе, җәмәгать, мин салдым. Ләкин мине Сабир яллады. Рамайны балта белән сугып үтерүче дә ул үзе.

Халык. Әһә, менә ул ничек?

Дерюгин. Староста! Өчесен дә тотып бәйләгез дә каравыл өенә илтеп ябыгыз.

Маһи. Абзыйлар... Без бу кешене урәдниккә генә биреп котыла алмабыз. Бүген алып китсәләр, иртәгесен кайтыр да тагын башкаларыбызны үтерер, без аны үзебез хөкем итик!

Д ә ү л и. Кызым, син ни эшлисең?..

М а һ и. Кит минем янымнан!.. Абзыйлар!.. Без аны үзе төрткән утка салыйк.

Ф ә й з у л л а. Дөрес, утка...

Д ә ү л и. Җәмәгать, бу нишләвегез, әллә котырдыгызмы?

Т и м е р г а л и. Агайлар, ни көтеп торасыз? Маһи әйткәнчә, утка ташларга кирәк.

Д е р ю г и н. Якын килмәгез!.. (*Револьвердан ата.*)

Т и м е р г а л и. Әһә, әле син мылтык белән куркытасыңмы?

М а һ и. Абзыйлар, үзен дә утка ташларга!..

Т и м а й. Әйдә, җәһәннәмгә поход пошел!..

Урядникны тоталар.

Д е р ю г и н. Господа, Сабирны алыгыз, ради бога, мине җибәрегез.

Урядникны җибәрәләр, чукына-чукына чыгып йөгерә.

Т и м е р г а л и. Әйдә, тотыгыз!

С а б и р. Тимергали, җанкисәгем, Фәйзулла абзый...

Ф ә й з у л л а. Әйдә, җәһәннәмгә кисәү бул!..

Шашкан халык толпасы Сабирны күтәреп утка таба китәләр.

Пәрдә

1934 ел

Б и р е м н ә р

1. Пьесага анализ ясагыз.

2. Анализ нәтиҗәләрен инша итеп языгыз.

Газиз Гобәйдуллин
(1887—1938)

Газиз Салих улы Гобәйдуллин 1887 елның 27 июнендә Казанда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Тугыз ел буена «Халидия» мәдрәсәсендә укый. Монда ул көнчыгыш телләрен өйрәнә һәм фәлсәфә, логика (мантыйк) фәннәрен үзләштерә.

Югары уку йортына мәдрәсә белеме белән генә кереп булмый. Егет бик кыска вакыт эчендә сигезьеллык гимназия курсына имтиханнар тапшыра. Ә 1909 елда Казан университетының юридик факультетына укырга керә. Бер елдан соң, укытучылары киңәше белән тарих-филология факультетына күчә. Университетны Газиз бик яхшы билгеләренә генә, дәрәҗәле диплом алып тәмамлый. Студент чакта ук фәнни хезмәтләре төрле журналларда басылуга карамастан, аспирантурага керерлек мөмкинлеге булмый. Троицк шәһәрендә укытучы булып эшли. Зөягә кайтып, укытучылар семинариясенең директоры вазифасын башкара.

Казан университеты аспирантурасына ул фәкать Октябрь революциясеннән соң гына кереп укый ала.

Тарих үзенең вакыйгаларына берьяклы гына бәя бирүне яратмый. Октябрь революциясенең кире яклары белән бергә, татар халкына китергән уңайлыклары да шактый була. Шуларның берсе итеп, татар балаларына белем алу өчен күп мөмкинлекләр тудыруны исәпләргә кирәк.

Газиз Гобәйдуллин аспирантураны күп санлы гыйльми мәкаләләре һәм китаплары белән танылып өлгергән галим булып тәмамлый. Шуңа күрә бу яшь егеткә Казанда Көнчыгыш академиясе төзү кебек гаять дәрәҗәдә җаваплы эш тапшыралар. Галим бу эшне җиренә җиткереп башкарып чыга. Үзе шунда тарих укыта. Профессор булып сайлана.

Галим, татар, башкорт, үзбәк, азәрбайҗан халыкларының тарихына, әдәбият тарихларына багышлап, дистәләрчә китап, йөзләрчә мәкалә яза. Язган хезмәтләренең барысы да диярлек үзе исән вакытта ук рус теленә тәрҗемә ителеп басылалар. Мәктәп балалары тарих фәнен күп еллар буена Газиз Гобәйдуллин дәреслекләреннән өйрәнәләр.

Гасырлар дәвамында үзен үзе аңларга омтылган халык, ниһаять, Мәрҗани һәм Газиз Гобәйдуллиннар тырышлыгы белән максатына иреште, үзенең язмышын күз алдына китерде, кемлеген белде, горурлыгы артты.

Кызганычка каршы, галимгә туган илендә эшләү өчен шартлар начарланганнан-начарлана бара. Аның хезмәтләрен сыйнфый көрәшкә игътибар җитмәүдә гаеплиләр, бастырмый башлыйлар. Газиз Гобәйдуллин читкә китәргә мәҗбүр була. Ул башта Үзбәкстанда, аннары Азәрбайҗанда хезмәт итә. Әлеге халыкларның үз телләрендә язып китаплар бастыра. Бу илләрдә дә мәшһүр галим булып таныла.

Ләкин миллионнар гомерен өзгән 1938 ел Газиз Гобәйдуллинны да аямый. Аның аяныч язмышы — татар милләтенең фаҗигасе. Ул — үткен фикерле сатирик та, нечкә күңелле лирик та. «Марс, уян» исемле беренче хикәясен әдип 1907 елда «Казан мөхбире» исемле газетада бастыра. Хикәяне шунда ук рус теленә тәрҗемә итәләр һәм рус газетасында да бастыралар. Мондый игътибар егетне канатландырып җибәрә. Шуннан соң ул, җиң сызганып, хикәяләр яза башлый. Әсәрләре күбәйгәч, аларны аерым китап итеп бастыра.

Язучы дөньяны сурәтләр бәйләнеше итеп, галим төшенчәләр җыелмасы итеп күрә, диләр. Газиз Гобәйдуллин — галим дә, язучы да. Тормышны ул ничек күрә? Әдип хикәяләрен укыганда шул сорауга җавап биреп карагыз.

ФОРТОЧКАЛЫ КӘЛӘПҮШ

Кәләпүшне калыплый торгач, Сәмигулла абзый кинәт туктады. Миңлебикә абыстай мич алдында коймак пешерә иде.

— Тукта әле, хатын,— диде ул,— куй әле беразга гына, үзеңә генә бер сүз әйтим, теге Закир киттеме? Ул булса сөйләмим; ишетмәсен, йә үзе ясар... хитри кеше ул...

— Тукта әле, карт, йөдәтмә, хәзер Маһруй белән кияү килер, әнә сәгать җиде тула...

— Туктасана, куй әле! Шул табаңны пешер дә кил!

— Менә булды... Хәзер киләм! — диде дә Миңлебикә абыстай, кулын алъяпмасына сөртә-сөртә, аның янына килде.

— Йә, нәрсә әйтәсең?

Сәмигулла абзый кулына калыплап бетергән кәләпүшне алды да:

— Менә мин нәрсә уйлап чыгардым: менә күрәсеңме? Кәләпүшче Лотфулла кәләпүш өстенә дүрт тишек ясаган булган... Мөселман духтыры да мактаган, ди: хәзер башка һава кереп торыр, хәзер татарның башы авыртмас инде, һава йөреп торыр, дип әйтә, ди... Ә мин хәзер япун күк булдым инде, тагын башка төрле әкәмәт чыгармакчы булам...

— Тизрәк булсана! Булырсың менә, әҗәткана, япун! Нишләмәкче буласың тагы? — дип, Миңлебикә абыстай иреннән сорап өлгермәде, Сәмигулла абзый сүзен дәвам итте:

— Менә нәрсә эшлим: күрәсең әнә тәрәзәдә шылтыр-шылтыр итеп фурточка әйләнеп тора; ясамакчы булам; кечкенә генә, челтер-челтер итеп, сандугач күк сайрап утыра торган фурточка...

— Калфакка да ясa син аны, — диде Миңлебикә абыстай, — безгә дә рәхәт булсын.

— Әлек кәләпүшкә ясыйм, аннан соң сезнең чыпчык күк калфагыгызга да ясармын... Кая, бир әле кайчы белән әнә беркөн кияүләргә алып кайткан пампаси[2] тартмасын. Хәзер ясап карыйм...

— Аңар мин сабын салып куйдым, юк эшкә...

— Бир, дим, хәзер бир... Кеше фурточкалы кәләпүш ясамакчы, милләтнең башы авыртуын бетермәкче була, ә син шуны да табып бирмисең.

Миңлебикә абыстай тартманы эзли башлады.

— Фу, коймак пешереп бетерергә дә ирек юк! Сиңа калды, фурточка эшләргә инде... әҗәткана!

— Эзлә, эзлә! Менә гәзитләрдә мактый башласалар, син дә сөенерсең... Менә һәммә кеше миңа заказ бирә башлар; ә минем игълан гәзитләрдә басылып чыгар: «Мин, кәләпүшче Сәмигулла әфәнде Гыйззәтуллин, табиблар кушканча, мәшһүр, файдалы фурточкалы, сайрый торган кәләпүш эшлим... Ихтирам белән, Сәмигулла Гыйззәтуллин», дип яздырырмын. Әйдә китсен безнең дан!

---

[1] Пампаси — конфет тартмасы димәкче була.



Миңлебикә абыстай бер калай тартма табып китерде:

— Аны кеше ничек киеп йөрер соң? Шыгырдап йөдәтер ич соң ул?!

— Алай түгел ул, хатын; элек ул башның яман исе чыкканчы сайрый да соңыннан баш истән тазаргач сайрамый! Менә безнең фурточка да һаман шыгырдамый бит!

— Әйдә, яса... Мин коймакларымны пешереп бетерим әле!

— Әй, сиңа әйтәм, кияү килгәч тагын син шапылдама, ул үзе ясый башламасын!

— Юк, юк, эстәгъфирулла... Сиңа сөенеч миңа да сөенеч ич!..

Сәмигулла абзый, тартманы кисә башлап, телен чыгарып эшләргә тотынды.

«Тукта әле, мин моны болай гына калдырмыйм... Илтерски куәте[1] белән, әнә теге кинима томанныендагы күк[2], тиз әйләнә торганнарын ясыйм»,— дип уйлады ул эченнән...

1917 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Хикәя вакыйгасын бик кыскартып: Сәмигулла абзый кәләпүшкә яңалык кертергә ниятли, дип кенә әйтергә мөмкин. Шул вакыйганы икегә ничек бүлеп була?

2. Шундый ярты-йортылы вакыйганы тулы бер хикәя итәр өчен, автор нинди алымнар кулланган?

3. Хикәя бер кешенең ахмаклыгы турында гына язылган кебек. Газиз Гобәйдуллин кебек галим һәм язучы, бәлки, шундый кечкенә максатны гына күз алдында тотмагандыр? Шулай итсә, бу әсәрнең субъектив эчтәлеген сөйләп карагыз.

---

[1] Илтерски куәте — электр куәте.

[2] Кинима томанныендагы күк — кинодагы сыман.

УЛ МАКТАНМЫЙДЫР ИДЕ

Бүрәнә артындагы читәнгә сөялеп дачникларның сүзләрен тыңлап торган Казаннан килгән парикмахер Хәйри дә үзенең нечкә генә тавышы белән сүзгә кереште:

Чәч алу,— даром шту прастуй эш хисаплансын, сезнең эшләр күк үк важный һәм читен эш ул. Мин сезгә, рөхсәт кылсагыз, бер сүз сөйләр идем, мактану булыр... Мин һәрвакыт мактанудан курка торган кеше, мин вапши туры кеше. Без сигез брат, шуның иң кечесе мин, иң олыбыз мәрхүм Әхмәтхан абзый иде, ну яхшы кеше иде. Менә шул сигез берадәрнең алтысы менә шул бераз мактануны сөя торган кешеләр иде... Мин, ни дип, яманлап әйтмим, вапши мин кеше гайбәт кылуны яратмыйм. Менә Гобәй абзый яхшы белә... Ривалюциядән элек Хәйри яхшы кеше, гайбәт иясе түгел, чәч алучы Шәрәфи гайбәт сата дип, сакал-мыегын миңа кереп төзәттерәләр иде. Шулай бит, Гобәй абзый? Менә шул сигез братның иң карты, ягъни мәрхүм Әхмәтхан абзый белән мин гаҗәп кешеләр булып чыктык... Әхмәтхан абзый сиксәнгә җитеп вафат булды, шул сиксән ел эчендә мин аның бервакыт мактанганын ишетмәдем... Дөрес, без зур кеше түгел. Шул, кыптыр-кыптыр чәч алып, сакал-мыек төзәтеп гомер уздырдык. Улыбыз — ул, кызыбыз кыз булды... Без инде шкул бетергән кеше түгел, ну шулай да, иске замандагы күк, плитуа белән чәч алып, кайчы белән кыркып башлаган кеше, бара-бара машина белән дә ала башладык. Менә хәзер прабур да ача беләбез; яруш та эшләп була. Ак чәчне кап-кара итеп тә буйый беләбез; кирәк булганда бөдрәләтеп тә ташлыйбыз. Мактанып әйтү түгел, бездә инде мактану дигән нәрсә юк та юк, аны без белмибез дә, белергә дә теләмибез. Без инде шулай туганбыз, шулай үләрбез дә...—дип сөйли башлаган иде, урысның әтәче бик ачы итеп бер кычкырды. Тау артыннан җәйге шәфәкъ күтәрелеп килә иде...

Биремнәр һәм сораулар

1. Чәч алучы сүзләренең ата-анасы юк. Авторга шуны күрсәтергә кирәк тә. Ләкин Г. Гобәйдуллин буш сүз сөйләтү белән генә канәгатьләнми, аңа көлеп бәя дә бирә. Моның өчен ул әлеге буш сүзләрне ниндидер бер тәртипкә китерергә тиеш була. Нинди тәртипкә китерә? Көлүен ничек белдерә?

2. Чәч алучы белән кәләпүшче Сәмигулла абзый арасында охшашлык бармы? Җавабыгызны исбат итегез.

3. Дәреслеккә хикәянең икенче яртысы гына керде. Баштагы өлеш төшеп калды. Шул төшеп калган өлешнең эчтәлеге нинди булырга

мөмкин? Сорауга җавап бирү өчен, чәч алучы сүзләрен игътибар белән тагын бер күздән кичерү кирәк булыр. Ләкин сез аны юмористик (сатирик) әсәрләрнең төзелешеннән чыгып та таба аласыз. Сатирик әсәрнең бер өлеше билгеле булса, икенче өлешенең нинди булуы сорала?

4. Хикәянең соңгы ике җөмләсе турында уйлагыз. Ни өчен «әтәч бик ачы итеп кычкырды» түгел, ә «урысның әтәче бик ачы итеп кычкырды»? Авторга көтмәгәндә таң ату турында әйтү нигә кирәк булды?

БУ МИЛЛӘТ НИЧЕК ТӘРӘККЫЙ ИТСЕН?

I

Хиффәтҗан абзый, Городской театрга барып җитәрәк, атланган атына бер камчы орды. Ат та аягүрә торды, хуҗасын ега язды... ул бөтен кешене гаҗәпләндерерлек бер эш кылган: атка атланган иде...

Әйе, ул атка атланды! Алай гына да түгел, хәтта соры френч киеп, билен дә Кавказдан алып кайткан черкес кәмәре белән буды... Фәс тә кигән иде.

Ник кәмәр такмаска, ник атка атланмаска? Хәзер бит Хиффәтҗан абзыйга бөтен имкян ачылды[1]: февраль ихтилалы[2] килеп чыкты... Аның күңелендә инде күп заманнар яшеренеп торган серләрне вөҗүткә чыгарырга вакыт җитте...

Бит ул кешегә генә сөйләми: аның бүген булачак митингта бик мөһим сүзләр сөйлисе бар... Бит Ходай ислам галәмен иске бөеклегенә кайтарырга аңарга насыйп иткән:

— Әфган, Иран, Мәракеш... Белуҗстан...

Юк әле, аны хәзер үк белдерергә ярамый:

— Менә бүген театрда булачак җыелышка барыгыз да шунда тыңлагыз... Ишетерсез... бөек фикерләрне аннан ишетерсез...

Театрга барып җитәрәк, атка яңадан бер камчы орды... Барып җитте... Атын бәйләде дә эчкә кереп китте.

II

Театрга кеше тулган... Хиффәтҗан абзый сәхнәгә якын эскәмияләрнең берсенә килеп утырды, уңга, сулга, алга әйләнеп, муенына таккан биноклен алып карады...

— Шушы ислам җәмәгатеннән,— дип уйлый башлады ул,— берләшкән ислам ясасаң да, бөтен ислам йортын котылдыру өчен сугыш башласаң: Әфган, Мәракеш, Җәзаир... Белуҗстан...

---

[1] Имкян ачылды — мөмкинлек ачылды.

[2] Ихтилал — революция.

Ләкин монда нәрсә сөйлиләр: җир, диләр. Белмим тагын нәрсә сөйлиләр; нигә болар? Белмиләр монда бер кешенең нинди фикерләр белән килгәнен...

Хиффәтҗан абзый түзмәде: рәистән сүз сорады. Күп ораторлар сөйләделәр. Безнең оратор да көтә-көтә ялыгып бетте...

Вак һөнәрмәндләр вәкиле Хиффәтҗан әфәндегә сүз бирелә! дигән тавыш кына аның ачуын бераз бетерде; биноклен сумкасына салды; кулына камчысын тотты; эре-эре чалыш атлап мөнбәргә менде...

Кесәсендә күп казына торгач, бер кәгазь чыгарды; аның нечкә ачы тавышы яңгырый башлады...

III

Мин, укучылар, аның бөтен сүзен монда күчереп тора алмыйм, ләкин аның бөек фикерләренә хөрмәтемне белдереп кенә кайбер сүзләрен язып алдым... Ул шундый сүзләр сөйләде:

Җәмәгате ислам! Мин Әфганда, Мәракештә, Җәзаирдә, Белуҗстанда... үзем булмадым, ләкин безнең мәхәлләбезнең имамы Хиҗазда, Истанбулда булган кеше; ул сугышка кадәр гаять күп гәзитләр укый иде... Яхшы кеше иде. Ислам дөньясы хәзер һәлакәт хәлендә; кайчандыр хәлифәтлек үзәге булган Бәгъдатның диңгезе кырыенда инглиз флутының туплары морҗаларын чекерәйтеп торалар... Әфган, Һинд, Җава, Мисыр, Җәзаир, Мәракеш һәм Белуҗстанда эшләр шундый ук... Безгә шушы хөррият белән файдаланып, ислам гаскәре төзергә кирәк... Әгәр кирәк булса, шул гаскәр илә (шуны да әйтеп узарга кирәк: шул урынга җиткәч, аның куллары йодрыкланды, тешләре ыржайды, тавышы ачыланды, аяклары тибә башлады. Ни өчендер, мин белмим, сөйли торган теле дә госманлылашты[1]) әгәр лазем исә[2], Аурупая барачакбыз: Лундрасын, белмәм дә һанәсен кан эченә батырачакбыз... Яшәсен ислам гаскәре! Моңарчы кирәкмәгән җирләрдә хезмәт итеп йөргән мөселман полковниклары, җәнәраллары, килегез бу байрак астына! — дип, кесәсеннән зур бер яшел материя чыгарып, ике кулы белән ике почмагыннан тотып селки-селки, мөнбәрдән[3] төште... Халык шаккатты...

---

[1] Госманлылашты — төрек телендә сөйли башлады, ди.

[2] Әгәр лазем исә — әгәр кирәк булса.

[3] Мөнбәр — трибуна.

IV

Чыккан вакытта ул, минем яныма килеп:

— Каты әйттемме, Газиз? — диде.

Мин бер җавап та бирмичә бара идем.

— Менә шулай итсәң, милләт тәрәккый итә ул, ул мужикка җир биреп ни чыга? — диде. Без театрның алдына чыктык.

— Минем атны күрмәгәнсең әле син? Менә монда бәйләнеп тора,— диде ул. Ләкин мин ат күрмәдем. Хиффәтҗан абзый күп каранды, анда-монда йөгерде, ләкин ат юк иде. Аңарга бер татар малаеның монда бәйләнгән бер атка атланып киткәнен сөйләделәр.

Шуның соңында минем ораторым тәмам йомшарды, агарды, күгәрде, кулындагы камчысын җиргә ыргытып:

— Менә инде, әфәндем, безнең мөселманның шул инде аның! Йә әйт инде зинһар: болай булгач, ничек итеп бу милләт тәрәккый итсен! Бетәр ул, черер, шуның өчен дә шул Әфган, Җәзаир, Һинд, Мәракеш, Белуҗстан... хәтта Мисыр, Гыйрак вә Шам шул хәлгә төшкәннәр? — диде.

1923 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Бу хикәя дә сатирик хикәяләргә хас булган каршылыкка корылган. Шул каршылыкны күрсәтегез.
2. Каршы якларны тапкач, төп персонажга бәя биреп була. Бәя бирегез.
3. Хикәянең фокус булырлык урынын табыгыз.
4. Оратор күп илләр турында сөйли. Бу илләрне кабатлату авторга нигә кирәк булган?
5. Хикәя героен Г. Газизнең башка хикәяләрендәге геройлары белән чагыштырыгыз. Чагыштыру нәтиҗәсеннән чыгып, әдипнең бу персонажлары белән ни әйтергә ниятләве турында сөйләгез.

СКРИПКАЧЫ ХӨСӘЕН

I

Хөсәен картның яше алтмыштан узса да, йөрәге унсигез яшьтән артык түгел иде. Ул яшьлек белән яшьлекнең мәфтүне[1] иде. Аның тәне дә яшь килеш сакланган: аның төшкән тешләре дә юк, агарып җитә язган чәчләре дә әүвәлге шикелле куе иде. Аның шул башын чуклы кызыл кәләпүш каплап тора, аны да ул кырынрак салып, купшырак итеп кия иде. Кәвешнең дә

---

[1] Мәфтүн — кол, баш июче мәгънәсендә.

шыгырдавыклысын кия, кәзәкиенә дә, үзе бай булмаса да, кызыл мәрҗән төймәләр тагадыр иде.

Хөсәен карт һәрбер язны гаять көтеп, рәхәтләнеп каршы ала, язның һәрбер сулышын, аның һәрбер хәятын күзәтә, шуннан зур ләззәт аладыр иде. Үзенең өч тәрәзәле йорты алдындагы мәңгелек яшел озын чыршыга кунып песнәк сайрый башлауны ул февраль ахырында бер зур сөенеч белән каршы ала; шуннан алып ул талчокка да аз менә башлый, үзенең сатлык иске скрипка, гитара, мандолиналарын да оныта, табигать туе — язны каршылау вә күзәтү белән мәшгуль буладыр иде. Беренче мәртәбә тамчы тама башлау, урамда гөрләвекләр ага башлау, чыпчыкларның чыр-чу килеп гайрәтләнеп йөри башлаулары аңарга бер куаныч бирә; өе алдына чыгып утырып, авылдан килгән мужиклардан:

— Агай-эне, тукта әле, иминчелекме? Кара карга килдеме инде? — дип сорый. Алар «килде» дисә, сыерчык килгәнне көтә башлый, өенең башындагы мәчет итеп ясалган оядан кыш буе гомер иткән чыпчыкны куып чыгарып, сыерчыкка урын әзерли иде.

Каршыларындагы Шәмсетдин бай бакчасына беренче мәртәбә килеп кунып сайрый башлаган сыерчыкны күргәч тә, пычрак булса да, аунамый калмый, безнең ояга кайчан килер икән дип көтәргә тотынадыр иде.

Хөсәен картның кечкенәрәк кенә өенең эче дә бер бакча төсле иде. Анда гөлләр күп була, ике тәрәзәсенә дә эленеп куелган читлекләрдә икс кенәрие дә була; аларны ул бик тәрбия итә, килгән-киткәнгә:

— Менә бусы клакулчек, менә бусы арганщик! — дип, кенәриләрнең үзенчәлекләрен дә сөйләп аладыр иде.

Ул карчыгы белән ятмый, шул кенәриләре, гөлләре, төзәтергә хәзерләнгән яисә сатарга алган музыка кораллары бүлмәсендә йоклый иде, чөнки, аның үзенең тәгъбиренчә, карчыгы Хөсни коры кеше, дәртсез кеше иде. Картының юк-бар нәрсәләр белән маташуын яратмый. Хөсәеннең иртүк торып, тегс кенәриләрне сайрату өчен, чынаяк тәлинкәсенең астын кырганын да сөйми, уятасың дип ачулана, Хөсәеннең «вакытлы-вакытсыз» скрипка белән озын көйләр уйнап җибәргәләвен дә ошатмый иде. Аны күп вакытта:

— Бу шайтан коралын уйнап утырганчы, «Хизбеләгъзам» укысаң, җәннәткә керермен дип курка торгансың! — дип тиргидер иде.

Хөсәен абзый карчыгы белән инде утыз биш ел торса да, аны эченнән яратмый, ләкин аңарга ачуланмый, дошманланмый:

— Үзе егылган еламас! — дип кенә үзен юата иде. Бәгъзе вакытта туйдыргыч шелтәләрдән качып, җәй көннәрендә кармаклар белән скрипкасын алып, безнең шикелле яшьләрне ияртеп, Бакалтайга кунарга китәдер иде.

II

Киң Идел рәхәтләнеп ага; июньнең кызу кояшы да әкрен генә, маңгаен гына күрсәтеп чыгып киләдер иде. Пар күтәрелеп, тирә-якны чолгап алган; болыннан колакны тондырырлык итеп тартар тавышлары ишетеләдер иде. Безнең кармакларның җепләре дә Иделнең агымы белән дер-дер селкенеп торалар, чәйнегебез дә әкрен генә кайный, Хөсәен абзый үзе исә, кармаклары янында хозурланып, дәртләнеп карап, чүгәләп утырадыр иде. Су кайнап чыгып, тамчылары астындагы утка төшеп чыжылдаганны ишеткәч, мин яр өстенә сикереп мендем.

— Хөсәен абзый, чәй салыйммы? — дидем. Хөсәен абзый да, бер кармагын алып, рәтләп салды да әкрен генә минем яныма менде.

Чәй эчәргә утырдык. Хөсәен абзый, торып, тал арасына кереп китеп, бер уч карлыган яфрагы алып килде. Үзенең чикмәнен безнең чәй яныбызга салып куеп, өстенә кырын ятты да:

— Дөнья бик ләззәтле нәрсә ул, улым! Аның бөтен ләззәте, тәме, рәхәте белән файдаланырга кирәк. Ләззәт таба алмасаң, таш арасыннан эзләп табып чыгарырга кирәк, менә булырсың чын кеше! — дип, карлыган яфракларын стаканнарга салды. Бер стакан чәй эчеп алгач, скрипкасын кулына алып, аякларын бөкләп утырып, күзләрен дә яртылаш йомып, бер ят көй уйнады. Миңа бу көй мәгълүм түгел бер аһәң иде; мин Хөсәен абзыйның һаман да татар көйләре уйнаганыннан бары шуларны гына белә дип уйлый идем... Бу көенең йөрәгемә каты бәрелүе, төн буена йокламый уздырганымны оныттырып, йокымны ачып җибәрде. Бу көйдә, чынлап та, бер гаҗәеп сер вә мәгънә бар иде; скрипканың тавышында бер гадәттән тыш дерелдәү, елаумы, сөенүме,— нәрсәдер бар иде... Хөсәен абзыйның төсе дә гадәттән тыш бер кыяфәткә кергән, күзләре яртылаш йомылган, йөзендәге җыерчыклар тагы да арткан төсле иде... Хөсәен абзый бу серле көйне ике мәртәбә кабатлады да, скрипканы куеп, киң Идел буйлатып озак карап торып, бер киң сулады:

— Әй мулла Гомәр, син бу көйнең мәгънәсен белсә идең! — диде. Мин дә сорашырга тотындым.

— Тукта әле, менә шул ясаган стаканымны эчим дә соңыннан сөйләрмен! — диде ул.

Үзе башындагы купшы соры бүреген салып куйды да элек башын кашып алып, соңра тирән уйга чумган кебек, түбән салып торды. Ул арада безнең баш очыбыздан, бик югарыда выжылдап, кычкырып, кыр үрдәкләре үтеп киттеләр... Хөсәен абзый шактый озак утырды... Кинәт башын күтәрде дә сөйләргә кереште.

III

— Мин унсигез яшьләремдә идем. Тәкъдир язгандыр инде, атам үлгәннән соң, фәкыйрьлек тә басып киткәч, кардәшыруларыбызның ай-вайларына карамыйча, Әчтерханга килеп, анда бер әрмән баена яллаңып, кибетендә бер ел хезмәт иткән соңында, аның Кара диңгез буендагы, Кавказ шәһәрендәге кибетенә җибәрелгән идем. Ул шәһәрнең матурлыгы, андагы зәңгәр диңгез, күккә җиткән башлары кар белән өртелгән таулары, андагы күп төрле агачлар, җимешләр әле дә минем күз алдымнан китми. Безнең кибетебезгә бик күп кеше керәдер иде; шәһәр халкының бик күп кешесе миңа таныш булып китте. Көннәрдән бер көн безнең кибетебезгә Алланың бер матур мәхлугы[1] керде. Мин аны күрүем белән, чын җанымнан сөйдем. Зур чем-кара күзләре, озынча борыны, кечкенә авызындагы энҗе күк ак тешләре, бу кызның минем алдымда басып торуы миңа бер картинадагы кыз басып торган күк тоелды. Бу кызны күрү белән, мин аңарга чын хөрмәт багладым. Сез, бу чагындагылар, гыйшыкның нәрсә икәнен белмисез бугай ла! Ул чын сөю бер кәмит нәрсә икән! Ул тиз табыла икән дә, шушы чыгып килә торган кояш шикелле, һич сүнми, йөрәкне ялтырата, яндыра икән... Мин бу кызга җүнләп мал да күрсәтә алмадым, мин аннан әллә нишләп оялдым; ул бер мәртәбә минем кызарган йөземә елмаеп карады да чыгып китте... Валлаһи менә мин, мулла Гомәр, торганмындыр бер сүз дә дәшмичә басып бер сәгать! Соңра мин ул кызны очратмаммы дип, көн саен кибеткә чыгам, аннан кайткач, урамда йөрим... Ләкин мин күп йөрдем, аны очрата алмадым. Көн-төн мин аның хакында уйларга тотындым. Бернәрсә белән дә юанмадым. Матур агач күрсәм, һәйбәт,

[1] Мәхлук — *бу урында:* бәндә.

бүртенгән гөл чәчәге күрсәм, карлы таулардан агып төшкән шарлавыкларны күрсәм, Алланың теге күземнән югалган мәхлугы шундадыр кук тоеладыр иде. Азрак юаныч бирмәсме дип, мин шушы скрипканы уйнарга тотындым; тиз көндә өйрәндем дә. Менә беркөн ерак илем, югалган фәрештәм хакында уйлап, кайгырып, төрле көйләр уйнап утырадыр идем, бер хатынның урамда шушы көйне җырлаганын ишеттем. Менә бу көйне шулчаклы яраттым, шуны уйнаганда теге фәрештәм белән сөйләшәм кук була башлады. Шуның өчен мин бу көйне яратам; ләкин мин аны һаман да уйнамыйм, сахрада, хозурда, күңелсенеп китеп, Алланың мәхлукатының матур җирендә генә уйнарга яратам. Мин аны Хөсни янында да уйнамыйм, чөнки ул юк-бар сүз белән ул көйне мыскыл итүе ихтимал! Ләкин шушы бер минутта сөюем миңа мәңгелек рәхәт бирде... Мин хәзер Аллага шөкерләр кылам: ярый әле мин ул кызны табып, үземнең сөйгәнемне белдереп, аның белән тора башламаганмын...

Мин бу сүзгә гаҗәпләндем:

— Ник? — дип сорадым.

— Ник булсын? Менә каршыңдагы чәчәк нинди матур, нинди сокланырлык! Менә син шуны яратам дип өзеп кара, ул хәзер шиңәр, хәзер корый башлар; аннан син хәзер туясың. Әмма син аны күреп яратып калып, ямьсез кышларда шул чәчәк турысында уйласаң, шул хыял аның чынысыннан да матур тоелмасмы? Шул уй сиңа зур ләззәт бирмәсме?!

Мин Хөсәен абзыйның бу сүзләре турында күп уйладым, ләкин, бу минем табигатемә ят булганга, аңлый алмадым...

Хөсәен абзый яңадан скрипкасын алды, болын яңадан моңлы вә серле музыка авазы белән тулды.

1921 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Хикәяне, үткән заман һәм хәзерге заман вакыйгалары дип, ике өлешкә бүләргә мөмкин. Шул ике вакыйганы сөйләгез, аларга исем бирегез. Бу ике өлешнең һәрберсе үз эченә башка вакыйгаларны сыйдыра. Шуларны санап чыгыгыз.

2. Хикәядәге табигать күренешләренең вазифалары турында сөйләгез.

3. Хөсәен абзыйга бәя бирегез.

4. «Скрипкачы Хөсәен» хикәясен сатирик хикәя дип уйласак, аның төзелешен ничек күз алдына китерер идегез?

5. «Скрипкачы Хөсәен» хикәясен мәхәббәт матурлыгы турындагы хикәя дип уйласак, әсәргә анализны ничек ясар идек?

6. Хөсәен абзый Газиз Гобәйдуллинның башка хикәяләрендәге типларга охшаганмы?

«Форточкалы кәләпүш» хикәясенә анализ

Бу кыска гына хикәянең сөйләрлек сюжеты да юк диярлек. Аны укып чыккач, эч катып көлмәгән кебек, күз яше белән еламыйсың да. «Әсәрнең эчтәлеге нәрсә турында?» дигән сорауга теләсә кем: «Бер тиленең буш хыяллары турында»,— дия ала.

Ләкин Газиз Гобәйдуллин кебек фикерле әдип ниндидер бер ахмак турында хикәя язып вакытын әрәм итәр идеме икән?

Әсәргә анализ ясыйк.

Сәмигулла карт, чыннан да, тузга язмаган нәрсә уйлап чыгара: татар кәләпүшенә вентилятор куймакчы була (ул вентиляторны «фурточка» ди). Кәләпүш тишекләренә әле вентилятор куелмаган, ләкин бу ниятен карт күкләргә чөеп мактый. Шул ачышы аркасында үзен бөтен халыкка билгеле бер адәм итеп күз алдына китерә.

Әсәр шул рәвешле сезгә яхшы таныш каршы якларга — персонажның ахмаклыгына һәм акыллы булып күренүенә бүленә.

Анализны дәвам итәбез: өлешләрне аерым-аерым өйрәнәбез. Беренче өлешне Сәмигулланың ахмак фикере дидек. Кәләпүш тишекләренә вентилятор кую уе үзе генә дә ахмаклыкның бик югары дәрәҗәсе дип бәяләнә ала. Ләкин автор аның белән генә дә чикләнми, героеның ахмаклык дәрәҗәсен арттыручы башка вакыйгалар да өсти.

1. Кәләпүш вентиляторын Сәмигулла конфет тартмасыннан ясамакчы була.

2. Вентилятор куелгач, кәләпүш сандугач кебек сайрап торачак.

3. Баш исе беткәч, сайрау туктый, ягъни «фурточка» автоматлашкан. Икенче өлешне Сәмигулланың дәгъвасы дидек.

Үз чиратында бу өлеш тә берничә дәгъвадан гыйбарәт:

1. Сәмигулла башына килгән фикернең кыйммәте шулкадәр зур, аны хәтта кияве дә белмәскә тиеш.

2. Сәмигулла үзенең ачышын япониар ачышы дәрәҗәсенә тиңләштерә.

3. Вентилятор милләтнең баш авыртуын бетерәчәк.

4. Аның белән һәммә кеше кызыксыначак, сораучылар күп булачак.

5. Бу ачыш Сәмигуллага дан китерәчәк.

Ике өлеш турында белгәннәрне гомумиләштереп, түбәндәге нәтиҗәгә киләбез:

Автор Сәмигулланың ахмаклыгын да, данга дәгъвасын да арттырганнан-арттыра бара. Арттыру юлы белән Газиз Гобәйдуллин кәләпүшче Сәмигуллага үз бәясен бирә һәм андый кешеләрнең күплеген күрсәтә. Хикәясендә, кәләпүш түбәсенә тишекләр ясап, милләтне коткарган Лотфулла турында әйтә. «Сиңа сөенеч — миңа да сөенеч» дип, ире шатлыгын уртаклашучы Миңлебикә абыстай турында сөйли. Кәләпүш форточкасын милләт язмышы белән бәйләп, укучыны уйланырга мәҗбүр итә.

Анализ ахырында хикәя өлешләренең үзара бәйләнешләрен эзлибез. Эзләнүнең бер юнәлеше мондый:

Г. Гобәйдуллин кыска гына хикәясендә дә татар башын дәвалау турында ике мәртәбә яза. Чирнең сәбәбе дә аңлашыла: кәләпүшкә капланып яшәүдә.

Уй шул урынга җитүгә, кәләпүш образы кинәт җанлана башлый. Автор эчен бушатырга тырыша, көлке астына поскан эчтәлекләрен ачарга керешә. Абайлап алабыз: кәләпүш татарның милли артталыгын алыштырып килүче билге түгелме соң, инде безгә таныш символ түгелме? Шундый фикергә килгәч, кәләпүш очындагы тишекләр дә, аларга сайрый торган форточка кую хыяллары да бөтенләй башка мәгънә алалар.

Татар милләтенең артталыгы — менә нәрсә борчый икән авторны. Бу артталыктан ничек чыгарга соң? Газиз Гобәйдуллин үзе әлеге сорауга җавап бирми. Ләкин хикәясендә ул шул юлны тапкан һәм тормышка ашыра башлаган кешеләр турында яза. Алар үзләрен милләтне коткаручылар дип исәплиләр. Лотфуллалар, Сәмигуллалар милләт башын тазарту юлларын табалар, ә татар табиблары һәм коймак пешерүчеләр аларны хуплап торалар.

Анализ нәтиҗәсендә без шундый фикергә киләбез. Газиз Гобәйдуллин кечкенә генә хикәясендә бик зур тема күтәргән, бөтен бер милләт язмышы турында язган, дибез. Алай да күңелдә шик бар әле. Бәлки, безнең фикер — хикәянең потенциаль (өстәмә) эчтәлеге генәдер? Шикне тарату өчен, язучының башка хикәяләренә анализ ясыйбыз.

«Бу милләт ничек тәрәккый итсен?», «Скрипкачы Хөсәен» хикәяләрендә дә Сәмигуллага охшаган типлар сурәтләнүен күреп алабыз. Алай гына да түгел, кәләпүш символының эчтәлеген башка бер хикәясендә «Милләт ничек алга китсен» дип, күз алдында торган темасын (объект темасын) үзе үк әйтеп бирә.

Исегездә калдырыгыз.

Үсешенең бер мәлендә җәмгыять кешеләрне яңача яшәргә һәм яңача уйларга кыстый башлый. Искечә яшәргә мөмкин булмавын күрсәтә. Әмма бу үсеш юлына кешеләрнең аңына һәм күңеленә кереп урнашкан, күптән инстинктка әйләнгән стандарт гадәтләр киртә булып ята. Бу гадәтләргә каршы көрәшү чиктән тыш авыр.

Кешеләр күңелендә күп еллар дәвамында урнашкан гадәтләргә и җ т и м а г ы й а ң диләр.

Иҗтимагый аң кешеләрне үзара килештерә, тату яшәтә. Моның өчен кешеләр үзләренең теләкләрен бик нык чикләргә тиеш булалар. Берәүнең теләге башкаларга зыян китерә башлау белән, иҗтимагый аң шунда ук башын калкыта һәм әлеге урнашкан тәртипләргә каршы чыгучыга чара күрә башлый. Кешеләр аңа үзләренең ризасызлыкларын, нәфрәтләрен белдерәләр, аны хәтта үз араларыннан да куа алалар.

Яңалыкка каршы чыккан иске гадәтләргә к о н с е р в а т и з м диләр.

Кешеләр үзләренең иҗтимагый аңнарын үзгәртә алмасалар, милләт үсешен тоткарлыйлар дип нәтиҗә ясыйк.

Татар әдәбияты үсешенең һәр чорында, урынсызга мактану гадәтенә каршы көрәшеп килде. Исегезгә төшерегез: Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимовлар буш кешеләрнең дәрәҗәгә омтылуына каршы дәррәү күтәрелделәр. Бу сыйфатның әкренләп гадәткә әйләнеп баруына алар чын күңелдән борчылдылар.

Революциядән соң дөньялар үзгәрде. Яңа система үзен саклап калу өчен яманны да яхшы итеп күрсәтергә кереште. Җитәкчеләр яңалыкны мактап, үзләрен мактадылар. Мактану татарлар арасына да килеп керде. Аннан башка да төтенләп торган учак дөрләп яна башлады. Мактану гадәткә әйләнеп, иҗтимагый аңга әйләнә.

Кешеләрнең бу начар гадәте милләт өчен ни дәрәҗәдә куркыныч булуын Газиз Гобәйдуллин Сәмигулла, Лотфулла, Миңлебикә, Хиффәтҗан образлары аша кисәтә.

Фатих Әмирханның Сәмигулла абзыйсы әле чәй-шикәр белән генә шашкан булса, Газиз Гобәйдуллин Сәмигулласы сәясәт югарылыгына менеп шаша. Ф. Әмирхан персонажының исемен Г. Гобәйдуллин ике чор кешесен чагыштыру өчен файдаланган дисәк, мөгаен, ялгышмабыз.

Мирсәй Әмир
(1907—1980)

ХИКМӘТУЛЛИННЫҢ МАНЕВРДА КҮРГӘННӘРЕ

Хәйлә барып чыкмады

Маневр турында мин былтырдан бирле ишетеп киләм. Шундый куркыныч булып килә ул минем күз алдыма —анда барсаң, бөтенләй башың югалып калыр, йә булмаса йөрәк майларың суырылып бетәр дә коры сөякләрең генә әйләнеп кайтыр кебек тоела иде.

Маневрга ике көн калды. Бөтен полк маневрга хәзерләнә башлады. Инде ни эшләргә? Баш китә бит мин әйтәм. Уйлыйм. Аяк терәп уйлый торгач, хәйләсен таптым.

Икенче көнне иртә белән торыр вакыт җитте. Борып-борып сигнал уйный. Мин йоклаган булып кына тыңлап ятам. Янымдагы иптәшләрем һәммәсе сикерешеп тордылар. Мин ятам әле. Башта план зур...

Берзаман тышта «становись» командасы булды. Шуннан соң гына артык соңга калмыйм тагы дип тордым. Киенгән булдым: гимнастеркамның төймәләрен эләктермәдем, обмотканың очын бәйләмәдем, каешның пряжкасын уң яктан алып, кабырга өстенә китереп эләктердем дә очын салындырып җибәрдем. Фуражканы бөтенләй кимәдем. Шушындый карга куркытырга куйган карачкы кыяфәтем белән, җан-фәрман ашыккан булып, строй алдына бардым. Барсам, командир килгән.

«Бигрәк тә шәп, мин әйтәм, эчтән генә, бу миңа нарядны бирә дә бирә инде, мин наряд алып, маневрга бармыйча, кухняда бәрәңге әрчеп калам», дим. Җәлт-җәлт килеп, командир алдына килеп бастым да яланбашка под козырек алдым:

— Иптәш командир, разрешите,— мин әйтәм,— стройга басарга!

Бөтен строй пырх итеп көлеп җибәрде.

Командир мине баштанаяк карап чыкты да:

— Иптәш Хикмәтуллин, сез сбордан өч көнгә калырсыз,— диде.

Өстемә салкын су койган кебек булды. Берни әйтә алмадым. Менә сиңа наряд!.. Менә сиңа кухня!..

Димәк, тәки котылып булмады.

Кәлимуллин белән ярыш ачтык

Мин «зәңгәрләр» отрядына эләктем. Берзаман бөтенләй тезелеп беттек. Кәлимуллин килде дә җиңемнән тартты:

— Хикмәтуллин, давай синең белән ярышабыз! Күрсәтик батырлыкны,— ди.

Кәлимуллин бәйләнсә, аңардан котылып булмый инде. Шундый тынгысыз кеше ул. Ничек күңеле төшә, ничек иренми, ничек өлгерә: сөйләмәгән сүзе, җитмәгән җире, эшләмәгән эше юк. Һичвакытта зарланмас, һичвакытта кайгырмас — гел веселый. Әллә нинди — саескан күкәе ашаган гамьсез нәрсә.

Менә шул кешегә килеп каптым бит, җәфа. Риза булмасам да куркам. Әллә нинди исемнәр тагып бетерер. Әллә ниләр кыландырып газетага төшереп куяр. Бәласеннән башаяк. «Ничек булса да түзәрмен әле. Газиз җаным исән-сау өстерәлеп кайтса, шул җитәр», дидем дә риза булдым. Кәлимуллин белән ярыш ачтык.

Арымаска. Аякны кырдырмаска. Өч көнгә биргән икмәк запасын вакытыннан элек бетермәскә. Командирлар тарафыннан бертөрле дә дисциплина җәзасы алмаска...

Җыеп кына әйткәндә, башка бәла алдым диген дә бетер инде.

Кайчан гына барып җитәрбез

Ярый. Берзаман чыгып киттек. Тып-тып басып барабыз. Шулай күңелле генә барганда, арттан үкчәгә баса башладылар. Баса да баса. Чыдамадым, борылып карадым: Кәлимуллин үзе.

— Што син,— мин әйтәм,— күзең чыкмагандыр бит, үкчәгә басмасаң!

— Аягыңны алыштыр,— ди бу миңа.

— Сиңа алыштырырга булмыймыни? — мин әйтәм.

— Мин колонна уңаена барам,— ди.

Бар, аның белән сөйләш. Тәки үз сүзен сүз итә. Һаман үкчәгә баса. Минем ачу кабара башлады. Борылып салып җибәрер дәрәҗәгә җиттем:

— Үкчәгә басуыңны ташлыйсыңмы, юкмы? — дип кычкырдым. Тавышымны командир ишетеп алды:

— Анда нинди тавыш? Стройда кычкырышмаска! — диде.

Үзе команда бирә башлады:

— Раз, два, три...

Анысы да Кәлимуллин яклы булып чыкты. Тыпыр-тыпыр биеп, көчкә аякны алыштырдым. Шуннан бераз җиңеләеп китте. Шулай да ачу басылмаган. Кайчан гына барып җитәрбез...

Капчыкта икмәк кычкырып тора

Бер авылга җитәрәк ял итәргә туктаттылар.

— Егерме биш километр килдек,— диделәр.

— Какой егерме биш! Миңа илледән артык тоелды. Уң аякның үкчәсе, сул аякның баш бармагы кабарып чыкты. Эчтә этләр өрә. Җитмәсә шунда, ачу китереп, гармун уйнарга, биергә тотындылар. Такмак әйтәләр. Маегызга чыдый алмыйсыз икән, мин әйтәм, эчтән генә. Үзем кешегә күрсәтми генә капчыкны казыйм. Капчыкта икмәк.

Кәлимуллин да чулт... мин дә чулт...

Елга аркылы саперлар күпер әмәлләделәр. Алдагы рәтләр экрен генә чыга башлаганда, караңгы төшкән иде инде. Әле күпердән чыгарга безгә чират җитмәгән. Әллә никадәр ял итеп алырга була... Читкәрәк киттем дә һәйбәтләп кенә, шинельнең чабуларын бот арасына кыстырып, бөгәрләнеп яттым...

Берзаман чабуымны тартканга уянып китсәм, ни күрим: каршымда Кәлимуллиннан башка бер кеше юк. Безнең бөтен отряд чыгып киткән. Мин берүзем читтә йоклап калганмын. Мине эзләргә Кәлимуллинны җибәргәннәр. Йөгерәбез икәүләп күпергә. Басмага барып җиттек. Суны күрүгә, тәннәр чиркана. Шулкадәр туңдырган.

— Минем арттан селкенмичә генә бар,— диде дә Кәлимуллин күпергә кереп китте. Мин аның артыннан... Күпер дигәннәренең күпер димәсәң хәтере калыр, су өстенә резинка мендәр тезеп чыкканнар, бәлтерәп кенә тора. Куркыныч. Атлап та булмый. Ни булса булыр дип, Кәлимуллин артыннан йөгерә башлаган идем, күпер янтайды да китте.

Кәлимуллин да чулт!

Мин дә чулт!

Гомердә сүгенми торган Кәлимуллинның: «Батырдың, сукин сын!» дип кычкырган тавышы гына колак төбендә тора. Отделком[1] үзе килеп чыкты. Үзе тирги, үзе өйрәтә:

— Өйрәткән вакытта колак салмыйсың, гел хатыныңны гына уйлап йөрисең, бөтен рота битенә кара ягасың. Менә шулай әкрен генә, туры гына, чайкалмыйча гына бас,— ди. Шулай сөйләндерә-сөйләндерә мине басмага алып кереп китте.

Басмадан чыга-чыга өйрәнеп киттем тагы.

Чыгып җиттек. Бу Кәлимуллинның холкына искитәрлек. Көлә-көлә яныма килде дә:

— Әйдә, хәзер синең белән йөгерешергә ярыш ачабыз,— ди. Югыйсә син дә туңасың, мин дә,— ди.

Тотындык үзе белән йөгерешергә.

Отряд бара стройда. Без йөгерешәбез.

Мич башында

Куна торган авылга җиде төн уртасында гына барып җиттек. Әле дә яхшы, алдан фатир хәзерләп куйганнар икән. Килү белән кердек. Шинельне аска җәйдем дә яттым. Бүтәннәр котелок белән аш алырга чыгып киттеләр. Мин барып йөрмим инде. Туңып үләр хәлем юк, мин әйтәм. Икмәк җитәр әле. Ачу белән икмәкне каерып алдым. Ашый-ашый йоклап китканмен.

Койрыклы бомба

Юньләп йокыга да китмәгән кебек идем әле, уята да башладылар. Күзләрне уа-уа тордым. Чалбарларны, чолгауларны тотып карасам — юпь-юеш. Мин аны, мич башы булгач, җылыдыр дип белгән идем. Мылтыгымны өстерәп төшерсәм, ни күрим... Мылтыгым кып-кызыл «чәчәк аткан»! Кызу-кызу гына сөртеп алдым. Эчен-тышын лачкылдатып майладым да йөгереп урамга чыктым.

Безнекеләр урам уртасына җыелган. Командир бүген булачак «сугыш» турында төшендерә. Ә Кәлимуллин шунда җентекләп-җентекләп сораша. Ничек иренми бу ата куян...

Ул арада кемдер әче тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Самолет!

Әллә кайсы миңа кычкыра:

— Кач! — ди.— Аэроплан хәзер бомба ташлый!

---

[1] Отделком — отделение командиры.

Аптырагач урам уртасына сузылдым да яттым. Ни күрим: бер койрыклы бомба туп-туры миңа карап төшеп килә. Тордым да бер якка йөгердем. Койрыклы бомба мин яткан җиргә якын гына килеп төште.

Бомба дигәнем каршы якның кайда ятуын белдергән хәбәр булган икән.

Инде тынычландым гына дигәндә, взвод командиры яныма килде. Мылтыгымны алды. «Чәчәк аткан» җирләрен төртеп-төртеп күрсәтте:

— 65 нче приказны бозган өчен, сиңа бер сутка арест,— диде. Ул арест сбордан тыш кала торган теге өч көн исәбенә керә микән, юк микән?

Команда да команда, өлгерер хәл юк

Бер урыннан бер урынга ашыгып күчә-күчә, урман арасында күренгән авылга карап юнәлдек.

Бервакытны, «дошман» шактый якын калды инде дигәч, безне яткан урыннан кузгатмый башладылар. Командир, җирне казып, чокырга төшеп ятарга кушты. Югыйсә «дошман»га күренәбез, атып үтерә, ди. Ә мин «дошман»ның кәгазь пуля белән атканлыгын сизеп алдым. Алдама, мин әйтәм эчемнән генә. Кәгазь белән атып үтерми торсыннар, дим.

Ашамыйча түзәр хәл юк. Үзем чеметеп-чеметеп кенә кабам, үзем ялт-йолт тирә-якка каранам. Иптәшләрем бар да, җирне казып, чокырга төшеп ятканнар. Бер мин утын кебек калкып ятам, күрәсең.

Менә шул көрәкне тартып чыгару минем иң яратмаган эшем инде. Җитмәсә мин аны, төшеп-нитеп калса бәласе булыр дип, ныгытып бәйләп бетергән идем. Хәзер менә чишеп ал! Инде казый башладым дигәндә генә, тагы алга барырга команда. Көрәкне тыгып өлгерер хәл юк.

Аяк өсте үлдем

«Дошман» белән ике ара якынайды. Шатыр-шотыр атышларның исәбе юк. Бервакыт «дошман» ягыннан үкереп танклар килә. Командир батыр булырга кушты, дим, эчемнән генә уйланам. Әллә, мин әйтәм, бер батырлык күрсәтеп, бөтен отрядны шаккатырыйммы дим. Гайрәтем тәнемә сыймый башлады. Куян җитезлеге белән сикереп тордым, мылтыгымны күтәреп, дошман ягына ташландым. Үзем йөгерәм, үзем мылтык төзим. Күп тә

китә алмадым, атка атланган ак җиңле бер посредник[1] килде дә тотты:

— Иптәш, сез үлдегез,— диде. Башымнан фуражкамны алып ташлады.

Аптырадым да киттем. Менә сиңа ишетмәсәң ишет. Ничек итеп мин теп-тере килеш үлеп ятыйм?

— Юк,— мин әйтәм,— иптәш командирның рөхсәтеннән башка үләр хәлем юк.

Посредник минем исем, фамилиямне, кайсы бүлектән икәнемне сорашып язып алды да егылырга кушып китте.

Сузылып яттым. Ятам. Үзем бер җирдә, фуражкам икенче җирдә.

Шуның белән минем өчен сугыш бетте. Артта кешедән качып кына утырдым да тынычланып кына икмәкне ашап бетердем.

Кызлар нигә көлә

Мин авылга барып кергәндә, отряд күптән өйләргә таралган иде инде.

Урам авызына барып керү белән, күзем кызларга төште. Сынатмаска кирәк. Гәүдәне бераз турылаттым. Чатанлыкны да сиздермәскә тырышыбрак баса башладым. Кызлар йотылып-йотылып миңа карый. Миңа караган берсе чырык-чырык көлә. Мин аның саен кәпрәям.

Сораша-сораша үзебезнең рота урнашкан җирне таптым. Безнең отделение урнашкан йортның почмагына халык җыелган. Шунда кызылармеецлар да, авыл картлары да, карчыклары да, кызлары да калмаган. Бары да кычкырып-кычкырып көләләр. Мин дә көлә-көлә араларына кердем. Керсәм, күз алдымда безнең ротаның «Ильичевка»сы. Якынрак барып карасам, адәм мәсхәрәсе итеп төшерелгән бер рәсем. Йөзенә караган кеше кычкырып көлмичә китми. Шул рәсемнең астына: «Хикмәтуллин иптәшнең походтагы кыяфәте»,— дип язганнар, имеш.

Тәннәрем эсселе-суыклы булып китте. Шул, Кәлимуллин эше. Башка кеше алай эшли алмас.

Әйтәм, миңа урамдагы бөтен кыз карый. Әйтәм, карыйлар да көләләр.

---

[1] Посредник — «сугыш»ка бәя бирен, арадашлык итүче.

Котыла алмассың бу Кәлимуллиннан

Почмактан тизрәк сыздым. Өйгә кердем. Анда иптәшләр миңа аш калдырганнар икән. Аш белән ашарга икмәк кирәк. Икмәксез генә ашый башладым.

Мин ашыйм, өй хуҗасы әби миннән сораша:

— Син нишләп соңга калдың, улым? — ди.

— Аягым бозылды шул, әби,— мин әйтәм.

— Чолгавыңны яхшырак урарга кирәк иде, балам,— ди.

— Икмәкне дә төшереп калдырганмын җитмәсә. Менә ашымны да икмәксез ашап утырам,— дидем.

Әби тагын да йомшарды. Бүлмәсенә кереп, миңа икмәк алып чыкты. Әй шулвакыт мин эчтән генә көләм, рәте табыла бит, мин әйтәм, адәм баласы аптырамый.

Әби миңа икмәк биреп торганда гына, Кәлимуллин килеп керде. Кабереңдә дә котыла алмассың бу Кәлимуллиннан. Әбинең икмәк биргәнен күреп калуы булды, бәйләнә дә башлады:

— Их, Хикмәтуллин, ничек син оялмыйсың, кая синең үз икмәгең? — ди.

— Судан чыкканда төшеп калган,— дидем.

Икмәк исе

Озакламый безне төнге оборонага алып китәләр. Бераз черем итеп алырга кирәк дидем дә мин фатирга кереп яттым. Ә капчыклар бары да бер почмакка өелгән. Шул капчыкларны күргәч, тынычлыгым югалды бит. Кешегә сиздермичә генә икмәк урларга чамалыйм. Шулай итмичә булмый. Югыйсә үземнең икмәк беткән. Зур саклык белән эшкә башладым. Бер капчык эчендәге икмәк күз ачып йомганчы икенче капчык эченә күчте. Икмәкле капчыкны баш астына куйдым да йокыга киттем... дигәндә генә уята да башладылар...

— Тиз бул, оборонага китәбез,— диләр. Көн җитмәде микәнни соң бу командирларга, төнлә өстерәп йөртмәсәләр, дим.

Әй Хикмәт, Хикмәт, хур булдың син, малай...

Бераз барганнан соң, безне юлдан читкә алып чыктылар. Урман арасына таралдык. Ятабыз. «Дошман ерак түгел, ди... Командир безгә яткан урыннарыбызны казырга кушты. Мин, бер төпсә кырыннан ышык кына, аулак урын табып, тик ята идем инде... Салкын. Күңелсез. Уңда да урман. Сулда да урман. Артта да урман.

Их, бу урманны төн буе кисеп, иртә белән өйгә утын ташырга, мин әйтәм... Берзаман утыннан кайтып керәсең. Гыйззелбанат каршы чыккан була. Өйгә керүгә, әни кап-кайнар итеп бәрәңге пешергән, самовар куйган... Их, аннан соң...

...Аннан соң... төп-төз булып үскән яшь имәннәрне кисә башладым...

Уянсам, ни күрим: күз алдымда кулына кечкенә дәфтәр белән каләм тоткан берәү утыра. Үзе бер кулы белән җиңемнән тарта:

— Иптәш, тор әле, тор. Синең фамилияң ничек, син кайсы ротадан? — ди. Ул китүгә, яныма Кәлимуллин килеп җитте:

— Әй Хикмәт, Хикмәт, хур булдың син, малай. Теге егет — полк газетасының военкоры,— ди.

Аптыраш

Яңадан күзне йокы алмады. Арт яктан сызылып таң ата башлады. Безнең алга чаба-чаба әлсерәп беткән бер эт килеп чыкты. Этнең муенында, үзенә күрә, портфель кебек әйбере бар. Шул портфель кебегеннән бер төргәк газета алып калдылар. Иптәшләр шыпырт-шыпырт кына газета укый башладылар.

Ул арада булмады яныма, газета тотып, Кәлимуллин килеп җитте.

— Газетада нәрсә язганнар, беләсеңме? Тыңла...

Минем турыда язганнар икән. Әйтмәгәнне калдырмаганнар.

Кәлимулин пышылдап кына укып бетерде дә:

— Ишеттеңме? — диде.

— Ишеттем,— мин әйтәм, ну бит, булдыра алмагач, нишлим инде мин. Аягымны юри кабартмыйм, аяк үзе кабара. Командирлардан җәзаны сорап алмыйм, үзләре бирәләр,— дидем.

Кәлимуллин миңа сөйләп бетерергә ирек бирмәде:

— Минем дә синнән артык җирем юк — бер дә наряд бирмиләр үземә. Син сәламәт кеше була торып, сугыш тәртипләренә өйрәнә алмыйм дисең икән, мин аңа ышанмыйм.

— Тукта әле,— мин әйтәм,— Кәлимуллин, син ялгышасың!

Кәлимуллин тыңлап та тормады:

— Мин синең сүзләреңә ышанмыйм инде, эшләп күрсәт,— диде. Үзе янымнан китеп тә барды... Мин тагы аптырашта калдым.

Җылы сүз

Тагын да бераз яктыра төшкәч, урман өстендә аэроплан күренде. Шунда ук команда тавышы ишетелде:

— Самолет!..

Бу команда миңа бик куркыныч тоелды. Әгәр дә самолет күреп калса, бу тискәрелекләрем өчен чын-чыннан бомба ташласа да хәләл, дидем эчтән генә, бөтен кешедән ныграк ашыктым. Күз ачып йомганчы агачлар арасына кереп, куе яфракларга чумдым. Отделком мине карап торган икән.

— Молодец, һәрвакыт менә шулай кирәк,— диде отделком.

Берьюлы күтәрелеп киттем. Миңа мондый җылы сүзләрне бик сирәк ишетергә туры килә. Бәхет бит бу — чиксез зур бәхет!..

Газ!

Безнең алдагы киң генә ачыклыкның аръягында мылтык тавышлары ишетелә башлады. Кинәт куркыныч команда булды:

— Газ! Газ!

Мин инде һәрбер команданы бик тиз җиренә җиткерергә үземә-үзем сүз биреп куйган идем. «Газ» командасы булу белән противогазыма ябыштым. Күз ачып йомганчы киеп тә куйдым. Инде тагы берәр мактау сүзе ишетим дип, командир иптәшкә борылмакчы идем, противогазым ертык булып чыкты, авыз-борыннарым бөтенләй ачык һавага чыгып торалар. Анысы ничего, маневрда чын газ җибәрмиләр, тик юкны гына әйтәләр. Шуннан инде газ бар дип уйлап, противогаз киясең. Ертык булды ни, булмады ни,— барыбер... Шундый уйлар белән тыныч кына алдымдагы ачыклыкка карасам, ни күрим: болыт шикелле, җиргә ишелеп, газ килә. Тирә-ягымдагы иптәшләргә карадым. Барысы да ныклап противогазларын кигәннәр. Еш-еш кына мылтык аткалап яталар. Минем аның саен кот оча. Ул арада булмый, газ өстебезгә үк килеп җитте. Мин нишләргә белмәгәч, җиргә капландым. Борыныма төчкелтем бер ис керде. Харап булдым, мин әйтәм, баш бетте. Сикереп тордым да командир янына йөгердем:

— Коткарыгыз, иптәшләр, харап булдым, противогазым ертык. Буылам.

Ул арада җиңенә ак бәйләгән бер посредник килеп чыкты.

— Иптәш кызылармеец, сез үлдегез,— ди. Битенә карадым. Противогазы юк. Минем эчкә җылы кереп китте. Әһә, мин әйтәм, чын газ түгел икән. Ә «үләргә» мин өйрәнгән инде. Егылдым.

Ул арада яныма отделком килеп җитте:

— Лагерьда вакытта мин сезгә противогазларыгыз ертык булса әйтегез, алыштырырбыз дип әйтмәдемме? — ди.

— Әйттең, иптәш командир. Мин бу хәл килеп чыгар дип белмәдем.

— Командир сүзен тыңламаган өчен, сиңа бер наряд, маневрдан кайткач үтәрсең. Кайда икәнеңне онытма, егет!

Бөтен шатлыкларым берьюлы очты. Нигә исән калганыма үкенә башладым. Инде кеше булып китимме дип кенә торганда... Тагын бер наряд...

Мине артка чыгардылар. Мин «үлек». Тере килеш үлек. Бигрәк хурлык бит. Тагын нәрсәләр дип газетага язарлар икән инде.

Минем кай җирем кешедән ким?

Көн урталары җиткәндә без «К» авылына киттек.

Бу юлы мин колоннадан калышмадым. Аякның кабарган җирләре дә бик бирешмәде. Врачларның даруы килеште, ахры. Исән-сау авылга килеп җиттек.

Отделком шаярта:

— Безнең Хикмәтуллинга газ килеште, ахры, колоннадан бер тешләм калышмады,— ди. Көлә.

Сүз арасына Кәлимуллин да килеп кушылды:

— Без Хикмәтуллин белән ярышабыз бит, иптәш командир. Хикмәтуллин хәзер күңел бирә башлады,— диде.

Минем турыда сүз чыккач, бөтен кызылармеецлар көлделәр. Имеш, Хикмәтуллин сызгыра-сызгыра йоклап яткан... Имеш, командир иптәш рөхсәтеннән башка Хикмәтуллинның үләсе килми. Имеш, Хикмәтуллин судан чыкканда бер аягын чишенеп, ботинкасын югары күтәреп, икенче аягын киенеп чыккан.

Боларны ишетеп торудан да туйдым. Минем өстән көлмәгән кеше юк. Мин мондый хәлне күтәрә алмадым. Минем кешедән кай җирем ким соң? Башымны югары күтәрдем дә взвод командиры янына килдем.

— Иптәш командир,— мин әйтәм,— миннән көләләр.

— Көләрләр шул, кем гаепле? Үзең ич, бары да дөрес сөйлиләр.

— Үзем гаепле, иптәш командир!

— Нигә үзең гаепле икәнне белә торып, үзеңне әзрәк төзәтмисең?

— Анысына да үзем гаепле, иптәш командир,—дидем. Авыр булса булды, оят кебек тоелса тоелды, тоттым да төзәлергә сүз бирдем. Кешедән кай җирем ким минем!

Командир шуны гына көткән кебек, эләктереп тә алды.

— Иптәшләр,— диде,— менә безнең рота күләмендә яман аты чыккан Хикмәтуллин үзен үзе кулга алырга сүз бирә — аны тикшереп торыгыз... Шул сүзен эштә күрсәтсен, ярдәм итегез.

Кеше рәтенә керәм дигәндә генә

Мин, Кәлимуллин, тагын өч кызылармеец — барыбыз биш кеше бергәләп фатирга кердек. Көне буе сугышта йөреп ачыгылган. Безгә чәй эчеп алырга кирәк.

Өстәл янына тезелешеп, капчыкларны чишә генә башлаган идек, Исламов дигән бер иптәшебез сикереп урыныннан торды. Исламов Кәлимуллинга карады да тыныч кына тавыш белән сүз башлады:

— Кәлимуллин, минем капчыктан икмәкне урлаганнар.

Кәлимуллин кинәт миңа борылды. Ә минем кулда икмәк.

— Хикмәтуллин, синең кичә икмәгең беткән иде бит, кайдан алдың? — ди миңа.

Йөрәгем жу итеп китте. Тотылам бит инде, мин әйтәм. Шулай да урладым дип әйтеп булмый, ни эшләргә — хәйләсез дөнья файдасыз — тоттым да ялганладым:

— Син күрдең бит, миңа «Ш» авылында теге карчык бирде.

Кәлимуллин ышанмаган кыяфәт белән икмәкне кулымнан алды. Үз икмәге белән чагыштырып карады да Исламовка сузды.

— Исламов, мә, бу икмәк минеке белән бертуган, синеке булырга тиеш, ә карчыкның икмәге мондый түгел иде,— диде. Аннан соң миңа борылды:

— Их син, Хикмәтуллин, инде караклыкка тотынгансың, оятсыз, җитмәсә төзәләм дигән буласың. Төзәлмисең син!..

— Актыккысы булыр, Кәлимуллин, аны бит мин кичә, несознательный чагымда алган идем. Бүген төзәлдем инде.

— Кичә алгансың, ә бүген карчык бирде дип алдалыйсың...

Их, харап булдым... Сүз таба алмыйм... Инде төзәләм, кеше рәтенә керәм дип кенә торганда, харап итте бу икмәк! Исламов та җебегән инде, шул икмәген җыебрак йөргән булса, алмаган булыр идем. Бәласе булмас иде...

Аштан соң мин, кайгы болытына уралган килеш, урамга чыктым.

Шикле кеше

Мин кайтып кергәндә, фатирда безнекеләрдән берәү дә юк, тик сары тун кигән бер яшь кенә усал күзле рус егете хозяйкалар белән сөйләшеп утыра иде.

— Што,— мин әйтәм,— молодой хозяин штоли?..

Ул үзенең хуҗа түгеллеген белгертте. Болай, так себя, күршегә кердем, ди. Шуннан соң ул миннән Кызыл Армия турында сорашты. Хәзер солдатларны әүвәлгедән хуже кысалар, ди. Ә крестьянга еще хуже, ди. Яманлый.

— Да,— дигән булам теге егеткә, бик шәп түгел. Ну бит,— мин әйтәм,— менә шулай, шулай, дим, комиссар сөйләгәннәрне сөйлим тегенәргә.

— Как хуш,— ди теге. Шикле кешегә охшый.

Шуннан соң без сөйләшмәдек. Мин әлеге дә баягы мәхәббәтле хозяйкадан ятарга урын сорадым. Ул миңа идәнгә урын күрсәтте. Астыма бер иске тун җәйде. Мин битем белән кровать астына борылып яттым. Кровать астында күзем киндергә төште. Зур бер сандык, сандык өстендә зур төргәк өр-яңа киндер.

Эшләр ярыйсы бара әле

Каты итеп җиңемнән тарттылар. Сикереп тордым. Кәлимуллин булып чыкты.

— Әйдә,— ди, Кәлимуллин әйтә,— бөтен кызылармеецлар чыгып беткәннәр инде, тизрәк!

Мин күз иярмәслек җитезлек белән ашыгып киенә башладым. Бүген калышмыйм әле, Кәлимуллин да әйтеп куя:

— Молодец, Хикмәтуллин, алга барасың,— ди.

Без урамга чыкканда, безнең рота җыелып беткән иде инде. Кушылдык. Командирлар сөйли башладылар.

— Безнең бурыч — «дошманны» артыбыздан җиткермәү. Безгә тәртипне бозмыйча, куркуга төшмичә сугыштан чыга белергә кирәк.

Бер мин җавап биреп куйдым:

— Ярар, иптәш командир...

Командир елмайды. Аңа Кәлимуллин да кушылды, башкалар да.

Мин хәзер беләм. Безгә, батырларча һөҗүм итә белгән шикелле, кирәк вакытта тәртип югалтмыйча чигенә белү дә кирәк.

Без кузгалдык.

Елга аръягында ерак түгел — «дошман».

Без агач араларына, чокырларга ышыкланa-ышыклана авылга якынайдык. Чокырларга ышыкланган пулеметлар «дошман»-ның өелебрәк торган җирен сайлап-сайлап сибәләр генә.

Их, кызык. Тау башыннан аз гына карап торсаң да, бөтен «сугыш» уч төбендә.

Уйларны тынычлап уйлап бетерергә вакыт юк. Тагын кузгалырга команда. Ничего, эшләр ярыйсы бара әле...

Гыйззелбанатымны кайтып күрү насыйп булмас микәнни?

Уйламаган җирдә безне атка атланган ике кеше килеп туктатты. Мине, Кәлимуллинны, теге мин күмәчен урлаган Исламовны, тагын безнең белән кунган ике иптәшне һәм отделкомны алып киттеләр. Алып баралар, бер сүз әйтмиләр. Ахырда без йоклаган фатирга алып килделәр. Әлеге безнең көләч хозяйка йөзләре агарган килеш каршы чыкты. Атлыларның берсе сорый:

— Болар households?

— Хозяйка отделкомга төртеп күрсәтте:

— Менә монысы гына бездә кунмады. Ә менә болары бездә кундылар.

— Кайсыннан шикләнәсез? — ди атлы.

Хозяйка туп-туры миңа төртеп:

— Вот самый подозрительный. Ул бик якын ятты.

Безне штаб туктаган фатирга алып бардылар. Безне тоткан кеше барыбызга да күзләрен йөртеп чыкты да:

— Әйтегез, кайсыгыз урлады? — диде.— Сез кунган квартирада сандык өстеннән кырык метр киндер урланган.

Йөрәгем жу итеп китте. Теге кичә мин сокланып яткан киндер. Кем алган?

Сорауга җавап бирүче булмады. Тирә-ягымда утырган иптәшләр борылып-борылып миңа карый башладылар.

Берәү дә эндәшми торганда, Исламов сикереп торды. Ялт итеп миңа карады:

— Менә,— диде,— безнең арада бердәнбер карак. Ул минем икмәгемне урлап тотылды. Ике көн эчендә биш-алты наряд алды. Самый алама кеше ул бездә.

Мин кызардым, битләрем ут кебек янды...

— Әйт дөресен, урладыңмы? — диде эзәрләүче.

— Юк, тимәдем.

Мине тентеделәр. Бернәрсә дә чыкмады. Эзәрләүче отделкомнан сорады:

— Бу малай шаярамы?

Отделком бераз миңа карап торды да:

— Да, замечается аңарда. Иң тотнаксыз, тыңлаусыз, тискәре кеше шул. Икмәк урлаганы да бар.

Шуның белән сораулар бетте. Бөтенесе миңа сылтадылар. «Мин алмадым» дип ялынып карадым. Юк, ышанмыйлар. Миңа

ышаныч югалган. Ул ышанычны тиз генә кайтарып алу бик кыен... Бик кыен...

Берүземне тотып алып калдылар. Киткән вакытта Кәлимуллин миңа борылып карады да сүзсез-нисез башын селекте. Шундый итеп селекте ул башын — йөрәкләремә тиде:

— Их, Хикмәтуллин, сиңа ышаныч калмады. Син, чыннан да, контр икәнсең,— дигән шикелле тоелды ул миңа.

Калдым. Йөрәгемдә чага торган үрмәкүч бар төсле. Ул үрмәкүч без кебек очлы, боз кебек салкын аяклары белән бертуктаусыз йөрәгемә батырып-батырып баса.

Ни эшләдем мин, ни эшләдем? Газиз башым киттемени? Гыйззелбанатымны кайтып күрүләр насыйп булмас микәнни?

Мин гаепсез. Ләкин мин аны ничек ышандырырмын? Булмас. Минем хәл кыл өстендә.

Чын дошман

Гыйззелбанатның бәхете бар икән. Икенче көнне Кәлимуллин килеп миннән сөенче алды.

Теге сары тунлы, усал күзле егетне хәтерлисеңме? Теге авылда кунганда, крестьяннарның хәле начар дип лыгырдап утырган иде — киселеп чыккан әшәке контр булган икән. Югалган киндер шуңардан чыккан. Киндер генә түгел, наган тапканнар. Шунда ук кулга алганнар үзен. Киндерне дә ул, киндер кирәк булганга түгел, Кызыл Армиянең исемен пычрату өчен яшергән икән, ди.

Ә минем эш ходта... Миннән башкаларныкы бигрәк тә. Алар бүген кайталар. Мин әле үземне дә алып кайта алмыйм. Тутырасы нарядларым бар әле минем.

Аламалык турында әйтелгән бер сүз миңа килеп тия

Безнең сборга килгәннәрне иртәгә кайтарабыз дигән көнне зур җыелыш булды. Бөтен полк җыелды. Комиссар сөйләде.

— Без бүген ударникларга бүләк биреп озатабыз, ди. Ләкин, ди, бездә ударниклар шулкадәр күп, кайсына бүләк бирергә белмәссең, ди.

Шулай мактады-мактады да ачулана башлады:

— Бездә бер-ике иптәш бар — алар хәтта укырга-язарга да өйрәнмәгәннәр. Бу, әлбәттә, хурлык.

Бу сүзләр шап итеп минем чикәгә килеп тиделәр.

Тагын бик күпләр чыгып сөйләделәр. Мактадылар. Алама якларны күрсәттеләр. Алама як турында әйтелгән бер сүз миңа килеп тиде.

Бүләк, миңа да бүләк!..

Берзаман бүләкләр бирә башладылар. Менә кызык китте. Иң башлап бер кечкенәрәк буйлы, юаш кыяфәтле кызылармеецны чакырдылар.

— Иптәшләр, менә бу иптәш... полкта иң яхшы ударник,— диләр.— Үзе колхозчы. Без аңа бүләк итеп бер сыер бирәбез!

Сәхнәгә бер сыер өстерәп чыгардылар.

Аннан соң берәүгә тагын тана бирделәр. Самовар, гармун алучылар да булды. Кәлимуллинны мактадылар-мактадылар да, гимнастерка белән чалбар бирделәр. Рәхмәт әйттеләр.

Бервакыт, һич уйламаганда, комсомол секретаре Шәрәфи яныма килеп чыкты да мине сәхнәгә алып китте. Әйдә, сиңа да бүләк бирәбез, ди. Башларым әйләнеп китте. Тагын хур итәләр икән, мин әйтәм, полк алдында хур итәләр...

Мине сәхнәгә чыгарып бастырдылар. Минем янга тагын берәүне китереп куйдылар. Шәрәфи безнең турыда сөйләп бирде:

— Менә болар бөтен полк күләмендә икәүдән-икәү яңалифчә укырга-язарга өйрәнмәгәннәр. Без аларга шуның өчен бүләк итеп әлифба бирәбез,— диде.

Бөтен полк күтәрелеп бәрелә. Сикереп-сикереп көләләр. Кул чабалар...

Мин әлифбаны кулга тоткан килеш чыктым да йөгердем. Теге дә миңа иярде.

Хатым китте, үзем калдым әле...

Икенче көнне халык кайта. Безнең авылныкылар да кайталар. Ә мин калам әле. Өч көнгә торып калу күңелсез күңелсезлеккә, ни эшлим соң?

Гыйззелбанатыма белер-белмәс кенә булса да гарәп хәрефләре белән тырнаштырып сагыну хаты яздым:

«Җаным Гыйззелбанат, сезгә хәләлемә бик сагынып, бик саргаеп сәлам хат. Мәгълүм булсын, иптәшләрем кайтканда, мине тотып калдыралар. Минем гаепләрем булды. Әүвәл командирларым сүзенә колак салмадым. Хәзер үкенсәм дә соңрак булды. Мине бераз эшләтеп кайтаралар. Мин кайтуга хәзерләнебрәк торыгыз. Бәлки, колхозга да кереп куярбыз. Миңа яңалифчә китап бүләк иттеләр. Яңалифчә өйрәнәсем бар. Ярый, хуш, җаным. Әти белән әнигә сәлам әйт.

Язучы хәләлең, Хикмәт.
Беренче октябрь, 1930»

«Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» әсәре — юмористик повесть. Шуңа күрә аңа анализ да юмор үзенчәлегеннән чыгып ясала.

Юмористик әсәрләр үзенчәлеген сез алтынчы сыйныфта өйрәнгән идегез. Юмор белән башка сыйныфларда да очраштыгыз. Шуларны искә төшерик һәм юмор күренешенә яңа сыйфатлар өстик.

Юмор әсәрнең эчтәлеге түгел. Ул — эчтәлекнең яшәү гамәле. Ләкин беренче чиратта юмор — дөньяга карашның бер төре.

Нинди төре?

Юморның тормышта үзе яраткан темасы бар. Башта шул өлкәне ачыклыйк.

Дөньяда бөтенләй кимчелексез кеше булмый. Намусларын югалткан кешеләрдә алар тулып ята. Андый кешеләр үз кимчелекләрен үзләре күрә алмыйлар. Сатира шундый кешеләр өчен яши. Кешеләрдә кимчелекләр булып тора, ләкин юньле кеше аларны бик тиз күреп ала һәм төзәтә.

Берәүнең дә үз кимчелекләрен башкаларга күрсәтәсе килми. Алай гына да түгел, күп кеше үз кимчелекләрен кимчелек итеп танырга теләми. Үзен гел яхшы итеп кенә күрәсе килә. Шуңа күрә һәркем үз кимчелекләреннән котылмакчы була. Ә моның өчен иң җиңел юл — аны аклау, аның ямьсезлеген матур итеп күрсәтү.

Бу чир белән бик күп кеше авырый. Шуңа күрә к и м ч е л е к безнең арабызда әхлак кануннарына ярарга тырышып яши бирә.

Юмор тормышның менә шул каршылыклы ягыннан көлү өчен туган.

Дөньяга юмор белән карый торган кеше бөтен булып күренгән күренешне каршы якларга аера. Кимчелек ягын тагын да ямьсезләтә төшә, матурлык ягының ясалма, нигезсез булуын күрсәтә. Ләкин юморист кеше яхшы ният белән көлә һәм үзендә усал мәкер юклыгын аңлар дип ышана.

Биремнәр һәм сораулар

1. Мисал. Бер башлап язучы редакциягә үзенең хикәясен алып килгән. Редактор кульязманы укып чыккан, ләкин ошатмаган.

— Кызганычка каршы, хикәягез басарлык түгел, — дигән.

— Беләсезме, мин Габдулла Тукай үлгән елны туганмын, — дигән башлап язучы.

— Тормыш шундый инде ул, кайгы бер вакытта да ялгыз гына килми, — дип җавап биргән аңа редактор.

2. Мисалда юморист кешене табыгыз. Каршылыклы күренешне икегә аерып күрсәтегез. Башлап язучыга бирелгән бәяне бер сүз белән әйтергә тырышыгыз.

3. «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» әсәре — юмористик повесть. Димәк, аның төзелешендә юморга хас каршылык ятарга тиеш. Уйлагыз: әсәрен язганчы Мирсәй Әмир күреп алган тормыш күренеше нинди булырга мөмкин?

4. Шул тормыш күренешен көлке хәленә китерү өчен автор нилэр эшләгән?

5. Хикмәтуллинга бәя бирегез.

6. Мирсәй Әмир 1930 елда күреп алган кимчелекләрнең актуальлеге бүген дә сакланганмы?

ФАҖИГАЛЕ МӘХӘББӘТ

(Чеховтан бозыбрак алынды)

Мин аның белән кайчан танышканмындыр, анысын белмим. Тик мин аңардан бер генә секундка да аерыла алмыйм һәм аның сүзеннән чыкмыйм. Аңар шулкадәр нык бирелгәнмен, шулкадәр нык буйсынганмын, үз гомеремдә аның сүзе белән йөрмәгән бер генә көнем барлыгын да хәтерләмим. Ул үзе дә мине бер генә секундка да ялгызымны калдырмый. Һәрвакыт минем янымда. Мин дә аңардан аерылып торырга тырышмыйм. Димәк, безнең арада якынлык бик көчле! Ләкин, хөрмәтле кызлар һәм хөрмәтле киленнәр! Безнең бәхетле тормышыбыздан көнләшмәгез. Безнең бу фаҗигале якынлыгыбыз минем өчен бертөрле дә файда бирми. Киресенчә, бу якынлык миңа зарар китерә. Беренчедән, ул, минем иптәшем, бер генә секундка да минем янымнан китмәве белән миңа эшләргә уңайсызлый. Аның аркасында мин башкалар белән тигез эшли алмыйм. Ел әйләнәсенә алырга тиеш булган барлык хезмәт көннәрем аның назлы теләкләрен канәгатьләндерү өчен корбан булалар. Йорт җиһазларымны рәтли алмыйм. Аның хәтерен саклавым аркасында бик күп көннәремне ачлы-туклы уздырырга туры килә. Аның аркасында халыктан сүз ишетәм. Аның аркасында кара такталарга эләгәм. Аның хакын саклап, кеше күзе алдында дәрәҗә төшә. Ләкин ул назлы бикә аларның берсен дә аңлый алмый, аңларга да теләми. Минем караңгы төпсезлеккә тәгәри баруым белән хисаплашмый, һаман үз янына тарта. Хәтта китап-фәлән укырга, кулга каләм алырга да ирек бирми. Менә әле дә, мин шушыларны язып утырам, ул минем яныма килгән дә кулымны тота, башымны сыйпый, күзләремнән үбә.

Җитәр инде, җаным, әйдә ятыйк, тәмле итеп йоклыйк,— ди, мине түшәккә өстери. Мин аңар буйсынам, артык яза алмыйм. Ул миңа сөлек шикелле ябышкан да каләмне ташларга куша. Һаман түшәккә тарта. Каләмемне кулымнан төшермәс борын сезгә аның исемен язып калыйм, аның исеме дә башкаларныкына охшамаган, ямьсез исем. Аның исеме — Ялкаулык.

1933 ел

ТЫР-ТЫР ЗАРИФ БРИГАДАСЫ

— Әпәй ашау харам? Миңамы? Кем әйтә аны? Бөтен колхоз әйтә? Минме эшләмәдем? Минем бригада эшләмәдеме? Халыктан оялырга кирәк азрак. Яз көне кары да эреп бетмәгән кыр өстенә иң башлап эз салучы кем иде? Тыр-тыр Зариф иде түгелме? Төнге сәгать өчтән үк торып, кырга чыгып китүче бригада Тыр-тыр Зариф бригадасы иде түгелме? Бер караңгыдан тикле янып-пешеп эшләү аркасында кырык баш атның унбише эштән чыккач, егерме биш ат белән чәчү планын башкарып чыгучы Тыр-тыр Зариф бригадасы иде түгелме? Имеш, Сабир бригадасы гына ударный! Кырык аты да исән булса, кем ударный булмый аны?.. Чәчү машиналары ватылып беткәч, өч йөз гектар җирне кул белән чәчеп чыгучы Тыр-тыр Зариф бригадасы иде түгелме? Бер үк җирне өч кабат эшләп чыкканнан соң, сыйфат комиссиясе карап канәгатьләнерлек тапмагач, бодайлар шыта башлаган булуга карамастан, тагын бер кат тырмалап чыгучы Тыр-тыр Зариф бригадасы иде түгелме? Уйлап сөйләргә кирәк аны, егетләр... Аның ни көлкесе бар, нигә авызыгызны ерасыз? Әлбәттә, шулай. Шулай шул: эшләгәннеке замана! Тыр-тыр Зариф бригадасыннан да күбрәк эшләгән бригада булганы да юк әле бездә. Утау вакытында безнең ничек эшләвебез берәүгә дә сер түгел ләбаса. Бер урынны бишәр кат утаучы кем иде? Бригадасындагы бөтен бала-чага, карт-корыларына кадәр һәммәсен кыр өстендә яткырып утаучы кем иде? Шул ук Тыр-тыр Зариф иде түгелме? Юк инде, энем, начар чәчкәнгә күрә чүпле дип лыгырдавыңның бер дә кирәге юк. Монда утау турында сүз бара, эшләү турында сүз бара. Ә утау ягыннан, ничә әйтсәң дә, иң күп эшләүче — Тыр-тыр... Сөйләдең тагын сүз, минем ни катнашым бар монда? Уңыш аз булуда Тыр-тыр Зарифның ни катнашы бар? Урыпҗыю вакытында Тыр-тыр бригадасы кемнән ким эшләде? Ургыч машиналарыбыз беренче көнне үк ватылып эштән чыктылар, бу сезгә мәгълүм бит. Бөтен чәчү мәйданын кул белән җыеп

алырга туры килдеме Тыр-тыр Зариф бригадасына? Килде. Әз эш кирәкмени анда! Уйлап сөйләргә кирәк аны... Кит, малакасус, бәйләнмә, минем мыекта ни эшең бар синең, кабарсын. Мыек турында сүз бармый монда, эш турында сүз бара. Әлбәттә, көнетөне йокы күрмичә эшләмәсәң, ничек итеп ул кадәр җирне коры кул көче белән җыеп алып бетерергә кирәк? Юк инде, Тыр-тыр Зариф бригадасын Сабир бригадасы белән тинләп булмый, Сабирның җирләрен бер тапкыр да рәтләп утарга туры килмәде. Уру вакытында ике машинасы да үкертеп эшләде, бер аты да арымады. Ә Тыр-тыр Зариф бригадасын кем белми? Бәла өстенә бәла мәче балаларыннан битәр туып кына тордылар бит. Әйдә, аннан янып-пешеп эшлә дә эшлә... Сиңа ни җитмәгән тагы, адәм актыгы, авызыңны чабата кебек җәеп утырасың, мин синең картузыңа бәйләнмим бит, минем эшләпәдә ни эшең бар? Эш турында сүз бара монда. Оялырга кирәк, егетләр. Әпәй ашау харам, имеш. Әйтерсең эшләми алган кеше бар... Әйе, көрәшмәгән ди! Тыр-тыр Зариф уңыш өчен көрәшмәс инде әллә кая! Кара исәп белән генә уйлап кара, ичмасам. Кем бригадасында урылган җир өстеннән егерме олау башак җыеп алынды? Тыр-тыр Зариф бригадасында түгелме? Сабир бригадасы белән чагыштырма син мине. Алты километрдан ындырга ташып сугучы кем булды? Тыр-тыр Зариф бригадасымы? Эшләмәсәң шулай буламыни? Нинди генә яктан карасаң да, Тыр-тыр бригадасыннан күп эшләгән бригада таба алмассың. Кем күп эшләгән — шул күп ала, каршы килеп кара син шуңар. Юк, шаярмагыз, Тыр-тыр Зариф мах бирмәс...

Тапканнар чагыштырыр әйбер, имеш, Сабир бригадасы гектарыннан унике центнер бодай алганда, Тыр-тыр Зариф бригадасы алты центнер алып калган. Ә иң күп эшләүче, көне-төне чабучы — Тыр-тыр. Битәрләргә хакыгыз юк. Тыр-тыр әрәмтамак түгел, күп эшләү ягыннан караганда, Тыр-тыр Зариф бригадасыннан да ударныйрак бригада юк. Ударниклар съездына Тыр-тыр Зариф бригадасы члены барырга тиеш. Әгәр шулай булмаса, ерма авызыңны, син үзең җил тегермәне, валлаһи дип әйтәм, исемем Тыр-тыр Зариф булмасын...

1933 ел

Бирем

Хикәяләргә анализ ясагыз.

Нәкый Исәнбәт
(1899—1992)

Нәкый Сиражетдин улы Исәнбәт (Закиров) 1899 елның 29 декабрендә элекке Уфа губернасы Златоуст өязе Малаяз авылында туа. Үз авылларында, аннары Уфаның, Казанның төрле мәдрәсәләрендә белем ала. Укытучылар курсын тәмамлаганнан соң, укытучы булып эшли.

Нәкый Исәнбәт — Габдулла Тукайлар заманында ук шигырьләр язып бастырган әдип. Аның гомере озын булды. Эшләгән эшләре исә аннан да күбрәк.

Башта ул шагыйрь булып таныла. «Син сазыңны уйнадың» җырын әдип егерме алты яшьлек егет чагында иҗат итә. Җыр бүген дә актуаль яңгырый.

Бу җырда күңелендә фәкать көрәш моңнарын гына саклаган лирик герой саз моңнарын ишетеп хәйран кала. Әлеге моңнар аның күңелендә көрәш еллары күмеп калдырган мәхәббәт хисләрен уята. Чын, матур хиснең көрәш моңнары булмавын әле генә аңлаган герой тәмам шашып кала. Ләкин узган гомерне кире кайтарып булмый.

Үткән ул даулы гомерләр,
Кан-көрәштә яңгырап.
Саклаганмын тик күңелдә
Шул көрәшнең моңнарын.

Башка буын кешеләренә дә бу юллар үз, шулкадәр якын.

Үзенең фаҗигасен аңлаган лирик герой рухи халәте турында:

Чыңлаган шул кылларыңдай,
Бер-бер үтте елларым,
Үтте айлар, үтте еллар,
Түзмәдем мин егъладым,—

ди.

Бу рухи халәт күп буыннарның гасырлар буена үзгәрмәгән рухи халәте иде дип әйтә алабыз.

Нәкый Исәнбәт — күп еллар буена татар сәхнәсен тоткан драматург. Аның «Спартак», «Миркәй белән Айсылу», «Хуҗа Насретдин», «Муса Җәлил», «Рәйхан», «Зифа» пьесалары аеруча күп куелалар. Татар драматургиясен Нәкый Исәнбәт пьесаларыннан башка күз алдына да китерергә мөмкин түгел.

Нәкый Исәнбәт татар халык авыз иҗаты әсәрләрен гомере буена җыя. Ул җыеп, эшкәртеп бастырган халык авыз иҗаты әсәрләре бөтен бер фәнни институтның күп еллар буена эшләгән эше белән тиңләшерлек.

СИН САЗЫҢНЫ УЙНАДЫҢ

Моңланып ай нурларында
Син сазыңны уйнадың;
Нинди кыллар чиртте, бәгърем,
Ул матур, яшь кулларың?

Бакчаның бер почмагында
Мин утырдым, тыңладым;
Тыңладым да мин ирексез
Яшьлегемне уйладым.

Уйладым мин яшьлегемне,
Син сазыңны уйнадың!

Кайгылы күңлем тавында
Яңгырады кылларың;
Яңрады ул моңлы кыллар...
Син сазыңны уйнадың.

Чыңлаган шул кылларыңдай,
Бер-бер үтте елларым;
Үтте айлар, үтте еллар,
Түзмәдем мин егъладым.

Үтте айлар, үтте еллар,
Син сазыңны уйнадың!

Үткән ул даулы гомерләр,
Кан-көрәштә яңгырап.
Саклаганмын тик күңелдә
Шул көрәшнең моңнарын.

Аһ, терелттең син күңелнең
Бар күмелгән кылларын!
Яңрап үткән ул гомернең
Мин авазын тыңладым.

Яңгырап үтте гомерләр,
Син сазыңны уйнадың!

1925 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Югарыда, Нәкый Исәнбәт иҗатына багышланган мәкаләдә, бу шигырьнең эчтәлеге аталып кына, исбат ителмичә әйтелә. Шигырьгә анализ ясыйк, лирик герой хисенең дәрәҗәсен һәм сәбәбен табыйк. Хис дәрәҗәсен автор «егъладым» дип үзе әйтеп бирә. Әмма сәбәбен: «яшьлеген сагынып хәсрәтләнә» дип кенә әйтү безне канәгатьләндерми. Сәбәпнең тирәнрәген табыгыз. Табылмаса, биремнәрнең башкаларына җавап эзләгез.

2. Саз моңы белән үткән еллар арасындагы бәйләнешне табыгыз. Автор бу бәйләнешне ничек күрсәткән?

3. Шигырьдә саз моңының үзенә генә бәйләнешле һәм лирик герой ишеткән сыйфатлары бар. Шуларны аерып әйтегез.

4. Чынлыкта саз моңы үткән гомер белән бәйләнми, лирик геройның хәтеренә тәэсир итә. Бу хәтердә ниләр бар? Сөйләгез.

5. «Син сазыңны уйнадың» дип автор биш тапкыр кабатлый. Бу сүзләрне төрле вакыйгалар янына куя. Ни өчен шулай итә?

БЕР ПЕЙЗАЖ

Ала-кола болытлар
Күк өстенә менәләр,
Алтын-сары күк өстен
Җиңәбез дип киләләр.

Урман тыныч мәһабәт,
Шик төшергән кем дә юк,
Бар да тыныч көн кәтә,
Тирбәтүче җил дә юк.

Тик күпердән күл аша
Таяклы бер карт үтә,
Алтын сары су өсте
Аңа көлеп ялт итә.

1924 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Әгәр бу шигырьнең сюжеты булса, аны «Җир тынычлыкка сусаган, тынычлык тели» дип әйтергә мөмкин булыр иде. Ләкин тынычлык Җир теләге генәме?

2. Көтелгән тынычлыкны бер карт кеше боза. Әмма гаҗәп әле генә тынычлык көткән табигать аңа ачуланмый. Ни өчен?

3. Сез «Син сазыңны уйнадың» һәм «Бер пейзаж» шигырьләрен укып, аларның эчтәлеген таптыгыз. Хәзер ашыкмыйча уйлагыз: бу ике әсәр арасында нинди дә булса бәйләнеш бармы?

4. Хәзер бу шигырьне лирик әсәр буларак өч өлешкә бүлеп карыйк. Әгәр тынычлык автор хисенең сәбәбе булса, ул сәбәп тудырган хисне атагыз.

5. Шигырьнең юану өлеше юк кебек. Уйлап карасаң, аны табып буламы?

АККОШ

Тугайлының тып-тын күлендә
Кояш ята көлеп төбендә,
Күл өстенә төшкән күк өстендә
Аккош йөзеп бара тын гына.

Муеннары айдай уелган,
Агып төшкән судай коелган,
Коелып-чәчелеп киткән шул су кебек,
Канатлары өскә кыелган.

1930 ел

Биремнәр

1. Шигырьнең эчтәлеген табыгыз.
2. Аны «Бер пейзаж» шигыре белән чагыштырыгыз.

ХУҖА НАСРЕТДИН

Комедия биш пәрдәдә

КАТНАШУЧЫЛАР:

Хуҗа Насретдин.
Гөлбану — хатыны.
Сәлви — кызы.
Хаммат — Сәлвинең сөйгәне.
Алчын — егет.
Зөбәрҗәт — Алчынның сөйгәне.
Сәхилә — карчык.
Бики — сәүдәгәр.
Ахун.
Колый тархан.
Җиһангир — легендар илбасар, уң аягы аксак.
Зәйнәгый — аның баш вәзире.
Низамый — казый.
Гыймай — баскак.

Дәрвиш.
Сачтараш.
Ике Касыйм.
Атамыш.
Карт.
Яшь кеше.
Җариялəр, гаскəр, халык.

Вакыйга урта йөзлəрдə Болгар шəһəрендə һəм аның янындагы Тимерче бистəсендə бара.

Беренче пəрдə

Болгардан ерак түгел Тимерче бистəсендə бер тыкрык. Сулдарак Хуҗаның йорты. Сəер генə ике катлы кыйшык өй; аны, аусын дигəн шикелле, кыйшаймаган ягыннан терəү белəн терəткəннəр. Югары катка тыштан менə торган иске баскыч. Каршында аскы ишек тирəлəп ян култыкса, анда утырыр җир: кечкенə тəбəнəк өстəл һəм шундый ук кечкенə тəбəнəк урындыклар. Шул буйда ук аскы өйгə ишек. Челтəрле, ачылмалы тəрəзə өстендə чарлак; тəрəзə янына җиллəргə эленгəн хөллə. Бики байның коймасы аша алма бакчасы күренə. Хуҗаның өенə каршы якта Сəхилə карчык чарлагы, коймага уеп эшлəнгəн ян капка. Артта тыкрык. Пəрдə ачылганда Хуҗаның өй эченнəн җыр белəн тоньк кына думбра авазы килə.

Сəхилə чарлагы ачыла. **Бики**, **Сəхилə** чарлакта күренəлəр.

Бики. Җыен тай-тулакның шул тирəдəн китүе юк. Бу хəерлегə түгел. Сəлвине урлап китə күрмəсеннəр. Соңлап куймыйк, җəтрəк.

Сəхилə. Əй, бөтен бистəгез белəн шаккаттыгыз инде бер Сəлвигə! Шушы Болгар белəн Үргəнеч арасында кəрван йөрткəн бай булдың, шул дивана кызыннан башкасын тапмадың!

Бики. Күз алдымда үскəн шул кызны алмасам, биллəһи дип əйтəм, ир аты күтəреп йөрмим, шушы сакалымны йолкып, үземне хатын дип йөртсеннəр!

Сəхилə. Алай дисең дə, кызның атасы бар бит əле... Хуҗа ни дияр?

Бики. Хуҗамы? Һəй! Хуҗа нишли ала ул? Йортына чаклы миңа асламга[1] салынган бит. Бер ишəге белəн кая бара ул? Телəсəм йортын саттырам да иртəгə зинданга утыртам. Бар, əйдə! Хатыны белəн генə сөйлəш. Мин үзем хəзер ахун белəн Колый тарханны алып килəм. Ул дивана уйлап торганчы, алдым-бирдем ясап эшне бетереп куярга кирəк. Əгəр дə Хуҗа, чынлап та, кире

[1] **Асламга** — бурычка.

кагарга уйласа, соңгы ишәгеннән яздырам мин аны. Бүген үк урлатам! (*Китә.*)

Сәхилә шакылдата.

Гөлбану (*өстән чыга*). Әйдүк! Хуш килдегез, Сәхилә эби.

Сәхилә. Әйдә әле, керик, сөйләрмен.

Гөлбану. Төкле аягың белән, Сәхилә эби. (*Аска кереп китәләр.*)

Дәрвиш, Хуҗа керәләр.

Дәрвиш. Йа шәйхем, мәдәт! Җиһангир хәзрәтләре миннән Зөбәрҗәт турында хәбәр көтә торгандыр. Бу тирәдән дә иснәштерергә кирәк. (*Каранып.*) Бу Хуҗа Насретдин йорты, ләкин аны бик хикмәтле дивана диләр, күрик! (*Тирәүне күреп.*) Сөбханалла, бу ни кирәмәт? Тирәү булса, авар яктан булырга кирәк иде, ә бу соң? (*Хуҗаның килгәнен күреп.*) Һай, Хуҗа Насретдин!

Хуҗа (*кулында балта, алъяпкычына йомычка төягән, башында түбәтәй, озын камзул, киң генә яшел ыштаннан*). Вай, дәрвиш! (*Баскычтан менеп өенә кереп китә.*)

Сәлви күренә.

Сәлви (*астан килеп чыга*). Минем башымны ашарга килгән җен карчыгы! Күренмиме ичмасам шул тирәдә Хаммат? (*Дәрвишне күреп*). Кем бу?

Дәрвиш (*кулын күз өстенә куеп*). Йа шәйхем, мәдәт! Йөзләрендә кодрәт нуры балкый, туры карый алмыйм, күзләрем камаша! Бу шул мин эзли торган Зөбәрҗәт түгелме? Һай, гүзәл, һай!

Сәлви. Якын килмәгез миңа!

Дәрвиш. Миңа Хуҗа кирәк.

Сәлви. Әти өйдә юк. (*Баскычка менә башлый.*)

Дәрвиш (*үзалдына*). Әти, ди? Димәк, бу — Хуҗаның үз кызы? Йа Алла! Үзең гөнаһка төшермә! Һай гүзәллек солтаны! Алла юлында тузан булган бер дәрвишкә ни өчен ялган сөйлисең? Әтиең өйдә бит!

Сәлви. Ул мондый суган суфиларын яратмый. Ләкин ул өйдә юк.

Дәрвиш. Хәзер генә кереп китте.

Сәлви. Кермәде!

Хуҗа (*чарлактан башын чыгара*). Керсә соң? Бәлки, ишеге икедер, берсеннән керсә, берсеннән чыгып киткәндер.

Сәлви (*югары карап*). Ай, оятлы булдым! Әти анда! (*Өскә кереп китә.*)

Хужа баскыч өстенә чыга.

Дәрвиш. Һай, Хуҗа! *(Кулы белән ишарә итеп аска чакыра.)*

Хуҗа. Вай, дәрвиш! *(Баскычтан төшә.)* Нәрсә бар?

Дәрвиш *(аңа савытын суза)*. Садака рәхим ит!

Хуҗа җавап бирми, баскычка менеп китә дә аны кулы белән чакыра.

Дәрвиш (*менеп, Хуҗаның йөзенә карап тора*). Йа Алла! (*Кулын суза.*)

Хуҗа. Алла бирсен.

Дәрвиш (*ачуланып*). Юк булгач, ник мине монда чакырып менгездең, түбәндә әйтмәдең?

Хуҗа. Ә син ник мине түбән чакырып төшердең, мин югарыда вакытта әйтмәдең?

Дәрвиш. Шайтандыр бу, йа шәйхем, мәдәт! (*Артта югала.*)

Хуҗа (*үзалдына*). Алла кунагы да бит ул, алай да артыннан карап калган яхшы, ишәкне сыптырып китмәсен! (*Артыннан чыга.*)

Сәлви ишектән атылып чыга. Хаммат керә.

Сәлви. Харап булдык, Хаммат! Өйдә Сәхилә карчык утыра. Хәзер мине Бики байга тотып биреп, алдым-бирдем ясамакчы булалар.

Хаммат. Качабыз!

Сәлви. Ай, ышыклан, Хаммат! Бики байлар үзләре килә... Кач! Кер шушы хөллә астына! (*Өстерәп кертә.*) Эндәшмә! Без аларның бөтен серләрен белергә тиеш! (*Аскы ишектән кереп китә.*)

Ахун, Колый тархан, Бики керәләр. Хөллә астында Хаммат.

Бики. Анасы ягыннан эш көйле. Сездәй кеше кода булып килгәч, Хуҗа Насретдин ни йөзе белән каршы килә алыр? Мәһәр өчен мин аның бурычларыннан кичәм бит!

Колый. Моңача Колый тархан сүзен кире каккан зат юк иде. Бу дивана да кире кага алмас... Теге хөлләне менә шунда гына югалттым мин аны.

Ахун. Буза боза сезне, тархан!

Колый. Сәхилә карчыкның җарияләрен[1] карыйм дип кенә кергән идем, күп булса бер ярты көрәгә[2] балын күтәреп эчкәнмендер, чыксам егылганмын. Уянсам, өстемдә хөлләм юк!

Бики. Ярый, миннән сиңа тач шундый бер хөллә, тархан.

[1] Җария — кол кыз.

[2] Көрәгә — мичкәгә охшаган савыт.

Хуҗа (*артларыннан килә, үзалдына*). Бики байга Хуҗа Насретдин кызын алырга киләләр...

Ахун. Менә бит Насретдин. Әссәламегаләйкем!

Хуҗа. Хуш килдегез, утырыгыз.

Колый. Тукта әле син, Насретдин, утырганчы бер эш бар. Зирәк булсаң әйт: без менә ахун хәзрәт белән сиңа ни өчен килдек?

Хуҗа. Ашар өчен килгәнсез, әлбиттә.

Колый. Менә белмәде, менә белмәде!

Хуҗа (*ишекне яртылай ачып куя да хатыны белән сөйләшкән була*).

Кунак килде, Гөлбану,
Инде нихәл итәргә?

Ярар, булмаса булган икән, пешер тансыкка тары боткасы. (*Тыңлаган булып.*) Ә? Май юк, дисең? (*Әйләнеп килә.*) Менә син әле, ә? Ярма белән тоз булса, ботка пешергән була идек бит, май юк!

Колый. Куй әле син аш-суыңны, бире кил. Башкода булып килдек без сиңа! Ха-ха-ха!..

Ахун. Кызыңны бирәсең, Насретдин, баба буласың!

Хуҗа. Ник аны баштук әйтмисез? Алай булгач, баба шулпасы эчерергә кирәк бит инде сезгә.

Колый. Без монда утырсак, өстебезгә аумасмы бу өең?

Хуҗа. Аумас, әнә кара, ул бит теге ягыннан терәткән! (*Кереп китә.*)

Колый. Терәткән... Әйткәннәр иде шул, кая әле... (*Терәүне күреп.*) Кара! Ха-ха-ха! Үз өстенә аварга терәткән. Ничек тора соң бу?

Ахун. Менә шунысын төшенеп булмый, ахмакны. Бу тыштан шулай булып та, эчтән бүтәнчә түгел микән, дим.

Колый. Пычак та бүтән түгел, күренеп тора, шыр дивана бу! (*Каранып.*) Болай үзе аш-суга, кием-салымга мул яши, ахрысы. Күрәсең чөйдәге киемнәрне? (*Гаҗәпләнеп.*) Тукта, ахун! (*Килә.*) Шул минем хөллә бит инде бу!

Ахун. Дөрес, тәкъсир, мин дә таныдым. Сезнеке. Димәк, теге көнне хөлләгезне бу салдырып алган булып чыга, тархан... Менә ул безгә кызын ничек бирер? Киреләп куйса, без аны шушы хөллә белән кеше алдында тотып... хур итәрбез.

Колый, ахун, Хуҗа.

Хуҗа (*олы табак су күтәреп чыга; араларына кереп*). Җитешегез баба шулпасыннан! (*Кашыклар куя.*)

Ахун. Ләхәүлә, бик сыек түгелме соң бу? Мин инде ашап кына килгән идем килүен.

Хуҗа. Аш ашка, урыны башка. Куктәге фәрештәләр генә ашамый торалар.

Колый (*кабып карап, гаҗәпләнеп*). Бу ни булды бу?

Ахун (*кабып, авызыннан озын су бөркеп*). Бу — су булды бу!

Хуҗа. Ашыйсы җирдә аш бар, эчәсе җирдә су бар, дип шуны әйткәннәр, тархан. Сыйлаганда су эч! Үтмиме әллә? Алай булса, хуш иттек! (*Кулын күтәрә.*) Амин, амин алманды, авызы-борыны ялманды: сакалдан акты, авызга тимәде.

Бар да торалар.

Колый. Бу ни булды бу? Баба шулпасы дип, Колый тарханга бер табак су эчертәләр! Ә никах?

Хуҗа. Нинди никах? Кыз йомышын кыздан сорарга кирәк.

Колый. Юк, моны кара әле син! Баба шулпасы дип Колый тарханга бер ләгән су чыгарып куя! Алай булса... (*Хөлләнең җиңен тотып.*) Каян алдың син моны?

Хуҗа. Менә сиңа мә! Бай кисә — котлы булсын, ярлы кисә — каян алдың!

Колый. Минеке бу! (*Камчысы белән хөлләгә суга.*) Минеке!

Ахун. Алма хөлләңне, тархан! Казый каршында җавап бирсен! Үзем шаһит! Әйдә! (*Чыгалар.*)

Хуҗа. Кара син, ә! Аш-суымны эчтең, йөз суымны түктең. (*Артларыннан табагы белән суны сибә.*) Мә!

Гөлбану (*аскы ишектән ашыгып чыга*). Кемнәр белән алыша бит! Берсе ахун, берсе тархан, шулар бит инде бөтен илеңә хуҗа!

Хуҗа. Хуҗа? Алар нинди хуҗа? Мин хуҗа! Мин үзем Хуҗа Насретдин.

Гөлбану. Кемгә тап булдым бит! Бер генә кеше дә аның телләренә чыдый алмый бит! (*Елый. Кереп китә.*)

Хуҗа. Ярый, мин дә хөлләмне киеп бер чыгып әйләним.

Хөллә үзлегеннән шуып төшә дә үбешкән Хаммат белән Сәлви күренә.

(*Гаҗәпләнеп.*) Хөлләсе хөллә, болары нинди хөрмә?

Хаммат. Хуҗа абзый, теләсәң ничек хөкем ит. Мин аны сөям... Менә без икебез дә синең алдыңда; мин аны сөям. Хәлфә, безгә атай бул!

Хуҗа. (*Хамматка*). Һай, син әле минем кияү булып чыктыңмыни? Хуш, алайса, төкле аягың белән кил, кияү!

Икенче пәрдә

1 нче сәхнә

Чат. Унда сәндерәдә сачтараш Хәйбүш күшеге. Артта мәчет почмагы. Анда Җиһангирның бик зур сугыш филенең башы чыгып күренеп тора. Янында сөңгеле һинд. Фил үз алдындагы савыттан борыны белән икмәкләрне эләктерел алып бөтен килеш авызына тыга бирә. Бу тамашаны күрергә алга халык җыелган. Бер якта ян сакчылары белән Колый тархан һәм ахун.

Бики (*мәчеттән чыга*). Харап булдык, җәмәгать! Тимерче Галәвиләр анда, Хуҗа Насретдинны җибәрик, дип авызланалар!

Ахун. Җиһангир хәзрәтләренәме? Әстәгъфирулла! Ул анда вәкил булып барса, бүген кыямәт! Анымы? Аны шушы халык алдында, тәүбә иттереп, җиргә тезләндерәм! Ахмакны!

Бики. Юк, хәзер үк аны тотып Җиһангирның казыена алып барырга кирәк!

Колый. Тотабыз! (*Ян сакчыларына.*) Сакчылар! Тиз барыгыз Хуҗага! Минем югалган хөлләм аның чөендә булыр. Өстенә кидереп, хәзер бире тотып китерергә! (*Сакчылар чыга. Бикигә.*) Баба шулпасы! Зинданда чери ул хәзер! Кызын син аласың, мин хәзер үземә бер җария сатып алам, туйлыйбыз!

Бики. Инде сүз бер, әйдәгез мәчеткә керик, сайлый күрмәсеннәр үзен. (*Кереп китә. Колый, ахун артыннан чыгалар.*)

Алчын белән Хуҗа (*хөллә кигән*) керәләр.

Алчын. Беләсеңме син, Хуҗа, хәзер мин шул акчаны табып илтсәм, Колый тархан да, Җиһангир явыз да авызларын күтәреп калачаклар, кыз минеке. Акыл бир!

Хуҗа. Акыл бир дә алтын бир. Күпме тора соң ул җария?

Алчын. Йөз алтын.

Хуҗа. Йөз алтын гына? Һәй, бөтенләй юк акча икән! Үзеңдә күпме бар соң?

Алчын. Бер алтын.

Хуҗа. Уһу! Бер алтын диген? Соң шулай булгач, яңадан туксан тугыз гына кирәк түгелме соң? Бөтенләй юкка борчылып йөрисең икән син... Ярый... Алай да син бераздан шул тирәгә сугыл. Эзләп карармын. Йә бар! (*Алчын чыга. Хуҗа баскычтан Хәйбүш күшегенә күтәрелә башлый.*) Йөз алтын, йөз алтын.

Хәйбүш (*чаршавын ачып*). Хуш киләсең! (*Аны күшеккә утыртып, чаршауны ябып куя*).

Ахун, Колый тархан, Бики, карт, яшь кеше, Сәхилә һәм башкалар керәләр.

Ахун. Минем сезгә сүзем шул: Җиһангир хәзрәтләренең филенә тел тидереп, аның ачуына дучар булмагыз.

Колый. Минемчә дә, бармау яхшы, җәмәгать! Инде бик барсын дисәгез, бу эшкә ахун үзе мәслихәт!

Бики. Тархан анда казый йомышы белән бара, мин дә барам.

Карт (*халыкка*). Алар үз эшләре белән бара бирсеннәр, без Хуҗа Насретдинны җибәрик.

Халык. Рас, рас, менә кешесе, Насретдин!

Хуҗа (*сәндерәдән килеп чыга*). Әү! Мин монда, нәрсәгә кирәк?

Яшь кеше. Менә үзе!

Карт. Якын кил, Хуҗа, ил мәслихәтенә катыш. Ишәгең югалдымыни?

Хуҗа. Аллага шөкер, югалды.

Ахун. Һи, ахмак! Дивана! Шөкер урынымыни бу?

Хуҗа. Шөкер булмыйча, шулвакыт ишәк өстендә булсам, үзем дә югалган булыр идем ич.

Тавышлар. Ха-ха-ха! Ничек, ничек ди? Өстендә булсам, диме?

Ахун. Нәрсә сөйли, нәрсә сөйли, ахмак! Шул ахмакны Җиһангир хәзрәтләренә илче булып барсын, дисез. Иң элек аның гакылын сынарга кирәк. Ягъни камилме? Ярый, менә мин аңа өч мәсьәлә бирим. Менә син, ягъни мәсәлән, безгә җавап бир: дөньяда иң кыйммәтле таш нинди таш?

Хуҗа. Тегермән ташы. Син тегермән ташыннан башка дөньяда торып кара!

Тавышлар. Дөрес әйтте шул! Ха-ха-ха!

Ахун. Ярый, әйт: җеназаның алдыннан барырга кирәкме, артыннанмы?

Хуҗа. Теләсәң каян бар, тик эчендә генә барма. Табут эчендә, дим.

Тавышлар. Менә дөрес! Кояштыр әгәр!

Ахун. Сафсата сөйлисең, ахмак. Менә тагын бер мәсьәлә бирим: кыямәт кайчан булыр?

Хуҗа. Ике.

Ахун. Ике диме? Ишеттегезме? Аныңча, ике кыямәт була! Хуш, ягъни мәсәлән, ул ничек ике кыямәт? Алар кайчан булачак?

Хуҗа. Берсе хатыным үлгәндә, берсе үзем үлгәндә.

Халык. Ха-ха-ха! Ай Хуҗа, ант әгәр, ай! Эчерде баба шулпасын ахунга!

Ахун. Туктагыз! Күрдегезме, Хуҗагыз иманга зәгыйфь. (*Хуҗага.*) Ахмак! Тиз иман яңарт! Тәүбә ит, ахмак! Әллә дога да кыла белмисеңме?

Хуҗа. Нигә белмәскә. Беләм. (*Кулын җәеп, күккә карап.*) Әй Алла, шушы ишәкнең дә аты бар, мин адәм булып ишәгем дә юк. Кайттым, сыендым, бир миңа мең алтын!

Колый. Уһу. Күпме сорыйсын белә, дивана!.. Меңне бирмәсә?

Хуҗа (*һаман күккә карап*). Йөзгә дә риза.

Колый. Йөзне бирмәсә?

Хуҗа. Алла булып та йөздән ким бирсә, алмыйм да мин!

Ахун. Йөздән бер алтын ким булса да алмыйсыңмы?

Хуҗа. Валлаһи, алмыйм!

Ахун. Шуңа ант иттеңме?

Хуҗа. Ант иттем! Көтәм!

Ахун (*Бикигә акрын*). Бики, тиз чыгар акчаңны! Бер тәңкәсен алып кал да ыргытыйк үзенә! Хур итәбез дошманыңны, бир! (*Янчыгын арттан Хуҗага ыргыта.*)

Хуҗа. Ә? Бу ни? Алтын!

Бар да. Карагыз, кара. Хуҗага күктән бер янчык алтын иңгән!

Ахун. Алай да санап бирегез үзенә! Бер алтын ким булса да ала алмый. Йә, санадыгызмы?

Карт. Санадык, хәзрәт. Туксан тугыз алтын.

Ахун. Туксан тугызмы? Алайса, ул Насретдинга тимәде. Бирегез монда.

Хуҗа (*сузылган янчыкны үзенә алып*). Тулмаганмыни? Туксан тугызны биргән Алла берне тагын бирер әле. (*Куенына тыга.*)

Ахун. Тукта, тукта, кая алып салдың? Кая антың? Антыңа хыянәт иттең!

Хуҗа. Хыянәт итсәм, Аллага хыянәт иттем, синең ни эшең бар?

Колый. Ә менә шундый эшебез бар. Ул Бики байныкы!

Хуҗа. Бики байныкы? Мин Бикидән алтын түгел, югалган ишәгемне дә сораганым юк...

Ахун, Колый, Бикиләр халык көлкесе астында кысылып сәхнәдән чыгалар. Гомуми көлү, шау-гөр белән сәхнәдән чыгып бетәләр. Алчын килеп керә. Арттан Сәхилә карчык кереп аларны күзәтә.

Хуҗа (*суза*). Тот, Алчын! (*Янчыкны бирә.*)

Алчын (*алып*). Миңа? Алтын? Тукта!

Хуҗа. Кулыңда бер алтының бармы? Шуны куш та кызыңа йөгер!

Алчын китә. Бики, Колый, ахун, ике сакчы керә.

Колый. Менә ул! Тентегез үзен!

Сакчылар Хуҗаны тентиләр.

Юк? Кайда алтын?

Хуҗа. Биргән Ходай алган.

Колый. Җәмәгать! Менә күрегез: минем югалган хәлләм аның өстендә! Тотылдың, Насретдин! Әйдә казыйга, бер кат тирең минеке!

Колый (*сакчыларга*). Алыгыз үзен!

Хуҗа, аның артыннан ахун, Бики һәм башкалар чыга.

Эчке пәрдә төшә

Сәхилә, Алчын кара-каршы очрашалар. Икенче башта Дәрвиш Сәхиләдән садака алып кала.

Алчын. Ах, бу синме? Мә! Тот йөз алтын, карчык! Зөбәрҗәт минеке!

Дәрвиш (*үзалдына*). Зөбәрҗәт?

Сәхилә. Алтын? Син акрын! Тирә-якта шымчылар йөри. Мин аны сиңа көндез бирә алмыйм, кич кил: ай туып, сөнге буе калыккач!

Алчын. Ай туып, сөнге буе калыккач! (*Уң яктан чыгалар.*)

Дәрвиш. Зөбәрҗәт табылды! Күрербез кем алдан җитешер. Очтым Җиһангир хәзрәтенә! (*Китә.*)

2 нче сәхнә

Эчке пәрдә күтәрелә. Төн. Хуҗаның өйалды. Ай яктысы. Урамнан Хаммат керә, көбә[1] кигән.

Хаммат (*тәрәзәне шакый*). Сәлви!

Сәлви. Хаммат? (*Аскы ишектән чыга.*) Бу синме? Нишләп син көбә кидең?

Хаммат. Мин кигән идем, хәзер сиңа киярге туры килә. Хәзер генә Җиһангирның баскагын бистә юлында күргәннәр... Сине җария итеп тотып алып китәргә булмасын! Шуның өчен син хәзер шушы көбәне киярге тиешсең! Мин синең киемнәрне киенәм.

Сәлви. Минем урынга сине тотып алып китсеннәрме? Кирәкми!

Хаммат. Мин ир кеше. Бер җае чыгу белән, качтым-киттем.

Сәлви, Хаммат кереп китәләр. Гөлбану чыга.

Гөлбану. Кемнәр белән алыша бит үзе, ә? Хәерче! Шулай ук башы бөтенләй олагыр микәнни моның, тилчәнең? Әле тагы

---

[1] Көбә — сугышчы киеме.

дивана сыңары булса да, ярап та куя иде үземә! Тук булмаса да кайгысы да юк иде. Кирәк булса, мәхәббәтле дә була иде бит, каһәр тигән!

Бер төркем гаскәре белән Гыймай баскак керә.

Гыймай (*команда бирә*). Атлар, шунда кал! Гаскәр, алга! Һу-лә-лә-лә! Урагыз! Һәйт, вайт! Гаскәр! Үрә кат! (*Сәхиләнең капкасын кага.*) Әй!

Сәхилә тавышы. Кем ул анда? Алчын, синме?

Гыймай. Мин, мин! Ач!

Сәхилә (*ачып чыгып*). Ә? Бу кем?

Гыймай. Аһа! Әләктең, карчык? Кайда жарияң? Бәйләгез үзен! Алып чыгыгыз кызын.

Берничә кешесе Сәхиләләргә кереп китә.

(*Гөлбануга килә.*) Син кем хатыны?

Гөлбану. Кирәкми! Килмәгез! Мин Насретдин хатыны!

Гыймай. Ә, син Насретдин хатынымыни? Шулмы синең өең? Басыгыз ишеген!

Ишеккә басалар. Аларга каршы эчтән кылыч уйный.

Кама, туна, һу-лә-лә-лә! Алыгыз кызын!

Сәлви көбә кигән, ишеккә аркылы егыла. Сәлви киемендәге Хамматны өстерәп алып чыгалар. Хаммат аларны очырып-очырып җибәрә.

Гыймай. Алыгыз җәтмәгә! Бер кызны җиңә алмыйсызмыни?

Хамматны алып китәләр, Сәхилә капкасыннан бәйле Зөбәрҗәт белән Сәхилә чыгарыла.

Зөбәрҗәт. Җибәрегез, җибәрегез! Мин илбасарга жария булмыйм!

Чыгалар. Алчын керә.

Алчын. Ә Зөбәрҗәт? Капка ватылган? Өй таланган! Ах, ах! Аларны алып киткәннәр!..

Гөлбану (*тез өстендә*). Сәлвиемне алып киттеләр! Хуҗамны алып киттеләр! Өемне туздырдылар! Аһ, аһ!

Алчын (*Сәлвигә*). Нишлибез, Хаммат?

Гөлбану (*Сәлвине Хаммат дип белеп, селкеп*). Йә, нишләп торасың җебеп, уҗым бозавы! Кыз сөя торган егетләр, имеш! Сезгә барган кыз! Барам үзем шул Җиһангир алдына да егылам аягына...

Пәрдә

Өченче пәрдә

Болгар шәһәрендә казый диванханәсе[1]. Артта рәшәткә. Болгар манаралары күренә.

Хуҗа, Колый тархан, Бики, саңрак казый Низамый керәләр.

Низамый. Вәгаләйкемәссәлам! Болгар йортындагы хөкем мәҗлесен ачык дип игълан итәм. (*Алга чыккан Бикине күреп, аңа.*) Хуш?

Бики. Шушы Хуҗа дигән кеше былтыр миннән вакытлы файдаланырга җир алып чәчте, әле булса түләгәне юк. (*Кәгазь суза.*)

Низамый (*шартнамәне карап*). Ник түләмисез, Насретдин әфәнде?

Хуҗа. Мин түләмим дигәнем юк. Каян чыгарган ул? (*Бикигә.*) Күпме бурычлы соң мин сиңа?

Бики. Илле өч сум.

Хуҗа. Соң шулай диген аны. Иртәгә егерме биш, аннан иртәгә тагын егерме биш сумын бирсәм, күпме кала тагын?

Бики. Өч сум.

Хуҗа. Соң шулай булгач? Өч сум өчен минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы?

Колый. Кара, кара, ни ди ул?

Бики (*гаризаны биреп*). Менә казый хәзрәт, шуның өстенә ул минем туксан тугыз алтынымны алды. Йөздән ким булса алмыйм дип ант итте, без, аны сынар өчен, туксан тугыз алтын санап алдына ыргыттык. Ул аны алып антына хыянәт итте. Шәригать буенча хәзер йөз таяк орып, шул бурычым белән алтынымны алып бирегез, тәкъсир.

Низамый. Димәк, туксан тугыз алтын синеке?

Бики. Янчыгына чаклы минеке. Мин анысын да бер алтын биреп алдым.

Хуҗа. Мин шул янчыгы белән йөз алтынга хисаплап алдым да аны. Мин ничек антымны тотмаган булам?..

Низамый. Әстәгъфирулла! Антын да тоткан, алтынны да шуыткан. Беленде: бу адәм авызыннан шайтан сөйли, артында шайтан тора.

Хуҗа (*казый янына килеп, колагына*). Каһәр суккан шул шайтан, артымнан гына килә дә шушы минутта өстемдәге

[1] Диванханә — хөкем иту йорты.

бикасапны[1] сиңа салып бирергә куша, казый хәзрәт... (*Бикасапны алдына куя.*)

Низамый (*тотлыгып*). Ә... Әйе... Әллә нигә бер генә шайтан сүзен тыңлап кую да ярый шул. Мәгълүм булды, җәмәгать! Бу бер дивана адәм, имеш. Аллаһе Тәгалә, бер хак дивананың догасын кабул итеп, аңар алтын индергән булса, ни гаҗәп!

Бики. Ничек? Сез шушы ялганчының сүзенә ышандыгызмы?

Хуҗа. Ул үзе ялганчы, казый әфәнде. Ул әле оялмас, шушы бикасапны да үзенеке дияр.

Бики. Әлбәттә, минеке.

Хуҗа (*казыйга*). Менә күрдегезме? (*Бикигә.*) Болай булса, син әле минем менгән ишәгемне дә үзеңнеке диярсең. Оятың җитсә, әйт!

Бики. Ишәкме? Ул да минеке!

Хуҗа. Менә күрдегезме нинди адәм белән эш итәсез?

Низамый (*Бикигә*). Җитте! Синең бер ялганчы адәм икәнең мәгълүм булды. Син аның диваналыгыннан файдаланып, бөтенләй көпә-көндез суярга җыенган адәм икәнсең. Синең үзеңә йөз таяк лазем булды. Хөкем тәмам. Сезнең ни гаризагыз бар, тархан?

Хуҗа. Тарханны монда мин алып килдем. Утын китергән өчен миңа бирәчәге бар иде, тәкъсир.

Колый. Кара, кара, син алып килдең? Тора тор! Иң элек җавап бир әле син, өстеңдәге хөллә кемнеке?

Хуҗа. Менә хөлләгә дә ия табылды. Синекемени ул, тархан?

Колый. Син аны урладың! (*Казыйга.*) Өстеннән хөлләмне салдырып бирегез дә шәригать буенча кисегез шул угрының кулын!

Хуҗа. Яхшы кара. Ялгышмыйсыңмы?

Колый. Үзе! Менә Бики шаһит. Кара чабуларын! Төймә бавын! Валлаһи минеке!

Хуҗа (*гаҗәпләнеп*). Алай булгач, ул тирес чүмәләсе өстендә йоклаган исерек син буласың?

Низамый. Сөйлә, Насретдин. Каян килде сиңа бу хөллә?

Хуҗа. Шулай, без беркөн Хаммат белән кайтып киләбез. Безнең борынга әллә каян бик сасы бер ис килә. Елга башында тирес түгелгән. Хаммат әйтә, әнә тирес өстендә үләксә ята, шуннан бу ис, ди. Янына барсак, тирескә борынын төртеп берәү йоклап ята. Үзе исерек. Янындагы агачка шушы хөллә эленгән...

---

[1] Бикасап — ефәк кием.

Низамый. Хуш, син аның кем икәнен танымадыңмы?

Хуҗа. Танырга бит, аның йөзе адәм карагысыз! Бите әллә нәрсә! Черегән йомырка бәреп киткәннәр аңа, казый хәзрәт. Тор, мин әйтәм, нәҗес. Көпә-көндез шулай ятарга ничек оялмыйсың? Шулай дип моның артына бер типтем, уянмый. Тукта, мин әйтәм, бу дуңгызның хөлләсен алып китәләр бит, иясе сорау белән кайтарып бирермен дип, алып киттем. Син идеңмени ул? Мә, ал хөлләңне.

Колый. Юк, тукта... Ялгышмыйммы? (*Карый.*) Бу минеке түгел. Карале, менә син!

Хуҗа. Кара чабуларын! Төймә бауларын! Тотып кара!

Колый. Әйттем бит, бөтенләй минеке түгел! (*Читкә.*) Менә каһәр суккыры. Кулым белән тотам, ала алмыйм.

Низамый. Яхшы. Тынычлап киегез, Хуҗа. Сез, тархан, хәзер аның бурычын түләгез, аннан, ялган сөйләгән өчен, ун алтын салым түләгез.

Колый. Аңамы?

Низамый. Юк, миңа. Аннан гафу үтенегез! Башка гарызлар юкмы? Хөкем тәмам! (*Хуҗаның иңсәсендәге бикасапны тотып куеп.*) Бикасап — минеке! (*Китә.*)

Хуҗа. Синеке, синеке. Ястүдән соң әтәч азан әйткәч тә, килеп алырсың! (*Китә.*)

Колый. Тот әле, тот! Ханнар белән бер табактан ашаган Колый тарханмы мин. Үз кулым белән шул кара сөяккә ялына-ялына хөлләмне бирдемме? Мин хан нәселеннән! Гариза язып Җиһангир хәзрәтләренең үзен күрәбез. Кая соң анда, ни пешерде ахун?

Бики. Ул гына Хуҗа өстеннән Җиһангирга сөйләп анда бер эш тә чыгармаса? Тукта, менә бит үзе килә.

Ахун. Ай-яй-яй-яй! Һәлак булдым мин, һәлак булдым!.. (*Килеп керә.*)

Колый. Әйт тиз: шул этнең башын кисәргә куштымы, юкмы? Ник дәшмисең?

Ахун. Әйттем, ул да түгел, фил, фил!

Колый. Фил? Нәрсә, син шул мәхәлләңә ярыйм дип, әллә фил турында сүз әйттеңме?

Ахун. Үзе сорады, мин әйттем; әйтүемә йөзе кап-кара киселде. Алай булса, менә мин сиңа өч мәсьәлә бирәм, көн батуга, килеп җавап бирерсең; бирә алмасаң, башың (*ышкып күрсәтә*) кых! диде.

Колый. Өч мәсьәлә дисең? Нәрсә, нәрсәләр?

А х у н. Җирнең уртасы кайда? Шуннан Җиһангир хәзрәтләре сакалын учлап тотты да, шушы сакалымда ничә бөртек йон бар? дип сорады. Әйт, Бики: ничә бөртек?

Б и к и. Әйе, диванага алтыннарымны бирдем дә, инде синең белән Җиһангирның сакалын санарга калдым!

А х у н. Өченчесе шул, диде, минем ялгыш уемны күрсәт, диде. Әйт: моңа ни дип җавап бирим мин?

Б и к и. Мин сәясәткә тыгылмыйм.

К о л ы й. Гариза яз, өстеннән Җиһангирга җибәрәбез.

Б и к и. Күрмисеңмени, кара җәяүгә калдым! Ике йөз алтын ул! Яз!

К о л ы й. Калдыр аны, җавабын уйлый торсын, бер гариза яздырып алырбыз, ул кул гына куяр, әйдә.

Чыгалар.

А х у н (*ялгыз*). Хуҗа килә. Шул дошман аркасында бу бәлагә тарыдым. Әгәр дә мин бу сорауларны аңа биреп карасам, ә? Сиздермичә генә? Әйтсен дивана! (*Нидер эзләгән була.*)

Х у җ а (*янына килеп, шулай ук каранып*). Ни эзлисең?

А х у н. Мин әйтәм, бу җирнең уртасы кайда икән, дим... Менә әле синең сакалыңны күргәч бер уй килде: ничә бөртек йон бар икән?

Х у җ а. Ярый, мәсьәлә бит гадәттә өч була. Өченчесен дә ишетик.

А х у н. Өченчесе: менә син әйт: минем ялгыш уем нәрсә?

Х у җ а (*читкә*). Уйлаган идем аны: аңа бу мәсьәләләрне Җиһангир биргән дип! (*Аңа.*) Синең ялгыш уеңны әйтергәме? Менә син, хәзер бу дивананы юмалап өч мәсьәләгә җавап алыйм да Җиһангирга шуларны әйтеп котылыйм, Хуҗа моны сизми дә калыр, дип уйлыйсың.

А х у н (*алдына тезләнә*). Инде үзең барысын да беләсең, коткар мине Хуҗа Насретдин әфәнде!

Х у җ а. Ярый, мин сине коткарырмын, ләкин син элеккеге кебек һаваланмассыңмы? Минем белән булышмассыңмы?

А х у н. Бетте, җизнәм, бетте!

Х у җ а. Ярый, алай булса, сал чапаныңны! Инде чалмаңны да салып бир!

А х у н. Ә, юк, булмый... Җиһангир хәзрәтләре янына ничек барыйм мин. Түбәтәй беләнме?

Х у җ а. Аңа син бармассың, мин барырмын.

А х у н. Минем өченме?

Хуҗа. Нишләп синең өчен йөрим ди мин? Илем өчен: тимерчелеләр аңа сине илче итмәделәр, мине илче иттеләр.

Ахун (*чалманы сала*). Тфү, тфү! Пәригә яулык, миңа саулык! (*Алга узып, бер Хуҗага, бер халыкка карап.*) Әләктеңме, ахмак?! Ул гына җитмәсә, без менә хәзер Бики байлар белән бергә бик һәйбәтләп синең өстеңнән кем икәнлегеңне язып менгезик. Беттеме башың?

Пәрдә

Дүртенче пәрдә

Тәхет залы. Уртада тәхет. Сул яклап килеп сакаллы, тунлы вәзирләр чыгып баса. Уң яклап килеп кызлар — җарияләр чыгып утыра. Озын буйлы баш вәзир Зәйнәгый чыгып, дөя шикелле сикертеп атлап, барысына да тиз генә күз салып туктый. Түпке ишектән Җиһангир килеп чыга. Башында очлы мех бүрек-таҗ, өстендә ас якалы, кыйммәтле, җиңсез тун. Аны күреп бар да иелгән килеш кала. Җиһангир тәхеткә аяк бөкләп утыра. Татар сакаллы, каты чырайлы, кара кеше.

Җиһангир. Әйтче, вәзир: бармы бу илдә, ичмасам, күңел ачардай бер кеше?

Зәйнәгый. Монда, Тимерчедә, Хуҗа Насретдин дигән бер көлке дивана бар икән, ишеткәнсездер. Кызы ифрат дәрәҗәдә гүзәл, имеш...

Җиһангир. Мин ул кызны тотып китерергә баскагыма боердым. Хәзер Насретдин тотып китерелсен! Әгәр дә ул чын дивана булмыйча, юри генә диванага салынган булса, башы шул урында өзеләчәк!

Хуҗа кереп баса, сакчылар аның юлына соңге тоталар.

(*Ачуын көчкә тотып.*) Рөхсәтсез минем сараема керәләрме?

Зәйнәгый. Кем син?

Хуҗа. Җиһангир хәзрәтләренең боерыгы буенча, кояш батуга килеп җитүче.

Җиһангир. Һа, алай булса, бу теге... ахун? Филемне алдырырга йөрүче? Алай!.. Мин куйган өч мәсьәләнең өчесенә дә җавап бирергә килдең инде син? Беренчесен әйт аңа, вәзир.

Зәйнәгый. Җирнең уртасы кайда?

Хуҗа. Әнә капкада минем ишәгем тора. Чык та шуның уң арт аягын күтәреп кара. Тояк эзе кайда булса, җирнең уртасы тап шунда.

Җиһангир (*гаҗәпкә калып*). Ничек? Тукта? Ышанмыйм!

Хуҗа. Ышанмасаң үлчә. Әгәр бер ягыннан бер ягы артык яки ким чыкса, аннан соң сөйләшербез.

Җиһангир. Карагыз әле моны! Ишәк тоягы, ә? Икенче мәсьәлә ни иде, вәзир? Менә минем сакалымда ничә бөртек йон бар?

Хуҗа. Шул ишәгемнең койрыгы бик пычрангач, мин аны кисеп алган идем... (*Кесәсеннән чыгара.*) Менә шул койрыкта ничә бөртек йон булса, синең сакалыңда да шулчаклы йон бар.

Җиһангир. Ишәк койрыгы?.. Нәрсә сөйли ул, ахмак? Мин моның белән килешә алмыйм!

Хуҗа. Килешмәсәң, моннан бер төк, синнән бер төк йолкып, санап карыйк! Нәкъ шулай булмаса, башымны кисәргә бирәм!

Җиһангир. Ярый. Син боларыннан котылдың, ләкин синең алдыңда өченче сорау бар: күрсәт, минем ялгыш уем нәрсәдә?

Хуҗа. Менә шул мине Тимерче ахуны дип уйлавың үзе ялгыш инде, тәкъсир. Мин үзем ахун түгел, мин шул бистәнең Хуҗа Насретдин дигән кешесе буламын. (*Чалмасын сала.*)

Җиһангир. Хуҗа Насретдин! Тукта! Ничек? (*Килеп карый.*) Чынлап та ул түгел! Мин бу кешене беренче күрәм!.. Ничек мин моның башта ук ахун түгел икәнен белмәдем соң?

Хуҗа (*сыгылып торган вәзирне күреп алып*). Ул шуның өчен: сезнең алдыгызда, гадәттә, тиешеннән артыграк иеләләр, шуңа күрә сез аларның йөзләрен күрми каласыз.

Җиһангир (*үзалдына*). Ю-ук-к... Бу дивана түгел! (*Хуҗага.*) Ярый, ләкин син бу кыюлыкны өстеңә алган кеше булгач, ахун урынына безгә илче дә булып килгән буласың. Хуш! Сөйлә: безнең Тимерчедәге ата филебез исәнме? Халык ашату авыр-фәлән дип зарланмыйлармы?

Хуҗа. Бик зарланалар, тәкъсир. Бер дә риза түгел!

Җиһангир (*кылычын тотып*). Ничек риза түгел?

Хуҗа. Ничек риза булсын, бер генә фил ич ул. Берүзенә генә күңелсез ич аңа, эче поша. Менә инде ул ата филнең янына тагын бер ана филеңне дә җибәрсәң, бер мәрхәмәтең урынына, ике мәрхәмәтең булыр иде, диләр.

Җиһангир. Һай, шулай дисеңмени әле син? Безнең биредәге ана филебез дә бик пошына башлады. Әллә бу җирнең һавасы килешмәде. (*Хуҗага.*) Ни кәсептәге кеше син?

Хуҗа. Игенче.

Җиһангир. Әйтче, синеңчә, кем зуррак: игенчеме, патшамы?

Хуҗа. Әлбиттә, игенче. Игенче патшасыз тора ала, менә патша игенчесез торып карасын!

Җиһангир. Миңа кара, Хуҗа. Мине сатсалар, күпме бирер идең син миңа?

Хужа. Сиңа бирергә? Кара син аны! Һаман мин бирим! Үзең ни бирәсең соң миңа?

Зәйнәгый (*акрын*). Сез аңа билегездәге кәмәрне вәгъдә итегез дә, ул ни бәя бирсә дә, дөрес түгел диегез, кәмәр үзегездә калыр.

Җиһангир (*кәмәрен чишеп, Хуҗага*). Син минем бәямне дөрес җиткереп бирсәң — бу сиңа. Күпме торам мин?

Хужа (*карап, чамалап*). Җиде йөз алтын.

Җиһангир. Тинтәк! Ә минем бар кигән киемнәрем генә җиде йөз алтын тора.

Хужа. Кәмәр минеке. Мин аны синнән отып алдым.

Җиһангир. Син минем киемнәремә генә җиде йөз бирдең бит әле. Мин үзем күпме торам соң?

Хужа. Үзең? Үзең син бер тиен дә тормыйсың, тәкъсир. (*Кәмәрне бәйли.*)

Җиһангир (*Зәйнәгыйга*). Аллаһе әкбәр! Киңәшеңә рәхмәт! Китте кәмәр! Ләкин мин дәүләт билгесе булган бу кәмәрне аңа бирә алмыйм, ничек кире кайтарып алырга соң?

Зәйнәгый. Башка нәрсә белән алыштырасыз гына.

Җиһангир. Алыштырып карыйк... (*Хуҗага.*) Һай, мин ашыга төшкәнмен, бу әманәт кәмәр икән, Насретдин. Ни теләсәң, аны сора, ләкин моны калдыр.

Хужа. Сорамас идем инде, ачуыгыздан куркам, күңел өчен генә сорасам сорыйм инде, алайса: бер генә көнгә миңа шушы тәхетеңне бирерсең!

Җиһангир. Тәхетемне? Сиңа? Синең хан булып карыйсың киләмени, һәй байгыш? (*Зәйнәгыйга.*) Кызык, нишләр иде икән ул хан булса? Тәкъдир үзе бирде бу кызыкны! Бүген бу дивана белән ял итәсем килә минем. Нишли ала ул? (*Хуҗага.*) Ярый, мин сиңа бер генә көнгә тәхетемне бирергә булдым, ләкин гаскәремнән башка.

Хужа. Вәгъдә? Игълан ит!

Җиһангир. Әй! (*Ишарә бирә.*)

Вәзирләр керәп, тәхет каршына тезләнеп утыралар.

Гаскәри эшем белән мәшгуль булуым сәбәпле, сәфәр аеның дүртенче киченнән таң Чулпаны калыккангача, гаскәремнән башка, барлык тәхет-хөкем эшләрен бу илнең хәким кешесе Хуҗа Насретдинга тапшырдым. Аның барлык әмерләрен минеке шикелле җиренә җиткерергә! Хуп! (*Таҗын Хуҗага салып бирә. Хуҗа, кәмәрне биреп, таҗны кия. Җиһангир Зәйнәгыйга акрын*

гына.) Син аның барлык хәленнән миңа хәбәр биреп торырсың!.. (*Чыга.*)

Зәйнәгый. Тынлык! Насретдин хан сезгә беренче ярлыгын боера.

Хуҗа. Сүзем: Тимерчедәге безнең ата филебез, биредәге ана филебезгә бик каты гыйшык тотып, койрыгыннан саргая башлаган икән, бөтенләй сарыга сабышмасын өчен, ашыгыч рәвештә бирегә, сөеклесе янына кайтарылсын! Мин беттем. Барыгыз!

Вәзирләр ашыгып чыгалар. Ишектә тавыш.

Ул ни анда тагы?

Ахун, Колый тархан һәм Бики, җирдән тезләре белән үрмәләп, тәхет алдына киләләр.

Хуҗа, таҗын артын алга киеп, чугын битенә төшерә.

Ахун (*кәгазь тоткан кулын күтәреп*). Сезгә гаризабыз бар иде, тәкъсир. (*Аңа суза.*)

Хуҗа (*аягы белән тибәреп*). Телдән генә сөйлә.

Ахун (*еламсырап*). Бисмиллаһи, хан хәзрәтенә мәгълүм булсын, илебездә бер бәдбәхет, динсез адәм заһир булды. (*Елый.*) Шул! Бер дә чыдар хәлебез калмады... Имамнардан көлә! Сезнең затыгызга тел тидерә! Халыкны котырта!

Колый. Ул бурычын түләми, ялган ант итә. Угры ул, тәкъсир.

Бики. Бик яман, бик бозык фигыльле кеше. Хөкемне алдалый ул, тәкъсир.

Хуҗа. Кара син явызны. Ни атлы соң ул?

Ахун. Аның аты — Хуҗа Насретдин.

Хуҗа. Әнә чатта җәмәгать коесы бозылган. Халык суга интегә. Хөкем сезгә шул: намуслы кеше өстенә яла ягу, әләк, гайбәт белән шөгыльләнгәнегез өчен дүртегез дә бүген кырыгар чиләк су чыгарып шул коены әрчеп, тазартып эшкә кертегез.

Зәйнәгый. Эшләрен тәмам иткәч, нишләтергә кушасыз?

Хуҗа. Сакалларын кыркып, өйләренә кайтарып җибәрегез! (*Йөзен ача.*)

Зәйнәгый. Мәрхәмәт ит, Насретдин хан!

Ахун. Насретдин хан?..

Бики. Сөбханалла!

Аларны сакчылар алып чыгып китәләр.
Еракта халык гүләгән тавыш.

Хуҗа. Ул ни анда, вәзир?

Зәйнәгый. Халык кычкыра, хан!

Хуҗа. Кычкыра, димәк, бугазлары буш. Икмәк амбарларын ачыгыз!

Зәйнәгый. Алар сездән кием дә сорыйлар, тәкъсир.

Хуҗа. Өләшегез соң...

Тыштан «Яшәсен Насретдин хан!» дигән хор ишетелә.

Хуҗа. «Яшәсен» диләрме? (*Тәрәзәгә.*) Җәмәгать! Теләкләрегезне кабул итеп, үлгәнче яшәргә булдым! Тынычлап кайтып китегез.

Гөлбану, Хаммат киемендә Сәлви керә.

Гөлбану. Кара син аны, нинди мәһабәт! Чынлап та, үземе соң ул? (*Якын килә.*) Синең өстеңдә шундый кием...

Хуҗа. Киемгә карама син, үземә кара: мин һаман шул Хуҗа Насретдин.

Гөлбану. Мин сине үз гомеремдә дивана дип күп рәнҗеттем шул. Син мине гафу ит!

Хуҗа. Әйе. Әлегә чаклы мин дивана идем, хәзер син дивана.

Гөлбану. Мин сине элек ничек белмәгәнмен! Сиңа тәхеттә утыру шундый килешә. Үзең шундый акыллы!..

Хуҗа. Моңарчы тәхеттә утырмаганга гына юләр Хуҗа Насретдин булып йөргәнмен икән. Тукта, Гөлбану бикә, менә хәзер син дә ханчалар киемен киярсең, дөньяда синнән дә акыллы, синнән дә гүзәл хатын тапмаслар! Әйдә, мин сиңа бүлмәңне күрсәтим! Киемнәреңне алыштыр. (*Гөлбану белән чыга.*)

Сәлви, соңыннан Хуҗа керәләр.

Хуҗа (*ишекне ябып*). Хаммат! Син биредә берүзең генәме?

Сәлви (*йөзен ачып*). Әти!

Хуҗа (*Сәлви икәнен күреп*). Кызым? Һай!

Пәрдә

Бишенче пәрдә

Шул ук сарай.

Хуҗа, аның артыннан Хаммат киемендә Сәлви керә.

Сәлви (*йөзен ачып*). Әти! Мин кыл өстендә йөрим! Уф!.. Минем йөрәгем чыга! Тизрәк Хамматны тап, әти! Хәзер бит аны минем урыныма Җиһангирга тотып бирәләр!

Хуҗа. Җиһангирга? Хамматнымы?

Сәлви. Әйе, әти. Мин барын да ишетеп тордым: хәзер Зөбәрҗәтне синең кулың белән үлемгә хөкем итеп, мине Җиһангирга бирәчәкләр. Аннан соң синең шәрабыңа агу салынган. Йә? Хәзер нишлибез Хамматны?..

Хуҗа. Һай, кызым, Хамматның башы синең телеңдә, син үз телеңә баш бул, тор шунда!

Зәйнәгый, җарияләр, Алчын һәм сарай кешеләре кереп тула.

Зәйнәгый. Сезгә җарияләрегез сәламгә киләләр, хан!

Хуҗа. Бу чаклы җарияләр биредә ни эшлиләр соң, вәзир?

Зәйнәгый. Алар сезнең сараегызның бизәге. Сезнең кәефегез өчен хезмәт итәләр, хан.

Хуҗа. Мин, күрәсез, болай да бик кәефле. Тагы ни эшлиләр?

Зәйнәгый. Матур җырлап бии беләләр, хан.

Хуҗа. Шулай дисеңме? Ярый алай булгач, бу җарияләрне Тимерче бистәсенә илтегез, халыкка биесеннәр.

Ак җария. Ай, алар биюне эшкә санамасалар, безне кунак та итмәсләр.

Хуҗа. Эшкә санамаса, казна амбарына төшеп йон тетәрсез.

Җарияләр. Ай, без йон тетә белмибез!

Хуҗа. Белмәсәгез, менә баш вәзир өйрәтер. Бистәгә дә сезне ул алып барып биетер. Барыбер аның бүтән эше юк.

Зәйнәгый (*үзалдына*). Һай, моның кулына калсаң! Үземне дә халыкка чыгарып биетер бу ахмак!

Зөбәрҗәт белән Сәхилә сак астында керәләр. Икенче яктан Алчын кереп баса. Бер кулында айбалта, биләгендә камчы.

Хуҗа. Ә!.. Сәхилә карчык!

Сәхилә. Аллаһе Тәгалә озын-озын гомерләр бирсен сиңа, Насретдин хан!

Хуҗа. Алласын Алла да, минем Алладан сорап алган йөз алтын ничек сиңа барып кергән, чыгарып бир әле шуны, карчык.

Сәхилә (*куенынннан янчыгын чыгарып, Хуҗага алып килә*). Мә!

Хуҗа. Шул җәлладның туй чыгымына дип Ходайдан алган акча ул. Бир аңа!

Сәхилә (*карганып, янчыгын Алчынга ыргыта*). Күргәнеңкүрмәгәнең...

Хуҗа (*аяк тибеп*). Җавап бир: ни өчен син адәм сатып көн итәсең, карчык?

Сәхилә *(үрмәләп килә-килә)*. Һай, ничек итим соң, балам? Мин бер карчык кына кеше инде. Ирем дә юк. Менә син хан кеше, миңа бер ир табып бир, мин дә җария белән сату итмәм.

Хуҗа. Әйе, бүтән эш бетте, сиңа ир табып бирәсем генә калды.

Ахун, тархан, Бики, Низамый *(элсерәп керәләр)*. Зәйнәгый, соңыннан сачтараш.

Зәйнәгый. Коены тазартып кайттылар, хан! Сезнең фәрманыгыз буенча, хәзер сакаллары кыркылырга тиеш.

Колый. Хатыннарым хакына сакалымны калдыр, хан!

Хуҗа. Хатының бик күпмени соң синең?

Колый. Өч кенә, тәкъсир.

Хуҗа. Тагын берне әйттерергә исәп бармыни?

Колый *(ахунга)*. Илтифат күрсәтә ич бу! Файдаланып калыйк! *(Хуҗага.)* Ник исәп булмасын?

Ахун. Йа хан! Безгә дә дүртенчегә берәр җарияне рәхим итсәң...

Бики. Инде үз кызыгызга өйләнү безгә насыйп булмагач...

Низамый. Мәңге синең догачың булыр идек!

Хуҗа. Һай, яшь йөрәкләр! Барыгыз да дүртенчегә өйләнәсегез киләме? Хәзер табам мин сезгә. *(Дәшеп.)* Сәхилә карчык! Ир кирәк, дидең. Йә? Син боларның кайсына барыр идең?

Сәхилә. Боларның кайсы алса да барыр идем.

Колый. Колый тарханга Сәхилә карчыкны дисеңме? Ә, юк, тукта!..

Хуҗа. Мин сиңа гына димим, дүртегез дә өйләнерсез. Хөкем тәмам. Дүртегезгә бер карчык, теләсә ничек бүлешегез. Сачтараш! Кыз катына керүдән элек кияүләрнең сакалын бик һәйбәтләп кырып җибәр.

Колый. Аңладым. Менә нәрсә ул баба шулпасы!

Торып кача башлый, җилкәсенә Сәхилә карчык ташлана, бар да кача, артларыннан — кайчылы Хәйбүш. Алчын аларны камчы белән куа, алар: «Карчык сиңа, сиңа!» — дип дәгъвалашкан хәлдә чыгалар.

Хуҗа. Бу нинди кыз?

Зәйнәгый. Җиһангир хәзрәтләреннән баш тартып качкан җария шул инде. Сезнең хөкемегезгә тапшырыла.

Хуҗа. Ах, оятсыз! Калачны камчыга алыштырасың? Бу тәрбиясезлегең өчен, син иң югары җәзага лаек булдың! Җәллад! Кулыңда камчы. Ор үзен!

Алчын. Чык, кызый! Җәзага хәзерлән! *(Камчысын шартлата.)* Ничек боерасыз, тәкъсир.

Хужа. Иң каты буу белән буып үтерергә! Биленнән!

Зөбәрҗәт. Алла, билем! Явыз-җәллад! Син мине... билемнән бусаң, мин сине бугазыңнан буыйм. Ах! (*Муеныннан коча.*) Аһ! (*Алчынның билгәгенә авып төшә.*)

Алчын. Ул... үлде!

Хужа. Күрше бүлмәгә чыгарып ташла!

Алчын Зөбәрҗәтне күтәреп чыгып китә.

Зәйнәгый (*үзалдына*). Рас та үлүе шул булдымы?.. Гаҗәп!..

Сәлви киемендә Хаммат кертелә.

Хужа. Һәй, кызым Сәлви килә! Кил, кил, сөйлә, кызым, ни хәлең бар?

Сәлви. Әһем!

Хужа. Яхшы, синең тәхет каршындагы хезмәтләрең безгә мәгълүм. Әгәр дә кыз үзе риза булса, мин сезнең никахыгызга каршы түгел. (*Хамматка.*) Йә кызый, Хаммат синең кулыңны сорый, ризамы син?

Хаммат. Риза!

Ахун чабып керә.

Ахун. Коткарыгыз! Аһ, аһ! Алмыйм мин ул карчыкны, Насретдин!

Хужа. Ярар, алмасаң, алмассың. Кая ике яшькә никах укып бир әле. Менә үзләре утыра. Егет бара, кыз ала.

Ахун. Сәлвиме? Ай, юк, укый алмыйм. Сәлвине Җиһангир хәзрәтләре боерыгында дип ишетәбез.

Хужа. Сачтараш!

Зәйнәгый. Чынга китте бу. Җиткерим! (*Чыга.*)

Ахун. Гафу боерыгыз, Насретдин хан! Мин укыйм... Бисмилләһи ррахман иррахим! Әлхәмде лиллаһ илләзи фәтарәл адәме...

Хужа. Ике шаһит кул куегыз! Бирегез монда кәгазьне!

Гөлбану керә.

Гөлбану. Никах! Миннән яшерен нинди никах бу?

Хужа. Менә кызыбызны Хамматка биреп ташладык ич.

Гөлбану. Ничек? Җиһангир хәзрәте үзе безнең киявебез булырга торганда...

Хужа. Тукта, хатын, чәпчемә, утыр әле яныма! Монда Җиһангир түгел, мин хан!

Зәйнәгый килеп керә.

З ә й н ә г ы й (*Сәлви белән Хамматның тоташкан кулларын өзеп*). Сәлви туташ — олуг Җиһангирның җариясе. Аны никахлау мөмкин түгел! Шул минут эчендә олуг Җиһангир гүзәл Сәлвине үзенә чакырта.

Х у җ а. Җиһангир хәзрәтенә гүзәл Сәлви кирәкме? Әнә ул! Алыгыз! (*Хамматны аңа табан этеп җибәрә.*)

Хаммат Зәйнәгыйның куенына барып кереп, йөзен ача.

З ә й н ә г ы й (*куркып*). Мыеклы? Сакаллы?

Г ө л б а н у (*шаккатып*). Карагыз моны! Бу минем кызым түгел! Ах!

Х у җ а. Чынлап та, ә? Моның сакалына чәч үскән!

З ә й н ә г ы й (*төшенеп*). Үскәнме? Әһә! Бу — Җиһангир хәзрәтенә хыянәт! (*Ашыгып чыга.*)

Х у җ а (*кызу-кызу йөри*). Эләктем! Бар да бетте! Нишләргә?

Г ө л б а н у. Күрдеңме менә үзеңнең шыр дивана икәнеңне? Күрдеңме?

Бер яктан А л ч ы н, З ө б ә р җ ә т, Г ө л б а н у, икенче яктан С ә л в и белән Х а м м а т керәләр. Тояк тавышлары.

Х у җ а. Менә киләләр!

Г ө л б а н у. Ай Алла, харап булдык! Нишлибез?

А л ч ы н. Арысланы китте, аюы килә.

С ә л в и. Аюмы? Үлгән булып ятсаң, тими, ди.

Г ө л б а н у (*Сәлвигә*). Юкны сөйләмә, син инде бала түгел!

Х у җ а. Тимә, хатын, кыз дөрес сөйли, үземә охшаган, акыллы булыр. Йә, бар, калдырыгыз әле мине, тегендә чыгыгыз, чык.

Хуҗадан башкалар чыга.

Үлгәнгә аю тими! Ә? (*Тәхеткә утыра.*)

Г ы й м а й, а х у н, К о л ы й, Б и к и, Н и з а м ы й, С ә х и л ә керә.

Г ы й м а й. Ишеккә карый — һарыш! Һәйт, вәйт! (*Ишектән керә.*) Үрә кат! Биредә мин баскак! Кайда ул?

К о л ы й. Менә утыра, суй үзен, баскак!

Г ы й м а й. Тапта, туна, ас, кис! Үз кулым белән башыңны өзим!

Х у җ а (*вәкарь белән*). Мин булам Насретдин. Нәрсәгә дулыйсың син?

Г ы й м а й. Ә, эмм... хәзер генә Җиһангир хәзрәтләре очрап, шәһәрне миңа тапшырып китте. Менә кулымда мөһере.

А х у н. Көнең бетте, дәһри! Төш тәхеттән! Сал минем чапанны! (*Килеп ябыша.*)

Бики. Сал бикасапны! Кайда йөз алтын?

Колый. Сал хөлләне! Минем дә йөз алтын!

Сәхилә. Минем дә йөз алтын!

Бар да ябыша, салдыралар.

Гыймай. Үрә кат! Дөнья белән бәхилләш, Насретдин!

Хуҗа. Дөнья белән мин бәхил, үкенечен куймадым, менә хатын белән, белмим. Рөхсәт итегез, аның белән бәхилләшеп чыгыйм.

Гыймай. Сиңа бер минут!

Хуҗа чыга.
Бераздан елаш ишетелә.

Нинди елаш анда? Карагыз?

Гөлбану (*кулында буш ташаяк, елап керә*). Ләгънәт төшсен, сезнең өчен шушы яшемдә ирдән калдым... Аh! Аh!

Гыймай. Миңа таба карап сөйлә, ни булды?

Гөлбану. Яныма чыкты, уф, янам, Гөлбану, дип, шушы торган ташаякны күтәреп эчүе булды...

Низамый (*ташаякны алып*). Шунымы?.. Карагыз, Алланың күрсәткән гыйбрәте бу: үзенә әзерләнгән агуны үз кулы белән күтәреп эчкән!..

Колый. Төбенә кадәр чүмергән бу!

Хаммат, Алчын, сачтараш, Сәлви, Зөбәрҗәт Хуҗаның паласка салынган гәүдәсен күтәреп чыгалар.

Гыймай. Куегыз!

Хуҗаны идәнгә сузып салалар.

Ахун. Гөнаһсын дәвер кылдырырга кирәк. Фидиясен карарга кирәк. Мәрхүм дивана кеше иде. Кем өстендә булса да кичелмәгән бурычлары калмадымы?

Бики. Калды: иң элек, янчыгы белән хисаплап, йөз алтын.

Сәхилә. Минем дә йөз алтын.

Колый. Минем дә.

Гөлбану. Аh, аh!

Алчын. Һәммәгезнең дә шул бер йөз алтын бит инде ул. Аны да әнә казый әфәнде Хуҗа файдасына хөкем итте. Изге кеше рәнҗеп ятмасын, кичә алсагыз, бурычларыннан кичегез.

Гөлбану (*сызланып*). Аh!

Бики. Тагын илле өч сум, йорты миндә дигәндәй... Сәлви сылу хакына кичмәсәк...

Гыймай. Насретдиныгызны алыгыз да чыгып китегез моннан! Күтәрегез! Әнә сезгә ишек. Һарш!

Хуҗаны үзенекеләр күтәреп ишеккә юнәләләр.

Хаммат. Белмим, без бу ишеккә ничек сыярбыз?

Тавышлар. Күтәрә төшегез, җәмәгать! Төшерегез. Юк, алай да булмый. Куегыз әле мәетне... Ничек чыгабыз бу ишектән, җәмәгать!

Хуҗа (*иң элек бер тезе күтәрелә, бар да каты сискәнә, аннан үзе торып утыра*). Җәмәгать! Мин үзем исән вакытта әнә теге арт ишекне киң ачып чыгып йори идем. Шуннан алып чыгыгыз.

Картлар. Йа Алла! Йа Алла! Укыныгыз, укыныгыз!

Паника. Хуҗа кулларын сузып өсләренә килә.

Ахун. Әйберен сорый. Бирегез! (*Чапанын ыргытып, чигенеп бара.*)

Колый. Валлаһи, минеке түгел! Ал хөлләңне! Мә!.. (*Хөлләне ыргытып, артка чигенә.*)

Бики. Нинди куркыныч! Тотма, җибәр... Мә бикасабыңны! (*Бикасапны ташлап кача.*)

Сәхилә. Абау! Йөз алтыныц да кирәкми! А, аһ!

Качалар.

Гыймай (*чукмарын күтәреп*). Ай! Миңа килмә! Үрә кат! Алгары һарш!

Барысы да качып бетә.

Хаммат. Ха-ха-ха! Менә без җиңдек!

Хор (*Хуҗа Насретдинны уртага алып җырлыйлар*).

Яшә, яшә, Хуҗа Насретдин.
Син үлемсез халык хикмәте.
Һәр кыенны ерып чыгучы,
Көлке синца дөнья михнәте.

Яшьләр өчен шатлык син,
Картларга да тансык син,
Халык үлмәс — син үлмәс,
Мәңге яшә, Насретдин!

Пәрдә

1940 ел

Хуҗа Насретдин комедиясенең төзелеше

Әсәргә анализ ясарга керешкәнче, аның жанр үзенчәлеген белергә кирәк дип сүз куешкан идек. Шулай итик.

«Хуҗа Насретдин» әсәре — комедия. Гади комедия генә дә түгел, әкият-комедия. Өстәвенә бу әкият-комедиянең эче тулы халык авыз иҗатыннан алынган мәзәкләр. Шуннан чыгып, комедия төзелешенең өч үзенчәлеген икеләнмичә язып куя алабыз.

1. Тылсымлы әкиятләрдә ярлы кеше төрле сынаулар аша үтә-үтә, киртәләрне уза-уза, кемнәрнеңдер ярдәме белән патша була. (Төзелеш: түбәндәге югарыга менә, югарыдагы түбәнгә төшә.) Комедия сюжеты төзелешенең дә әкият төзелешенә охшавын үзегез исбат итегез.

2. Комедиянең конфликты буш кешеләрнең җитдилеккә дәгъва кылуыннан гыйбарәт. Колый тархан, ахун, Бики, Гыймай, Җиһангирның шундый кешеләр булуын исбат итегез.

3. Кире персонажларның дәгъваларын Хуҗа Насретдин үзенең мәзәкләре белән юкка чыгарып бара. Мәзәкләр бу персонажларның эчке бушлыгын ачалар, Хуҗа Насретдинны җиңүдән җиңүгә алып баралар.

Хуҗа Насретдин образы

Хуҗа Насретдин — җор, үткен телле, батыр, игелекле кеше. Аның дошманнарыннан саклану, якыннарына ярдәм итү һәм халыкны Җиһангир филеннән коткару кебек өч максаты бар. Хуҗа ниятләренең барысын да тормышка ашыра. Шул ук вакытта ул алдашудан да, хәйләдән дә, хәтта урлашудан да баш тартмый. Ул нәкъ халык мәзәкләре герое кебек үзен алдарга теләгәннәрне алдый, талаучыларыннан урлый, җәберләүчеләренә җәбер белән җавап бирә. Үзенә һөҗүм иткәнне көтеп ятучылардан түгел. Хуҗа Насретдин — актив көрәшче. Ул башлап дошманнарына үзе һөҗүм итәргә ярата. Тапкыр кеше буларак, дошманының ни эшләячәген чамалап, шуңа тапкыр җавабын алдан ук уйлап куя.

Хуҗа Насретдин — татар халкының тапкырлыгын, яшәү дәртен, игелек сыйфатларын үзенә туплаган җыелма образ. Игелеклеге, хөкемдарларның барысына каршы көрәш башлап җиңеп чыгуы, аны халык әкиятләрендәге идеал-герой белән тиңләштерә.

Әсәрнең субъектив эчтәлеге

Комедия вакыйгаларының кайчан, кайда баруына игътибар итик һәм Хуҗа Насретдин яшәгән шартларны әсәр язылган шартлар белән чагыштырыйк. Шулай итәргә безнең тулы хакыбыз бар. Нинди чор турында язса да, әдип ул чорга,— барыбер үзе яшәгән чор проблемаларын китереп кертә. Шулай итеп, ул йә үзен борчыган проблемаларны башкаларга да җиткерергә ниятли, йә аны үзенчә чишмәкче була, яисә заманга бәя бирә. Субъектив эчтәлек шул була, дидек.

Комедиядә тасвирланган заман белән әсәр язылган заманны чагыштырыйк. Хуҗа Насретдин Болгар дәүләтенең иң авыр елларында яши. Дәүләтнең бәйсезлеге югалган. Аны чит халык гаскәрләре басып алган. Халык тәмам бөлгән, чөнки баскыннарның үзләрен һәм аларның туя белмәс филен туйдырырга тиеш. Җиһангир — илдә хокуклары чикләнмәгән бердәнбер хаким. Андый хакимнәргә диктатор диләр. «Җиһангир» — бөтен дөньяны яулап алучы дигән сүз. Өстәвенә аның бер аягы чулак.

30 нчы елларда татар халкының язмышы борынгы Болгар халкы язмышына бик охшаган. Аның да мөстәкыйльлеге юк. Ә хөкемдары — бер кулы чулак, хокуклары чикләнмәгән диктатор. Утызынчы еллар диктаторының максаты да — бөтен дөньяны яулап алу — «Җиһангир» сүзенең эчтәлегенә туры килә. Татар халкы да, болгарлар соңгы ризыкларын филгә биргән кебек, чиксез зур налог бурычына соңгы малларын бирергә тиеш булалар. Бу елларны да, тарханнар, ахуннар, Бикиләр кебек, чиновниклар, баскыннар белән уртак тел табып, баскыннар идеологиясен үткәрәләр.

Күрәбез, элекке заман һәм 30 нчы елларның тормыш шартлары бер-берсенә бик охшаган. Икенче төрле әйткәндә, Нәкый Исәнбәт, тоталитар режимга үз бәясен бирү өчен, аңа юри болгарлар тормышын охшаткан. Җиһангирлар заманында ничек булса, тормыш хәзер дә шулай, ди автор, күптәнге вакыйгаларга бәя биргән булып, үз заманына бәя бирә.

Нәкый Исәнбәт ике чор тормыш шартларын охшаткан, ләкин шул ук вакытта аермасын да күрсәткән. Аерма нәрсәдә соң? Аерма — 30 нчы елларда Хуҗа Насретдин кебек халыкны актив яклаучы булмауда.

Хуҗа Насретдин халык хыялын һәм Нәкый Исәнбәт теләген җиренә җиткереп үтәгән дә үлгән. Ул юк, ә менә хаксызлык һаман яши.

Ике чорны чагыштыру безне шундый нәтиҗәгә китереп җиткерә. Шуннан соң әдипнең идеясен генә беләсе кала.

«Хуҗа Насретдин» комедиясенең идеясе нинди?

Җавапны үзегез табыгыз.

Биремнәр һәм сораулар

1. Теләсә нинди тылсымлы әкият сюжетын исегезгә төшерегез. Аның сюжетын бер генә вакыйгага калдырып сөйләп карагыз.

2. Шул бер вакыйганы «Хуҗа Насретдин» комедиясенең сюжеты белән чагыштырыгыз. Уртаклыгын һәм аермасын күрсәтегез.

3. Колый, ахун, Бики, Гыймай, Җиһангирларның дәгъвалары турында сөйләгез.

4. Хуҗа Насретдин дошманнарының дәгъваларын нинди юл белән юкка чыгара?

5. «Проблема» атамасының эчтәлеген исегезгә төшерегез. «Әсәрнең субъектив эчтәлеге» бүлегендә авторның өч нияте саналган: үзен борчыган проблемаларны куюы, аларны үзенчә чишәргә тырышуы һәм тормыш вакыйгаларына бәя бирүе, диелгән. Комедиядә шул ниятләрнең кайсысы бар?

6. Хуҗа Насретдинны ни өчен җыелма образ дибез?

7. Хуҗаны үткен фикерле кеше, дидек. Аның үткен фикерле булуын исбат итегез.

8. Нәкый Исәнбәт комедиясен ни өчен әкият сюжетына корган?

ЙОМГАК

Гражданнар сугышы елларында иҗат иткән язучылар революция тудырган җиңү пафосын күрсәтә алдылар. Моның өчен алар романтизм методының яңа мөмкинлекләрен ачтылар: теләкне ышаныч, ышанычны чынбарлык итеп тасвирладылар. Шуңа күрә бу еллар романтизмы матур өметләр, бәхетләр, шатлыклар белән чорналган иде.

Шуның белән бергә, революцион романтизм юнәлеше халыкны көрәшкә, дөньяны яулап алырга чакырды, вату, җимерү турында рухланып язды, кешеләрнең нәфрәт хисен мактады. Әмма татар әдәбияты мондый тайпылышларга сизгер булды. Әдипләр сугыш елларында кешеләрдә арта барган нәфрәт хисенә борчылдылар, кансызлыкларына каршы көрәштеләр. Хәтта гражданнар сугышы еллары кебек авыр елларда да кешеләрнең иманын саклап калырга тырыштылар. Революция дә, сугыш та татар әдәбиятын тоткан юлыннан читкә бора алмады.

20 нче еллар әдәбияты (20—25 еллар) яңа тормышта яңа эчтәлек, шул эчтәлекне ачарлык яңа алымнар эзләү еллары булды.

Гражданнар сугышы тәмамлану сәбәпле, бу елларда дошман югалып торды. Көрәшне дәвам иттерү өчен, аны каяндыр табарга кирәк иде. Революцион романтизм тарафдарлары хәзер иясез явызлыкка каршы ябырылдылар. Ул явызлык җирдәге гаделсезлек, шәфкатьсезлек, гомумән хаксызлык иде. Гомумән хаксызлыкны әдипләр тормышның авырлыгына да, үтәлмәгән вәгъдәләр өчен дә гаепле иттеләр. Әдипләрнең берише аны күктән төшерделәр, кемдер җирдән үстереп чыгарды, кемдер явызлык, хаксызлык дигәндә, хакимиятне күз алдында тотты. Явызлык күп эчтәлекле, күзаллавы кыен булган бер күренеш иде. Икенче төрле әйтсәк, ул кешеләрнең ачу, үпкә, үч хисләренә төренгән ризасызлык иде.

Явызлыкка каршы үзләре генә көрәшкә күтәрелүчеләр дә бар иде. Алар үзләрен гыйсъянчылар дип атадылар.

Әдәбиятның революцион романтизм юнәлеше бермәлне үзенең революционлыгын шул рәвешле күрсәтте.

Алай да дошманына исем табарга кирәк иде. Һәм шулай булды да. Яңа дошман иске тормыш һәм аның калдыклары булып чыкты. Дин, сәнгать, әдәбият, гореф-гадәтләр, хәтта гаилә дә — бар да иске тормыш, ягъни буржуазия барлыкка китергән яманлыклар дип саналдылар.

Көрәш нәтиҗәсендә юкка чыккан искелек урынын пролетариат сәнгате, пролетариат әдәбияты, гадәтләре, гаиләсе алырга тиеш иде. Ләкин теләсә нинди яңалык иске нигезендә генә туа ала. Бушлыкта яңа сәнгать тә, әдәбият та туа алмады. Иске мәдәниятне җимереп, аның урынына өр-яңа пролетариат мәдәниятє төзергә тырышучыларга пролеткультчылар диләр.

Бу елларда революцион романтизм юнәлеше кризис кичерә. Язар өчен тема һәм пафос таба алмый. Үзләрен символистлар, футуристлар, имажинистлар дип йөртүче әдипләр барлыкка килә. Алар үзләрен яңа әдәбиятны тудыручы кешеләр дип белдерәләр. Яңа әдәбиятның яңа темасы итеп хезмәт дәртен сайлыйлар. Заводларның кара төтенен мактыйлар, тимергә тимер бәргән, машина эшләгән тавышлар шигырьләрнең яңа яңгырашын тәшкил итәргә тиеш булалар. Әмма татар әдәбияты үз юлы белән баруын дәвам итте.

20 нче елларда куәтләнеп киткән реализм юнәлеше тормыштагы яңа эчтәлекне әдәбият мирасыбызга таянып ачты. Тормыштагы яңа күренешләргә бәя биргәндә, электән килгән рухи кыйбласын югалтмады. Нинди генә авырлыкларда да кешеләрнең кеше булып калуларын сурәтләде, кешеләрне бер-берсен яратырга, бер-берсенә ярдәм итешергә чакырды.

Бу елларда иҗат иткән әдипләр тормыш авырлыкларының вакытлы күренеш булуына, кешеләрне бәхетле, азат итәчәк матур киләчәкне күрә алачакларына ихлас күңелдән ышандылар. Ул вакытта коммунизм дип аталган бәхет дөньясын матурлык итеп сурәтләделәр.

20 нче еллар әдәбиятның реализм юнәлеше өчен дә яңа эчтәлек, яңа алымнар эзләү еллары булдылар. Асылы ачылып җитмәгән идеология белән тормыш арасындагы каршылыкны әдипләр хыяллары белән чишәргә тырыштылар. Авыр тормыш эченнән киләчәк чалымнарын эзләделәр. Шул ук вакытта ачлык елларының фаҗигасен сурәтләделәр. Бу елларда реализм юнәлеше романтизм һәм натурализм методлары белән үзара ярәшеп яшәделәр. Әдипләр тормышның катлаулы күренешләрен сурәтләү өчен яңа стиль эзләделәр.

30 нчы елларда да татар әдәбияты үзенең ике юнәлештә үсүен дәвам итте. Революцион романтизм юнәлеше «революцион» дигән сыйфатын саклап калырга тырышты. Динне сүгүне дәвам итте, ачуы килгән бер күренешне искелек дип, буржуазия калдыгы дип орышты. Еллар үткән саен идеология бу юнәлешне яңадан-яңа дошманнар белән тәэмин итеп торды. Хәзер бу юнәлеш кулакларга каршы көрәшә башлады. Кулакны мәкерле, астыртын, ерткыч, саран итеп күрсәтте. Әдәби әсәрләргә корткычлар кереп тулды. Алар да, кулаклар кебек, гел этлек кенә эшләп тордылар, яхшы кешеләр аларны бик оста фаш иттеләр. Әдәби әсәрләр шул рәвешле бер-берсенә охшадылар. Алар геройларының исемнәре һәм корткычларның кылган юньсезлекләре белән генә аерыла башладылар. Әдипләрнең берише тормышны аллы-гөлле бәхет бакчасы итеп күкләргә күтәреп мактады. Дошман белән көрәшүче батыр янына, әсәрнең төп герое булып, көн-төн эшләүче эшче персонажы килеп басты.

Болар берсе дә язучылар үзләре уйлап чыгарган уйдырма түгел иде. Әдипләр чын күңелләреннән тормышны социалистик метод белән үзгәртеп язам дип ышандылар. Яшәешне шул рәвешле бозып сурәтләү, чыннан да, тормыш үзе иде, чөнки шулай язуны таләп иткән идеология үзе тормышның аерылгысыз бер өлеше, бердәнбер хакыйкать дип аңлатылды. Шуңа күрә идеология белән тормыш арасындагы каршылык кешеләргә тагын да ачыграк күренә башлады.

Хакимият язучыларны да идеологиягә хезмәт иттерергә тырышты. Яманны яхшы дип, яхшыны яман дип язарга боерды.

Гаделлек белән гаделсезлек, ялган белән хакыйкать арасындагы чикләрнең югала баруын иң элек зирәк Фатих Әмирхан күреп алды. «Шәфигулла агай» хикәясендә идеологиягә ярашуның телне дә, әхлакны да, шуның белән милләтне дә бетерүен алдан күреп язды.

Гаделлек-гаделсезлек Һ. Такташ иҗатының төп темасына әверелде. М. Галәү, үзенең Саҗидәсен Төркиядә калдырып, татарларны оештырырлык көчнең юклыгын әйтеп куйды. Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Тинчуриннар макталырга гына тиешле тормышның ямьсез яклары турында яздылар.

Әйтергә ярамаган хакыйкатьне икенче эчтәлек итеп оештыру максатыннан чыгып, әдәбият стилен үзгәртте. Әсәрләрдә фокуслар артты, метафора-сурәтләр, метафора-вакыйгалар күбәйде. Кабатлаулар аша авторлар әйтәсе килгән сүзләренең иң әһәмиятлеләренә төртеп күрсәттеләр.

30 нчы елларда татар язучыларының күбесе — иң кыюлары, иң талантлылары кулга алынды. Алар язган китаплар юкка чыгарылды. Ул китапларны уку катгый тыелды. Әмма Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Х. Туфаннар язган әсәрләр, татар әдәбиятының төп юнәлешенә маяк булудан туктамадылар. Кыйналган, йончылган әдәбият, нык басып, Ватан сугышы чорына керде.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш 3

ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Әдәбиятта көрәшкә чакыру идеясе

Мәҗит Гафури

Кызыл байрак 10

Шамун Фидаи

Тукай 11

Җырла әле 11

«Мөкатдәс хәнҗәрем төшмәс кулымнан...» 12

Мәхмүд Максуд

Изге көрәшкә 12

Каравылда 14

Фәтхи Бурнаш

Чәчәктән һәйкәл 15

Галиәсгар Камал

«Кызыл алма» китабы 19

«Бәдәвам» китабы 20

Яңа «башмак» көе 20

Татарча 20

Әдәбиятта әхлак темасы

Галимҗан Ибраһимов

Яңа кешеләр 22

20—30 НЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

20 нче еллар әдәбиятында революцион романтизм юнәлеше

Гадел Кутуй

Карт пычкычы 43

Кави Нәҗми

Ике ант 44

Мансур Крыймов

Көрәш кочагында 44

Демьян Фәтхи

Йолдызлар 45

20 нче еллар әдәбиятында реализм юнәлеше

Фатих Әмирхан

Шәфигулла агай 48

Һади Такташ
Нәләт ... 64
Кояш күктә шулай мәңге йөзәр ... 68
Такташ үлде ... 69
Ертык бүрек ... 71
Болай... гади җыр гына ... 72
Хәсән Туфан
Барабыз ... 83
Тегеләрнең кызы ... 84
Бездә туа яңа кешелек ... 86
Лу-и-зааа... ... 87
Озату ... 88
Ак каен ... 89
Су астында бер егет бар ... 90
Ә йолдызлар дәшми ... 91
Узып барышлый ... 92
Сәлам әйтегез ... 96
Галимҗан Ибраһимов
Тирән тамырлар ... 100
Гомәр Бәширов
Сиваш ... 138
Гадел Кутуй
Тапшырылмаган хатлар ... 172
Мәхмүт Галәү
Болганчык еллар ... 194
Мөһаҗирләр ... 226
Таҗи Гыйззәт
Чаткылар ... 281
Газиз Гобәйдуллин
Форточкалы кәләпүш ... 305
Ул мактанмыйдыр иде ... 308
Бу милләт ничек тәрәккый итсен? ... 309
Скрипкачы Хөсәен ... 311
Мирсәй Әмир
Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре ... 319
Фаҗигале мәхәббәт ... 335
Тыр-тыр Зариф бригадасы ... 336
Нәкый Исәнбәт
Син сазыңны уйнадың ... 339
Бер пейзаж ... 340
Аккош ... 341
Хуҗа Насретдин ... 341

Йомгак ... 370

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник по татарской литературе для 10 класса
татарской средней общеобразовательной школы

Издание третье

Казань. Издательство «Магариф». 2007

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
10 нчы сыйныфы өчен дәреслек

Өченче басма

Редакторы *З.М.Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л.С.Золондинова*
Рәссамы *Ю.А.Денисов*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Л.М.Тиляк*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Л.Р.Вафина*
Корректоры *С.З.Гыймалетдинова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 0111.2007.
Форматы 60×90⅟₁₆. Офсет басма. «Школьная» гарнитурасы.
Басма табагы 23,5 + форз. 0,25. Нәшер-хисап табагы 22,8 + форз. 0,38.
Тиражы 5200 д. Заказ С-1132.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20 а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.


Фокус

Иҗтимагый аң



Тип